

КӘРИМ ТИНЧУРИН

# ПЬЕСАЛАР

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2021

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
Т46

*Татарстан Республикасы Президенты каршындагы
Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм
«Татнефть» хәйрия фондының «Рухият» программасы
ярдәме белән эшләнде.*

**Тинчурин, К. Г.**

Т46 Пьесалар / Кәрим Тинчурин ; [төз. Р. Ваһапова]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2021. – 582 б.
ISBN 978-5-298-04198-0

Татар әдәбияты классигы, драматург Кәрим Тинчуринның әлеге китабында танылган пьесалар урын алды.

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6

ISBN 978-5-298-04198-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2021
© Ваһапова Р. Г., төзү, 2021

# САКЛА, ШАРТЛАМАСЫН!..

*Комедия*

*Дүрт пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Шакирҗан – татар бае.
Габбаса – аның хатыны.
Шәрифҗан – аларның уллары.
Мөршидә – Шакирҗанның кардәш кызы.
Мортаза бай – Шакирҗан байның дусты, бик юан кеше.
Мансур – газета идарәсендә эшләп йөрүче яшь язучы.
Ибраһим – Мансурның иптәше.
Садрый – бозык байбәтчә.
Сәляхетдин – байбәтчә.
Николай Александрович – пристав, бик юан кеше.
Сәйфетдинов, Фёдоров, Шымчы – бутишниклар.
Гыйлаж бабай – Шакирҗан байның дворнигы.
Нурмөхәммәт – Шакирҗан байның типографиясендә эшче.
Сәгатьче.
Әби – Мансурның бүлмә хуҗасы.
Гөлҗамал – Шакирҗан байның асравы.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Байлар дачасы. Уртада алтын шарлы челтәр капка. Сулда тәрәзәле һәм пыяла ишекле зур терраса. Уңда дача эскәмиясе. Сулда өстәл һәм урындыклар. Куе урман. Кояшлы, бик якты көн.

I. Гыйлаж бабай ялгызы.

Гыйлаж бабай *(капка янында)*. Көш, көш, юньсезләр! *(Җирдән таш алып.)* Монда сезгә ни калган? Үз йортыгыз тармыни? Көш, көш, дим, әрсезләр. *(Тагын таш алып бәрә.)*

Мансур килеп керә. Таштан куркып кала.

II. Гыйлаҗ бабай һәм Мансур.

Мансур. Чү, бабай? Ни эшлисең? Башны ярырсың.

Гыйлаҗ бабай *(куркып)*. Ялгыш, энем, ялгыш. Тавыкларны куадыр идем. Йөдәтеп бетерделәр.

Мансур. Суярга кирәк үзләрен. Кем тавыклары соң?

Гыйлаҗ бабай. Күрше тавыклары. Көнозын шунда чуалалар.

Мансур. Чуалсалар ни, рәхәтләнсеннәр. Сиңа уңайсызламый торганнардыр ич?

Гыйлаҗ бабай. Бай ачулана. Кеше тавыкларын кертергә кушмый. Әтәче — бигрәк усал нәрсә. Безнең әтәчне кыерсыта. Безнең әтәчнең токымы яхшы булса да, яшь әле. Күрер күзгә зур булса да, көче азрак шул. Күршенеке карт әтәч, килеп-килеп безнең әтәчне талап китә. *(Тавыкларны күреп, борылып.)* Көш, көш!.. Ни калган сезгә монда? Көш, дим, зимагурлар! Көш, дим, юлбасарлар!.. *(Таш алып бәрә.)* Көш, дим!..

Мансур. Байлар өйдәме?

Гыйлаҗ бабай. Карт бай шәһәрдән кайтып җитмәде әле.

Мансур. Бикәләр өйдәме?

Гыйлаҗ бабай. Өйдә.

Мансур. Тагын кемнәр бар?

Гыйлаҗ бабай. Нигъмәтҗан шәһәргә байны алып киткән иде. Иртәгә кызлар да бәйрәмгә хәзерләнергә китәчәкләр, мин дә шәһәргә кайтам. Мунча керәсе бар. Бәйрәм бит, ахрысы. Байның иске читеген бирергә булган иде әле бикә. Гает намазына читек киеп барырмын дип торам. Юкса итек тәмам эштән чыкты инде. Яхшы итек иде. Тузды шул, тузды.

Мансур. Тузса, баеңнан яңаны сорарга кирәк.

Гыйлаҗ бабай. Безгә, картларга, кайда инде яңа итекләр! Нигъмәтҗан көне-төне үзе белән бергә йөрсә дә, аңар да әле яңаны алып бирми. Байның быел расходлы елы шул. Яңа итекләр даулап булмый инде. Көзгә чыдаса, кыш өчен кайгырмыйм. Кышны чабатадан да уздырып була аны. Көз көне пычракта карт кешегә уңайсызрак. Миндә риматиз чире бар дип әйтәләр. Аяклар сызлый. Риматиз юешкә ярамый икән. Көзгә кадәр итекләр таралып бетмәсә ярар иде. Дегетләп, һәйбәтләп чормага куйган идем. Көзгә чыдаса, кыштан курку юк. Кыш көне су ташыганда, итек уңайсыз була. Көзгә чыдаса, кыштан,

Алла боерса, курку юк. Тәндә җан булганда, салкынга бирешмисең аны. Кыштан курку юк, Алла боерса.

М а н с у р. Бабай, сиңа ничә яшь?

Г ы й л а җ б а б а й. Яшь дигәндә, яшькә байлык зур. Югары оч Хисами белән бер елны каралдык. Менә аның инде гүр иясе булганына, уракка төшкәндә, нәкъ унбер ел була. Миңа дә күптән вакыт инде дә, ризык бетмәгән булгач торасың икән шул. Карчыкны җирләгәнгә, бәрәңгеләр казыганда, нәкъ унсигез тула. Яшькә байлык зур. Аллага тапшырып җиденче кибәнне башладык инде.

М а н с у р. Нәрсә дисез?

Г ы й л а җ б а б а й. Җиденче унга керештек инде. Көлтәләр җыйганда, алтмыш дүрт була.

М а н с у р. Мин сезгә йөз яшь бардыр дип торам.

Г ы й л а җ б а б а й. Йөзгә кадәр торып булмас инде. Менә син мине унбиш ел элек күрсәң иде… Мин, пристаньда эшләгәндә, егерме потны эһ тә итмичә күтәреп пароходка кертәдер идем. Хәзер беттек инде. Балаларның кайгысы картайтты.

М а н с у р. Ни булды балаларга?

Г ы й л а җ б а б а й. Кыз балаларны, Аллага шөкер, башкардык. Ир балалардан бәхет булмады.

М а н с у р. Тәүфыйксыз булып чыктылармы әллә?

Г ы й л а җ б а б а й. Ул яктан, Аллага шөкер, балаларга үпкәләр хәл юк. Балалар менә дигән егетләр иде. Зур улым Низаметдин исемле иде. Шул Низаметдин, мескен, шахтада җир астында күмелеп калды. Гәүдәсен дә таба алмаганнар. Икенчесе Шакир атлы иде. Анысы күрше авыл алпавытында бик яхшы урында торадыр иде. Арыш суккан вакытта машинага кысылып, кулын бөтенләй эштән чыгарды. Барлыгы өч атна авырып, гүр иясе булды. Яшьләр үлгәнче, мин үлсәм, яхшырак булыр иде бит, Алланың язмышына каршы барып булмый. Күрәсең, җир өстендә ризыклары беткән инде. Балаларның игелекләрен күрергә язмаган, күрәсең. Кыз балалар да ирләре янында, Уралда, алтын базларында торалар. Ахыргы көннәремдә япа-ялгыз калдым. Алла шулай язган, күрәсең. Берни итәр хәл юк.

М а н с у р. Үлгән балаларың өчен акча ала алдыңмы?

Г ы й л а җ б а б а й. Акча чыгар, дип әйткәннәр иде. Без надан халык рәтен белмәгәч китереп бирүче булмады. Алпавыт марҗасы гына, Шакирым үлгәч, күмәренә дип, ун сум акчалата, өч пот он биргән иде. Башка нәрсә бул-

мады. Судлашып йөрсәң дә, барыбер шул инде. Безнең, мужикның, сүзен кем тыңлый... Бай булсаң инде, бер хәл. Прошение яздырырлык суман булмагач, кая барсаң да, рәт юк инде безнең халыкка. Адвокат ялларга әйткәннәр иде, әлеге фәкыйрьлек аркасында ул да эшләнмәде. Ихи-хи-хи!..

М а н с у р. Шакирҗан байда күптәннән торасыңмы?

Г ы й л а ж  б а б а й. Көзгә ун ел тула.

М а н с у р. Күпме жалованье аласың?

Г ы й л а ж  б а б а й. Кая инде ул жалованьелар! Менә пристаньда йөк ташыган вакытларда көненә йөз егермешәр тиен төшергән чаклар була иде. Ул вакыт яшь идем әле. Хәзер картайдык инде. Мин бит хәзер авыр эшләргә ярамыйм. Өс-башны карыйлар. Тамак тук. Миңа хәзер инде артыгы кирәкми дә. Бай да, бикә дә, үлгәч яхшылап җирләрбез, диделәр. Өчен дә, җидесен дә, кырыгын да яхшылап, муллаларга сәдакалар биреп, Коръән укытып уздырырбыз, диделәр. Миңа шунысы булса, башкасын сорамыйм инде. Алла кабул итсен. Торасын тордык инде. Кеше кулында булу белән ахирәт якларын бер дә рәтләп булмады. Гөнаһы күп инде. Тапшырдык.

М а н с у р. Бер дә курыкма, бабай. Мондагыдан кыен булмас әле.

Г ы й л а ж  б а б а й. Булмасын инде. Юкса дөньяда да михнәт, ахирәттә дә тәмуг булса, кыенрак шул. Әнә байларның эше җайлы. Дөньяда да рәхәт, ахирәттә дә аларның җайлы булыр.

М а н с у р. Ни өчен алай дип уйлыйсың?

Г ы й л а ж  б а б а й. Байлар намазын укый, зәкятен бирә, сәдакасын бирә. Хаҗына бара, корбанын чала. Аңар мулласы да, ишаны да догасын бирә. Ә безнең ишеләр догасыз, фатихасыз, гөнаһка чумып, каралып бетәсең.

М а н с у р. Укый беләсеңме?

Г ы й л а ж  б а б а й. Һи, каян беләсең аны! Безнең заманда ул юк иде. Әтидән яшьли ятим калдык. Унике яшьтән бирле кеше кулында. Рәтләп догаларны да белеп булмый. Үлгәч, анда сорарлар.

М а н с у р. Кайда?

Г ы й л а ж  б а б а й *(бармагы белән җирне күрсәтеп)*. Тегендә.

М а н с у р. Кемнәр?

Г ы й л а ж  б а б а й. Ни инде... сораячаклар инде.

М а н с у р. Соң кемнәр сораячаклар?

Г ы й л а ж  б а б а й. Әллә...

М а н с у р *(бармагы белән җирне күрсәтеп)*. Анда балчыктан башка беркем дә юк.

Г ы й л а җ б а б а й. Юк?

М а н с у р. Юк!

Г ы й л а җ б а б а й. Көш, дим, зимагурлар! Кая киләсең тагын? Хәзер бай кайтыр бит. Әллә бәреп тәпиләреңне сындырганны көтәсеңме? Көш! Тәмуг кисәве!.. Көш, дим, рәхмәт төшкере!..

М а н с у р *(тәмәкесен чыгарып)*. Бабай, тәмәке тартасыңмы?

Г ы й л а җ б а б а й. Юк, андый эшләргә, Аллага шөкер, өйрәнеп булмады. Ашап-эчеп, тәмәкеләр дә тарта башласаң, кая инде ул безгә. Андый эшләр безгә кул түгел. Син соң үзең кем буласың?

М а н с у р. Минем исемем Мансур.

Г ы й л а җ б а б а й. Бай баласымы? Сәүдәдәме?

М а н с у р. Юк, мин дә крестьян баласы.

Г ы й л а җ б а б а й *(гаҗәпләнеп)*. Крәстиэн малае? Соң монда нишләп кенә торасың?

М а н с у р. Газетада эшлим.

Г ы й л а җ б а б а й *(гаҗәпләнеп)*. Алай!.. Ул гәзит дигәнне син язасыңмы?

М а н с у р. Әйе, шул язучыларның берсе булам.

Г ы й л а җ б а б а й. Алай... Байга килгән идеңмени? *(Тора.)*

М а н с у р. Әйе.

Г ы й л а җ б а б а й. Гәзит китердеңме әллә?

III. Ә ү в ә л г е л ә р һәм М ө р ш и д ә.

М ө р ш и д ә *(өйдән чыгып, Мансурны күреп аптырап кала)*. Бабай, казан астына утын керт әле!

Г ы й л а җ б а б а й. Утын? Ә, әйе, утын шул. Онытканмын. Картлык шул. Ухху-ху-ху... *(Сөйләнеп чыгып китә.)*

IV. М а н с у р һәм М ө р ш и д ә.

М ө р ш и д ә *(Мансур янына килеп, як-ягына карап)*. Мансур, бу ни эшең инде?

М а н с у р. Нәрсә? *(Кулын бирә.)*

М ө р ш и д ә. Көпә-көндез монда нигә күренәсең? Икебезне дә хур итәсең бит.

М а н с у р. Борчылма, Мөршидә, мин сиңа килмәдем.

М ө р ш и д ә. Миңа килмәдең?

М а н с у р. Асылда, мин сиңа килдем, әмма өстән караганда мин сиңа килмәдем.

М ө р ш и д ә. Син ни сөйлисең?

М а н с у р. Мин, теге хикәянең акчасын сорарга дип, Шакирҗан байга килдем. Өстән караганда бу шулай. Асылда, сиңа килдем. Бабай, барысы да шәһәрдә бәйрәмгә хәзерләнергә киттеләр, дигәч, син дә шәһәргә киткәнсең дип уйлаган идем. Менә нәрсә, җаный, мин бүген монда Ильяс әфәнделәрнең дачасында кунам. Уңай вакыт таба алсаң, барып чык. Менә теге әйткән китап шул инде. *(Китап бирә.)*

М ө р ш и д ә. Күрше-колан күрмәсә генә ярар иде. Дәү абый да хәзер кайтыр. *(Куркып карана.)*

М а н с у р. Тукта әле, Мөршидә, син көннән-көн бозыла барасың. Бераз батыррак булырга кирәк. Син бит кеше. Кешелек хакыңны җуймаска тиеш.

М ө р ш и д ә. Сизелсә, яхшы түгел. Болай да әле дәү абый бу арада гел ачуланып тора.

М а н с у р. Кара әле, Мөршидә, батыррак бул. Үзеңне шулардан кыерсыттырма. Әллә алардан башка тора алмабыз дип уйлыйсыңмы? Төкер барысына да!.. Ярый, хуш, Ильяс әфәнделәргә кил. Мин хәзер шунда барам. Сине көтәрмен.

М ө р ш и д ә. Кара әле, Мансур, мин бүген өйдән чыга алмыйм шул. Син иртәгә үзең шәһәрдәге йортка кил. Дәү абый да, Габбаса апа да дачада калачак. Мин асраулар белән генә өйдә булырмын. Шунда яхшылап сөйләшеп, бер карарга килербез. Үзем дә монда торудан тәмам туйдым инде. Дәү абый атлаган саен тирги, җикеренә. Тизрәк өстеннән җибәрәсе килгәнне аңлата. Кияү дә табып куйганнар бугай инде. Теге Мортаза байның Садрыен беләсеңме?

М а н с у р. Әллә шул бозык малайга бирмәкчеләрме?

М ө р ш и д ә. Үз кызлары булмагач, аларга кем булса да булсын. Тик бай булып, придан гына сорамасын. Садрый да бу арада тәмам бер имгәк булды инде, һичбер яры чыгар хәл юк, бәйләнә... Әллә нинди сөю хатлары язган була. Мәсхәрә итмәсә генә ярар иде. Бик усал дип әйтәләр үзен.

М а н с у р. Юк өчен борчылма. Бернәрсә дә булмас. Ләкин мин шунсына аптырыйм: Шакирҗан бай ни дип ул Садрыйга сине бирмәкче икән?

М ө р ш и д ә. Ни өчен булсын, придан бирмәс өчен. Әткәйнең өлешен, шулай итеп, үзендә ябып калмакчы, ди. Зарифа җиңги дә шулай дип әйтә.

М а н с у р. Юк, аның өчен булмас. Мин бөтенләй киресен уйлыйм.

М ө р ш и д ә. Шул, шул, Зарифа җиңги дә шулай ди. Кара әле, Мансур, әткәй өлешен бирмәсә нишләрбез?

М а н с у р. Мөршидә, син һаман әле шул юк-бар фикерләреңне башыңнан чыгарып ташлый алмыйсың икән. Бирсә бирә, бирмәсә бирми. Нәрсә аның өчен пошынырга? Әллә ачка үләрбез дип куркасыңмы? Менә минем һичбер кесәмдә бер тиен акчам булмый. Шулай булса да торам әле. Ачка да үлгәнем юк, кеше каршысына барып хәер сораганым да юк. Ярый, хуш. Ильяс әфәнделәргә ничек тә килергә тырыш.

Уң яктан С а д р ы й күренә.

Юк-бар нәрсәләр өчен борчылма. Ярый, хуш!

V. М а н с у р, М ө р ш и д ә һәм С а д р ы й.

С а д р ы й. Исәнмесез, Мөршидә туташ! Нихәл син, эшчеләрне баетучы хәерче? Ха-ха!..

М а н с у р. Мөршидә туташ, мин сезнең дачагызда этләр юк дип торган идем.

С а д р ы й. Шул, шул, «пролетариат», «товарищ», чабуыгызны җыебрак йөрегез бу тирәдә.

М а н с у р. Әллә чабуга ябыша торган гадәтегез дә бармы?

С а д р ы й. Буталып йөргән чабуларны бездә бик тиз кыскарталар. Ха-ха!..

Мөршидә, читкә барып, эскәмиягә утыра, китабын укыган була.

М а н с у р. Чабуга ябышучыларга бездә таяк белән җавап кайтаралар.

С а д р ы й. Таякның ике башы бар бит, «товарищ»! Ха-ха!..

М а н с у р. Дөрес әйттегез, Садрый бай, ике башлы. Берсеннән тоталар, икенчесе белән... *(Таягын бутап ала.)*

С а д р ы й. Сез сугышырга хәзерләнмисезме тагын? Ха-ха!

М а н с у р. Кем белән?

С а д р ы й. Белмим, кем беләндер.

М а н с у р. Алай булгач?

С а д р ы й. Шул шул. Сезгә бераз чабуыгызны җыя төшебрәк йөрү дә зарар итмәс иде, дим.

М а н с у р. Бер мәртәбә ишеткән идек инде ул хәбәрне.

С а д р ы й. Үзегез өчен яхшырак булыр, дим.

М а н с у р. Сез үзегезне яхшырак карагыз. Докторга барырга соңга калмагыз.

Садрый. Нәрсә?!

Мансур. Докторга барырга соңга калмагыз, дим.

Садрый. Соңга калсак, без аны үз өебезгә китерә алабыз. Ә менә сез, галахлар шайкасы, үзегезнең урыныгызны белергә тиеш идегез. *(Үртәп.)* Дачага килдек, диең, ә? Байларны сүксәк тә, аларның тормышларына карап, авыздан селәгәй ага, диең, ә? Ха-ха!

Мансур. Ә сезнең кебек юләр балыклар туганнан ук селәгәй авыз булып туганнар.

Садрый. Син бу сүзләреңне әнә тегендә, кер юучы пролетаркаларыңа барып сөйлә. Бай кызлары алдында, байлар йортында мондый сүзләрне сөйләргә килешми. Бу әдәпсезлек була. Дорфалык була, «товарищ».

Мансур. Нәзакәт хакында сезнең шикелле юләр балыклар үгет бирә башласалар, кояш кире яктан килеп чыкмасмы соң?

Садрый. Әй, синең ише правосыз галах белән сөйләшеп торуы да хурлык. *(Мөршидәгә табан борылып.)* Мөршидә туташ, бүген көймәдә чыгабыз. Компаниянең түрендә сез булырсыз.

Мансур. Койрыгында сезме?

Садрый. Молчать! Син сөрлеккән белән сөйләшмиләр. Бик талашасың килсә, әнә безнең этнең хәзергә эше юк. Ул сине компаниягә кабул итәр. Аның да правосы юк, синең дә. Нәкъ чиләгенә күрә капкачы инде. Ха-ха!..

Мансур. Ә бездә сезнең шикеллеләрне «праволы ишәк» дип йөртәләр. Бу правоны сездән беркемнең алырга хакы юк.

Садрый. Шулай, Мөршидә туташ, вәгъдәме?

Мөршидә. Нәрсә, нинди вәгъдә?

Мансур. Мөршидә туташ, саташа ул.

Садрый. Без, саташканда да, сездән тирәнрәк йөзәбез.

Мансур. Кабактамы?

Садрый. Безгә, туган, кабакта да урын түрдә, думада да урын түрдә. Ә сезгә бер генә түр бар. Ул теге, капкасына тәре асылган йорт. Беләсең бугай син аны? Ха-ха!.. *(Үткен сүзләр әйткән саен, Мөршидәгә «шәп әйттем бит» дигәндәй мактанып карап куя.)*

Мансур. Беләм мин аны. Ха-ха-ха!..

Мөршидә. Мансур әфәнде, китабыгыз өчен рәхмәт. Өйгә кермәдегез инде. Хәзергә сәламәт булыгыз!

Мансур. Мин Шакирҗан байны көтәм әле.

Мөршидә. Ә, әйе, шулай бит. Миңа өйгә керергә кирәк инде. Дәү абый озакламыйча кайтыр. Хәзергә хушыгыз! *(Китә башлый.)*

Садрый. Мөршидә туташ! Мөршидә туташ!

Мөршидә *(уңайсызланып кына яртылаш борылып)*. Нәрсә?

Садрый. Миңа җавап бирмәдегез?

Мөршидә *(коры гына)*. Нинди җавап?

Садрый. Безнең белән көймәдә чыга торгансыздыр бит? Бәдри байның кызлары да чыгалар. Артыгыздан керимме?

Мөршидә. Кермәгез. Мин чыкмыйм.

Садрый. Ни өчен?

Мөршидә җавап бирмичә кереп китә.

VI. Мансур һәм Садрый.

Мансур *(истиһза белән)*. Нихәл? Каптыгызмы?

Садрый. Син безгә карама. Без кабабыз да, шулай ук каптырабыз да.

Мансур. Мөршидә туташ тирәсе өчен саеракка ошый.

Садрый. Анысы безнең эш.

Мансур. Шулай инде, юләрләрне чәчеп үстермиләр. Аларны безнең бай йортлары хәзерләп кенә тора.

Садрый. Байларны сүксәк тә, бай кызларына карап селәгәй ага, диең, ә?

Мансур. Ага, диең, ә?

Садрый. Селәгәй агызып кына калыр да шул.

Мансур. Калыр, диең, ә?

Садрый. Галахлар шайкасы шул. Билләһи газыйм, галахлар шайкасы. Ха-ха!

Мансур. Ха-ха, диең, ә?

Садрый. Тукта әле, син шул хәерче башың белән ни дип, эт шикелле, байлар дачасы тирәсендә чуаласың?

Мансур. Син әле черегән башың белән дә чуаласың бит.

Садрый. Нәрсә, ни дисең?

Мансур. Черегән башың белән дә чуаласың, дим.

Садрый. Бу ни дигән сүз?

Мансур. Черегән дигән сүз.

Садрый. Бу хакта без синең белән бер очрашырбыз әле. Һәрбер узып барган зимагурга үземне кимсетергә рөхсәт итмәм.

М а н с у р. Сез үзегез баштанаяк кимчелек бит. Шакшының шакшылыгын исбат иткәнен дәлил итеп шакшылыкны алалар. Бу — табигый канун...

С а д р ы й. Бер очрашып, синең белән яхшылап хисаплашасы бар әле, егет. Без синең ише генә галахларны күргән.

М а н с у р. Без дә синең шикелле этләрнең койрыкларын кисә торабыз.

С а д р ы й. Ярый инде, Мөршидә туташ хөрмәтенә мин монда җәнҗал чыгармыйм. Икенче урында булса, син бу кыланышларыңның сумасын җилкәңә күтәреп алып киткән булыр идең.

М а н с у р. Хәзердән үк эшне бетерергә мөмкин. Нигә аны сузарга? Аннан соң нигә монда Мөршидә туташны катнаштырырга?

С а д р ы й. Таракан булырга азапланабыз, диең, ә? Ха-ха! Ләкин соңгарак калгансың, егет. Без алай пешкән җимешкә карап кына тормыйбыз.

М а н с у р. Шуннан соң?

С а д р ы й. Әүвәле-ахры шунда инде.

М а н с у р. Турыдан-туры әйтергә батырлыгыгыз җитми.

С а д р ы й. Андый эшләр белән мактануны бездә егетлеккә санамыйлар. Ә сез, Мөршидә туташ дип, селәгәегезне агызып тик йөрегез.

М а н с у р. Мөршидә туташның сезнең ише юләр балыклар белән эше бик аз аның.

С а д р ы й. «Эше беткәч»...

М а н с у р *(кызып)*. Нәрсә, нәрсә дидегез?!

С а д р ы й. Кәҗә белән кәбестә хикәясен ишеткәнегез бармы, дим? Ха-ха!

М а н с у р. Нәрсә?

С а д р ы й. Ишеткәнегез юк идемени?

М а н с у р *(ярсып)*. Син бер ятим кызны пычратырга ничек җөрьәт итә аласың? Мөршидә минем кәләшем икәнлегеннән хәбәрең юк идеме әллә? *(Шашынып кала. Тиз генә террасага барып.)* Мөршидә туташ! Монда чыгыгыз әле!

Садрый китмәкче була, Мансур аның юлына аркылы төшә.

Юк, сабыр итегез, чибәр егет! Без сезнең белән хисапны мәңгегә өзәргә тиеш.

М ө р ш и д ә чыга.

VII. Мансур, Садрый һәм Мөршидә.

Мөршидә. Мансур әфәнде, сез чакырдыгызмы?

Мансур. Мөршидә туташ, менә бу пычрак җан сезнең гыйффәтегезгә тап төшерерлек сүзләр белән сезне тәхкыйрь кыла. *(Садрыйга.)* Йә, Мөршидә туташ хакында миңа әйткән сүзләрегезне тәкрар итегез!..

Садрый. Юри тавыш чыгарып, сезне хур итмәкче була. Мөршидә туташ, ышанмагыз... Ялганлый ул...

Мансур. Шулаймы? Ялганлыймы? Менә, алайса, сезгә туры сүз! *(Яңагына суга.)* Җитәрме, әллә тагын кирәкме?

Садрый як-ягына карана да явыз елмаеп куя.

Мөршидә. Тукта, Мансур, син ни эшлисең?

Мансур *(Садрыйга)*. Әгәр дә яңадан кешеләрнең саф вөҗданнарына кара ягарга уйласаң, икенче төрлесе булыр. *(Мөршидәгә.)* Ярый, хуш, җаным, гафу ит инде! *(Садрыйга.)* Моннан соң телеңне тыя алмасаң, мин тыярмын... *(Китә.)*

Мөршидә өйгә керә.

VIII. Садрый ялгыз.

Садрый *(баскан җирендә озак катып калганнан соң, бармагы белән янап)*. Ярый, егет, без синең белән очрашырбыз әле.

Уйлана. Чыгып китә башлый. Шәрифҗан һәм Сәляхетдин очрыйлар.

IX. Садрый, Шәрифҗан һәм Сәляхетдин.

Шәрифҗан. Син монда икәнсең, без сине эзләп йөрибез.

Садрый китмәкче була.

Тукта әле, кая китәсең? Синдә йомыш бар иде.

Садрый. Нинди йомыш? Нәрсә тагы?

Шәрифҗан. Син безгә бераз акча биреп тор әле.

Сәляхетдин. Әгәр теләсәң, компаниягә үзеңне дә кушабыз.

Садрый. Нинди компаниягә?

Шәрифҗан. Аркадиягә чебиләр килгән. Араларында бер мөселман, бер төрек чебие дә бар. Только зур маркалардан. Аз акча белән рәт чыгарып булмый. Менә шулар белән тизрәк танышасы иде. Бик чибәр чебиләр.

Араларында бер гарәп кызы да бар. Мәккәдән туры килгән, ди. Тизрәк кулга алырга кирәк үзләрен.

Садрый. Йә?

Шәрифҗан. Шул, син берничә көнгә биш йөз сум биреп тор әле.

Садрый *(коры гына)*. Бирә алмыйм.

Шәрифҗан. Ни өчен?

Садрый. Иске бурычыңны түләгәнең юк әле.

Шәрифҗан. Изгеч! Әллә син аны түләмәм дип куркасыңмы? Әткәй Варшавага малга киткәч, берьюлы барысын түләрмен.

Сәляхетдин. Алайса, чебиләр кулдан оча...

Садрый. Каян килгән соң ул чебиләр?

Шәрифҗан. Алар үзләре заграничный, ди. Французча сөйләшәләр, ди. Кыш көне Оренбургта булганнар. Минһаҗлар утырып кайтканнар инде. Рәтләре шәп, ди. Только, малай, акча күбрәк кирәк, ди. Ул теге синең Нилли, Леопатраларың боларга асрау булырга да яраксызлар, ди.

Сәляхетдин. Фирештәләр инде. Сандугач кебек сайрыйлар. Бигрәк тә татар чебие белән төрек чебие шәп. Ә гарәп кызы шундый бии, карап үләрсең. Өс-баш, мин сиңа әйтсәм, көзге шикелле, җем-җем итеп тора. Агай-эне өчен өзелеп кенә торалар.

Шәрифҗан *(кызып)*. Өзеләләр, диең, ә?

Сәляхетдин. Мөселман булганда, урысларга карамыйлар да.

Шәрифҗан. Әгәр дә бу чебиләрне кулга ала алмасак, хурлыгыннан чәнчелеп китәргә генә кала бит, полный позор.

Садрый. Гөнаһ шомлыгына каршы, миндә дә рәт юк. Закирдан рәт ничегрәк икәнен сорамадыгызмы?

Сәляхетдин. Бу арада аның да көймәсе комга терәлеп тора. Акча юклыктан теге күтәрмә борынлы шамшаметкасын очырган.

Шәрифҗан. Әгәр дә бу чебиләрне кулдан ычкындырсак, бөтен дөньяга адәм мәсхәрәсе булып калабыз бит.

Сәляхетдин. Оренбург егетләре аларны менә дигән итеп тәрбияләгәннәр. Шуларны сагынып авыз сулары корый.

Шәрифҗан. Безгә дә, егетләр, сынатырга ярамый. Без үзебезне күрсәтергә тиеш.

Садрый. Юк бит, миндә дә рәт юк.

Сәляхетдин. Бардыр әле. Үткән атнаны гына мең ярым эләктерден ич.

С а д р ы й. Ул мең ярым өч мең булып очты инде.

С ә л я х е т д и н. Шулай алга килгән җәннәт нигъмәтләреннән колак кагып калабызмыни инде?

Ш ә р и ф җ а н. Бу хурлыктан, билләһи газыйм, чәнчелеп китәргә генә кала. Позор!..

С а д р ы й. Син соң бер-ике йөз генә эләктерә алмыйсыңмы?

Ш ә р и ф җ а н. Юк шул. Әткәй Варшавага малга дип акчаны тиененә кадәр кассадан да ала бара. Тәмәкелек тә чиртеп булмый.

С а д р ы й. Акча банкыдамыни?

Ш ә р и ф җ а н. Өйдә әле...

Г ы й л а ж б а б а й күренә.

X. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Г ы й л а ж б а б а й.

Г ы й л а ж б а б а й. Бай, бикә сине чакырган иде.

Ш ә р и ф җ а н *(куркып)*. Әллә әткәй кайттымы?

Г ы й л а ж б а б а й. Юк әле, кайтмады.

Ш ә р и ф җ а н. Ярый, бар, эшеңдә бул. *(Терраса тәрәзәсеннән кычкыра.)* Әнкәй! Әнкәй! Әллә чукракландыгызмы? Мөршидә! Әнкәй мине нигә чакырган? Ә? Нәрсә ди? Әй, чәнчелеп китегез!.. *(Үзалдына сөйләнә-сөйләнә.)* Мин, акча бирә, дип торам.

Г ы й л а ж б а б а й *(тавыкларны куып)*. Көш, көш, дим, юньсезләр! Көш, дим, рәхмәт төшкерләре. Көш...

Ш ә р и ф җ а н. Әй син, карт чүмәлә, эшеңдә бул!

Г ы й л а ж б а б а й китә.

XI. С а д р ы й, Ш ә р и ф җ а н һәм С ә л я х е т д и н.

С а д р ы й *(шул арада уйланып тора. Кинәт бер нәрсә исенә төшкән шикелле булып уйланып, яктырып китә. Урыннан торып)*. Булды, егетләр, акча булды!..

Ш ә р и ф җ а н. Булды?!

С ә л я х е т д и н. Чынлапмы?

С а д р ы й *(як-ягына каранып)*. Мин хәзер бер яңа эш уйлап чыгардым. Әгәр дә барып чыкса, биш йөз түгел, биш-ун мең эләктерергә мөмкин.

Ш ә р и ф җ а н. Йә, йә?

С а д р ы й. Әгәр дә шуны булдырсагыз, чебиләр безнең кулда булуында, билләһи газыйм, шик-шөбһә юк.

Ш ә р и ф җ а н. Йә, йә, хуш?

С а д р ы й. Әткәңнең өйдә акчасы барлыгын тәгаен беләсеңме?

Ш ә р и ф җ а н. Беләм, тәгаен беләм.

С а д р ы й. Ул акчалар синең кулыңа күчүгә син каршы тормыйсыңмы?

Ш ә р и ф җ а н. Тапты сүз! Әткәйнең үзенең минем кулга күчүенә дә мин каршы түгел.

С ә л я х е т д и н. Ай, чебиләр, чебиләр! Кулдан ычкыналар...

Ш ә р и ф җ а н *(Сәляхетдингә)*. Тик тор әле, изгеч! Йөрәкне яндырма! *(Садрыйга.)* Йә, хуш, шуннан соң?

С а д р ы й. Мине яхшылап тыңласагыз, барысы да була.

Ш ә р и ф җ а н. Йә, йә?

С а д р ы й. Син теге газета язучы Мансур малайны беләсеңме?

Ш ә р и ф җ а н. Хәерче ич ул.

С а д р ы й. Менә шул Мансур малай әтиеңнең акчаларын өйдә асраганын белгән.

Ш ә р и ф җ а н. Йә, йә?

С а д р ы й. Менә шул галах Мансур үзенең шайкасы белән сезгә «руки вверх!» ясарга җыена.

С ә л я х е т д и н. Нәрсә?

С а д р ы й. Билләһи газыйм. Мин аны хәзер генә сиздем. Ул менә хәзер генә монда иде.

Ш ә р и ф җ а н. Бездәме?

С а д р ы й. Әйе. Шайкасындагы бер кеше белән сөйләшеп торганын тыңлап тордым. Ләкин алар әле акчаның шәһәрдәме, өендәме, дачадамы икәнен тәгаен белмиләр күренә. Менә шул акчалар аларның кулына төшкәнче, үз кулыбызга төшерсәк, аларга сандык төбендәге кирәксез кәгазьләр генә калачак. Осталык белән эшләгәндә, акча синдә булачак, ә бөтен гаеп алар өстендә калачак. Кәгазьләр аларда булгач, башкасы кирәкми. Ләкин моны бик тиз, бәйрәмгә кадәр эшләп алырга кирәк. Юкса соңыннан соң булыр. Ләкин бу серне, акча безнең кулга кергәнче, бик яшерергә кирәк. Булмаса, бөтен нәрсәдән колак кагып калырбыз. Мансур малай бүген монда куна бугай. Төнлә аның артыннан күз-колак булып йөрергә кирәк. Кемнәр белән йөрер икән?

С ә л я х е т д и н. Акча безнең кулга ничек керер соң?

С а д р ы й. Аның хакында хәзер берәр яры барып яхшылап сөйләшергә кирәк.

С ә л я х е т д и н. Егетләр, менә монда ерак түгел, теге куе наратлыкта тиен күргән идем. Шуны барып атыйк әле. Сез шунда бара торыгыз. Әлеге мәсьәләне дә шунда гына сөйләшербез. *(Китә.)*

Башкалар да кузгалалар.

Шәрифҗан. Ул Мансурның андый уйда икәнлеген белмәгән идем.

Садрый. Син әле бик күп нәрсәне белмисең. Мин ул галахны хәзер бик яхшы аңладым.

Китәләр.

XII. Шакирҗан.

Шакирҗан *(зур паузадан соң, җиләннән, күк тиредән тегелгән бүректән, җилән астыннан ак казаки, кулында зур зонтик, капка төбенә җиткәч)*. Көш, көш, әрәмтамаклар! Көш, имгәкләр! Көш, көш, көш, дим, ахальниклар. Монда сезгә ни калган? Көш, Яэҗүҗ-мәэҗүҗ токымы! Гыйлаҗи! Гыйлаҗи! Кайда дөмектегез?.. Көш, көш, галдиш, көш!.. *(Таш белән бәрә.)*

XIII. Шакирҗан һәм Гыйлаҗ бабай.

Гыйлаҗ бабай *(ашыгып, аксый төшеп)*. Көш, көш, юньсезләр! Көш, дим, мәнсезләр!

Шакирҗан. Кая дөмегеп торасың? Нигә боларны карамыйсың? *(Борылып өйгә керә-керә.)* Кайсыгыз бар анда? Кунаклар килә. Самавыр куегыз! *(Кереп китә.)*

XIV. Гыйлаҗ бабай.

Гыйлаҗ бабай. Көш, көш, җәһәннәм кисәүләре! Кая качасың, кая? *(Колачларын җәеп тавыкларны җибәрмәскә тырыша.)* Кая барасың, уңмаган, кая, кая?.. Көш, көш, көш! Бай кайтканны күрмәскә күзең чыкканмыни! *(Тавыкларны куып китә.)*

XV. Мөршидә һәм Шакирҗан.

Мөршидә өстәл урынын хәзерли. Соңыннан Шакирҗан бай керә.

Шакирҗан. Шәрифҗан кая?

Мөршидә. Иртәдән бирле өйдә күргәнем юк.

Шакирҗан *(чәйнекнең капкачын ачып карап)*. Кайсыгыз чәй салды?

Мөршидә. Мин.

Шакирҗан. Синдер шул. Мин сиңа ике кунак дип татарча әйттем бит. Менә син монда ике табынга җитәрлек чәй салгансың. Кара аны, кызый, минем йортта алай

бармакларың озаймасын. Киявең өендә юмартланырсың. Икенче шундый эшеңне күрсәм, бармакларыңны тапармын. Өстәл җыйганда, чәйнекне селкемәссең. *(Шикәр савытының капкачын ачып карап.)* Бу шикәрне дә син тутырдыңмы?

М ө р ш и д ә. Калса әрәм булмас.

Ш а к и р җ а н. Калса, әрәм булмаганын мин дә беләм. Малны кадерсезләсәгез, бәрәкәте кача. Шикәр белән болай юмартланырга минем шикәр заводым юк. Ишетсен колагың! Минем шикәр заводым юк. Киявеңдә теләгәнчә кыланырсың. Йортымдагы бәрәкәтне качырасыз. *(Варенье күреп.)* Вареньены савытыннан ташытканчы тутырмасаң, кулың корыр идемени? Һе, дөнья корыткыч әрәмтамаклар! Расходыгыздан башка бер файдагыз юк. Бисмиллаһ-иррахман-иррахим. *(Бармагы белән варенье савытының читен сөртеп ала һәм бармагын ялый.)* Ярый, бар, эшегезне карагыз! Учак астында кирәксезгә утын ягып тормагыз!.. Йә, бар, бар, киләләр...

Сәхнә артыннан тавыш ишетелә. Ш а к и р җ а н каршы ала.

XVI. Ш а к и р җ а н, М о р т а з а һәм п р и с т а в.

Ш а к и р җ а н. Әйдәгез, рәхим итегез, әйдәгез!.. Микалай Ләксәндрич, түрдән рәхим итегез!..

М о р т а з а. Ха-ха-ха!.. Әмма да кызык иткәнсез үзләрен.

Ш а к и р җ а н. Микалай Ләксәндрич, рәхим итегез! Самавыр чыгарыгыз!

П р и с т а в. Рәхмәт, Шакир Искәндәрич! Шуннан соң өннәре дә чыкмады. *(Кылычын салып урындыкка элә.)* Алар белән башкача эшләп булмый.

М о р т а з а. Миндә аларның берсе торган иде. Әмма ләкин мин тезгенне кыска тоттым. Әмма ләкин, мин сиңа әйтим, кереп бер ай торырга өлгермәде, бунтовать итә башлады. Аш начар, имеш, куна торган урын начар, имеш, эш авыр, имеш. Жалованье аз, дип, малайларны котырта башлаган. Ә, алаймы, дим, эш начармы, дим, эш авырмы, дим, жалованье азмы, дим, куна торган урын начармы, дим. Алайса, энекәш, син бездән еаграк бул, синең ише кызыл авызларны бик күп күргән, дим. Әмма ләкин, мин сиңа әйтим, шул сүзләргә каршы нәрсә ди бит? Син мине чыгарасың икән, ярты айлык жалованьемны алдан биреп чыгар, ди. Алаймы, дим, соң ярты айлык кына азрак булмасмы, дим. Берьеллык ук биримме, дим. Сез миңа ярты айлык жалованьемны алдан бирергә ти-

ешсез, ди. Ни өчен, дим, мин сиңа эшләмәгән өчен акча бирим, дим. Син минем үги улым да түгел, наёмщигым да түгел, дим. Әмма ләкин, мин сиңа әйтим, үзенекен кисә бит. Сез миңа бирергә тиеш, ди. Яхшылыкта бирмәсәң, мин сине судка бирермен, ди. Алай булса, энекәш, син бар, минем белән судлаш инде, син бүгеннән безнең кеше түгел, сиңа бәддога, дидем. Әмма ләкин, мин сиңа әйтим, шуңар каршы менә нәрсә ди бит! Син, ди, бәддогаң белән карт хатыныңны кайтып куркыт, ди. Әмма мине түгел, аның базары узды инде, ди. Алаймы, дим, син әле бәддогалар тикшерәсең икән, синең хакың ана сөте шикелле хәләл, дидем дә ярты айлык торган жалованьесын да бирмичә чыгардым. Хи-хи-хи!.. Билләһи газыйм, шулай иттем. Хи-хи-хи!.. *(Көлгән саен бик каты йөткерә.)*

П р и с т а в. Кара син канальяны!

Ш а к и р җ а н. Йә, хуш, хуш, нигъмәттән җитешегез!

М о р т а з а. Миңа аның сигез сумы кыйммәт түгел. Минем белән үз арасындагы аерманы, көчне күрсәтүе кыйммәт. Ара-тирә шулай өйрәткәләсәң, калганнары ефәк шикелле булалар.

Ш а к и р җ а н. Микалай Ләксәндрич, безнең типографиядә дә юлдан язганнарның берничәсе бар. Үзләренә һичбер сүз әйтер хәл юк. Һич санламыйлар. Эш куша башласаң, яисә болай ярамый, тегеләй кирәк дисәң, илтифатка да алмыйлар. Мин бит аларның хуҗалары, ахрысы. Әле бер көннәрдә берсе, шулай эш кушып торганда, миңа ни әйтә бит: син, ди, кассага төшеп файдаңны сана, ди. Монда безнең эшкә тыкшынып, чуалып йөрмә, ди. Шул маңкаларның сүзләренә гарьләнеп үлә яздым бит. Таяк белән күкрәгенә төрткән идем, фабричный инспекторга барып жалоба биргән. Суккан, кыйнаган булсам, бер хәл иде. Төрттем генә бит.

П р и с т а в. Сугарга ярамый. Кыйнарга закон кушмый. Кеше күрмәгәндә эләктергәләсәң — зарар юк. Ха-ха-ха! Бездә, полициядә, шундый эшләр бик яхшы куелган. Безгә эләккәннәрен без бик яхшы өйрәтәбез.

Ш а к и р җ а н. Микалай Ләксәндрич, син безнең шул юньсезләрне дә бераз акылга утырта алмассыңмы икән? Юкса бер дә санламыйлар.

П р и с т а в. Була ул, берәр гаеп табып безнең кулга төшерсәгез өйрәтергә була. Әгәр дә полицейский берәр гаеп табып, аларны жандармский управлениегә эләктерсәгез, анда аларны бик яхшы шомартып чыгарырлар. Аларның арасында партийныйлар юкмы икән?

Ш а к и р җ а н. Булмаган кая. Бөтенесе партия алар. Һәр көн гәзит укыйлар. Прокламацияләре дә булырга охшый.

М о р т а з а. Микалай Ләксәндрич булдырыйм дисә, булдыра инде ул.

Ш а к и р җ а н. Син, ди, миңа караганда азрак эшләсәң дә, күбрәк ашыйсың, ди. Шул маңка малай, хәерче эт шул сүзләрне миңа әйтә бит. Мин әйтәм, мин, энекәш, дим, бер ялгызым сезнең йөздә утызыгызны туйдырып торам, дим. Юк, ди, без сине һәм бернәрсә эшләми торган әрәмтамак семьяңны туйдырабыз, ди. Шул сөрелгән малай миңа, үзенең хуҗасына, шул сүзләрне әйтә бит. Йә, ничек көлеп үлмәссең дә ничек ахырзаман алды димәссең.

П р и с т а в. Да, бишенче елдан соң дураклар күбәйде. Да, әле сез ишеттегезме, Иванов дачасында бүген иртә белән «руки вверх!» ясаганнар бит.

М о р т а з а *(куркып)*. Һай!..

Ш а к и р җ а н. Кара син аны!

М о р т а з а. Ничек булган соң?

П р и с т а в. Иртәнге поезд үтәргә ун минут калгач, ике кеше, кереп, «руки вверх!» ясап, Василий Ивановичтан алтмыш мең сум акчасын алып чыкканнар.

Мортаза. Ай, юләр, юләр. Ни пычагыма ул кадәр акчаны дачага алып барган соң?

П р и с т а в. Ул шул поезд белән туры Мәскәүгә китәргә уйлаган булган икән.

М о р т а з а. Соң ул кадәр акчаны, үзе белән алып бармыйча, банк аркылы перевод ясатса, булмадымы икән?

Ш а к и р җ а н. Анысы шулай да, хәзер бит банкларны да талыйлар.

М о р т а з а. Таласа ни, таласа, аны таламый ич. Казна барыбер түли ич.

Ш а к и р җ а н. Аның артыннан йөргәнче, вакыт үтә бит. Сәүдәгәр кешегә, һәрбер тиен дигәндәй, вакыт та кадерле ул.

М о р т а з а. Талаучыларны танып калмаганмы соң?

П р и с т а в. Маска кигән булганнар. Кулларында бомбалары да булган.

Ш а к и р җ а н. Бомбалары да булган, диең!..

М о р т а з а. Эзләренә төшмәдегезме әле?

П р и с т а в. Хәзергә юк әле. Эзлибез.

М о р т а з а. Качканнардыр инде.

П р и с т а в. Кабергә качып кына котылмасалар, җир өстендә бездән котыла алмаслар.

М о р т а з а. Микалай Ләксәндрич, сезнең дә хезмәт авыр инде.

П р и с т а в. Служба, ничего не поделаешь.

Ш а к и р җ а н. Бу арада әллә нинди, сез шәһәрне начар саклыйсыз. Талаулар, ягъни мәсәлән, «руки вверх!»лар бик күбәеп китте.

П р и с т а в. Басарбыз әле.

Ш а к и р җ а н. Баса гына күрегез инде. Барлык таяныч сездә генә.

М о р т а з а. Әлегә, Аллага шөкер, безнең агай-эне, мөселман арасында ул-бу күренми.

Ш а к и р җ а н. Алла сакласын, диең. Ишәеп китсәләр, безгә дә килә башларлар.

П р и с т а в. Шулай, бервакыт Киевта служить иткән чакта, Пётр Марденко дигән бер байга, егерме дүрт сәгать эчендә илле мең сум акчаны Днепр буена бер таш өстенә куярга кушып, анонимный язу җибәргәннәр. Хәзерләмәсәң, үзеңне үтерербез, дигәннәр. Полицмейстер миңа карап әйтә, бу эшне, Николай Александрович, сиңа тапшырам, ди, син генә аларны тотсаң тота алырсың, ди. Ярый, дим, ваше высокоблагородие, дим. За царя и родину не пожалею, дим. Ну, Николай Александрович, с богом, ди. Мин, яныма бер городовой алып, штатский киемнәргә киенеп, бер төргәк кәгазь алып, Днепр буена, әлеге таш янына киттем. Төн караңгы иде. Шәһәрдән чыкканда, каланча уникене сукты. Әлеге таш янына җитәрәк, городовойга җиргә ятарга куштым. Мин, таш янына барып, кулымдагы төргәкне таш өстенә куйдым да үзем, ташка ышыкланып, теге канальяларны көтә башладым. Каланчада сәгать берне сукты. Менә кинәт таш янында, җирдән үскән шикелле, ике кеше пәйда булды. Шикләнеп таш янында әйләнгәләделәр дә, акчаны алмакчы булып, таш янына килеп җиткәч, мин тиз генә таш астыннан сикереп торып *(боларның иңсәләреннән эләктереп ала)*, стоп!!! *(Әле берсенә, әле икенчесенә карап ала.)*

Ш а к и р җ а н. } Микалай Ләксәндрич!
М о р т а з а. } Микалай Ләксәндрич!

П р и с т а в. Виноват, виноват! Извиняюсь...

М о р т а з а. Йә, йә, шуннан соң?

П р и с т а в. Әтәчләр шикелле, ике кулымда селкенәләр. Юк, ычкына алмыйлар. Шулай да бер канальясы бомбасын аяк астына ташлады. Мин, как храбрый солдат, растеряться итмәдем. Бомбаны тибеп җибәргән идем, бомба суга барып төште. Шулай итеп, бер ялгызым икесен...

Шул вакыт якында мылтык аткан тавыш ишетелә. Пристав, сикереп торып, бер кулына кылыч алып, берсенә револьвер тота.

Смирно!..

Шакирҗан. Миңа тиде бугай.

Мортаза. Юк ла, миңа тиде шикелле.

Шакирҗан. Кара әле, башка тимәгәнме?

Мортаза. Күкрәккә керде шикелле.

Пристав. Команда, вперёд!.. Миннән калмагыз.

Мортаза байны алга этә. Мортаза Шакирҗанны алга этә. Шакирҗан приставны алга этә. Пристав саклык белән алга атлый башлый. Шакирҗан самавырны күтәреп кача. Аның артыннан Мортаза кача.

Пристав ялгыз кала.

Один в поле не воин... *(Кача.)*

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шакирҗан байның кунак бүлмәсе. Зәвыксыз җыештырылган. Диварда зур сәгать. Тимер сандык яки тимер шкаф сыман бер нәрсә уң якта дивар буенда тора. Уртада һәм уң якта ишекләр.

I. Садрый, Сәляхетдин һәм Шәрифҗан.

Садрый. Әгәр дә кычкыра йә карыша башласа — атасыз. Пробка булса да, бүлмәдә бик нык шартлый ул. Кая, бомба булдымы?

Шәрифҗан. «Бомба»га яраклы түгәрәк нәрсә таба алмадым.

Садрый. «Бомба»сыз һич ярамый. Бар, зуррак бәрәңге яки шалкан табып китер.

Шәрифҗан китмәкче була.

Садрый. Шәрифҗан, син аны карага буя!

Шәрифҗан. Ярый. *(Чыгып китә.)*

II. Садрый һәм Сәляхетдин.

Садрый. Эшне бик пөхтә эшләргә кирәк. Иң беренче, каушамаска кирәк.

Сәляхетдин. Тотылсак — яхшы булмас. Төрмәгә ябулары бар.

Садрый. Кызык син, Сәляхи, Шәрифҗан аның улы. Ә син дустының улы. Җитмәсә, ул сиңа үзенең киявенә

караган шикелле карый бит. Төрмәне исеңә дә китермә. Алар, халык теленә чыкмас өчен, үзләре тырышырлар әле. Безнең татар халкы бит семьядагы серләрнең халык арасына чыгуыннан үлемнән курыккан шикелле курка.

Сәляхетдин. Тотылсак — яхшы булмас.

Садрый. Әгәр тотылсагыз, менә нәрсә: Шакирҗан байны куркытыр өчен, юри эшләнгән мәзәк, дип әйтерсез. Мин дә шулай әйтермен. Аннан соң сездә бит чын кораллар булмый. Пугач та бәрәңге. Аның өчен кем сезне төрмәгә япсын? Юк өчен баш ватма. Бүгеннән калдырырга һич ярамый. Юкса Мансур малай килеп эләктереп китәр. Аннан чебиләр безнең кулдан бөтенләйгә ычкынырлар. Ә бу барып чыкса, бөтен дөнья безнеке булачак.

Сәляхетдин. Ә ул куркуыннан үлсә?

Садрый. Кем? Шакирҗан абыймы?

Сәляхетдин. Әйе, йөрәге ярылса?

Садрый. Шакирҗан байның йөрәген ярыр өчен, күкрәгенә туптан атарга кирәк. Ат ите ашаган кешенең һичбер вакыт йөрәге ярылмый, докторлар шулай ди.

III. Садрый, Сәляхетдин һәм Шәрифҗан.

Шәрифҗан *(кулындагы түгәрәк нәрсәне күрсәтеп)*. Булды.

Садрый. Нәрсә, шалканмы? *(Түгәрәк нәрсәне карый.)*

Шәрифҗан. Юк, ашханәдә өстәлдә камыр тора иде. Шуны эләктердем.

Садрый *(кесәсеннән битлекләр чыгарып)*. Менә сезгә битлекләр. Йә, киеп карагыз әле.

Сәляхетдин, Шәрифҗан битлекләрне кияләр.

Яхшы. Менә париклар.

Кияләр.

Булды, һич таныйрлык түгел. Шәрифҗан, син Сәлях киемен киярсең. Сәляхка мин кием таптым. Йә, ярый. Йә, чыгып торыгыз. Мин Шакирҗан бай булып торам. Чыгыгыз!

Чыгалар.

Йә, керегез!

Сәляхетдин. Руки вверх!

Шәрифҗан. Мин сандыкны ачармын.

Садрый. Алай булгач, ачкычларны сорарсыз.

Сәляхетдин. Ә бирмәсә?

Садрый. Бер мәртәбә атарсыз.

Шәрифҗан. Моны кая куйыйм?

Садрый. Ишек төбенә куярсыз да бер сәгатьсез урыныңнан кузгалма диярсез.

Сәляхетдин. Ә кузгалса?

Садрый. Кузгалмас. Менә шулай эшне бетереп чыгарсыз да, чүплек базы артындагы ишектән безнең йортка үтеп, акчаны миңа калдырып, үзегез тиз генә Шәрифҗан бүлмәсенә кереп утырырсыз. Шау-шу башлангач та ярдәмгә чыгарсыз. Күп сөйләшмәгез. Бернәрсә күрмәгән дә, белмәгән дә булып күренегез!

Икенче бүлмәдә Шакирҗан байның тавышы.

Шәрифҗан. Әти уянган.

Садрый. Әйдәгез!

Ашыгып чыгып китәләр.

IV. Шакирҗан һәм Габбаса.

Шакирҗан. Болай булса, сез мине тереләй кабергә кертерсез. Кайсы байның асравына марҗа оегы алып биргәнен күргәнегез бар, йә?

Габбаса. Читеге юк бит, атасы.

Шакирҗан. Булмаса, мин гаеплемени?

Габбаса. Соң, бәйрәмдә яланаяк йөрмәс бит.

Шакирҗан. Ә, шулаймыни? Оек алып биргәч, ул ботинка да сорый башлар. Ботинка булгач, биленә каеш даулый башлар. Берәү генә түгел, бер көтү бит алар. Хезмәтчеләрне үзегез аздырып бетерәсез. Ул мокытларга утыз тиенлек күн башмак нигә ярамаган? Соң син үзеңне онытма. Миңа килгәндә, ботинкаң бар идеме? Мөселман кызына марҗа оегы ярамый ул. Хәзер оегын кире кибеткә төшереп бирегез!

Габбаса. Тукта әле, атасы, бәйрәмгә аягына кияргә бернәрсә дә юк бит аның.

Шакирҗан. Минем иске читекне кияр.

Габбаса. Аны дворник Гыйлаҗи картка бирдем.

Шакирҗан. Нәрсә, нәрсә?

Габбаса. Әйе, гаеткә кияр дип бирдем. Ул үзе аны ямамакчы булды.

Шакирҗан. Юк, сез мине чынлап бөлдерергә керешкәнсез, ахры.

Габбаса. Гаеткә киеп барырга бернәрсә дә юк дигәч, биргән идем.

Ш а к и р җ а н. Тагын аңар чапан кирәк түгелме? Бәлки, аның сәгате дә юктыр әле? Бәлки, аңар намаз туны да кирәктер? *(Гайрәтләнеп.)* Кит, ябалак, мут хатын! Күземә күренмә.

Г а б б а с а. Чү, чү, атасы! Газиз көннәрдә генә болай кыланмасана! Алла аның урынына гаип хәзинәләреннән бирер.

Ш а к и р җ а н. Бирер, бирер. Тот капчыгыңны. Сиңа гаип хәзинәләр хәзерләп куйган, ди. Хәзер барып алып кайтасы гына бар. Гомерендә гаеттән гаеткә битен юмаган, каткан мужикны шатландырган өчен, Алла сиңа бирде, ди. Бирмәгән ни. Сәдака бирердәй урыннар аннан башка да бик күп. Алла кабул гына итсен. Хәзер барып дворниктан читекләремне алып, асрау кызга бәйрәмдә кияргә алып бир.

Г а б б а с а чыга башлый.

Кара әле, сиңа әйтәм, моннан соң малайларга шикәр урынына кичә алып кайткан кисмәктәге вареньены бирә башлагыз.

Г а б б а с а. Ул эшкә яраксыз бит.

Ш а к и р җ а н. Нәрсәсе эшкә яраксыз?

Г а б б а с а. Әчеп, күгәреп беткән бит.

Ш а к и р җ а н. Бисмилла әйтеп капсалар, төчер әле. Ул мокытларга ярамаган, ди, тагын. Авылда бит аларга ул да эләкми әле. Кара аны, сиңа әйтәм, бәйрәм дип, күп чәпчемәгез. Быел болай да расходлы ел.

Г ө л җ а м а л керә.

V. Ш а к и р җ а н, Г а б б а с а, Г ө л җ а м а л.

Г ө л җ а м а л *(тузган аяк киеменнән)*. Бай абый, Нурмөхәммәт абый килгән. Керергә мөмкинме, ди.

Ш а к и р җ а н. Керсен. Әй син, чабаталы бикә, бикәң алып биргән оекны хәзер кибеткә кире төшереп бир. Мөселман кызына марҗа оегы кияргә ярамый. Ул сиңа хәрәм, хәрәм, ишетәсеңме, хәзер төшереп бир. Аның урынына мин сиңа үземнең иске кәҗүл читекләремне бирермен. Аның башлары бераз тузган булса да, балтырлары яхшы. Чын кәҗүл. Бәйрәмгә кәҗүл читек киярсең. Сиңа әйтәм, дворниктан хәзер алып читекләремне Гөлҗамалга бир. Кара син, гөмбә, карап киен. Бар, керсен.

Г ө л җ а м а л бер Габбасага, бер Шакирҗанга карап, яшенә тыгылып чыгып китә.

Корбанлыкка азык бирмәсеннәр. Ике көнне ашамый да торыр әле. Китап шулай куша. Ике көн эчендә чорт та булмас. Сират күпереннән җиңелрәк үтәр.

Габбаса чыга. Нурмөхәммәт керә.

VI. Шакирҗан һәм Нурмөхәммәт.

Нурмөхәммәт *(кара сакаллы, ябык)*. Әссәламегаләйкем!

Шакирҗан. Ни бар?

Нурмөхәммәт. Бай, мин сезгә...

Шакирҗан. Йә, йә, төче телләнмә! Йомышыңны әйт тә эшеңә кит!

Нурмөхәммәт *(уңайсызланып)*. Ун сум акча кирәк иде. Шуны киләсе ай жалованьесы хисабына алдан бирә алмассызмы?

Шакирҗан. Бирә алмыйбыз.

Нурмөхәммәт. Бәйрәм дә килеп җитте. Беррәттән балага да исем куштырмакчы идек. Хатынны да докторга күрсәтәсе бар...

Шакирҗан. Хәерче башыгыз белән... хәерчеләр үрчетергә сезгә чорт кушканмыни? Балагыз минем кушуым буенча тумаган бит. Үзегезне генә туйдырып торуым җитмәгән, тагын балаларыгызны муеныма такмакчы буласызмыни?

Нурмөхәммәт. Сезнең муенга такмыйбыз. Мин жалованье хисабына сорыйм бит.

Шакирҗан. Йә, йә, нәрсәгә әле сезгә бала?

Нурмөхәммәт. Булды инде шунда... Алла биргәндер...

Шакирҗан. Әнә бар, Алла туйдырыр да. Алладан сорамыйсыз. Миңа киләсез.

Нурмөхәммәт. Бай, хатынны докторга күрсәтми һич ярамый.

Шакирҗан. Тукта, хәерче башың белән, шундый зур расходлар тотып, хатыныңны докторларга күрсәтергә син кем? Син бер-бер баймы, әллә мирзамы?

Нурмөхәммәт. Бик каты авырый бит. Менә инде икенче көн бер локма йотканы юк. Докторга күрсәтми һич ярамый.

Шакирҗан. Әй, мәҗүс каныннан яралган бәдәвамнар. Алланың тәкъдиренә ышанмыйча, доктордан ярдәм көткән булалар. Бар, бар, эш калдырып, юк артыннан йөрмә. Ризыгы бетмәгән булса, докторсыз да үлмәс әле.

Аллага ышанырга кирәк, Аллага... Синең хатыныңны доктор яратмаган бит, Алла яраткан. Алла үзе хәстәрен дә күрер. Бар, юк артыннан эш калдырып йөрисе булма!

Нурмөхәммәт. Бай, соравымны җиргә салма? Бик кирәк иде. Шуның өстенә энекәшне дә патша хезмәтенә алдылар. Аңар да бераз бирергә кирәк. Бәйрәмгә анысын-монысын аласы килә. Хатын да...

Шакирҗан *(бүлдереп)*. Кара әле, кем, Нурмөхәммәт, синең энеңнең солдатка алынуына мин гаепле түгел. Бу — бер. Икенче, ул солдат булса, патша хәзрәтләре аларны ашата, эчертә, киендерә. Тагын аларга ни кирәк? Бәйрәм дисең икән, үз дәрәҗәңә карап уздырырсың әле.

Нурмөхәмммәт. Өч айдан бирле киемемне тегүчедән ала алмый торам.

Шакирҗан. Ә өстеңдәге киемең нигә ярамаган? Гаеткә бару, — энем, туйга бару түгел ул. Ару-пакь булса, шул җитте.

Нурмөхәммәт. Бәйрәм бит.

Шакирҗан. Булса ни? Бәйрәм дип син тагын: йорт сатып алырга теләмисеңме? Тукта әле, соң син миннән ай саен жалованье аласың бит. Аны кая куеп бетерәсең?

Нурмөхәммәт. Унбиш сумны айга бүлгәч, көнгә илле тиен генә төшә бит ул.

Шакирҗан. Ә соң синең көнгә ун сум, депутат жалованьесы аласың киләмени?

Нурмөхәммәт. Ун сум димим, шулай да бу жалованье азрак шул.

Шакирҗан. Әгәр дә жалованьеңны азсынсаң, без сине тотмыйбыз. Иртәгә үк хисабыңны өз дә, дүрт ягың кыйбла.

Нурмөхәммәт. Унҗиде ел торганны хәзер дә торырбыз инде аны. Тик менә хәзер акча бик кирәк иде шул.

Шакирҗан. Миңа да, энем, акча бик кирәк. Сиңа ун сум кирәк булса, менә миңа иртәгә илле мең сум хәзерләп куярга кирәк. Кая, миңа илле мең сум акча бир дип, синең бугазыңа ябышмыйм бит. Ярый, бар эшеңдә бул. Минем синең белән сөйләшеп торырга вакыт юк. *(Үз ягына чыга.)*

Нурмөхәммәт, өметсезләнеп, башын аска салып, бераз тора да, башын чайкап, бик кайгылы чыгып китә.

VII. Гыйлаҗ бабай һәм Гөлҗамал.

Шаулашып керәләр. Гыйлаҗ бабайның кулында иске читекләр.

Гыйлаҗ бабай. Биргән, ди, бирми ни, тот капчыгыңны!

Гөлҗамал. Бай үзе әйтте. Гыйлаҗ бабайдагы кәҗүл читек сиңа булыр, диде.

Гыйлаҗ бабай. Бикә үз кулы белән бирде бит. Гыйлаҗ бабай, дога кылып, гаеткә киеп барырсың, диде. Гаеттән соң минем өчен дә, баең өчен дә дога кылырсың, диде.

Гөлҗамал. Бай миңа бикә алдында, кәҗүл читек сиңа булыр, диде...

Гыйлаҗ бабай. Бу кәҗүл түгел ич. Башкасын әйткәндер ул сиңа. Әнә бу кәҗүл түгел.

Гөлҗамал. Юк, юк, нәкъ шул үзе. Әнә башы да сүтелгән. Җир йотсын, бай үз авызы белән шулай дип әйтте. Кәҗүл читек сиңа булыр, диде.

Гыйлаҗ бабай. Гөлҗамал, син, кызым, юкка булашма. Ирләр читеген киеп йөрү сиңа бер дә килешмәс.

Гөлҗамал. Бай шулай диде, кая, бир!

Гыйлаҗ бабай. Ертык ич ул. Синең аны ямарга көнең дә юк.

Гөлҗамал. Бай шулай куша бит.

Гыйлаҗ бабай. Гөлҗамал кызым, әгәр дә бу читекләрне миннән алмасаң, бер ай буена утыныңны ярып ашханәгә ташып куярмын. Сиңа ирләр читеге нәрсәгә ярый? Ә миңа ул гаеткә киеп барырга ярар. Минем аны ямарга көнем дә бар.

VIII. Гыйлаҗ бабай, Гөлҗамал һәм Шакирҗан.

Шакирҗан. Бу ниткән тавыш тагы? Сезгә монда ни кирәк?

Гөлҗамал. Гыйлаҗ бабай читекләрне бирми.

Гыйлаҗ бабай. Бай, мин аларны ямап, гаеткә киеп бармакчы идем. Бикә шулай диде. Минем ямаулык көнем дә бар. Ә ул кыз кеше. Кыз кешегә ирләр читеге килешми.

Шакирҗан. Ә син, мокыт, читекләрне Гөлҗамалга бир.

Гыйлаҗ бабай. Бай, гаеткә киеп бармакчы идем. Минем ямаулык көнем дә бар. Бикә шулай диде. Ямап киярсең, диде. Карт көнемдә, рәхәтләнеп, читек киеп, гает укыр идем. Киләчәк гаеткә кадәр тора да алмам инде. Әйе, ямап, гаеткә киеп барыр идем шул, бай.

Шакирҗан. Гаетне яланаяк укысаң, савабы күбрәк булыр. Пәйгамбәрләр гомер буе яланаяк йөргән. Читекләр Гөлҗамалга кирәк.

Г ы й л а ж б а б а й. Бай, Алла хакы өчен, миннән алмасана! Минем ямаулык кү... *(Яшенә буыла.)*

Ш а к и р җ а н. Кая, читекләрне бир әле. *(Читекләрне алып карый.)* Һе, эм-м... боларга баш салдырганда, үземә дә кияргә яраpлык икән әле. Ә, әйе, абыстагыз ялгышкан. Болар үземә кияргә яраклылар икән әле. Әйе, абыстагыз ялгышкан. Ярый, эшегезгә барыгыз.

Г ы й л а ж б а б а й. Ә читекләр?!

Ш а к и р җ а н. Әйтәм бит, абыстагыз ялгышкан, дип.

Г ы й л а ж б а б а й. Булмыймыни?

Ш а к и р җ а н. Киләсе гаеткә кадәр яхшылап хезмәт итсәң, үземнән соң боларны сиңа бирермен. Ә син, кызый, оекларыңны хәзер үк кибеткә кире төшереп бир. Йә, барыгыз, эшегездә булыгыз!

Гыйлаж бабай белән Гөлҗамал бер-берсенә карашып торалар.

Г ө л җ а м а л *(авыр сулап)*. Менә сиңа кәҗүл читек. *(Чыга.)*

Г ы й л а ж б а б а й. Алай... Гомеремдә бер читек киеп гаеткә барырмын дип тора идем, ул да булмады. Киләсе гаеткә, Алла боерса, киләсе гаеткә. Исән-сау булсак. *(Чыга.)*

Ш а к и р җ а н *(читекләрне карап)*. Балтырлары чибәр әле. Бары баш салдырырга гына кирәк буласы икән.

IX. Ш а к и р җ а н һәм Г ө л җ а м а л.

Г ө л җ а м а л *(кереп)*. Бай абый, сәгатьче килгән.

Ш а к и р җ а н. Керсен.

Г ө л җ а м а л чыга.

Бу расходтан кабергә кермичә котылып булмастыр, ахры.

С ә г а т ь ч е һәм М а н с у р керә.

X. Ш а к и р җ а н, С ә г а т ь ч е һәм М а н с у р.

С ә г а т ь ч е. Әссәламегаләйкем!

Ш а к и р җ а н. Вәгаләйкемәссәлам. Әйдә, кем, әйдә.

М а н с у р. Исәнмесез!

Ш а к и р җ а н. Аллага шөкер. *(Сәгатьчегә.)* Менә әле, кем, сәгать туктап китте. Машина арасына таракан кергән булырга кирәк. Шуның тараканын алып кына җибәр әле.

Сәгатьче, урындыкка басып, сәгатьне карый башлый.

Аннан соң бераз машинасын әрчисе булыр.

Мансур. Шакирҗан әфәнде, мин теге китапның хисабын бетерергә дип килгән идем.

Шакирҗан. Ә, алаймы? Ярый... *(Сәгатьчегә.)* Бик дөрес йөридер иде. Пассаж сәгатеннән бер дә калышмый иде. Әле үзебезнең дачада вакыт туктап киткән.

Мансур. Шакирҗан әфәнде, минем йомышымны...

Шакирҗан *(борылып)*. Ә, кем, хәзер, хәзер... *(Сәгатьчегә.)* Суга торган машинасы да аз гына зарарланган булырга кирәк. Әллә ничек тәртипсез суга башлаган. Бер сугарга тотынса, собор чиркәве төсле туктый белми.

Сәгатьче. Монда шактый хикмәтләр бар.

Шакирҗан. Юк, алай зур бозыгы булмаска тиеш.

Мансур. Шакирҗан әфәнде, минем йомышымны үтәп җибәрсәгез, яхшы булыр иде.

Шакирҗан. Хәзер, хәзер. *(Сәгатьчегә.)* Кая, бозык җирен таптыңмы инде? Таракан кергәнме? Әллә чебенме?

Сәгатьче. Юк, зуррак нәрсә кысылган монда.

Шакирҗан. Әллә үрмәкүч үкме?

Сәгатьче. Үрмәкүч тә түгел. Зуррак нәрсә, зуррак нәрсә, дим.

Шакирҗан. Зур дигәч тә, сыер кысылмагандыр бит. Йә, нәрсә кысылган?

Сәгатьче. Бай, моның машиналары арасына бер сумлык акча гына кысылган.

Шакирҗан. Акча? Чынлапмы? *(Урындыкка менеп карый башлый.)*

Сәгатьче. Һи-һи-һи... Шул бер сумны миңа бирсәгез, сәгатегез йөри башлар.

Шакирҗан. Ә, алаймы?.. Юкса акча да кыстырып куярлар бездә.

Сәгатьче. Бер сум бирсәгез, сәгатегезне ходка куям.

Шакирҗан. Күбрәк булмыймы соң?

Сәгатьче. Җәһүд булса, өч сум сорар иде. Без рус байларыннан бу хезмәткә йөз егерме бишне алабыз.

Шакирҗан. Ярый, яхшылап төзәт, бәясеннән эш тормас.

Мансур. Шакирҗан әфәнде, минем эшне бетерик әле. Минем бер дә вакыт юк.

Шакирҗан. Хәзер була. *(Сәгатьчегә.)* Кем, син инде эшкә ашырырлык итеп яхшылап төзәт.

Мансур. Мине озак көттерергә уйлыйсызмы?

Шакирҗан. Ә, кем, хәзер була. Син инде маши-

наларның тузаннарын да сөрт, һаман да һаман сәгатьче чакырып булмый.

Мансур. Шакирҗан әфәнде, чынлап әйтәм, минем вакытым юк.

Шакирҗан. Йә, хуш, хуш. Әйе, минем дә вакытым юк. Тиз генә йомышыгызны әйтегез дә китегез.

Мансур. Китап басылып чыгып, сатыла башлавына ике ай булды. Ә сез әле һаман миңа гонорар биргәнегез юк.

Шакирҗан. Ягъни мәсәлән, китабыгыз өчен акчамы?

Мансур. Әйе.

Шакирҗан. Күпме?

Мансур. Безнең башта сөйләшүебез ике мең бастыру иде. Мин шуңа карап китапны егерме биш сумга саткан идем. Әмма сез аны алты мең бастыргансыз икән.

Шакирҗан. Юк, юк, ике мең басылды, ике мең. Аны малайлар сине үртәп әйткәннәр. Йә, хуш, сезгә әкият рисаләгез[1] өчен күпме бирик соң?

Мансур. Ничек күпме? Вәгъдә буенча, ике меңнән егерме биш сум акча. Ун данә китап. Ә дүрт меңе өчен күпме кирәктер. Мин белмим әле.

Шакирҗан. Әкиятегезне бик матур, пөхтә итеп бастырдык. Үзебезгә дә бик кыйммәткә төште.

Мансур. Анысы сезнең эш инде.

Шакирҗан. Йә, күпме бирик соң?

Мансур. Хәзергә егерме биш сум акча, ун данә китап бирегез.

Шакирҗан. Ярый, өч сум бирим инде, алайса.

Мансур. Ничек өч сум?!

Шакирҗан. Артык бирә алмыйбыз. Бигайбә. Торговый дом артык бирергә риза түгел.

Мансур. Торговый домнарыгызда минем эшем юк. Мин сезнең белән сөйләштем.

Шакирҗан. Ярый, биш сум бирик, алайса.

Мансур. Егерме биш сумнан бер тиен дә ким алмыйм.

Шакирҗан. Җитәр, энем, биш сум җитәр. Аның каравы никадәр шөһрәтең тарала бит.

Мансур. Анысы — икенче мәсьәлә. Сез миңа яхшылыкта шул егерме биш сумны бирсәгез бирәсез, бирмисез икән, мин судка бирәм.

---

[1] Рисалә — кечкенә китап.

Ш а к и р җ а н *(торып)*. Ихтыярыгыз. Без артык бер тиен дә бирә алмыйбыз. Торговый дом риза түгел. Энем, дулама әле, утыр әле. Биш сум да — бик зур акча бит, бик зур акча. Безгә әкиятләрне авылда әбиләр бушлай да сөйлиләр иде. Ә без сиңа акча биреп никадәр шөһрәтеңне таратабыз. Кая, биш сум тәмам алып бетердем дип, шунда кулыңны куеп җибәр әле.

М а н с у р. Кул да куймыйм, биш сумны да алмыйм. Соң егерме биш сумга килешеп, биш сум алырга минем башыма тай типмәгән бит.

Ш а к и р җ а н. Егерме биш сумга хәзерге заманда бер әкият алырга минем дә башыма тай типмәгән, энем.

М а н с у р. Димәк, биш сумнан артык бирмисез?

Ш а к и р җ а н. Бәли[1], әфәндем, бирмибез.

М а н с у р. Ярый, мин сезне күндерермен әле. *(Тора.)*

Ш а к и р җ а н. Менә мәктәп китаплары язсагыз, күбрәк тә бирергә мөмкин.

М а н с у р. Актык мәртәбә әйтәм, минем хакымны бирәсезме, юкмы?

Ш а к и р җ а н. Биш сум бирәм.

М а н с у р. Ярый, бер туры килгәндә күндерермен әле! *(Ашыгып чыга.)*

XI. Ш а к и р җ а н һәм С ә г а т ь ч е.

Ш а к и р җ а н. Иртәгә ачуың басылгач, кирәк булса, килеп алып китәрсең әле. Йә, кем, буламы?

С ә г а т ь ч е. Бу барып чыкты, бай.

Ш а к и р җ а н. Йөри башладымы инде?

С ә г а т ь ч е. Яшь киленнәр суга барганнан ким йөрми.

Ш а к и р җ а н. Йөри, диең, алайса?

С ә г а т ь ч е. Шаулата гына... Кая, бай, мине җибәрсәгез инде.

Ш а к и р җ а н. Ярый, Аллага тапшырдык. Хезмәтеңә соңга калма.

С ә г а т ь ч е. Хезмәт хакымны биреп җибәрсәгез, яхшы булыр иде.

Ш а к и р җ а н. Ягъни мәсәлән, ничә тиен бирик соң?

С ә г а т ь ч е. Бер сум. Килешкәнчә.

Ш а к и р җ а н. Бер сумлык монда нинди эш булсын.

С ә г а т ь ч е. Башка кеше өч сум алыр иде. Материал керттем бит мин анда.

---

[1] Б ә л и — әйе.

Шакирҗан. Ярый, утыз тиен бирермен. Сәлясун[1].

Сәгатьче. Бай, җәберләмәгез.

Шакирҗан. Син үзең җәберлисең әле. Йә, җитәме?

Сәгатьче. Юк, булмый. Ярый, сиксән тиен алырмын инде.

Шакирҗан. Ярый, кырык тиен, әрбәгун[2] итим инде, алайса.

Сәгатьче. Ичмасам, җитмеш тиен бирегез! Кырык тиенлек материал гына керде.

Шакирҗан. Әрбәгун җитәр. Бездә кырык тиенгә бөтен көн хезмәт итәләр. Ә син бер минутлык хезмәтеңә кырык тиенне азсынасың. Алладан куркырга кирәк, энем.

Сәгатьче. Йә, ярый, булган булган инде. Алтмыш тиен итегез!

Шакирҗан. Кырык тиен бик җиткән. Мин сезгә дога кылырмын.

Сәгатьче. Йә, бирегез, илле тиен.

Шакирҗан. Кырык тиеннән артык бер тиен дә бирә алмыйм. Дога кылырмын мин сезгә. Әйе, дога кылырмын.

Сәгатьче. Йә, ярый, бирегез кырык тиенегезне.

Шакирҗан. Ә, кем, сәгать бер атна йөрсен әле. Әгәр дә туктамаса, кибеткә төшәрсез дә, шунда акчагызны бирермен.

Сәгатьче. Иште бу ишәк чумарын. Бай, бәйрәмгә акча бик кирәк иде шул.

Шакирҗан. Бәйрәм узганчы сынап карыйк. Акчагыз бездә югалмас. Ярый, хуш, минем эшем бар. *(Читекләрне алып китә башлый.)* Ә, кем, синең читек ямарга осталыгың юкмы?

Сәгатьче. Анысын булдырып булмас. Шулай да акчага кайчанрак керим соң?

Шакирҗан. Бәйрәмнәр үткәч.

Сәгатьче. Ярый, сәламәт булыгыз.

Шакирҗан. Хуш, хуш, Алла абруй бирсен. Чибәр егет икәнсең.

Сәгатьче чыга.

XII. Шакирҗан ялгызы.

Шакирҗан *(урындыкка менеп сәгатьне суктырып карый)*. Аннан-моннан гына чокып алды. Таракан гына

---

[1] Сәлясин, сәлясун – утыз.

[2] Әрбәгыйн, әрбәгун – кырык.

кысылган булгандыр әле. *(Төшеп, акча сандыгын ачып, акча саный башлый.)*

Шулвакыт Сәляхетдин белән Шәрифҗан килеп керәләр. Күзләрендә битлекләр. Киемнәре алмашынган. Башларында париклар.

XIII. Шакирҗан, Сәляхетдин һәм Шәрифҗан.

Сәляхетдин *(каушап, калтыранып)*. Руки вверх! Тыныгызны чыгарасы булмагыз! *(Пугачын Шакирҗанга төзи.)* Әгәр бер генә сүз эндәшсәгез, шул минут башыгызга пробка керер.

Шәрифҗан. Пуля керер.

Сәляхетдин. Әйе, пуля керер.

Өстәлдән акчаны алып чыгарга хәзерләнәләр.

Шәрифҗан *(«бомба»ны калтыратып идән уртасына куеп)*. Әгәр дә бездән соң урыныгыздан кузгалсагыз, бу бомба шартлар. *(Акчасын төшерә.)*

Шакирҗан акчага ташлана. Өчәү тартыша башлыйлар.

Шакирҗан. Бирегез! Бир! Минем акчаларым!.. Минем акчаларым!..

Сәляхетдин белән Шәрифҗан Шакирҗанны егалар. Шакирҗан, аларның чәчләренә ябышып, ике кулында ике парикны тотып кала. Шашына, Сәляхетдин белән Шәрифҗан эшләпәләрен тотып йөгереп чыгалар. Шакирҗан ялгыз калгач, «бомба»ны күреп куркып, акча сандыгына ташлана.

Караул! Караул!..

Бүлмә буйлап шашып йөри. Ялгыш бомбага басып сикереп китә. Габбаса, Гөлҗамал һәм Гыйлаҗ бабай керәләр.

Китегез, кит!.. Шартлый... Алыгыз аны! Алыгыз, ташлагыз!.. Палисәгә барыгыз! Палисәгә! Палисәгә!..

Гөлҗамал «бомба»ны кулына ала.

Ташла! Ташла! Харап итәсең!.. Ташла, дим мин сиңа! Ташла!..

Гөлҗамалга суга. Гөлҗамал «бомба»ны кулыннан төшерә.

XIV. Әүвәлгеләр һәм Сәйфетдинов.

Сәйфетдинов. Нәрсә бар? Ни булды?

Ш а к и р җ а н *(җикеренеп, аңа каршы барып)*. Руки вверх!.. Руки вверх!..

Сәйфетдинов кулларын күтәрә.

Ш а к и р җ а н. Руки вверх ясап... *(Буыла.)* Ах, әйтә дә алмыйм... Утыз мең сум акчамны талап чыгып киттеләр...

С ә й ф е т д и н о в. Хәзер начальство килә. Ничә кеше?

Ш а к и р җ а н. Ике... Өченчесе әнә... *(«Бомба»ны күрсәтә.)*

С ә й ф е т д и н о в. «Бомба»!

Ш а к и р җ а н. Зинһар, хәзер чыгып тот үзләрен! Бәйрәм чәйлеге дә, корбан ите дә бирермен. Нәрсә торасың катып? Бар, дим! *(Кулында парикларын селки.)*

С ә й ф е т д и н о в. Тес-сс!.. Начальство кило. *(Ишек төбенә барып баса.)*

П р и с т а в керә.

XV. Ә ү в ә л г е л ә р һәм п р и с т а в.

П р и с т а в. Нәрсә бар? Ни булды? Исәнмесез? *(Шакирҗанга кулын бирә.)*

Ш а к и р җ а н. Харап булдык, Микалай Ләксәндрич, харап булдык.

Кулы урынына парик тоттыра. Пристав куркып, сискәнеп китә.

С ә й ф е т д и н о в. Ваше благородие, «бомба»!

П р и с т а в *(тагы сискәнеп)*. Ә? «Бомба»?! Кая?

С ә й ф е т д и н о в. Менә, ваше благородие!

Пристав, аның артыннан Шакирҗан, аның артыннан Сәйфетдинов «бомба» әйләнәсендә куркып, саклык белән генә әйләнәләр.

П р и с т а в. Әйе, «бомба»!

С ә й ф е т д и н о в. Ваше благородие, динамит түгелме икән?

П р и с т а в *(сискәнеп китеп)*. Әйе, адская машинага да охшый. Әй син, Сәйфетдинов, хәзер барып жандармский управлениегә хәбәр ит. Хәзер сыщиклар һәм адская машина алырга инженерлар җибәрсеннәр!

С ә й ф е т д и н о в. Слушаюсь, ваше благородие! *(Чыга.)*

П р и с т а в. Мин сезнең белән хәзер протокол язармын. *(Парикларны күреп.)* Ә болар нәрсәләр?

Ш а к и р җ а н. Чәчләре кубып калды.

П р и с т а в *(кулына алып)*. Аһа!.. Париклар! Монда зур шайка булган булырга кирәк. *(Утырып яза башлый.)* Чит кешеләр чыксыннар!

Г ө л җ а м а л, Г ы й л а җ  б а б а й чыга.

Ничә кеше иде?

Ш а к и р җ а н. Утыз мең.

П р и с т а в. Нәрсә?!

Ш а к и р җ а н. Әйе, утыз мең сум.

П р и с т а в. Ничә кеше иде?

Ш а к и р җ а н. Ике.

П р и с т а в. Өсләрендә нәрсә иде?

Ш а к и р җ а н. Күрмәдем.

П р и с т а в. Ничә яшьләрендә?

Ш а к и р җ а н. Белмәдем.

П р и с т а в. Башларында нәрсә иде?

Ш а к и р җ а н *(парикларны күрсәтеп)*. Менә чәч!

П р и с т а в. Аһа!..

С а д р ы й керә.

XVI. Ә ү в ә л г е л ә р  һәм С а д р ы й.

С а д р ы й. Нәрсә булды сездә? Исәнмесез, Николай Александрович!

П р и с т а в. А, а! Исәнмесез, Садрый Мортазич! Менә монда шайка эләктердек әле.

С а д р ы й. Шайка!

П р и с т а в. Чү, чү, Садрый Мортазич! Динамо-машина бар. *(Шакирҗанга.)* Ә бүген сезгә кемнәр килде?

Ш а к и р җ а н *(тәмам хәлдән таеп)*. Бер приказчик килгән иде. Аннан соң Сәгатьче сәгать төзәтеп китте. Аннан соң... теге әкият язучы Мансур малай килгән иде.

С а д р ы й. Ул ни өчен килгән иде?

Ш а к и р җ а н. Әкияте өчен акча сорарга.

С а д р ы й. Акча бирдегезме?

Ш а к и р җ а н. Бирдем дә, аз дип, алмыйча чыгып китте.

П р и с т а в *(зур эш ачкан шикелле)*. Так, так, так...

Ш а к и р җ а н. Ачуланып, янап чыгып китте.

П р и с т а в. Янады, дисезме?

Ш а к и р җ а н. Янады.

С а д р ы й. Николай Александрович, бер генә минутка монда килегез әле. *(Читкә чакыра.)*

П р и с т а в. Чем могу служить, Садрый Мортазич?

Садрый. Бу талауда шул Мансурның катнашы булырга тиеш.

Пристав. Ни өчен алай уйлыйсыз, Садрый Мортазич?

Садрый. Ул беркөн дачада шулайрак аңлатты. Безнең әле татар байларыннан аласы иманаларыбыз бик күп, диде.

Пристав. Дальше?

Садрый. Аны шул талау алдыннан гына, бүген түбәндә парадный төбендә бер кеше белән сөйләшеп торганын күргәннәр.

Пристав. Аһа!.. Мин дә шулдыр дип уйлаган идем. Аның фамилиясе Исмәгыйлов шикелле?

Садрый. Әйе, Исмәгыйлов.

XVII. Әүвәлгеләр һәм Сәйфетдинов.

Сәйфетдинов. Дежурныйны жандармский управлениегә җибәрдем.

Пристав. Ярый. Әй син, Сәйфетдинов, сакла, шартламасын!..

Сәйфетдинов. Слушаюсь, ваше благородие!..

Пристав. Ә безгә теге бүлмәгә чыгып протоколны тәмам итәргә кирәк. Аңынчы инженерлар да килеп җитәр. *(Кәгазьләрен җыеп, ике кулында ике парикны тотып.)* Һа, канальялар!.. Эләктегезме?

Уң якка чыгып китәләр. Сәйфетдинов «бомба» алдында үрә катып, кылычын чыгарып, калтыранып басып кала.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мансурның бүлмәсе. Уртада һәм сулда ишекләр. Ике якта ике тәрәзә. Өстәл өстендә китаплар. Карават. Бүлмә уртача җыештырылган.

I. Мансур ялгыз.

Мансур *(язып утыра).* Менә тәмам да булды. *(Язган кәгазьләрен актарып.)* Үһ-һу!.. Аз дигәндә биш йөз юл булыр. Юлы ике тиеннән хисаплаганда... ун сум. Һу!.. Бүген илтеп бирсәм, иртәгә укып чыксалар, берсекөнгә бассалар... биш-алты көннән шыгырдап торган унлык безнең кесәдә булачак. Биш сумын әбигә бүлмәсе өчен бирсәм, дүрт сумын кибеткә ашаган өчен түләсәм, алты сумын учительгә бирсәм, калганына бик нык итеп киерел-

гәнче ашармын. Тукта, тукта, ашауга күпме кала икән? Биш сум да, дүрт сум, була тугыз сум. Тугыз сум да алты сум, була унбиш сум... *(Сызгыра.)* Биш сум тулмый ич. Бу ничек була инде? Минем кесәмдә, бурычларны түләгәннән соң, бер сум чамасы акча калырга тиеш иде бит. Ә монда биш сум тулмый әле. Бу ничек болай булып чыкты соң? Биш тә дүрт тугыз. Тугыз да алты унбиш. Юк, чыкмый. Ничек соң бу болай? *(Кинәт.)* Фу, шәйтан, хикәя яза-яза тәмам баш чуалган бит. Алты сум бүген тәрҗемә өчен Ильясның китерәсе бар бит әле... Шулай шул. Төгәл бер сум ашарга кала. *(Киенә башлый.)* Тукта, әбигә әйтеп куярга кирәк. Әби, әби!

Әби керә.

II. Мансур һәм әби.

Әби. Нәрсә, балакай? Самавыр кирәкме әллә?

Мансур. Юк, әби, самавырны кичкә шәпләп кайнатып куярсың. Менә нәрсә: мин хәзер чыгып китәм. Минем бер иптәшем бүген миңа акча китерәчәк. Әгәр дә килсә, мине көтсен.

Әби. Нинди акча?

Мансур. Минем өлешемә тигән акча. Хәзер кайтыр, диең. Мине көтсен!

Әби. Ярый, балакай. Тыңласа әйтермен. Бүген әле хуҗа да фатир акчасы өчен тагы хезмәтчесен керткән иде. Иртәгә Мансурдан алгач бирермен, дидем.

Мансур. Яхшы иткәнсең. Без, әби, хәзер баедык инде. Байның фатир акчасын гына түгел, йортын сатып алырга да мөмкин.

Әби. Ай, балакай, самавырым ташый торгандыр. Чәй эчмичә генә чыгасыңмыни?

Мансур. Эчмичә генә.

Әби. Алайса, каплап куярга кирәк. *(Чыга.)*

III. Мансур ялгыз.

Мансур. Тизрәк барырга кирәк. *(Эшләпәсен киеп чыгып барганда, Ибраһимга очрый.)*

IV. Мансур һәм Ибраһим.

Ибраһим. Уф, уф!.. Менә әкәмәт! Бу хәлләрне күрермен дип уйламаган идем.

Мансур. Нәрсә? Сиңа тагын ни булды?

Ибраһим. Адәм мәсхәрәсе иттеләр, туган. Ярый әле, котылдым.

М а н с у р. Нәрсә, ни булды? Әллә ашаган өчен түләмичә чыгып барганда эләктеңме?

И б р а һ и м. Кичә көнозын бернәрсә ашамаганым үзеңә мәгълүм бит.

М а н с у р. Йә?

И б р а һ и м. Шул. Ачлыктан төне буе йоклый алмадым. Таңнан торып Минһаҗга барганда, теге мәлгунь Шакирҗан байның капкасы төбендә тотып, арестовать итеп, охранный отделениегә алып барып, тоташтан биш сәгать сөйләттеләр. Сөйли-сөйли телләрем талып бетте. Барлык документларны алып калдылар. Эттән дә битәр ачыктым. Кесәдә бер тиен акча юк. Кая, зинһар, әбидән алып булса да, бер сум биреп тор әле. Иртәгә түләрмен.

М а н с у р. Ни өчен соң арестовать иттеләр?

И б р а һ и м. Кем белә аларны. Берсе, «бомба», ди. Икенчесе, утыз мең, камыр, ди. Башыма париклар киертеп чәчләремне тузгытып бетерделәр. Алдыма корымга буялган түгәрәк бер нәрсә китереп куеп, моны берәр яры күргәнең юкмы, дип сорыйлар. Сине дә сораштылар.

М а н с у р. Хуш?

И б р а һ и м. Әй, чәнчелеп китсеннәр лә. Кая, иптәш, бик ашыйсы килә бит. Эчәгеләр тишек насос шикелле чыж да чож килә.

М а н с у р. Янымда бер тиен дә юк шул. Кичкә булыр.

И б р а һ и м. Бер ун гына тиен юкмы, ичмасам?

М а н с у р. Чирек тиен дә юк.

И б р а һ и м. Ичмасам, бераз күмәч бир.

М а н с у р. Күмәч булса, үзем рәхәтләнеп чәй эчәр идем әле.

И б р а һ и м. Инде ни эшләргә?.. Шулай ук бүген ачка үләргә туры килерме икәнни?

М а н с у р. Әгәр дә берәр сәгать ашамыйча чыдый алсаң, акча була.

И б р а һ и м. Юк, иптәш, бер сәгать түгел, бер минут та чыдар хәлем калмады... Бер сәгатьтән буламы соң?

М а н с у р. Тәгаен була.

И б р а һ и м. Кәкре каенга гына сөятмәссеңме икән?

М а н с у р. Була, дим инде. Ильяс берәр сәгатьтән тәрҗемә өчен минем өлешемне китерәчәк.

И б р а һ и м. Ул өлешкә генә тигән булгач, бер туярлык та булмас инде.

М а н с у р. Туярлык булыр, кайгырма. Көтеп тор шунда. Кара әле, бәлки, ул үзе китермәс. Берәр кеше артын-

нан гына җибәрер. Ул вакыт инде мин булып акчаны алып калырсың.

Ибраһим. Ничек син булып?

Мансур. Шулай, Мансур булып. Юкса акчаны бирмәү ихтималы бар бит.

Ибраһим. Юк инде. Андый һавадагы акчаны көтеп монда вакыт уздырганчы, берәр яры барып сугылырга кирәк. *(Тора. Эшләпәсен кия.)*

Мансур. Әгәр дә рәт чыкмаса, миңа кил.

Ибраһим. Юлда егылып үлмәсәм килми дә булмас шул.

Чыгалар.

V. Садрый ялгыз.

Садрый *(керә, карана)*. Һә, галах малай, менә хәзер инде карыйк. Ничек итеп бу боткадан ычкынырсың икән. Бай кызлары тирәсендә күп йөренә торгач, синең ише маңка малайларны шулай итеп өйрәтәләр. *(Кәгазьләрен чыгарып кайсын китап эченә куя, кайсын карават астына ташлый.)* Менә бу кәгазьләр синең арт сабакларыңны өйрәтәчәкләр. *(Кәгазьне, калын китап эченә куйганда, идәнгә төшерә.)* Фу, чәнчелгере!

VI. Әби һәм Садрый.

Әби *(сәхнә артыннан чыгып кычкыра)*. Перес! Перес! Алланың дәргяһыннан сөрелгән[1] нәрсә, монда килеп җиттеңмени? *(Чыга.)* Әбәү, монда кеше бар икән. Сезгә кем кирәк?

Садрый. Мин Мансур әфәнденең иптәше булам. Йомыш бар иде. Өйдә юк икән.

Әби. Хәзер генә чыгып китте.

Садрый. Алаймы? Хушыгыз!.. *(Чыга башлый.)*

Әби үз бүлмәсенә китә, ишектә Мөршидә очрый.
Садрый белән Мөршидә бер-берсен күрү белән катып калалар.

VII. Садрый һәм Мөршидә.

Садрый *(паузадан соң)*. Мөршидә иптәш, ничек болай монда киләсе булдыгыз?.. Әллә җөйче кызыгыз монда торамы?

Мөршидә дәшми.

Каушамагыз. Була ул... Менә мин дә тегүче эзләп монда ялгыш кергәнмен. Сез, бәлки...

---

[1] Дәргяһтан сөрелү — мәрхәмәттән мәхрүм ителү.

Мөршидә *(батыраеп)*. Мин Мансур әфәндегә килгән идем.

Садрый. Үзегез генәме?

Мөршидә. Әйе, үзем генә.

Садрый. Кара син аны. Сезнең яңа һөнәрләрегез дә бар икән. Безнең бай йортларында үскән кызлар түгел, рәтлерәк асрауларыбыз да мондый эшләр белән чуалмыйлар.

Мөршидә. Сез мине монда килергә мәҗбүр иттегез.

Садрый. Мин?!

Мөршидә. Әйе, сез. Әгәр дә кичә полициягә Мансур өстенә ялган ялалар ябып, донос ясаган булмасагыз, мин монда килмәгән булыр идем.

Садрый. Кара син аны. Ха-ха... Сез фискал да була беләсез икән. Әллә Шакирҗан байның йортына кереп таларга да сез юл күрсәттегезме?

Мөршидә. Йә Алла! Сез нәрсә сөйлисез?

Садрый. Каушамагыз, каушама... Хәер, сез алданган гына бит. Мин сездән андый начар эш булыр дип шикләнмим.

Мөршидә. Әллә юкса... *(Елый башлый.)*

Садрый. Тынычланыгыз, Мөршидә туташ! Мин хәзер сезнең алдыгызда бер сер ачарга мәҗбүр булам. Сез талаучылар тозагына эләккәнсез бит. Сез, Мансур малайның төче телләренә ышанып, үзегезне тәмам хур иттегез бит. Шул жулик, талаучы малай белән бөтен шәһәргә данызыз таралачак.

Мөршидә. Садрый әфәнде, мине тәхкыйрь кылмавыгызны[1] үтенәм.

Садрый. Мин сезне тәхкыйрь кылмыйм. Бөтен шәһәр ду килә ич.

Мөршидә. Нәрсә?

Садрый. Мансурларны Шакирҗан байны талатырга ишек ачып кертүче сез дип...

Мөршидә. Ярабби! Бу ялган каян килеп чыккан тагын?

Садрый. Мин дә башта ышанмаган идем. Әмма хәзер сезне монда очраткач ышанырга туры килә шул. Дөрес, мин сезне яман ният белән эшләгәнсез дип әйтә алмыйм. Яшьлегегез белән бер жуликның тозагына төшкәнсез. Ул сезгә китап биргән булып, сезне сөйгән булып маташуы, сезнең өчен түгел, Шакирҗан байның акчасын талау

---

[1] Тәхкыйрь кылу – хурлау, мыскыллау.

өчен хәйлә булганын хәзер үзегез дә күрә торгансыздыр.

Мөршидә *(куркып)*. Сез ни сөйлисез? Мансур аны һич эшләмәс! Сез генә шулай уйлыйсыз. Сез Мансурдан үч алыр өчен эшләгән эшләрегезгә мине ышандырмакчы буласызмы әллә? Юк, юк, Мансур андый кеше түгел. Кичәге талауда Мансурның катнашы юклыгына минем шөбһәм юк. Садрый әфәнде, Алла хакы өчен, Мансур өстенә яла якмагыз! Мин аны сөям. Мин сезгә булачак кеше түгел. Үлсәм дә мин сезгә булачак кеше түгел. Безнең арабызга кермәгез, Мансурны харап итмәгез! Беләм, сез монда яхшы ният белән йөрмисез. Кызганыгыз безне!.. Әгәр дә Мансур хакына яхшылык эшлисегез килмәсә, минем өчен, үлгән атам хакы өчен, Мансурны да, мине дә харап итмәгез! Мәрхүм әткәм сезнең әткәгезнең дусты булган бит.

Садрый. Менә шуңа күрә дә мин сезне шул жуликларның тозагыннан коткарырга тырышам.

Мөршидә. Ул жулик түгел. Мансур – яхшы кеше. Аның талауда зәррә кадәр гаебе юк.

Садрый. Сез шулай дип әйтәсез дә бит, полиция икенче төрле сөйли.

Мөршидә. Полиция сезнең сүз буенча гына Мансурдан шикләнә бит. Сез юк дисәгез, алар ышанырлар.

Садрый. Мин ялганлый алмыйм шул. Аннан соң талаганны таламаган дип әйтеп үземне үзем бәйләр хәлем юк.

Мөршидә. Садрый әфәнде, сездән ялынып, ялварып сорыйм. Безне харап итмәгез!..

Садрый *(гаять кызып)*. Безне? Ха-ха!..

Мөршидә. Әйе, безне. Мин Мансурны сөям. Мин мәңгегә, мәңгегә аныкы. Көзгә безнең туебыз була.

Садрый. Ә мин?!

Мөршидә. Мин сезнеке була алмыйм.

Садрый. Юк, сез минем хатыным булырга тиешсез!

Мөршидә. Мөмкин түгел. Мин сезнеке була алмыйм.

Садрый. Мөршидә туташ, сез яшьлек белән генә бу сүзләрне сөйлисез. Мин сезне Мансур малайга караганда мең өлеш артык бәхетле ясармын бит. Сез бер генә минутка булса да акылыгызны башыгызга җыеп карагыз әле. Мансур белән нинди бәхет табармын дип уйлыйсыз? Менә күрәсезме аның тора торган урынын? Нигә охшый? Гомерегез буенча хәерчелектә яшәячәксез бит. Мин сезне

сөям. Мин сезне кадерләрмен. Мин сезне бөтен көчем белән бәхетле ясарга тырышырмын. Дөрес, минем гаепләрем бар. Ләкин яшьлектә кемдә булмый ул. Әгәр дә сез минем хатыным булсагыз, ант итеп әйтәм, менә дигән ир булырмын. Хәзерге бөтен гадәтләремне ташлап, сезнең сүзегездән чыкмаска сүз бирәм. Мөршидә туташ, үзегезне дә, мине дә харап итмәгез! Йә, ризамы?

Мөршидә. Юк. Мин үз иркемдә түгел. Мансурдан аерыла алмыйм. Әгәр дә миңа аз гына ихтирамыгыз булса, минем өчен, минем хакыма, Мансурны харап итмәгез!

Садрый. Мөршидә туташ! Актык сүзем: әгәр дә Мансурны ташларга көчегез җитмәсә, бу пычрак эшкә сез дә эләгәсез бит.

Мөршидә. Әгәр дә вөҗданыгыз күтәрсә, теләсәгез, хәзер үк мине харап итегез! Күрәсез, минем монда бер ярдәмчем дә юк.

Садрый. Менә нәрсә, Мөршидә туташ, мин сезгә эчемдәге бөтен серләремне әйттем. Үземне сезнең кулыгызга тапшырырга булдым. Әмма сез... Моннан соң мин нинди генә начарлык эшләсәм дә, никадәр түбән төшсәм дә, сәбәпчесе сез икәнлеген хәтерегездән чыгармагыз! Үзегез мине мәҗбүр итәсез.

Мөршидә. Садрый әфәнде, эш минем ихтыярда түгел. Соң мин ни эшлим?

Садрый. Ярый, чүбек чәйнәүдә мәгънә юк. Берберегезне сөясез икән, чәнчелегез!.. *(Начар күз белән озак итеп Мөршидәгә карап тора.)* Мансурны коткарасыгыз киләме?

Мөршидә. Менә рәхмәт сезгә, Садрый әфәнде!

Садрый. Хәзер сез минем белән извозчикка утырып барырга тиешсез.

Мөршидә *(куркып)*. Кая?

Садрый. Баргач белерсез...

Мөршидә. Нәрсә?

Садрый. Әгәр дә хәзер минем белән бармасагыз, ул вакытта соң булыр.

Мөршидә. Кая чакырасыз?

Садрый. Мансурның эшләрен барып җайларга кирәк. Юкса аны бүген төнлә арестовать итүләре бик ихтимал. Бер кулга алынгач коткаруы читен булыр.

Мөршидә *(читкә)*. Ярабби! Бу кеше мине кая алып бармакчы була икән?

Садрый. Ризамы?

Мөршидә. Сез мине кая алып бармакчы буласыз?

Садрый. Әйттем бит инде.

Мөршидә. Юк, мин сезнең белән бара алмыйм.

Садрый. Ихтыярыгыз. Мансур сезнең өчен кадерле бит. Ә миңа дисә, асмагайлары, тереләй җиргә күмсеннәр үзен.

Мөршидә. Нәрсә? Әллә Мансурны асарлармы?

Садрый. Асу гына түгел, чәнчелдереп төшерерләр. «Руки вверх!» уен эш түгел ул.

Мөршидә. Ярабби!.. Сез мине кая чакырасыз соң?

Садрый. Баргач белерсез.

Мөршидә. Полицмейстергамы?

Садрый. Баргач белерсез.

Мөршидә. Ярый, әйдәгез!

Садрый *(чыга-чыга)*. Бер атуда ике куян... Ха-ха!..

Чыгып китәләр.

VIII. Сәйфетдинов ялгыз.

Сәйфетдинов *(өстән казаки, эчтән полиция киеме кигән килеш, кереп карана)*. Өйдә юкка охшый. Әмма эләктерсәм, медальнең шәбен бирерләр иде соң. Шакир байдан да бер егерме биш тамар иде. Тукта, бу бүлмәдә нәрсә бар икән? *(Чыга.)*

IX. Сәйфетдинов һәм әби.

Сәйфетдинов *(сөйләшеп керәләр)*. Кая китте соң?

Әби. Белмим. Сезгә соң ул ни эшкә кирәк?

Сәйфетдинов. Мин аның авылдагы абзасы булам.

Әби. Алай икән.

Сәйфетдинов. Туган абзасы. Соң ничек, энекәш акчага бик интекмиме?

Әби. Интекмәгән кая инде. Менә әле бүлмә өчен миңа да түли алганы юк. Ашау-эчүенең дә бер дә рәте юк. Яртылай ач тора, мескенкәем. Минем дә арттырырлык кисәгем булмый. Әнә шул, бүлмәләр тотып, очны очка ялгап, көчкә генә торам шунда.

Сәйфетдинов. Ә үзе соң тиз кайтырмы?

Әби. Бер дә белмим.

Сәйфетдинов. Соң, чыгып киткәндә, бер сүз дә әйтмәдемени?

Әби. Хәзер кайтырмын, көтеп торсын, диде.

Сәйфетдинов. Ә аңа кунак киләсе бармыни?

Әби. Юк. Иптәше акча китермәкче булган, ахрысы.

Сәйфетдинов. Нинди акча икән ул?

Әби. Өлешенә тигән акча.

С ә й ф е т д и н о в. Өлешенә тигән, диең, ә?

Ә б и. Әйе.

С ә й ф е т д и н о в. Алай!.. *(Халыкка.)* Йомгакның очы монда икән. *(Әбигә.)* Шулай инде, юк вакытта бер сум да зур акча инде.

Ә б и. Нинди бер сум?

С ә й ф е т д и н о в. Мансурга иптәше китерәчәк акча, дим.

Ә б и. Нигә, бер сум гынамыни?

С ә й ф е т д и н о в. Артык булмас, дип уйлыйм. Алар бит сәүдәгәр түгел.

Ә б и. Ай Алла, шулай бер генә сум булырмы икән? Бүлмә өчен тагы бирә алмасмы икәнни?

С ә й ф е т д и н о в. Бәлки, артыграк та булыр, мин белеп әйтмим.

Ә б и. Артыграк булыр шул. Ник дисәң, миңа гына биш сум бирәсе бар. Кибетчегә дүрт сум.

С ә й ф е т д и н о в. Бүген түлим, димәгәндер бит?

Ә б и. Тәгаен бүген кичкә түлим, диде. Әйткән сүзендә тора торган иде. Әйе, әйе, кичкә түлим, диде. Байыйбыз, әби, кайгырма, байыйбыз, диде. Аз акча кулына төшкәндә, бер дә алай кычкырынмый иде.

С ә й ф е т д и н о в. Бер дә үзгәрмәгән икән. Авылда да шулай кулына бераз акча керсә кычкыра башлый иде. Яшь шул әле, яшь. Кычкыра, диең, ә?

Ә б и. Кычкыра, балакай, бик кычкыра. Байның йортын сатып алырмын, ди.

С ә й ф е т д и н о в. Кара син аны. Йорт сатып алырбыз, диең, ә? Хи-хи-хи!.. Ай, бу яшьләрне... Бераздан әйләнеп керермен. *(Борылып.)* Ә соң өйдән үзе генә чыгып киттеме?

Ә б и. Иптәше белән.

С ә й ф е т д и н о в. Байыйбыз дип кычкыра, диең. Барлык тапкан акчасын иптәшләренә ашатып бетермиме соң?

Ә б и. Белмим инде, ничектер.

С ә й ф е т д и н о в. Бәлки, акчалы иптәшләре дә бардыр?

Ә б и. Каян беләсең, бәлки, бардыр да.

С ә й ф е т д и н о в. Күбәүме соң үзләре?

Ә б и. Кайсы чагында унар кеше җыелып, бүлмәне тәмәке төтененә тутырып, бөтен күмәчне ашап бетереп чыгалар.

С ә й ф е т д и н о в *(халыкка)*. Менә кайда икән динамит шайкасы! *(Әбигә.)* Ә машиналар һаман да ясыймы?

Ә б и. Ясый торгандыр инде. Ашарга кирәк бит.

С ә й ф е т д и н о в. Ярый, әби, мин бераздан кайтып керермен. Мин килгәнче кайтса, мин килгәнне әйтмә. Үзем күренеп бер шатландырыйм әле энекәшне. Хуш, әби! *(Чыга.)*

Ә б и. Хуш, бәбкәм, хуш. *(Үз ягына чыга.)*

X. С ә й ф е т д и н о в ялгыз.

С ә й ф е т д и н о в *(кайтып кереп, яшеренеп)*. Юк инде, бу шайканы кулдан ычкындыру юк. Нәрсәләре бар икән? Динамитлары кая икән? *(Карават асларын актара. Соңыннан өстәлгә килеп китапларын актарып, бер калын китапны алып укый башлый.)* Ту-ту... Тул- стый... В-в-вай-н-н-наимир... ур-ман... Гһә, тулстый, вайна, мир, урман... Моның мәгънәсе нәрсә икән? Әһә, болар урманда безгә, начальствога каршы, вайна ачарга уйлыйлар икән. Ваше благородиегә илтеп бирим әле. Ул мондыйларның иҗеген дә, сүрәсен дә белә иде.

XI. С ә й ф е т д и н о в һәм Ш ы м ч ы.

Ш ы м ч ы. Берсе килә. Капкадан керә калды.

С ә й ф е т д и н о в. Син үзе белән сөйләш... Мин карчык янына чыгам. *(Чыга.)*

XII. Ш ы м ч ы һәм И б р а һ и м.

И б р а һ и м *(кереп, шатланып)*. Ә, сез килгәнсез дә икән. Кая, тизрәк бирегез!

Ш ы м ч ы *(елмаеп)*. Нәрсәне?!

И б р а һ и м. Нәрсә булсын, акча!

Ш ы м ч ы. Акча?

И б р а һ и м. Сине Ильяс Әхмәтов җибәрдеме?

Ш ы м ч ы. Белегез!

И б р а һ и м. Ашагач... *(төчкерә)* мин сезне белермен.

Ш ы м ч ы. Бүген пароль «ашагач»мыни?

И б р а һ и м. Ашагач, әйе лә. Сезне Ильяс җибәрдеме, дим?

Ш ы м ч ы. Әйе, ул.

Сәйфетдинов ишектән карый.

Ә соң сез үзегез кем?

И б р а һ и м. Мин Ибраһим. Ә, юк ла, мин, мин... Мансур булам. Кая, минем өлешемне бирегез. Минем ашаганым юк.

Ш ы м ч ы. Сезнең өлешкә күпме тиде, дип уйлыйсыз?

И б р а һ и м. Йөз мең булмас инде. Күпме җибәргән булса, шул инде.

Ш ы м ч ы. Ул сума ничә кешегә бүленде дип беләсез?

И б р а һ и м. Икегә булырга кирәк.

Ш ы м ч ы. Соң сез аны икәү генә эшләдегезмени?

И б р а һ и м. Икәү генә.

Ш ы м ч ы. Бик авырга килгәндер?

И б р а һ и м. Авырга килмәгән кая. Яза-яза бармакларга сөялләр чыгып бетте.

Ш ы м ч ы. Комитетка күпме бирелде дип беләсез?

И б р а һ и м. Кайсы комитетка?

Ш ы м ч ы. Билгеле, үзебезнекенә…

И б р а һ и м. Комитетыгызда эшем юк. Минем үз өлешемне генә тизрәк бирегез. Ашыйсым килә. Үләм инде. Йөгерә-йөгерә тәмам хәлдән тайдым. Егерме алты сәгать тоташтан бернәрсә ашаганым юк бит.

Ш ы м ч ы. Утыз меңгә туярга мөмкин.

И б р а һ и м. Нинди утыз меңгә?

Ш ы м ч ы. Кичәге.

И б р а һ и м. Бүген булды бит ул. Биш сәгать тоташтан сөйләттеләр. Сөйли-сөйли телем калмады. Камыр, диләр, утыз мең, диләр. Сез дә беләсезмени аны?

Сәхнә артында кыштырдаган тавыш ишетелә.

Ш ы м ч ы *(револьверын чыгарып)*. Сез арестован!..

И б р а һ и м. Шаяртмагыз әле… *(Револьвердан томмакчы була.)*

С ә й ф е т д и н о в керә.

XIII. И б р а һ и м, Ш ы м ч ы һәм С ә й ф е т д и н о в.

Ш ы м ч ы. Моны алып китегез! Мин башкаларны кабул итәм.

И б р а һ и м. Шаяртмагыз әле. Әллә ачка үтермәкче буласызмы?

Ш ы м ч ы. Үлмәссез, үлмәссез. *(Сәйфетдиновка.)* Сез кара ишектән чыгыгыз. Хәзер ярдәмгә килсеннәр.

С ә й ф е т д и н о в. Слушаюсь!

Чыга башлыйлар.

Әйдәгез, чибәр егет!

И б р а һ и м. Болардан ачка үлмичә котылып булмас, ахры.

Уң якка чыгалар. Шымчы ялгыз калгач карана, эзләнә. Садрый калдырган кәгазьләрне таба.

Шымчы. Аhа!.. Талый белгәннәр, эзләрен яшерә белмәгәннәр. Яңараклар, ахрысы.

XIV. Шымчы һәм Шакирҗан.

Шакирҗан *(ишектән, куркып, башын тыгып карый)*. Мөмкинме?

Шымчы. Рәхим итегез! *(Халыкка.)* Монысы сакаллар куеп йөри икән.

Шакирҗан. Әссәламегаләйкем! Исәнме, саумы, сәламәтме! *(Карана.)* Мансур әфәнде өйдә юкмыни?

Шымчы. Хәзер кайтыр.

Шакирҗан. Кая гына китәсе булды икән? Сез белмисезме?

Шымчы. Йомыш белән генә китте. Хәзер кайтыр. Рәхим итегез, утырыгыз!

Шакирҗан *(утыра, карана)*. Тиз кайтырмы икән?

Шымчы. Хәзер кайтырга тиеш. Сез әлеге эш хакында килдегезме?

Шакирҗан. Кайсы эш?

Шымчы. Өлешегезне алырга килдегезме?

Шакирҗан *(халыкка)*. Мордарлар! Минем хәләл акчаларымны өлешләп бүлеп тә өлгергәннәр икән.

Шымчы. Нигә дәшмисез?

Шакирҗан. Өлеш, диең, ә?

Шымчы. Әллә шикләнәсезме?

Шакирҗан. Зәррә кадәр дә шикләнмим.

Шымчы. Сезнең өлешкә күпме тиде?

Шакирҗан. Тиде инде. Алла хәерле кылсын. Менә шуның аркасында Аршауга китә алмыйча калдым.

Шымчы. Варшавага? Кайчан китмәкче идегез?

Шакирҗан. Бәйрәмнәрне үткәргәч тә китәргә иде исәп. Менә бу эшләр килеп чыкты.

Шымчы. Хуш?

Шакирҗан. Тәмам аяктан екты.

Шымчы. Хуш, хуш?

Шакирҗан. Үз кешегә бу кадәр бер дә килешми инде. Мин аның китабын бастырдым. Үземчә яхшылык иттем. Изгелеккә каршы яманлык шул була инде.

Шымчы. Әллә җәберләделәрме?

Шакирҗан. Җәберләмәгән кая, бөтенләй пычаксыз суйды.

Шымчы. Өлешегезне бирмәдеме әллә?

Ш а к и р җ а н. Нинди өлеш? Нәрсә саташасың тагы?
Ш ы м ч ы. Пычаксыз суйды, дисез ич.
Ш а к и р җ а н. Суйды шул, пычаксыз суйды. Менә моннан, иңсәдән суйды.
Ш ы м ч ы. Күпме генә бирде соң?
Ш а к и р җ а н. Нәрсә, кем бирде?
Ш ы м ч ы. Акча.
Ш а к и р җ а н. Акча?
Ш ы м ч ы. Сез миннән һаман шикләнәсез. «Ашагач»... *(Төчкерә.)*
Ш а к и р җ а н. Ярхәмәкеалла! Нәрсәне ашагач?
Ш ы м ч ы. Пароль.
Ш а к и р җ а н. Орёл?
Ш ы м ч ы *(халыкка)*. Монысы бигрәк усал икән.
Ш а к и р җ а н. Юкка гына ул миңа ачу тота. Китабын нинди пөхтә итеп бастырдык.
Ш ы м ч ы. Аның китабын сез бастырдыгызмыни?
Ш а к и р җ а н. Соң.
Ш ы м ч ы. Типография әле һаман шул урындамы?
Ш а к и р җ а н. Шул урында булмыйча, кая булсын?
Ш ы м ч ы. Урыны тынычмы соң?
Ш а к и р җ а н. Хәзергә Аллага шөкер, тыныч әле.
Ш ы м ч ы. Әле һаман шул ни... дәме?
Ш а к и р җ а н. Капкадан кергәч.
Ш ы м ч ы. Әйе, хәтерлим. Бер мәртәбә булганым бар иде.
Ш а к и р җ а н. Әллә сезнең бездә берәр нәрсә бастырганыгыз бармы?
Ш ы м ч ы. Җир хакында бер нәрсә.
Ш а к и р җ а н. Мансур әфәнде гулять итәмени?
Ш ы м ч ы. Гулять итмәскә. Хәзер бит бай чак.
Ш а к и р җ а н *(сынап)*. Әллә... ничек? Атасыннан акча килдемени?
Ш ы м ч ы. Ә утыз мең...
Ш а к и р җ а н. Ә?! *(Халыкка.)* Имансызларның шайкалары монда икән. Акчамны туздырып бетермәс борын полициягә барып әйтергә кирәк. *(Шымчыга.)* Мансур әфәнде кая гулять итә? Белмисезме?
Ш ы м ч ы. Сез дә анда бармакчы буласызмы?
Ш а к и р җ а н. Юк, мин болай гына... *(Халыкка.)* Тизрәк полициягә әйтергә кирәк. *(Шымчыга.)* Ярый. Хуш булыгыз!

Китмәкче була. Шымчы револьверын чыгарып каршы тора.

Шымчы. Руки вверх!

Шакирҗан. Каравыл! Каравыл! Талыйлар! Талыйлар!

Шакирҗан белән Шымчы көрәшә башлыйлар. Шымчы Шакирҗанны егып, сакалын йолкый башлый.

Шымчы. Һе, сакал куйдыңмыни? Сакал куйдыңмыни!.. Чорт, нинди каты ябышкан!..

Шакирҗан. Каравыл! Сакалым! Каравыл! Сакалым!.. Үтерәләр!.. *(Шымчының сакалына ябышып, куйган сакалын тартып ала.)*

Пристав һәм Сәйфетдинов керәләр.

XV. Шымчы, Шакирҗан, пристав, Сәйфетдинов.

Сәйфетдинов *(кулында револьвер)*. Ваш благороди! Бөтен шайкаларын тоттым.

Пристав *(каушап, револьверын төзәп)*. Руки вверх!

Шакирҗан *(кулындагы сакалга карап хәйран булган җиреннән, пристав тавышына уянып китеп, приставка каршы барып.)* Микалай Ләксәндрич! Сакал!.. Сакал! Сакал!

Пристав *(сакалны дикъкатьләп карап)*. Аһа, сакал!..

Шакирҗан. Әйе, әйе, билләһи газыйм, сакал. Кызыл авыз сакалы!..

Пристав. Действительно, сакал!

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук бүлмә.

I. Шакирҗан һәм Садрый.

Садрый *(яшерен кереп)*. Өйдә юк күренә. *(Кулы белән изәп.)* Әйдә, әйдә, өйдә юк.

Шакирҗан. Хуш, утыз мең эләккәч, нишләп өйдә торсыннар. Хуш, йә, кем, Садрый, хуш, инде нишлибез, хуш!.. Акчаны туздырып бетерәләр бит бу юньсезләр. Суга баткан шикелле булдылар бит. Бөтен полиция, бөтен жандармский управление аякта. Хуш, хәтта губернатор үзе дә ул юньсезләрне эзләргә чыккан, ди. Юк бит, юк. Тота алмыйлар. Ай, бу утыз мең, вакытсыз гүргә кертер,

ахрысы. Хуш, кемнәр генә кулында сез, җанкисәкләрем, газапланып йөрисез икән? Садрый, синеңчә, ничек? Хуш, утыз меңем табылырмы? Юкмы? Ә, хуш…

С а д р ы й. Алла кулындагы эш. Шулай да валлаһе әгъләм биссәваб[1], Шакирҗан абзый!

Ш а к и р җ а н. Шулай инде, энем, әүвәл – полиция, икенче Алла инде. Аллаһы хәзрәтләре полиция күңеленә Әбүгалисина сизгерлеген салсын иде. Хуш, хуш, тәмам акылым чуалды. Бүген иртә белән полицәмистергә менгән идем… Ни эшләп инде, дим, хуш, Никифр Никифрич, акчаларымны таба алмыйсыз, дим. Әллә юньләп эзләмисезме, дим. Хуш? Юк, ди, Шакирҗан бай, по всем статиәм эзлибез, ди. Хуш, дим, алай булгач, каторый статиә хороший, дим? Статиәләр бар да хороший, ди. Айгырым авырып тора, яхшырак бер ат аласы, ди. Үзең дә беләсең, ди, каракларны җәяү эзләп булмый, ди. Биш йөз сум бирдем шул. Хәзер инде бәхетсез бу утыз мең расходлары белән утыз бишкә басты инде. Юк, юк, тапмыйча һич ярамый. Ул кызыл авызларның оялары монда. Бер кайтмый булмаслар әле. Кайтырлар. Хуш, кем, Садрый, теге бүлмәгә кереп кара әле, шунда сыра эчеп-нитеп утырмыйлармы икән?

С а д р ы й. Хәзер. *(Чыга.)*

Ш а к и р җ а н. Хуш, бүген төшемдә нәрсә күрдем соң?.. Юк шул, юк. Бернәрсә дә күрмәгәнмен, ахры. Кирәк чагында төше дә иңми бит, юньсез, барысы миңа каршы торалар. Барысы да каршы, хуш!..

II. Ш а к и р җ а н, С а д р ы й, ә б и.

С а д р ы й. Менә абыстайдан башка берәү дә юк.

Ш а к и р җ а н. Абыстай, менә сиңа нәзер сәдакам бар иде. Бик әйбәтләп кенә дога кыл әле.

Ә б и. Рәхмәт, рәхмәт. Алла гаип хәзинәләрен ачсын инде! Аллаһы әкбәр!

Ш а к и р җ а н. Абыстай, бу Мансур дигәнегез бер дә өйдә тормыймы әллә? Кайчан килмә, өйдә булмый.

Ә б и. Гел өйдә генә тора иде. Кичәле-бүгенле әллә ни булган үзенә. Өйгә кайтмыйча тора. Үзем дә борчылып беттем инде.

Ш а к и р җ а н. Соң кая киткән иде?

Ә б и. Иртә белән хәзер кайтырмын дип чыгып киткән җиреннән суга баткан шикелле булды.

---

[1] В а л л а һ е  ә г ъ л ә м  б и с с ә в а б – Алла дөреслекне белә.

Ш а к и р җ а н. Башка вакытларда читтә кунып ятканы булмый идемени?

Ә б и. Өйдә генә куна иде. Иптәшенең кәбестә бакчасына барган чакларда гына кунып кайта торган иде. Андый чакларда әйтеп китә торган иде.

Ш а к и р җ а н. Соң ул өйдә юк чакта аңар килеп, аны сораучылар булмадымы?

Ә б и. Булмаган кая. Кичә әллә никадәр кешеләр килеп аны сорадылар. Әле ул гынамы? Әллә нинди ирләр килеп ду күчеп сугышып, кычкырышып киттеләр. Базга качып кына сәламәт калдым. Ярый әле, нәрсәләрне урлап чыкмаганнар.

Ш а к и р җ а н. Хуш... Алай икән. Кичә сугыштылар, диең, ә?

Ә б и. Бик каты сугышканнар булса кирәк. Тавышлары базга кадәр аермачык ишетелде.

Ш а к и р җ а н. Бәлки, алар берәр нәрсә бүлгәннәрдер?

Ә б и. Бәлки, бүлгәннәрдер дә.

Ш а к и р җ а н. Менә нәрсә, абыстай. Мансур өйгә кайткач та, үзенә белгертмичә генә, миңа килеп әйт. Зур бакча каршысындагы Шакирҗан бай йортын сорасаң әйтерләр. Шулай итсәң, нәзер сәдакаларымны алтыннан тамызырмын... Хуш... Менә әүлиялар рухына тагы дога кыл! *(Сәдака бирә.)*

Ә б и. Аллаһы әкбәр. Ярый, кайткач та барып әйтермен. *(Чыга башлый.)* Ә, кем, син үзең кем буласың соң?

Ш а к и р җ а н. Мин, хуш... *(Садрыйга.)* Мин кем әле, хуш?

С а д р ы й. Бу Мансур әфәндене үзенең конторына хезмәткә алмакчы була.

Ә б и. Алай, бик рәхмәт инде. Юкса бик ярлы тора, мескенкәй. Баш-аяклы итә күрегез инде үзен. Сусаган булсагыз, самавыр куйыйм, байлар.

С а д р ы й. Юк, рәхмәт. Без хәзер китәбез.

Ә б и. Башка йомыш юкмы?

Ш а к и р җ а н. Хуш, юк, абыстай, юк!

Ә б и чыга.

Хуш, монда нәрсәләр икән? Китаплар. Шулар арасына яшермәделәрме икән? Караш әле, Садрый!..

Зур капчыктан китаплар актаралар.

Юк шул, юк...

С а д р ы й. Урлый белгәнне яшерә дә белгәннәрдер инде алар.

Ш а к и р җ а н. Юк, Алла боерса, минем хакым ул кызыл авызлар өстендә калмас. Минем малым, әлхәмделилла, зәкятле мал! Үземә үк насыйп булыр әле.

С а д р ы й. Амин! Шулай булсын инде.

Ш а к и р җ а н. Соң бит ул кызыл авызлар мал кадерен белә торган халыклармы? Әрәм-шәрәм итеп кенә бетерерләр. Ай, җанкисәкләрем, утыз меңкәйләрем, кайда гына хуҗасыз ятим булып тилмереп торасыз икән?

С а д р ы й *(читкә)*. Бер дә тилмереп тормыйлар әле.

Ш а к и р җ а н. Мине сагынып тилмерә торгансыздыр, бичаракайларым. Мин бит сезне нинди кадердә генә тотадыр идем. Шулай ук сезне кабат күрә алмаммы икәнни? *(Елый.)*

С а д р ы й. Борчылмагыз, Шакирҗан абзый, елауда файда юк. Каракларны эзләргә кирәк.

Ш а к и р җ а н. Эзлим дә бит, табылмыйлар. *(Елый.)*

С а д р ы й *(тәрәзәдән күреп)*. Чү, болар кемнәр?! Алар, алар, билләһи газыйм, алар!

Ш а к и р җ а н. Кемнәр? Әллә акчалармы?

С а д р ы й. Акчаларыңны урлаучылар.

Ш а к и р җ а н. Ә?!

С а д р ы й. Мансур белән Мөршидә. Монда таба киләләр.

Ш а к и р җ а н. Кая, кая бәдбәхетләр? *(Йодрыкларын селкеп.)* Һә, мин сезне, тәмуг кисәүләре!.. Һу, мин сезне, яхшыдан яман туган, иблис ялчылары!.. Чү, чү, кулларында чемоданнары да бар. Вокзалга, пристаньга түгелме икән?

С а д р ы й. Алар монда таба киләләр. Шәһәрдән качарга җыеналар, күрәсең. Бик вакытында үзләрен очраттык. Хәзер барып, полициягә хәбәр итәргә кирәк.

Ш а к и р җ а н. Полициягә дә, губернаторга да, охранкага да — барысына да хәбәр итәргә кирәк. Әйдә, киттек.

С а д р ы й. Без полиция белән кайтып килгәнче, алар шылсалар?

Ш а к и р җ а н. Хуш, шылырлар шул. Хуш, соң ни эшлибез?

С а д р ы й. Менә нәрсә, мин полициягә барып хәбәр иткәнче, син монда яшеренеп кал. Нәрсә сөйләшерләр. Бәлки, акчаңның кая яшергән урынын да ычкындырырлар. Әгәр инде нәрсәләрен алып кача башласалар чыгып тотарсың.

Ш а к и р җ а н. Хуш, бәрәкалла, мәслихәт. Хуш, кая качыйм, өстәл астынамы?

С а д р ы й. Ярамый.

Ш а к и р җ а н. Карават астына?

С а д р ы й. Ярамый.

Ш а к и р җ а н. Ишек артына?

С а д р ы й. Ярамый.

Ш а к и р җ а н. Монда башка качарлык урын да юк.

С а д р ы й. Ә менә кая, менә шул капчыктагы китапларны бушатыйк та, шунда кереп ят.

Ш а к и р җ а н. Мәслихәт... *(Кереп ята.)* Син инде, кем, Садрый, капчыкның авызын катырак бәйләп куй. Сизә күрмәсеннәр. Юкса үтереп үк китәрләр.

С а д р ы й. Була ул. Менә шулай. Мин киттем. *(Капчык авызын бәйли башлый.)*

Ш а к и р җ а н. Полициягә дә, губернаторга да — барысына да бар!

С а д р ы й чыга. Пауза.

III. М ө р ш и д ә һәм М а н с у р.

М а н с у р *(шашынып)*. Әллә шашканнармы алар? Ибраһимны күрмәдеңме?

М ө р ш и д ә. Аны кичә тотып япканнар.

М а н с у р. Төрмәгәме?

М ө р ш и д ә. Белмим. Ләкин япканнар.

М а н с у р. Хуш?

М ө р ш и д ә. Шул, кичәдән бирле бөтен полиция, охранка сине эзләп йөриләр. Бездә бөтен җирдә сакчылар, полицейскийлар тора. Мине һичбер яры чыгармыйлар. Шакирҗан абый һуштан тайдырганчы кыйнады. *(Елый.)*

М а н с у р. Синеме?

М ө р ш и д ә. Әйе. *(Елый.)*

М а н с у р. Ни өчен?

М ө р ш и д ә. Бергәләп урлагансыз, ди. Син аларга акча урынын күрсәткәнсең, ди. Акчаларымны хәзер табып китер, юкса үтерәм, ди. Көчкә генә бакча аркылы качып котылдым. *(Елый.)*

М а н с у р. Йә, тынычлан, Мөршидә... Хуш, мине эзлиләр, дисеңме әле?

М ө р ш и д ә. Бик эзлиләр.

М а н с у р. Хуш. Инде нишлибез?

М ө р ш и д ә. Безгә хәзер бу шәһәрдән бер минут тормыйча китәргә кирәк.

М а н с у р. Кая?

М ө р ш и д ә. Кая күз күрер. Ләкин хәзер, хәзер үк китәргә кирәк. Юкса сине дә, мине дә харап итәчәкләр.

М а н с у р. Минем бит бер тиен дә акчам юк.

М ө р ш и д ә. Миндә бар. Яхшырак нәрсәләремнең барын да менә монда төядем. Мин инде мәңгелеккә ул йорттан аерылдым. Әйдә, җаным, тизрәк китик. Зинһар, китик.

М а н с у р. Минем бит фельетоным өчен акча аласым бар.

М ө р ш и д ә. Күпме?

М а н с у р. Ун сум.

М ө р ш и д ә. Калсын, калсын. Монда эш акчада түгел, башта эш, аңлыйсыңмы, башта! Тотылсак, башыбыз гомергә харап булачак бит.

М а н с у р *(уйланып йөреп, капчык өстенә утыра)*. Менә юләр балыклар. Каян уйлап чыгарганнар, ә мин тагын Ильясның кәбестә бакчасында гамьсез ятам. Монда хәлләр болай икән.

М ө р ш и д ә. Ул кулыңдагы төенеңдә нәрсә тагын?

М а н с у р. Кәбестә. Яшелчәләр кибетенә күрсәтергә дип, Ильяс биреп җибәрде. Кара әле, Мөршидә, син җәйнең бу вакытында яңа кәбестә күргәнең бар идеме?

М ө р ш и д ә. Нигә булмасын.

М а н с у р. Мин бу вакытта яңа кәбестәне беренче тапкыр күрәм. Ильяс оранжереяда үстергән. Аңарда меңләп калды әле. Кил әле, җаным, утыр, бераз хәл җый! *(Капчыкка икәү утыралар.)* Шулай, китикме икән? Бәлки, бернәрсә дә булмас әле?

М ө р ш и д ә. Булмаган кая, акча синдә дип бөтен шәһәр шаулый.

М а н с у р. Бер яктан, шатлык, икенче яктан, бу аяк астыннан чыккан бәла башымны тәмам катырды, йә, буласы булыр. Кайгырма, җаным. Менә без хәзер икәү бергә. Бүгеннән син минем гомерлек дустым буласың. Шунысы җитә. Ә безнең киләчәкне…

М ө р ш и д ә *(торып)*. Шулай да, Мансур, китәргә ашыгырга кирәк.

М а н с у р. Өлгерербез әле.

М ө р ш и д ә. Килеп бассалар?

М а н с у р. Минем бу бүлмәне эзләп тапканчы бер атна үтәр.

М ө р ш и д ә. Садрый белә бит.

Ш а к и р җ а н *(Мөршидә капчык өстенә кинәт утыргында)*. Ай, кабыргам!

М а н с у р *(сикереп торып)*. Бу нинди тавыш?

М ө р ш и д ә *(капчыкны күрсәтеп)*. Менә моннан чыкты.

М а н с у р. Ха-ха-ха!.. Син, Мөршидә, бигрәк каушагансың. Колагыңа әллә нәрсәләр ишетелә башлаган.

М ө р ш и д ә. Юк, чынлап, шуннан чыккан төсле тоелды.

М а н с у р. Анда иске китаплардан башка бернәрсә дә юк. *(Капчыкны типкәли.)*

М ө р ш и д ә. Соң, тавыш?

М а н с у р. Әбинең биле сызлый торгандыр. Бу капчыкны үз урынына кертик әле. Чынлап та, уңайсызлап тора. *(Капчыкны типкәли-типкәли карават астына кертәләр.)* Менә шулай. Йә, кил, утыр, Мөршидә. *(Караватка утыралар.)* Менә нәрсә, җаным, бүген монда куныйк. Иртәгә мин теге ун сумны алгач, пароходка утырып, безгә, авылга китәрбез. Теге, морзаларча, бикәчләү сәяхәте булыр. Шәп бит?

М ө р ш и д ә. Син һаман шаярасың, Мансур. Безгә бүгенгә түгел, бер сәгатькә дә калырга ярамый. Аңлыйсыңмы син шуны? Ярамый, ярамый, ярамый.

М а н с у р. Кара әле, Мөршидә, син туй ясамас борын ук талаша башладың. Туйдан соң сугыша башламасаң ярар иде.

М ө р ш и д ә. Мансур, нигә син мәсьәләнең зурлыгын искә алмыйсың?

М а н с у р. Башта искә алган идем. Ләкин тора-бара һәрбер уңайсызлыкларга күнегелә икән. Минемчә, бер көннән бернәрсә дә булмас.

М ө р ш и д ә. Мансур, син минем белән чынлап сөйләшәсеңме, әллә...

М а н с у р. Бетте. Әйдә, киттек. Ун сум янса янар инде. Ә синең соң акчаң пароход билетына җитәрлекме?

М ө р ш и д ә. Артыгы белән.

М а н с у р. Алай булса, әйдә, киттек. *(Караваттан төшкәндә, капчыктагы Шакирҗанның аягына баса.)*

Ш а к и р җ а н. Ай, аягым!

М ө р ш и д ә *(сикереп төшеп)*. Бу нәрсә тагын?

М а н с у р. Тагын тавыш? Әллә караватастында кеше бармы?

Эзлиләр.

Юк, бернәрсә дә юк.

М ө р ш и д ә. Тәгаен менә монда кычкырган шикелле ишетелде.

М а н с у р. Әллә бу иске китапларга җеннәр ияләшкәнме? *(Капчыкны типкәли.)* Бер җирдә бернәрсә юк. Әби, әби!

IV. М ө р ш и д ә, М а н с у р һәм ә б и.

Ә б и. Нәрсә, кем бар анда? Ай, балакаем, кайттыңмыни?

М а н с у р. Әби, син элек шуны безгә әйт: билең авыртамы?

Ә б и. Бик авырта, балакай. Менә күсәк белән кыйнаган шикелле инде.

М а н с у р. Әйттем бит. Ха-ха-ха!..

Ә б и. Кунак бар икән. Күрми дә торам. Исәнме, бәбкәм. Кунакка самавыр куярга кирәк. Син, Мансур, балакай, кайда йөрисең? Кичәдән бирле башымны әйләндереп бетерделәр.

М а н с у р. Кемнәр?

Ә б и. Кемнәр икәнлекләрен белмим. Әмма башымны бик әйләндерделәр.

М а н с у р. Йә, йә?

Ә б и. Әллә нинди кешеләр килеп, сине сораштырып көтеп тордылар-тордылар да соңыннан сугыштылар. Базга качып кына котылдым. Аллага шөкер әле, нәрсәләремә тимәгәннәр.

М а н с у р. Соң син кемнәр икәнен сорашмадыңмыни?

Ә б и. Алдан килгәне абзаң дип әйтте үзен. Соңынтын килгәннәре әллә нәрсәләр сораштырып башымны әйләндереп бетерделәр.

М ө р ш и д ә. Әйттем бит...

М а н с у р. Йә, йә?

Ә б и. Шул, гөмбә, диләр, каравыл, диләр, акча, диләр. Башымны катырып бетерделәр. Бүген дә сине сорап бер әфәнде белән бер бай кеше килгәннәр иде. Йорты теге зур бакча каршында, ди. Әй, аты коргыры, исеме хәтеремнән чыккан лабаса. Әй балакай, кәбестә алып кайттыңмыни?

М а н с у р. Әби, син безгә самавыр куй. Безне бик һәйбәтләп сыйла!

М ө р ш и д ә. Юк, юк, рәхмәт. Безнең вакытыбыз юк, әби.

Ә б и. Минем самавырым бик тиз кайный. Хәзер булыр, балалар. Кәбестәңне... *(Ала башлый.)*

М а н с у р. Кешенеке ул, әби.

Ә б и. Ярый, ярый. Хәзер самавырым кайнап чыгар, Алла боерса. *(Чыга.)*

М ө р ш и д ә. Син чәйләр эчеп әллә төрмәгә ябыласың киләме?

М а н с у р. Нигә?

М ө р ш и д ә. Юк, Мансур, бу шаяруларың урынсыз. Бел дә тор: килеп басарлар.

М а н с у р. Безнеме?

М ө р ш и д ә. Әйе.

М а н с у р. Әй, исең киткән икән. Без полициянең борын төбеннән кача алабыз. Әнә ул тәрәзәне күрәсеңме?

М ө р ш и д ә. Йә?

М а н с у р. Менә шул инде.

М ө р ш и д ә. Нәрсә шул инде?

М а н с у р. Менә шуннан бакчага, аннан тар тыкрык буйлап күлгә, күлдә көймәләр күп була. Берсенә утырабыз да выжт пристаньга. Анысы өчен син кайгырма... Шулай да җыенырга кирәк булыр, ахрысы.

Җыена башлыйлар.

М ө р ш и д ә *(тәрәзәдән карап)*. Аралыкка төшә икән.

М а н с у р. Синең чемоданың шактый авыр бит. Икегә бүлмибезме?

М ө р ш и д ә. Теләсәң ни эшлә. Бөтен приданым шунда инде.

М а н с у р. Син үзең придан. Хәер, артык авыр түгел лә. Ә минем приданым, менә шул юрган эченә сыеп бетәр. Байлар да үзебез тегеләй. Әнигә килен белән барып төшкәч, күзе дүрт булыр.

М ө р ш и д ә *(икенче тәрәзәдән карап)*. Мансур! Мансур! Садрый полицияләр белән монда таба килә. Харап булдык! Тотылдык!..

М а н с у р. Кая?.. Әһә, алай икән... *(Ишекне бикли.)* Әйдә, җаный, чәйне пароходта эчәрбез инде. *(Җепне өстәлгә бәйләп, сул як тәрәзә катына китереп, чемоданны ташлап.)* Әйдә, җаный!..

Төшәләр. Кәбестә өстәлдән идәнгә төшә. Шакирҗан тыпырчына.

Ш а к и р җ а н. Качмагыз! Рөхсәт юк!! Качмагыз! Качмагыз! Каравыл! Каравыл! Качтылар!! Каравыл!! *(Кычкыра-кычкыра, тамагы карлыгып, тавышсыз кала.)*

Ишек дөбердәтәләр.

А р т т а н. Именем закона, руки вверх!.. Ачыгыз! Ач!..

Тавышланалар. Ишекне ватып бик саклык белән керәләр.

V. Пристав, Сәйфетдинов, Фёдоров.

Пристав. Именем закона, руки вверх!.. Кая болар?! Әй Сәйфетдинов! Фёдоров! Эзләгез!..

Эзлиләр.

Сәйфетдинов. Ваш благороди! *(Бармагы белән кәбестәгә күрсәтә.)*

Пристав. Нәрсә?

Сәйфетдинов. Кәбестә!

Пристав *(сискәнеп китеп)*. Ә?! Минемчә, ул — «бомба»!

Сәйфетдинов. Дөрес, ваш благороди, ул — «бомба»!..

Әйләнеп карыйлар.

Пристав. Әйе, «бомба»!.. Ах, канальялар. Нинди оста эшләгәннәр. Тыштан караганда кәбестә дип уйларсың үзен. Ә эчендә... брр...

Куркынып чигенәләр.

Сәйфетдинов. Ваш благороди, нәкъ кәбестә!

Пристав. Күчәне дә бар. Нинди эшләгәннәр!

Сәйфетдинов. Ваш благороди, губернаторның шулпасына салыр өчен эшләмәгәннәрме икән?

Пристав. Моннан шулпа пешерсәң, тозлы булыр. Ах, канальялар! Нинди оста эшләгәннәр бит. Нәкъ кәбестә. Әй Сәйфетдинов, кара әле, филтәсе янмыймы?!

Сәйфетдинов. Юк, ваш благороди, филтәсе күренми. Бәлки, эчтәдер.

Пристав *(сискәнеп)*. Ә?.. Конечно, эчтәдер. Әй Сәйфетдинов, шартламасмы ул?

Сәйфетдинов. Белә алмыйм, ваш благороди!

Пристав. Барыгыз. Бөтен бүлмәләрне тентегез! Кулга эләккәннәрен ычкындырмагыз!

Сәйфетдинов. Слушаюсь, ваш благороди!

Чыгалар.

Пристав *(бүлмә буйлап эзләнеп, капчыкны тотып, сискәнеп китә)*. Әй Сәйфетдинов!

Сәйфетдинов *(кереп)*. Нәрсә, ваш благороди!

Пристав бармагы белән капчыкка төртеп күрсәтә. Сәйфетдинов белән Фёдоров капчыкка атылалар.

Пристав. Смирно! Әй Сәйфетдинов! *(Бармагы белән тагын капчыкка күрсәтә.)*

Сәйфетдинов *(Фёдоров белән капчыкны капшап карыйлар да, килеп)*. Ваш благороди, капчыкка кеше үтереп салганнар!..

Шакирҗан тыпырчына.

Һәммәсе. Тере, тере, тере!..

Куркышалар.

Пристав. Ә минемчә, разбойникларның берсе анда юри качкан.

Сәйфетдинов. Сезнеке дөрес, ваш благороди!

Пристав. Әй Сәйфетдинов!.. *(Бармагы белән капчыкка төртеп күрсәтә. Тегеләр ташланалар.)* Стой! *(Кире кайталар.)* Кирәген бирегез!

Фёдоров белән Сәйфетдинов капчыкны, өстерәп чыгарып, бер күтәреп, бер төшереп, идәнгә бик каты, бик озак бәрәләр.

Сәйфетдинов. Менә сиңа! Менә сиңа! Капчыкка яшеренденңмени! Таба алмаслар дип белдеңмени?

Пристав. «Бомба»дан кәбестә ясадыгызмыни? Аша әле, туганкай, аша!.. Ничек, тәмлеме?.. Ха-ха-ха!..

Сәйфетдинов. Менә сиңа, кызыл авыз! Менә сиңа, бунтовщик!..

Пристав. Ныграк, ныграк! Капчыкны чишегез!.. Чыгарыгыз үзен монда!

Чишәләр. Хәлдән тайган Шакирҗан бай бугазыннан тавышын чыгара алмыйча икъ-пыйк дип ишарә белән Мансурларның качканлыкларын аңлатырга тырыша.

Пристав. Баа!.. Шакирҗан бай, сез ничек монда?! Сез ничек эләктегез?!

Шакирҗан тавышсыз ишарә белән кулларын бутый.

Сәйфетдинов. Ваш благороди. Аның телен кискәннәр.

Пристав. Әй!.. Ягез, авызыгызны ачыгыз.

Шакирҗан башын чайкый.

Ачыгыз, ачыгыз! Авызыгызны ачыгыз!..

Шакирҗан авызын ача.

Телегезне чыгарыгыз! Телегезне! Йә, йә, чыгарыгыз телегезне! Чыгарыгыз, дим!

Шакирҗан телен чыгара.

Көрәк кадәр тел. Сүз юк.

Сәйфетдинов. Ваш благороди! Аның кече телен кисқәннәр. Безнең мөселманнарда кечкенә тел була.

Пристав. Ягез, икенче телегезне күрсәтегез! Кая ул?.. Кая?

Сәйфетдинов. Ваш благороди, эчтә була ул, бик эчтә...

Пристав. Эчтә, эчтә! Кая соң эчтә? Корсагында түгелдер бит?

Сәйфетдинов. Ул, ул...

Пристав. Йә, ярый. Полицмейстерның үзенә икенче телегезне күрсәтерсез!.. Хәзер әйдәгез минем арттан!.. *(Кире кайтып.)* Әй Сәйфетдинов, сакла, шартламасын!..

Сәйфетдинов. Слушаюсь, ваш благороди!..

Чыгалар. Сәйфетдинов, калтыранып, кылычын чыгарып, кәбестә янында басып кала.

Пәрдә.

*1918 ел*

# КАЗАН СӨЛГЕСЕ

*Музыкаль комедия*

*Дүрт пәрдәдә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Мөәззин.
Әсма – аның хатыны.
Саҗидә – зур кызлары.
Мөршидә – кече кызлары.
Ильяс – мәхдүм кода.
Салих – шәкерт.
Бану – авыл кызы.
Бибинур – авыл кызы.
Шәмси әби – карчык.
Ибраһим.
Хәзрәт.
Староста.
Картлар, егетләр, кызлар һ. б.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл мөәззиненең җыйнак өе.
Оркестр «Бәдәвам» көен уйный.

### I КҮРЕНЕШ

Мөршидә, Саҗидә, Әсма, Шәмси әби.

Мөршидә, Саҗидә.

Барыңыз Алла бер диген,
Ислам дине хак диген,
Иван үрәдник диген,
Алла дигел бәдәвам.
Ислам динен тотмаган,
Су буена төшмәгән,
Улдыр адәми шәйтан,
Алла дигел бәдәвам.

Киңдер, Кадир, кодрәтең.
Тотсаң җирнең кендеген,
Әйләнмә, тик тор, диген,
Алла дигел бәдәвам.

## II КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Мөәззин.

Мөәззин.
Кая, хатын, чапаным?
Кая, хәшәп, ташладың?
Синнән дә һич уңмадым,
Хәзрәткә туйга барам.
Әсма.
Чапаның шунда иде,
Җилән астында иде,
Кадакка элгән иде. —
Әйләндермә башларым...
Мөәззин.
Исәнме, Шәмси әби!
Сине күрми дә торам.
Кая, тизрәк бул инде,
Хәзрәткә туйга барам.
Шәмси әби.
Үзең нихәл, мөәззин!
Шәйхи картның фидиясен
Алып бетердеңме син
Улларыннан, тидия?
Мөәззин.
Яхшыдан яман туган
Мужик балаларыннан
Алырсың син алардан!
Хәзрәткә туйга барам.
Кая, кая, сиңа әйтәм,
Хәзер мәҗлескә китәм,
Чапаным сездән көтәм.
Хәзрәткә туйга барам...
Шәмси әби.
Туй дигәннән, мөәззин,
Нәүбәт синдә, сизәмсең?
Буйга җиткән ике кызың
Туй көтәләр, тидия.
Сиңа бар яшьрен серем,
Бикәңә дә сөйләдем.

Чыксаңыз ла, кызларым,
Мәслихәт бар, тидия.

Мөәззин.

Нәрсә, нәрсә ул тагын?
Фараз кылдык, мин тыңлыйм.
Әллә яучылап килдең?
Һе, һе, һе, тидия.

Шәмси әби.

Яучылык качмас әле,
Зиһнемне бүлмәсәнә!
Яхшылап тыңласана
Сүзләремне, тидия.
Тирә-як муллалары
Җиткән уллары белән
Хәзрәткә туйга килгән
Кода булып, тидия.
Шиңгән каен авылының
Рәүф хәзрәт мәхдүме
Юри монда килгән, ди,
Кыз күзләргә, тидия.

Мөәззин.

Кыз күзләргә, дисеңме?
Растын син сөйлисеңме?
Югыйсә үртисеңме
Азанчыңны, и надан?..

Шәмси әби.

Юк, юк! Алла сакласын!
Җир упсын, ялганласам.
Әйтер идем, тыңласаң,
Бер сүз сиңа, тидия.

Мөәззин.

Әйт, әйт унны, йөзне әйт!
Хәерле булыр, шаять.
Кемгә булган бигаять
Мәхдүм кода, тидия?

Шәмси әби.

Әйтсәм, син ышанмассың,
Йә җәнҗал чыгарырсың,
Йә өеңнән куарсың
Ялганчы дип, тидия.

Мөәззин.

Әйт, әйт инде, и хәшәп!
Ихлас белән мин тыңлыйм,
Йә, тиз бул инде, ахмак!

Вакытым юк, тидия.
Фараз кылдың, мәсәлән.
Эч серләрне яшереп,
Саклап калу — зур хәрәм.
Китап әйтә, тидия...

Ш ә м с и ә б и.

Мәхдүм кода күңеле
Бу йортта, имеш, диләр.
Күзләргә килгән, диләр,
Кызларыңны, тидия.

М ө р ш и д ә.

Менә, әткәй, чапаның!..

С а җ и д ә.

Менә камыш таягың!..

Ә с м а.

Шәмси әби кая соң?

Ш ә м с и ә б и.

Монда, монда, тидия!..

М ө ә з з и н.

Кызларыңа әйт хәзер,
Киенеп-ясансыннар,
Кершән һәм иннекләрен
Буянсыннар, тидия!..
Шиңгән каен мәхдүме
Кода булып килгән, ди,
Күзе безгә төшкән, ди.
Күзеңне ач, ябалак!
Шиңгән каен мулласын
Кем икәнен беләмсең?
Тирә-якта берүзе
Җир кендеге, тидия!
Шиңгән каен мәхдүме
Үзе Коръән-Хафиз, ди...
Казанда бер шәкерт, ди.
Йоклап ятма, тидия!
Ул чагында эшләр шәп,
Син кодагый, мин кода,
Беләсеңме, и хәшәп!
Хәзрәткә,
Байларга туйга барам!
Мәхдүм булса бигаять,
Туй да итәрбез, шаять.
Кая соң минем таяк?
Эшеңне бел, ябалак!

Чыга.

Ш ә м с и  ә б и.

Ярый, Әсма, миңа да
Китә башларга вакыт.
Утыра-утыра онытып
Җибәргәнмен, тидия.

С а җ и д ә.
М ө р ш и д ә. } Шәмси әби, Шәмси әби, утыр әле!

Ш ә м с и  ә б и. Бик озак утырдым инде. Икенче бер тагын килеп «Мөхәммәдия» укытып китәрмен.

М ө р ш и д ә. Шәмси әби, яшь килен ничек, матурмы?

С а җ и д ә. Аягына ни кигән, калфагы ничек, зурмы?

Ә с м а. Бирнәләрен күрдеңме? Күпме?

Ш ә м с и  ә б и. Казан кызы булсын да — бирнәсе булмасын. Казан кызы булсын да — матур булмасын, Казан кызы булсын да — читек-кәвеш кимәсен, ул аннары нигә ярый. Указлы мәхдүмебезгә сорасак, төрек солтаны да кызын бирер иде, сорамадык кына.

М ө р ш и д ә. Буе-сыны ничек?

Ш ә м с и  ә б и. Бик матур, бик килешле. Менә болай гына. Баш, күз, аяк, кул әйтерлек тә түгел инде. Кара җимеш төсле майланып торган кечкенә генә кап-кара күз дисеңме, җеп калынлыгы гына кап-кара каш дисеңме! Аяклары кәкре...

М ө р ш и д ә. Кәкре?

Ш ә м с и  ә б и. Әйе, балакаем, кәкре. Бик матур, бик кәкре. Казан кызы булсын да — аяклары кәкре булмасын. Ул аннары нигә ярый.

М ө р ш и д ә. Кәкре булгач, ничек матур була инде ул?

Ш ә м с и  ә б и. Шулай, кызым, кәкренең дә матурлары була икән. Хак мөселман хатын-кызларының аяклары кәкре булыр, дигән китап. Остабикә үзе шулай ди. Хәзрәте Хәдичәнең дә кәкре булган, ди. Китап кушканча, балакайлар, китап кушканча. Кәкре аяк арасыннан фәрештәләргә очып йөрергә уңай була икән, ди. Туры аяклы кешеләрнең тезләренә бәрелеп фәрештәләрнең канатлары сынар, дигән китап. Аяклары дисәгез бик матур, бик кәкре. Саваплы аяклар. Араларыннан берьюлы өч фәрештә очып үтәрлек.

Ә с м а. Соң ничек, бирнәләрен күрдеңме? Нәрсәләре бар?

Ш ә м с и  ә б и. Күрмәгән кая, аның нәрсәләрен күреп бетерер өчен, гомерең дә җитмәс.

М ө р ш и д ә.
С а җ и д ә. } Нәрсәләре бар соң? Нәрсәләре бар?

Ш ә м с и ә б и. Биш сандык тулы асыл күлмәкләре, дүрт сандык ефәк күлмәкләре, өч сандык йон күлмәкләре, бер сандык энҗеле калфак, беләзек, алка, йөзек.

М ө р ш и д ә. Ситсы күлмәкләре юкмыни?

Ш ә м с и ә б и. Юк.

С а җ и д ә. Тагын, тагын нәрсәләре бар?

Ш ә м с и ә б и. Бер сандык аяк чолгаулары, ике сандык тәһарәт чүпрәкләре, дүрт сандык сөлгесе...

М ө р ш и д ә. Сөлгеләре ниндиләр? Бездәге төслеме?

Ш ә м с и ә б и. Юк, балакайларым, бездәгеләргә бер дә охшамый. Казан сөлгеләре инде.

Ә с м а. Казан сөлгесе, дисең?

М ө р ш и д ә. Тизрәк, тизрәк күрәсе иде Казан сөлгесен. Күчереп алыр идек өлгесен.

С а җ и д ә. Нинди була икән Казан сөлгесе?

Ш ә м с и ә б и. Караганда күзне чагылдырырлык була икән ул Казан сөлгесе. Бик кадерле кодаларга гына бирнә итеп биреләсе, ди. Кая, Әсма, мин китим инде. Килен күрендерергә чакыра килгән җирдән, сүзгә мавыкланып озаграк утырдым шул.

Ә с м а. Шәмси әби, булмаса булган икән инде, бераз сабыр ит. Мин дә синең белән бергә барырмын.

Ш ә м с и ә б и. Ә-ә шул. Хатын-кыз җыелганчы бирнә карый торырбыз.

Ә с м а. Әйе шул. Хәзер өс-башымны гына алыштырыйм да, китәрбез.

Ш ә м с и ә б и. Ярый, ярый. *(Әсма чыга.)* Кызлар, ай, кызлар! Саграк булыгыз. Безнең илләргә тилгәннәр килгән, урлап китмәсеннәр үзегезне.

М ө р ш и д ә. Әй, аның ише җебегәннәрдән алдырмабыз әле.

Ш ә м с и ә б и. Алай димәгез. Ул тилгәннәр арасында Казан шәкертләре дә бар, диләр.

М ө р ш и д ә. Булса ни!

Ш ә м с и ә б и. И бәбкәләрем, Казан шәкертләрен сез әле белмисез икән. Алар сезнең генә түгел, Казан кызларының да башларын тубал итеп ташлыйлар, ди. Мәхдүмнәр алар «Бәдәвам» китабын укыганны гына тыңлап тормаслар, «Йосыф» китабына да керешерләр. Белеп торыгыз аны.

С а җ и д ә. Алар белгән «Йосыф» китабын без белеп оныткан инде.

Шәмси әби. Аларның «Йосыф» китаплары башка-чарак, ди.

Мөршидә. Кызыл тышлы булмас инде.

Шәмси әби. Бәлки, кызылдыр да, каян беләсең аны. *(Пауза.)* Кызлар, Шиңгән каен хәзрәтенең улы Хәниф мәхдүм монда хәзрәтләргә кыз ягыннан кода булып килгән, ди. Авызына иблис төкергән, ди, Казан шәкерте, ди.

Саҗидә. Ничек төкергән?

Шәмси әби. Шулай, тоткан да төкергән… Өс-башларыгызны үзгәртебрәк, хушбуйларны сибебрәк, калфакларны киебрәк, иннекләрне сөртебрәк, читекләрне киебрәк, күкрәкләрне киеребрәк, чапаннарыгызны ачыбрак, башларыгызны күтәребрәк, вак-вак итеп атлабрак, урамга да чыгыбрак, су буена төшебрәк, йөзләрне дә ачыбрак, бил-сыннарны чайкабрак йөрү кирәк.

Мөршидә. Шәмси әби, үзең күрдеңме?

Шәмси әби. Кара, кара, күзләре нинди яна… Гыйшык чебене йөрәгеңнән тешләп алдымы әллә?.. Юк, балакай, аны уйлау сиңа иртә әле. Менә апаң әйтсә, бер хәл. Аның нәүбәте. Сиңа, Алла боерса, башкасы да булыр әле.

Саҗидә. И, Шәмси әбинең шул булыр инде. Атам өендә торуыма күпсенә.

Шәмси әби. Юк, балакай, бер дә күпсенмим. Сыерчыкның оясы булмаса сайрамый, ди. Сезнең яшь чакларыгыз, сайрар-сайрашыр чакларыгыз.

Мөршидә. Их, күрәсе иде үзен.

Шәмси әби. Кемне?

Мөршидә. Казан шәкертен.

Шәмси әби. Кара, кара… сине бу узып китмәсә ярар иде, балакай…

Мөршидә. Шәмси әби, мин болай гына. Син инде тагын әнигә әйтә күрмә.

Шәмси әби. Чынлап булса да әйтмәс идем әле. Җанлы тәндә була ул. Гаеп түгел.

Әсма керә.

## III КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Әсма.

Әсма. Әйдә, киттек, Шәмси әби.

Шәмси әби. Әйдүк, әйдүк.

Әсма. Балалар, каралышып, буялышып йөрмәгез. Илдә ят кешеләр бар, өс-башыгызны рәтләгез!

Ш ә м с и  ә б и. Әйттем инде, әйттем, барысын да әйттем.

М ө р ш и д ә. Әнкәй, тиз кайт. Без куркабыз. Төнгә калма.

Ш ә м с и  ә б и. Курыксагыз, әнә кызларның киндер тукмаклаган җирләренә барыгыз. Анда бик күңелле.

Ә с м а. Ай, аталары белсә үтерер. Әйдә, Шәмси әби!

Ш ә м с и  ә б и. Әйдә, Әсма. Сау булыгыз, балалар. Киндер тукмаклаган җиргә, дим, сиздермичә генә.

М ө р ш и д ә.<br>С а җ и д ә. } Сау бул, Шәмси әби. Тагын кереп утыр!

Ә с м а, Ш ә м с и  ә б и чыгалар.

## IV КҮРЕНЕШ

М ө р ш и д ә, С а җ и д ә.

М ө р ш и д ә. Апа җаным! Апа җаным! Апа җаным! *(Кочаклап әйләндерә.)*

С а җ и д ә. Нәрсә? Нәрсә? Чү, җибәр!..

М ө р ш и д ә. Бер нәрсә сорар идем дә, ачуланырсың шул.

С а җ и д ә. Ачуланырлык булса ачуланырмын да шул.

М ө р ш и д ә. Юк, апа, ачуланырлык түгел.

С а җ и д ә. Алайса, ачуланмам.

М ө р ш и д ә. Юк, ачуланырсың.

С а җ и д ә. Ачуланырмын шул.

М ө р ш и д ә. Юк ла, нәрсәсенә ачуланасың аның.

С а җ и д ә. Алайса, ачуланмам.

М ө р ш и д ә. Әем, ачуланырсың.

С а җ и д ә. Әле син шулаймыни? Мине ачуландырмакчы буласыңмыни?

М ө р ш и д ә. Бик кирәгең бар!

С а җ и д ә. Кирәгем булмаса, нәрсәгә такылдыйсың соң?

М ө р ш и д ә. Апа, әллә әйтимме?

С а җ и д ә. Әйт.

М ө р ш и д ә. Әллә әйтмимме?

С а җ и д ә. Әйтмә.

М ө р ш и д ә. Әйттерәсең килми шул. Әнә, әнә күзләреңә хәзердән үк зәһәрең чыкты.

С а җ и д ә. И, үз күзләрең бик шәп инде. Песи күз.

Мөршидә. Минем күзләрем бер дә песи күзләренә охшамаган әле. Ә менә синең күзләрең, нәкъ тавык күзе, кып-кызыл.

Саҗидә. Ә синең бәбәкләрең аю күргән этнеке шикелле акаеп тора.

Мөршидә. Синең акаер иде дә, акаерлык хәле юк шул.

Саҗидә. И бозау бәбәк, салам сыйрак, тавык баш! Сөйләшкән була бит тагын.

Мөршидә. Ә синең, ә синең борыныңа чуан чыга. Күркә борын, үрдәк баш, сары маржа, каләм каш!

Саҗидә. Ә синең ашагач, эчең богырдый. И лыгырдый, быгырдый, Мөршидәнең эчләре арба кебек шыгырдый, лыгырдый, шыгырдый, быгырдый...

Мөршидә. Ә синең, йоклаганда, борының сызгыра. Көтүченең курае Саҗидәнең борынында. Төннәр буе сызгыра йоклап торган урынында. Әлли, бәлли, сызгыра... сызгыра... сызгыра!..

Саҗидә. Ә синең... Ә синең... Менә сиңа! *(Бәрә.)*

Мөршидә. Әлли, бәлли, сыбызгы борын! Әлли, бәлли, сыбызгы борын! Бәрмә, дим. Кая бәрәсең? Менә үзеңә! Менә, менә!..

Сөлгеләр белән сугышалар. Ильяс керә.

## V КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Ильяс.

Ильяс. Мөәззин бабай өйдәме?

Мөршидә. } Әбәү, пәрәмәч! Кеше ич бу!
Саҗидә. }

Мөршидә. Чуваш калдыгы, сиңа ни кирәк?

Саҗидә. И син, чепи күз, трубкаңны пыскытма әле монда. Бу сыер абзары түгел.

Мөршидә. Нигә дөмегеп катып торасың? Ни кирәк сиңа?

Ильяс. Мин урман арты боярының көтүчесе булам. Тәкәбез югалган иде. Монда юкмы икән дип кергән идем.

Саҗидә. И җүләр, кәҗәләр өйдә буламыни?

Ильяс. Мөәззин бабайның кәҗәләре бар дигәч, килгән идем.

Мөршидә. Юк, юк. Безнең тәкәбез дә, кәҗәләребез дә үзебезнеке. Олак, тфиит!..

С а җ и д ә. Бу нәрсә бу?
И л ь я с. Кая?
С а җ и д ә. Менә монда.
И л ь я с. Курай.
М ө р ш и д ә. Уйный беләсеңме?
И л ь я с. Белмәгәч, курай тотып йөрмәс идем.
М ө р ш и д ә. Оста уйныйсыңмы?
И л ь я с. Тыңлаучылар яраталар иде.
М ө р ш и д ә. Безгә аз гына уйнап алмыйсыңмы?
И л ь я с. Рөхсәт итсәгез, мөмкин.
С а җ и д ә. Кара, кара, рөхсәт дип, муллаларча ычкындыра. И надан!
М ө р ш и д ә. Чынлап, бераз гына уйнап алмыйсыңмы?
И л ь я с. Уйнар идем дә, анагыз күрер бит.
М ө р ш и д ә. Күрмәс, күрмәс. Ул өйдә юк.
С а җ и д ә. Йә, сырланма. Уйнасаң уйна, уйнамасаң, табаның ялтырат! Йә, уйныйсыңмы?
И л ь я с. Була.
М ө р ш и д ә. Йә?
И л ь я с. Ә?
С а җ и д ә. Мә! Ха-ха-ха!.. Йә, уйныйсыңмы инде?
И л ь я с. Берьюлымы?
М ө р ш и д ә. Әллә аерым-аерым да уйный беләсеңме?
И л ь я с. Беләм.
М ө р ш и д ә., С а җ и д ә. Ә? Ха-ха-ха!.. Йә, телеңә күп салынып торма. Уйна!
И л ь я с. Алай ачулангач уйнамыйм.
М ө р ш и д ә. Юк, юк, ачуланмыйбыз. Уйна.
И л ь я с. Була.
С а җ и д ә. Йә?
И л ь я с. Уйныйм ич!
С а җ и д ә. Уйнамыйсың ич.
И л ь я с. Уйнамыйм шул.
С а җ и д ә. Йә, нигә син уйнамыйсың, чуваш калдыгы?
И л ь я с. Оялам.
С а җ и д ә., М ө р ш и д ә. Оялам? Ха-ха-ха!..
И л ь я с. Икегезгә берьюлы уйнарга оялам шул.
М ө р ш и д ә. Йә, йә, оялма. Әйдә, менә шунда утыр да уйна!

Урталарына утырталар. Курайда — «Казан сөлгесе».

М ө р ш и д ә. Апа, беләсеңме нәрсә?
С а җ и д ә. Белмим.

М ө р ш и д ә. Сизденме?
С а ж и д ә. Юк.
М ө р ш и д ә. Менә нәрсә!
С а ж и д ә. Нәрсә?
М ө р ш и д ә. Тыңла әле.
С а ж и д ә. Тыңлыйм ла.
М ө р ш и д ә. Бу.
С а ж и д ә. Әйе, бу.
М ө р ш и д ә. Бу.
С а ж и д ә. Бу.
М ө р ш и д ә. Бу, дим.
С а ж и д ә. Кем?
М ө р ш и д ә. Тегеннән.
С а ж и д ә. Кайдан?
М ө р ш и д ә. Бу теге Шиңгән каен мәхдүменең ялчысы түгелме икән?
С а ж и д ә. Белмим.
М ө р ш и д ә. Шулдыр.
С а ж и д ә. Улдыр.
М ө р ш и д ә. Безне күзләргә килмәгән микән?
С а ж и д ә. Ә-ә-ә... Әллә кайчан шулай диләр аны. Әйдә, киенеп, матурланып чыгыйк әле.
М ө р ш и д ә. Без хәзер чыгабыз. Көтеп тор!
С а ж и д ә. Кара аны! Берәр нәрсә селтәмә! *(Чыгалар.)*
М ө р ш и д ә. Без хәзер.
С а ж и д ә. Без хәзер.
И л ь я с. Кәҗәләр зарарсыз. *(Ишектән карый.)*
С а л и х *(тәрәзәдән)*. Йә, ничек, эш пешәме?
И л ь я с. Пешә, малай.
С а л и х. Кайсы ошады?
И л ь я с. Тегесе.
С а л и х. Кайсы тегесе, кечкенәсеме?
И л ь я с. Алар икесе дә бертигез ич.
С а л и х. Сеңлесеме, дигәнем?
И л ь я с. Мин кайсы апа, кайсы сеңел икәнлеген белмим бит.
С а л и х. Яшьрәге ошадымы?
И л ь я с. Билләһи газыйм, берсенең дә авызын ачтырып тешен карамадым... Кара әле, Салих малай, хәзер ни эшлибез инде? Әллә син дә монда керәсеңме? Юкса бик чая нәрсәләргә охшыйлар. Муенны кашымасыннар, дим.
С а л и х. Мин капка төбендә генә торырмын. Алай-болай эләктерә башласалар, каравыл кычкырырсың тагын.

Ха-ха-ха... Кара әле, кызлар киндер тукмаклаган җиргә үзләрен чакырып хат язып калдыр!

Ильяс. Әйе шул. Мәслихәт. Фу, бигрәк бөркү, тирләп беттем. *(Чишенә. Хат яза.)* «Әлхат нисфелмөләкат, син җаныйга сәлам хат. Бүген кичкәрәк, әтиең икендегә киткәчрәк, киндер тукмаклаган кызлар янына чык...» Имзасын ничек куярга икән? Казан шәкерте дип куям. Казан шәкертенең базары монда шәпкә охшый. Икенчесенә дә язарга кирәк... «Әлхат нисфелмөләкат, син җаныйга сәлам хат. Бүген кичкәрәк, атаң икендегә киткәчрәк, киндер тукмаклаган кызлар янына чык!» Боларның кайсы апа, кайсы сеңел икән, ә?

Саҗидә, Мөршидә керәләр.

Саҗидә. Минем яулыгым, үз яулыгым. Билләһи, үземнеке. Ябалак күз! Бир яулыгымны!

Мөршидә. Сукырайдыңмы әллә? Үз яулыгым ич!

Саҗидә. Минеке!

Мөршидә. Түгел! *(Тәкрар әйтәләр.)*

Саҗидә.
Мөршидә. } Әтәч, кеше бар ич! *(Чыгалар.)*

Ильяс. Нигә болар болай куркыштылар? Пәрәмәч, харап булдым лабаса. *(Киенә.)* Сынатмаска кирәк. Юкса тәпәләп чыгарулары да бар.

Саҗидә
Мөршидә } *(керәләр)*. Әтәч, кеше юк ич!

Мөршидә. Кара әле, монда берәр кеше кермәдеме?

Ильяс. Керде.

Мөршидә. Кем?

Ильяс. Белмим.

Саҗидә. Соң син аның белән сөйләшмәдеңмени?

Ильяс. Юк.

Мөршидә. Кая китте?

Ильяс. Белмим.

Саҗидә. Нәрсә карап тордың соң син?

Ильяс. Мин кәҗәләремнән башкасын сорашмадым.

Мөршидә. Берәр нәрсә калдырмадымы?

Ильяс. Калдырды.

Саҗидә.
Мөршидә. } Нәрсә калдырды? Нәрсә калдырды?

Ильяс. Белмим.

Саҗидә.
Мөршидә. } Ә?!

И л ь я с. Әйе.
М ө р ш и д ә. Калдырды, дисең ич?
И л ь я с. Калдырды.
М ө р ш и д ә. Соң, нәрсә калдырды?
И л ь я с. Белмим, нәрсәдер.
М ө р ш и д ә. Әй аңгыра тавык! Сакалы бар идеме?
И л ь я с. Юк.
М ө р ш и д ә. Мыегы?
И л ь я с. Юк.
М ө р ш и д ә. Башы?
И л ь я с. Юк. И, бар иде бугай. Муен өстендә бер түгәрәк нәрсә бар иде, баш булгандырмы, нәрсә булгандыр шунда.
М ө р ш и д ә. Соң, куллары бар идеме?
И л ь я с. Бар иде бугай.
М ө р ш и д ә. Кулы белән берәр нәрсә бирмәдеме?
И л ь я с. Берне генә бирмәде шул.
М ө р ш и д ә. Соң ничәне бирде?
И л ь я с. Икене.
М ө р ш и д ә. Ничек бирде?
И л ь я с. Менә шулай.
М ө р ш и д ә.<br>С а җ и д ә. } Хат, хат, хат!..
С а җ и д ә. Кемгә бирергә кушты?
И л ь я с. Апасына.
С а җ и д ә. Миңа, миңа, миңа!..
И л ь я с. Ә монысын сеңлесенә диде.
М ө р ш и д ә. Миңа, миңа, миңа!..
И л ь я с. Мәгез!
М ө р ш и д ә.<br>С а җ и д ә. } Кайсы миңа? Кайсы миңа?..
И л ь я с. Менә монысы... Юк, түгел икән, монысы. Юк, түгел лә... Ә, менә монысы. Әй, юк ла...

Салихның сызгырганы ишетелә.
И л ь я с, кызларны ике якка бәреп, тәрәзәдән качып чыга.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авылда мәчет алды. Киртә белән уралган. Уртада капка. Капкадан авылның матур бакчалы урамы күренә. Кызлар киндер тукмаклыйлар. Егетләр җыелалар.

### I КҮРЕНЕШ

Оркестр «Әпипә» көен уйный. Хор. Бию.

Кызлар.

Сук, сук, ныграк сук!

Егетләр.

Киявеңә киндерә.

Кызлар.

Сук, сук, ныграк сук!

Егетләр.

Киявеңә киндерә.

Хор.

Кызлар тукмаган киндерә
Яшь йөрәкне көйдерә.
Кызлар тукмаган киндерә
Яшь йөрәкне көйдерә.
Бәр, бәр, ныграк бәр,
Ефәк төсле йомшарсын!
Бәр, бәр, ныграк бәр,
Ефәк төсле йомшарсын!

Кызлар.

Ефәк юрган итеп ябып,
Мине сагынып йокларсың.
Ефәк юрган итеп ябып,
Мине сагынып йокларсың.

Егетләр.

Чуп, чуп, ныграк сук,
Көчең әрәм китмәсен.
Чуп, чуп, ныграк сук,
Көчең әрәм китмәсен.

Кызлар.

Кызларда көч күп була ул,
Бер дә исең китмәсен.
Кызларда көч күп була ул,
Бер дә исең китмәсен.

Егетләр.

Ныграк, ныграк, ныграк сук,
Беләкләрегез талмасын!

Ныграк, ныграк, ныграк сук,
Beләкләрегез талмасын!

Кызлар.

Беләге талган кызларны
Хатын итеп алмассың!
Беләге талган кызларны
Хатын итеп алмассың!

Оркестр уйный. Бию дәвам итә.

## II КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Салих.

Салих. Егетләр, урман арты боярының көтүчесе килгән. Үзе чуваш икән. Башына эшләпә кигән, үзе кап-кара, нәкъ чегән. Авызына курай капкан, чыбыркысын җилкә аркылы таккан. Култык астына капчык аскан. Нәкъ шәйтан.

Егетләр. Йә, йә?

Салих. Шул курайда уйнаганда, чыдап кына тор тыңлаганда. Ә инде җырлаганда, оказия! Хәйран да…

Егетләр. Соң ул кайда?

Салих. Каравыл лапасы алдында, халык, малай, халык анда!.. Ахырзаман, кыямәт!..

Егетләр. Нигә килгән соң ул монда?

Салих. Кәҗәләре югалган. Шуны эзләп монда килгән. Күргән-белгән юкмы икән дип сораша. Оказия инде, тамаша. Кураен да уйнап ала, җырлап ала. Үзе нәкъ кыз бала. Елмая, кызара, ояла!.. Әйтерсең лә әүлия…

Егетләр. Әйдәгез, әйдәгез, алып килик үзен монда. Кызлар, сез ни дисез?

Курай артта уйный.

Гөлбану. Килсен, килсен. Күзебез тимәсен, исебез китмәсен.

Салих. Чү! Уйный…

Бибинур. Мин бу көйне беренче тапкыр ишетәм.

Гөлбану. Мин дә, мин дә. Бу — яңа көй, ахры.

Бибинур. Яңа кешедә иске көй булмас инде.

Салих. Халык хәйран булып тыңлап тора үзен. Түбән оч мөәзин бабай манарадан тыңлый-тыңлый картларны икендесез калдырган, ди. Егетләр, әйдәгез, киттек. Кыз-

лар, киндерегезне тукмаклашырга, кочаклашырга, уйнашырга, җырлашырга, тамыр тартышырга килеп җитәрбез. Көтеп торыгыз.

Җырлашып чыгалар.

Гөлбану. Кит, кит, шәкерт димәсәң хәтере калыр.

Оркестр «Алмата» көен уйный.

Хор.

Кыйгак, кыйгак, кыр казлары
Килер, язлар җиткәндә,
Бу кыз бала ник назлана,
Кысып, суырып үпкәндә.

Курай оркестр белән «Сибелә чәчәк» көен уйный.

## III КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр, Мөршидә, Сажидә.

Мөршидә.

Курай моңы моңлы икән,
Курай моңы моңлы икән.

Сажидә.

Йөрәккә хәсрәт сала икән,
Йөрәккә хәсрәт сала икән.
Чит илләрдән безгә яр килгән,
Кавышырга насыйп яр микән?

Гөлбану. Чү, чү, Мөршидә, моңланма.
Бибинур. Әллә таныш көйме бу сиңа?
Мөршидә. Ул туктады, ул туктады.
Гөлбану. Йә кызлар, әйдәгез, ай батканчы тукмаклап калыйк!

Оркестр «Әпипә» көен уйный. Хор.

Кызлар.

Тукмак, тукмак, ныграк сук —
Киявемә киндерә,
Тукмак, тукмак, ныграк сук —
Киявемә киндерә,
Йомшак киндер, ак сөлге
Яшь киленне сөйдерә,
Йомшак киндер, ак сөлге
Яшь киленне сөйдерә.

Салкын кышның ак кары
Аклыгына көнләшә,
Салкын кышның ак кары
Аклыгына көнләшә.
Аккошларның мамыгы
Төсле киндерем йомшара,
Аккошларның мамыгы
Төсле киндерем йомшара.

Г ө л б а н у. Хәзрәт киленен, Казан кызын күргәнегез бармы, кызлар?

Б и б и н у р. Каян күрәсең аны, Казан кызы ич ул. Чапан астыннан башын да чыгармый, ди.

Г ө л б а н у. Чыгарыр әле. Менә безнең белән уракка йөри башласа, чапаны тиз очар.

Б и б и н у р. Хәзрәт килене нишләп уракка йөрсен?

Г ө л б а н у. Нигә йөрмәсен. Безнең авылда эшләмәгәнгә икмәк бирмиләр.

М ө р ш и д ә. Бик матур, ди. Аяклары да бик матур, бик кәкре, ди.

Г ө л б а н у. Абау, чатанмыни?

М ө р ш и д ә. Белмим. Шәмси әби әйтә, бик матур, бик кәкре, ди. Китап шулай куша, ди. Бүген үзен күрендерәләр бит. Безнең әнкәй дә шунда китте.

Г ө л б а н у. Алай, кәкре, диең?

М ө р ш и д ә. Әйе, Казан кызлары арасында аякны кәкрәйтү купшылыктан санала, ди. Туры аяклы кызга кияү дә чыкмый икән, ди. Кияүләр кәкре аяклы кызларны әтәч тары чүпләгән шикелле чүпләп кенә торалар, ди. Туры аяклылары кияүсез, урамда сызгырып, тик йөриләр, ди. Хәзрәтнең улы да аның аякларына гашыйк булган, ди. Кәкре аякта мәхәббәт орлыгы була, ди. Шәмси әби, шулай, ди.

Г ө л б а н у. Андый мәхәббәт орлыгын бер дә теләмәс идем әле.

Б и б и н у р. Әнә, әнә Әсма абыстай килен күрендереп кайта. Сорыйк әле үзеннән.

М ө р ш и д ә. Әнкәй, әнкәй! Кызлар сине чакыралар.

Ә с м а. Нихәл, кызлар, ни йомыш? Киндер йомшарамы?

Б и б и н у р. Ал да гөл, Әсма абыстай. Мамык төсле.

Ә с м а. Кызлар, бүген монда чит илләрдән бик күп егетләр килгәннәр. Берсеннән-берсе асыллар. Бай уллары, мәхдүмнәр, Казан шәкертләре. Итәкләрегезне җыйнабрак йөрегез. Казан шәкертләре бик усал булалар бит алар. Җыр чыгарып китмәсеннәр.

Г ө л б а н у. Әсма абыстай, Әсма абыстай, Казан кызы матурмы?

Ә с м а. Бик матур, бик күркәм. Күзләре шомырт шикелле ялт-йолт килә. Кашлары инде җептән калын дисәм ялган булыр. Нечкә генә, кап-кара.

Г ө л б а н у. Аяклары кәкре, ди. Дөресме?

Ә с м а. Дөрес, кәкре. Бик матур кәкре. Ул инде вак-вак атлап, чайкалып киткәндә бик килешеп тора. Симез үрдәк шикелле.

Б и б и н у р. Кәкре аяк ничек матур була инде ул?

Ә с м а. Әллә тагын, һәммәсе дә бик матур дигәч, миңа да матур төсле күренде шунда. Мин үзем алай ук кәкре аякны яратмыйм.

Г ө л б а н у. Бирнәләре күпме?

Ә с м а. Бик күп. Бихисап. Менә миңа да бирнә бирделәр.

К ы з л а р. Кая, кая, нәрсә?

Ә с м а. Менә ул. Күрсәгез исегез китәр инде. Хәйран инде. Сез дә кызлар булып торасыз. Казан кызлары, чынлап та, бик уңганнар икән.

К ы з л а р. Кая, кая, нәрсә?

Ә с м а. Хәзер, хәзер була, балалар. *(Чүгәли.)* Бик затлы нәрсә инде. Күрсәгез һушыгыздан таярсыз матурлыгына. Яулыгымның очлары чияләп бәйләнгән икән. Ярый инде, икенче вакыт күрсәтермен.

М ө р ш и д ә. Әнкәй, бәгырем! Хәзер, хәзер күрсәт инде!

К ы з л а р. Әсма абыстай, күрсәт инде!

Ә с м а. Ярый, ярый, күңелегез булсын, күрсәтим инде. Үзе дә шул бөтен мәҗлескә ялгызыма гына эләкте. Ай, балалар! Чишелми шул, чишелми! Иртәгә күрсәтермен.

М ө р ш и д ә. Әнкәй, хәзер күрсәт инде!

К ы з л а р. Әсма абыстай, зинһар, күрсәт инде!

Ә с м а. Күрәсегез бик киләмени?

К ы з л а р. Бик, бик!..

Ә с м а. Күрсәтим микәнни?

К ы з л а р. Күрсәт, күрсәт, Әсма абыстай!..

Ә с м а. Менә ул! Ай Алла, әллә йорт анасы чуалткан инде, һич чишәр хәл юк. Ярый *(урыныннан тора)*, балалар, соңга калмагыз. Әтиегез ачуланыр.

М ө р ш и д ә. Бирнәне, бирнәне күрсәтмисеңмени? Бир, үзем чишәм.

Ә с м а. Чишә алсаң, мә, кызым... Юк, юк, тукта. Йә, ихтизарланып яулыгымны ертырсың. Үзем чишәм. Иб-

лиснең гыйфрит койрыгын төенләгәненнән дә яманрак төенләнгән. Юк, балалар, юкка мөнтәзыйрланмагыз[1], хәшәпләнеп, өйгә генә кайтып китим.

Мөршидә. Әнкәй, бәгырем, мин бармагымның йомшаклары белән генә чишәрмен.

Әсма. Ихтизарланып китеп ертмасаң бирәм.

Кызлар. Менә рәхмәт! Менә рәхмәт!

Әсма. Юк, булмый... Әбүҗәһел койрыгы да болай каты төйнәлмәгәндер. Ярый, кайтыгыз, балалар!

Мөршидә. Бирнә, бирнә?!

Әсма. Менә ул...

Кызлар. Күрсәтмисеңмени?

Мөршидә. Әнкәй, бу нишләвең инде? Үзең дә чишә алмыйсың. Бездән дә чиштермисең?

Әсма. Атагыз кайткач, шуңардан гына чиштерермен инде.

Гөлбану. Мөәззин бабайның чишкәнен без карарга барабыз... Сездән калмыйбыз.

Әсма. Йә, алайса, мәгез. Үзегез чишегез. Яулыгымны гына ерта күрмәгез.

Кызлар. Юк, юк.

Әсма. Юк, туктагыз, үзем тагын маташып карыйм әле. Колһуалла укыгач чишелә торган иде. Ә менә, менә, булды шул.

Кызлар. Ах, сөлге, Казан сөлгесе!..

Оркестр, хор. «Казан сөлгесе».

Кызлар, Бибинур, Гөлбану, Мөршидә, Саҗидә.

Каюлары нинди тигез аның,
Ука белән ефәк аралаш.
Бигрәк матур Казан сөлгесе,
Бигрәк матур Казан сөлгесе,
Җем-җем итә аның өлгесе.
Ике башы тигез, тигез аның,
Рәхәтләнә күңел карагач.
Бигрәк матур Казан сөлгесе,
Бигрәк матур Казан сөлгесе,
Җем-җем итә аның өлгесе.

Әсма. Ярый, кызлар, мин кайтыйм инде. Кая, Казан сөлгемне бирегез!

---

[1] Мөнтәзыйрлану — көтү, өметләнү.

Б и б и н у р. Әсма абыстай, карап туйыйк инде. Бигрәк матур икән. Үрнәкләрен өйрәнеп калыйк дибез.

Ә с м а. Каралта күрмәгез, һаман-һаман Казан сөлгесе бүләк итүче булмас.

Г ө л б а н у. Буямабыз, Әсма абыстай. Менә Мөршидә алып кайтыр.

Ә с м а. Кызым, кара, буятма. Кайтканда төреп кенә алып кайт. Тузанланмасын. Кызым Мөршидә, мә, синең кулыңа бирәм. Синнән алырмын да. Тегендә-монда, диясе булма!

М ө р ш и д ә. Ярый, әнкәй. Җаным төсле үк саклармын.

Ә с м а. Ярый, хушыгыз, балалар. Мөршидә, дим, оны-та күрмә сөлгемне. Тузанланмасын. Җиргә куймагыз...

М ө р ш и д ә. Юк, юк, әнкәй.

Ә с м а. Кызым Мөршидә, кара аны, сиңа бирдем, синнән алырмын. Куллары белән таплатмасыннар. *(Чыга.)*

М ө р ш и д ә. Ярый, әнкәй, ярый.

Б и б и н у р. Илаһым, бизәкләре нинди күп, нинди вак-лар, нинди матурлар.

М ө р ш и д ә. Чигешләре, каюлары төрле-төрле.

Г ө л б а н у. Казан кызларының аяклары кәкре булса да, куллары туры, күрәсең.

М ө р ш и д ә. Чү, егетләр киләләр.

Б и б и н у р. Егетләргә күрсәтик әле. Исләре китсен.

М ө р ш и д ә. Юк, юк, күрсәтер хәлем юк. Йә берәрсе кызык итеп борынын сөртер.

Г ө л б а н у. Кулларына бирмәбез.

К ы з л а р. Күрсәтик, күрсәтик!..

## IV КҮРЕНЕШ

К ы з л а р, е г е т л ә р.

Е г е т л ә р. Ха-ха-ха... Әмма дә кызык иткәнсең, малай, молодец!

И л ь я с. Шулай итмичә дә булмый шул. Кяфердән шулай үч алмасаң, ничек аласың аны. Мин әйтәм, мин синең дуңгызларыңны көтмим, дим. Дуңгызларымны көтмичә, әллә кызларымны көтәр идеңме, ди.

С а л и х. Йә, йә!

И л ь я с. Юк, көтәрсең, ди. Юк, көтмәм, дим. Юк, көтәрсең, ди. Юк, көтмим, дим. Дуңгызларымны көтмәсәң, мин сине чыгарам, ди. Мин әйтәм, син дуңгыз көтмәгән өчен мине чыгарсаң, мин тотармын да татарларның мөфтиләренә прашение бирермен, дим. Ул синең

кәбестәләреңне санар, дим. Юк, ди, мөфти, ди, мирза, ди. Мирза мөфти үзе сине төрмәгә яптырыр, ди. Шулаймы, дим, яптырырмы, дим. Ярый, алайса, мин синең дуңгызларыңны көтәм, дим. Шулай итеп, сиксән сигез мең дуңгызын көтә башладым.

Салих. Һай-һай. Сиксән сигез мең, диең? Җөгертәсеңдер.

Ильяс. Ие, сиксән сигез мең. Араларында сыердан да зурлары бар, малай. Шулай беркөнне, дуңгызларны сазлыктан алып кайтып, ашханәгә кергән идем, өстәлдә чебен үтерә торган бер шешә дару тора. Тукта, дим, берәр нәрсәгә ярар әле, дим. Кесәгә ялт!

Салих. Ялт, диең?

Ильяс. Әйе, ялт. Иртә белән әлеге сиксән сигез мең дуңгызны сазлыкка илткәч, теге чебен үтерә торган даруны сазлык өстенә сибеп җибәрдем. Шуннан, малай, дуңгызлар кырыла башламасыннармы. Бер атна эчендә сиксән сигез мең дуңгыздан берсе дә калмады. Араларында бояр үзе генә калды.

Салих. Кырылды, диең?

Ильяс. Чукырдаша-чукырдаша кырылдылар.

Салих. Соң, бояр нәрсә ди?

Ильяс. Нәрсә дисен, дуңгызлардан бәхет юк. Татар дуңгызларыннан ничек булыр дип, дүрт кәҗә, бер тәкә алды. *(Колакка сөйли.)*

Салих. Нигә дүрт кәҗә, бер тәкә ул?

Ильяс. Мөселманча эшләде. Татарларга дүрт хатын белән торырга яраганны, нигә тәкәгә ярамасын, ди.

Бибинур. Бу нинди чуваш икән?!

Мөршидә. Урман арты алпавытының көтүчесе. Кәҗәләр эзли, ди.

Егетләр. Ха-ха-ха!.. Чеп-чи урыс икәнсең!

Салих. Йәле, егет, кураеңда уйнап ал әле! Юкса, күрмисеңме, кызлар көзге чебиләр шикелле бөрешкәннәр.

Гөлбану. Җылытучылар булмагач бөрешкәндер шул.

Ильяс. Нәрсә ди ул?

Салих. Уйна, уйна! Сиңа түгел, миңа әйтә.

Оркестр, курай «Казан сөлгесе» көен уйный.

Кара, эшеңдә бул!

Ильяс. Миңа әнә тегесе ошый.

Мөршидә. Күз карашларыннан башым әйләнә башлады. Бу ул үзе булырга кирәк. Бигрәк тә чибәр мәхдүм икән.

С а җ и д ә. Ул, ул... Каһәр генә суккан икән, үзе булган икән. Мөршидә, әнкәй Казан сөлгесен хәзер үк алып кайт диде бит сиңа. Нигә монда катып торасың?

М ө р ш и д ә. Ярый, апа, хәзер алып кайтырмын.

Оркестр «Казан сөлгесе» көен уйный.

И л ь я с.

Һаваларда тилгән, ай, очадыр.
Урын, урын сайлый кунарга.
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Сөйләшик барып аулакка!..

М ө р ш и д ә.

Чит илләрдән килгән, матур, тилгән
Урын табар микән илләрдә?
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Сөйләшик барып аулакка!..

С а җ и д ә.

Курайларда уйнап, букча тагып,
Кайдан килдең, егет, безгә син?
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Сөйләшик барып аулакка!..

И л ь я с.

Мәдрәсәләр күргән мин булырмын.
Китап, Коръән укып мин үстем.
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Сөйләшик барып аулакка,
Сөйләшик барып аулакка!..

М ө р ш и д ә.

Алдамасаң мине, чибәр егет,
Ачармын мин йөрәккәемне.
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Сөйләшик барып аулакка!..

И л ь я с.

Канатлар куеп очып килдем,
Сине, бәгырем, сине күрергә...
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Каушыйк, каушыйк, матур, яшь чакта,
Сөйләшик барып аулакка!..

Е г е т л ә р, к ы з л а р таралалар.

С а җ и д ә. Мөршидә, сиңа монда ни калган? Бар, хәзер Казан сөлгесен өйгә илт. Әнкәй башыңны ашар.

М ө р ш и д ә. Мин ялгыз кайтырга куркам, үзең илт!

С а җ и д ә. Юк, син илт!

М ө р ш и д ә. Юк, син илт!

С а җ и д ә. Син илт!

М ө р ш и д ә. Син илт!

С а җ и д ә.<br>
М ө р ш и д ә. } Яраттым шул Казан шәкертен.

Оркестр «Казан сөлгесе» көен уйный.

И л ь я с.

Казаннардан кайткан, ай, сөлгене<br>
Саф суларга төшеп кем чайкар?<br>
Бар илт, бар илт Казан сөлгесен,<br>
Яраттым шул матур сеңлесен.

С а җ и д ә. Аһ, харап булдык! Каравылчы килә...

М ө р ш и д ә. Качыйк, качыйк...

С а җ и д ә капкадан чыгып китә.

И л ь я с. Әйдә, әйдә мәчеткә!..

Мәчеткә керәләр.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Икенче пәрдәдәге күренеш. Ә с м а, С а җ и д ә керәләр.

### I КҮРЕНЕШ

Ә с м а, С а җ и д ә.

Ә с м а. Йа Ходай, монда да юк. Йөрмәгән җирем калмады. Су буенда да юк, ындыр артында да юк, таллар арасында да юк. Әллә икесен бергә урлап киткәннәр инде? Үзе генә булса бер хәл иде. Казан сөлгем әрәм булды лабаса. Җеназам өстенә ябарлык бер нәрсәм булды, дип шатланган идем. Насыйп булмаган, күрәсең. Син, апа башың белән, нәрсә генә карап тордың, аңгыра тавык!

С а җ и д ә. Өйгә кайтыйк дип никадәр ялындым, ә ул...

Ә с м а. Ичмаса, Казан сөлгесен генә алып кайту кирәк

иде. Аталарына ни җавап бирермен? Ил күзенә ни йөзебез белән күренербез? Күрәчәкләремә каршы балалар үстергәнмен икән!

Саҗидә. Әнкәй, күпер астын карыйк, шунда утырмыйлар микән?

Әсма. Булмас, булмас. Тәгаен, урлап алып киткәннәрдер. Таң да атты, көтү дә чыккан. Бөтен дөньяга адәм мәсхәрәсе итте бу кыз бала.

Оркестр, курай уйный. Көтү тавышы. Әтәчләр кычкыра.

## II КҮРЕНЕШ

Ильяс, Мөршидә.

Ильяс.

Таңнар атып, Чулпан йолдызлары
Сүнеп килә якты күкләрдә.
Сөям, сөям сине, матурым,
Сөям, сөям сине, матурым,
Кайчан кавышырбыз без тагын?

Мөршидә.

Йөрәгемне суырып алдың, егет.
Хәсрәтләргә салыр өченме?
Сөям, сөям сине, матурым,
Кайчан кавышырбыз без тагын,
Кайчан кавышырбыз без тагын?

*(Елый.)*

Ильяс.

Елама, матур, елама, күз яшьләрең
Ал таңнарда җиргә таммасын.
Сөям, сөям сине, матурым,
Кайчан кавышырбыз без тагын,
Кайчан кавышырбыз без тагын?

Мөршидә.

Сызлый, егет, сызлый йөрәккәем,
Сызлый татып гыйшык җәфасын.
Сөям, сөям сине, матурым,
Сөям, сөям сине, матурым,
Кайчан кавышырбыз без тагын?

Мөршидә. Аһ, харап булдык, җаным, харап булдык! Әткәй намазга да килә. Урамга көтү дә чыккан. Кая гына барыйк? Тотылдык, хур булдык!..

Ильяс. Әйдә, җаным, бире. Менә шунда картларның намаздан чыкканын көтеп торырбыз.

### III КҮРЕНЕШ

Шулар ук, мөәззин һәм картлар.
Музыка.

Мөәззин.

Заказ тәһарәт алып,
Кулга таякны тотып,
Башка чалманы киеп
Алла өчен, тидия!

Картлар.

Әгәр әтәч булмаса,
Иртә таң намазына
Кемнәр уятыр иде,
Эһем, эһем, тидия.

Оркестр уйный. Азан әйтәләр. Пауза.

Мөршидә. Харап кына булдым, харап булдым!..
Ильяс. Нәрсә булды, нәрсә бар?
Мөршидә. Харап кына булдым, ай, харап булдым!..
Ильяс. Нәрсә, нәрсә? Әллә...
Мөршидә. Харап булдым, дим, харап булдым!..
Ильяс. Нәрсә харап булдың, ни бар?
Мөршидә. Калды бит, калды.
Ильяс. Нәрсә калды?
Мөршидә. Калды, калды Казан сөлгесе!..
Ильяс. Кая?!
Мөршидә. Анда.
Ильяс. Ә!..

Оркестр «Казан сөлгесе» көен уйный.

Мөршидә.

Казаннардан килгән, ай, сөлгене
Мәчет мөнбәрендә калдырдым.
Калды, калды Казан сөлгесе,
Калды, калды Казан сөлгесе,
Калды ла бит гыйшкыбыз билгесе.
Нигә алдың, егет, кочагыңа,
Нигә мәчетләргә керттең?
Калды ич, калды ич Казан сөлгесе,
Калды ич, калды ич Казан сөлгесе,
Калды ла бит гыйшкыбыз билгесе.

Ильяс.

Чәчләребез бергә бәйләнгәндер,
Ташламамын, җаным, син ышан.

Калды, калды Казан сөлгесе,
Калды ла бит гыйшкыбыз билгесе,
Калды ла бит гыйшкыбыз билгесе.

М ө р ш и д ә.

Мәчетләргә хәтфә намазлыклар
Чигеп бирер идем, котылсам.
Калды ич, калды ич Казан сөлгесе,
Калды бит гыйшкыбыз билгесе,
Калды бит гыйшкыбыз билгесе.

И л ь я с.

Сәхәрләрдә Коръән чыгар идем,
Мәдрәсәдә яткан чакларда.
Калды ич, калды ич Казан сөлгесе,
Калды бит гыйшкыбыз билгесе,
Калды бит гыйшкыбыз билгесе.

И л ь я с, М ө р ш и д ә.

Мәңге шулай кочар идем.
Мәңге иркәләрмен кочакта.
Калды ич, калды ич Казан сөлгесе,
Калды ла бит гыйшкыбыз билгесе.

## IV КҮРЕНЕШ

М ө р ш и д ә, И л ь я с, к а р т л а р.
Оркестр «Бәдәвам» көен уйный.

К а р т л а р.

Киңдер, Кадир, кодрәтең,
Иртә намаз сөннәтен
Һәйбәтләп укып чыктым,
Кабул кылгыл, тидия.
Җиде оҗмах ишеген,
Җитмеш җиде хур кызын,
Әлван-әлван нигъмәтен
Насыйп кылгыл, тидия.
Дәхи кәүсәр шәрабын
Һәм тәмле хөрмәләрен
Насыйп иткел син барын
Закускага, тидия.
Йомшак хөллә туннарын
Һәм бүре толыпларын,
Һәм кама бүрекләрен
Насыйп кылгыл, тидия.
Чалгы, урак алтыннан,
Сәнәкнең көмешләрен,

Тимер тарантасларын
Насыйп кылгыл, тидия.
Атның да юргаларын,
Кәҗә, сарык, сыерларын
Симез иткел син барын.
Сөт күп булсын, тидия.
Арыш уңсын, мул булып.
Тары уңсын, мең булып.
Ындырлар торсын тулып
Кибәннәргә, тидия.
Язын, көзен туй булсын,
Йортлар бирнәгә тулсын,
Киленнәр уңган булсын,
Эһем, эһем, тидия.

Оркестр «Казан сөлгесе» көен уйный.

Мөәззин.
Таптым, таптым Казан сөлгесен.
Ничек кергән монда, җен белсен!
Мөршидә.
Харап булдык, җаным, без тотылдык.
Ильяс.
Харап итте Казан сөлгесе.
Халык.
Таптык, таптык Казан сөлгесен.
Кая, тизрәк халык җыелсын.

Халык керә.

Мөршидә, Ильяс.
Качып кынай булмый: тозак, тозак
Безнең юлыбызга корылган.
Халык.
Таптык, таптык Казан сөлгесен,
Таптык, таптык Казан сөлгесен.
Кая, тизрәк халык җыелсын!
Мөршидә.
Котылырга, җаным, бу хурлыктан
Хәйләләрен эзләп үзең тап.
Халык.
Таптык, таптык Казан сөлгесен.
Кая, тизрәк халык җыелсын!
Ильяс.
Курыкма, курыкма, җаным, коткарырмын.
Менә хәзер шунда кереп ят!
*(Капчыкка сала.)*

Халык.

Таптык, таптык Казан сөлгесен,
Таптык, таптык Казан сөлгесен.
Кая, тизрәк халык җыелсын!

Мөәззин. Җәмәгать! Бу сөлгенең мәчеткә керүе тикмәгә түгел. Бер хикмәт булырга кирәк монда.

1 кода. Хикмәт бар, хикмәт бар!

2 кода. Зур хикмәт бар монда, бик зур!

Мөәззин. Җеннәр алып кермәдеме икән анда?

1 кода. Җендер, җендер!

2 кода. Тәгаен җендер.

Мөәззин. Картлар! Моның хикмәтен хәзрәттән сорарга кирәк. Фәтвасын ул тапсын.

1 кода. Сорыйбыз, сорыйбыз!..

2 кода. Фәтвасын хәзрәт тапсын.

Хәзрәт. Ие, ягъни мәсәлән, фараз кылдык, хуш… бу инде, мәсәлән, хуш, бинабәрин[1], ие, фаразан, мәсәлән, бу инде хуш… сөлге!

1 кода. Дөрес, дөрес.

2 кода. Ие, сөлге.

Хәзрәт. Бу инде, фаразан, ягъни мәсәлән, ие, хуш… Казан сөлгесе!

1 кода. Дөрес, дөрес.

2 кода. Ие, Казан сөлгесе.

Хәзрәт. Ие, хуш, ягъни мәсәлән, фараз кылдык, бу инде, фаразан, җен эше.

1 кода. Дөрес, дөрес.

2 кода. Тәгаен җен эше.

Хәзрәт. Фаразан, бу нәрсәгә мулладан башкага кагылырга ярамый.

Мөәззин. Мөәззингә дә дөрес, дигән китап.

Хәзрәт. Хуш, фаразан, моның серләренә дучар булырга кирәк. Җеннән, фаразан, кәҗә тәкәсе исе килер, дигән китап. Шуның өчен, фаразан, иснәп карарга кирәк. *(Ятып исниләр.)* Хуш, ягъни мәсәлән, ие, хуш, фараз кылдык, җенне эзләргә кирәк.

1 кода. Дөрес, дөрес.

2 кода. Эзләргә кирәк, эзләргә кирәк. *(Эзлиләр.)*

Мөәззин. Менә ул! Тотарга кирәк, тотарга кирәк. Алдан хәзрәт, хәзрәт барсын.

Хәзрәт. Ягъни мәсәлән, фараз кылдык, ие, хуш, би-

---

[1] Бинабәрин – шулай булгач.

набәрин, бездән булмас. Безнең, фаразан, тәһарәтебез шөбһәле хәзер. Фараз кылдык, мөәззин барсын.

1 кода. Дөрес, Дөрес.

2 кода. Мөәззин барсын.

Мөәззин. Юк, җәмәгать, бездән булмас. Аның өчен минем тәһарәтем кичәге шул. Ягъни мәсәлән, иске. Яңа тәһарәтле кеше бару кирәк.

Ильяс. Картлар! Бу җен түгел. Бу — урман арты боярының көтүчесе…

1 кода. Алай…

Мөәззин. Син, хәшәп, ахмак! Ни эшләп монда утырасың, халыкны куркытып? Бар, бар, юлыңда бул!.. Йә, ни эшләп катып торасың? Тукта, тукта, ни эшкә монда килдең? Ә?

Ильяс. Кәҗәләребез югалган иде. Шуларны эзләп килгән идем. Төнгә калгач кайтырга курыктым да шунда кундым.

Мөәззин. Соң кәҗәләреңне таптыңмы?

Ильяс. Берсен таптым.

Мөәззин. Шунда кундым, дисеңме?

Ильяс. Әйе.

Мөәззин. Төнлә мәчеттә җеннәр йөргәнне ишеттеңме?

Ильяс. Ишеттем.

Халык. Ә, ә, ә!!

Ильяс. Ишеттем, дим. Төн буенча шау килделәр.

Мөәззин. Әйттем бит, җен эше дип. Син аларны монда алып килгәнсеңдер әле. Моңарчы, Аллага шөкер, тыныч иде. Ярый, ярый, бар, юлыңда бул!

1 кода.<br>
2 кода. } Бар, бар!

Ильяс капчыгын күтәреп китә башлый. Капчык ертыла. Мөршидәнең аяклары салынып төшә.

Мөәззин. Тукта әле, бу нәрсә?

Ильяс. Кәҗә.

Мөәззин. Ә?!

Ильяс. Кәҗә, дим.

Мөәззин. Кая, кая?

Әсма керә.

Әсма. Кая, сөлгем табылган, ди. Кая, кая? Ә менә ул, Казан сөлгем!

Мөәззин. Аһ, адәм хурлыклары, ил корткычлары!

Менә сезнең аркагызда яңгыр да яумый, игеннәр булмый. Терлек-туар кырыла. Бәйләгез үзләрен!

2 кода. Бәйләгез, бәйлә! *(Бәйлиләр.)*

1 кода. Бир кирәкләрен! *(Ян-якка тарткалыйлар.)*

Мөәззин. Кара аны, җүнсезләр, хәшәпләнергә нинди урын тапканнар. Бирегез кирәкләрен!

Әсма. Әтәч! Тотылганнар. Кем кызы икән? Күлмәге минем Мөршидәм күлмәге төсле үк.

Мөәззин. Син, син, чуваш башың белән, безнең мөселман кызларын, фаразан... ядәч! Чәче купты! Чәче купты!..

1 кода. Бирегез кирәкләрен!.. *(Чишендерәләр.)*

Оркестр «Казан сөлгесе» көен уйный.

Ильяс, Мөршидә.

Хуш, бәхил бул, дөнья, соңгы сәгать.
Сандугачлар фирак[1] көйлиләр.

Халык.

Тик тор, тик тор, адәм актыгы,
Тик тор, тик тор, адәм актыгы,
Ил өстенә төште хурлыгы.

Мөршидә, Ильяс.

Кичерегез, картлар, йөрәк утын!
Яшь чакларда гына яна ул.

Халык.

Тик тор, тик тор, адәм актыгы,
Тик тор, тик тор, адәм актыгы,
Ил өстенә төште хурлыгы.

Хәзрәт. Җәмәгать, фараз кылдык, ягъни мәсәлән, бу эш — бик зур эш. Боларны шәригать буенча, фаразан, хөкем итәргә кирәк.

Ибраһим. Нинди хөкем тагын? Кыйнап үтерергә дә, вәссәлам! Җәмәгать, фараз кылдык.

Салих. Картлар, боларның гөнаһлары бик зур. Хәзрәт әйткәнчә, шәригать буенча хөкем итәргә кирәк. Минемчә, боларны без шул агачларга бәйләп, иртәгә кадәр шунда калдырырга кирәк.

Мөәззин. Качып китсәләр нишләрбез?

Салих. Сакчы куярбыз. Сакчы булгач кача алмаслар.

Хәзрәт. Фаразан, ягъни мәсәлән, хуш, шул агачларга иртәгә кадәр, фаразан, бәйләп кую — мәслихәт.

1 кода. Бәйлибез, бәйлибез!.. *(Бәйлиләр.)*

---

[1] Фирак — аерылышу.

2 кода. Бәйләргә, бәйләргә.

Мөәззин. Староста, десятник, урядниккә хәбәр итәргә кирәк.

1 кода.<br>2 кода. } Шулай кирәк, шулай кирәк.

Оркестр «Әпипә» көен уйный.

Мөәззин.

Староста, десятник, кая, тизрәк килсеннәр!
Староста, десятник, кая, тизрәк килсеннәр!

Халык.

Кая, тизрәк, кая, тизрәк, кая, тизрәк килсеннәр.
Кая, тизрәк, кая, тизрәк, кая, тизрәк килсеннәр.

Пәрдә төшә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Өченче пәрдәдәге күренеш.

### I КҮРЕНЕШ

Оркестр «Казан сөлгесе» көен уйный.

Ильяс, Мөршидә.

Сандугачлар килеп канат кагып
Сайрамаслар инде таңнарда...
Калды, калды хурлык билгесе,
Калды, калды хурлык билгесе,
Харап итте Казан сөлгесе.

Каф тавыннан якты кояш чыгып
Нурларын чәчә алмас юлларга.
Калды, калды хурлык билгесе,
Калды, калды хурлык билгесе,
Харап итте Казан сөлгесе.

Ильяс.

Сулар агар, ташып дулкын-дулкын,
Дулкыннарда йөзеп кем үтәр?
Калды, калды хурлык билгесе,
Калды, калды хурлык билгесе,
Харап итте Казан сөлгесе.

Мөршидә.

Мәхдүм башың белән тоткын булдың,
Илләреңә хәбәр кем итәр?

Калды, калды хурлык билгесе,
Калды, калды хурлык билгесе,
Харап итте Казан сөлгесе.

## II КҮРЕНЕШ

Шулар ук, Ибраһим, Салих.

Салих. Нихәл, Ибраһим абый? Бу яхшыдан яман туган нәрсәләрне качырмадыңмы?

Ибраһим. Бер әләккәч ычкындыру юк инде ул.

Салих. Кызы кем икән, танымадыңмы?

Ибраһим. Менә таң аткач, җыен алдында кем икәнлеге беленер. Тик менә мөәззиннең хатыны белән кызы төн буенча тынычлык бирмәделәр. Ничә мәртәбә куып җибәрдем үзләрен. Менә синдә, шәкерт, теге беркөнге шикелле йокыдан эчә торган нәрсәң булса, анасы ярар иде.

Салих. Нәрсә соң ул алай?

Ибраһим. Теге фәрештә бармагы дисезме әле — фифирус.

Салих. Кеше күрер бит.

Ибраһим. Мин җиң эченә тыгып кына, менә болай гына.

Салих. Янымда юк.

Ибраһим. Өйдә бармы?

Салих. Бар. Иренмәсәң, барып алып кил.

Ибраһим. Каян табармын мин аны?

Салих. Ападан сорарсың. Тәрәзә башында дисәң табып бирер.

Ибраһим. Ә боларны нишлибез соң? Качарлар бит.

Салих. Син килгәнче, мин каравыллап торырмын. Тизрәк кил. Минем намазга кадәр хәзрәткә барасым бар.

Ибраһим. Очып кына килермен. Кара аны, шәкерт, кача-нитә башласалар, шул күсәк белән башларына бәр. Староста үзе шулай диде.

Салих. Ярый, ярый. Бар тизрәк бул. Шырпысын да онытма!

Ибраһим. Тәрәзә башында, дисеңме?

Салих. Әйе.

Ибраһим. Яхшы карый күр үзләрен! *(Чыга.)*

Салих. Йә, бар! *(Ильяс белән Мөршидә янына килә.)* Йә күгәрченнәр, эшләр начар бит: намаздан чыгуга, хәзрәтләр, картлар халык алдында сезне хөкем итәчәкләр, ә ул хөкемнең нәтиҗәсе нәрсә буласы үзегезгә мәгълүм инде. Йә, әйдәгез, миңа булышыгыз!

И л ь я с. Әйдә, качыйк тизрәк!

С а л и х. Ярамый. Ул чагында мине харап итәсез. Аннан урамнарда, тирә-якларда каравыллар куелган. Үзегез дә инде, мәчеттән башка җир таба алмагансыз. Син, Ильяс, чишен, хәзер чишен!

И л ь я с. Нәрсә?

С а л и х. Күп шапырдама, чишен дигәч чишен! Ә син, Мөршидә туташ, менә бу бүрәнәгә шушы күлмәкне киерт!.. Тизрәк маташыгыз! Менә шулай, менә шулай... Яулыгыгызны башына ябыгыз! Менә шулай... Тизрәк маташыгыз!.. Чү... киләләр!.. Качыгыз! Манарага! Манарага!.. Качыгыз!

И л ь я с белән М ө р ш и д ә качалар.

## III КҮРЕНЕШ

С а л и х, И б р а һ и м, х а л ы к.

И б р а һ и м *(йөгереп кереп)*. Картлар намазга киләләр... Кая, бир күсәкне!

Оркестр «Тәкый гаҗәп» көен уйный.

Н а м а з  х а л к ы.
Һәр мөэмин хак мөселманның җилкәсендә
Кырык бер фарыз, җитмеш җиде сөннәт булыр, дигән.
Дәхи аның бишмәтенең кесәсендә.
Чүпрәге йөрер, дигән имди. Әптч! Ху-ху-ху-тфү!..

С а л и х. Мөәззин бабай, мәшәкатьләнеп манарага менеп азан әйтмә, мин азан әйттем инде.

М ө ә з з и н. Бәрәкалла, шәкерт, бәрәкалла!

С т а р о с т а. Ибраһим энем, халык килсә, безнең намаздан чыкканны көтсеннәр. Бу оятсызларга хөкем булачак. *(Мәчеткә керә.)*

## IV КҮРЕНЕШ

И б р а һ и м. Ярый, Саттар агай. *(Карачкыларга карап.)* Менә, җүнсезләр, үзегезгә хәзер хөкем булыр. Ни йөзегез белән картлар алдында торырсыз? *(Егеткә төртеп.)* Синең инде иманың да, оятың да юк. Син чуваш инде. *(Кызга.)* Ә син, мөселман башың белән, чуваштан башка кеше таба алмадыңмы, җүнсез! Әнә күрәсез, яхшы кешеләр намаз укыйлар. Аллага гыйбадәт кылалар. Ә сез монда, агач төсле, катып торасыз, йә, әйтегез әле, ни йөз

белән картларга күренмәкче буласыз? Йә, хуш, ни йөзегез белән муллалар, картлар алдында басып торырсыз, дим! И имансыз, мордар кяферләр! Син нигә аны безнең мәчеткә алып кердең? Нигә үзеңнең чиркәвеңә алып бармадың, ә? *(Төртеп.)* Һи, букән, сүз кайтарырга телең бармыймыни? Бармас шул. Ә син атаң-анаң алдында ни йөз белән торырсың? Кардәш-ыруларыңа ничек күренерсең? Сине бит хәзер чорт та кияүгә алмас.

## V КҮРЕНЕШ

Ибраһим һәм Салих.

Салих. Әйе, әйе, сине хәзер чорт та үзенә хатын итеп алмас. Синеңише имансыз агачлар урманда азмыни?

Халык җыела.

Ибраһим. Бусы оятыннан бөтенләй телдән калган.

Салих. Ә син, агач букән, нигә сөйләшмисең?

Ибраһим. Ә менә монысы нәкъ карачкы, катып тора. Җүнсез булса да, оят бар икән әле үзендә.

Салих. Егетләр! Хәзрәтләргә, картларга урындыклар кирәк булыр. Хәзер монда менә бу агачларга хөкем була. Тиз генә алып килегез әле.

Берничәсе чыга.

Ибраһим. Һи, җүнсезләр, йөзләрен яшергән булганнар. Алай оялырлык булгач эшләмиләр аны!

Оркестр «Кәҗә бәете» көен уйный.

Салих. Тавышланма. Хәзрәтләр чыгалар.

## VI КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм картлар.

Намаз халкы.
Иртә намаз укыганга ахирәттә
Чибәр-чибәр эһем, эһем булыр, дигән.
Бик елмаеп ул ятачак, ди, зур оҗмахта,
Мәшанчылар шулай дигән инде, эһем, тфү!..

Староста. Җәмәгать! Таралмагыз. Менә бу уйнашчы азгыннарга хөкем була. Ә менә урындыклар да булган. Кая, менә шунда куегыз. И Галиулла, кәгазь, караң кая? Йә, хәзрәтләр, утырышыгыз! Картлар, кодалар, сез дә

утырыгыз. Үрәдникнең базарга барасы бар икән, эшне башкарырга хәзрәтләр белән миңа тапшырды.

Утыралар, Староста медален кия.

Хәзрәт. Ягъни мәсәлән, инде фараз кылдык, бинабәрин, хуш, хөкемне шәргъ[1] шәрифчә, фаразан, кылабыз инде. Шуның өчен, фаразан, мәгъюбәнең[2] ир хатынымы, толмы яки кызмы икәнлеген, фаразан, безгә белергә кирәк.

Староста. Ибраһим, бу җүнсез – хатынмы, кызмы?

Ибраһим. Белә алмадым, Саттар агай.

Староста. Әллә тол хатынмы икән?

Ибраһим. Белә алмадым.

Хәзрәт. Ягъни мәсәлән инде, фаразан, үзеннән сорарга кирәк була инде.

Староста. Ибраһим, ул җүнсезнең кызмы, хатынмы икәнлеген тиз генә белеп кил әле.

Ибраһим. Бездән булмас, Саттар агай, аның өчен...

Мөәззин. Кем, шәкерт, бар әле, кая әле, шәкерт, теге чүпрәк башның кызмы, хатынмы икәнлеген барып белеп кил әле.

Салих. Хәзрәтләр, картлар рөхсәт итсәләр, мөмкин.

Картлар. Рөхсәт, рөхсәт!

Кода *(барып)*. Әй син, чүпрәк баш, ир хатынымы син, толмы, әллә кызмы?.. Хәзрәтләр сорыйлар. Шунсыз булмый, ди.

Хәзрәт. Ие, ие, фаразан, ансыз һич булмый инде. Шәргъ шәриф бит, ахрысы, фаразан, белергә куша инде.

Кода. Йә, әйт инде. Хәзрәтләрне көттермә. Йә, әйт инде, әйт!

Мөәззин *(барып)*. Йә, әйт, хәшәп! Кызмы, хатынмы? Йә, йә, оялма!.. Оялма, хәшәп!

Хәзрәт. Фаразан, ягъни мәсәлән, көчләмәгез. Сөкүт[3] фаразан, ризалык галәмәте инде. Ягъни мәсәлән, шәрган[4], фаразан, никахсыз хатын була инде.

Староста. Әллә син, җүнсез, телеңне йоттыңмы?

Хәзрәт. Кем, Саттар, көчләмәгез. Мондый вакыйгаларда, фаразан, төрле хәлләр була ул. Бәлки, Хак Тәбарәкә вә Тәгалә телен алгандыр. Менә, фаразан, китапларның әйтүләренә караганда, шундый, фаразан, бина-

---

[1] Шәргъ – шәригать.
[2] Мәгъюбә – гаепләнүче хатын-кыз.
[3] Сөкүт – эндәшмәү.
[4] Шәрган – шәригать буенча.

бәрин, хуш, фаразан, шундый эшләр вакытында Бохараи шәрифтә гаҗәп, фаразан, хәлләр булган. Шәйхан Габделсыгырхан заманында, фаразан, шуның шикелле бер иркәк белән бер хатын уйнаш кылып тотылган булганнар, фаразан, ягъни мәсәлән, шул гөнаһкярлар, фаразан, хөкем алдында, фаразан, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән, хуш, фаразан, ташка әверелгәннәр.

Картлар. Кара син аны, ташка, диең, ә?

Мөәззин. Ташка әверелү эшмени. Шуның шикелле хәзрәти Исхак заманында уйнашчыларның берсе ишәккә, берсе тәвәгә әверелгән дигән сүзләр дә бар китапларда. Аның өчен бу гөнаһ — гөнаһларның иң әшәкесе. Хәшәбе инде. Шуның шикелле, бу хәшәпләрне дә Аллаһы Тәгалә хәзрәте, хәзрәт әйткәнчә, ни эшләргә дә кодрәте бар. Ташка түгел, агачка әйләнүләре дә мөмкин!

Староста. Ибраһим, син саклаган чакта, телләре бар идеме?

Ибраһим. Күрмәдем.

Староста. Бар әле, чувашның теле урынында микән? Кара әле.

Мөәззин. Ә, кем, Ибраһим, фаразан, кирәк түгел. Иншалла, урынындадыр.

Староста. Алай булса, хәзрәтләр, эшкә керешик. Нинди җәза бирәбез боларга?

Хәзрәт. Фаразан, шәргъ шәриф буенча хөкем булса, ягъни мәсәлән, беренчесе, фаразан, тереләй җиргә күмү, икенчесе, фаразан, бил тикле җиргә күмеп, ташлар атып үтерү, өченче төрлесе инде, фаразан, капчыкка салып манарадан ташлау инде. Дүртенче төрлесе инде, фаразан, ике мең таяк ору, менә шул җәзаларның кайсын, фаразан, ягъни мәсәлән, җәмәгать кабул итәр.

2 кода. Минемчә, элек бил тикле җиргә күмеп, ташлар белән бәрергә кирәк. Соңыннан манарадан ташларга кирәк.

1 кода. Минемчә, элек һәйбәтләп суктырырга кирәк, соңыннан манарадан ташлау кирәк, анда да үлмәсәләр, тереләй җиргә күмү кирәк.

Мөәззин. Саттар агай, безгә инде үлем җәзасы белән хөкем итүебез өчен урядник хәзрәтләре сүз әйтмәсме?

Староста. Теләсәгез нишләгез үзләрен, дип үземә әйтеп калдырды. Шәригать кушканнан узып булмый инде. Бу җүнсезләрне яхшылап өйрәтмәсәң, башкалары да шул эшкә ябышыр! Аннан соң аның берсе кеше түгел бит, чуваш кына. Икенчесе дә шуннан артык түгел! Менә

шуларның гөнаһ шомлыгы аркасында яңгырлар яумый, иген булмый, казнага имана җыелмый. Моның өчен становой хәзрәтләре үзе дә рәхмәт кенә әйтер әле. Картлар, сезнеңчә, ничек?

Б е р ә ү. Эш сезнең кулда. Без катыша алмыйбыз.

С а л и х. Хәзрәттән узып булса да әйтим, боларның гөнаһлары бик зур, шуның өчен ут төртеп яндырырга кирәк үзләрен. Алар бик яхшы янарлар.

Х ә з р ә т. Кем, шәкерт, яндыру — Аллаһы Тәгалә, фаразан, эше. Ахирәттә, фаразан, болай да янарлар. Дөньяда, фаразан, җәзаларын күреп үтсеннәр.

С а л и х. Дөньяда ук яндырырга кирәк.

Х ә з р ә т. Юк, анысы, фаразан, ярамый, гөнаһ була.

С а л и х. Боларны җиргә күмүдән эш чыкмас.

Х ә з р ә т. Анысы, фаразан, шәргъ шәриф боерганча була.

С а л и х. Минемчә, алар утыннан башка нәрсәгә яраклы түгелләр.

М ө ә з з и н. Җәмәгать, картлар, хәзрәтнең сүзеннән узып булмас, әйдә, минемчә, үтермәскә, ике мең таяк кына орырга кирәк үзләренә.

С т а р о с т а. Хәзрәтләр, шуңар ризамысыз?

Х ә з р ә т. Риза, риза!

С т а р о с т а. Кая, Ибраһим, яткыр үзләрен. Китерегез таяк. Үзем сугам. Хәзрәт, суккан өчен савап булыр бит?

Х ә з р ә т. Фаразан, кырык корбан чалганның савабы булыр, дигән.

С т а р о с т а. Яткыр үзләрен, чувашыннан башлыйк.

М ө ә з з и н. Менә минем таяк нык тамыр агачыннан. Бисмиллаһ-иррахман-иррахим.

И б р а һ и м. Йә, әйдә, картлар алдына барып ят. Йә, ни эшләттең? Нәрсәгә бүкән төсле катып торасың. Әйдә, дигәч, әйдә, диләр сиңа! *(Төртә. Агач ава.)* Җәмәгать, үлгән!..

Х ә з р ә т. Юк, фаразан, һушыннан гына тайгандыр. Ятып торсын.

С т а р о с т а. Әйдә, икенчесен китер!

И б р а һ и м. И, син, чуваш калдыгы, әйдә, ят! Әйдә, дим, инде! Әллә син дә... *(Агач авып китә.)* Җәмәгать, монысы да үлде!..

Х а л ы к. Үлгән!..

Җыелып карый башлыйлар.

С а л и х. Җәмәгать, агачка әверелгәннәр.

Хәзрәт. Яһу хуҗа Бәһаветдин! Кәрамәт[1] бу, фаразан, кәрамәт!

Мөәззин. Җәмәгать, нишлибез инде боларны? Урәдник, становой хәзрәтләренә ни җавап бирәбез инде?

Хәзрәт. Фаразан, Алланың кодрәте белән бүрәнәгә әверелделәр, диярбез.

Мөәззин. Гөнаһлары бик зур булган икән. Соң син, кем, Ибраһим, агачка әверелгәннәрен сизмәдеңме? Фәрештәләр яки иблиснең килеп-китеп йөрүен күрмәдеңме?

Ибраһим. Һич сизмәдем. Яннарыннан бер адым да читкә китмәдем.

Хәзрәт. Фаразан, күк капусы-фәлән ачылмадымы? Хуш?

Салих. Җәмәгать! Бу Алла тарафыннан безгә иңдерелгән бик зур бер гыйбрәт инде.

Староста. Соң, хәзрәтләр, боларны нишлибез инде?

Мөәззин. Күмәргә кирәк.

Староста. Бүрәнәләрнеме?

Мөәззин. Ие. Алар бит — заһирән[2] генә бүрәнәләр. Асылда, синең шикелле үк кешеләр.

Хәзрәт. Дөрес, дөрес, фаразан, өсләрендәге киемнәре фидияләреннән булыр.

Ибраһим. Ничек инде, хәзрәтләр, җеназасыз гына күмәбезме?

Хәзрәт. Китапта бүрәнәгә, ягъни агачка, фаразан, җеназа укылыр, дигән мәсьәлә күренми. Синеңчә, ничек, мөәззин?

Мөәззин. Җеназа укылмаганның фидиясе дөрес түгел... Аннан соң болар бит — тыштан гына агачлар. Эчтән кешеләр бит, чын кешеләр. Менә күз алдыбызда агачка әверелделәр бит. Ике кеше шаһәдәт бирсә, шәргән шул җитә. Ә монда без барыбыз да үз күзләребез белән күрдек бит. Ибраһим, Саттар ага, менә бу агачларның ярты сәгать моннан элек чын кеше икәнлекләренә шаһәдәт бирәсезме?

Ибраһим.<br>Саттар. } Бирәбез, бирәбез... Җәмәгать, сез ни дисез?

Халык. Шулай инде...

Хәзрәт. Фаразан, боларның берсенә генә җеназа укый алабыз. Чувашы аның кяфер, фаразан, җеназа дөрес түгел.

---

[1] Кәрамәт — могҗиза.

[2] Заһирән — тыштан караганда.

Мөәззин. Юк, хәзрәт, ул кеше чагында кяфер иде. Ә хәзер ул агач. Шуның өчен аның мөселман булуы да ихтимал.

Хәзрәт. Синеңчә, фаразан, һәр икесенә дә җеназа лазем, ягъни мәсәлән, фарыз дисеңме, фаразан?

Мөәззин. Ие, ие, һәр икесеннән дә фидия тиеш.

Хәзрәт. Фаразан, бу агачларга, ягъни мәсәлән, бүрәнәләргә, фаразан, җеназа укыйкмыни, җәмәгать?

Халык. Үз эшегез!..

Мөәззин. Кем, Ибраһим, шәкерт Гыйльметдин, кая, табутны китерегез!

Табутка китәләр.

Саттар. Хәзрәтләр, боларны юып кәфенләү эшен нишлибез инде?

Мөәззин. Агачка нигә кирәк кәфен... Ләхеткә салабыз да — вәссәлам, йә, кая, егетләр, кабер казырга барыгыз!

Ибраһим *(табут китереп)*. Табут булды, хәзрәтләр.

Мөәззин. Бисмиллаһ-иррахман-иррахим. Күлмәге дә яулыгы да ярарлык икән... *(Егетне карап.)* Ә бу хәшәпнең сәләмәдән башка бер нәрсәсе дә юк икән. Моңар, җәмәгать, җеназа дөрес түгел... Кая, бусын гына табутка салыйк. *(Табутка салып, кыйблага каршы басып.)* Кая, җәмәгать, сафланыгыз! Тәһарәтсезләрегез, тәяммем сугыгыз!

Халык тәяммем сугып сафлана.
Оркестр «Казан сөлгесе» көен уйный.

Ильяс.

Казаннардан Мәскәү күренә микән,
Биек манарадан карагач?..

Бүрәнәләрне әйләндереп.

Хәзрәт.

Бу ни, бу ни, кайдан бу тавышш?
Бу ни, бу ни, кайдан бу тавышш?
Калдырыгыз бу эшне... хуш...

Халык.

Ш... ш... ш...

Мөршидә.

Җеназа укып күмелмәссең,
Гөрләп уттай янып яраткач.

Х ә з р ә т.

Бу ни, бу ни, кайдан бу тавыш?..
Бу ни, бу ни, кайдан бу тавыш-шшш?..
Калдырыгыз бу эшне... хуш...

Х а л ы к.

Ш... ш... ш... ш...

С а т т а р. Җәмәгать, тавыш мәчеттән ишетелә. Мөәззин, барып кара әле!

М ө ә з з и н. Миннән булмас, булмас, җәмәгать. Фидияләре дә үзләренә булсын. *(Күлмәкләрне ыргыта.)* Хәзрәт барсын!

Х ә з р ә т. Бездән, фаразан, булмас. Катгыян булмас, фаразан.

С а л и х. Җәмәгать! Бу аларның өрәкләре түгелме икән?

М ө ә з з и н. Ә-ә!

С а л и х. Тс... с.. с!.. Шауламагыз! Юкса барыбыз да харап булабыз.

Х ә з р ә т. Җәмәгать, фаразан, аятелкөрси укыгыз! Фаразан, каранча догасы укып тирә-якларыгызны менә шулай сызыгыз! *(Сызып күрсәтә. Үзе шул сызык эченә кереп кунаклый.)*

С а т т а р. Кода, син мәчеткә кер әле. Тавыш шуннан килә бит. Әгузе бисмилла әйтсәң, берни дә булмас.

С а л и х. Алай-болай булса, бәхил булыгыз, җәмәгать!

Х ә з р ә т.<br>
М ө ә з з и н. } Бәрәкалла! Бәрәкалла! Аятелкөрси укып бар!

С а л и х мәчеткә керә. Бераздан бик каты кычкырып чыга. Аның артыннан И л ь я с, М ө р ш и д ә чыгалар.

С а л и х. Өрәк, өрәк, өрәкләр!..

Х ә з р ә т.<br>
М ө ә з з и н.<br>
С а т т а р.<br>
К а р т л а р. } Ләхәүлә, ләхәүлә, ләхәүлә!!!

Куркып чабып чыгалар. Шау-шу. Яшьләр көләләр.

С а л и х. Яшьләр, туктагыз! Иптәшләр, менә бу кеше минем дустым. Шиңгән каен мулласының улы, Казан шәкерте, Ильяс мәхдүм. Менә монысы — аның киләчәк хәләл җефете, мөәззин бабайның кече кызы. Мин хәзер аларга никах укыйм! Йә, утырышыгыз, рәтләп торыгыз! Эһем, эһем... Әл Хәмидулла, әл Хәмидулла, әл Хәмидулла!

Йә әммәл байгура,
Беләм диеп кайгыра,
Мужиклардан каера,
Карт хатынын аера.

Х а л ы к.

Ха-ха-ха!

С а л и х.

Йә әммәл хәзрәт,
Гакылы башында әзрәк.
Аңа тик бөлеш кирәк,
Җиң эчендә чүпрәк,
Сакалы нәкъ ярык көрәк.

Х а л ы к.

Ха-ха-ха!

С а л и х.

Йә әммәл мөәззин,
Фидиядә синең күзең.
Бакыр грош син үзең,
Кулыңнан китте кызың.

Аллаһы әкбәр, котлы булсын никахлар! *(Кул биреп котлый.)* Егетләр, өстәлләрне алыгыз!

Я ш ь л ә р.

Мулла, мөәззин, үрәдник кирәкми.
Бүген туйлар итәбез, итәбез!
Бүген туйлар, туйлар, туйлар!

Музыка, бииләр.

И л ь я с, М ө р ш и д ә.

Мәдрәсәдә китап киштә-киштә,
Киштә саен утыра фәрештә.

Кая, кая Казан сөлгесе?
Апасыннан матур сеңлесе.

Сөлге белән аларны урыйлар.

И л ь я с, М ө р ш и д ә.

Хафаланма, җаным, курыкма һич тә,
Дуслар ярдәм итә һәр эштә.
Бигрәк матур Казан сөлгесе!
Апасыннан матур сеңлесе.

С а л и х. Йә, кияү белән килен, менә монда рәхим итегез! Ибраһим, мәчеттән киемнәр чыгар! Галиулла, өстәлне китер! Утырыгыз! Теге карт-корыларны куркытып, авылдан ук качырыйк әле. Ха-ха-ха-ха!

Х а л ы к. Утырыгыз, утырыгыз!

И л ь я с, М ө р ш и д ә.

Рәхмәт кенәй, дуслар, рәхмәт сезгә,
Кавыштырдыгыз гомергә.

Х а л ы к.

Серле икән Казан сөлгесе,
Апасыннан матур сеңлесе!

Кычкыру, сызгыру, шау-шу. Табынны тирә-якка чайкап алып чыкканда...

П ә р д ә т ө ш ә.

*1922 ел*

# ЗАР

*Бәни адәм фаҗигасе*

*Алты пәрдәдә*

ФАҖИГАДӘГЕ КАТНАШУЧЫЛАР:

Газазил – бәни адәм шәхси теләкләренең матурлык, ирек, бәхет, яхшылыкка мәңгелек омтылышының тимсаль мөҗәссәме[1].
Дәҗҗал – хакимият, канун.
Шәйтан – мәкер, хәйлә, ваклык.
Яэҗүҗ – капитал.
Мәэҗүҗ – милитаризм.
Дәббәтеларз – хезмәт, эш.
Ирек – ихтыяр, ирек.
Мәхәббәт – дуслык, мәхәббәт.
Бәхет – шатлык, бәхет.
Бәдбәхет – бәла-каза, бәхетсезлек.
Адәм – кеше.
Һава – матурлык.
Мәһди – мәзлүмнәр[2] хакы өчен көрәшүче даһи.
Мөһәндис – техника белгече, инженер.
Җәбраил – ялчы, илче.
Исрафил – хәбәрче.
Газраил – үлем, әҗәл.
Гөнаһ – язык, гөнаһ.
Малик – комендант, сакчы.
Вакыт – заман, гомер.
Хәким – нәзари[3], гыйлем, фәлсәфә.
Микаил.
Нәби – архиб.
Җиһангир – капиталга кадәр булган җиһангирлык.
Вәзир – дини хакимият ялчысы.
Мулла – ислам рухание.

---

[1] Тимсаль мөҗәссәме – образлы гәүдәләнеше.
[2] Мәзлүмнәр – изелгәннәр.
[3] Нәзари – теоретик.

Папа — католик рухание.
Поп — христиан рухание.
Раввин — яһүд рухание.
Генерал — патша.
Гаскәри мәэмүр[1].
Яшь офицер.
Нечкә түрә.
Яшь егет.
Гыйшык пәрәст[2].
Эт иярткән бай карчык.
Эт иярткән матур хатын.
Таза ир.
I ач ир.
II ач ир.
Ач хатын.
I тук хатын.
II тук хатын.
Хайваннарны химая[3] җәмгыяте әгъзасы.
Юан бай.
Юка бай.
I зобани.
II зобани.
III зобани.

Ачлар, туклар, гаскәриләр, палачлар, сакчылар, ак фәрештәләр, кара фәрештәләр, зобанилар, гөнаһкярлар[4], җир әһелләре, гыйфритләр, җеннәр, пәриләр, хур кызлары, вилданнар һәм башкалар.

## БЕР-ИКЕ СҮЗ

«Зар» пьесасының мәүзугы[5], — борын-борыннан бәни адәм күңелен дулкынландырып, яшәү өчен, төрле дәверләрдә төрлечә көрәшнең көчле фактор икәнлеген күрсәткән мәңгелек мәсьәлә.

Җир йөзендә хакимият хөкем сөрә башлаган көннән бирле, шул хакимиятне саклау юлында «диннәр», «игътикад»ларга әсас ителгән[6] кануннар, низамнар чыгарылып, төрле дәвердә төрлечә химая ителгәннәр. Мөстәбид[7] ха-

---

[1] Мәэмүр — чиновник.
[2] Пәрәст — табынучы.
[3] Химая — яклау, саклау.
[4] Гөнаһкяр — гөнаһ эшләр эшләүче.
[5] Мәүзугъ — тема.
[6] Әсас ителү — нигезләнү.
[7] Мөстәбид — изүче, деспот.

кимиятне саклау юлында иң зур гамил[1], шөбһәсез, «дин», аның башлыгы «Алла». Аллалар тарихын тикшергәндә, төрле дәверләрдә, төрле халыкларда йөз меңнәрчә аллалар күрәбез.

Ләкин бу аллаларның асылы бер: ул — «тудыручы», «рәхмәт итүче» һәм «җәза бирүче» — «гали хаким», ягъни адәмнең тупас акыл даирәсе сыйдыра алмаган, аңлашылмаган һәм һичбер төрле дәлил белән исбат ителмәгән көч... Бәни адәм мәдәниләшкән саен, аллалар да мәдәниләшә, төрләнәләр. Аерым дәверләрдә хакимият нинди төс алса, аллалар да шул төскә кертеләләр.

Бу махинацияләрнең барысы — шул дәвердәге хакимиятнең иҗаты. Истибдад[2] хакимияте хөкем сөргән Шәрык илләрендә аллаларның мөстәбид[3], мөстәкыйль ителүе табигый. Шулай итеп, аллаларның дуслары, дошманнары җәгъли[4] рәвештә тудырыла.

Шәрык диннәренең барысында диярлек мөстәбид хакимиятнең нигезен саклау юлында адәмдәге шәхси теләк, табигый омтылышларның хакимияткә каршы мәңге көрәшкән тимсаль мөҗәссәмнәрен күрәбез.

Менә, мәсәлән: хакимият кануннарына баш июче бөтен халыкларда Газраил Мәнфур, Мәкъһур, Мәлгунь көч дип санала. Аның болай саналуы табигый. Чөнки гомумнең шәхси теләкләре белән хакимиятнең теләкләре һичбер вакытта да җыела алуы мөмкин түгел. Ә инде аерым шәхеснең теләкләре — хакимиятнең теләкләре белән капма-каршы дошманнар. Аның өчен адәмнең табигый яратылышында аның шәхси тормышы, шәхси теләкләре — хәяттә асыл нигез һәм табигый канун. Шулай булгач, бу көндәге рәсми бөтен диннәрнең төбе хакимияткә, аның канун, низамнарына әсас ителгәнгә, кешенең аерым шәхси теләкләренә, омтылышларына ирек бирелми. Менә шул хакимият, канун, низамнарга буйсынмыйча, үзенең шәхси мәнфәгатьләре, теләкләре, омтылышлары өчен көрәшүчеләрнең тимсаль мөҗәссәме булган Газазил хакимият — дин исеменнән «оҗмахлардан» сөрелә, инсаниятнең[5] дошманы итеп күрсәтелә. Хакимият тарафыннан шәхси мәнфәгатьләре, теләкләре изелгәннәрне

---

[1] Гамил — хаким.
[2] Истибдад — чикләнмәгән власть.
[3] Мөстәбид — үзе теләгәнчә эш йөртүче, деспот.
[4] Җәгъли — ясалма.
[5] Инсаният — кешелек дөньясы.

яклап, шулар исеменнән һәм алар өчен хакимият рәсми дингә каршы көрәшүчеләрнең тимсаль мөҗәссәме булган «газазил» мәсьәләсе төрле дәверләрдән, бик күп гасырлардан бирле искерми торган мәңгелек мәсьәлә булып бу көнгә кадәр килде.

«Зар» фаҗигасендә бәни адәм хәятендә күренгән хосусиятләрне, мәсьәләләрне, бер кешенең халәт рухыясына, хосусиятләренә җыеп-мәркәзләштереп, кырыктан артык хосусиятләр, шуларның тимсаль мөҗәссәмнәре булган дин китапларындагы хыялый типлар аркылы бирергә тырыштым.

Төрле дәверләр, бик күп гасырлар буенча шәрык халыкларының йөрәгендә тирбәлеп үскән бу хыялый типларның, бәни адәм хәятендә торткан фәлсәфи әһәмиятләрен үзем аңлаганча, үзем генә изах итәргә уйлап, «Зар» фаҗигасен язарга батырчылык кылдым.

Бу мәңгелек мәсьәләне хәл итүне дәгъва итмәгәнлегем шикелле, иске чүпләрдән яңа бакча төзергә дә уйламыйм, һәрхәлдә, уйлап укып чыккан яки дикъкать белән сәхнәдән караган кешеләргә бу фаҗига шул мәңгелек мәсьәлә хакында уйларлык яки уйлата алырлык кечкенә генә бер тәэсир калдыра алса, теләгемә ирешкән булыр идем.

*Кәрим Тинчурин.*

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Оҗмах. Баскыч-баскыч булып күккә таба күтәрелгән, төрле төстәге мәрмәр таулар очсыз-кырыйсыз ераклыкта югалалар. Араларыннан сулар, кәүсәрләр агып тора. Кәүсәр буйларында гөлләр, хыялый матур агачларның түбәләре, һавада төрле болытларга кушылып югалалар. Төрле төстәге яктылык алмашынып торган саен, таулар, сулар, гөлләр, агачлар төсләрен алмаштыралар. Өстә, тау уртасында, нурлардан үрелгән чардуганга охшашлы михраб, ул михрабтан еракка, очсыз-кырыйсыз еракка, хөрмә агачлары белән бизәлгән юллар, сукмаклар сузылалар. Юлларның башлары, сулары өскә таба күтәрелеп агып торган чишмәләр белән бергә, икенче тагын да матуррак оҗмахка кушылалар. Чардуган гел үзгәреп тора: бер кызара, бер карала, бер ачылып үтәли күренә йә бөтенләй кара нурларга төренә. Сулда, асылташлардан оештырылган, биш манаралы михраб. Михрабның айлары зәңгәр нур белән капланган.

Һәр җирдә матурлык, һәр урында яктылык.
Ләкин күңелсез... җансыз һәм зәвыксыз...
Матурлыкта ямьсезлек сизелеп тора.

## I КҮРЕНЕШ

Газазил, Дәҗҗал, Шәйтан, Ирек, Мәхәббәт, Бәхет, Дәббәтеларз, Яэҗүҗ, Мәэҗүҗ, Бәдбәхет, Малик, ак фәрештәләр, кара фәрештәләр һәм башкалар.

Газазил.

Тәңре!
Җитмеш җиде мең ел тоташ сәҗдәдәмен,
Җитмеш җиде мең ел тоташ коллыктамын,
Табалмадым оҗмахыңда җан теләген;
Зәвыктырган зар тормыштан алҗыдым мин!
Тәңре!
Мәхәббәттән, туганлыктан мәхрүм итеп,
Ник яраттың ирексез итеп дәртсез оҗмах?!
Ләүхелмәхфүзләреӊ мәңге тоткын итеп,
Ник яраттың минем «мине» кара нурдан?!

Дәҗҗал.

Тәңре!
Ник яраттың тәмугларны санлы итеп?!
Ник яраттың ак нурларны, кәүсәрләрне?!
Ник яраттың оҗмахыңны якты итеп?!
Ник яраттың былбылларны, ак гөлләрне?!
Тәңре!
Сиңа мәңге кара коллык итәр өчен,
Ярат миңа көчле тәхет, ут, богаулар!
Ярат миңа кара таштан бөек дарлар!
Алар сине мәңге саклап торачаклар!
Тәңре!
Юлдаш итеп миңа кара бәдбәхетне,
Җитмеш җиде мең җиһанга баш ит мине;
Сөякләрдән корыр идем нык тәхтемне;
Саклар идем кануныңны һәм үзеңне!

Дәббәтеларз.

Тәңре!
Әлмисактан бирле тоташ, тын алмыйча,
Биек-биек таш-тауларны тигезләп, мин
Аптырадым, тигезлекне табалмыйча;
Хозурыңа үз хакымны эзләп килдем.
Тәңре!
Кайда соң ул вәгъдә иткән изгелегең?!
Кайда соң ул, көч кадерен тәкъдир иткән?
Кайда соң ул, кая качкан тигезлегең?
Нигә, Тәңре, яшерден син аны миннән?!
Тәңре!

Әлмисактан бирле тоташ, туктамыйча,
Ташлар ватып, җирләр казып эзлим аны;
Башым катты «тигезлек»не табалмыйча;
Синнән сорыйм, күрсәт аны, кая, каны?!

Шәйтан.

Оҗмахка каршы тәмуг тудырган,
Иреккә каршы богау кордырган,
Күкрәкләремә дәсисә[1] салып,
Ак нурдан мине тудырган Тәңре!..
Коткы, вәсвәсә, шомлы дәсисә
Сулышларымнан җил булып исә,
Көнләү, дошманлык, риялы дуслык —
Әгәр кирәксә, миндә бер кесә...
Җитмеш җиде мең галәм өстенә
Саласым килә утлы дәсисә...
Бәйрәм итәрмен тик шул чакта мин,
Кайгырмас идем, койрыгым өзсәң дә.

Бәдбәхет.

Тәңре!
Мин баскан эздән үләннәр үсмәс;
Күз текәгән җирдән кошлар оча алмас;
Кайнар сулышым — зәһәрле агу,
Табылмас аңа оҗмахта дару.
Тын хәрабәләр — ядкярем минем;
Гөрзи, тәмуглар — уртакдашларым.
Нурлардан качкан төнге ярканат,
Зур күз ябалак — ярларым минем.
Каннар сыгамын саф йөрәкләрдән,
Сарайлар салып ак сөякләрдән,
Ташка язгандай эз калдырырмын,
Тар күңелләрдә мәңге калырмын.

Бәхет.

Тәңре!
Баскан эземнән гөлләр, гонҗәләр
Үсеп торалар сулмыйча алар.
Карашларымда былбыллар сайрар,
Ал күбәләкләр уйнап очарлар.
Якты нур төсле йомшак карашым,
Күләгә булып үтәр һәр эшем.
Иркә гөл төсле мәңге яшь башым
Сихерләп торыр оҗмах кояшың.

[1] Дәсисә — хәйлә, алдау.

Баглар, кәүсәрләр — минем дусларым,
Кемнәрне кочар назлы кулларым?
Кемнәрне назлар иркә җырларым?
Юк, юк!..
Оҗмахта аны күрә алмамын.

Я э җ ү ж.

Тәңре!
Оҗмах күрке, кәүсәр суы сөендерми,
Ни файда бар, алар минеке булмагач!
Сөендерми нурга чумган гарше көрси[1],
Хуҗа булып аңарга мин утырмагач!
Зур оҗмахның, киң җиһанның байлыклары
Минем кулда уенчыктай уйнамагач!
Җитмеш җиде мең галәмнең алтыннары
Сөендерми алар — минеке булмагач!
Җитмеш җиде мең галәмнең бөтен барын:
Энҗеләрен, алтыннарын, җәүһәрләрен,
Киң җирләрен, диңгезләрен, урманнарын,
Тау-ташларын, көмеш, бакыр, тимерләрен —
Менә монда бер ноктага җыя алмагач;
Ни шатлык бар, аларга хуҗа мин булмагач!
Аһ, аһ... Ярсый күңелем аждаһадай!..
Чыгар, чыгар киң җиһанга, көчле Ходай!
Килер бер көн — тәхет көрси миңа табыныр,
Минем катгый әмеремнән чыга алмаслар.
Күккә ашкан ләгыль-якут сарайларым
Каршысында сүнеп калыр бу оҗмахлар!..

М ә х ә б б ә т.

Тәңре!
Сулыш алу кыен миңа оҗмахларда.
Тоткынлыктан коткаручы булмасмыни?
Ирекле җилдәй, ирекле илгә, йолдызларга,
Гөлләр тулы бакчаларга китәсе иде!
Саф кәүсәрдәй, якты нурдай ирекле булып
Чыгасы иде киң җиһанга тоткынлыктан,
Богаулардан, гөнаһлардан азат булып,
Качасы иде, качасы иде бу упкыннан!..

М ә э җ ү ж.

Тәңре!
Малга каршы җан сораган көчле утлар,
Ташкын булып, дулкынланып, мәңге агар.

---

[1] Гарше көрси — күк тәхете.

Газраилнең каты әҗәл сулышлары
Җәһәннәмдәй киң җиһанда мәңге янар.
Авыр гөрзи, көчле кистән, зәһәрле ук
Хөкем сөрер җитмеш җиде мең галәмдә.
Оҗмахларның тыныч көне артык тонык
Булып кала, киләчәкне уйлаганда.
Арттан, алдан, өстән, астан, уңнан, сулдан
Җан сораган аждаһалар шартлаганда,
Тетрәп торыр бөтен җиһан дәһшәтемнән.
Бөтен җиһан кайнар аның упкынында.
Меңәр-меңәр сафлар тоткан сугышчылар
Кара-каршы бәрелешеп сугышканда,
Сил-сил булып агар каннар, җаннар очар,
Очар җаннар Газраилнең кочагында!

И р е к.

Тәңре!
Китәм, китәм үз илемә, азатлыкка,
Яши алмыйм артык монда, көч калмады.
Мине мәҗбүр итеп монда буйсынырга
Ләүхелмәхфүз мине тәмам богаулады.
Зобанилар, тар кануннар арасында
Чикле төштә яши алмыйм мин чикләнеп,
Яши алмыйм, чикле оҗмах һавасында,
Яши алмыйм бу оҗмахларда бикләнеп.

Д ә җ җ а л.

Ходай!
Дар, богау, тәхет
Иркемдә булса;
Кара бәдбәхет
Кулымда булса,
Изәрмен шунда
Туган һәр җанны,
Уйнармын шунда
Тибеп каннарны!

Б ә х е т.

Ходай!
Нурлар шәгъләсе[1],
Гөлләр хуш исе,
Кәүсәр агышы,
Гашыйк сагышы,
Чагыштырганда,
Күләгә булып

---

[1] Ш ә г ъ л ә, ш ө г ъ л ә – балкыш.

Кала каршымда,
Барысы сулып!

Шәйтан.

Ходай!
Коткы, җасуслык[1]
Минем иманым.
Мал төсле сатлык
Кара вөҗданым.
Җиһанда золым
Өстен булгачтын,
Бәйрәм итәрмен
Биеп шул чакта.

Мәэҗүҗ.

Ходай!
Бакчалар, гөлләр
Утымда гөрләр.
Дәрья, диңгезләр
Көчемнән кибәр.
Кылыч, ук, гөрзи,
Зәһәрле төтен
Бөтен җиһанда
Йөртер хөкемен!..

Бәдбәхет.

Ходай!
Кыргый козгыннар —
Хәбәрчеләрем,
Тын хәрабәләр —
Сөенчеләрем.
Бәла-казалар —
Эшләгән эшем;
Хәсрәт-михнәтләр —
Салыр карашым.

Яэҗүҗ.

Алтын, җәүһәрләр —
Иманым минем,
Хуҗалык, байлык —
Теләгем минем.
Җитмеш җиде мең
Галәмнең көчен
Үз бәхетем өчен
Фида итәрмен.

---

[1] Җасуслык — шымчылык.

Д ә б б ә т е л а р з.

Ходай!
Әлмисактан ук
Казып нык җирне,
Шәфкатьсез юклык
Җәзалый мине.
Тын да алмыйча
Казып нык җирне,
Эзлим талмыйча
Чын тигезлекне!..

М ә х ә б б ә т.

Моңлы йөрәктә
Нур уйнаганда,
Куе тирәктә
Кошлар кунганда, —
Чәчәк бөресе,
Нурлар чаткысы,
Җиһанның күрке —
Ярларым минем.

И р е к.

Ходай!
Нурлар шәгъләсе
Очып торганда;
Рәхәт шәүләсе
Тонык торганда;
Ачылыр гөлем —
Кызыл якуттай,
Очар теләгем —
Һавада коштай.

Г а з а з и л.

Әй син!..
Җиһанда иркен
Ак көн күрергә
Янган пакь дәртем!
Янсын гомергә
Чын дуслык, ирек!
Һәм саф матурлык
Яшәгән чакта,
Яшәмәс коллык.

Соңгы монологларны һәммәсе бергә, бер үлчәү белән беравыздан сөйләп тәкрар итәләр. Шулвакыт Исрафил сигез морҗалы быргыдан кычкырта.

## II КҮРЕНЕШ

Җ ә б р а и л *(килеп, Газазилгә ихтирам күрсәтеп).*
Күрекле оҗмахны, якты нурларны,
Һава, туфракны, кәүсәр суларны
Юктан бар иткән, бөек Тәңремнең
Әмере белән хәбәр китердем!..
Б а р ы с ы.
Сәмган вә таган, сәмган вә таган![1]

Газазилдән башкалар сәҗдәгә китәләр.

Җ ә б р а и л.
Уттан, нурдан безне яраткан
Кодрәт иясе, кодрәте белән
Судан, балчыктан яратты бер җан!
Аңар башияр җитмеш җиде мең
Галәмдә булган керсез һәрбер җан!
Г а з а з и л.
Ләүхелмәхфүздә мин аны күрдем.

Исрафил быргы кычкырта.

Җ ә б р а и л.
Төпсез тәмуглар, уттан болытлар
Аның каршында тетрәп торырлар.
Асыл сөяге — аксыл мәрҗәннән,
Якты күзләре — кара нурлардан,
Атылып торган йолдызлар төсле,
Тизгер киң гаклын күрәчәк аның
Җитмеш җиде мең киң, серле җиһан.
Б а р ы с ы *(Газазилдән башка).*
Кем соң ул җан? Кем соң ул җан?
Җ ә б р а и л.
Ул — Адәм!..
Б а р ы с ы.
Адәм!..
Д ә җ җ а л.
Кемнәргә каршы яратты икән
Гаҗәп бу җанны гали ля мәкян!..[2]
Б а р ы с ы *(Газазилдән башка).*
Мәрхәба-я-я! Адәм! Мәрхәба-я-я! Адәм!..

---

[1] С ә м г а н в ә т а г а н — баш өсте, ләббәйкә.
[2] Л я м ә к я н — урыны билгесез нәрсә. Бу очракта Алла күздә тотыла.

Исрафил быргы кычкырта.

Җ ә б р а и л.
Җитмеш җиде мең серле галәмгә
Баш итеп аны яраткан Тәңре.
Судан, балчыктан туган Адәмгә
Сәҗдә кылыгыз!.. Бу аның әмере!..

Барысы сәҗдә кылмакчы булганда, Газазил туктата.

Г а з а з и л.
Буйсынмагыз!..
Җирдән яраткан түбән Адәмгә
Сәҗдә кылырга кем мәҗбүр итә?
Кем безне болай тарта түбәнгә?
Кем безне болай көчләп хур итә?!
Д ә җ җ а л.
Безне яраткан көчле Тәңребез!..
Б а р ы с ы *(ятып сәҗдә кылалар).*
Боерыгына без баш орамыз!..
Г а з а з и л.
Кара балчыктан, буталчык судан,
Тик бер сулыштан яралган җанга
Буйсынырмы соң нурдан яралган?
Лаекмы соң ул мондый зур данга?!
Җ ә б р а и л.
Киң ихтыяры шулай хак тапкан.
Г а з а з и л.
Ул шашкан.
Д ә җ җ а л.
Куй, саташкан!
Б а р ы с ы.
Йа Рахман, йа Рахман!

Исрафил быргы кычкырта.

Ш ә й т а н.
Кара болытлар көчәйгән саен,
Кара күкрәгем яктыра бара.
Г а з а з и л.
Нурдан яралган, бар гөнаһлардан
Пакь булган җаннар һич буйсынмыйлар.
Мәңге яклар изге хакларын,
Үз намусларын һич таптамаслар.
Җирдән, түбәннән яралган ул җан
Кимсенеп табыныр алтын-ташка да.

Тар-мар килсә дә бөтен бер җиһан,
Баш ормамын мин «мин»нән башкага!..
Нурдан яралган, рухи нурланган
Чын фәрештәләр түбән төшмәсләр,
Каһәрлек белән даннар чыгарган
Мөстәбидләргә кол һәм булмаслар!

Д ә җ җ а л.

Аның иксез-чиксез киң кодрәте
Җирне нурдан артык күрсә, кем карышыр?
«Көн фәякүн»[1] дигән көчле ихтыяры,
Ләүхелмәхфүзе сине генә буйсындырыр.

Г а з а з и л.

«Көн фәякүн» иясенә, ля мәкянга,
Ләүхелмәхфүз нигә кирәк булган аңа,
Утлы, мөһер, кодрәт каләм, көчле җәхим,
Зобанилар, нигә кирәк тагын аңар?
Юк!..
Курку дәһшәтләре чолгап аны,
Тәңре курка халык иткән колларыннан,
Куркуыннан кабызды ул тәмугларны,
Куркакларны качырмакчы утларыннан,
Нигә газап, нигә сәҗдә, нигә коллык?!
Нигә тагын кирәк булган бу оҗмахлар?!
Аһ, юк, юк!..
Нурның уттан курыкмаганын белә бит ул,
Әмма утны көчле сулар сүндерә ала.
Безнең нурдан яралганны күрә бит ул,
Шул вәсвәсә аңа шомлы курку сала.

Д ә җ җ а л.

Нурдан туган гали коллар адашсалар,
Зәмһәрирдә туңып торган урыннар бар.
Имам булып ахырында саташсалар,
Аларга да ләүхелмәхфүз урын табар.

Ш ә й т а н *(Дәҗҗалга).*

Безнең имам булырга син мөстәхыйксың.

И р е к.

Ләүхелмәхфүз көче белән чикләндереп,
Нигә тота оҗмахында тоткын итеп?!

Д ә җ җ а л.

Кемгә каршы баш күтәрдең, гөнаһкяр җан,
Кемнең утлы уйларына алдандың син?!

---

[1] К ө н  ф ә я к ү н – «Бул!» дию белән үк булдыру.

Ирек.

Мин үзем ут, утлы җилләр миннән исә,
Мин үзем нур, нурлы уйлар миннән оча!
Әмма Тәңре тоткын итеп нигә, нигә,
Минем нурлы юлларымны нигә кисә?!

Шәйтан *(Газазилгә).*

Дәҗҗал синең мөнбәреңә кулын суза,
Тәңре мондый җинаятькә булмас риза!..

Газазил.

Югал, сатлык, имансыз җан!..

Барысы.

Аман, аман, әл аман!..

## III КҮРЕНЕШ

Микаил *(Газазилгә).*

Тәңре сине дәргяһында көтеп тора.

Газазил.

Тәңре белән эшем беткән, кирәк булса,
Үзе килсен, үзе килсен, кирәксенсә!

Дәҗҗал.

Мордар!

Барысы.

Сөбханалла, сөбханалла!

Яэҗүҗ.

Тәңрегә каршы!

Мәэҗүҗ.

Көфран нигъмәт!

Шәйтан.

Ә-тә-тә-тә-тә-тә!..

Дәббәтеларз.

Бу нәрсә соң? Аңлый алмыйм!

Бәдбәхет.

Ха-ха-ха!

Ирек.

Алда хәят, алда хәят!..

Бәхет, Мәхәббәт *(Газазилгә).*

Коткар безне, коткар безне!..

Дәҗҗал *(Җәбраил, Микаилгә).*

Ә сез нигә тик торасыз? Әллә сез дә...

Микаил, Җәбраил, Исрафил.

Бу турыда безгә фәрман булганы юк!

Дәҗҗал *(Газазилгә).*

Зәмһәрирнең тын алгысыз суыгында
Мәңге шунда калган чагың мин күрермен.

Бозлы карлар катар синең сулуыңда.
Бозлы тимер нәләт камытын кидерермен!

Ирек.

Зәмһәрирнең каты салкын газабына
Дучар булсаң, сине эзләп мин барырмын.
Мин барырмын сиңа нурдан ал-гөл тотып.
Мин барырмын коткарырга, коткарырмын!

Мәхәббәт.

Синең белән бергә булсам зәмһәрирдә,
Минем өчен бу оҗмахтан артык булыр.

Шәйтан.

Анда сезгә рәхәт булыр, тыныч булыр. Хи-хи-хи!

Дәббәтеларз.

Мин җибәрмәм зәмһәриргә аны моннан!..
Әгәр инде Тәңре әмер сала калса,
Зәмһәрирнең упкынына аның җанын,
Зәмһәрирне оҗмах ясар бу кулларым.
Мин аңламыйм, мин аңламыйм, аңлый алмыйм,
Нигә газап күрсәтергә пакь җаннарга?!

Бәдбәхет.

Зәмһәрир, тәмуг,
Богаулы табут,
Зиндан-зәнҗирләр
Һәм зобанилар;
Утлы болытлар,
Гыйфрит, диюләр,
Авыр гөрзиләр,
Ялкын хөллә тун,
Зәһәрле төтен
Яшәгән чакта —
Мин һәм яшәрмен!
Ха-ха-ха-ха-ха!

Дәҗҗал, Яәҗүҗ, Мәәҗүҗ, Шәйтан сикерәләр, кыланалар.

Барысы.

Ха-ха-ха-ха-ха...

Бәдбәхет.

Куркак йөрәкләр,
Кара күкрәкләр
Миңа килсеннәр!
Мин коткарырмын!
Ха-ха-ха-ха-ха!

Барысы.

Ха-ха-ха-ха-ха!..

Г а з а з и л.

Кызганыч коллар!
Нурдан яралган җаннарыгызның
Утын сүндереп, күмерләндереп,
Аяныч коллар хәленә кереп
Калуыгыздан мин нәфрәтләнәм!..

Д ә б б ә т е л а р з.

Мин аптырадым, эзләп тапмадым,
Кайда соң, кайда качкан тигезлек?!

Г а з а з и л.

Ул монда юк!
Тәхет-көрсиләр аңарга дошман.
Оҗмахта аны юкка эзләмә.
Ул башка илдә, ул безне көтә,
Ул безне көтә, син миңа ышан!..

Д ә җ җ а л.

Ләүхелмәхфүздә кодрәт каләме
Ут белән язып тора барысын!

Г а з а з и л.

Җиһанга коллык, мәңге тоткынлык
Хәзерләп торган кодрәт каләме
Шул шомлы утта мәңгегә калсын!..

Д ә җ җ а л.

Ул — Тәңремезнең киң ихтыяры!

Г а з а з и л.

Ул аның шомлы золым коралы!

Ш ә й т а н *(Яәҗүҗ белән Мәәҗүҗне читкә алып китеп)*.

Тәңрегә каршы гыйсъян чыгарып,
Сезне тозакка төшермәк була.

Я ә җ ү ж, М ә э җ ү җ.

Безне?!

Б ә д б ә х е т

Ха-ха-ха!..

Дәҗҗал тыңлый.

Ш ә й т а н.

Әйе, сезне.
Ирек, мәхәббәт аңа табынган.

Д ә җ җ а л.

Нәрсә, ни булган?..

Ш ә й т а н.

Оҗмахта безгә шатлыклы көннәр
Югалып бара, ә сез сизмисез.

Тәңрегә каршы гыйсъян чыгарып,
Гарше көрсигә үрмәләгәннең
Кыланышыннан әллә күрмимсез?!

Д ә җ җ а л.

Сабыр!..

Я э җ ү җ, М ә э җ ү җ.

Ә соң ләүхелмәхфүз?

Б ә д б ә х е т.

Ха-ха-ха!..

Ш ә й т а н.

Ләүхелмәхфүздә кодрәт каләме
Яшерен фәрманнар утлардан сыза,
Дүзәх[1] утлары, зобанилары
Җитмеш җиде мең кат көчәйтелгәннәр,
Ләкин ул көчләр аны җиңә алмас.
Ирек, мәхәббәт өчәүләр бергә
Сезне тәмугка утын итәрләр.
Гарше көрсидә үзләре калып,
Бөтен җиһанга хөкем итәрләр.

Я э җ ү җ.

Безне тәмугка?!

М ә э җ ү җ.

Кайнаган утка?!

Ш ә й т а н.

Мәңгегә утка.

Я э җ ү җ, М ә э җ ү җ.

Мәңгегә утка?!

Д ә җ җ а л.

Сабыр!

Б ә д б ә х е т.

Ха-ха-ха!..

Д ә җ җ а л.

Чү, тукта!..
Ләүхелмәхфүз бар чагында,
Ирек тормас оҗмахында.
Зобанилар яшәгәндә,
Мәхәббәткә урын табылыр
Дүзәхнең киң кочагында!..
Инде кала ул ялгызы —
Безнең якта Тәңре үзе.
Тәмуглар, ләүхелмәхфүз,
Каты куллы гарше көрси,

---

[1] Д ү з ә х — тәмуг, җәһәннәм.

Нык мөнҗәникъ[1], утлы гөрзи —
Барысы да безнең якта.

Ш ә й т а н.

Имамлыкны алып аннан,
Сине имам итү кирәк.
Сөреп аны киң оҗмахтан,
Җәһәннәмгә тыгу кирәк.

Д ә җ җ а л.

Шулай кирәк! Шулай кирәк!

Я э җ ү җ.

Җәһәннәмгә ул мордарны!

М ә э җ ү җ.

Тирәнгәрәк, тирәнрәк!

Б ә д б ә х е т.

Ха-ха-ха!..

Д ә җ җ а л.

Ләүхелмәхфүз, тәхет-көрси,
Богау, тәмуг, утлы гөрзи,
Мин булганда, хөкем сөрер.

Ш ә й т а н.

Тс-с-с!.. Юкса сизенер.

Д ә җ җ а л, Я э җ ү җ, М ә э җ ү җ.

Май кап!..

Б ә д б ә х е т.

Ха-ха-ха!..

Г а з а з и л.

Кара туфрактан яратып Адәм,
Кодрәт күрсәтеп масайган Тәңре.
Яңа мәгъбүдләр[2] ясап яңадан,
Көчәйтмәк була зәгыйфь тәкъдирен.
Судан, балчыктан туган Адәмгә
Сәҗдә кылдырып безне кимсетеп,
Нифак[3] салырга уйлый оҗмахта.
Мөстәбид Тәңре, мөстәбид тәхтен
Сакламак өчен, соңгы чарага
Керешеп тагын халык кылып, Адәм,
Сәҗдә кылырга шул бичарага
Мәҗбүр итмәкче, утлар күрсәтеп.
Ләкин ялгыша, Тәңре ялгыша!..

---

[1] М ө н җ ә н и к ъ — сугыш коралы, ныгытмаларны ваттыру өчен таш аткыч.

[2] М ә г ъ б ү д — Алла, пот, санәм.

[3] Н и ф а к — алдакчылык, икейөзлелек.

Һ ә м м ә с е.
Машалла! Машалла!
Ш ә й т а н.
Ул шаша.
Я э җ ү җ, М ә э җ ү җ.
Саташа!
Д ә җ җ а л.
Чиктән аша!..
Г а з а з и л.
Тәңре ялгыша!..
Б ә д б ә х е т.
Ха-ха-ха!..
Д ә җ җ а л.
Тукта!..
Г а з а з и л.
Миңамы бу?!
Кара йөрәктән чыккан бу әмер!
Миңамы бу?!
Миңа, саф нурдан яралган җанга!
Миңа?!
*(Пауза.)*
Нигә тындыгыз? Нигә куркыштыгыз?
Тынычланыгыз! Тыныч булыгыз!
Тәмугларым юк, мин Тәңре түгел!
Мин Тәңре түгел, мин Тәңре түгел!
Моннан болай һәм сезгә баш түгел!
Моннан болай мин һәм имам түгел!
Хәбәр итегез хәзер үзенә!
Язып куйсын ул кара утлардан
Ләүхелмәхфүзенә!
Ваз кичтем, китәм, дәргяһын ташлап.
Мин хәзер имам бер тик үземә,
Үз әмәлемә, якты фикеремә.
Моннан болай юк миңа Тәңре!
Юк аның миңа мөстәбид әмере!
Нурланган фикерем, утлы йөрәгем,
Минем үз «мин»ем минем чын Тәңрем.
Ишеткәнегез гуаһ булыгыз!
Бу булыр минем катгый теләгем!
Моннан болай юк, юк миңа Тәңре!
Нурланган фикерем, утлы йөрәгем,
Минем үз «мин»ем минем чын Тәңрем!..
Ирек, мәхәббәт, чын, саф матурлык —
Минем иманым, нык, чын иманым!

Мәңгегә дошман миңа тәңрелек.
Шул гади уйдан мәңге кайтмамын!..

Күк күкри. Исрафил быргы кычкырта. Буталу, тавыш.

Җәбраил.
Адәм!..

Нурлар эчендә Адәм күренә. Исрафил быргы кычкырта.

Җәбраил.
Аңар сәҗдә фарыз!..
Һәммәсе.
Мәрхәба-я-я, Адәм!.. Мәрхәба-я-я, Адәм!..

Сәҗдә кылалар.

Газазил *(ялгыз басып калып).*
Надан!..
Бәдбәхет.
Ха-ха-ха!..

Күк күкри. Быргылар кычкырталар. Шау-шу, нурлар уйный вә башкалар.

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәгечә.

### I КҮРЕНЕШ

Газазил, Мәхәббәт һәм Бәхет.

Газазил.
Каты ак мәрмәр буйсынды миңа;
Буйсынды миңа энҗе һәм җәүһәр;
Буйсынды миңа һәм кара төтен,
Тик буйсынмады иркә, серле өн.
Буйсынды миңа гөлләр, лаләләр,
Буйсынды миңа нурлы шәгъләләр.
Буйсынды миңа дәһшәтле моң төн,
Тик буйсынмады иркә, серле өн.
Ак мәрмәрләрдән сылу тәннәрең,
Сылу тәннәрең, ак беләкләрең.

Кара төтеннән синең чәчләрең,
Сызылып торган кыйгач кашларың,
Ак мәрмәрдән киң күкрәкләрең,
Алсу якуттан ал иякләрең.
Күзләрең синең кара җәүһәрдән,
Нурларын ала якты кәүсәрдән,
Саф ак мәрмәрдән ак муеннарың,
Зифа камыштай зифа буйларың!
Ак керфекләрең лалә үзәге,
Моң күзләреңнең күрекле бизәге.
Язгы таң кебек алланып торган
Бит алмаларың күзекмәс диеп,
Былбыл күзедәй бер миң утыртам,
Шатлык чокыры шат күренсен дип.
Каты ак мәрмәр буйсынды миңа,
Буйсынды миңа энҗе һәм җәүһәр,
Буйсынды миңа һәм кара төтен,
Тик буйсынмады иркә, серле өн.
Акылым эшләтеп азрак уйласам,
Исрафилсыз да өрә алырмын җан.
Бу матур сынга хәят бирә алсам,
Сөенер иде күреп бар җиһан!

## II КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр, Яэҗүҗ, Мәэҗүҗ, Шәйтан, Бәдбәхет.

Шәйтан.
Кара, кара! Адәм төслүк, ике аяклы!
Яэҗүҗ.
Куллары да ике ич моның. Борыны да бар.
Мәэҗүҗ.
Адәм төслүк, ике куллы, биш бармаклы.
Шәйтан.
Бары булган. Булмаганның урыны да бар.
Бәдбәхет.
Ха-ха-ха!..
Һәммәсе.
Хи-хи-хи!..
Яэҗүҗ.
Башларына дулкын-дулкын төтен аскан.
Мәэҗүҗ.
Тере төслүк, аягына нинди баскан.

Ш ә й т а н.
Туң боз төсле, тумас борын катып калган.
Б ә д б ә х е т.
Ха-ха-ха!..
Һ ә м м ә с е.
Хи-хи-хи!..
Г а з а з и л.
Ялган!
Ул туачак. Хәят сурын мин өрермен
Ул туачак бөтен җиһан шатлыгына!
Минем иҗат, мин үк аны терелтермен.
Күтәрермен бөек гарше әгъласына.
Ш ә й т а н.
Нигә соң ул таш курчагың катып тора?
Нигә аның күзләрендә утлар янмый?
Я э җ ү җ.
Исеме ничек аның, барып сора.
М ә э җ ү җ.
Исемең ничек, Биби-бүкән, әллә ташмы?
Б ә д б ә х е т.
Ха-ха-ха!..
Һ ә м м ә с е.
Хи-хи-хи!..
Ш ә й т а н.
Чү, туктагыз! Әнә аңар җан кертә!
Я э җ ү җ.
Безне генә тапамаса ярар иде.
Һ ә м м ә с е.
Ха-ха-ха!..
М ә э җ ү җ.
Ай, булмады! Була язып булмый калды!..
Ш ә й т а н.
Хәят сурын борнысына күбрәк өрде.
Һ ә м м ә с е.
Ха-ха-ха!..
Ш ә й т а н.
Әнә, әнә! Яңа тылсым, яңа тылсым.
Бу юлы инде тәгаен ул йөреп китәр.
Я э җ ү җ.
Болай булгач йөрүләрең читтә торсын.
М ә э җ ү җ.
Колагыннан бора калса биеп китәр.
Һ ә м м ә с е.
Ха-ха-ха!..

Ш ә й т а н.

Кара, кара! Җан керә бит, чишмә чыкты.

Я э җ ү ж.

Кай җиреннән?

Ш ә й т а н.

Борыныннан.

М ә э җ ү ж.

. . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . .

Һ ә м м ә с е.

Ха-ха-ха!..

И р е к.

Миһербанлы!
Бир аңа син чын, саф хәят, терелт аны!
Аның дусты булыр идем, аһ, аңласаң!
Ирекле җилдәй ирекле итәр идем аны!

Ш ә й т а н.

Җансыз ташны!

Я э җ ү ж.

Таш курчакны!

М ә э җ ү ж.

Уенчыкны!

Һ ә м м ә с е.

Ха-ха-ха!..

М ә х ә б б ә т.

Шул гөлкәем иркә назлы күкрәгендә,
Ак нур кебек, мәңге янып торсын иде.
Нурга чумып йомшак саба җилләрендә
Күбәләктәй гөлләр сайлап йөрсен иде.

Ш ә й т а н.

Иде, иде, тагын — иде.

Я э җ ү ж.

Янә — иде.

М ә э җ ү ж.

Вә һәм — иде.

Ш ә й т а н.

Чү, туктагыз, башын иде.

Һ ә м м ә с е.

Ха-ха-ха!..

Сикерешеп шаулыйлар, көләләр.

## III КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Дәҗҗал.

Дәҗҗал.

Ни бар монда?

Шәйтан.

Тәңре Адәмне туфрак-балчыктан
Халык кылгачтын, аңарга каршы
Менә бу шашкан шушы ак таштан
Җансыз таш курчак уйлап чыгарган.
Нәфасәт, пакьлек, чын, саф матурлык
Тәңресе итеп, Тәңрегә каршы
Шул курчак белән гыйсъян чыгарып
Маташкан була, гакылдан язган.

Яәҗүҗ.

Бар җиһанның шатлыгы, ди. Син дә шатлан!

Һәммәсе.

Ха-ха-ха!..

Мәәҗүҗ.

Барсы булган. Җаны гына тик юк икән.

Һәммәсе.

Ха-ха-ха!..

Газазил.

Җаны да булыр. Җан сорап аңа,
Каһәр Тәңрегә ярдәмгә бармам!

Дәҗҗал.

Көфер, көфер сөйлисең син, гөнаһкяр җан.
Ләүхелмәхфүз, кодрәт каләм бар чагында,
Санәм ташка асла иңмәс хәят — җан.
Нинди йөрәк батырланган оҗмахында?!
Хакка шәрик булырга син уйладыңмы?!

Газазил.

Ул миңа кимлек булыр иде.

Дәҗҗал.

Кермәс пакь җан, санәм ташка хәят бирмәс.
Хәят бирү тик Тәңренең иркендә ул.
Гарше көрси, ләүхелмәхфүз ирек бирмәс.
Ват санәмен, гөнаһкяр җан! Тиз тәүбә кыл!

Газазил.

Тәңре туфрактан яратты Адәм.
Мин мәрмәр таштан яраттым санәм.
Туфрактан булган күрексез Адәмгә
Бөтен бар оҗмах китте сәҗдәгә.

Җан өрсәм шушы ак таш санәмгә,
Чын илаһ булыр бөтен галәмгә.
Аның кануны, зобанилары,
Утлы дүзәхе, сират мизаны –
Берсе дә булмас! Чөнки ул Гали!..
Тәңрегә Тәңре булыр пакь заты!..

Һәммәсе.

Ха-ха-ха! Шул санәм?!

Газазил.

Әйе, шул санәм.
Озак та үтмәс, килер бер заман,
Тәңреләр бетәр. Ул калыр мәңге.
Аның зур даны күкләргә ашар.
Җитмеш җиде мең галәм алкышлар!
Җитмеш җиде мең галәм җенесен
Ул берләштерер, ул дуслаштырыр!
Аңардан өстен булалмас һич зат,
Чөнки чын илаһ фәкать нәфасәт!..
Ирек, Мәхәббәт – дусларым минем.
Яңа дустымыз – менә нәфасәт!..
Үзем дә аңа сәҗдә кылырмын.
Үзем бирермен аңарга хәят!..

Ирек, Мәхәббәт, Бәхет.

Хәят, хәят, хәят!..

Һәммәсе.

Ха-ха-ха!..

Дәҗҗал.

Ул шашкан.

Шәйтан.

Адашкан.

Яэҗүҗ.

Юлдан язган.

Һәммәсе.

Йа Рахман, йа Рахман!..

Газазил.

Ялган!..
Фикердәшләрем, саф, чын дусларым,
Бирегез сазымны, килде хак илһам!..

Санәмгә карап уйный башлый. Мәхәббәт, Бәхет, Ирек гөлләр-нурлар белән санәмне бизиләр. Булышалар. Түземсезлек белән нәрсәдер көтәләр. Бераздан соң санәм йөреп китә.

Газазил, Мәхәббәт, Ирек, Бәхет.

Хәят! Хәят! Хәят!..

Д ә җ җ а л  г р у һ ы  һ ә м м ә с е.
Ләхәүлә вәләкуәтә иллалла... Эһем, эһем, эһем!..
Ш ә й т а н.
Бу ни булды бу?!
Д ә җ җ а л.
Бу, бу, бу... эһем...
Я э җ ү җ.
Күрдеңме?
М ә э җ ү җ.
Ә син?!
Я э җ ү җ.
Гаҗәеп бу!
М ә э җ ү җ.
Гараиб[1] бу!
Ш ә й т а н.
Ләүхелмәхфүз ни эшли икән?
Д ә җ җ а л.
Тәңре үзе сиздә микән?
Ш ә й т а н.
Тс-с-с!..
Һ ә м м ә с е *(куркынып чыгып киткәндә)*.
Тәңрегә тиззз!..
Г а з а з и л  г р у һ ы  һ ә м м ә с е.
Мәрхәбә, хуш килдең. Мәрхәбә, хуш килдең!
М ә х ә б б ә т.
Син безгә хәят китердең, иркә,
Илаһ булырсың дәртле йөрәккә!
И р е к.
Матурлыгыңнан күңелем курка.
Мине куарлар синең яныңнан.
Кабынсаң әгәр моның утына,
Минем барлыгым чыгар күңелдән.
С а н ә м.
Мин кем?
Г а з а з и л.
Син матурлык, син нәфасәт, син Һава!
Һ а в а.
Мин кайда?
Г а з а з и л.
Оҗмахта.
Һ а в а.
Бу кем?

[1] Г а р а и б, г а р и б ә — күрелмәгән, ишетелмәгән хәл.

Г а з а з и л.

Ирек.

Һ а в а.

Бу кем?

Г а з а з и л *(кызыл гөл бирә)*.

Мәхәббәт.
Җиһанны сиңа, сине җиһанга
*(Мәхәббәт ак гөл бирә)*
Яраттыручы, табындыручы.

Һ а в а.

Бу?

Г а з а з и л.

Бәхет.
Иркәли алсаң, ул мәңге сиңа
Итагать итәр, иркәләмәсәң,
Ул синнән китәр, ул синнән бизәр.
*(Бәхет төссез чуар гөл бирә.)*

Һ а в а.

Син кем?

Г а з а з и л.

Мәхәббәт, ирек, чын матурлыкка
Мәңге-мәңгегә хезмәт итәргә
Ант иткән бәндә...
Тәңресен ташлап, сине тудырган,
Йөрәге белән тик сезне сөйгән,
Ерак-еракка алга омтылган,
Сезнең хезмәткә җирдән һәм күктән
Урын алырга антлы сүз биргән,
Ул җан менә мин!..

И р е к.

Ирекле җил төсле ирекле итәрмен,
Тәмуг-богаудан азат итәрмен.
Мине яр дисәң, һич үкенмәссең,
Коллык газабын асла күрмәссең!..

М ә х ә б б ә т.

Шәгъләдән тизгер, ак күңлең очар,
Лалә-чәчәкләр тик сине кочар.
Дәртле йөрәгең нурланган чакта
Ашарсың өскә минем кочакта.

Б ә х е т.

Иркәләп сине шатландырырмын.
Шатландырырмын шат чакларыңда.
Зәмин булмаса, гөлдәй корырмын,
Син дә сулырсың шул чакларыңда.

Газазил.
Җиһанда мәңге тик ул калачак.
Бетсә дә җир, күк, оҗмах, киң җиһан,
Шул чакларда да ул яшәячәк.

## IV КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр, Исрафил, Җәбраил, Дәҗҗал, Яэҗүҗ, Мәэҗүҗ һәм башка фәрештәләр.

Исрафил быргы кычкырта.

Җәбраил.
Хәзрәте Адәм тәшриф[1] боера!
Барысы.
Мәрхәбә! Мәрхәбә! Мәрхәбә!

Адәм керә.

Адәм *(күңелсез, аска карап, берәүне дә күрмичә алга үтә)*.
Күңелсез оҗмах, синдә ямь тапмыйм, синдә тәм тапмыйм.
Күңел ашкына, йөрәк сукрана, күкрәк тарсына.
Күңел юксына, тәмле оҗмахта рәхәт таба алмыйм.
Ярдәм таба алмыйм, кайгым баса алмыйм, нәфес ашкына.
Мин монда үксез, юлдашсыз, дуссыз, кыргыйдай ялгыз,
Эч серләремне, күкрәк дәртемне ачып сөйләрлек
Беркем дә юк, күңелем боек, йөрәгем ярсыз.
Йөрәгем ярсыз, күзләрем нурсыз, гел бертөрлелек
Каплады җанны, каралтты канны бу дәртсез оҗмах.
Иртә-кич сәҗдә, өзлексез тәүбә, булдым чын тоткын.
Оҗмах бизәге күңелне борчый, җан шат булмагач.
Йа Ходай! Әйт син, ни өчен мине, мине яраттың?!
Дәҗҗал.
Сәҗдә кылырга!
Ләүхелмәхфүздә ачык язылган синең язмышың,
Туган көннән языла бара гамәл дәфтәрең.

---

[1] Тәшриф – килү.

Олуг Тәңремез кодрәте белән киләчәгеңнең
Барысын алдан хәл кылып куйган
ләүхелмәхфүздә.

Адәм.

Барысын алдан хәл кылып куйгач киләчәгемнең,
Нигә берьюлы ачып бирми соң күрәчәгемне?
Нинди кызыгы аңар бар икән күз яшьләремнең,
Нигә богаулап асрый соң ул теләкләремне?!

Дәҗҗал.

Анысы синнән мәңге яшерен калачак сер.

Адәм.

Беләсем килә киләчәгемне, аңлыйсым килә.
Әгәр дә Тәңре чынлап көчле һәм гадел икән,
Нигә серләргә, тар пәрдәләргә качып яшеренә?

Җәбраил.

Йә Адәм, Тәңреңне исеңдә тот һәрдәм!

Дәҗҗал.

Тәүбә сәҗдәсе, тәүбә сәҗдәсе, тиз тәүбә, тәүбә!

Адәм *(сәҗдә кыла)*.

Ярлыка, Тәңрем, гөнаһкяр җанны, ярлыка мине!
*(Торып ташка утыра.)*
Ялгыз, мәңге ялгыз!..
Киләчәкләрем яшерен, билгесез, караңгы, нурсыз.
Ләүхелмәхфүзгә язылып куйган кара язмышым,
Нәрсә икәне мәңгегә яшерен, серле, билгесез.
Гомергә шулай коелыр микән ачы күз яшем?

Шәйтан.

Мин синең якын, якын иптәшең,
Нәрсә телисең, барын үтәрмен.
Яшәгән чакта менә шул башым,
Мин сине монда кимсеттермәмен.
Серне ачмаска әгәр сүз бирсәң,
Ләүхелмәхфүздән киләчәгеңне
Күрсәтә алам, әгәр теләсәң...
Яшер куйныңа шушы чәчәкне.

Адәм.

Беләсем килә, беләсем килә киләчәгемне.
Шатлык-рәхәтме, әллә хәсрәтле каты газапмы?

Шәйтан.

Хәзер, хәзер үк әнә ул тауга тиз бар, соңайма!
Качып, яшеренеп көтеп тор шунда минем
кайтканны.
Ләүхелмәхфүздән чын тәкъдиреңне урлап
килермен.

*(Дəҗҗал катына барып яшерен сөйлəнə, карана.)*

Адəм.

Урлап килермен, ни дигəн эш бу?!
Беренче тапкыр ишетəм бу сүзне.

Яэҗүҗ.

Сəлам Тəңренең сөйгəн колына.
Шушы йөзекне алсаң кулыңа,
Гөллəр үсəрлəр баскан юлыңда!
*(Йөзек биреп, Дəҗҗал катына килə.)*
Һичбер нəрсəдəн хəбəре юк бичараның.
Бер күрүдə тозагыма чалкан төште!

Шəйтан.

Гомере озак булмас монда бу хайванның,
Урлашырга хəзердəн үк күнде инде.

Мəэҗүҗ.

Сəлам Тəңренең сөйгəн дустына!
Шушы коралны алсаң кулыңа,
Дошманың килмəс синең өстеңə.
Яки яшерен төшсə юлыңа,
Харап итəрсең барысын, аңла:
Тик минем сүздəн һичвакыт чыкма!
*(Корал бирə.)*

Дəҗҗал.

Адəм!
Үз дəрəҗəңне белеп йөр монда, монда син хуҗа!
Ал шул «мөһер»не — тəхетеңне саклар гомер буенча!..
*(Шəйтанга.)*
Барып Тəңрегə барысын ирештер!

Яэҗүҗ.

Тəңре ник кенə яратты икəн,
Киң оҗмахында шушы ахмакны?

Мəэҗүҗ.

Бу Адəм дигəн юк нəрсə икəн,
Гакыл, фикере бигрəк сай икəн.

Дəҗҗал.

Ак көн күрсəтмəү безнең муенда.
Белдегезме соң, нəрсə уенда?..

Яэҗүҗ.

Нəрсəдер көтə, һаман эзлəнə.

Мəэҗүҗ.

Һəр якты йөзгə дəррəү тезлəнə.

Дəҗҗал.

Əй син, Бəдбəхет, нигə Адəмне тəбрик итмисең?

Б ә д б ә х е т *(Адәм янына килеп).*
Ха-ха-ха!..

Һәммәсе Адәм янына киләләр.

Д ә җ җ а л.
Кәефең хуш булсын, Тәңренең яры!
Ал шул шәрабны көчле кулыңа!
Ләүхелмәхфүзнең киң ихтыяры
Тәхет һәм таҗлар куйды юлыңа!..
Гөрзи, богаулар, зиндан һәм дарлар –
Синең дусларың, сине сакларлар.
М ә э җ ү җ.
Бу корал сиңа алдан юл ачар,
Дошманнарыңның каннарын чәчәр!
А д ә м.
Нәрсә, дошманнар? Кемнәр соң алар?
Д ә җ җ а л.
Ирек, мәхәббәт, нәфис матурлык –
Сиңа дошманнар, аларга ат ук!
А д ә м *(җанланып).*
Ирек, мәхәббәт, нәфис матурлык!
Кайда соң алар? Булырмы табып?
Д ә җ җ а л.
Ләүхелмәхфүздә утлы хәрефләр
Әлмисактан ук алар хакында.
Дәһшәтле сүзләр язып торалар.
Галәм дәфтәрең һәр сулыш саен
Беркетә бара яман уйларың.
Ирек, мәхәббәт, нәфис матурлык
Турында уйлау сиңа ул хәрәм.
Тәхеткә сәҗдә, Тәңрегә коллык –
Муеныңда фарыз, онытма, Адәм!
Җ ә б р а и л.
Йә Адәм! Тәңреңне исеңдә тот һәрдәм!..
А д ә м.
Ярлыка, Тәңрем! Ярлыка мине!..
*(Сәҗдә кыла.)*
Кем ул? Кем ул?!
*(Һаваны күреп, шашынып.)*
Я э җ ү җ.
Матурлык.
М ә э җ ү җ.
Санәм.

Адәм һавага таба бара башлый. Гөнаһ, Шәйтан, зобанилар акырышып керәләр.

## V КҮРЕНЕШ

Гөнаһ.

Ул сиңа хәрәм, хәрәм, хәрәм!..
Тәңренең утлы болытларында,
Ыжгырып торган тәмугларында
Гөнаһкяр җаннар мәңге янарлар.
Мәңге янарлар ут упкынында!..

Зобанилар.

Мәңге янарлар ут упкынында!..

Гөнаһ.

Читкә карама, читтә оят бар.
Өскә карама, өстә гөнаһ бар.
Уңга карама, уңда — дәртле уй.
Сулга карама, сулда — зифа буй.

Зобанилар.

Сулга карама, сулда — зифа буй!

Гөнаһ.

Башыңны бөгеп син аска кара,
Аска кара да берни уйлама.
Тәңренең исемен беркет күңелдә.
Бар көчеңне куй тәсбих зикергә!

Зобанилар.

Бар көчеңне куй тәсбих зикергә!..

Гөнаһ.

Соңгы матурлык дәхи моңлы саз,
Ирек, мәхәббәт һәм әрсез бәхет
Тәңрегә дошман, сиңа да дошман,
Сиңа ят алар, бул син бәдбәхет!..

Һәммәсе.

Сиңа ят алар, бул син бәдбәхет!..

Адәм.

Кем ул, кем ул?!

Дәҗҗал.

Санәм.

Адәм бара башлый.

Гөнаһ.

Ул сиңа хәрәм!

Һәммәсе.

Ул сиңа хәрәм!

Г а з а з и л  г р у һ ы.
Хата, хата!
А д ә м.
Ул серле җанга мин каршы барам!..
Һ ә м м ә с е.
Ул сиңа хәрәм!
А д ә м.
Хәрәм?!
Ни дигән сүз ул? Кайдан ул килгән?
Г ө н а һ.
Ләүхелмәхфүздә уттан язылган.
Сине саклаучы вөҗданы калкан.
Г а з а з и л  г р у һ ы.
Ялган, ялган!
Д ә җ җ а л  г р у һ ы.
Йа Рахман! Йа Рахман!
Җ ә б р а и л.
Адәм, Тәңреңне исеңдә тот һәрдәм!
А д ә м.
Ярлыка, матур! Ярлыка мине!

Һавага сәҗдә кыла. Күк күкри.

Һ ә м м ә с е.
Хәрәм, хәрәм!..
Д ә җ җ а л.
Көфер, көфер!..
Г ө н а һ.
Беттең, беттең син, и гөнаһкяр җан!..
*(Әләме белән Адәмгә суга.)*
Д ә җ җ а л.
Тәүбә кыл! Хәзер юнәл гарешкә!
Г ө н а һ.
Оҗмахта урын юк ул мәшрикъка!
Җ ә б р а и л.
Йә Адәм! Тәңреңне исеңдә тот һәрдәм!
А д ә м *(тезләнә)*.
Юлыктыр, Тәңре! Юлыктыр мине
Шушы гүзәлгә. Шушы пакь җанга!
Г ө н а һ.
Ул сиңа хәрәм!
Д ә җ җ а л.
Ул – тик таш курчак.
Г ө н а һ.
Гөнаһкяр, мордар, түбән уенчак!

А д ә м.
Әйт, гүзәл, әйт, кем соң үзең? Кайдан иңдең?
Кайда тудың, кайда үстең, ничек исемең?
Һ а в а.
Исемем Һава, карашымнан нурлар ява.
Д ә җ җ а л.
Кая, кая, зобанилар, зобанилар!
Тәмугларның ишекләре хәзер, хәзер ачылсыннар!
Г ө н а һ.
Оҗмахларда гөнаһ ага!..
Һ ә м м ә с е.
Гөнаһ ага, гөнаһ ага!..
*(Чыгып китәләр.)*
Г а з а з и л г р у һ ы.
Ха-ха-ха!..
Г а з а з и л.
Кара йөрәкләр нурдан качтылар.
Тәмугларына юллар ачтылар.
Юк, юк ул тәмуг безнең пакь җанга,
Шатлыклы хәят балкыйдыр анда.
Б а р ы с ы.
Шатлыклы хәят балкыйдыр анда.
М ә х ә б б ә т.
Сезгә гомерлек минем бүләгем.
И р е к *(нурдан гөл бирә)*.
Ирекле тормыш катгый теләгем!
Б ә х е т.
Бөтен барлыгым сезгә багышлыйм.
А д ә м.
Күрекле гүзәл, ямьле Һава, кил, кил миңа!
Чолгап алды күкрәгемне көчле ялкын!
*(Кавышалар, кочаклашалар.)*
Һ а в а.
Чолгап алды йөрәгемне серле ялкын!
Г а з а з и л.
Тәңре җиңелде! Тәңре җиңелде!
Һ ә м м ә с е.
Тәңре җиңелде! Тәңре җиңелде!
*(Шатланышып сикерәләр, бииләр.)*
А д ә м.
Энҗе бөртекле, нурлы ак гөлгә
Күбәләк булып юлыксам иде!
Шул гөл алдында гомергә бергә
Онытылып шулай торалса идем.

Һава.

Йөрәкнең назы, гөл үзәкләрен
Гомергә шулай сөя алсам иде.
Күкрәккә тулган саф теләкләрем
Күзеңә карап әйтә алсам иде.

Адәм.

Кәүсәрнең нуры шәгъләә сипкәндә,
Күзеңдә өмет күрә алсам иде.
Күбәләк төсле назлы очканда,
Канатларыңны коча алсам иде...

Һава.

Гөлнең хуш исе качынган төсле,
Качынып сиңа бара алсам иде.
Суда уйнаган якты нур төсле,
Йөрәкләреңә үтә алсам иде.

Адәм.

Йомшак җил төсле, тавышсыз-тынсыз,
Дулкын чәчеңне үбә алсам иде.
Нурлы шәгъләләр, ал лаләләрне
Сөя алган төсле сөя алсам иде.

Һава.

Былбыл авазы чут-чут иткәндәй
Сызгырганыңны ишетсәм иде.
Керфек уйнатып, дәртле ләхендәй[1]
Ашкынганыңны күрә алсам иде.

Адәм.

Мохит диңгезе дулкыны төсле,
Көчле күкрәгең коча алсам иде.
Дүзәхнең тирән упкыны төсле,
Мәхәббәтеңдә яна алсам иде.
*(Кочаклапышалар.)*

## VI КҮРЕНЕШ

Дәҗҗал бөтен груһы белән килеп керә. Исрафил быргы кычкырта.

Дәҗҗал.

Әгәр Һавадан ваз кичмәсәң, син
Җәһәннәмендә мәңге янарсың!..

Җәбраил.

Оҗмах, тәмугны юктан яраткан,
Сине яраткан олуг Тәңре

[1] Ләхен – җыр, көй.

Мәңгегә сөрде сезне оҗмахтан.
Бу — аның соңгы катгый әмере!
Дәҗҗал груһы барысы.
Мәңгегә сөрде сезне оҗмахтан.
Бу — аның соңгы катгый әмере!..
Җәбраил.
Синең, Газазил, ләүхелмәхфүздә
«Мәлгунь» ләкабең[1] уттан язылды.
Газазил.
Без китәбез ташлап аның ләүхелмәхфүзен һәм үзен;
Без китәбез ташлап аның ләхед төсле оҗмахларын;
Без китәбез ташлап аның богаулы гарше көрсиен;
Без китәбез ташлап аның кодсиятен[2], бөтен барын.
Газазил груһы барысы.
Без китәбез ташлап аның кодсиятен, бөтен барын.
Газазил.
Иркен илдә, иркен булып, зобанилардан котылып,
Ямьле тормыш төзербез без. Яшәрбез без бер җан булып;
Әгәр дә сез бер күрсәгез ул ят илнең матурлыгын,
Онытырсыз оҗмахтагы матурлыкларның барлыгын.
Анда дәрья, анда диңгез, анда кырлар, моң тургайлар,
Анда урман, анда күлләр, анда иксез зур тугайлар,
Төрле-төрле булып тора чәчәкләре, лаләләре...
Яз-көзләре, җәй-кышлары, ак көннәре, тын төннәре...
Иркен биек күкләрендә ак болытлар узышалар,
Түбәнрәк һава ярып, ирекле кошлар уйнашалар.
Суларында дулкын ярып, ак балыклар йөзәләр,
Төпләрендә куакланып, кызыл мәрҗәннәр үсәләр.
Без китәбез ирекле илгә, иркен сулыш алыр өчен,
Без яшәрбез мәңге бергә, ирекле, ямьле хәят өчен.
Газазил груһы.
Без яшәрбез мәңге бергә, ирекле, ямьле хәят өчен.
Адәм.
Ялгызлыкның авырлыгын, боеклыгын белсәң иде,
Түзә алмыйча бу упкыннан качар идең, иркә ярым,

[1] Ләкаб — кушамат.
[2] Кодсият — изгелек, пакьлек.

Мине монда ялгызымны калдырып, син китсәң иде,
Сине эзләп табар өчен, корбан итәр идем барын.

Һ а в а.

Мин аңламыйм, аңлый алмыйм, кемнәр уйный тәкъдир белән?
Сине тоткын итеп, монда хөкем сөргән кем ул тагын?

А д ә м.

Тәңре.

Д ә җ җ а л.

Гали әмере.

Г а з а з и л.

«Көн фәякүн» уены белән уйнап шашкан,
Хәлдән тайган, карт фокусчы!..

Д ә җ җ а л г р у һ ы.

Мәлгунь!

Һ а в а.

Кайда соң ул?

Д ә җ җ а л.

Ламәкәндә!

Һ а в а.

Ламәкәндә?!

Д ә җ җ а л.

Әйе, анда...

Г а з а з и л.

Юк ул анда!..

Д ә җ җ а л г р у һ ы.

Мәлгунь!..

Г а з а з и л.

Фокусчының ихтыярын менә болар,
Менә болар корал итеп алганнан соң,
Ламәкәндә юкка чыкты. Ул юк хәзер.

Д ә җ җ а л.

Ул бар! Ул көчле!

А д ә м.

Юк, юк миңа синнән башка Тәңре, Илаһ!..

Д ә җ җ а л.

Зур, зур гөнаһ...

И р е к.

Ирекле йөрәк яшәгәндә, юк ул гөнаһ!

Г а з а з и л.

Юк ул гөнаһ, йөрәкләрдә якты нурлар
Дулкынланып оча-оча уйнаганда.

Мәхәббәт.

Мәхәббәтнең көчле уты янган чакта,
Гасый канун, рия, гөнаһ юкка чыга!..

Һава.

Канун, гөнаһ нәрсә соң ул?

Газазил.

Саф вөжданга киертелгән нәләт богау.

Дәҗҗал.

Җан иясен турылыкка өндәүче юл.

Газазил.

Күңелләрдә яктылыкны сүндерүче,
Караңгылык тудыручы зур афәт ул.

Дәҗҗал *(Адәмгә килеп)*.

Син гөнаһкярга хәят бирүче изге гаршендә,
Ләүхелмәхфүздә кара утлардан тәкъдирең яза.
Вакыт үтмәгән: ваз кич болардан!

Адәм *(Һавага күрсәтеп)*.

Менә ул, менә хәят бирүчем, минем илаһым!..
Минем илаһым, дәртле илаһым, күрекле илаһым!
Менә карагыз, аның алдында сәҗдә кыламын.
*(Тезләнә.)*

Җәбраил.

Шул сулыштан бу оҗмахлар хәрәм сезгә,
Мәңгелеккә Тәңре сөрде сезне җиргә.

Газазил.

Без курыкмыйбыз ачу иткән утлы көчтән,
Без курыкмыйбыз ләүхелмәхфүз язуыннан.
Бездә гакыл, бездә ирек, алда хәят.
Хур, мөстәбид җәлладларга нәләт, нәләт!..

Газазил груһы.

Хур, мөстәбид җәлладларга нәләт, нәләт!..

## VII КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Дәббәтеларз.

Дәббәтеларз.

Мин дә монда артык калмыйм. Сезнең белән
Җиргә күчәм, тигезлекне эзләр өчен.
Нәләт үлек оҗмахтагы җинаятькә!..

Газазил груһы.

Нәләт үлек оҗмахтагы җинаятькә!..

Дәҗҗал груһы.

Нәләт сезгә, мәлгуньнәргә!

Г а з а з и л.

Бер көн килер, кодсиятен, бөтен барын
Көл итәрбез, көрсиләрен, тәхетләрен.
Бер көн килер, нәләт камыты сезне буар,
Тик шул чакта хәят нуры шат ялтырар.
Көчле хәят, дәртле хәят, нурлы хәят!
Оҗмахлардан өстен торган ирекле хәят!

Г а з а з и л  г р у һ ы.

Оҗмахлардан өстен торган ирекле хәят!
*(Оҗмахны ташлап чыгалар.)*

Д ә җ җ а л  г р у һ ы.

Нәләт, нәләт, нәләт!

Ахыргы сүзләрне әйткәндә, күк күкри. Куркынычлы авазлар, быргы тавышлары оҗмахны ду китерә. Оҗмах караңгыланып, төссез, җансыз калган шикелле була.

П ә р д ә  т ө ш ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### I КҮРЕНЕШ

Сәрәндип атавы. Табигать табигый хәлендә, гаять бай. Гөлләр, яфраклар гадәттәгедән зур һәм матурлар. Бөтен җирдә чын сафлык, матур табигыйлек күренеп, ялтырап тора. Г а з а з и л таш-тауның иң биек түбәсенә басып тора. А д ә м тау астында, Һ а в а н ы ң тезенә башын куеп, уйланып утыра. К а л г а н н а р төрле кыяфәттә табигатьнең матурлыгына сокланып торалар. Әтрафта сулар, болыннар, урманнар, ачык күк йөзендә сирәк-сирәк ак болытлар йөреп тора. Кояш бөтен зурлыгы, матурлыгы белән бергә ялтырый.

Г а з а з и л.

Тәмугсыз, оҗмахсыз, иркен киң дөнья!
Богаулы оҗмахтан сөрелдек сиңа.
Кабул ит син безне туганың итеп,
Кабул ит син безне дусларың итеп.
Коллыкка, тәмугка нәләтләр әйтеп,
Ирекле яшәргә без иңдек сиңа.
Ач безгә киң итеп тулы кочагың,
Турылык эзләп без иңдек сиңа.
Без синең мәңгелек якын дусларың,
Җанланып гөлләнер ямьле кырларың,
Иясез боеккан дәртсез көнеңә
Җан-дәрман салырга без иңдек сиңа.
Балыктай йөзәрбез диңгезләреңдә.
Аккоштай очарбыз саф күкләреңдә.

Ташлардан, таулардан оҗмах ясарбыз,
Сәҗдәсез, гөнаһсыз мәңге яшәрбез.

Һ ә м м ә с е.

Хаклыкны үз иткән саф вөҗдан белән
Мәңгелек тормышка без иңдек сиңа.

И р е к.

Тәңренең богаулы оҗмахын ташлап,
Богаусыз яшәргә без иңдек сиңа.

Һ а в а.

Чикләнгән упкынны мәңгегә ташлап,
Чикләүсез яшәргә без иңдек сиңа.

М ә х ә б б ә т.

Дуссыз, чын ярсыз тормышны ташлап,
Янып яшәргә без иңдек сиңа.

Д ә б б ә т е л а р з *(сөенеп)*.

Эшсезләр, ялкаулар дөньясын ташлап,
Мөкатдәс эш өчен без иңдек сиңа.

А д ә м.

Без кайда?

Г а з а з и л.

Без җирдә.
Биек бу таулар, кырлар, урманнар,
иксез киң дәрья,
Дәрьяда ташлар, көчле болытлар, киекләр, кошлар,
Барлык табигать, бөтен мәхлукат[1] баш ияр сиңа;
Баш ияр сиңа җилләр, диңгезләр, ерак йолдызлар…
Баш ияр сиңа бар кяинатның[2] яшерен серләре,
Баш ияр сиңа үкереп торган җирнең үзәге.
Баш ияр сиңа көчле кояшның сихри нурлары,
Баш ияр сиңа сине яраткан табигать үзе.
Үткен карашың, сихри ук төсле, миләрдән үтеп,
Көчле гакылың, фаразлар гизеп, йолдызлар үтеп,
Хөкемен йөртер җитмеш җиде башка җиһанда.

А д ә м.

Без кайда?

Г а з а з и л.

Без җирдә.

Д ә б б ә т е л а р з.

Киң илдә.

И р е к.

Иркендә.

---

[1] М ә х л у к а т – җан ияләре.
[2] К я и н а т – дөнья, галәм.

Һ а в а.
Без бергә.
М ә х ә б б ә т.
Гомергә.
Һ ә м м ә с е   б е р г ә.
Гомергә!..
Д ә б б ә т е л а р з.
Мөкатдәс эшнең утлы сулышы ирекле киң җирдә
Мәңгегә калып хаким булачак шунда гомергә.
Мөкатдәс эшнең сихри китмәне, шул киң җир йөзен
Чын оҗмах ясап, хәйран итәчәк Тәңренең үзен.
Мәңге ялкынлы эшнең көченнән туган бу оҗмах
Тәңре оҗмахын юкка чыгарыр шәүкәте белән.
Мөкатдәс эшнең катгый әмере безгә баш булгач,
Масая алмас Тәңре үзе дә кодрәте белән.
Б а р ы с ы.
Масая алмас Тәңре үзе дә кодрәте белән.
А д ә м.
Без кайда?
Г а з а з и л.
Без җирдә.
Д ә б б ә т е л а р з.
Киң илдә.
Һ а в а.
Без бергә.
М ә х ә б б ә т.
Гомергә.
И р е к.
Иректә.
Һ ә м м ә с е.
Гомергә!..
И р е к.
Каршыңда иксез-чиксез зур дәрья, уңыңда урман,
Сулга күз атсаң, сузылып яткан иркен киң дала.
Артка карама, үткән ул, беткән. Анда киң томан;
Дәртле күңелдән башың күтәреп, алга син кара!
Тик алда гына таба алачаксың дәртеңә дәва.
Дәртсез оҗмахны чыгар күңелдән, чыгар мәңгегә,
Ямьле киң җирдә мәңге яшәрбез иркендә бергә.
А д ә м.
Мин кайда?
Г а з а з и л.
Син җирдә.

Д ә б б ә т е л а р з.
Киң илдә.
И р е к.
Иркендә.
Һ а в а.
Без бергә.
М ә х ә б б ә т.
Гомергә.
Һ ә м м ә с е.
Гомергә!..
А д ә м.
Мин җирдә?!
Б а р ы с ы.
Гомергә!..
М ә х ә б б ә т.
Энҗе-җәүһәрдән тукылган өлге, чәчеп нурларын.
Ачылган чакта еракта — анда ал таң нурлары.
Яшерен сөйләрләр саф йөрәгеңә сөю серләрен,
Ак гөлгә кунып, канат тибрәтеп, җир былбыллары.
Һ а в а.
Мәңге без бергә, ак көн күрергә без иңдек җиргә,
Мәңге без бергә, тормыш төзергә без иңдек җиргә.
Мәңге без бергә, бер булыр өчен без иңдек җиргә.
Оныт үткәнне, үткән көн кайтмас, калсын ул артта.
Алда безгә киң, иркен юл ачык, алда сәгадәт!
Мәңге без бергә, башлык итәргә без иңдек җиргә.
Мәңге без бергә, бәхет корырга без иңдек җиргә!
Б а р ы с ы.
Гомергә.
Г а з а з и л.
Анда ул булса, монда сез хаким бөтен барлыкка.
Күтәр күзеңне каршыңда торган саф матурлыкка!
Д ә б б ә т е л а р з.
Эш сине чакыра чын турылыкка, алга, зурлыкка!
И р е к.
Ирекле киң илдә урын калмасын түбән хурлыкка.
Б а р ы с ы.
Анда ул булса, монда сез хаким бөтен барлыкка.
А д ә м, Һ а в а.
Анда ул булса, монда без хаким бөтен барлыкка.
Һ а в а.
Мин сине салмам, сөекле Адәм, зарлы коллыкка!
А д ә м.
Мин сине салмам, гөлкәем, Һавам, түбән хурлыкка!

Б а р ы с ы.
Гомер итәрбез җирнең ямьнәрен уртаклап бергә.
Без ташламаска антлар итәбез сезне гомергә.
Чын ярлар булып тормыш төзербез бу җирдә бергә.
Г а з а з и л.
Ант итәм мин йолдызларның кара төндә сүнүе белән,
Ант итәм мин җитмеш җиде мең галәмнең бетүе белән,
Ант итәм мин диңгезләрнең таң чыгыдай кибүе белән,
Артка чигенмәм һәм кимсеттермәм заруриятеңне!
Д ә б б ә т е л а р з.
Мохитләр кибеп, урыны чүл булса,
Җирнең барлыгы янып көл булса,
Шул чагында гына маңгай тирләрем
Үз теләге белән сөртмичә кибәр.
Шул чагында гына көчле китмәнем
Үз ирке белән кулымнан төшәр.
И р е к.
Ант итәм гөрзиләрнең, зинданнарның
Җәһәннәмдә суык көлен күрү белән,
Ант итәм мин юк итәргә богауларын,
Зынҗырларын көчсезләрнең көче белән!
М ә х ә б б ә т.
Ант итәм мин, күбәләкнең ал лаләгә
Кунып канат каккан нурлы көне белән.
Ант итәм мин, сандугачның күләгәдә
Мәгъшукасын сөеп әйткән көе белән,
Йөрәкләрнең теләгенә каршы килмәм!..
Һ а в а.
Ант итәм мин, шәфкать тулы күңелем белән,
Зөрриятеңне мәңге саклап мин калырмын.
Б а р ы с ы.
Без саклармыз зөрриятең,
Күтәрмез кодсиятең.
Күтәреп без кодсиятең,
Гареш ашар зур өммәтең.
Баш ияр бар, бар кяинат!
Мәрхәбая, хуш килдегез,
Мәрхәбая, хуш килдегез,
Мәрхәбая, адәми зат!..

*(Чыгалар. Таулардан, сулардан, кырлардан, урманнардан җавап кайтаралар.)*

Мәрхәбая, хуш килдегез!..
Мәрхәбая, хуш килдегез!..

А д ә м *(кояшка карап)*.
Бу нәрсә?!

Г а з а з и л.
Ул кояш, кортка җимнәр, тәмле җимешләр
Яратучы ак, миннәтле[1] кояш.

Д ә б б ә т е л а р з.
Киң җир йөзендә эш һәм тик кояш
Мәңге, мәңгегә булачаклар баш.

М ә х ә б б ә т.
Ал лаләләргә җан-дәрман биргән,
Күбәләкләрне үбеп уйнаткан.
Дала-кырларга җан сурын үргән,
Сине сәламләп ул бүген туган.

И р е к.
Киң дәрьяларны, ак болытларны
Ак нурларында йөздерер өчен,
Оҗмахны ташлап, Тәңрегә каршы
Көрәшер өчен, күккә ул менгән.

А д ә м.
Ул!..

Г а з а з и л.
Табигать шаһы.

М ә х ә б б ә т.
Гөлләр патшасы.

Д ә б б ә т е л а р з.
Хезмәт алласы.

И р е к.
Үч алу ташы.

А д ә м.
Кайда соң, кайда аның дәргяһы?!
*(Сәҗдә кылырга урын эзли, тезләнә башлый.)*

Г а з а з и л.
Тукта!

И р е к.
Ул аңар мохтаҗ түгел.

Д ә б б ә т е л а р з.
Менә хәзер күп-күп итеп
Китерермен җимешләрен,
Әнуаг-әнуаг нигъмәтләрен.

---

[1] М и н н ә т л е – ярдәмле.

Мәхәббәт.

Мин китерәм сезгә җыеп
Ак лаләсен, саф гөлләрен.

Ирек.

Ә мин, ирекле җилгә атланып,
Күреп кайтыйм диңгезләрен,
Далаларын, саф күлләрен.

Газазил.

Ә мин анда былбылларга
Өйрәтим җирнең көйләрен.
*(Һәммәсе чыгалар.)*

## II КҮРЕНЕШ

Адәм, Һава.

Һава.

Җир патшасы, сулар шаһы, нинди уйлар
Каплап синең саф миеңне уйландыра?
Нинди серләр, чолгап синең йөрәгеңне,
Күзләреңдә нур сүндереп моңландыра?
Сагындыңмы әллә дәртсез оҗмахларны,
Сагындыңмы әллә Тәңре дәргяһларын?
Юксындыңмы ләүхелмәхфүз, гөрзиләрне,
Оныттыңмы зобанилар богауларын?!

Адәм.

Мин ач, мин ач һәм ялангач, күрмисеңме?
Нәрсә күреп шатланыем бу яланда?
Мәңге шулай газаплармы гасый җанны?
Йөрәгемә каннар сава, уйлаганда.

## III КҮРЕНЕШ

Адәм, Һава, Шәйтан, Дәҗҗал, Яәҗүҗ, Мәәҗүҗ, Бәдбәхет һәм Гөнаһ.

Гөнаһ.

Тилмермә, Адәм, дөнья зарына,
Вакыт үтмәгән саф тәүбә өчен.
Тәңредән сиңа сәлам китердем,
Кире чакыра, кайт оҗмахына.

Адәм.

Мине?! Йа Рахман!
*(Сәҗдәгә китә.)*

Һава.

Ялган!

Д ә җ җ а л.
Җитмеш җиде мең галәмнең үче белән
Җәһәннәмнең ут дәрьясы сезне көтә.
Ләүхелмәхфүз, аждаһалар теле белән
Гөнаһларны сулыш саен ул бөркетә.
Зобанилар утлар чәчкән гөрзиләрен
Сезнең өчен дүзәхләрдә уйнаталар.
Кара йөзнең, сезне алдаган Газазилнең,
Гасый җаны сезнең белән бергә янар.
Б а р ы с ы  б е р г ә.
Сезнең белән бергә янар, бергә янар!..
А д ә м.
Юк, юк, Тәңре ярлыкар.
Һ а в а.
Ул куркыр.
А д ә м.
Мине коткар!..
Г ө н а һ *(Һавага)*.
Кул тиермә! Ул сиңа хәрәм!
Б а р ы с ы.
Тотма, җибәр!
Һ а в а.
Җитәр!
*(Адәмне Һавадан аермакчы булалар.)*
Җитәр сезгә, хаин җаннар! Кагылмагыз!
Бу безнең җир, безнең тәхет, безнең оҗмах!
Ш ә й т а н.
Безгә үпкә асравыгыз, Һава, нахак,
Әмер мәгъруф әһле хакка фарыз бит ул.
Илче күңеле, саф су төсле, кердән азат.
Без тик илче. Бездән теләк — мәңге яшь бул!
М ә ә җ ү җ.
Һәм чибәр бул!
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!
Һ а в а.
Көлмәгез!
Хакыгыз юк безне монда кимсетергә!
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!
Һ а в а *(читкә)*.
Аһ, боларның авазлары агу төсле.
Саф йөрәкне кисәк-кисәк телеп ала.

Д ә җ җ а л.
Ул уйлана.
Ш ә й т а н.
Әйе, шомлана.
Д ә җ җ а л.
Гарше көрси, ләүхелмәхфүз, утлы канун
Адым саен, сулыш саен сезне тотар.
Балкып торыр матурлыгың, зифалыгың,
Тауда үскән ал гөл төсле, тиздән сулыр.
Һ а в а.
Юк, юк, хата! Мин мәңгелек, мин мәңге яшь!

Ш ә й т а н.
Мәңгелек тик Тәңре генә, бер ул гына.
Ә син әрсез Газазилнең теләгенә
Курчак булган тик вакытлы бер җан гына.
Бер көн килер, син сулырсың, сулган гөлдәй.
Матурлыктан калыр авыр хәтер генә.
Бер көн килер, карачкыдай, күләгәдәй
Кибеп калыр сылу тәнең мәңгелеккә.
Бер көн килер, бу җирләрдә кош-корт калмас,
Барсы кайтыр, Тәңремезнең үз аслына,
Бер көн килер, тау, таш, дәрья — берсе калмас.
Д ә җ җ а л.
Гасыйларга утын булыр Һавиядә.
Ш ә й т а н.
Бер көн килер, син матурдан ямьсез диеп,
Зәвыксыз дип, кызык итеп көләчәкләр.
Бер көн килер, мәңгелеккә сине моннан
Ямьсез диеп, дәртсез диеп сөрәчәкләр.
Һ а в а.
Юк, юк, мин мәңгелек! Мин мәңгелек!
Д ә җ җ а л.
Мәңгелек тик Тәңре генә,
Аның кискен әмере генә.
Б а р ы с ы.
Аның кискен әмере генә.
Һ а в а.
Адәм, Адәм, коткар мине, коткар мине!
Утлы сүзләр, шомлы уйлар шомландыра.
Җиргә иңгән хаин Алла хыянәте
Саф йөрәкне, аямыйча, аһ, яндыра.
Китик моннан, качыйк моннан мәңге-мәңге
Тәңре мәкре ирешмәгән пакь илләргә:

Болытларга, йолдызларга, ак күкләргә,
Болар белән тумас шатлык безгә җирдә.

А д ә м.

Мин арыдым, көч калмады, дәртләр сүнде,
Йөрәгемне чолгап алды шөбһә-курку;
Мин отылдым, ачлык мине тәмам җиңде;
Мин җиңелдем, Тәңре җиңә. Аһ, авыр бу!..
*(Елый.)*

Д ә җ җ а л.

Ела!
Ела, Адәм, мәңге шулай син еларсың!
Өзлекмичә мәңге аккан күз яшеңнән
Дәрья булыр. Ә мин анда коенырмын,
Уйнармын да тик көләрмен язмышыңнан.

Б ә д б ә х е т.

Ха-ха-ха!

Д ә җ җ а л.

Ела!
Ела, Адәм! Мәңге ела! Җир сеңдермәс,
Кирәксенмәс синең гасый яшьләреңне.
Күз яшьләрең ләүхелмәхфүз караларын
Һичбер вакыт көчсезләтмәс һәм үзгәртмәс.
Ела!
Ела, Адәм! Үз гөнаһың өчен ела!
Шатлык белән күз яшьләре бергә алар.
Чын күңелдән тәүбә кылып гафу сора,
Күз яшьләре Тәңре өчен кирәк алар.
Ела!
Ела, Адәм! Зарларыңа җиһан тулсын.
Беренче тапкыр җиргә тамган яшьләреңнән
Җир йөзенә хәсрәт гөле балкып торсын.
Син түгелме ваз кичүче үз бәхетеннән?

Б а р ы с ы.

Ха-ха-ха!

Д ә җ җ а л.

Ела!
Ела, ела! Мәңге ела, беткәнчегә,
Күз яшьләре тамырыңнан кандай аксын.
Күз яшьләре тәкәбберлек утын баса,
Күз яшеңә син яшәгән җиһан тулсын.
Ела!
Ела, Адәм! Елау кадерен белеп ела,
Әлмисактан яралган бу саф тамчылар
Кыяматтә кәүсәр булыр ак җаныңа.

Күз яшендә тик табарсың ярдәмчеләр,
Шәфкатьче алар гына булыр сиңа.

Адәм.

Аһ!
Нинди сүзләр сез сөйлисез? Нинди бетү?
Нәрсә тагын ул кыямәт, мин мәңгелек!
Мин мәңгелек җиһан шаһы, белдегезме,
Мин әбәди, мин мәңгелек, мәңге терек!

Дәҗҗал.

Әгәр дә күрсәң ләүхелмәхфүзнең
Утлы юлларын, котларың очып,
Мәңгегә шунда торараташ булып
Калыр идең син!
Ләкин ул сер кыяматкәчә
Сиңа фаш булмас һәм аңлашылмас.

Адәм.

Нигә соң Ходай зар-тәкъдиремне
Кайлап баглаган ләүхелмәхфүзгә,
Нигә яраткан соң мине Тәңре,
Минем көчемнән куркырлык булгач?!

Дәҗҗал.

Сине күтәреп гарше көрсигә,
Тәхетләр сайлап куелган иде,
Ләкин алдандың син Газазилгә...

Шәйтан.

Калганын үзең син аңла инде.

Һава.

Тәхетләр сайлап, җәллад итәргә,
Сине яраткан куркак Тәңре.

Адәм.

Тәхетләр мине әле һаман да
Көтәләрме соң гарше әгълада?

Дәҗҗал.

Тәхетләр көтә тик ялгызыңны.

Адәм.

Ялгызымны?! Юк, юк!
Хәйләле тозак корылган анда,
Калам мин монда мәңгегә, җирдә.

Һава.

Бергә.

Адәм.

Гомергә.

Һава.

Аермас безне...

Ш ә й т а н.
Хәтта кабер дә.
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!
А д ә м.
Нәрсә ул кабер?
Д ә җ җ а л.
Иң көчле тәхет.
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!
Һ а в а.
Югал, бәдбәхет!
Д ә җ җ а л.
Ләүхелмәхфүздә шулай язылган.
А д ә м.
Чын тормыш эзләп, без иңдек җиргә.
Ш ә й т а н.
Дәртсез оҗмахтан риясыз җиргә иңгән Адәмгә
Риялы булып үзен алдалау кирәкте микән?
Кояш шәүләсе төшүдән борын сөңге буена,
Фикер үзгәртү җир шаһларына килешә микән?
Берничә сулыш моннан элгәре ялварган идең,
Ачлык, тарлыктан, ялангачлыктан күңелең әрнеп,
Җир тормышыннан, шул далалардан зарланган идең.
Ә хәзер күрәм: гүя торасың җирдә тәм табып,
Ташлап җир белән оҗмах көрәшен, чын туганнарча
Сөйләшеп алсак, мәсьәләләрне уртага салып.
Эшнең ахыры, әлбәттә, булыр син уйлаганча.
Дуслар табарлык вөҗдан-иманым минем дә бар бит.
Уйлап кара син: киң оҗмахтагы гамьсез тормышны,
Анда син шулай бер кисәк нанга мохтаҗ идеңме?
Якты ай төсле ялтырый иде ыспай күренешең.
Анда син шулай корган агачтай ялан идеңме?
Гыйльман, вилданнар хезмәтләреңә тайярлар[1] иде.
Шәраб-нигъмәтләр, хөллә-зиннәтләр карында иде.
Сәмруг кошыннан тәмле нигъмәтләр табында иде.
Ә монда нәрсә? Нәрсә көтәсең, нинди өмет бар?
Нинди теләкләр сине яндырыр, тамак ач булгач?
Киләчәгеңне уйлап кара син: алда, әйт, ни бар?
Өзлексез ачлык, мәңге мохтаҗлык һәм ялангачлык!
Матур теләкләр, бәхет, өметләр — бик шәп нәрсәләр,

[1] Т а й я р — әзер.

Ләкин ач көе ул зур фикерләр истән чыга шул.
Йөрәктән күбрәк акыллык эшләтсәң,
һич үкенмәссең.
Җирдә чын патша, суларга хуҗа; «аңа» син «ир»
бул!
Әнә түбәндә уйнашып торган кыр кәҗәләрен
Тәңре ни өчен яратканлыгын һаман белмисең.
Оҗмахта чакта аларның симез, тәмле итләрен
Ашаганыңны әле һаман да син төшенмисең.
Әнә аккошлар, әнә киек казлар, симез үрдәкләр —
Барысы алар синең ризыгың, синең нәфәкаң[1].
Алдыңда тора олуг хөрмәтләр, әнуаг нигъмәтләр,
Ә син ачлыктан кибеп, бөрешеп торасың, хайван!..
Ачлыктан дәрман үзең тапмасаң, табучы булмас.
Бу оҗмах түгел, күктәге хәлвәләр алдыңа иңмәс.
Үз теләге белән һичбер нәрсә атылып килмәс.
А д ә м.
Әйе, әйе, дөрес, үз көчем белән яшәргә тиеш.
Дәббәтеларз күптән шулай әйткән иде бит.
Туйдыручы һәм ризык бирүче тик мөкатдәс эш.
Ш ә й т а н.
Дөрес!
Сүздә генә калмавыңны күрер өчен,
Эшкә кабил икәнеңне күрсәтеп бир!
Әнә теге кәҗәләрнең иң симезен
Ун сулышта менә монда тотып китер!
А д ә м.
Мин ач!..
Ш ә й т а н.
Алай булгач!..
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!
А д ә м *(гарьләнеп)*.
Булдыра алмам дип әллә уйлыйсызмы?
Ш ә й т а н.
Карап карыйк, җир патшасы, гайрәтеңне!
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!..
А д ә м.
Кара инде алай булса!..
*(Тау астына китә.)*

[1] Н ә ф ә к а — яшәү өчен кирәк булган мал, азык.

Һ а в а.
Адәм!
А д ә м.
Хәзер!..
Һ а в а.
Адәм, тукта!..
Г ө н а һ, Б ә д б ә х е т.
Юкка!..
*(Һаваны тотып читкә алып китәләр.)*
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!
Ш ә й т а н.
Йөгер, йөгер, әһә, әһә, менә шулай.
Менә шулай, кулыбызга төште бугай.
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!

А д ә м тирләп, арып кыр кәҗәсен күтәреп алып килә.

Ш ә й т а н.
Качмас өчен, аякларын үлән белән
Бәйләп тә куй. Менә шулай, менә шулай!..
Көн ягына каратып сал йөзе белән,
Инде хәзер маңгаена таш белән бәр!..
*(Таш бирә.)*

Адәм, ташны алып, кәҗәгә бәрергә күтәрә.

Д ә җ җ а л.
Бисмиллаһи Аллаһы әкбәр!..
Ш ә й т а н.
Бәр!..

Адәм бәрә.

Һ а в а *(читтә тарткалашып)*.
Җибәр! Җибәр!.. Аһ!..
Б а р ы с ы.
Ха-ха-ха!..
А д ә м *(таш белән кәҗәгә бәргәч, шашынып кала, һушыннан тая)*.
Кан!..
Һ а в а.
Ярдәм, ярдәм, ярдәм!..
*(Кычкырып, газазилләр киткән якка ашыгып китә.)*
Ш ә й т а н.
Һушыннан тайды. Ярдәм кирәк.

М ә э җ ү җ.
    Шундый чакта кайнар каннар шифа була.
Д ә җ җ а л.
    Кая, тизрәк!

Шәйтан, учлап канны китереп, Адәмгә эчертә.

Я ә җ ү җ.
    Бисмилла!..
А д ә м *(иңеп, як-ягына карана)*.
    Мин ни эшләдем?
Б ә д б ә х е т.
    Эш эшләдең.
Б а р ы с ы.
    Ха-ха-ха!..
Ш ә й т а н.
    Итен ашарсың.
Я ә җ ү җ.
    Тиресен киярсең.
Д ә җ җ а л.
    Канын эчәрсең.
Б а р ы с ы.
    Ха-ха-ха!..

Тау өстендә Г а з р а и л пәйда була.

Г а з р а и л.
    Әҗәл, әҗәл, әҗәл!..
    Үлем, әҗәл, кан исләрен сизәм монда.
    Кем күтәрде әҗәл ташын җанга каршы?
    Кемнең кулы күтәрелде миннән башка
    Пакь җир йөзен ал каннарга чылатырга?
    Кем ул, кайда? Хак яраткан изге җанга
    Җәллад булып кул салучы, җан алучы?!
    Кемнең кулы буялды бу нахак канга,
    Кем ул, минем тәхетем белән шаяручы?!
А д ә м.
    Мин ялгыштым.
Г а з р а и л.
    Син ялгыштың!..
Б а р ы с ы.
    Ха-ха-ха!..
Г а з р а и л.
    Күрәм, күрәм кулларыңда нахак каннар.
    Гуаһ бирә җинаятең хаклыгына.

Әҗәл, үлем төсләренә буялганнар.
Ни йөз белән кайтачаксың дәргяһына?!
Гадәләте чикләүсез киң хак Тәңренең
Ләүхелмәхфүз хөкеме белән мәгълүм итәм,
Мине җиргә чакыручы беренче син!..
Шул сулыштан җир йөзенә әҗәл сибәм.
Бүгенгәчә җир йөзендә җан иясе
Әҗәл, үлем дигән хәлне белми иде.
Бүгеннән соң шул җинаятьнең иясе
Әҗәл суын үзе эзләп, үзе тапты.
Бүгеннән соң хәятеңә чик сызылды,
Бүгеннән соң «гомер» сиңа канун булыр.
Ләүхелмәхфүз битләрендә шул язылды.
Бүгеннән соң синең гомерең «фани» булыр.

Адәм.
Ничек?! Юк, юк, мин мәңгелек, мин әбәд...

Газраил.
Син мәмат!..

Адәм.
Юк, юк, булмас! Мин мәңгелек!..

Газраил.
Син үлек!..

Барысы.
Син үлек!.. Ха-ха-ха!..

Газраил.
Синең елларың, синең көннәрең санаулы калды.
Канга каршы кан, җанга каршы җан түләтә Тәңре.
Бу — аның әмере!..

Адәм.
Юк, юк, мин теләмим, юк, мин үлмим, мин әбәд!..

Барысы.
Ха-ха-ха!..

Газраил.
Соңгы сулышың минем кулда.

Адәм.
Коткарыгыз! Коткар!..

Барысы.
Ха-ха-ха!..

Адәм.
Кара җинаять алдады мине, аһ, алдадылар,
Ялварам сиңа, кайтар гомеремне, мәңге яшим мин.

Дәҗҗал.
Хак Тәңренең мәрхәмәте иксез-чиксез,
Оҗмахларга кире кайтсаң — гафу итәр.

Ш ә й т а н.

Хәятеңне мәңгелеккә һибә[1] итәр.

А д ә м.

Җитәр, җитәр!..

Бау салмагыз якты, ирекле хәятемә!

Б а р ы с ы.

Тәүбә, тәүбә!

А д ә м.

Тәңре!..

*(Тезләнә. Яңадан торып елый, ыңгыраша.)*

Булмый, булмый!..

Д ә җ җ а л.

Мәңгелек хәят әгәр теләсәң, хәзер син тезлән!

Г а з р а и л.

Тезлән!

Б а р ы с ы.

Тезлән!

А д ә м.

Әгәр Тәңрегә сәҗдә кирәксә, ул алсын аны.

*(Тезләнә.)*

Телем әйләнми.

Б а р ы с ы.

Тәүбә, тәүбә!

А д ә м.

Йөрәгем күнми.

Б а р ы с ы.

Тәүбә!

А д ә м.

Вөҗданым кушмый.

Б а р ы с ы.

Тәүбә!

Г а з р а и л.

Мәңгелек хәят әгәр теләсәң, нәфсеңне син җиң!

Б а р ы с ы.

Нәфсеңне син җиң!

А д ә м.

Булдыра алмыйм.

Б а р ы с ы.

Нәфсеңне син җиң!

А д ә м.

Ышана алмыйм.

---

[1] Һ и б ә – бүләк.

Б а р ы с ы.
Нәфсеңне син җиң!
А д ә м.
Көрәшә алмыйм.
Б а р ы с ы.
Әҗәл, әҗәл, әҗәл!
Г а з р а и л.
Әҗәл хак.
А д ә м.
Хәят, хәят, хәят!..
Г а з р а и л.
Хәят өстәсәң, Тәңре дәргяһын исеңдә тот син!
Б а р ы с ы.
Хәят өстәсәң, Тәңре дәргяһын исеңдә тот син!
А д ә м.
Тәңре!
Агаһ бул син, тик мәңгелек хәят өчен
Сиңа кайтмам!..
Б а р ы с ы.
Тәүбә!..
А д ә м.
Тәңре!..
Ннк яраттың, ник яраттың хурлык өчен!
*(Елый.)*
Б а р ы с ы.
Тәүбә, тәүбә!

## IV КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р, Г а з а з и л, Һ а в а, И р е к, Б ә х е т, М ә х ә б б ә т һәм б а ш к а л а р.

Һ а в а.
Коткарыгыз, коткарыгыз бичараны!
Г а з а з и л.
Адәм!
Г а з р а и л.
Әҗәл!..

А д ә м, кайсысына карарга белмичә аптырап, үзе белән үзе тартыша.

Г а з а з и л.
Ирекле тормыш алда сине балкып көтә.
Д ә җ җ а л.
Әҗәл сиңа үлем угын янап тора.

Г а з а з и л.
Аслың туфрак хезмәтеңә хәзер тора.
Хәят кучеп борыр, дәрья дулкынындай.
Синең көчле зөрриятең «мәңге» калыр.
Г а з р а и л.
Синең көчсез зөрриятең фани булыр.
Д ә җ җ а л.
Анда сине мәңгелек көн, оҗмах көтә.
Ш ә й т а н.
Анда сине гарше әгъла зурлык көтә.
И р е к.
Анда сине кара тормыш, коллык көтә.
Д ә җ җ а л  г р у һ ы.
Тәүбә кыл! Тәүбә кыл!
Г а з а з и л  г р у һ ы.
Нык тор! Нык тор!
Д ә җ җ а л  г р у һ ы.
Тәңрегә сәҗдә!
Г а з а з и л  г р у һ ы.
Җиреңнән кучмә!
Җ ә җ җ а л  г р у һ ы.
Тезлән!..
Г а з а з и л  г р у һ ы
Уйлан!..
Д ә җ җ а л  г р у һ ы.
Адәм, уйлама!..
Г а з а з и л  г р у һ ы.
Уйла!..
А д ә м.
Икенең берсе, икенең берсе: йә җир, йә оҗмах.
Икенең берсе, икенең берсе, шомлы соңгы фал.
Хәят йә әҗәл!..
Бер якта — оҗмах, өзлексез сәҗдә, мәңгелек хәят.
Икенчесендә — ирек, мәхәббәт, матурлык, әҗәл.
Икенең берсен, теләсәң кайсын ал, Адәм, сайлап,
Икенең берсен шобагаңа сал: «хәят» йә «әҗәл».
Мәңгелек хәят чакырып торганда киң кочагына,
Йөрәк теләгән алга сөреп, мин кабул итмәсәм,
Рәнҗер яшь җаным, әҗәлнең каты тар
кочагында.
Рәнҗер ул мәңге җиһаннан аны әгәр аерсам…
Юк!..
Мәңге коллыкта, дәртсез оҗмахта мәңге калганчы,
Дәртле киң җирдә иркенләп үлү мең өлеш артык.

«Ирексез», «бәхетсез», «мәхәббәт», «яр»сыз мәңге
торганчы,
Тормыш рәхәтен бер көн күрүе мәңгедән артык.
Юк, юк, бу – хата. Таулар, дәрьялар,
күктә болытлар
Мәңге калганда, минем мәңге калырга хакым бар.
Айлар, кояшлар, төнге йолдызлар
Сүнгәндә генә, җанымны көчләп тартып алырлар.
Ләүхелмәхфүзнең залим кануны салса дүзәхкә,
Шунда да үлмәс якты өметем киләчәк өчен.
Җансыз, өметсез, туфрак булганчы, мәңгелек газап
Артык булачак, ак тәнне ташлап җан чыгуыннан.
Аһ, нәрсәгә соң миңа чын хәят, мәңге булмагач?
Ни файда миңа, мин үлгәннән соң,
матур гөлләрдән?
Аһ, нәрсәгә соң ирек, мәхәббәт, бәхет, матурлык?
Минем үз «минем» мәңге аларны күрә алмагач?
Юк, бу да – хата. Кайдан эзләргә хаклык үзәген?!
Әгәр Тәңрегә каршылык кылсам, гөнаһым өчен
Иртәгә үк, бәлки, шул ак кояшны күрә алмамын...
Нәрсә соң гөнаһ, кайдан килгән ул?
Һә, минем өчен?!
Минем өчен, ә? Минем өчен, ә? Ха-ха-ха-ха-ха!..
Юк!..
Ул алай түгел. Гөнаһ – Ходайның сәҗдә иманы.
Дәҗҗал, Шәйтаны – барысы бергә үзенә булсын.
Саф минлегемне мин үзем таптым, ул бирмәде аны,
Өмет белән ышанычым да үземдә калсын.
Аһ, ни уйлыйм мин, мине балчыктан, юктан яраткан
Тәңрегә каршы баш күтәрергә нинди җан белән
Мин җөрьәт итәм?.. Юк, юк, мин сиңа, Тәңре,
баш орам!..

*(Борылып тезләнә. Һава, төрле чәчәкләргә бизәнеп, Бәхет, Ирек, Мәхәббәт янында балкып тора.)*

Җиде оҗмахны, җир һәм күкләрне кодрәтең белән
Яраткан Тәңре, синең каршыңда, синең каршыңда,
Синең каршыңда сәҗдә кыла алмыйм.
Мин җирдә калам!..
Җирдә калам мин. Кирәкми үзең һәм
оҗмахың да!..

*(Һавага ташлана. Ирек, Мәхәббәт, Бәхет, Газазил чәчәкләр белән бизиләр.)*

Газазил груһы.

Мәрхәбә! Мәрхәбә! Мәрхәбә!..

Д ә җ җ а л   г р у һ ы.
Нәләт! Нәләт! Нәләт!

П ә р д ә   т ө ш ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мәдәният һәм капитал тарафыннан алҗытылган табигать. Урманнар киселгән; таулар казылган. Төрле шахта һәм приискларның галәмәтләре күренә. Уртада адәм сөякләреннән өелгән зур тау. Г а з р а и л шул тауның башында басып тора.

### I КҮРЕНЕШ

Г а з р а и л.
Үлем, әҗәл даласында көчле патша тик мин генә,
Минем хөкемем ут, зәһәрдән каты көчле һәм дәһшәтле!
Кодрәт белән кадап әҗәл билгеләрен бөтен илгә,
Ул билгеләр калачаклар мәңгелеккә, мәңгелеккә!..
Тәхетем булып хезмәт итә адәми зат сөякләре.
Үткен утлы карашымда мәрхәмәт юк һичбер җанга,
Һәр җирдә мин, тик мин генә тетрәтәм йөрәкләрне.
Миннән рәхим, миннән каһәр һичбер зат юк бу җиһанда.
Тик мин генә!..
Тик мин генә җан иясен баш ордырам кодрәтемә.
Тик мин генә юк итә алам җир йөзендә бөтен барын.
Тик мин генә хыянәтсез булып калдым зур Тәңремә,
Тик мин генә мәңге-мәңге шулай, мәңге җан алырмын.
Тик мин генә!..
Сөякләргә, буш чүлләргә бөтен җиһан тулгач кына,
Туктармын мин җан кыюдан, җиһанда җан беткәч кенә.
Тын алырмын болын, кырлар, киң дәрьялар кипкәч кенә,
Тын алырмын бар кяинат, якты кояш сүнгәч кенә.
Җиһандагы җан, хәят, кан — миңа алар дошман һәм ят;
Юк тереклек, барсы үлек, барсы үлек минем өчен.
Кискен җилләр сызгырганда, җир йөзендә хәят эзләп,
Булмас хәят, табылмас ул, табылмас сер һәм им өчен.

Минем дәһшәт теләкләрем җир йөзендә катгый канун.
Миндә генә шатлык, кайгы берләшә ала, оеша ала.
Мәрхәмәттә һәм газапта баш булырлык кем бар тагы?
Миндә генә җан иясе чын теләген таба ала.
Тик мин генә мәңгелек ут, мәңгелек юл җир-күк өчен,
Тик мин генә чын кануннар җиһан өчен төзи алам.
Тик мин генә дәрья булып агып торган күз яшьләрен
Сихри-серле канат белән сыйпый алам, сөртә алам!..
Тик мин генә!..
Минем өчен кайгы, хәсрәт, шатлык, рәхәт — берсе дә юк.
Тик бар — канун, серле канун, «үлем-әҗәл», зар кануны.
Юк минем өчен чын гадәләт һәм хыянәт — берсе дә юк;
Тик бер үлем, мәңге юклык, таратамын җирдә шуны!..
Кара төндәй минем кара канатларым җир йөзенә
Җәелгәндә, иксез-чиксез каберлекләр, мазарлыклар бүләк итә;
Далаларда тау-тау булып өелешкән ак сөякләр,
Хәрабәләр, үләксәләр җан сыкратып мәңге яшәр.
Үткән җилләр ганбәр[1] төсле кан исләрен китерәләр;
Анда, анда, тирән, юеш, тар базларда, кыр, тауларда
Мөһәндисләр белемнәрен миңа хезмәт иттерәләр.
Мине хезмәт көтә анда. Ха-ха-ха-ха-ха!..
*(Чыга.)*

## II КҮРЕНЕШ

Алдан гаскәриләр, шәм тоткан ялчылар, палачлар, түрәләр, сакчылар, суфилар, руханилар, монахлар улашып керәләр. Мөһәндис, Дәҗҗал, Яэҗүҗ, Мәэҗүҗ, Шәйтаннарны төрле халыклардан гыйбарәт коллар зиннәтле чардуганда күтәреп керәләр. Гөнаһ чыбыркысы белән колларны чыбыркылый.

Яэҗүҗ.
Мөһәндис!
Бу җирләрнең өсләрендә ни булганын
Барын алдым. Эче кирәк миңа аның;
Эчендәге хәзинәсен чыгарырга
Никадәр көч кирәк тагын?

[1] Ганбәр — хуш исле сыек матдә.

М ө һ ә н д и с.
Йөз мең эшче, йөз мең көрәк аңа кирәк.
Я э җ ү ж.
Йөз мең көрәк хәраҗатын[1] каплармы соң?
М ө һ ә н д и с.
Шөбһәсез.
Ләкин хәвефле бер ягы бар: дары белән
күтәрткәндә,
Алып калыр күп корбаннар.
Я э җ ү ж.
Күңелеңне тыныч тот син ул турыда –
Бездә эшче бетмәс әле, кызганмагыз.
Көрәкләрен башкалары казып алыр.
Табыш булсын, башкаларын искә алмагыз.
Сөякләрен кярханәләр эшкә кертер.
Өч йөз мең җан һибә итәм бу эшеңә.
Өч йөз мең җан бетсә әгәр, алты йөз мең,
Алты миллион эшче әзер, алар казыр.
М ө һ ә н д и с.
Минем яңа коралларым гаҗәп көчле:
Бер сулышта шушы бөек ташлы таулар
Юк булачак, дулкындагы күбек төсле.
Юк булачак меңәр-меңәр көчле җаннар.
Я э җ ү ж.
Адәм җаны кызганудан үткән инде,
Ул – мал түгел, мал табучы корал гына.
Мал кадерен белү кирәк, ул кирәкле,
Эшче бетмәс, корт шикелле, тик ал гына!
Җир тарихын без булдырдык, без тудырдык,
Җир байлыгын күкрәгеннән тартып алып,
Көнгә каршы ялтыратып без чыгардык.
Без калырбыз мәңге аңар хуҗа булып.
Ш ә й т а н *(яшерен)*.
Дөрес!
Мөһәндиснең ихтирагын[2] сатып алып,
Үзен дә шул бер үк базга тыгу кирәк.
М ә э җ ү ж.
Мөһәндис!
Бер сулышта йөз мең адәм кыра торган,
Сугыш өчен бер корал бир ясап миңа.

---

[1] Х ә р а җ а т – чыгымнар.
[2] И х т и р а г – уйлап табу.

Әгәр шуны теләгәнчә булдыра алсаң,
Каһарманга лаек нәшан[1] булыр сиңа!

Я э җ ү җ.
Ә мин
Бармагыңа якут гәүһәр кидерермен.

М ө һ ә н д и с.
Тырышырмын.

Ш ә й т а н.
Ант иттереп, кул куйдырып алу кирәк.

М ә э җ ү җ.
Мөһәндис!
Әнә теге тау башында болытларны
Күрәсеңме? Җитеп булмый, биекләр бит.
Шулар белән сугышырлык корал кирәк.
Җир безнеке, ул ычкынмас. Адәм кирәк.

Б а р ы с ы.
Алар кирәк.
Күктән яңгыр көтеп торган ахмакларны
Шул базларга кертергә юллар кирәк.

М ө һ ә н д и с.
Алар белән сугарыла туган илем.

Б а р ы с ы.
Туган илең? Ха-ха-ха!..

Ш ә й т а н.
Чәч агартып, баш катырып укыганда,
«Туган илең» сиңа ярдәм күрсәттеме?

Я э җ ү җ.
Менә сиңа «туган илең» – алдан түлим.
*(Акча бирә.)*

М ө һ ә н д и с *(каушый).*
Белмим...

Я э җ ү җ.
Биргәндә ал. Күк капусы ябылгачтын,
Дога, зарлар һәм теләкләр кабул булмый.

М ө һ ә н д и с.
Ярый. Ләкин...

Я э җ ү җ.
Ал!..

Мөһәндис ала.

М ә э җ ү җ.
Коточыргыч ихтирагың тәмам булгач,
Каһарманга лаек «нәшан» син тагарсың.

---

[1] Н ә ш а н, н и ш а н – орден.

Ш ә й т а н.
Тәбрик итәм бәхет яуган көнең белән.
Шаять, монда кул куюдан ваз кичмәссең.

Мөһәндис кул куя.

М ә э җ ү ж.
Мөһәндис!
Әнә шушы тау артында зур диңгезләр бар;
Ул диңгезләр артларында чит илләр бар;
Ул илләрдә күз күрмәгән байлыклар бар;
Энҗеләр бар, хайван төсле эшчеләр бар.
Шул илләрне моннан торып алу өчен,
Дөнья йөзе күрә алмаган корал чыгар!
Ул коралда эшләгәндә, адәм көчен
Мөмкин кадәр аз итүне исеңә ал.
Чөнки заман бозылып тора бу арада;
Ышаныч юк корал бирү корамага.
Ә мин дигән корал булса, ул коралда
Эшләүче үз көчемез дә җитәр аңа...
Җир, күк, тау, таш, куе болыт, ут көчләрен
Бергә җыеп, бер кәрамәт тудыр, егет!
Ул чагында безгә каршы килгәннәрнең,
Барын тирән җир астына тыгар идек.
Ш ә й т а н.
Чын, Мөһәндис эшлим дисә, ул булдырыр.
М ә э җ ү ж.
Яэҗүҗ сине алтыннарга коендырыр.
Ә мин синең күкрәгеңә шул нәшанны
*(Зур нәшанны күрсәтә.)*
Шул шатлыклы көнне үзем тагар идем.
М ө һ ә н д и с.
Уйлап карармын.
Я э җ ү ж.
Менә сиңа вәгъдә өчен.
*(Акча бирә.)*
Ш ә й т а н *(Мәэҗүҗгә)*.
Хәзер инде ул ычкынмас.
Әфәнделәр, ялыкккансыз, боерыгыз...
Б а р ы с ы.
Рәхмәт!..
*(Үкерешеп-улашып китәләр.)*

## III КҮРЕНЕШ

Г а з а з и л  һәм  М ә һ д и.

Г а з а з и л.
Мөһәндиснең белемлеген сатып алып,
Җир үзәген кимерергә юл тоталар.
М ә һ д и.
Безгә үлем хәзерләгән ул коралны
Җир йөзеннән мәңгелеккә җую кирәк.
Г а з а з и л.
Мөһәндиснең ул коралы, табигатьнең
Бөтен көчен бер ноктага җыеп алып,
Җир йөзеннән бөтен барлыкны корытып,
Тәхетләрне саклар өчен билгеләнгән.
М ә һ д и.
Мөһәндиснең ул коралы чыкмас борын,
Тәхетләрнең көлен күккә ташлау кирәк.
Җан кыючы корал безгә кирәк түгел.
Телләремез сөңге, каләмемез зәһәрле ук.
Г а з а з и л.
Безгә кирәк ару вөҗдан, чын саф күңел,
Безгә кирәк ирек, дуслык, чын матурлык.
М ә һ д и.
Әйдә, киттек!..
*(Китәләр.)*

## IV КҮРЕНЕШ

Б ә д б ә х е т.
Киң җир йөзендә зур күпчелекнең җилкәләрендә
Албасты булып кара хөкемемне үтәп торамын.
Җир балаларын кан йоттырамын үз илләрендә;
Үз илләрендә вакытсыз гүргә өндәп торамын.
Кояш нурларын, язның гөлләрен каплыйм алардан;
Йөрәк каннарын күкрәкләреннән сыгып аламын.
Ләүхелмәхфүзнең, язмышның боерыкларын
Йөрәкләренә һәр сулыш саен ярып саламын.
Тирән базларда эшләгән чакта күмеп калдырам;
Иген кырларын, туган йортларын утка ягамын.
Ата-анадан зар балаларын аера торам;
Саф намусларын, хезмәт көчләрен малдай сатамын.

## V КҮРЕНЕШ

Б ә д б ә х е т һәм а ч л а р.

Ерактан ыңгырашкан авазлар белән ачлар: ач х а т ы н н а р, б а л а л а р г р у һ ы килә. Сөякләрдән өелгән тау итәгенә егылалар.

А ч л а р б а р ы с ы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.
А ч.
Кайда кадәр язмыш безне бу сукмактан алып барыр?..
Б ә д б ә х е т.
Гүргә кадәр.
А ч.
Кайчан гына котылырбыз бу хурлыктан, мохтаҗлыктан?
Б ә д б ә х е т.
Кабердә.
А ч.
Кайчангача кара болыт безнең өстә сарылып торыр?
Б ә д б ә х е т.
Мәхшәргәчә.
А ч.
Менә безнең туганнарның сөякләре тау-тау булган.
Б а р ы с ы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.
А ч.
Кайда кадәр михнәт юлы шул килештә алып барыр?!
Б ә д б ә х е т.
Тәмугкача.
Б а р ы с ы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.
А ч.
Аһ, нигә генә атмый икән күптән көткән якты таңнар?
Кемнәр генә залимнәрнең кәсәсенә агу салыр?!
Б ә д б ә х е т.
Һичкем.
А ч.
Кемнәр генә, кемнәр генә безнең хәлне күреп аңлар?
Б ә д б ә х е т.
Сүнгән таулар.
Б а р ы с ы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.

Ач.
Урманнарда киек бетте, елгаларда сулар кипте.
Ач хатын.
Тамырларда каннар кипте, күкрәкләрдә
сөт калмады.
Барысы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.
Ач.
Зур шәһәрләр, ак сарайлар төзедек без.
Үзебезгә ышыкланыр җир калмады.
Җир йөзендә комсызларны сыйладык без,
Үзебезгә каткан икмәк табылмады.
Барысы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.
Икенче ач.
Су, су, актык теләк!..
*(Үлә.)*
Ач хатын.
Ярдәм кирәк! Ярдәм кирәк...

## VI КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Газраил.

Газраил.
Мин хәзер!..
*(Утлы байрагын күтәрә.)*
Барысы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.

## VII КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Газазил.

Газазил.
Ач туганнар, зур сөенеч, Мәһди инде.
Барысы.
Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.
Газазил.
Бәйрәм якын. Гарәфәсе таңын атты.
Яныбызга туганыгыз Мәһди кайтты.

## VIII КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр, Мәһди һәм Дәббәтеларз. Мәһди кулында зур байрак.
Сөякләр өстенә баса.

Барысы.

Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте.

Мәһди.

Туганнар!
Мин сез көткән, күктән иңгән Мәһди түгел!
Сезнең кебек газапларны күреп үскән,
Җирдә туып, җирдә үскән керсез күңел;
Сезнең төсле, елгаларның суын эчкән.
Күк Мәһдие — киң чүлдәге сәраб[1] кына.
Мин, Мәһди «мин!», ярдәмгә дип сезгә килдем.
Азатлыкка илтер тик шул байрак кына.
*(Газраилгә.)*
Ә син югал! Монда артык эзең күрмим.
Югал, югал! Сарайларга хәзер кит син!
Ач туганнар, күзләрегез күрә алмый,
Җирләремез, тауларымыз нигә охшый?
Кайда киткән тулып торган ал лаләләр?
Киң болыннар, бу урманнар нигә охшый?!
Бу сөякләр — ата-баба сөякләре.
Шул хурланган сөякләрне кулга тотып
Ант итик туздырырга сарайларны.

Барысы.

Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте…

Дәббәтеларз.

Мин тудырдым җиһанга ул сарайларны,
Минем аны ватарга да көчем җитәр.
Дию төсле ватып шушы зур ташларны,
Мин тудырдым кярханәләр, зур шәһәрләр.
Очып китсен барысының көле күккә.
Яңаларын ясап җиһан тутырырмын.
Җир йөзләрен оҗмах иттем залимнәргә,
Алар өчен җәһәннәм дә тудырырмын.
Җир йөзенә таратып су тамырларын,
Сахраларда зур бакчалар ясадым мин.
Көне-төне казысам да таш-тауларын,
Зур сазларын, йортсыз-җирсез мин, ач калдым.
Җир минеке, кярханәләр, зур шәһәрләр —
Барысы да, барысы да үземнеке!..

---

[1] Сәраб — рәшә.

Чүкечемез, китмәнемез бар чагында,
Җиһанга без яңа оҗмах тудырырмыз!..

Б а р ы с ы.

Без арыдык, көч калмады, дәрман бетте...

М ә һ д и.

Ата-баба сөякләрен хурлаучылар —
Җир йөзеннән сөрелергә тиеш алар.
Соңгы көрәш, соңгы сулыш, алга! Алга!
Үлем илтик комсыз, залим сарайларга!

Б а р ы с ы.

Үлем сарайларга!

М ә һ д и.

Шул хурланган сөякләрне кулга тотып
Ант итик туздырырга сарайларны!..

Б а р ы с ы.

Ант итәбез туздырырга сарайларны!..

Г а з а з и л.

Алга!..

М ә һ д и.

Үлем сарайларга!..

Б а р ы с ы.

Алга!..
*(Чыгалар.)*

Ант иткән вакытта, һәрберсе берәр сөяк күтәрә. Чыгып киткәндә, сөякләрне бутап, янап чыгалар.

П ә р д ә  т ө ш ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Капитал һәм мәдәниятнең берләшкән зиннәтле сарайга охшашлы мәйданы. Уртада биек тәхет. Тәхетнең артында, өстә — дар. Тәхет алдында, сул якта, зиннәтле тимер шкаф. Уң якта зиннәтле зур туп. Тимер шкаф артында, өстә, Яәҗүҗ тәхете, туп артында, өстә, Мәәҗүҗ тәхете. Мәйданның тирә-ягында туплар, пулемётлар һәм с а к ч ы л а р сакта тора. Мәйдан төрле герблы флаглар белән, үләннәр белән зиннәтләнгән. И р е к, М ә х ә б б ә т, Б ә х е т богауланганнар.

### I КҮРЕНЕШ

Р у х а н и л а р, м о н а х л а р, с у ф и л а р, г е н е р а л л а р, п а т ш а л а р, т ү р ә л ә р, б а й л а р тимер шкафка һәм тупка төрле рәвештә (һәр халык үзенчә) тәгъзим галәмәтләре белән ихтирам күрсәтәләр. Д ә җ җ а л кергәндә, һ ә м м ә с е сәҗдәгә китәләр. Дәҗҗалның бер ягында Г ө н а һ, икенче ягында Б ә д б ә х е т. Дәҗҗал тәхеткә менеп

утырганчыга кадәр, музыка уйнап тора, зур ихтирам белән каравыл астында Мөһәндиснең яңа ихтирагы тәхеткә якын бер җиргә куела. Гаскәри һәм гражданнарча тәкәллефләр-церемонияләр ясала.

Дәҗҗал.
Безнең өчен кирәк эшне кодрәтле фән тәмам кылды.
Безнең өчен соңгы сүзне мәдәният бүген әйтте.
Бу көнгәчә милкемезне көнлекчеләр саклый иде;
Бүгеннән соң мәңгегәчә аны саклар зур фән көче.
Бүгеннән соң тәхет-таҗга шикләнерлек эш калмады;
Бүгеннән соң безне саклар табигатьнең сихри көче.
Бүгеннән соң, меңәр-меңәр әрәмтамак асрар өчен,
Ихтыяҗ юк. Бүгеннән соң шул машина безне саклар.
Бүгеннән соң канлы, ерткыч ихтилалны[1] басар өчен,
Сатлык җаннар, ач хайваннар, курамалар кирәк түгел.
Мөһәндиснең зур белеме азат итте куркулардан.
Бүген тәхет-таҗлар көне; байлык, шатлык, корал көне.
Мөһәндиснең белем, фәннең ватанына хезмәт көне,
Табигатьне һәм халыкны буйсындыру, җиңү көне.
Бүген тәхет, хуҗаларның, богауларның бәйрәм көне.

Яэҗүҗ.
Бу шатлыклы ак көннәрне күрсәтүче
Зур фән булса, сәбәпчесе син, Мөһәндис,
Кая, кил, ал, менә сиңа аның өчен!..
*(Акча бирә.)*

Мөһәндис.
Рәхмәт!..
*(Сәҗдә кыла. Төрле тәкәллефләр күрсәтә.)*

Мәэҗүҗ.
Ата-бабаң һәм нәселең күрә алмаган
Зур нәшанны ватан өчен үзем тагам.

Гаскәри тәкәллефләр күрсәтелә. Кул чабалар, кычкыралар, тәбрик итәләр.

Барысы.
Мең яшәсен тәхет, ватан!
Аны сөйгән чын каһарман!

---

[1] Ихтилал — баш күтәрү, фетнә.

Ш ә й т а н.
Бүген фәннең табигатьне җиңгән көне,
Бүгенге көн көчлеләрнең бәйрәм көне.
Мөһәндиснең искиткеч зур ихтирагын
Әманлыкта чын күңелдән котлау көне.

Музыка уйный. Халык: «Ура, виват, яшә», — дип кычкыра. Гаскәри нәмаешлар.

М ө һ ә н д и с *(машинаның ачкычын биргәндә, тәхет алдында сәҗдә кылып).*
Табигатькә безне хуҗа иткән корал
Тәмам булды. Әмерегезгә тайяр тора.
Д ә җ җ а л.
Мөһәндис!
Безнең тәхет, милкемезне саклар өчен,
Ниләр, ниләр вәгъдә кыла безгә бу фән?
М ө һ ә н д и с.
Бу көнгәчә җир тарихы мондый көчне
Күргәне юк, белгәне юк, ханнар ханы.
Д ә җ җ а л.
Ниләр генә вәгъдә итә соң ул безгә?
М ө һ ә н д и с.
Теләкләрнең иң зурларын!..
Д ә җ җ а л.
Афәрин!
Нинди көчкә малик соң бу ихтирагың?
М ө һ ә н д и с.
Кирәккәндә мең чакрымлык даирәдә,
Менә шуннан бер кендеген басу белән,
Һичбер җаннан җан иясе калмаячак.
Д ә җ җ а л.
Афәрин!

Мөһәндис Яэҗүҗ, Мәэҗүҗ белән сөйләшә.

Ш ә й т а н.
Бу коралның серен монда күмәр өчен,
Мөһәндиснең хәят җебен кисү кирәк.
Аңа охшаш башка кулда булмас өчен,
Мөһәндисне җир йөзеннән сөрү кирәк.
Аларның бит белемнәре малдай сатлык.
М ә э ж ү ж.
Йә Мөһәндис, тәбрик итәм шөһрәт белән,
зур дан белән,

Тәхет өчен, ватан өчен зур хезмәтләр күрсәттең син,
Тарихларда исемнәрең язылачак ал кан белән.

Ш ә й т а н *(Мөһәндискә).*

Аң бул: монда яңа бер сер яшеренә, син сизмисең.
*(Яәҗүҗкә яшерен сөйли.)*

Я э җ ү җ.

Алай булгач, югалтырга кирәк аны җир йөзеннән.
Беткәнмени, кирәк булса, икенчесе табылыр тагын.

Шәйтан яңадан Мөһәндискә килеп яшерен сөйли.

М ө һ ә н д и с.

Төшенә алмыйм, ачыграк әйтсәгез лә.

Ш ә й т а н.

Ничә еллар чәч агартып эзләп тапкан хәзинәңне
Бер кап алтын, бер нәшанга сатып калу ничегрәк?

М ө һ ә н д и с.

Ни димәкче буласың син?

Ш ә й т а н.

Чит илләргә илтеп сатсаң, шөһрәт-малга чумар идең.

М ө һ ә н д и с.

Шөһрәт тансык туклар өчен. Әмма минем...

Ш ә й т а н.

Сизәм, сизәм.
*(Дәҗҗалга барып.)*
Хәзер тотып астыр аны, фәннең «сере» бездә калсын.
*(Гыйшык пәрәсткә барып.)*
Әнә теге озын буйлы чибәр хатын
Сине чакыра, кочагына бар тиз, ашык!
*(Гаскәри янына барып.)*
Теге егет хатыныңны алдалаган.
Намус даулап, бар, хәзер син сугышка чык!
*(Юан байга барып.)*
Әнә теге озын кеше сиңа каршы
Көндәш булып, кибет ачып күршеңә,
Сине йотып, сиңа капчык тактырмакчы.
*(Түрәгә барып.)*
Әнә теге ришвәт хурны күрәсең бит,
Баш вәзирнең тирәсендә койрык бутап,
Хәйлә белән сине күздән төшермәкче,
Сине куып үзе шунда утырмакчы.
*(Баш вәзиргә барып.)*
Кара, кара, әнә теге салам сыйрак
Ихтирамсыз, аягыңа басып китте.
*(Бай карчыкка барып.)*

Почмактагы сылу егет сиңа карап
Гыйшык тотып аһ итә. Кызган аны!

Шәйтан коткысы киткәннән соң, һәрберсе үз дошманын күзе белән, хәрәкәте белән сагалап, бәйләнергә уңай вакыт сайлап йөри башлый.

Г а с к ә р и *(Гыйшык пәрәст янына барып).*
Гафу итегез, «мещан» әфәнде, бу ни эшегез?
Г ы й ш ы к п ә р ә с т.
Нәрсә дисез? Сүзегезне кире алыгыз!
Г а с к ә р и.
Уйламыйм да.
Г ы й ш ы к п ә р ә с т.
Мин патум... почёт... гр-р-р-р!..
Г а с к ә р и.
Тик торыгыз!
Тапланган намус кан белән генә юыла алыр.
Ш ә й т а н *(Гыйшык пәрәсткә).*
Бирешмәгез! Бирешмәгез!..
Г ы й ш ы к п ә р ә с т.
Нәрсә? Әллә...
Г а с к ә р и.
Менә нәрсә!..
*(Перчаткасын йөзенә бәрә.)*
Г ы й ш ы к п ә р ә с т.
Әйдә, әйдә, мин курыкмыймын атышудан.
Г а с к ә р и.
Әйдә!..
*(Чыгалар.)*
Ч и б ә р х а т ы н.
Зинһар, туктагыз! Икегезне дә мин бит сөямен!
Туктагыз, дим. Ах-ахх!..
*(Һуштан тая.)*

## II КҮРЕНЕШ

Х а т ы н н а р г р у һ ы бер таза и р н е чолгап алып, өстерәп керәләр. Аны кочалар, үбәләр. Икенче якта и р л ә р г р у һ ы бер бозык к ы з н ы өстерәп керәләр, кочалар, үбәләр. Чибәр хатын, урыныннан торып, хатыннар груһына катнаша. Р у х а н и л а р догалык, тәреләр, матислар күтәреп керә.

М у л л а.
Арзан бәһагә иман сатамын, иман сатамын!
Алганнар уңар, алмаган мордар, Аллаһы әкбәр!..
*(Дога кыла.)*

Һ а в а.
Арзан бәягә оҗмах билеты, индульгенция!
Алмаганнарга хәзерләдем мин инквизиция!
Р а в в и н.
Фәләстыйннан яңа гына килеп төшкән
Изге матиса, тозсыз маиа, милли маиа!
П о п.
Тимер тәре, көмеш тәре, алтын тәре,
Агач тәре, балчык тәре, бакыр тәре.
*(Чукына.)*

Халыкның кайсы сәдака бирә, кайсы тәре, маиа, индульгенция сатып ала.

Ю а н  б а й.
Минем белән тартышырга чәчең җитмәс,
Син бай булсаң, мин синнән дә баерак шул.
Ю к а  б а й.
Нәрсә дисең?!
Ю а н  б а й.
Без күп күргән синең ише яфрак астын,
Базар сиңа беткәнмени, эшлим дисәң!..
Ю к а  б а й.
Син шашкансың.
Ю а н  б а й.
Кайдан килгән доктор тагын, юләр балык!
Ю к а  б а й.
Туктагыз, дим!..
Ю а н  б а й.
Туктамасам нишләтерсең?..
В ә з и р.
И син, салам сыйрак! Мәхкәмә көчеге!
Хәзер килеп, гафу теләп, кулымны үп!
*(Нечкә түрә ашыгып килеп кулын үбә.)*
Син ни диеп минем яңа чирвигемне
Тәхкыйрь кылып, аягыма басып үттең?
Н е ч к ә  т ү р ә.
Ялган сөйли. Мине куып, үзе шунда...
В ә з и р.
Кем, нәрсә? Кем?!
Н е ч к ә  т ү р ә.
Билләһи, дөрес, зинһар, мине хур итмәгез!
Егерме ел хезмәт иттем тәхет өчен,
Чалбар төбем әйтеп тора, күрмисезме?

В ә з и р *(чалбар төбен карап).*
Әһә, әйе, шактый шома, көзге төсле,
Аның минем чирвигемә дошманлыгын
«Рәсми итеп» гаризада күрсәтерсез.
Г е н е р а л.
И!
*(Туташ белән үтеп барган офицерны туктатып.)*
Ни өчен син честь бирмәдең көчегемә!
Күрмисеңме муенындагы дәрәҗәсен?
Я ш ь о ф и ц е р.
Гаеп миндә!
*(Честь бирә.)*
Г е н е р а л.
Ә син ахмак! Гаскәр шәэнен кимсетәсең.
Тезлән хәзер, тәпиен үп!..
*(Офицер көчекнең тәпиен үбә.)*
Рөхсәт, бар кит!

## III КҮРЕНЕШ

М ө һ ә н д и с Я ә җ ү җ, М ә ә җ ү җ г ә машинаның серләрен күрсәтә. Х а л ы к кайнап йөреп тора. Б а й к а р ч ы к Я ш ь е г е т к ә сарылып керә.

Б а й к а р ч ы к.
Сылу егет, ай нурлары диңгез дулкынында
Сахиранә уйнап торган моң кичләрдә
Синең белән икәү бергә тын почмакта
Яшәрәсем килә синең кочагыңда!..
Я ш ь е г е т.
Гафу итегез, ханым-әфәнде!
Б а й к а р ч ы к.
Юк, юк! Янам, язгы назлы күбәләктәй,
Дәртле гыйшык утларында. Аһ, аһ, янам!..
Ал, ал мине кочагыңа! Аһ! Мин үләм,
Алтыннарым, җәүһәрләрем әрәм кала!..
Я ш ь е г е т.
Алтын, җәүһәр дисезме сез? Кайда алар?
Б а й к а р ч ы к.
Йөрәгемдә.
Я ш ь е г е т.
Ераграк икән шул.
*(Китмәкче була, карчык сарыла.)*

Бай карчык.

Юк, юк. Якын сиңа, якын, менә алар!
*(Алтыннарын бирә.)*

Яшь егет *(Алтыннарны алып, карчыкны кочаклап).*

Аһ, алтыным!..

Бай карчык.

Аһ!..

Чыгып китәләр. Таза ирне хатыннар бер-берсеннән тарталар, үзара талашалар, сугышалар.

Тук хатыннар бергә.

Миңа, миңа!.. Миңа!..

Беренче тук хатын.

Сөйгән ярым!

Таза ир.

Ха!..

Икенче тук хатын.

Матур ярым!

Таза ир.

Ха!..

Беренче тук хатын.

Әйдә, китик.

Таза ир.

Ха!..

Икенче тук хатын.

Кил, кил!..

Таза ир.

Ха!..

Барысы бергә.

Миңа! Миңа!..

Беренче тук хатын.

Колың булырмын.

Таза ир.

Ха!..

Икенче хатын.

Алтын түләрмен.

Таза ир.

Ха!..

Барысы бергә.

Миңа, миңа!..

Беренче тук хатын.

Зарыктырма!

Т а з а  и р.

Ха!..

И к е н ч е  т у к  х а т ы н.

Аһ, онытма!

Т а з а  и р.

Ха!..

Б а р ы с ы  б е р г ә.

Миңа, миңа!..

*(Тарткалашып-талашып, таза иргә сарылып чыгалар.)*

Д ә җ җ а л.

Мәэҗүҗ!
Ихтирагның бар серләрен төшендеңме?
Мөһәндистән башка аны эшләтергә,
Әйт, кулыңнан килә алырмы?..

М ә э җ ү җ.

Килер, тәфсир[1]!

Д ә җ җ а л.

Син ни дисең?

Я э җ ү җ.

Ихтыярың канун безгә.

Д ә җ җ а л.

Мөһәндис!
Тәхетләрнең тынычлыкта калуы өчен,
Сине асып үтерергә тиеш таптым.
Зурлап сине шул урында асачакмыз!

М ө һ ә н д и с.

Мине?! Ни өчен?!

Д ә җ җ а л.

Минем әмерем — катгый канун.

М ө һ ә н д и с.

Нинди гаебем, хыянәтем мине үлемгә
Хөкем кыла?! Мин бит әле шатлыгымны
Гаиләмә уртаклашып өлгермәдем.

Д ә җ җ а л.

Синең гаиләң — тәхет, ватан.

М ө һ ә н д и с.

Иҗатымда юкса мәкер сизелдеме?
Моны эшләп башкаларга әҗәл-үлем
Эзләсәм дә, кансызлыктан түгел иде...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

---

[1] Т ә ф с и р — аңлатып сөйләп бирү.

Киләчәктә киң җиһанны нахак канга
Батыруда сәбәп булып гаепләнсәм,
Ул гаепне сездән түгел, башкалардан,
Башкалардан күтәртергә тиеш идем.

Д ә җ җ а л.

Киң җиһанны кан силенә батырырга
Тик без генә, тик без генә хаклы аңа!..

М ө һ ә н д и с.

Ни өчен соң бу алтыннар, бу мәртәбә?
*(Алтыннар һәм нәшанын күрсәтә.)*

Д ә җ җ а л.

Тәхет, ватанга хезмәтең өчен.

М ө һ ә н д и с.

Ни өчен соң дар агачы мине көтә?

Д ә җ җ а л.

Белемең өчен.

М ө һ ә н д и с.

Белемем өчен?!
Ул чагында алтыныгыз, нәшаныгыз
Кире кайтсын үзегезгә, әмма минем
*(алтын, нәшанны ташлый)*
Хәятемә бау салучы хөр белемем!..

*(Машинага ташлана. Яәҗүҗ белән Мәәҗүҗ аны машина янына җибәрмиләр.)*

Д ә җ җ а л, Я ә җ ү җ, М ә э җ ү җ.

Ул безнеке!

Ш ә й т а н.

Син саттың, без алдык. Хи-хи-хи...

М ө һ ә н д и с.

Хыянәт, хыянәт, хәянәт!..

*(Төрле якка ташлана. Аны җибәрмиләр. Тоталар. Ул газаплана, шашына.)*

Д ә җ җ а л.

Үлгәндә, күкрәкләрен бизәп торсын,
Каһарманга лаек булган ул зур нәшан.
Үлгәндә, алтын көчен татып үлсен,
Сине зурлап без асарбыз, син Каһарман!..

*(Нәшанны күкрәгенә тагалар. Алтынны биленә асалар.)*

М ө һ ә н д и с.

Әфәнделәр, соңгы теләк, соңгы теләк!
Минем белән бергә-бергә сез аны да...

Д ә җ җ а л.

Юк, ул безгә кирәк.

Мөһәндис.
Коткарыгыз! Коткарыгыз!
*(Тезләнә.)*
Дәҗҗал.
Минем сүзем — катгый канун.
Мөһәндис.
Юк, юк, мин бетәм икән, сез дә бетегез!..
*(Машинага ташлана.)*
Дәҗҗал.
Ачкычы миндә.
Барысы.
Ха-ха-ха!..

## IV КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр, Газазил, Мәһди һәм башкалар.

Дәҗҗал.
Җәлладлар, хәзер торыгыз!

Җәлладлар, асар өчен, дар агачын хәзерли башлыйлар.

Мөһәндис *(гаять ачуланып, калтырап, җаны бугазына килеп, сәхнәнең алдына, Газазил, Мәһди торган якка килеп чыгып, тешләрен шыгырдатып, бармакларын гасәби кысып)*.
Әһә, шулаймы?.. Заид «т» белән нәкыйс «б»...
Юк, алай түгел. Нәкыйс «т» белән
*(Тәкрарлый.)*
Нәкыйс «җ», нәкыйс «т» белән нәкыйс «җ»...
Инде асыгыз!..
Газазил *(Мәһдигә)*.
Исеңдә тот, нәкыйс «т» белән нәкыйс «җ».
Мәһди.
Ике нәкыйстан заид туа.
Дәҗҗал.
Тәхет, ватан өчен җанын аямаган
Каһарманга лаек булган хөрмәт белән,
Ата-бабаң күрә алмаган зур дан белән,
Сине асарга боерамыз фәрман белән...

Җәлладлар асарга алып менәләр. Гаскәри һәм төрле-төрле тәкәллефләр ясала. Кул чабалар. «Ура», «виват» тавышлары.

Хайваннарны химая җәмгыяте әгъзасы.
Хайваннарны яклый торган җәмгыятьнең
Бер әгъзасы булуым белән, шуны әйтәм:

Урынсызга һичбер хайван кыйналмасын,
Сугылмасын, җан иясе рәнҗемәсен.
Җәбер, золым һәм үлемгә без чын дошман.
Дөнья йөзе чебен канын күрә алмасын.
Үтенеч шул синңа, җәллад, җәмгыятьнең:
Бау салганда, ак якасын буямасын!..

Д ә җ җ а л.

Руханилар, бу кешегә җиде оҗмах ишекләре
Бөтен килеш ул сәгатьтән ачык булсын!

Р у х а н и л а р.

Ачтык, тәкъсир!

Руханилар догалык бирәләр. Тәре үптерәләр. Маиа кисәге каптыралар. Оҗмах билетын муенына тагалар. Мәһди машинаның бер җебен кисә.

М ә һ д и.

Нәкыйс «т» киселде.

Г а з а з и л.

Катгый һөҗүм кирәк хәзер!
*(Чыгалар.)*

Д ә җ җ а л.

Сазчылар сазларын чалсыннар!..
*(Пауза.)*
Сазчылар!..

В ә з и р.

Уйнамыйлар, баш тарталар!

Д ә җ җ а л.

Сазларын ватыгыз! Үзләрен асыгыз!

*(Ерактан шау-шу, гөрләү, яман авазлар ишетелә. Туклар куркып калтырана башлыйлар, гаскәриләр тупларын төзиләр һәм башкалар.)*

Бу нинди тавыш? Бу нинди шау-шу?!

В ә з и р.

Тәкъсир, халык күтәрелгән. Монда киләләр.

Д ә җ җ а л.

Кем җөрьәт итәр сарайның тәхетен таптарга!
Әй сез, әрәмтамаклар, коралга!
Машинаны эшләтегез, ал ачкычын!

*(Машинаның ачкычын Мәәҗүҗгә ташлый, Мәәҗүҗ машина тирәсендә әйләнә. Туплар яңгырый, пулемётлар шалтырый, бомбалар ярыла.)*

М ә ә җ ү җ.

Кискәннәр. Машина эшләми!..

Д ә җ җ а л.

Әрәмтамаклар! Коткарыгыз! Коткарыгыз!

*(Башкалар качарга урын эзләп аптырап йөргәндә.)*
Аһ, сез качасыз, үзем барам.

Мәйданны тирә-яктан ачлар груһы чолгап ала. Туп тавышлары көчәя. Дәҗҗалга каршы Газазил сугыша. Ирек бау сала. Мәһдигә каршы Мәәҗүҗ сугыша. Мәхәббәт бау сала. Яәҗүҗгә каршы Дәббәтеларз сугыша. Бәхет бау сала. Барын җыеп бәйләп җиргә салалар. Тәхетләр, шкафлар, туплар, дарлар утта тар-мар килә.

Мәһди *(җыен үлек, җимерекләр өстенә басып байрак тотып)*.
Җиһан безнеке!
Барысы.
Хәят, хәят, хәят!..

Пәрдә төшә.

## АЛТЫНЧЫ ПӘРДӘ

### I КҮРЕНЕШ

Әгъраф. Уңда оҗмах. Сулда тәмуг. Уртада күгәреп беткән бик зур чаң. Чаңның теленә Вакыт утырган. Чаңның түбәсендә төрле төстәге утлар сүнәләр, кабыналар, тагы сүнәләр. Чаң акрын гына әйләнә. Тәмуг ут дулкыннарында ыжгырып кайнап тора. Оҗмах сүрелгән. Күңелсез һәм дәртсез күренә.

Вакыт.
Сәгать, көннәр үткән саен,
Атна, айлар алга атлый...
Еллар саны гасыр санын,
Артта калган гомерләрнең
Тирән эзен дәвер каплый...
Сәгать... көннәр... атна... айлар...
Еллар... Дәвер... Мең гасырлар
Сугыла чаңда, сугыла заман...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
*(«Даң» итеп мәһабәт бер суга.)*
Хәким.
Җир йөзендә яшәгәндә, дуслык, дидем,
Иман, дидем, золым, дидем, хаклык, дидем.
Адәм гакылын, фәрасәтен буйсындырдым.
Бусы булыр, ә монысы булмас, дидем.
Киң җиһанда яшәгәндә, белем, дидем,
Вөҗдан, дидем, нәфес, дидем, юкны эзләдем.
Калын-калын зур китаплар язып тордым;
Яңа юллар сызып торган зур китаплар.

Әйе, зур китаплар!..
Дөя кадәр зур китаплар...
Утлар чәчкән нык кануннар язып тордым.
Йөрәкләрдә ташкын булып шаулап аккан
Теләкләргә, әмәлләргә юллар сыздым.
Калын-калын зур китаплар язып тордым.
Әйе, зур китаплар...
Дөя кадәр зур китаплар...
Белем белән саф вөжданны туган итеп,
Җир йөзенә хәким итеп куймакчы идем.
Киң җиһанны шул нур белән нурландырып,
Калын-калын зур китаплар язып тордым.
Әйе, зур китаплар...
Дөя кадәр зур китаплар...
Ләкин Вакыт, ихтыярын ирекле итеп,
Минем көчле әмәлемә богау салды;
Богау салды юлларыма үлем сибеп.
Ләкин мәңгелеккә якты эзем җирдә калды.
Яңа юллар сызып торган зур китаплар.
Әйе, зур китаплар...
Дөя кадәр зур китаплар...

Җиһангир.
Дошман, дидем, бөтен җиһан дошман, дидем,
Дус эзләдем, әмма аны табалмадым.
Гөрзи орып, кылыч чабып юл эзләдем,
Ләкин аны кан эчендә табалмадым.
Арык-арык булып аккан адәм каны
Дәрья булды. Шул дәрьяда җилкән корып,
Җил-давылга карамастан йөзеп йөрдем.
Кан эчендә йөзеп йөрдем, көч күрсәтеп...

Хәким.
Юк, юк!..
Җир калдырган якты эзләрем яшәгән чакта,
Аның нурлары монда да иңәр. Мин аны көтәм.

Җиһангир.
Нинди нурлар?

Хәким.
Серле, тылсымлы, җил төсле көчле белем нурлары.

Җиһангир.
Алар җирдә юк.

Хәким.
Булырга тиеш. Җирдәге адәм яшәгән чакта,
Ул нурлар аңар һава шикелле кирәк булачак.

Н ә б и.
Рухани азык бирә алмаган белем утлары
Җанга баш булып яшәгән чакта киң җир йөзендә,
Эзләгәннәрен таба алмаслар җир угыллары.
Таба алмаслар, таный алмаслар үз-үзләрен дә.
Кем белә, бәлки, күптәннән алар, үз язмышларын
Чит кулга биреп, киң җир йөзеннән югалганнардыр;
Кем белә, бәлки, күптәннән алар, чын юлдан язып,
Тарихка каршы гыйсъян чыгарып җиңелгәннәрдер.
Х ә к и м.
Белем җиңелмәс, ул — мәңгелек ут, ул мәңге янар,
Мин көтәм аның җитмеш җиде мең галәмгә өстен
Булып чыгуын, мин көтәм аны, ул монда ашар.
Җ и һ а н г и р.
Хата, зур хата.
Белемгә каршы кылыч-гөрзиләр яшәгән чакта,
Ул баш була алмас үлем баш булган комсыз
җиһанда.
Х ә к и м.
Тик белем генә башлык итәргә тиеш җиһанда...
Н ә б и.
Игътикад, иман кара күкрәкне нурландырмаса,
Белемнең көче ялгыз башына берни кыла алмас.
Җ и һ а н г и р.
Юк ул игътикад, юк ул хак иман, юк ул чын белем,
Бар тик бер нәрсә:
Көч!..
Аны саклап күтәрелгән кылыч...
Менә ул канун, белем, игътикад һәм чын, саф иман.
Х ә к и м.
Дөньяга тормыш, гакылга ачкыч була алырлык
Зур китапларым яшәгән чакта яшәр адәмнәр.
Җ и һ а н г и р.
Юк алар!..

## II КҮРЕНЕШ

М а л и к, з о б а н и л а р һәм И с р а ф и л.

М а л и к.
И сез, Тәңренең садыйк коллары, зобанилары,
Тиз җиңелегез, сезгә Тәңредән зур фәрманнар бар.

Исрафил кычкырта. З о б а н и л а р тәмуглардан ут дулкыннары чыгарып җыелалар.

Зобанилар.
Ләббәйкә, тәкъсир, ләббәйкә, тәкъсир!
Малик.
Кодрәтле Тәңре гарше әгълада, ләүхелмәхфүзгә
Утлы сүзләрдән төзелгән катгый фәрманын сыза...
Зобанилар.
Сәмган вә таган, сәмган вә таган!
Малик.
Тәмугта мәңге янарга мәхкүм гөнаһкяр җаннар
Тәңрегә каршы алты тәмугта баш күтәргәннәр.
Алты тәмугта, ишетәсезме сез, алты тәмугта!
Җиденчесендә — менә монысында —
нинди хәлләр бар?
Зобанилар.
Бездә дә шул ук куркынычлы хәл...
Малик.
Ихтимал?
Зобанилар.
Шулай, тәкъсир.
Малик.
Тыңлагыз!
Менә хәзердән бар зобанилар, бөтен тәмуглар
Барлык көчләрен шул ихтилалга каршы куйсыннар.
Ут богаулары, ялкын таулары арттырсыннар!
Арттырсыннар соңгы чиккәчә җәза-газаплар.
Бу — Тәңремезнең катгый әмере!
Зобанилар.
Сәмган вә таган, сәмган вә таган.

## III КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Икенче зобани.

Икенче зобани.
Тәкъсир, әл әман. Ихтилалчылар безне кысрыклый,
Каршы торырга мәҗал[1] калмады.
Малик.
Кайда соң, кайда ялкын таулары, утлы гөрзиләр?
Икенче зобани.
Файда бирмиләр,
Файда бирмиләр аждаһаларның һәм гыйфритләрнең
Авызларыннан очкан агулы ялкыннары да.

---

[1] Мәҗал — көч, җегәр.

М а л и к.
Ләүхелмәхфүзнең катгый нык хөкемен күргән
булсагыз,
Тәңренең чиксез киң кодрәтенә иман итсәгез,
Тәмуг фетнәсен, фетнәчеләрен вәйран итегез!
З о б а н и л а р.
Мөмкин түгел.
М а л и к.
Нәрсә дисез?!
И к е н ч е з о б а н и.
Алар көчлеләр.
М а л и к.
Кемнәр?
И к е н ч е з о б а н и.
Гөнаһкярлар.
М а л и к.
Япәруар дикәр!..
И к е н ч е з о б а н и.
Соңгы вакытта җир хакимнәре фетнәчеләрне
Исәпсез-сансыз төркемнәр белән безгә озаттылар.
Менә шул җаннар уттан оешып җиңәләр безне;
Ярдәмгә диеп Газазил кәүмен җирдән көтәләр.
М а л и к.
Газазил кәүмен җирдән көтәләр?..
Ә ләүхелмәхфүз?!
Ләүхелмәхфүздә аңа ишарә күренгәне юк.
И к е н ч е з о б а н и.
Ләүхелмәхфүзнең катгый фәрманы йомшара бара.
Фетнәчеләргә каршы торырлык көч бетә бара.
М а л и к.
Бу ни сүз тагы?! Әллә югыйсә Тәңрегә каршы
Гыйсъян чыгарган мәлгуньнәр бармы сезнең
арада?
З о б а н и л а р.
Сөбханалла! Сөбханалла!..
И к е н ч е з о б а н и.
Гарше әгълага мәңгегә, тәкъсир,
садыйк колларбыз,
Ләкин ни чара, бездә көч кими һәр сулыш саен,
Фетнәчеләргә шыгрым тулдылар тәмугларыбыз,
Урын калмады аларга анда газаплау өчен.
М а л и к.
Яна тәмуглар хәзерләр Тәңре кодрәте белән,
Шунда салырсыз искеләренә сыймаганнарын.

## IV КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр, Гөнаһкяр һәм Өченче зобани. Бер төркем зобанилар, утлы гөрзиләр белән кыйнап, Гөнаһкярны алып керәләр.

Өченче зобани.
Тәкъсир, менә фетнәче җанга дүзәх төбендә
Урын калмады. Кайсы тәмугка рөхсәт итәсез аны салырга?
Малик.
Нинди гөнаһың, и гөнаһкяр җан, монда озатты?
Гөнаһкяр.
Гөнаһсызлыгым, бәни адәмгә чикләүсез булган
Саф мәхәббәтем җир оҗмахыннан монда озатты.
Малик.
Җирдә оҗмах юк. Көфер сөйлисең, гөнаһкяр бала!
Гөнаһкяр.
Җирдә чын оҗмах тудырыр өчен көрәшкән чакта,
Җир хакимнәре мине астылар дар агачына.
Малик.
Тәңредән башка оҗмах төзергә кем җөрьәт итә?
Кем, ламәкәнең, ләүхелмәхфүзнең теләкләренә
Каршылык кылып, Тәңрегә каршы фетнә күтәрә?!
Гөнаһкяр.
Без.
Малик.
Сез кемнәр?
Гөнаһкяр.
Адәмнәр.
Малик.
Кайда?
Гөнаһкяр.
Җирдә.
Малик.
Ялган!
Тәңренең сөйгән мотыйг коллары яшәгән чакта,
Булмас ул оҗмах Тәңре ваз кичкән киң җир йөзендә.
Оҗмах һәм тәмуг тик монда гына мәңге яшәрләр.
Гөнаһкяр.
Алар бетәрләр.
Киң җир йөзендә оҗмах булгач та, безнең туганнар
Мондагы тәмуг, зобаниларны вәйран итәрләр.
Малик.
Тәңренең яңа һәм зур тәмугларын әгәр күрсәгез,
Ялган уйлардан мәңгелеккә ваз кичәр идегез.

Тәхет-тәңрегә буйсынмаганнар — барысы шунда,
Кара кисәүгә әверелеп, шунда мәңге янарлар.

Гөнаһкяр.

Алар сүнәрләр.
Безнең туганнар ул тәмугларны тиздән күмәрләр;
Ирекле киң җирдә көрәш утлары балкыган чакта,
Аның каһарман көрәшчеләре монда күчәрләр.
Тәңрегә каршы көрәшер өчен, монда күчәләр.

Малик.

Оҗмахтан сөргән хур Газазилнең утлы уйлары
Зәһәрләп сезне Тәңре юлыннан адаштырганнар.
Җирдә ул булса, монда Хак Тәңре һәм аның хөкеме
Патшалык итә һәм мәңге итәр, гөнаһкяр җаннар.
Алып китегез, җәхимнең[1] тирән җитмеш җиденче
Соңгы катына салып куегыз, мәңгегә калсын!

Икенче зобани.

Анда урын юк.

Малик.

Боз богауларга богаулансын ул зәмһәрирендә!

Өченче зобани.

Анда урын юк.

Малик.

Дүзәхнең кайнап торган майлары кәбаб итсеннәр!

Беренче зобани.

Ул фетнәчеләр кулына күчте.

Малик.

Әллә югыйсә сез, җинаять байрагын тотып
Тәңрегә каршы, фетнәчеләргә кушылдыгызмы?

Зобанилар.

Сөбханалла, сөбханалла! Тотабыз без аның әмерен.

Малик.

Үзем табармын мин аңа урын!..

Суккалап алып китә. Зобанилар һәммәсе тарала. Тәмуг яңадан көчлерәк ыжгыра башлый.

Хәким.

Җир көрәшенең көчле дулкыны монда да күчкән.
Бу зар тормыштан котылу көне якынлап бара.
Җирдә ихтилал, җирдә үзгәреш, җир күтәрелгән.
Мөстәбидләрнең тәхет кануны ялкынлап яна.
Мин ялгышмадым, җирдә чакта ук шулай дип яздым,
Шулай уйладым; аңа ышандым: шулай булды да.

---

[1] Җәхим — тәмуг.

Җ и һ а н г и р.

Гыйсъян, ихтилал, фетнә, җәнҗаллар, нәрсә соң алар?
Әгәр дә мине кодрәтле Тәңре кылыч тоттырып
Җибәрсә җиргә, бер кизәнүдә юк итәр идем;
Таратыр идем фетнәчеләрнең илен туздырып,
Бар иде заман, үткен карашым, көчле кылычым
Күренгән чакта, каршымда торган барлык
дошманым
Җилдә төтендәй югала иде... Бар иде көчем,
Бетмәс гайрәтем, еракта, артта калдылар алар...
Шулай да булса, Тәңре боерса кайтырга җиргә,
Фетнәчеләрнең ал каннарыннан дәрьялар ясап,
Фетнә утларын сүндерер идем шул каннар белән.

Х ә к и м.

Ул заман үткән, батыр Җиһангир, ул кайтмас инде...

Җ и һ а н г и р.

Әйе, ул кайтмас... Әгәр дә чынлап җир угыллары
Гарше әгълага, ләүхелмәхфүзгә һөҗүм итсәләр...

Х ә к и м.

Минем мантыйкча, һөҗүм итәргә тиешләр алар,
Белем һәм гакыл Тәңредән өстен булырга тиеш.

## V КҮРЕНЕШ

Сигез морҗалы быргыдан гаршеләрне тетрәтеп кычкырта. Җ ә б р а и л, М а л и к, В и л д а н, Г ы й л ь м а н н а р, Х у р к ы з л а р ы, Ф ә р е ш т ә л ә р, Д и ю л ә р, П ә р и л ә р, Ж е н н ә р, З о б а н и л а р төрле яктан атылып чыгалар.

Җ ә б р а и л.

Вилдан, гыйльманнар һәм зобанилар тиз җыелсыннар,
Гарше әгъладан, ләүхелмәхфүздән фәрман китердем.
Барлык оҗмахлар, бөтен тәмуглар хәзер, шул сәгать,
Гадәттән тыш нык зур саклык белән сакта торсыннар.
Җирдә Газазил, җир әһлен җыеп Тәңрегә каршы
Фетнә чыгарып, гарше көрсигә һөҗүмгә килә.
Тәмуг көчләрен, зобаниларны шуларга каршы
Катгый көрәшкә хәзер торырга Тәңре боера!..

М а л и к.

Җиде тәмугның җидесендә ихтилал бара,
Тәмуг фетнәсен басарлык көч тә бездә калмады.

Җ ә б р а и л.

Ирек, Мәхәббәт һәм ялган Мәһди Газазил яклы
Соңгы көрәштә Дәҗҗал һәм Шәйтан кулга
төшкәннәр.

Гарше әгъланың кодрәт көрсие курку эчендә
Фетнәчеләрнең авазларыннан калтырап тора.
Белем байрагын дулкынландырып һава йөзендә,
Иксез көч белән җир әһле монда һөҗүмгә килә!..

Б а р ы с ы.
Сөбханалла, сөбханалла!..

Исрафил кычкырта.

Җ ә б р а и л.
Җир белән күкнең хәбәр юллары күптән киселде;
Ләүхелмәхфүзнең кодрәт каләме дәһшәттән сүнде.

Б а р ы с ы.
Сөбханалла! Сөбханалла!..

Җ ә б р а и л.
Әнә тыңлагыз, җирдә аваз бар. Юлга чыктылар.
Газазил, Мәһди алдан киләләр байраклар тотып.

## VI КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р һәм И к е н ч е з о б а н и.

И к е н ч е з о б а н и белән бергә б е р г р у һ з о б а н и л а р ашыгып керә.

И к е н ч е з о б а н и.
Әл әман, тәкъсир, каршы торырлык көчемез калмады;
Зәмһәрир[1] хәзер фетнәчеләрнең кулына күчте.

М а л и к.
И зобанилар, хәзер торыгыз катгый көрәшкә!
Җир әһелләре каты үч белән безгә киләләр…
Ачыгыз Каф, Нон, Каһәф тауларын, ут дәрьяларын;
Тиз-тиз чыксыннар гыйфрит, диюләр, җен һәм пәриләр!

Исрафил кычкырта. Барысы да чыгалар.

Х ә к и м.
Җир белән күкне берләштерергә җирдә чакта ук
Уйлаган идем, шул сәгать җитте, җир күкне җиңде.

Н ә б и.
Тәңре исеменнән низамнар төзеп йөрүем өчен,
Җир угылларына күренергә дә оялам.

---

[1] З ә м һ ә р и р – каты суык.

Җ и һ а н г и р.
Җирнең кылычы тәмуг гөрзиен җиңде бит, ахры.
Х ә к и м.
Җирнең белеме, үткен фикере Тәңрене җиңде.

Күк күкрәгән тавышларга охшаш авазлар; дию, пәри тавышлары, утлар, йолдызлар коела. Таулар ишелә. Оҗмахта утлар сүнә. Д и ю л ә р, Ф ә р е ш т ә л ә р, Х у р к ы з л а р ы, В и л д а н н а р, З о б а н и л а р качалар. Җир әһелләре, чыралар тотып, тәмуг һәм оҗмахларны басып алалар.

## VII КҮРЕНЕШ

Г а з а з и л.
Соңгы көрәштә без өстен чыктык.
Көчсез ля мәкян билгесез урынын калдырып
качкан!..
Ирекле җир өстен оҗмах ясадык... Яэҗүҗ,
Дәҗҗаллар
Юк анда хәзер, юк анда хәзер хуҗа һәм коллар.
Анда тигезлек, анда мәхәббәт, анда тик дуслык!
Соңгы көрәштә без өстен чыктык.
Бөтен тәмуглар сүндерелсеннәр һәм күмелсеннәр,
Җирдә һәм күктә тик оҗмах кына яшәргә тиеш.
Акыл, йөрәкне томалап торган богау-зынҗырлар
Җитмеш җиде мең галәм өстеннән күтәрелсеннәр!
Соңгы көрәштә без өстен чыктык!..
Бу булыр безнең иң соңгысы һәм...

## VIII КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р, М ә һ д и.

М ә һ д и.
Дуслар, туганнар, күңелсез хәбәр:
хәйләкәр Шәйтан,
Богаулы урынын калдырып, яңадан качкан!..
Г а з а з и л.
Ах, ычкынган!..
М ә һ д и.
Җиргә яңадан!..
Г а з а з и л.
Алга!..

Һәммәсе, чыраларын яндырып, яңадан җиргә китәләр. Мәйданда фәкать В а к ы т кына кала.

В а к ы т.

Сәгать, көннәр үткән саен,
Атна, айлар алга атлый…
Еллар саны гасыр санын,
Артта калган гомерләрнең
Тирән эзен дәвер каплый…
Сәгать, көннәр… атна… айлар…
Еллар… дәвер… мең гасырлар…
Сугыла чаңда, сугыла заман!..
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Авыр итеп бер мәртәбә суга.

П ә р д ә   т ө ш ә.

*1922–1923 еллар*

# АМЕРИКАН

*Комедия*

*Дүрт пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Апуш
Касыйм
Искәндәр
Самат
Зәйнәп
Нурия } студентлар.

Муса — электәге җәмәгать хадиме, татар киеменнән, жилет кигән.
Шәехмирза — элекке адвокат.
Габдуллаҗан — спекулянт.
Сәлим — тарихчы.
Насих Николаевич — мирза.
Сәлимгәрәй — электәге полиция чиновнигы.
Дилбәр — Мусаның кызы.
Мәйсәрә — Габдуллаҗанның кызы.
Разия — Габдуллаҗанның хатыны.
Нигъмәт — карт интеллигент.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Студентлар торагы.
I. Апуш, Касыйм.
Касыйм китап укып караватта ята. Апуш идәнгә ятып, җырлап плакат яза.

Апуш.

Без — коллык, наданлык дошманы,
Без — хөр студентлар ордасы.
Без яңа ил нигезен корабыз,
Без Совет өчен тайярларбыз!

Без бар, без яшь, яна бездә көч,
Билгебез китап, урак һәм чүкеч.
Бер, ике, өч; бер, ике, өч...

Касыйм. Шыңшыма әле, укырга уңайсызлыйсың.

Апуш. Син колакларыңа бармакларыңны тыгып тор... *(Яңадан җырлый башлый.)*

Без бүгенге көн җепләреннән,
Без киләчәккә юл сузабыз.
Без үткән көннәрне күмәбез,
Без тарих белән узышабыз.
Без бар, без яшь, яна бездә көч,
Билгебез китап, урак һәм чүкеч.
Бер, ике, өч; бер, ике, өч...

Плакатын күтәреп, җырлап чыгып китә.

Касыйм. Иртә җыр, кич җыр. Каян чыга бу кешедә бетмәс-төкәнмәс перманентный җыр. Ирек бирсәң, җырлап кына торырлар иде. Нәрсәгә дәртләнә торгандыр?!

II. Касыйм, Искәндәр һәм Самат.

Касыйм *(каршы барып).* Булдымы?

Самат. Юк.

Касыйм. Юк?

Самат. Әйе.

Касыйм. Ай, юри шаяртасыз, егетләр. Күзләрегездән күреп торам. Юк, чынлап, Искәндәр иптәш, булдымы?

Искәндәр. Юк.

Касыйм. Ничек юк?

Искәндәр. Шулай юк.

Касыйм. Нигә юк?

Искәндәр. Юкка күрә юк.

Касыйм. Нишләп инде ул алай юк?

Искәндәр. Юк.

Касыйм. Карагыз әле, егетләр, мин сезнең белән уйнап сөйләшмим.

Искәндәр. Без дә шулай ук синең белән шаярырга атлыгып тормыйбыз.

Касыйм. Бу ничек була инде?!

Искәндәр. Берничек тә булмый.

Касыйм. Самат, булмаса, син дөресен әйт.

Самат. Дөресе шул инде.

Касыйм. Юкмы?

С а м а т. Әйе.

К а с ы й м. Нигә юк, дим мин сезгә?!

С а м а т. Юкка күрә юк, дибез ләбаса без сиңа.

К а с ы й м. Ни өчен юклыгын аңлатыгыз, булмаса.

С а м а т. Ай Алла, тәмам урман чәере булдың лабаса. Юкны аңлыйсыңмы? Юк, юк, юк!

К а с ы й м. Аңламыйм да, аңлый да алмыйм.

С а м а т. Кызык!

К а с ы й м. Сезгә, бәлки, кызыктыр да, ә миңа кызык түгел. Төшенә алмыйм.

С а м а т. Искәндәр, булмаса, син төшендер.

К а с ы й м. Төшенә дә, аңлый да алмыйм.

И с к ә н д ә р. Аңларсың.

К а с ы й м. Аңламыйм. Чынлап әйтәм, аңлый алмыйм.

И с к ә н д ә р. «Юк» дигән сүзнең мәгънәсе саф татарча — юк, казакча — жок, русча — нет, немецча — найн, фарсыча — нист, украинча нема була, французча — ноң, гарәпчә — ля, инглизчә — ноу, латинча — нон эст, кытайча — мыйю. Инде аңладыңмы?

К а с ы й м. Аңлый алмыйм. Аңларга теләмим.

И с к ә н д ә р. Теләрсең.

К а с ы й м. Менә шул телләрдә «бар» дигәнне әйтеп чыксаң икән син миңа. Һе, юк, нет, найн, имеш. Аңлый алмыйм, чынлап аңлый алмыйм.

И с к ә н д ә р. Хәзер аңларсың. Дөньяда булмаган нәрсәгә «юк» диләр.

К а с ы й м. Аның булуы мөмкин түгел.

И с к ә н д ә р. Мөмкин.

К а с ы й м. Мөмкин түгел, чөнки дөньяда булмаган нәрсә юк.

И с к ә н д ә р. Ә, мин әйтәм, бар.

К а с ы й м. Юк.

И с к ә н д ә р. Бар.

К а с ы й м. Юк, юк, юк.

И с к ә н д ә р. Менә шул юклыкны аңлатып бир син миңа.

К а с ы й м. Юкны ничек итеп мин сиңа аңлатыйм?!

И с к ә н д ә р. Мин сиңа аңлаттым бит.

К а с ы й м. Нәрсә аңлаттың?

И с к ә н д ә р. «Юк»ны. Ха-ха-ха!

К а с ы й м. Чү әле, чү! Башымны катырма. Нәрсә турында сүз бара иде соң?

И с к ә н д ә р. «Юк»ны таптырып азаплансаң, үзеңнең дә юкка чыгуың бар.

К а с ы й м. Һе, юк диген... Ә мин сезгә ышанып торам тагын. Болай булгач, түгәрәкне таратабыз.

И с к ә н д ә р. Түгәрәк таралмас.

К а с ы й м. Болай булгач, таралмый хәле юк аның.

С а м а т. Кечкенә генә авырлыкка да каршы көрәшә алмагач, нинди совет студенты, ди, син.

К а с ы й м. Болай булгач, күрегез дә торыгыз, түгәрәк үзлегеннән таралачак.

И с к ә н д ә р. Ликвидаторлык белән миең чуалган синең.

К а с ы й м. Үзегез, юк, дисез бит.

И с к ә н д ә р. Юкны бар итә белергә кирәк.

К а с ы й м. Сүздәме?

И с к ә н д ә р. Эштә дә шулай булырга тиеш.

К а с ы й м. Амин!

И с к ә н д ә р. Синең теләкләреңә мохтаҗ булганыбыз юк әле.

К а с ы й м. Булырсыз әле, дөнья, диләр аны.

И с к ә н д ә р. Мохтаҗ булмабыз.

III. Ә ү в ә л г е л ә р һәм А п у ш .

А п у ш *(Касыймга).* Әй син, җебегән, чәй урыны да хәзерләмәгәнсең бит.

И с к ә н д ә р. Әзергә хәзер булырга өйрәнгән бит ул. Кая, китер монда.

К а с ы й м. Ни дигән сүзең инде бу?

И с к ә н д ә р. Стаканыгызны сөртеп бирергә рөхсәт итегез, Касыйм әфәнде.

К а с ы й м. Әй, калдыр әле шул мәгънәсез чәнечкеләреңне.

И с к ә н д ә р. Дөрес. Мәгънәле чәнечкеләр хәзерли башларга вакыт җитеп бара.

К а с ы й м. Ул вакытларны көтә-көтә, үзеңә кетәклеккә менәргә туры килмәсен.

И с к ә н д ә р. Безнең өчен кайгырырга сиңа туры килмәс.

К а с ы й м. Кем белә бит. Дөнья, диләр аны, дөнья...

И с к ә н д ә р. Сезнең дөнья буялган, ди, йонга.

К а с ы й м. Сезнеке, безнеке юк хәзер.

И с к ә н д ә р. Сезнеке — сезнеке, безнеке — безнеке әле. Аларны бер казанга салып кайнатмыйлар. Провокация җибәрмә.

С а м а т. Егетләр, белеп торыгыз, бу бүлмәдә актык чәйләрне эчәбез.

К а с ы й м. Ничек актык чәйләрне?

С а м а т. Беренче числодан студентлар өчен тулай столовой ачыласы, ди.

К а с ы й м. Алты айдан бирле ишетәбез лә без аны.

И с к ә н д ә р. Әйтеп бетер.

К а с ы й м. Нигә бәйләнәсең син миңа?

И с к ә н д ә р. Әйтеп бетер.

К а с ы й м. Әйтермен, куркып тормам. Тулай столовой, имеш. Көтегез, сезгә хәзерләп куйганнар, ди... Ул столовойлар ачылганчы, без дә монда булмабыз.

С а м а т. Дөрес. Сез булмассыз, әмма без булырбыз.

К а с ы й м. Булырлык булса, моңарчы булган булыр иде инде.

С а м а т. Аптырыйм мин сиңа, Касыйм. Бу ышанмаучылык сиңа каян килә?

И с к ә н д ә р. Каныңа сеңгән аның.

К а с ы й м. Ничек канына сеңгән?

И с к ә н д ә р. Картларның бүрене нихәтле кадерләсәң дә, урманга карый дигән сүзләрен ишеткәнең бармы?

К а с ы й м. Кем бакчасына атылган таш инде бу?

И с к ә н д ә р. Мулла бакчасына.

А п у ш *(пырхылдап көлеп җибәреп).* Шәп әйтелде бу, ха-ха-ха!..

К а с ы й м. Рәхәтләнеп чәй эчәргә дә бирмисез бит сез миңа. *(Торып китә.)*

А п у ш. А-а, гаҗәп четерек икәнсең!

И с к ә н д ә р. Нәрсәләрнең үз исемнәре белән атарга яратам мин.

К а с ы й м. Хуш, әйтеп бетер, үз исемнәре белән әйтеп бетер. Әйтеп бетер, дим мин сиңа!.. *(Стаканын идәнгә ташлый.)*

И с к ә н д ә р. Безне, туган, мылтык атып та куркыта алмадылар. Стакан ватып кына өркетмә син безне...

К а с ы й м. Соң, атамның муллалыгына мин гаеплемени?

И с к ә н д ә р. Синең мулла малае булуыңа әллә мин гаеплеме? Син, стакан ватып, атаңны барып куркыт, әмма безне түгел.

А п у ш. Шәп әйтелде, ха-ха-ха!

К а с ы й м. Ярый, бу мыскыл итүләрегезнең бер чиге булыр!.. *(Яный.)* Бер чиге булыр. *(Чыгып китә.)*

И с к ә н д ә р. Янама!

А п у ш. Кыланышларына карап гарьләнеп үләрсең.

С а м а т. Чит элемент башлары белән совет вузына

оялап алганнар да, нәсел-нәсәпләрен исләренә төшерергә дә ярамый.

Искәндәр. Бу тәти егетләрнең нервларын баса башларга вакыт.

Апуш. Кыланышлары белән тырнак тирләтәләр. Шул башы белән комсомолга керергә заявление биреп, комсомол билетын калкан итәргә маташтырып караган иде дә, барып чыкмагач...

Искәндәр. Гомерләренең кыскарганын сизенәләр алар.

Апуш. Чынлап та, революциянең дүртенче елында ни кыланган булалар бит!

Самат. Аның болай стакан ватып чыгуларының сере бар.

Апуш. Сере ачык: комсомолга үрмәләмәкче була.

Искәндәр. Серләрен сүтәрбез әле.

Апуш. Җыенысын себереп...

Ишек кагалар.

Искәндәр. Керегез!

IV. Әүвәлгеләр, Зәйнәп һәм Нурия.

Зәйнәп. Исәнмесез, иптәшләр!

Искәндәр. А-а, Зәйнәп, хуш киләсез!

Апуш. Әйтәм лә бүлмә нурланып китте, Нурия кергән икән.

Самат. Әйдәгез, иптәшләр, түрдән узыгыз, чәйдән рәхим итегез.

Зәйнәп. Рәхмәт.

Искәндәр. Чынлап, рәхим итегез.

Нурия. Без хәзер генә эчтек.

Зәйнәп. Без сезгә бер йомыш белән килгән идек.

Искәндәр. Чәй эчә-эчә сөйләшүе күңеллерәк була. Рәхим итегез!

Апуш *(бер кулына стакан, икенче кулына чынаяк асты тотып).* Стаканнанмы, тарелкасыннанмы? Теләгәнеңне сайла!

Нурия. Чынлап, эчәсем килми. Йомыш белән килгән идек.

Искәндәр. Чәй чәйләтә, йомыш йомышлата.

Апуш. Йомыш белән, дисеңме?

Зәйнәп. Тарих түгәрәге турында.

Искәндәр. Кечкенә мәсьәлә икән.

Нурия. Ничек, әллә булдымы?

И с к ә н д ә р. Юк.
З ә й н ә п. Юк?
И с к ә н д ә р. Сез чәй эчә-эчә сөйләшегез әле.
З ә й н ә п. Чынлап юкмы?
А п у ш. Әйе.
З ә й н ә п. Кызганыч.
С а м а т. Иптәшләр, без юк эшкә керештек бугай.
З ә й н ә п. Ничек юк эшкә?
С а м а т. Тарих түгәрәге дигән булып, юк материаллар эзләп вакыт уздырабыз. Безгә материаллары әзер фәннәрне ныграк үзләштерү файдалырак булыр.
Н у р и я. Анысы, әлбәттә, шулай. Ләкин бер башлаган эшне төпләмичә, урталыкта калдыруы да шәп түгел бит.
И с к ә н д ә р. Теге карт төлке, профессорны әйтәм, юк материаллар эзләтеп башны катырмыймы икән? Бүген Самат белән бармаган җирне, кермәгән көтепханәне калдырмадык. Әллә юри бирмиләр, әллә чынлап та юк инде. Менә хәзер генә шул материалларны эзләп аптырап, әлсерәп кайттык.
З ә й н ә п. Булмаган нәрсәләрне профессор эзләтеп азапламас. Материаллар бар. Профессор үзе дә белә алмаган бик кызыклы тарихи материаллар табарга юллар ачылып тора әле монда.
И с к ә н д ә р. Ничек?
З ә й н ә п. Кара, кара, колакларын торгызды, ха-ха-ха!
Н у р и я. Сез бу шәһәрдә зур спекулянт Габдуллаҗан дигән байны ишетеп беләсезме?
А п у ш. Кызын беләм, үзен юк.
И с к ә н д ә р. Кызы да бармыни?
А п у ш. Бар, диләр, үзем күргәнем юк.
З ә й н ә п. Менә шул Габдуллаҗан байда Идел һәм Кама буенда яшәгән борынгы халыкларның тарихларына бәйләнгән бик кыйммәтле тарихи материаллар саклана, ди.
И с к ә н д ә р. Алар аңа каян килгән?
З ә й н ә п. Нурия, сөйлә.
Н у р и я. Ул аларны, чехлар Казаннан качкан вакытларда, чехлар койрыгына тагылып качучы учёныйлардан эләктергән, диләр.
И с к ә н д ә р. Ничек эләктергән?
Н у р и я. Сакларга алып калып үзләштергән.
И с к ә н д ә р. Спекулянтка ул тарихи материаллар ни эшкә кирәк булган икән?
Н у р и я. Ул аларның бәяләрен бик яхшы белә, ди. Заграницага валютага сатам, дип тора, ди.

С а м а т. Спекулянт алданмас.

З ә й н ә п. Менә шул материалларны, әллә кайларга сатып олактырмас борын, түгәрәккә алырга кирәк.

И с к ә н д ә р. Әкият кенә түгелме икән соң?

Н у р и я. Әкият түгел. Бик яхшы тикшереп белдем. Моннан ике-өч йөз ел элек язылган кулъязма китаплар барлыгын да беләм.

И с к ә н д ә р. Алай булгач, бу эшне башкарып чыгаруны сиңа тапшырырга кирәк. Тикшергәнсең дә икән.

Н у р и я. Булмый. Әллә ничә сугылып карадым. Күрсәтми дә, каһәр.

И с к ә н д ә р. Нәрсә ди?

Н у р и я. Юк, дигән була.

И с к ә н д ә р. Бәлки, чынлап та юктыр.

Н у р и я. Бар дигәч бар инде. Баштарак үзем эшне боздым. Сатып алучы бар, дисәм, бәлки, күрсәткән дә булыр иде. Студент, дигәч, өеннән куып чыгарды. Мин инде аңа кабат бара алмыйм. Мине таный. Профессорга әйткән идем, ул үрле-кырлы сикерә. Ничек кенә булса да, ул материалларны кулга төшерергә кирәк, ди. Ул тарихи материаллар арасында Арслан хан заманыннан калган ярлыклар бар, ди. «Шаһнамә»нең моннан ике йөз сиксән ел элек язылган кулъязмасы барлыгын да тәгаен беләм.

И с к ә н д ә р. Чын булса, кызык мәсьәлә бу.

Н у р и я. Чын, чын.

И с к ә н д ә р. Чынлап кызык мәсьәлә бу... Иптәшләр, Зәйнәп, чәй эчә-эчә сөйләшик.

З ә й н ә п. Бик кыстагач, бер стакан эчми булмас, ахры.

И с к ә н д ә р. Менә шулай кирәк. Мин үзем дә кыстатмыйм, кыстатканны да яратмыйм. Чәй бетеп киткән ич монда.

Б а р ы с ы. Ха-ха-ха!

И с к ә н д ә р. Хәзер кайнарын китерәм.

З ә й н ә п. Юк, юк, рәхмәт, мин юри генә әйтәм.

И с к ә н д ә р. Чынлап әйтәм, кыстатканны яратмыйм.

Н у р и я. Йә иптәшләр, бу мәсьәләгә сез ничек карыйсыз?

С а м а т. Минемчә, бернәрсә дә чыкмас. Юкка вакыт кына әрәм итү булыр.

А п у ш. Милиция аркылы алдырып булмасмы икән?

Н у р и я. Булмый. Җиде кат җир астында яшереп тота, ди, ул аларны.

З ә й н ә п. Ул турыда профессор белән дә сөйләштек. Яхшылык белән алу юлларын табарга кирәк.

Искәндәр. Һе, сез дә сүз сөйлисез. Спекулянттан яхшылык белән алмакчы буласыз. Ул аларның акча торганын белсә, җанын биргәндә дә бушлай бирмәс.

Зәйнәп. Хәйлә белән, дигәнем.

Апуш. Ай, белмим. Спекулянтны хәйләләү җиңел булмас.

Искәндәр. Кызык, бик кызык... Бу турыда уйларга кирәк.

Самат. Минемчә, бу эштән берни дә чыкмас. Юкка вакыт әрәм итеп, көлкегә генә калырга мөмкин.

Искәндәр. Булырлык булса, вакыты чорт с ним. Көлкегә калсак, анысы начар.

Зәйнәп. Шаулап-шаулап та, шуны булдыра алмасак, көлкегә дә калырбыз шул. Минемчә, бу эшне юлда калдыру ярамый. Искәндәр, син ничек уйлыйсың?

Искәндәр. Нурия әйткән материаллар чынлап та бармы икән соң?

Нурия. Бар, дим ич инде. Башка материалларның йөгенә кермәстән, Арслан хан заманыннан калган ярлыклар белән «Шаһнамә»нең иске кулъязмасы барлыгын тәгаен беләм.

Искәндәр. Тәгаен беләсең?

Нурия. Тәгаен беләм.

Искәндәр. Ничек, каян беләсең?

Нурия. Әйтсәм әйтим инде, Габдуллаҗан асравы — минем апамның дусы. Шуның аркылы белдем.

Самат. Тарихи материаллар белән кызыксынучы хатынның Габдуллаҗан байда асрау булып торуына ышана алмыйм.

Нурия. Миңа ышанасызмы, Самат иптәш?

Самат. Ышанам. Ләкин бит сез үзегез ул материалларны күрмәгәнсез.

Нурия. Ул турыда күңелегезне тыныч тотыгыз. Материаллар бар. Тик аларны вакытында кулга гына төшерергә кирәк.

Зәйнәп. Искәндәр, син ничек уйлыйсың?

Искәндәр. Бу, — бер яктан караганда, бик кызык эш. Ләкин ул эшләр артыннан йөрергә минем вакытым юк.

Нурия. Сез ничек, Самат иптәш?

Самат. Мин бу эшкә ышанмыйм.

Зәйнәп. Сез, Апуш иптәш?

Апуш. Бу эшкә профессорның үзен җигәргә кирәк.

Зәйнәп. Әй, боларның кулларыннан эш киләмени! Әйдә Сәлимнәргә...

И с к ә н д ә р. Туктагыз! Апуш белән Саматка үз исемемнән сөйләргә хак биргәнем юк әле. Бу — бер, икенчедән, бу эштә ашыгырга ярамый. Уйларга, уйларга, тагы бер кат чынлап уйларга кирәк. Сәлимнәр, дисез.Сәлимнәр булдыра алганны без дә булдырырбыз ла анысын. Эшне моннан башласак, ничегрәк булыр икән?..

З ә й н ә п. Йә, йә!

И с к ә н д ә р. Һәрбер мещан төтен җибәрергә, мактанырга ярата. Аларның ул ахмаклыкларыннан да, бәлки, берәр эш чыгып куяр. Моның өчен безгә модный бер зур кеше ясап чыгарырга кирәк.

С а м а т. Ни сөйлисең син?

И с к ә н д ә р. Сабыр. Ул зур кеше, бердән, хак мөселман булырга тиеш, икенчедән, каяндыр ерактан килгән булырга тиеш. Өченчедән, аның нindидер бер дәрәҗәсе булырга тиеш.

А п у ш. Тиешләрең күбәебрәк китте, Искәндәр.

И с к ә н д ә р. Сабыр. Үз арасында булмаганны борынгы халык күктән көткән. Ә хәзерге бездәге мещаннар заграницадан көтәләр. Әнә Габдуллаҗан бай да тарихи материалларны заграница өчен саклый, дисез бит.

С а м а т. Заграницалар турында уйлый торган булса, ул спекулянттан ераграк булыгыз. Әллә нинди хәтәр эшләргә эләгеп, совет студенты дигән зур исемгә каралык китермик. Сак булыгыз, иптәшләр!

И с к ә н д ә р. Тышкы кыяфәткә, койрыклы сүзләргә алданмаган мещанның дөньяга туганы юк әле. Бая әйткәнчә, алар көтәләр. Нәрсә көткәнлекләрен үзләре дә белмиләр. Мещан, спекулянт халкы алдашырга нихәтле оста булсалар да, читтән килгән «зур» кешеләргә, в кавычках, шулай ук тиз алданалар. Бу турыда чынлап, ныклап уйларга кирәк.

С а м а т. Теләсәгез ни әйтегез, иптәшләр, бу эш була торган түгел. Каникулыгызны юк артыннан йөреп әрәм итмәгез. Әнә профессор үзе йөрсен. Хәзер лекцияләре дә юк. Барыбер Идел буенда балык тотып ята.

З ә й н ә п. Тарих түгәрәген таратыргамыни?

С а м а т. Әллә нинди шикле спекулянтның кулындагы төтен материалларга нигезләнгән түгәрәкнең булуыннан булмавы артык.

Н у р и я. Аны соң башта нигә уйламадыгыз?

А п у ш. Юк, юк, иптәшләр, түгәрәкне таратмыйбыз, таратмыйбыз!

Искәндәр *(кинәт бик каты кычкырып).* Эврика!..[1]

Зәйнәп, Нурия *(куркышып).* Ah!..

Апуш. Ни булды сиңа?

Искәндәр. Эврика!

Барысы. Нәрсә?

Искәндәр. Булды, иптәшләр, булды!

Барысы. Нәрсә булды?

Искәндәр. Түгәрәк өчен кирәкле тарихи материалларны кулга төшерү өчен юл табылды.

Апуш. Юл?

Искәндәр. Юл түгел, план.

Нурия. План?

Искәндәр. План түгел, мәзәк.

Самат. Мәзәк?!

Искәндәр. Юк, юк, мәзәк тә түгел, әкәмәт.

Зәйнәп. Әкәмәт?

Искәндәр. Әкәмәт тә түгел, теге ни… теге ни… фокус!

Барысы. Фокус?

Искәндәр. Юк, фокус та түгел, теге ни… ни… бар бит әле… үзегез дә беләсез бит инде. Теге ни, аты коргыры… *(Бер кулын югары күтәреп, бармакларын шартлатып эзли.)* Ә, булды… Апуш, пәрәмәч ашыйсың киләме?

Апуш. Юк.

Искәндәр. Алдалыйсың… *(Корсагына төртә.)*

Апуш. Чү әле.

Самат. Нәрсә дуракланасың!

Искәндәр. Шулай, дисеңме? *(Корсагына төртә.)*

Самат. Нишләттең?

Зәйнәп. Болай мыскыл итәрсез дип уйламаган идек. Әйдә, Нурия.

Искәндәр *(кызларга ташланып)*. Зәйнәп! Нурия! Шатлыктан, җир йотсын, шатлыктан гына!.. *(Эчләренә төртмәкче булып кизәнә.)*

Зәйнәп. Нишлисең, Искәндәр?!

Искәндәр. Гафу итегез, йөз, мең, миллион кат гафу итегез.

Нурия. Нигә безне мыскыл итәсез!.. *(Кычкырып җибәрә.)*

Зәйнәп. Әнә кешене елаттыгыз ич. *(Кычкырып еламсырап җибәрә.)*

---

[1] Эврика — таптым.

С а м а т. Бу ни хәл, иптәшләр?!

А п у ш. Нигә елыйсыз, ха-ха!

С а м а т. Нишләттең син аларны?

И с к ә н д ә р. Мин, мин берни дә эшләтмәдем.

С а м а т. Йә-йә кызлар, елагыз инде, алайса.

И с к ә н д ә р. Зәйнәп, Нурия! Габдуллаҗан спекулянттан тарихи материалларны акчасыз алырга юл таптым.

З ә й н ә п. Ә?.. Чынлап әйтәсеңме?

Н у р и я. Алдамыйсыңмы?

И с к ә н д ә р. Ике-өч көннән тарихи материаллар, ярлыклар, иске кулъязмаларга үзегезне күммәсәм... күммәсәмме... күммәсәм...

Н у р и я. Һаман мыскыл итеп бездән көлә. *(Еларга җыена.)*

И с к ә н д ә р. Бетте, актык сүз. Монда килегез. Апуш, син минем ярдәмчем булырсың. Башка бер кеше дә кирәк түгел. Тыңлагыз!

Б а р ы с ы. Йә?!

И с к ә н д ә р. Тыңлыйсызмы?

Б а р ы с ы. Йә, йә!

И с к ә н д ә р *(уртага басып).* Американ!

Б а р ы с ы. Нәрсә?!

И с к ә н д ә р. Американ.

С а м а т. Нәрсә, итекме?

И с к ә н д ә р. Түгел.

З ә й н ә п. Читекме?

И с к ә н д ә р. Түгел.

А п у ш. Автомобиль?

И с к ә н д ә р. Түгел.

Б а р ы с ы. Нәрсә соң?

И с к ә н д ә р. Американ!

З ә й н ә п. Ә?..

Н у р и я. Ни соң?

С а м а т. Нәрсә?

А п у ш. Кем?

И с к ә н д ә р. Мин!..

Б а р ы с ы. Син? Ха-ха-ха!..

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уртача җыйналган кабинетка охшашлы бүлмә.

I. Муса ялгызы.

Муса *(ишектән карап).* Анасы, анасы, пәрәмәчне карап пешерегез. Итен, маен кызганмагыз. Кунак ни җитте кеше түгел, Америка профессоры. Ишетегез, пөхтә булсын. Хуш. Бу профессор Америкадан нинди максат белән килде икән? Хөкүмәт эшләре беләнме икән әллә? Юк, юк, тәгаен өйләнергә килгәндер. Америка никадәр шәп булса да, тәрбияле милли кызлар юк шул анда. Бу инде үзе татар булгач, татар кызына, ягъни милли туташка өйләнүне тиеш тапкандыр, күрәсең. Туп-туры миңа килүе мәсьәләне тагын да мөһимләштерә. Шулай ук минем шөһрәтем Америкага кадәр барып җиткәнме икәнни? Хәер, гаҗәп түгел. Җитсә дә җитәр шул. Милләт өчен кулдан килгән кадәр эшләдек инде, Алла кабул гына итсен инде. Большевиклар гына кадерне белмәделәр. Әнә укыган, тәрбияле, абруйлы кеше Америкадан торып кадеребезне белгән. Ай, бу мәдәният бик зур нәрсә шул. Хуш. Бу хакта кызым белән сөйләшеп алырга кирәк. Хатын-кыз бит ул ахмак була. Дилбәр, Дилбәр кызым, монда чык әле. Әгәр дә эшләр теләгәнчә барып чыкса, Аллаһныкын белмәссең. Баба булып Америкага да барып куярсың шул. Әйе, әйе, һәр эш Хода кулында инде.

II. Муса, Дилбәр.

Дилбәр. Нәрсә, әткәй?
Муса. Кызым, якынрак кил.
Дилбәр. Нәрсә, әткәй?
Муса. Озакламыйча, кызым, безгә Америка профессоры киләчәк.
Дилбәр. Беләм, әткәй. Тиз килерме икән соң?
Муса. Берәр сәгатьтән килергә тиеш. Кызым, профессор хәзрәтләре өйләнмәгән кеше икән.
Дилбәр. Өйләнмәгән?!
Муса. Әйе, өйләнмәгән. Монда килүенең максаты: тәрбияле, укыган милли туташка өйләнү булса кирәк. Менә инде башлап безгә кунак булып килүендә сер булырга кирәк.
Дилбәр. Сер?!
Муса. Әйе, сер.
Дилбәр. Соң ул...

М у с а. Сабыр, сабыр. Ул сер, минем уйлавымча, син булырга кирәк. Әгәр дә күңеленә ошасаң, бәлки…

Д и л б ә р. Әткәй, син мине оялтасың.

М у с а. Мондый чакта ата белән кыз арасында оят булмый. Мин бит, ахры, синең бәхетең өчен тырышам. Әгәр дә чәчләрегез бәйләнгән булса, бәлки, киявебез профессор белән миңа да Америкага китәргә туры килер. Менә шуның өчен профессор алдында үзеңне яхшы тот. Теге Пётр Иванич кызыннан өйрәнгән тәртипләреңнең барысын да яса. Ул, татар булса да, Америка зыялысы инде. Күрешкәндә, ничек әле, болай итәсезме әле? *(Посып күрсәтә.)* Шулай посып күрешерсең. Йә, эшләп кара, кара әле.

Дилбәр реверанс ясый.

Яхшы, күркәм чыга икән. Башыңны бераз күтәрә төш. Йә, яңадан эшләп кара.

Дилбәр реверанс ясый.

Посканда, менә шулайрак поссаң, матуррак чыгар төсле *(посып күрсәтә).* Йә, тагын бер посып күрсәт.

Дилбәр реверанс ясый.

Әһә, бәрәкалла, яхшы, күркәм, милли булып чыга. Сөйләшкән чакта, шулай кулларыңны күкрәгеңә куеп тот. Теге сурәттәге кызлар төсле. Күзләреңне зур итеп ачып, югарыга карап тор. Милли булсын. Ул, бердән, тәгъзим галәмәте, икенчедән, килешле булып чыга. Күлмәгеңнең иң модныен ки. Хәер, өстеңдәге ярарлык икән. Энҗе, алтыннарыңны барысын да ас, ислемаеңны кызганма. Тешләреңне яхшылап щёткалап ю. Ис килмәсен. Алай-болай… эһем… эһем…

Звонок.

Чү, килделәр бугай. Бар, чакырмыйча чыкма! Милли гадәтләреңнең барысын да кылырсың. Бар, бар!..

Д и л б ә р чыга.

III. М у с а, И с к ә н д ә р һ ә м А п у ш.

А п у ш. Профессор хәзрәтләре боердылар.

М у с а. Хуш киләсез. Мәрхәбә, таныш булыйк. Муса Мәхмүди сабыйк җәмәгать хадиме.

И с к ә н д ә р. Чикаго дарелфөнүненең профессоры. Нью-Йорк академиясенең әгъзасы, профессор Булат Сон.

М у с а. Сезне ханәбездә күрү белән бәхетлебез, әфәндем. Боерыгыз! *(Урын күрсәтә.)*

И с к ә н д ә р. Рәхмәт. *(Төртә.)* Гафу итегез, мин шулай.

М у с а. Әйе, әйе, тәкәллефсез булуыгызга бик шат... Профессор хәзрәтләре, сез безнең шәһәребездә озак калырга уйлыйсызмы?

И с к ә н д ә р. Эшләрем тәмам булганчы калырмын дип уйлыйм.

М у с а. Гафу итегез, хөкүмәт эшләре беләнме, әллә?..

И с к ә н д ә р. Һәм хөкүмәт, һәм фән, һәм тарих, һәм... һәм...

М у с а. Бәрәкалла, бик гүзәл, бик күркәм.

И с к ә н д ә р. Муса әфәнде, исемегез шулай шикелле.

М у с а. Бәли, бәли.

И с к ә н д ә р. Муса әфәнде, мин сезне дә, гаиләгезне дә Америкада чагында ишетеп белгән идем.

М у с а. Ә, әйе, бик рәхмәт. Мин бик шат. Мин үзем дә, сез килер алдыннан гына, шулай уйлаган идем.

И с к ә н д ә р. Муса әфәнде, мин сезнең әткәгезне дә беләм. Ягъни ишетеп беләм.

М у с а. Әйе, әйе, мәрхүм шактый мәгълүм кеше иде.

И с к ә н д ә р. Мин сезнең белән якыннан дуслашасым килә. *(Торып, кулын сузып төртә.)* Гафу итегез!

М у с а. Бик рәхмәт. Мин бик шат.

И с к ә н д ә р. Шәһәрегездә Габдуллаҗан исемле спекулянт бар икән.

М у с а. Әйе, бар. Карун дәүләтенә малик кеше инде. Бик саран, ахмак бәндә.

И с к ә н д ә р. Менә шул Габдуллаҗан спекулянтта Арслан ханнан калган тарихи ярлыклар бар икән. Сезнең шул хакта хәбәрегез юкмы?

М у с а. Әйе, бар, дип әйтәләр. Ләкин үз күзем белән күргәнем юк. Ул аларны һичбер кемгә күрсәтми.

И с к ә н д ә р. Шулай дигәннәр иде. Хәер, ул мәсьәлә минем өчен мөһим түгел. Минем башка зуррак эшләрем бар. Муса әфәнде, бер стакан кайнар су булса, мин бик шат булыр идем.

М у с а. Бәлки, чәй эчәрбез?

И с к ә н д ә р. Лимон белән булса, мөмкин.

М у с а. Була, була. Рәхим итегез, менә бу әфәнде сезне пәрәмәч ярата дигән иде.

И с к ә н д ә р. Аһ, бик, бик!.. Беләсезме, Муса әфәнде, минем иң яраткан ашым пәрәмәч инде. Һичбер риясыз,

бик яратам. Шул яраткан ашымны егерме ел ашаганым юк. Россиягә килгәч тә, берьюлы егерме пәрәмәч ашап бетерергә ант иткән идем. Үзегез уйлап карагыз. Егерме ел бит, егерме ел. Сөйгән ашым, милли пәрәмәчебезне ашаганым юк.

Муса. Сез Америкада егерме елдан бирле торасызмыни?

Искәндәр. Әйе, егерме ел. Мин унбиш яшемдә Америкага барган идем.

Муса. Кыяфәтегез, тфү, тфү, күз тимәсен! Бик яшь әле.

Искәндәр. Без, америкалылар, тиз картаймыйбыз. Һи-һи-һи... *(Төртә.)* Гафу итегез! Әйе, гимнастика белән бик нык маташабыз.

Муса. Сез бик күңелле кеше икәнсез, профессор хәзрәтләре. Гафу итегез, мин хәзер. *(Чыга.)*

Апуш. Сайрый беләсең, малай. Көлмичә чыдап булса ярар иде. Син ул корсакка төртүеңне куй. Килешми...

Искәндәр.Тес-с-с!..

Муса керә.

Муса. Менә рәхим итегез, чәй. Сез, бәлки, кофе яисә какао тели торгансыздыр?

Искәндәр. Юк, рәхмәт. Мин үзебезнең Россиянең милли чәен сагындым.

Муса. Бәрәкалла, бәрәкалла. Газиз милләтебезне онытмаган икәнсез. Ә безнең эшләр монда тәмам чуалды. Бу әфәнде, шаять, үз кешебездер?

Искәндәр. Үз кешебез, сез аңар ышаныгыз.

Муса. Афәрин, афәрин. Дөньяда үз акылларында калган кешеләр дә бар икән әле.

Искәндәр. Ул да милли пәрәмәчебезне бик ярата икән.

Муса. Ә, әйе, пәрәмәч. Гафу итегез! *(Чыга.)*

Апуш. Пәрәмәче җитәрлек булырмы икән? Бик ашыйсы килә бит, малай. Тамакны туйдыргач та, тизрәк моннан сызарга кирәк.

Искәндәр. Тес-с-с!..

Муса яңадан керә.

Муса. Менә инде милли пәрәмәчебез... Рәхим итегез!

Искәндәр. Әйе, милли пәрәмәч. Мин инде тансыкка күбрәк ашармын. Сез гаепләмәгез. Апуш әфәнде, рәхим итегез. Миңа инде үз өемдәгечә иркенләп утырыр-

га рөхсәт итегез. Сез миңа, Муса әфәнде, бик ошадыгыз. Пәрәмәчегез дә бик ошады.

Муса. Рәхмәт илтифатыгызга. Сез дә миңа бик ошыйсыз. Никадәр күп ашасагыз, шулкадәр безне якын күргән булырсыз. Җитешегез.

Искәндәр. Рәхмәт.

Муса. Сез Американың кайсы җиреннән, шәһәреннән сәфәргә чыктыгыз?

Искәндәр. Пәрәмәч шәһәреннән. Ә... ни, Чикаго шәһәреннән.

Муса. Һавалар ничек калды?

Искәндәр. Яхшы.

Муса. Сәяси хәлләр ничек?

Искәндәр. Яхшы.

Муса. Профессор хәзрәтләре, бу бездәге Советлар хакында Американың фикере ничек?

Искәндәр. Төрлечә.

Муса. Тиз бетәрләрме икән инде?

Искәндәр. Нәрсә?!

Муса. Җитешегез, җитешегез!.. Ә, монда беткән икән. Кайнарын китерик.

Искәндәр. Рәхим итегез, бигрәк ләззәтле пәрәмәчләр икән.

Муса. Милли нәрсәләр ләззәтле була инде ул, профессор хәзрәтләре.

Искәндәр. Шулай була икән.

Муса чыга.

Апуш. Ну, пәрәмәче, малай! Тагы бер егермене сыпырырмын, ахрысы. Әллә кунарга да калыйкмы икән? Яхшы кешегә охшый.

Искәндәр. Тес-с-с!..

Муса керә.

Муса. Менә кайнары да булды. Зинһар, сез ашый күрегез инде, ашагыз.

Искәндәр. Рәхмәт.

Муса. Профессор хәзрәтләре, шәһәребезнең могтәбәрләреннән сезнең белән танышырга теләүчеләр бар иде. Әгәр сез кабул итсәгез, бүгенге кичәбез бер гыйльми кичә төсен алыр иде.

Искәндәр. Комиссарлармы?

Муса. Юк, юк. Аларны без, әһем, әһем... Хода сакласын! Ул халык белән Хода каберләрне янәшә итә күр-

мәсен инде. Мин әйткән кешеләр — игътибарлы, абруйлы, чын кешеләр. Шәһәребезнең голәмәсе, могтәбәр милли байлары.

Искәндәр. Ярый, бик яхшы. Мин каршы түгел. Ләкин бүген кабул итә алмыйм. Шулай да иң якын һәм иң могтәбәр кешеләрегездән бер-икесен кабул итәрмен.

Муса. Ярый, ярый. Иң могтәбәрләреннән бер-икесен генә чакыртырмын. Әйе, алар хәзер килеп җитәрләр. *(Чыга.)*

Искәндәр. Ул бозау башларның эч серләрен белергә кирәк. Мин алар белән сөйләшкәндә, күз алдымда торма. Теге Габдуллаҗан бай нигә озак килми икән? Соң син аңар әйттеңме?

Апуш. Әйткән идем... Пәрәмәче җитәрме икән, малай?

Искәндәр. Җитмәсә, милли кабартмасын сорарбыз.

Муса керә.

Муса. Гафу итегез, сезнең чәйләрегез беткән икән. *(Стаканнарны алып чыга.)*

Апуш. Каеш кыса башлады, малай. Мин бу бичара мәхлукны кызгана да башладым инде.

Искәндәр. Зарар юк, зур эшләр корбансыз булмый.

Муса керә.

Муса. Рәхим итегез, профессор хәзрәтләре. Профессорлык хезмәтен күптәннән алып барасызмы?

Искәндәр. Биш елдан бирле.

Муса. Шактый бар икән. Бер дә ишетелмәгән иде.

Искәндәр. Бу соңгы елларда хәбәрләшү мөмкин түгел иде бит.

Муса. Дөрес, дөрес, мөмкин түгел иде. Нинди фәннәрдән дәрес бирәсез?

Искәндәр. Һәммәсеннән дә.

Муса. Америкада сездән башка тагын мөселман профессорлары бармы?

Искәндәр. Хәзергә юк әле. Бер-ике елдан булырлар. Бер үзбәк, бер төрек, яңадан бер татар профессорлыкка хәзерләнә калдылар. Моннан сау-сәламәт кайтып булса, мин аларны профессор итәргә тырышачакмын.

Муса. Тырышыгыз инде, профессор хәзрәтләре, тырышыгыз, милләтебез профессорларга бик мохтаҗ... Ә-ә... Мин сезгә кайнарын китерим. *(Чыга.)*

Апуш. Туям бит, малай.

Искәндәр. Алаймы, әһе.

Муса керә.

Муса. Менә кайнарыннан рәхим итегез. Профессор хәзрәтләре, сезнең ата-анагыз исәннәрме?

Искәндәр. Мәрхүмнәр.

Муса. Нинди кәсептәге кешеләр иде?

Искәндәр. Әткәй, мәрхүм, инглиз флотында капитан иде. Ә әнкәй, әнкәй... Әнкәй әткәйнең хатыны иде.

Муса. Бик яхшы, бик яхшы, сезнең асылыгыз зат каннардан икән.

Искәндәр. Әйе.

Муса. Үзегезнең ничек, рәфикагыз бармы?.. Ягъни хатыныгыз бармы?

Искәндәр. Юк.

Муса. Туры килмәдемени?

Искәндәр. Әйе, чөнки, чөнки Америкада безнең татарлардан зыялы гаиләләр юк. Ә мин үземә милли рәфика, ягъни татар кызын рәфика итәргә ант иткән идем. Үзегезгә билгеле, антны бозу – гөнаһ. Аннан соң мәрхүм әткәй белән әнкәйнең васыятьләре дә шулай иде. Хатының милли булсын, дип кычкырып үлделәр.

Муса. Бәрәкалла, бәрәкалла. Инабәтле нәселдән икәнсез. Ә менә бездә сез эзләгән, ягъни сез теләгән милли туташлар бар инде.

Искәндәр. Тәрбияле, милли туташларга кияүләр дә күптер инде.

Муса. Юк шул, юк. Берәү дә калмады, чөнки могтәбәр гаиләләрнең егетләре чехлар, колчаклар белән китеп беттеләр. Хәзерге вакытта бездә яхшы, игътибарлы кияүләргә ихтыяҗ бик зур. Әйе, ифрат зур инде. Рәхим итегез, пәрәмәчтән җитешегез! Ә, профессор хәзрәтләре, минем бердәнбер кыз балам бар. Әгәр дә теләсәгез, мин аны сезнең белән таныштырыр идем. Бик тәрбияле бала инде. Профессорларга ихласы бик зур. Шигырьләр язарга да булдыра. Аш-суга да осталыгы бар.

Искәндәр. Шулаймы? Чыгар монда. *(Төртә.)* Ә... Гафу. Мин бик шат булыр идем. Милли туташларыбызның йөзләрен күрмәгәнгә егерме ел булды бит инде.

Муса. Алай булса, мин хәзер. Хәзер... Дилбәр, Дилбәр, кызым, монда чык әле. Хиҗапны ташлату турында бик каты көрәштем. Аны сезгә һәркем дә әйтер. Мин башта ук, туганда ук хиҗапка каршы идем. Бала чагымда ук әнкәй мәрхүмнең яулыгын башыннан тартып ала торган булганмын. Һи-һи-һи!..

Искәндәр. Милләтебез сезнең шикелле зыялы аталар белән мактана торгандыр.

Дилбәр керә.

IV. Әүвәлгеләр һәм Дилбәр.

Дилбәр. Нәрсә, әткәй?.. Аһ, пардон, мусио, гафу итегез. *(Реверанс ясый.)*

Муса. Профессор хәзрәтләре, минем Дилбәрем шул инде, танышыгыз.

Дилбәр реверанс ясый.

Искәндәр. Мин бик шат. *(Дилбәргә төртә.)* Гафу итегез, туташ, мин шулай инде.

Дилбәр. Аһ, пардон, мусио.

Муса. Әйе, әйе, кызым, профессор хәзрәтләре сөйгән кешесенә шулай төртергә ярата икән.

Дилбәр. Аһ! *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. Муса әфәнде, сезнеңчә, ничек?

Муса. Нәрсә, профессор хәзрәтләре?

Искәндәр. Минемчә, шундый милли туташлары булган милләт яшәргә тиеш.

Муса. Яшәсен милләт!

Дилбәр. Яшәсен милләт! *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. Мадемуазель, Дилбәр туташ, утырыгыз!

Дилбәр *(реверанс ясый).* Мерси...

Искәндәр. Сез, туташ, нәзакәт һәм ыспайлыгыгыз белән безнең Америка ледиләрен оялтачаксыз. *(Төртә.)* Гафу итегез!

Дилбәр *(реверанс ясый).* Мерси.

Муса. Без инде, профессор хәзрәтләре, азрак кызыбызга французча да укыттык. Кызым, хәерле көн французча ничек була?

Дилбәр. Бон жур, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Хәерле иртә ничек була?

Дилбәр. Бон матин, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Хәерле кич ничек була?

Дилбәр. Бон суар, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Мин Американы яратам ничек була?

Дилбәр. Җим бүлә Америк.

Искәндәр. А-а-а! Французчаны бик һәйбәт беләсез икән. Мин Америкада чакта үз илебездә милли туташларыбыздан французча белүчеләр булыр дип һич уйламаган идем, милләтебез бик тәрәккый иткән икән.

Муса. Тырыштык инде, профессор әфәнде. Кулдан килгән кадәр балаларыбызны милли рухта тәрбия итәргә тырыштык инде. Дөрес, бездә бик зур приданлы бай кызлары да бар, ләкин милли тәрбияләре бик зәгыйфь шул. Яхшы милли тәрбия байлыктан артык бит, профессор хәзрәтләре. Без инде кызыбызга французча да, русча да укыттык. Шуның белән бергә, милли музыка белән дә таныштырдык. Кызым, Дилбәр, профессор хәзрәтләренә берәр милли көй җырлап алмыйсыңмы?

Искәндәр. Минем милли көй ишетмәгәнгә нәкъ егерме ел.

Муса. Кызым, ишетәсеңме, профессор хәзрәтләре нәрсә ди? Җырла, җырла, кызым, назландырма!

Дилбәр. Оялам, әткәй. *(Реверанс ясый.)*

Муса. Җырла дигәч җырла. Алай карышырга ярамый. Тәрбиясезлек була... «Әллүки, бәллүки» көен җырла. «Әллүки, бәллүки»не җырла.

Дилбәр «Әллүки» көенә тамак төбеннән европача тавышлар чыгарырга тырышып җырлый. Җырлап бетергәч, һәммәсе дә кул чабалар. Дилбәр кат-кат реверанс ясый.

Искәндәр. Үзебезнең милли көебезне милли туташыбыз авызыннан ишеткәндә, Европа, Американың опералары юк булып калдылар. Яшәсен милли көй! «Әллүки, бәллүки!»

Муса. Яшәсен милләт!

Дилбәр. Яшәсен милләт! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Бик һәйбәт җырлый иде, бүген бераз кабзыять[1] алган булырга кирәк. Ун яшеннән бирле балалар кичәсендә җырлап килә. Кызым, профессор хәзрәтләренә пианинода «Галиябану»ны уйнап күрсәт әле.

Искәндәр. Пианинода уйный беләсезме, туташ? *(Төртә.)*

Дилбәр. Аһ, пардон, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Белә, белә, бик һәйбәт, моңлы итеп уйный. Йә кызым, назланма, белгәнне күрсәтү гаеп түгел. Шулай бит, профессор хәзрәтләре? Белгәнне күрсәтү гаеп түгел бит?

Искәндәр. Бик дөрес. *(Төртә.)* Ә гафу... Безнең Америкада белмәгәнне күрсәтү дә гаеп түгел.

Муса. Әнә ишетәсеңме, профессор хәзрәтләре нәрсә ди?

---

[1] Кабзыять — каушау.

Д и л б ә р. Нәрсә уйныйм соң? *(Реверанс ясый.)*

М у с а. «Галиябану»ны, ул шәп чыга.

Дилбәр бер бармак белән «Галиябану»ны ялгыш-йолгыш уйнап чыга. Кул чабалар.

И с к ә н д ә р. А-а-а... Милләтебезнең, хосусән, милли туташларыбызның шул егерме ел эчендә тәрәккый итүләренә хәйран калам. Яшәсен пианино!

М у с а. Яшәсен милләт!

Д и л б ә р. Яшәсен милләт! *(Һәр «яшәсен» дигәндә, реверанс ясый.)*

И с к ә н д ә р. Яшәсен милли туташларыбызның имән бармаклары! *(Төртә.)*

Б а р ы с ы. Яшәсен!..

Дилбәр һаман реверанс ясый.

М у с а. Шулай булгач, милләтебез бетмәс бит, профессор хәзрәтләре?

И с к ә н д ә р. Юк, һич бетмәс. Бетәргә рөхсәт юк. Әгәр дә милләтебез тагын биш-ун ел шул юлыннан аерылмыйча барса, һич шөбһәсез, Американы узып китәчәк.

М у с а. Американы, дисезме?

И с к ә н д ә р. Әлбәттә, һич шөбһә юк. Чөнки бездә аларда булмаган хосусиятләр бар. Милли пәрәмәчебез бар, милли «Галиябану»ыбыз бар, милли туташларыбыз бар, милли татарларыбыз бар. Кирәк-яракның һәркайсы бар. Ә аларда ул юк.

М у с а. Аларда юк икән, профессор әфәнде?

И с к ә н д ә р. Аларда машина, автомобиль, һөнәрдән башка һичбер милли нәрсәләре юк.

М у с а. Ишетәсеңме, кызым? Америкада юк, ди. Булмаса булган икән инде, профессор хәзрәтләре, Дилбәр туташтан милли бию биеп алуын үтеник.

И с к ә н д ә р. Милли бию дә беләсезмени?

Д и л б ә р. Уй, мусио!.. *(Реверанс ясый.)*

И с к ә н д ә р. А-а!.. *(Төртә.)*

Д и л б ә р. Аһ, пардон мусио!..

М у с а. Бик матур бии. Ун елдан бирле балалар кичәсендә биеп килде. Мактап гәзиткә дә яздылар. Бик һәйбәт бии. Кызым, кайда, биеп күрсәт. Профессор хәзрәтләренең күрәсе килә.

И с к ә н д ә р. Әйе, әйе, мин бик шат булырмын. Егерме елдан бирле милли бию күргәнем юк бит.

М у с а. Ишетәсеңме, кызым, егерме елдан бирле, ди.

Д и л б ә р. Мин музыкасыз бии алмыйм. *(Реверанс ясый.)*

И с к ә н д ә р. Менә Апуш әфәнде уйнар. Ул аз-маз шалтыраткалый бугай.

М у с а. «Әпипә»не биесенме, «Әтнә»неме? Һәр икесен дә булдыра.

И с к ә н д ә р. Җаны эстәгәнен биесен.

М у с а. Кызым, Әпипә, Әпипә!.. Йә, йә, бас, кызым Әпипә, син басмасаң, мин басам. *(Бию хәрәкәтләре ясый.)*

Дилбәр «Во садули» рәвешенчә, «Әпипә»гә бии. Кул чабалар.

И с к ә н д ә р. Яшә, мең, миллион мәртәбә яшә, Дилбәр туташ! Бу милли биюебезне карап торганда, Американың балеты бөтенләй юкка чыга... Тагы бер мәртәбә яшә! *(Кул бирә.)* Син яшәсәң... *(Төчкерә.)* Син яшәсәң... *(Төчкерә.)* Борынга әллә ни булган. *(Төчкерә.)*

Д и л б ә р. Томау төшкәндер, пардон. *(Реверанс ясый.)*

И с к ә н д ә р. Шулайдыр. *(Төчкерә, төртә.)* Гафу итегез, мин әйтмәкче идем... *(Төчкерә.)*

Искәндәр төчкергән саен, Муса ярхәмәкеалла дип тора. Соңыннан үзе дә төчкерә башлый.

Д и л б ә р *(төчкереп)*. Пардон! *(Реверанс ясый.)*

И с к ә н д ә р. Бәрәкәт.

Ш ә е х м и р з а керә.

V. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Ш ә е х м и р з а.

Ш ә е х м и р з а. Кайда ул Америка профессоры, кайда?

М у с а. Кызым, ир-ат бар, чык!

Д и л б ә р чыга.

Акрын, акрын, зинһар, акрын!.. Безнең сабыйк милли адвокатларыбыздан Шәехмирза Юкабашов әфәнде.

И с к ә н д ә р. Мин бик шат. *(Кулын бирә һәм төртә.)*

Ш ә е х м и р з а. Ай профессор әфәнде, минем бүсерем бар. Шуның өчен үтенәм...

И с к ә н д ә р. Миллидер инде ул.

М у с а. Әйе, әйе, ышанычлы милләтчеләребездән.

Ш ә е х м и р з а. Мин сезнең белән танышуыма, профессор әфәнде, бик шат. Гафу итегез, профессор әфәнде, мин сезгә бер сөаль бирәм.

И с к ә н д ә р. Рәхим итегез.

Шәехмирза. Сез большевикмы, түгелме?

Искәндәр. Америкада большевиклар юк.

Шәехмирза. Мин сезгә ышанам. Шулай буласын алдан ук сизгән идем, профессор әфәнде. Сез моны күрәсезме? *(Тазын күрсәтә.)*

Искәндәр. Шактый шома икән.

Шәехмирза. Мине таз диләр, ә мин әйтәм, мин әйтәм, ул — мәдәнилек, галимлек галәмәте, дим. Сезнең пеләшегез бармы, кайда?..

Искәндәр төртә.

Ай, бүсерем!.. Менә, Муса әфәнде, һәрбер мәдәни, галим кешенең башы пеләш булырга тиеш. Ә сез таз дисез.

Муса. Сезнең пеләш түгел, таз, Шәехмирза әфәнде.

Шәехмирза. Юк, ялгышасыз, пеләш!

Муса. Шәехмирза әфәнде, юкка кызмагыз. Сезнең атагызның да башы таз иде. Тазлык — сезнең нәселдән килгән милли авыру инде ул.

Шәехмирза. Милли булса булыр, ләкин мин таз түгел, пеләш.

Муса. Шәехмирза әфәнде, сез милли тазлыгыгыз белән мактанырга тиешсез. Әйе, әйе, сезнең җиде буынга кадәр бөтен нәселегез таз.

Шәехмирза. Нәсел тикшерергә калганда, Муса әфәнде, сезнең хәлегез начаррак булачак. Сезнең нәселегездә бирән авыруы бар. Сезнең атагыз бирән авыруыннан үлгән. Анагызның уң аягы ярты аршин кыска булган.

Муса. Син үлгәннәргә тимә, энем. Синең атаң — миссионер Ильминскийга милләтне саткан кеше.

Шәехмирза. Ә син үзең? *(Колакка.)*

Муса. Кем әйтә аны, кем әйтә?

Шәехмирза. Мин әйтәм.

Муса. Юк, сез аны әйтә алмассыз!

Шәехмирза. Әйтәм һәм әйтермен!

Муса. Юк, син исбат ит! *(Якасына ябыша.)*

Шәехмирза. Тотма якадан.

Искәндәр *(араларына кереп төртеп).* Әфәнделәр, сез икегез дә бик маһир ораторлар икәнсез. Әгәр дә Америкада булсагыз, шөбһәсез, бөтен дөньяга мәшһүр милли адвокатлар булыр идегез.

Шәехмирза. Аңар тагын адвокат булырга! Мөәззин дә була алмады. Ә мин, әфәндем, факультет ярым бетергән кеше. Бу большевиклар булмасалар, мин үзем дә әллә

кайчан профессор булган булыр идем... Минем гыйльми әсәрләрем дә бар.

Муса. Профессор хәзрәтләре, ышанмагыз, ялганлый! Аның әсәрләренә кибетләрдә тоз тутырып саталар. Ахмак ул.

Шәехмирза. Ахмак кешенең пеләше булмый. Менә ул!

Муса. Пеләш түгел ул, таз!

Шәехмирза. Юк, пеләш!

Муса. Ә мин әйтәм, таз!

Шәехмирза. Ә мин әйтәм, пеләш!

Муса. Юк, таз!

Бер-берсенә кизәнә башлыйлар.

Искәндәр *(урталарына кереп, төртеп).* Әфәнделәр, сабыр!

Шәехмирза. Синеңчә, профессор әфәнденең дә башы тазмы?

Муса. Син таз!

Шәехмирза. Ә син хәйләләп Америка паёгы ашадың. Өстеңнән язып кына бирәсе бар.

Муса. Бар, бар, әйт. Ә мин синең чехларга шпионлык иткәнеңне әйтермен.

Габдуллаҗан керә.

VI. Әүвәлгеләр һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Әссәламегаләйкем! Америка профессоры кайда?

Муса. Габдуллаҗан бай, рәхим итегез. Менә ул!

Габдуллаҗан. Исәнме? Кая, бер дога кылыйк.

Дога кылалар.

Сез, профессор әфәнде, Америкадан кайчан чыктыгыз?

Искәндәр. Апрельдә.

Габдуллаҗан. Америкада сәүдә эшләре ничек бара?

Искәндәр. Шәп.

Габдуллаҗан. Ничек, профессор әфәнде, Америкада акча алтын, диләр?

Искәндәр. Көмеше дә бар.

Габдуллаҗан. Көмеше дә бар, диең?

Искәндәр. Бар.

Габдуллаҗан. Юлга расход күпме чыкты?

И с к ә н д ә р. Йөз доллар.

Г а б д у л л а җ а н. Безнеңчә күпме була инде?

И с к ә н д ә р. Шул чама.

Г а б д у л л а җ а н. Кара аны, бөтенләй юк икән! Өй җәмәгатьләрегез сау калдылармы?

И с к ә н д ә р. Сау.

Г а б д у л л а җ а н. Үзегезнең җәмәгатегез бармы?

И с к ә н д ә р. Юк.

Г а б д у л л а җ а н. Юк, диең?

И с к ә н д ә р. Әйе, юк.

Ш ә е х м и р з а. Профессор әфәнде, сез кайсы шәһәрнең университетында эшлисез?

И с к ә н д ә р. Вашингтонда.

М у с а. Чикагода түгелмени?

И с к ә н д ә р. Чикагода да, Нью-Йоркта да, мин бөтен Америка шәһәрләренең университетларында эшлим.

Ш ә е х м и р з а. Профессорлыкка берәр буш урын юкмы?

И с к ә н д ә р. Кем өчен?

Ш ә е х м и р з а. Үзем өчен. Мин факультет ярым бетердем бит. Гыйльми әсәрләрем дә бар.

М у с а. Таз башың белән кайда үреләсең инде син?! Аларның үзләрендә дә синең шикелле әрәмтамаклар бетмәгәннәрдер әле.

Искәндәр белән Габдуллаҗан үзара сөйләшәләр.

Ш ә е х м и р з а. Син, шәкерт хәлфәсе, ике галим сөйләшкәндә, арага ботыңны кыстырма, яме?

М у с а. Синең гыйлемеңә сукыр анаңнан башка кеше ышанмый бит.

Ш ә е х м и р з а. Ә син, шәкерт, шифырт, күмер карагы!

М у с а. Минем, әлхәмделилла, ундүрт әсәрем бар. Ә син гомереңдә бер әсәр нәшер иттең, аңа да кибетләрдә тоз тутырып саталар.

Ш ә е х м и р з а. Ә синең әсәрләрең кәгазь капчык ясарга да ярамый.

И с к ә н д ә р. Муса әфәнде, бик рәхмәт хөрмәтегезгә, безгә рөхсәт итегез.

М у с а. Юк, юк, профессор хәзрәтләре. Кунып китәрсез. Сез бу дивананың сүзләренә карамагыз. Ахмак психопат ул!..

Ш ә е х м и р з а. Менә профессор әфәнде, шаһит булыгыз, менә бу шифырт, хәлфә кисәге мине ахмак, психопат

дип тәхкыйрь итте[1]. Мин аны иртәгә үк 173 нче статья буенча судка бирәмен. *(Чыга.)*

Искәндәр. Мин, бәлки, иртәгә үк Америкада булырмын.

Муса. Ничек, әллә аэропланыгыз да бармы?

Искәндәр. Әйе. Милли пәрәмәчегезгә, лимонлы чәегезгә рәхмәт. Әгәр дә Америкага барсагыз, миңа кунак булып төшегез. Ниопост урамында. 16 818 нче йортта, 84 нче катта, 9987 нче номерлы фатирда, 1189 нчы бүлмәдә мин булырмын.

Муса. Юк, юк, мин сезне, кундырмыйча, һич җибәрмим. Минем сезгә үзегезгә генә сүзләрем, йомышларым да бар әле.

Габдуллаҗан. Профессор әфәндене кунарга мин үземә алып барам.

Муса. Юк, бай, кеше кунагын алай тартып алып китәргә хакыгыз юк. Профессор хәзрәтләре бездә кала.

Габдуллаҗан. Юк инде, Муса хәлфә, алай үзеңә генә бөтен нәрсәне йомарлап тотмыйлар аны. Профессор әфәнде иртәгә китәчәк булгач, мин аны үземә кунарга алып барам. Әйдә, профессор әфәнде.

Муса. Юк, юк, рөхсәт юк. Кеше кунагын алып китәргә хакың юк.

Габдуллаҗан. Бик бар, менә дигән хакым бар. Син милләт хадиме булсаң, мин дә милләт бае. Алай үз ягыңа гына каерма.

Искәндәр *(төртеп).* Әфәнделәр, мин үз номерыма кайтам.

Муса. Юк, юк, рөхсәт юк. Бәхил түгел, миндә каласыз.

Габдуллаҗан. Муса хәлфә, син алай әрсезләнмә. Профессор әфәнде бездә кунар. Бездә мунча да ягылды. Махсус заказ — милли кабартма да пешерелде. Мунчадан чыгуга пирәш тә бар. Әйдә, әйдә, профессор әфәнде. *(Култыклый.)*

Муса. Юк, юк, рөхсәт юк. Бездә кунар. *(Култыклый.)*

Габдуллаҗан. Юк, безгә барыр.

Муса. Юк, бездә калыр.

Габдуллаҗан. Тартма, киемен ертырсың.

Муса. Нигә кеше кунагын талап алып китәсең!

Габдуллаҗан. Әйдә, профессор.

---

[1] Тәхкыйрь итү — хурлау, мыскыллау.

М у с а. Кал, профессор.
Г а б д у л л а җ а н. Әйдә безгә!
М у с а. Җибәрмим!

Соңгы сүзләрне тәкрарлап Искәндәрне як-якка тарткалыйлар.

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мещаннарча җыйналган кунак бүлмәсе.

I. Р а з и я, М ә й с ә р ә бүлмә җыештыралар.

Р а з и я. Кызым, тузаннарны яхшы сөрттеңме икән инде? Кунак ни җитте түгел, ди, американ, ди. Алла сакласын, шакшы торалар дип, бөтен дөньяга яманатыбызны таратыр.

II. Р а з и я, М ә й с ә р ә һәм Г а б д у л л а җ а н.

Г а б д у л л а җ а н. Кайда, буласызмы инде? Кирәк-ракның барысы да булдымы инде?
Р а з и я. Булды, атасы, булды.
Г а б д у л л а җ а н *(үчекләп).* Булды, атасы, булды, атасы. Мин сиңа талчукчы да, читекче дә түгел. Сүз сөйләшә белмисез, һи, атасы, атасы... Кайчан гына шул тупаслыкларыгыздан котылырмын икән инде. Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс, дигәннәр, дөрес шул. Һичбер төрле итеп тәрәккыйпәрвәрләндереп булмый үзегезне. Кара аны, Разия ханым, актык мәртәбә әйтәм, әгәр дә тагы «атасы» дип эндәшкәнеңне ишетсәм, билләһи газыйм дип әйтәм, яңагыңнан утлар чыгарырмын!
Р а з и я. Яшьлектә өйрәнмәгәч, картайгач булмый икән шул. Онытып җибәрәм.
Г а б д у л л а җ а н. Онытмаска кирәк. Шул бер-ике сүзне өйрәнмәскә, миегез черемәгәндер бит. Тупас дисәң тупас инде шул безнең татар хатыннары.
Р а з и я. Ярый инде, сиңа әйтәм, юк өчен...
Г а б д у л л а җ а н. Нәрсә, ничек ничек?..
Р а з и я. Юк, болай гына, атасы.
Г а б д у л л а җ а н. Ә?..
Р а з и я. Бәйләнмә инде, сиңа әйтәм...
Г а б д у л л а җ а н. Сиңа әйтәм?! Сиңа әйтәм?! Әллә син мине авылдан базарга кәбестә төяп килгән гыйбад дип уйлыйсыңмы?! Яңадан шул «сиңа әйтәмеңне» авызыңнан чыгарсаң, телеңне кадак белән тишәрмен. Гыйбди

дисәң гыйбди. Мужик, надан… Бу кадәр замананы аңламаган, тәрәккыйгә күнмәгән хайваннар булырсыз икән! Ат кәмитендә бит аюны да сездән яхшырак, сездән тәрәккыйпәрвәррәк итеп нәзакәткә өйрәтәләр. Бу кадәр аңгыра булырсыз икән. Кара аны, Разия ханым, бүген кешеләр алдына чыгасы булма! Синең өчен бөтен планнарымнан колак кагар хәлем юк. Әнә ашханәдә дөмегеп тор. Кеше итәргә, кеше арасына кертергә тырышмадым түгел инде. Алла кабул итсен. Ә син һаман үзеңнең мокытлыгыңнан аерыла алмыйсың.

Р а з и я. Ярый инде, ярый. Юк өчен дөнья кубарма. Теләсә генә ни эшләт, исемең белән эндәшеп гөнаһлы булыр хәлем юк.

Г а б д у л л а җ а н. Теләсәң шәйтан дип эндәш. Әнә шул «сиңа әйтәм» белән «атасы» дигәнеңне генә ташла!..

Сиңа әйтәм, атасы, имеш… Кәнәфи менә шунда торсын. Әйдә, тот!

Р а з и я кәнәфине күтәрә.

Бисмилла диген, юньсез.

Р а з и я. Әгүзебилләһи минәшшәйтан ирраҗим, бисмилләһи…

Г а б д у л л а җ а н. Кирәкмәгәндә, артыграк юмартланып та китәсең. Әгузесен калдырсаң да ярый. Һаман шул иске остабикәләр тәрбиясе бетми үзегездә. Келәмнәрне кактыгызмы?

Р а з и я. Кактык, ата… сиңа… ә…

Г а б д у л л а җ а н *(җиһазларны, келәмнәрне яулыгы белән сыпырып карый).* Кайда, кызым, одеколон чыгар. Бүлмәнең һавасын тазартырга кирәк.

М ә й с ә р ә чыгып китә.

Ходаның хикмәте, шул ат мае исеннән кабергә кермичә качып булмас, ахры. Әлдә инде сезнең тәннәрегезгә үк сеңгән… Никадәр тәрәккыйпәрвәрләнмә, ат мае һаман үз эшендә.

Р а з и я. Милли ис, атасы, милли…

Г а б д у л л а җ а н. Милли дип инде, комганыңны да шкаф башына китереп куй. Һәр нәрсә үз урынында килешә. Ат мае белән милләт тәрәккый итми.

Р а з и я. Ай Алла, үзең әле үткән ел гына, яшәсен милли ат мае, яшәсен аның исе дип, мәйданда нотык сөйләгән идең.

Г а б д у л л а җ а н. Кайчан, кайчан?..

Р а з и я. Теге урамга бүрәнәләр тезеп, сабитларга каршы...

Г а б д у л л а җ а н. Тик тор, чүпрәк баш! Шул башың белән сәясәт тикшергән буласың тагын. Аны аңлый белергә кирәк әле сиңа!

Р а з и я. Ярый инде безгә, үзебезгә, мөселманча булгач, маеннан да җирәнмибез, исеннән дә чиркәнмибез.

Г а б д у л л а җ а н. Ярый, ярый, шапылдама!

М ә й с ә р ә керә.
III. Р а з и я, Г а б д у л л а җ а н һәм М ә й с ә р ә.

М ә й с ә р ә. Атакай, булды.

Р а з и я. Атакай дип кайдан шул мишәр сүзләрен уйлап чыгардыгыз?

Г а б д у л л а җ а н. Дөнья күрмәгәнлек адым саен килә дә чыга. Театрларга да йөртәм ләсә үзеңне. Бар икән дөньяда аңгыралар.

Р а з и я. Әти, әткәй дип эндәшү нигә ярамагандыр үзеңә!

Г а б д у л л а җ а н. Әти, әткәй дип без үстек. Безнең аталар-бабалар үскәннәр. Заманасында ул яраган. Хәзер заманасы башка. Тәрәккый заманы. Нигә соң син, чүпрәк баш, чыра якмыйсың? Нигә электрик ягасың, ә? Кызым, теге өрдерә торган машинаны да китер. Кая, кызым, кая, мондарак кил әле! Бу нәрсә?

М ә й с ә р ә. Борын, атакай.

Г а б д у л л а җ а н. Тимерче кебек корымланып йөрмәсәң ярамас дип куркасыңмыни, чүпрәк баш!

Р а з и я. Иртәдән бирле тузан эчендә бит, атасы.

Г а б д у л л а җ а н. Сорамаганга җавап бирү ахмаклык була ул, Биби Разия ханым, белдеңме? Әллә инде бүлмә дә җыештырмас идегезме? Әнә Германиядә менә дигән кызлар, гимназия бетергән кызлар асраулар эшен эшлиләр, ди. Бар, кызым, әйткәнне эшлә.

М ә й с ә р ә. Ни эшлим, атакай?

Г а б д у л л а җ а н. Соң мин ни эшләргә куштым?

М ә й с ә р ә. Әллә тагын, оныттым, атакай.

Г а б д у л л а җ а н. Соң синең башың кайда? Миең черегән нәрсә!

М ә й с ә р ә. Беләм, атакай, беләм, әфәндем. Машина. ***(Чыга.)***

Г а б д у л л а җ а н. Менә юньләп тыңлагач була ул.

Р а з и я. Кем... ни... әй... әй...

Габдуллаҗан. Айлама миңа. Мин эт тә, ат та түгел. Исемем бар минем.

Разия. Ярый ла инде... Американнан башка, мәҗлестә тагын кемнәр булыр?

Габдуллаҗан. Беренчедән, американ түгел. Америка профессоры. Ишетәсеңме? Америка профессоры, чүпрәк баш. Икенчедән, мәҗлес түгел, зыяфәт, банкет... Мәҗлес белән банкет арасында никадәр аерма булса, американ бае белән Америка профессоры арасында да шулкадәр үк аерма бар. Бу ниткән сүз аңламас аңгыра булдыгыз сез! Син төне-көне тәрәккыйпәрвәрләнергә, җәмәгать эшләренә керергә тырышып йөрисең. Ә болар монда сине иске базга, кадимлеккә өстериләр.

Разия сүзсез генә төртә.

Нигә миңа төртәсең? Телеңә җен кагылмагандыр бит?

Разия. Аптырадым инде мин, аптырадым. Атасы, дисәң ярамый. Сиңа әйтәм дисәң ярамый. Әй, дисәң ярамый. Төртсәң тагы ярамый. Соң нихәл кылыйм инде? *(Елый.)* Тәрәккыйпәрвәрлегең үзеңә булсын, нигә чәнчелмисең шунда! *(Елый.)*

Габдуллаҗан. Елама, елама, миңгерәү тавык. Үзең өчен тырышам бит. Банкетны да белмәскә, оят бит. Безнеңчә зыяфәт, Европача банкет дип бер кешенең шәрәфенә багышлап ясалган мәҗлескә әйтәләр.

Разия. Манкитыңда да барыбер мәҗлестәге шикелле үк тыгынырга җыелалар бит.

Габдуллаҗан. Ярый, ярый... Дорфа сүзләреңне үзеңнең чүпрәк башлар мәҗлесләреңә калдыр. Банкетның хикмәтләрен аңларга шомарасың бар әле. Банкет ул зур нәрсә, бик зур.

Разия. Алай булгач, мунча ягарга да кирәк булыр инде.

Габдуллаҗан. Кирәк, кирәк, ләүкәләрен һәйбәтләп кайнар су белән сабынлап юыгыз, Разия ханым. Теге утынлыктагы иске китапларның тузаннарын сөртеп монда кертегез. Аннан соң малайны базарга җибәреп, бик күп итеп, татарча һәм русча гәзитләр, журналлар алдырып, өстәл өсләренә куегыз. Берәр заграничный-сурәтле журналлар табылмасмы, барысын алсын, акча кызганмасын.

Разия. Ярый, ярый, алдырырбыз. Әрәм булмаслар. Бәлеш асларына җәяргә дә ярарлар. Юкса йортта им өчен бер кәгазь кисәге юк бит.

Габдуллаҗан. Телефон шылтырыймы?

Р а з и я. Әллә тагын, кагылган кеше булмады.

Г а б д у л л а җ а н *(шалтыратып).* Шылтырый ич.

Р а з и я. Бу американ бигрәк расходлы кунак булды.

Г а б д у л л а җ а н. Расходсыз гына синең ул аңгыра тавыгыңны... Йә, ярый, ярый, бар, ашларыңны кара! Пәрәмәч, кабартмаларың яхшы булсын. Пәрәмәчтә ихласы зур, ди, аның. Банкет булса да, бездә ул милли булыр.

Р а з и я. Кунак ашы җирдә калмас, дигәннәр. Алла хәерле итсен инде. *(Чыга.)*

IV. Габдуллаҗан ялгызы.

Г а б д у л л а җ а н. Эшләнәсе эшләр, алынасы нәрсәләр алынып бетте бугай инде. Чынлап та, хатын әйтмешли, бу американ үзенең банкеты белән шактыйга төшәр төсле күренә. Хәер, эшләр уйлаганча барып чыкса, ун өлеш итеп кайтарырбыз әле. Син Америка профессоры булсаң, без дә үз эшебездә профессор, әфәндем. Алдатмабыз әле. Дөньяда көтелмәгән эшләр була. Көтелмәгәндә әллә ниләр эшләп ташлый ул, дөнья, диләр аны. Башына тай типмәгән кеше дөньясында харап булмый ул. Бабайлар да, дөнья куласа: әйләнә дә бер баса, дип ялгышканнар. Дөрес, дөнья куласасын куласа, әйләнүен дә әйләнә, анысы дөрес. Әмма әйләнеп басмый! Өскә чыгара. Җилкәдән тотып өскә чыгара. Бабайлар сүзе белән йөрсәң, авылда кара ипи кимереп, йә берәр шахтада күмер казып торыр идең. Ә монда эшләр бөтенләй башкача, Америка профессорының бабасы. Ә, һи-һи-һи, уйласам йөрәкләр кытыкланып китә. Тукта әле, бу чүпрәк башларны шул хакта агаһландырып куярга кирәк. Юкса көтелмәгәндә әллә ни эшләп ташламасыннар тагын. Акыл өләшкәндә кершән буянып калган халык бит алар. Анасы!.. Әй, тфү, Разия ханым, кызым, монда керегез!.. Тиз булыгыз инде. Имгәкләр! Шулай диген, көтелмәгәндә, диген, җилкәдән тотып чыгара, диген. Һи-һи-һи...

V. Г а б д у л л а җ а н, Р а з и я, М ә й с ә р ә.

Р а з и я. Син чакырдыңмы?

Г а б д у л л а җ а н. Килегез, утырыгыз... Кызым, син дә утыр.

Утыралар.

Р а з и я. Ни бар?

Г а б д у л л а җ а н. Менә нәрсә, кызым, Мәйсәрә туташ. Хатыным, Разия ханым. Мин иске фикерле, тупас

кара татар бае да түгел, ишаннарга кул биреп дөньямны ахирәткә алмаштыручылардан да түгел. Мин замана кешесе, тәрәккыйпәрвәр, милләтче татар углы татармын...

Р а з и я. Мөселман, диең, атасы.

Г а б д у л л а җ а н. Тик тор, син, ишәк. Нәүбәтең җиткәч сөйләшерсең. Менә шулай, кызым туташ. Мин кара фикерле каткан татар түгел, замананың теләкләренә каршы килмим. Хәзер инде замана башка төрле. Ору, сугу, көчләүләр модада түгел. Хәзер эшне заманача, тәрәккыйпәрвәрләрчә йөртү модада. Менә шуңа күрә мин сине үзең теләмәгән кешегә көчләп кияүгә бирү ягында түгел, кызым. Бүген безгә киләчәк американ — бик зур могтәбәр кеше. Үзе — профессор, үзе — хак мөселман. Америкада тора. Әгәр дә чәчләрегез бәйләнгән булса, кызым, гомерең буенча автомобильдә генә йөрерсең. Төшендеңме, кызым туташ?

М ә й с ә р ә. Әбәү, мин аңар чыкмыйм!

Г а б д у л л а җ а н. Сөйләп бетергәнне көт, миең черегән нәрсә! Шулай, әгәр дә син аңар кияүгә чыксаң, җаның ни тели, шуны алырсың, әбәзияннан сак тектереп бирермен. Әйтәм бит, җаның ни тели, шуны алып бирермен.

М ә й с ә р ә. Әем, мин аңарга чыкмыйм!

Г а б д у л л а җ а н. Сөйләп бетергәнне көт, дим, юкә баш! Менә мондый, иресеннән, менә шуның озынлыгы энҗе алып бирермен. Теге берлиант кашлы беләзекне дә бирермен.

Р а з и я. Тукта әле, кем, ни...

Г а б д у л л а җ а н. Тик тор, чүпрәк баш. Синнән акыл сораган кеше юк бит әле. Бу йортта син хуҗамы, минме?

Р а з и я. Юк, мин болай гына, ихтыяр үзеңдә.

Г а б д у л л а җ а н. Әгәр дә насыйп булып аңарга кияүгә чыксаң, Америкага китәрсез. Ел саен берәр кат без дә барырбыз. Сез аннан вагонлап-вагонлап мал җибәрерсез. Без монда сатарбыз да, алтынга әйләндереп, сандыкларга тутырып, сезнең янга Америкага торырга китәрбез. Бу тупас Рачы халкы арасында торуы да туйдырды инде. Төшенәсеңме, кызым, эшләрнең кая барганын?

М ә й с ә р ә. Яшьме соң үзе?

Г а б д у л л а җ а н. Менә килгәч күрерсең. Ул сиңа гашыйк булган. Ашым аш, суым су түгел, ди.

М ә й с ә р ә. Әй, аның ише... һи-һи-һи!..

Г а б д у л л а җ а н. Аннан соң шуны да истә тот, кызым: син аның аягы астында туфрак булырга тырыш. Минем өемнән чыгып киткәннән соң, тәрбияң аның кулында

булачак. Кем ашын ашаганыңны һәрвакыт исеңдә тот. Яхшы булсаң, сый күрерсең, яман булсаң, ут күрерсең. Дөрес, синең гомереңә җитәрлек мин үзем дә сиңа придан бирермен, ләкин мөселман кешегә шәригать боерыгыннан чыгарга ярамый. Хатын ирнең колы булырга тиеш.

Мәйсәрә. Әем, алай ут йотарлык булгач, мин аңарга чыкмыйм.

Габдуллаҗан. Мин, кызым, тупас татар бае түгел. Әгәр дә күңелеңә ошамый икән, мин сине көчләп бирмим. Ә инде минем сүземә каршы килүең өчен, яңагыңнан утлар чыгарырмын. Мин сине утыз яшькә кадәр ашатып түремдә тотмам. Хәзер заманасы ул түгел. Гомер буе кияүгә чыкмасаң да, мин сине һич бирәүгә көчләп, елатып бирмәм. Ә инде башбаштаклыгың өчен яңагыңнан утлар чыкканны көт тә тор... Мин синең белән ике сөйләшмәм. Мин замана кешесе. Син белгән җәдитлекне мин дә беләм. Йә, ни әйтерсең, кызым?.. Дәшмисең?..

Разия. Дәшмәү ризалык галәмәте ул, атасы.

Габдуллаҗан. Син тик тор, әрәмтамак! Дәшмәү ризалык галәмәте дип эш кылырга мин кадим бай түгел. Миңа үз теле белән шартлатып әйтеп бирсен. Мин аны көчләп бирергә теләмим. Инде минем планнарымны җимерә икән, үзенә үпкәләсен. Яңагын кабыргалы бозау кәтлитеннән ким ясамам. Йә кызым!.. Мин көтәм!..

Мәйсәрә. Риза.

Габдуллаҗан. Менә, бәрәкалла, кызым. Менә бу эш чын җәдид, зыялыларча булып чыкты. Үзеңә дә уңай, миңа да яхшы. Халык күзендә дә күңелле.

Разия. Миңа инде, атасы...

Габдуллаҗан. Синнән сорамаганда, син тик тор, яңадан шул тупас «атасы» дигәнеңне ишетсәм, кара аны... Кая, кызым, бар, һәйбәтләп борыннарыңны, йөзләреңне юып, теге мутный күлмәкләреңне киеп, рәтләнеп, хәзерләнеп тор. Озакламыйча килә дә башларлар. *(Одеколон өрдерә.)* Ә син, Разия ханым, ашларыңны кара.

Разия. Ярый, ярый... Кем... ни...

Габдуллаҗан. Ни бар?

Разия. Шулай ук бердәнбер кызыбызны...

Габдуллаҗан. Син ашларыңны бел. Башкасына катышма. Синең эшең түгел, бар, бар!

Разия. Ярый, ярый, Алла хәерле итсен иде инде. *(Чыга.)*

Габдуллаҗан. Ярый, бер яктан эш бетте. Инде профессорның җебен тотарга кирәк. Хәер, алай куркы-

нычлы конкурентлар күренми әле. Өч-дүрт төргәк белән егерме-утыз каратны күрсәтсәң, күзе томаланыр әле. Беләбез без ул халыкны. Үзбәк әйтмешли, пүл булсын, пүл булса, барысын да кол итәргә була.

Звонок.

Әһә, килделәр бугай. *(Чыга.)*

VI. Габдуллаҗан, Нигъмәт.

Габдуллаҗан. Әйдә, әйдә, Нигъмәт әфәнде, рәхим итегез!

Нигъмәт. Профессор әфәнде юкмыни әле?

Габдуллаҗан. Вакыт бар әле. Ул халык бит сәгате-минуты белән йөри торган халык инде.

Нигъмәт. Дөрес, дөрес. Үзегез ниләр бетереп торасыз?

Габдуллаҗан. Яңа хәбәрләр сездәдер инде. Дөньяда ниләр бар? Гәзитәләрендә ниләр язган булалар? Налоглар турында тагын берәр кәсафәт тудырырга уйламыйлармы?

Нигъмәт. Тудырган кәсафәтләре дә җитәрлек булды инде. Ни эшләмәкче була торганнардыр инде. Менә Европа дәүләтләре белән килешүдән берәр хикмәт чыкмасмы инде.

Габдуллаҗан. Ничек, әллә берәр нәрсә чыгар төсле күренәме?

Нигъмәт. Күренергә тиеш. Чит дәүләтләр капиталы кергәч, җирле капиталга да юл ачылырга тиеш.

Габдуллаҗан. Соң гәзитләрендә ниләр язалар?

Нигъмәт. Иске мунча, яңа таш. Һаман шул бер балык башын чәйниләр. Тегеләй эшлибез, болай эшлибез дип мактанудан уза алмыйлар әле. Юньләп эшләгән бер эшләре юк. Мәмләкәт тоту бунт чыгару түгел икән шул.

Габдуллаҗан. Шулаен шулай да, кем, Нигъмәт әфәнде, көч алар кулында бит.

Нигъмәт. Тарих бер урында тормый, Габдуллаҗан әфәнде. Бүген алар булса, иртәгә эш башында безнең булуыбыз да бик мөмкин.

Габдуллаҗан. Әнә теге бүрәнә җөмһүрияте заманында нинди уңай вакыт туры килгән иде. Кулдан ычкындырдыгыз бит шуны.

Нигъмәт. Юк, Габдуллаҗан әфәнде, ул алай түгел. Без сезгә, милли байларга, ышанып харап булдык ул чагында.

Габдуллаҗан. Ничек безгә ышанып харап булдыгыз? Киресенчә, без сезгә ышанып харап була яздык. Иләдегез инде, Нигъмәт әфәнде, иләдегез. Алла хәерле кылсын инде.

Нигъмәт. Ярый инде, үткән эшкә салават, дигәннәр бабайлар. Үткән беткән инде. Ул эшләр киләчәк өчен сабак булсын. Тарих ул йокламый, һаман алга атлый. Бабайлар әйтмешли, дөнья куласа: әйләнә дә бер баса.

Габдуллаҗан. Менә ул – хата фикер, Нигъмәт әфәнде. Дөрес, дөнья куласасын куласа, әйләнүен дә әйләнә, ләкин...

Звонок.

Профессор килде. *(Чыга.)*

VII. Габдуллаҗан, Шәехмирза, Сәлим, Нигъмәт.

Габдуллаҗан. Әйдәгез, әйдәгез, рәхим итегез!

Шәехмирза. Килмәдемени әле? Исәнмесез, Нигъмәт әфәнде.

Күрешәләр.

Сәлим. Габдуллаҗан әфәнде, безнең бу мәҗлесебезне сизмәсләрме икән?

Габдуллаҗан. Мәҗлес түгел, зыяфәт, банкет, Сәлим әфәнде.

Шәехмирза. Бүредән курыккан урманга бармас, дигәннәр бабайлар. Куркырлык булгач килмиләр аны.

Сәлим. Сез, Шәехмирза әфәнде, зыялы адвокат булсагыз да, тәрбиягез барып чыкмаган.

Шәехмирза. Ә сез һаман татарлыктан чыга алмыйсыз. Мин факультет ярым бетергән кеше. Һәрхәлдә, сезнең мәдрәсә тәрбиягездән артыграк. Мин тәрбия күргән кеше. Гаҗәп, безнең татар зыялылары нәзакәт дигән нәрсәне белмиләр. Менә Нигъмәт әфәнде мәдрәсәдә укыган шәкерт кенә булса да, ул бөтенләй башка.

Габдуллаҗан. Әфәнделәр, сөйләшәсе сүзегез булса, сөйләшеп бетереп куегыз, профессор алдында, зинһар, сынатмагыз.

Шәехмирза. Син, Габдуллаҗан әфәнде, бер сәүдәгәр генә. Зыялылар сөйләшкәндә тыңлап торырга кирәк.

Габдуллаҗан. Мин үз өемдә үзем хуҗа. Теләсәм сөйләшермен, теләмәсәм тыңлап торырмын.

Звонок.

Тес-с, зинһар, тавышланмагыз. Килде. *(Чыга.)*

Сәлим. Нигъмәт әфәнде, сез профессор хакында нинди фикердә?

Нигъмәт. Мин әле аны күргәнем юк бит. Һәрхәлдә, милләтебез өчен зур мактану инде, зур хәзинә.

Шәехмирза. Зур мактану, имеш. Менә мин факультет ярым бетергән кеше. Революция булмаса, әллә кайчан профессор булган булыр идем. Шулай инде. Ерактагы кояш якты була, ди.

Тавыш ишетелә, һәммәсе рәтләнәләр.

VIII. Әүвәлгеләр, Габдуллаҗан, Муса, Дилбәр.

Муса. Әле килмәдемени?

Габдуллаҗан. Хәзер килергә тиеш. Рәхим итегез!

Күрешәләр.

Нигъмәт. Муса әфәнде, ни эшләр куптарасыз? Әллә нигә картаеп киттегез бу арада.

Муса. Гомер уза бит.

Нигъмәт. Юк, революция картайтты сезне.

Муса. Анысы да бардыр инде... Газиз милләтебез сакчысыз көтү шикелле горбәттә[1] калды бит. Бала-чага эш башына менеп утырып, безне бөтенләй читкә кактылар бит. Ни өчен? Милләткә утыз ел хезмәт иткән өчен. Менә шул утыз еллык хезмәтнең җилгә очканын күрү җиңел түгел шул.

Шәехмирза. Шулай була ул. Теге вакытта учредительный собраниегә мине сайлаган булсагыз, бәлки, бу хәлләр булмаган да булыр иде. Ә сезнең ышанычлы вәкилләрегез нишләттеләр үзегезне? Сезне монда агач атка атландырып калдырып, үзләре заграницага тайдылар. Шулай була ул. Ә сез эшне өйләгә кадәр бетереп куйдыгыз.

Нигъмәт. Муса әфәнде, американ профессор сездә булган, ди.

Муса. Әй-йе, булды.

Нигъмәт. Нинди тәэсир калдырды?

Муса. Чын зур галим икәнлеге һәрбер сүзеннән, хәрәкәтеннән күренеп тора.

Шәехмирза. Миңа да ул бик ошады. Мин беренче күрүдә үк аның зур галим генә түгел, философ икәнлеген анык белдем.

Габдуллаҗан. Алланың хикмәте ул профессор,

---

[1] Горбәт – ялгызлык.

бер дә бездәге укыган кешеләргә охшамый. Бездә укыган кешеләр юләр сымаграк булалар бит, әйеме? Ә ул алай түгел, профессорларның да урта бармагы булырга кирәк.

Шәехмирза. Габдуллаҗан әфәнде, сез сәүдәгәр кеше, сез, бәлки, базар малын яхшы да таный торгансыздыр, әмма инде учёныйларга бәһа куюны сез безгә тапшырыгыз.

Габдуллаҗан. Юк, алай түгел, адвокат әфәнде. Кеше белән кешене без дә аера беләбез. Мин сәүдәгәр булсам да, әлхәмделилләһ, тәрәккыйпәрвәр, милли сәүдәгәр. Мин профессор әфәнденең зур кеше, чын галим икәнлеген үзем аңладым.

Муса. Профессор әфәнде инде милләтебез өчен бик зур мактану. Америка шикелле Америкада профессор булу бу инде җиңел эш түгел. Шуның өстенә иң кадерлесе, профессор хәзрәтләре безнең мәсләктәге кеше икән. Һәрбер тәрәккыебезгә, милли эшләребезгә куанып тора.

Шәехмирза. Мин профессор хакында моннан биш ел элек ишеткән идем. Һәм үзенә бер хат та язган идем...

Сәлим. Әллә сез, Шәехмирза әфәнде, профессор белән якын мөнәсәбәттәме?

Шәехмирза. Ә, әййе, әййе... Мин аның философ икәнлеген тәгаен беләм. Европада, миннән кала, иң зур галимнәрдән саналырга тиешле. Әййе, әййе... Американың яшь галимнәренең иң зурысы инде.

Габдуллаҗан. Американың иң зур галиме безнең агай-энеләрдән бит ә, Сәлим әфәнде? Әгәр дә берәр үткен сәүдәгәребезне дә Америкага җибәреп алсак, андагы сәүдәгәрләрнең арт сабакларын укытыр идек без анда!.. Һи-һи-һи... Американың иң зур кешесе, диең...

Нигъмәт. Муса әфәнде, профессор сезгә шулай туп-туры үзе килеп төштемени?

Муса. Әййе, безнең профессор хәзрәтләре белән мәгънәви танышлыгыбыз күптән инде. Ул минем бөтен әсәрләремне укып чыккан. Мин дә аның хакында француз журналларыннан шактый гына нәрсәләр моталәгә кылган идем. Аннан соң безнең мәрхүм әткәй белән профессор хәзрәтләренең әткәсе шәрик булып укыганнар. Болардан башка профессор хәзрәтләре ана ягыннан безгә кардәш тә була икән.

Сәлим. Нинди уйлар, нинди максатлар белән ул монда килгән?

Муса. Гыйльми тикшерүләр өчен, аннан соң үзенең бәгъзе бер хосусый йомышлары да бар икән.

Сәлим. Нинди йомышлар?

Муса. Гафу итегез инде, анысын сер итеп саклавымны үтенде.

Сәлим. Бу Советлар хакында нәрсә ди?

Муса. Ул хакта озак сөйләшмәдек. Шулай да Советларга кире икәнлеге күренә.

Шәехмирза. Галим профессор булсын да, имеш, кире карамасын.

Сәлим. Юк, алай димәгез, Европада Советлар яклы профессорлар бар.

Габдуллаҗан. Советлар яклы булган профессорларның профессорлыклары да Шәехмирза әфәнденең адвокатлыгы шикелле генәдер инде.

Шәехмирза. Габдуллаҗан әфәнде, сез, беренчедән, мещан, икенчедән, торгаш. Шуңа күрә гыйлем-фән хакында сүз барганда тыңлап кына торырга тиеш.

Габдуллаҗан. Сез, Шәехмирза әфәнде, юләр балык. Башка түгел.

Шәехмирза. Ә син идиот...

Звонок.

Нигъмәт. Әфәнделәр, сабыр. Звонок бар. Профессор килде.

Габдуллаҗан. Ә профессор!.. Хәзер!.. *(Ашыгып чыга.)*

Шәехмирза. Менә койрык сөяге. Спекулянт, ул да сөйләшкән була бит.

Барысы. Тесс-с-с!.. Профессор!..

Тавыш ишетелә.

IX. Әүвәлгеләр, Габдуллаҗан, Насих, Сәлимгәрәй.

Насих. А-а-а, татарның бөтен могтәбәрләре монда икән. Хәерле кич, әфәнделәр.

Күрешәләр.

Нигъмәт. Насих Николаевич әфәнде, сез соңга калдыгыз.

Насих. Мин Сәлимгәрәй мирзаны көтеп тордым. Хезмәт кешесе бит, ахры, урынын ташлап чыга алмады.

Габдуллаҗан. Әфәнделәр, профессор хәзрәтләре килергә тиеш. Шуңар күрә милли банкетыбызны алып бару хакында берәр мәслихәт бирүегезне үтенәм.

Нигъмәт. Чынлап та, банкетның программасын төзергә кирәк. Шуның өчен, шул банкет программасын төзү

хакында фикер алышу өчен, вакытлы гына бер рәис, бер сәркатип сайларга кирәк.

Насих. Сез, Нигъмәт әфәнде, соңгы вакытта тәмам кызыллашып киттегез. Нигә кирәк рәис! Банкет — банкет ул. Сөйләрбез, тост күтәрербез. Шуның белән эш тә бетәр.

Муса. Юк, ул алай түгел, Насих Николаевич әфәнде. Профессор хәзрәтләрен милли эшләребез белән һәм сәяси карашларыбыз, планнарыбыз белән таныштырырга тиешбез. Бөтен татар большевик дип уйлап китә күрмәсен.

Нигъмәт. Минемчә, әфәнделәр, татарның рухын эченә алган бөтен җәмәгать хадимнәребез бергә җыелган җирдә мәсьәләне төплерәк кую мәслихәт. Без һәркаюыбыз үз специальностебыздан сөйләргә тиешбез. Менә, мәсәлән, мин татар зыялылары исеменнән сөйләрмен.

Габдуллаҗан. Нигъмәт әфәнде аны булдыра инде, тик әнә беркөнге, мәйданда сөйләгән төсле генә була күрмәсен инде.

Нигъмәт. Анысы бит аның күз буяр өчен генә иде. Минемчә, нотыкларны үзара бүлешеп куярга кирәк.

Муса. Ярый, мәслихәт. Мин бәйнәлмиләл һәм шәрык сәясәтендә тоткан юлыбыз хакында сөйләрмен.

Шәехмирза. Мин фән һәм шәригать хакында сүз алам.

Нигъмәт яза.

Сәлим. Мин татар тарихы һәм аның имласы хакында мәгълүмат бирермен.

Муса. Мәслихәт, мәслихәт.

Насих. Мин инде большевиклар хакында нотык тотармын.

Сәлимгәрәй. Мин киләчәктә татар милләтенең тотачак хәрби тактикасы хакында рапорт бирермен.

Барысы. Мәслихәт, мәслихәт. Яхшы булыр бу.

Габдуллаҗан. Әфәнделәр, сез инде миңа да берәр сүз табып бирегез.

Муса. Әйе, әйе... Сез инде, Габдуллаҗан әфәнде, банкетны рәсми итеп ачарсыз һәм банкетның рәисе булырсыз.

Барысы. Мәслихәт, мәслихәт.

Шәехмирза. Менә монда мәсьәләнең иң зур ноктасы бар. Кемгә алдан сүз бирелергә тиеш?

Барысы. Чынлап та, бу мәсьәлә мөһим һәм зур!

Нигъмәт. Минемчә, бу мәсьәлә бик җиңел хәл кылынырга тиеш. Профессор зыялы кеше булганлыктан, бе-

ренче сүз зыялылар хакында сөйләүчегә, ягъни миңа бирелергә тиеш.

Муса. Минемчә, гомуми мәсьәлә хакында сөйләүче алдан сөйләргә тиеш. Бәйнәлмиләл, шәрык мәсьәләсе — хәзерге вакытта бик зур мәсьәлә. Шуңа күрә миңа алдан сүз бирелсен. Аннан безнең иске татар гадәте буенча да миңа тиеш. Чөнки мин милләтебез өчен барыгыздан да артык эшләгән, тырышкан кеше.

Сәлим. Минемчә, хәзерге вакытта татар милләте өчен нәрсә мөһим булса, шул хакта сөйләүче алдан сөйләргә тиеш. Тарих, имла мәсьәләсеннән дә зур эшебез юк бит безнең.

Сәлимгәрәй. Әфәнделәр, һәрвакыт банкетларда гаскәриләргә алдан сүз бирелә. Чөнки рапортсыз бернәрсә дә чыкмый. Минем рапорт. Шуңар күрә алдан мин рапорт бирергә тиеш.

Насих. Сез һәркайсыгыз аерым мәсьәлә хакында нотык тотасыз, ә минем нотыгым информация урынында булачак. Шуңар күрә, әлбәттә, баштан мин сөйләргә кирәк.

Габдуллаҗан. Ә минемчә, банкетның рәисе баштан сөйләргә тиеш.

Нигъмәт. Юк, алай түгел ул.

Габдуллаҗан. Синеңчә дә түгел.

Шәехмирза. Үзем баштан сөйлим, үзем.

Муса. Әфәнделәр, башлап мин сөйләргә тиеш.

Насих. Нигә мин түгел, син кем булдың соң?

Нигъмәт. Әфәнделәр, булмаса, тавышка куйыйк!

Барысы. Мин, мин сөйләргә тиеш! Мин!..

Нигъмәт. Әфәнделәр, туктагыз!..

Барысы. Үзем сөйлим, үзем!..

Шау-шу башлана, Апуш керә.

X. Әүвәлгеләр, Апуш һәм Искәндәр.

Апуш. Әфәнделәр!.. Әфәнделәр, Әфәнделәр!.. Профессор хәзрәтләре боерды.

Барысы. Тес-с-с!

Һәммәсе телдән калып сафка тезеләләр. Шул ук вакытта Искәндәр керә.

Искәндәр. Әфәнделәр, сәлам!

Барысы. Мәрхәбә, профессор хәзрәтләре!..

Башларын ияләр. Искәндәр баскан килеш кала.

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук бүлмә.

I. М ә й с ә р ә һәм Д и л б ә р.

М ә й с ә р ә. Кара, кара, Америка профессоры да аракы эчә икән.

Д и л б ә р. Укыган халык эчәргә яраталар, ди әткәй.

М ә й с ә р ә. Кара, кара, йөзе нинди кызарып китте. Яхшы гына төшергәндер, ахры. *(Дилбәрне култыклап.)* Кара әле, Дилбәр, кешегә әйтмәсәң, мин сиңа бер нәрсә сөйләр идем.

Д и л б ә р. Ни эшләп әйтим, Алла сакласын. Сүз ташып йөрергә, мин Чулак Фатыйма түгел ич.

М ә й с ә р ә. Әем, әйтмим. Кешегә сөйләрсең.

Д и л б ә р. Билләһи, сөйләмим. Сөйләр булсам, телем корысын.

М ә й с ә р ә. Сөйләмәссеңме?

Д и л б ә р. Юк, дим инде.

М ә й с ә р ә. Менә, алайса, нәрсә, әлеге Америкадан килгән мөселман профессоры бар бит, әйеме?

Д и л б ә р. Йә, йә?

М ә й с ә р ә. Ләкин, зинһар, кешегә әйтмә. Әткәй мине шул профессорга кияүгә бирә.

Д и л б ә р. Ә профессор ризамы соң?

М ә й с ә р ә. Нәрсәгә?

Д и л б ә р. Сиңа өйләнергә.

М ә й с ә р ә. Әй ябалак, әйтәм ич, зур придан белән дип... Әти әйтә, акча барысын да эшли, ди.

Д и л б ә р. Кара әле, Мәйсәрә, син аңар кияүгә чыкма.

М ә й с ә р ә. Нигә?

Д и л б ә р. Ул бит сине, ата-анаңнан, кардәш-кабиләңнән аерып, әллә кая алып китә.

М ә й с ә р ә. Ә китсә ни? Әти әйтә, ел саен бер кат үзегез күрешергә килерсез, ди. Бер кат үзебез барырбыз, ди. Аннан ул тора торган Америка каласында большевиклар да, Советлар да юк, ди. Автомобильләрдә генә йөриләр, ди. Шулай булгач, кызыктым шул... Алтын-көмеш, энҗе дә бик арзан, ди. Берлиянт шул Америка каласыннан чыга икән. Икмәк урынына анда шоколад кына ашап торалар, ди. Шоколад анда тауда үсә икән.

Д и л б ә р. Теләсәң ни эшлә, үзеңне чукындырсалар, соңыннан үкенерсең дә — кайтмас.

М ә й с ә р ә. Нишләп чукындырсыннар? Әти әйтә, әгәр

дә, ди, шул профессорга барсаң, ди, ни генә сорасаң да кызганмам, ди. Әбәзиян сак тектерермен, ди.

Дилбәр. Әбәзиян маймыл була бит ул. Маймыл тиресе киеп йөрерсеңмени?

Мәйсәрә. Әбәзиян нишләп маймыл булсын ул! Мех ул, бик кыйммәтле мех. Әй мескен, шуны да белмисеңмени? Маймыл булса, кем кияр иде соң аны? Әбәү, маймыл тиресен кияргә!

Дилбәр. Син ул Американың кайда икәнлеген беләсеңме соң?

Мәйсәрә. Хаждан да ерак түгелдер әле. Әнә кешеләр хаждан да кайталар. Әти әйтә, сез миңа Америка каласыннан вагонлап-вагонлап мал җибәрерсез, ди. Мин аны монда сатармын, бик күп кенә акча булгач, алтынга әйләндереп, үзем дә сезнең яныгызга торырга Америкага күчәрмен, ди. Шулай булгач, нишләп риза булмыйм?!

Дилбәр. Аның анда хатыны бар, ди. Көндәш өстенә сине алмакчымыни?

Мәйсәрә. Булса, мин аны баргач та куып җибәрермен.

Дилбәр. Хәер, теләсәң ни эшлә. Мин синең урыныңда булсам, әллә нигә дә аңар кияүгә чыкмас идем. Монда бит сине теләсә кем алыр. Үзең матур, бай, укыган...

Мәйсәрә. Кем укыган, минме? Мин бернәрсә дә белмим. Валлаһи, басканны көчкә генә таныйм. Байлык булгач, укуның нигә кирәге бар? Ярлы кешеләр берәр җирдә хезмәт итеп тамак туйдырыр өчен укыйлар бит. Ә миңа ул нигә? Чү, чыгалар бугай!

II. Дилбәр, Мәйсәрә, Искәндәр, Габдуллаҗан, Насих, Шәехмирза, Сәлим, Нигъмәт, Апуш, Муса, Сәлимгәрәй.

Искәндәр. Әфәнделәр, сезнең белән бер мәҗлестә булуыма мин бик шат! *(Төртә.)* Гафу итегез, без, американлылар...

Насих. Зарар юк.

Искәндәр. Сез мирзамы әле?

Сәлимгәрәй. Шулай, ваше превосходительство.

Габдуллаҗан. Рәхим итегез, утырышыгыз!

Искәндәр. Рәхмәт. Туташлар, рәхим итегез! *(Урын күрсәтә.)*

Дилбәр. Мерси... *(Реверанс ясый.)*

Мәйсәрә Дилбәрнең реверанс ясаганын күреп посып ала.

Н а с и х. Профессор әфәнде, Америкада безнең эмигрантлар күпме?

И с к ә н д ә р. Бихисап.

Н а с и х. Хәлләре ничек?

И с к ә н д ә р. Һәйбәт. Сезнең һәркаюыгызга сәлам әйттеләр. Һәм, мөмкин булса, арыш сохарие җибәрүегезне үтенделәр.

Н а с и х. Нигә? Матди яклары начармыни?

И с к ә н д ә р. Юк, бик яхшы. Һәркемгә дә ватан кадерле бит. Аларның Русиядән килгән арыш сохарие бик ашыйсылары килә.

С ә л и м. Профессор әфәнде, татар тарихы хакында Америка голәмәсе нәрсә ди?

И с к ә н д ә р. Бик шәп, ди.

С ә л и м. Шул хакта Америка голәмәсе берәр нәрсә эшлиме?

И с к ә н д ә р. Бик нык эшли. Ул хакта, гомумән, эшләр бик кызу бара. Татар тарихын тикшерү өчен, махсус алтмыш биш катлы бина төзелде. Һәм дә йөз дә сигез автомобиль әзерләнде.

С ә л и м. Бик күп. Әллә татар тарихы хакында яңа кәшфиятләр дә бармы?

И с к ә н д ә р. Бик күп.

С ә л и м. Кара син аны, бик күп, диең, алайса. Ә татар имласы хакында мәсьәләләр ничегрәк?

И с к ә н д ә р. Хәтта әйтергә мөмкин, бихисап.

С ә л и м. Мәнбәгъләре әсаслымы соң?

И с к ә н д ә р. Бик әсаслы, бик нык, тимер шикелле нык.

С ә л и м. Нәрсә соң ул алай Америка голәмәсен татар тарихын тикшерергә мәҗбүр итте?

И с к ә н д ә р. Мөһим бер ярлык. Ул ярлык хакында мондагы матбугат та бик шаулаган, дип ишеткән идем.

С ә л и м. Теге бер мулланың бер мужиктан урлап алган ярлыгымы әллә?

И с к ә н д ә р. Әйе, мужиктан бер мулла, мулладан бер хәлфә, хәлфәдән бер газета мөхбире, мөхбирдән газета конторщигы, конторщиктан көтепханә назиры, назирдан бер урам каравылчысы урлаган ярлык. Аны аэроплан белән бер спекулянт, Америкага китереп, миллион долларга сатты. Менә инде шул ярлык татар тарихына нык нигез ителеп алынды. Аннан соң иске Болгар ханнарының ярлыкларын, Арслан ханның бөтинамәсенең бер нөсхәсен Һинд голәмәләреннән берсе безгә, Америкага китереп тапшырды.

Габдуллаҗан. Болгар ханнарының ярлыклары, дисезме?

Искәндәр. Әййе, һәм Арслан ханның бөтинамәсе.

Габдуллаҗан. Ул ярлыклар һәм бөтинамә ике нөсхә булганмыни?

Искәндәр. Әйе, ике нөсхә булган. Аны моннан сигез йөз алтмыш биш ел элек Арслан хан җыеп, ике нөсхә яздырып калдырган икән. Шуның бер нөсхәсен без таптык, икенче нөсхәсен Русиядә дигәннәр иде. Шуны эзләргә дип, мин монда килдем.

Сәлим. Соң берсе булгач, аның икенчесе нигә кирәк?

Искәндәр. Дөрес, артык кирәге юк. Ләкин без аларны чагыштырып карамакчы булабыз. Сез, Габдуллаҗан әфәнде, шул ярлыклар хакында миңа берәр мәгълүмат бирә алмыйсызмы?

Габдуллаҗан. Юк, мәгъзүр, бирә алмыйбыз. Миндә ул ярлыклар юк. Мин бернәрсә дә белмим. Аны дошманлык белән генә миндә дип әйтәләр. Миндә бернәрсә дә юк.

Искәндәр. Ә сез, мөәррих әфәнде, шул мөһим ярлыклар хакында бернәрсә дә белмисезмени?

Сәлим. Мин... эһем... Мин... әййе... мин... Эһем. *(Габдуллаҗанга карый.)* Бу хакта Габдуллаҗан әфәнде рөхсәт итсә?..

Габдуллаҗан. Нәрсә син такылдыйсың? Кеше бар дип тә уйлар. Миндә, профессор әфәнде, ярлыклар юк. Әййе, без надан кеше. Без аның рәтен дә белмибез.

Искәндәр. Хәер, без бу хакта икенче вакыт яхшылап сөйләшербез. Шулай түгелме?

Габдуллаҗан. Сөйләшәсе-нитәсе юк, мин бернәрсә дә белмим.

Муса. Теге ишан бабаңнан калган ярлыклар кайда соң?

Габдуллаҗан. Тапты сүз! Мин каян белим? Әнә зиратка барып үзеннән сора. Шифырт дисәң шифырт. Мөгезсез сыер төсле чакырмаган җиргә килеп керә. Менә юньсез!

Искәндәр. Хәер, ул ярлыкларның хәзер безнең америкалылар өчен әһәмиятләре юк. Бездә бит алар бар инде. Мин болай гына сорадым.

Габдуллаҗан. Булмас, ышанмыйм. Аның чыннары сездә булмас! Әйе, профессор әфәнде, ашыйсыгыз килсә, бездә аш бар, эчәсегез килсә, пирәш бар, йоклыйсыгыз килсә, түшәк бар, әмма ярлык-марлык бездә юк.

Искәндәр. Шулаймы? *(Төртә.)*

Габдуллаҗан. Ай!.. Әйе, шулай.

Сәлим. Профессор хәзрәтләре, Чыңгыз хакында Америка голәмәсе нәрсә ди?

Искәндәр. Бик шәп, ди. Әле мин китәр алдыннан гына, Чыңгыз гаскәрләренең Америкага килеп сугышканлыгы һәм Американы алуы турында бик зур гыйльми бәхәсләр булды.

Сәлим. Ничек, әллә Чыңгыз гаскәренең Американы фәтех итүе сабит[1] булдымы?

Искәндәр. Әйе, бик ышанычлы, төпле дәлилләр һәм ярлыклар белән Чыңгыз гаскәренең Шимали[2] Американы алуы фән белән беркетелде.

Сәлим. Хуш, хуш, бу хәбәр – безнең өчен гаҗәп зур вакыйга һәм материал. Бу хакта иртәгә үк журналларга мәкаләләр җибәрәм. Ничек, ничек булган? Хода хакы өчен, сөйләгез әле.

Искәндәр *(төртә).* Гафу итегез! Туташларны зарыктыру булмасмы соң?

Дилбәр. Пардон, мусио!

Мәйсәрә Дилбәрчә кыланып поса.

Сәлим. Хуш, хуш, профессор әфәнде, ничек булган?

Искәндәр. Нәрсә ничек булган?

Сәлим. Америкадагы Чыңгыз гаскәре?

Искәндәр. Ә, әйе. Ул болай булган... Чыңгыз ханның Тимер Йөрәк исемле бер бик көчле батыры булган икән. Көннәрдән бер көнне шул батыр, үз янына короллы йөз кеше алып, Американы сугышып алу максаты белән, зур сәфәргә чыккан. Алты ай сәфәрдән соң, бик каты сугышлар соңында, Шимали Американы алган. Шуннан соң әлеге батыр, исән калган юлдашлары белән, Җәнүби[3] Американы алырга барганда, Кардиллери таулары арасындагы Җон даласына очрап, шунда бөтен гаскәрләре белән харап булган.

Сәлим. Җон даласы, дисезме?

Искәндәр. Әйе, Джунгылы дигән мәшһүр җирне ишеткәнегез бармы?

Сәлим. Әйе, әйе.

Искәндәр. Менә шул Джунгылының асыл исеме

---

[1] Фәтех итүе сабит – яулап алуы ачык.
[2] Шимали – Төньяк.
[3] Җәнүби – Көньяк.

Җон даласы икән. Аңар ул исемне башта татарлар кушканнар икән. Шуннан соң инде америкалылар шул татар сүзе булган Җон даласын Джунгылы дип йөртә башлаганнар.

Сәлим. Профессор әфәнде, мөмкин булса, шул хакта сезнең белән яхшылап бер утырышасы иде.

Искәндәр. Бик мөмкин. *(Төртә.)*

Сәлим. Ай... Рәхмәт!

Мәйсәрә. Дилбәр җаным, кәрчитым кыса, үләм инде. Әйдә, бауларын бераз бушатып керик.

Дилбәр. Мусио, пардон, безнең йомышыбыз бар.

Реверанс ясый. Мәйсәрә дә ясый.

Искәндәр. Рәхим итегез, рәхим итегез!

Дилбәр, Мәйсәрә чыгалар.

Сәлимгәрәй. Виноват, ваше превосходительство! Бездәге бу коммунистлар, Советлар һәм вак-төяк җөмһүриятләр турысында Америка җәмәгатьчелегенең фикере ничек?

Искәндәр. Бик һәйбәт. Быел мамык, шоколад, дөге, автомобильләр бик уңды.

Насих. Профессор әфәнде, менә бу безнең солтанәтле, көчле Рус иле төрле вак җөмһүриятләргә бүленүенә менә безнең ватанпәрвәрчеләрнең йөрәкләре бик әрни. Русның гали ханданы хөкем сөргән вакытларда бөтен халыкка рәхәт иде, татарларга аеруча рәхәт иде. Поляклар, еврейлар алар инде борын-борыннан ихтилалчылар[1] иде. Менә мәрхүм падиша хәзрәтләренең кучеры, ат караучысы татар булган. Менә бит падиша хәзрәтләре дә татарларга ничек ышанган. Менә хәзерге совет власте төрле халыкларга мохтариятлы җөмһүриятләр биреп, утарларны талап алып, халыкны узындырды. Сез уйлап карагыз, җөмһүрият төзегән булып, җыен бала-чаганы эш башына утырттылар. Менә, Муса әфәнде, Шәехмирза әфәнде, Габдуллаҗан байларны һичбер җиргә сайламыйлар. Менә Сәлимгәрәй мирза штатский советник, полковник, хәзер конторщик булып тамак туйдыра. Бу бит мәсхәрәлек. Бу кешенең дәрәҗәсеннән, мәгълүматыннан көлү була. Әле аннан да куарга торалар, ди.

Сәлимгәрәй. Әле тагын көчләп татар телен укыталар.

---

[1] Ихтилалчылар – фетнәчеләр.

Н а с и х. Да, да, бусы инде бик зур ахмаклык. Мин французча, инглизчә, немецча, хәтта японча да укытуны аңлыйм, ә инде татарча өйрәтүне һич башым сыйдыра алмый. Безгә, татарларга, культура кирәк, ә алар татарча укытып маташалар. Безне, яшьлектә татарча укый алмаган картларны, татарча укырга мәҗбүр итәләр. Бу мәсхәрәлек, позор, издевательство! Нигә миңа кирәк татарча уку? Әйтсәгез лә, нигә кирәк? Менә сез мәдәни кеше, Америка профессоры, йә, әйтегез, Америкада французча укыталармы? Укыталар. Японча укыталармы? Укыталар. Ә татарча укыталармы? Юк. Мең мәртәбә юк.

С ә л и м г ә р ә й. Ерунда на постном масле! Менә нәрсә, ха-ха-ха…

Н а с и х. Мәдәни һичбер мәмләкәттә татарча укытмыйлар. Ә монда болар татар теле укытырга уйлап чыгарганнар. Җитмәсә, урысларга да укытып маташалар бит.

С ә л и м г ә р ә й. Мәҗбүр итәләр, ваше превосходительство.

М у с а. Юк, татар телен бөтенләй онытырга ярамый. Милли тел сакланырга тиеш. Ләкин урысларга татар телен өйрәтүгә мин дә каршы. Минемчә, урысларга тел өйрәткәнче, ислам динен өйрәтү артыграк булыр иде.

И с к ә н д ә р. Шулаймы?.. *(Төртә.)*

М у с а. Ай!..

И с к ә н д ә р. Гафу итегез!

Г а б д у л л а җ а н. Бу Советлар, профессор әфәнде, сәүдә эшен бик кысалар. Менә Алла, хәзер суманы ашап ятабыз. Сез инде шул хакта безгә бераз ярдәм итегез. Чыдар хәл калмады бит инде, ахрысы.

Ш ә е х м и р з а. Әгәр дә миңа Америкада профессорлыкка урын тапсагыз, валлаһи, бер көн монда тормас идем. Тәмам туйдырып бетерделәр.

И с к ә н д ә р. Габдуллаҗан әфәнде, сездә тарихи ярлыклар бар, диләр. Мөмкин булса күрсәтегез әле.

Г а б д у л л а җ а н. Миндә?! Миндә, профессор әфәнде, миндә ярлык юк. Миндә бернәрсә дә юк.

И с к ә н д ә р. Шулаймы? Әййе, бер мәртәбә сораган идем бугай… Русиянең аракысын мактыйлар иде, чынлап та шәп икән.

Г а б д у л л а җ а н. Аракы түгел, профессор әфәнде, коньяк.

И с к ә н д ә р. Ә, әйе, коньяк, каньяк, куньяк. Имлачы әфәнде, сез инде коньякны хәзер ничек итеп язасыз?

С ә л и м. Авыздан ишетелгәнчә, профессор әфәнде.
И с к ә н д ә р. Куньяк дипме?
С ә л и м. Әйе, куньяк.
И с к ә н д ә р. Әллә каньяк дипме?
С ә л и м. Әйе, каньяк дип. Ишетелгәнчә инде.
Ш ә е х м и р з а. Габдуллаҗан әфәнде, профессор әфәнде ялыккандыр инде.
Г а б д у л л а җ а н. Кунаклар, бераз ашап аласы иде.
И с к ә н д ә р. Ашадык бит инде.
Ш ә е х м и р з а. Анысы аның банкет закускасы гына иде бит.
И с к ә н д ә р. Шулаймыни?
Г а б д у л л а җ а н. Сез дә, егет, әйдәгез, ә сез, профессор әфәнде?
И с к ә н д ә р. Рәхмәт, минем ашыйсым килми. Тәмәке булса бирегез.
Г а б д у л л а җ а н. Рәхим итегез, рәхим итегез, милли тәмәке.
И с к ә н д ә р. Рәхмәт, минем үземнең радио утым бар.
Н а с и х. Бу Америка гаҗәп могҗизалар тудыра: таяк башында шырпы! Бик оригинальный нәрсә икән.
И с к ә н д ә р. Әгәр дә ул сезгә ошаса, мин аны сезгә бүләк итим. Минем хатирәм итеп тотарсыз.

Таягын суза. Насих алмакчы була.

Н а с и х. Бик рәхмәт, сез галиҗәнап икәнсез, рәхмәт!
И с к ә н д ә р. Юк, бүген үк бирә алмыйм. Иртәгә яки киткәндә, мин аны сезгә калдырырмын.
Н а с и х. Бик рәхмәт!
Г а б д у л л а җ а н. Кызым, кызым, Мәйсәрә, кая югалдың, чүпрәк баш?
М ә й с ә р ә. Нәрсә, атакай?

Д и л б ә р, чыгып, ирләр белән китә.

Г а б д у л л а җ а н. Кызым, профессор абзаң белән сөйләш.

Барысы чыгып китәләр.

Кара әле, берәр нәрсә кирәк булса кычкырырсың! *(Чыга.)*

III. И с к ә н д ә р һәм М ә й с ә р ә.

И с к ә н д ә р. Туташ, утырыгыз!
М ә й с ә р ә. Рәхмәт! *(Посып ала).*

Бер-берсенә карашып, озак сүзсез торалар.

Искәндәр. Туташ, дөньяда сезнең иң зур теләгегез нәрсә?

Мәйсәрә. Иң зур теләкме?

Искәндәр. Әйе, иң зур теләгегез.

Мәйсәрә. Әем, әйтергә оялам.

Искәндәр. Оялмагыз, әйтегез, туташ. Хуш, дөньяда иң зур теләгегез нәрсә?

Мәйсәрә. Кияүгә чыгу. Һи-һи-һи...

Искәндәр. Бик яхшы. Рәхмәт, акыллы сүз әйттегез. Билгедә торткан киявегез бармы?

Мәйсәрә. Бар.

Искәндәр. Кем?

Мәйсәрә. Электәгесеме, хәзергесеме?

Искәндәр. Теләсә кайсы булсын, хуш. Электәгесе кем?

Мәйсәрә. Электәгесе — энҗече Хәбибрахман улы.

Искәндәр. Ә хәзергесе?

Мәйсәрә. Хәзергесе син.

Искәндәр. Мин?

Мәйсәрә. Әйе.

Искәндәр. Рәхмәт. Бу да акыллы сүз. Сез, туташ, бик акыллы икәнсез.

Мәйсәрә. Әти генә мине юләр дип тирги.

Искәндәр. Әткәгез сезне тиргимени?

Мәйсәрә. Бик тирги, тәмам туеп беттем инде үзләреннән. Шуның өчен тизрәк кияүгә чыгасым килә дә бит... Син мине тиргәмәссең бит?

Искәндәр. Юк, юк, мин сине автомобильдә генә йөртермен. Теләсәң, аэропланда очырырмын.

Мәйсәрә. Юк, аэропланда очырма син мине, мин куркам. Башым әйләнеп егылырмын. Автомобильдә генә йөртерсең, яме? Синең үз автомобилең бармы?

Искәндәр. Минем йөз дә биш автомобилем бар.

Мәйсәрә. Йөз дә биш? Бик күп икән. Без иртә белән берсендә, көндез берсендә, кич берсендә, төнлә берсендә йөрербез.

Искәндәр. Ярый, ярый.

Мәйсәрә. Син миңа бик күп итеп энҗе алырсың. Ә син миңа күптәннән гыйшык тотасыңмы?

Искәндәр. Биш елдан бирле.

Мәйсәрә. Мескен. Нигә соң сәлам хатлары бер дә язмадың? Ә туебыз кайчан булыр?

Искәндәр. Теләсәгез бүген үк мөмкин. *(Төртә.)*

Мәйсәрә. Пәрәмәч!.. Нигә төртәсең? Әле никах укылганы юк ич!

IV. Әүвәлгеләр һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Нәрсә, ни бар?

Мәйсәрә. Әти, ул төртә.

Габдуллаҗан. Ә, эһеммм... Кирәк нәрсәгез булса сорагыз.

Искәндәр. Рәхмәт! Габдуллаҗан әфәнде, сезнең кызыгыз гаҗәп акыллы икән. Әгәр дә ул сөйләгән сүзләр дөрес булса...

Габдуллаҗан. Нәрсә, нәрсә?

Мәйсәрә. Әти, без туй хакында сөйләдек.

Габдуллаҗан. Ничек, профессор әфәнде, сез ризамы?

Искәндәр. Риза, ләкин бер шартым бар.

Габдуллаҗан. Приданы? Җаныгыз ни теләсә, шуны бирәбез. Әгәр дә акча кирәк булса, менә рәхим итегез. Хәзердән үк.

Искәндәр. Юк, бик рәхмәт. Минем акчага мохтаҗлыгым юк.

Габдуллаҗан. Соң нәрсә генә?

Искәндәр. Миңа сез придан итеп Болгар ханнарының тарихи ярлыкларын һәм Арслан ханның бөтиен бирергә тиешсез.

Габдуллаҗан. Миндә һичбер төрле ярлык юк.

Искәндәр. Мин әйтәм, бар.

Габдуллаҗан. Юк, профессор әфәнде, миндә ярлык-марлык юк.

Искәндәр. Алай булса, гафу итегез. Мин Муса әфәнденең кызы Дилбәр туташка өйләнәм.

Габдуллаҗан. Хәерче бит ул. Өстенә кияргә күлмәге дә юк бит аның.

Искәндәр. Мин үзем бай. Шул ярлыкларны бирсәгез, бу көннән үк мин сезнең киявегез. Берничә көннән Америкага китәрбез. Теләсәгез, сезне дә алып китәрмен. Аннан товарлар алып кайтырсыз. Миндә кирәкле язуларның барысы да бар.

Габдуллаҗан. Юк, кияү, тфү... профессор әфәнде, миндә ярлыклар... Ничек дисез? Америкадан товар алып килеп булыр, дисезме?

Искәндәр. Теләсәгез, ун вагон.

Габдуллаҗан. Ә, ун вагон? Ярлыкларны бирергә ярамый.

Искәндәр. Аннан соң сездә бит ул ярлыклар базда күмелеп яталар. Ә мине ул ярлыклар бөтен дөньяга мәшһүр итәчәкләр. Менә шулай, Габдуллаҗан әфәнде, бирсәгез, иртәгә туй. Бирмәсәгез, гафу итегез. Мин бүген үк, Дилбәр туташка өйләнеп, Америкага китәм.

Габдуллаҗан. Кияү, профессор әфәнде, теләсәгез җанымны сорагыз, җәл түгел, әмма ярлыкларны бирә алмыйм. Үзем үлгәч, сезгә калдырырмын.

Искәндәр. Димәк, бирмисез?

Дилбәр күренә.

Габдуллаҗан. Бирә алмыйм. Мирас ул.

V. Әүвәлгеләр һәм Дилбәр.

Искәндәр. Алай булгач, гафу итегез. *(Төртә.)* Ә Дилбәр туташ, рәхим итегез! Минем сезгә бик мөһим йомышым бар иде, рәхим итеп утырыгыз!

Габдуллаҗан белән Мәйсәрә яшеренеп каранып утыралар.

Дилбәр. Мирси, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр *(тегеләрнең караганнарын сизеп).* Дилбәр туташ, әткәгез миңа сезнең фикерегезне ирештергән иде. Мин башта Мәйсәрә туташка өйләнмәкче идем, хәзер инде сезгә өйләнергә булдым. Сез ризамы?

Дилбәр. Мирси, мусио!.. *(Реверанс ясый.)* Риза!.. *(Тагын реверанс ясый.)*

Искәндәр. Алайса, иртәгә...

Муса керә.

VI. Әүвәлгеләр һәм Муса.

Муса. Профессор әфәнде, сез мине бик хафага салдыгыз. Гүя сез Габдуллаҗан байның кызына өйләнмәкче буласыз, имеш, дөресме?

Искәндәр. Шулай уйлаган идем.

Муса. Сез ул эшегез белән бик зур ялгышлык эшлисез. Аның кызы юләр, шыр тиле, надан, тәрбиясез, авыру. Аның әбисе дә шашып үлде. Габдуллаҗан үзе дә урлашып кына баеды. Революция вакытында халыкны талап баеды. Жулик, карак ул, кызы дивана.

Габдуллаҗан *(чыдаша алмыйча атылып чыгып).* Кем карак? Кем юләр? Кем жулик? Нәрсәңне урладым? Кем күргән, ә, кем күргән? Тоттыңмы? Ә?.. *(Бугазына ябыша.)*

М у с а. Карак шул! Урлашып баедың.

Г а б д у л л а җ а н. Син үзең шифырт, син үзең күмер карагы.

Бугазга-бугаз киләләр.

М ә й с ә р ә *(Дилбәргә барып).* Мин юләрмени? Мин авырумыни? Минем әтием каракмыни? Сез үзегез мулла нәселе. Сорыкортлар!..

Д и л б ә р. Юләр шул, шыр тиле. Әтиең карак.

М ә й с ә р ә. Каракмы? Менә сиңа, менә сиңа!..

Д и л б ә р. Чеметмә! Җибәр, чеметмә, юләр!

Сугышалар.

И с к ә н д ә р. Туташлар!.. *(Төртә.)* Сабыр!.. Әфәнделәр!.. *(Төртә.)* Сабыр!..

Халык җыела.

Г а б д у л л а җ а н. Җәмәгать, менә шаһит булыгыз, менә бу күмер карагы мине карак дип атады!

И с к ә н д ә р. Җәмәгать, бернәрсә дә юк. Сабыр!.. Болай үзара гына. *(Габдуллаҗанны читкә алып.)* Габдуллаҗан әфәнде, ярлыкларны бирсәгез, хәзер туй итәрбез. Юкса Дилбәр туташ минем хатыным дип хәзер игълан итәм.

Г а б д у л л а җ а н. Ә кем, профессор әфәнде, ни эшлибез соң? *(Мусага.)* У-у-у... сине, күмер карагы! *(Кизәнә.)*

И с к ә н д ә р. Эш сездә. Әгәр хәзер үк ярлыкларны бирсәгез, Мәйсәрә туташ минем хатыным дип хәзер үк игълан итәм. Теләсәгез, туйны да бүген үк итәргә мөмкин. Юкса...

Г а б д у л л а җ а н. Ярый. Аллага тапшырдым. Риза.

И с к ә н д ә р. Юк, кулга ярлыклар кермичә, мин риза түгел.

Г а б д у л л а җ а н. Бетте, бетте, риза. Хәзер алып килермен. У-у, сине, күмер карагы! Йә, Мәйсәрә минем хатыным дип игълан итегез!

И с к ә н д ә р. Әфәнделәр, хәзер мин сезнең алдыгызда бик зур эш ачачакмын... Әфәнделәр, мин өйләнәм...

Б а р ы с ы. Өйләнәсез! Кемгә?

И с к ә н д ә р. Мин... *(Габдуллаҗанга карый, Дилбәргә карый.)*

Г а б д у л л а җ а н. Ярый, ярый, риза. Алып киләм... *(Чыгып барганда.)* У-у... сине, күмер карагы! *(Кизәнә.)*

М у с а. Профессор әфәнде, зинһар, байлыкка кызык-

магыз, кызы юләр бит. Җырлый да, бии дә, пианинода уйный да, французча сөйләшә дә белми. Минем кызым милли алтын бит!..

Габдуллаҗан керә.
VII. Әүвәлгеләр һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Менә, кияү, рәхим ит! Бөтен бәхетемне кызым белән сиңа тапшырам!.. *(Искәндәр, алып, язуларны карый.)*

Муса *(Муса белән Дилбәр бер читтә посып, боегып басып торалар).* Кызым, әйдә, киттек. Дөньяда акчага сатылмаган нәрсә юк икән, Америка профессорлары да акчага сатылалар икән. Әйдә, кызым, үзеңә насыйп милли егет табылыр әле. *(Чыгалар.)*

Габдуллаҗан. Кияү, мунча ягарга кушмыйкмы?

Искәндәр. Кушыгыз!..

Шәехмирза. Профессор әфәнде, Америкага баргач, зинһар, миңа берәр профессорлыкка урын хәзерләп куегыз әле.

Искәндәр. Ничек, Мәйсәрә, бу кешегә профессорлыкка урын хәзерлимме?

Мәйсәрә. Хәзерлә.

Искәндәр. Ярый, профессор булырсың. *(Төртә.)*

Шәехмирза. Бик, бик рәхмәт!.. *(Кулын кыса.)*

Сәлимгәрәй. Профессор әфәнде, берәр полициядә урын табылмасмы?

Искәндәр. Табылыр.

Сәлимгәрәй. Рәхмәт.

Сәлим. Профессор әфәнде, миңа ярлыкларның читләрен генә, әз генә, ерактан гына күрсәтмисезме?

Искәндәр. Күрсәтермен. Әфәнделәр, мин бүгенге милли тарихи кичәне яңача үткәрмәкче булам. Шуның өчен картлардан бер биш минутка гына чыгып торуларын үтенәм.

Барысы. Чыгабыз, чыгабыз!..

Искәндәр. Мин чакырмыйча кермәгез!

Габдуллаҗан. Ярый, ярый, әйдәгез, кунаклар, кияү белән кызның саулыгына бераз пирәшләп ала торыгыз!

Чыгалар.

Искәндәр. Ә син, Мәйсәрә, барып, ак күлмәгеңне киеп чык. *(Төртә.)*

Мәйсәрә. Төртмә әле, юньсез, никах укылганы юк ич әле. Һи-һи-һи!.. *(Чыга.)*

VIII. Искәндәр.

Искәндәр. Мондагы халык үзләре тарихи ярлыклар икән. *(Ярлыкларны күтәреп чыгып китә.)*

IX. Мәйсәрә, соңыннан башкалар чыга.

Мәйсәрә *(кереп, Искәндәрнең киткәнен күреп).* Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм, кая киттең?! Качты, качты!.. Әткәй, әткәй, әткәй!..

Габдуллаҗан. Нәрсә, ни бар?

Мәйсәрә. Әткәй, киявең качты!..

Габдуллаҗан. Ә?

Барысы. Тес-с-с!

Габдуллаҗан. Харап булдык! Нәрсә карап тордың? Соң син, чүпрәк баш, ни карап тордың!..

Барысы. Тес-с-с!.. Тегеннән булмасын.

Габдуллаҗан. Ә?

Барысы. Утларны сүндер!..

Габдуллаҗан. Тес-с-с!..

Барысы. Тес-с-с!..

Утлар сүндерелә.

Пәрдә.

*1923 ел*

# СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАР

*Драма*

*Дүрт пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Сәрвәр — ятимә кыз.
Исмәгыйль — аның сөйгәне, хәзрәттә ялчы. Ятим егет.
Гөлнур — Сәрвәрнең әбисе.
Фәрхи — им-том итүче карчык.
Фатыйма — Сәрвәрнең дус кызы.
Сираҗи — көтүче карт.
Шәйбәк — көтүче малай.
Сафый — кабер казучы.
Беренче егет.
Икенче егет.
Өченче егет.
Беренче кыз.
Саттар — староста.
Писарь.
Мулла.
Мөрид.
Җиһанша — авыл карты.
Насыйр — авыл кешесе.

Егетләр, кызлар, картлар, бер пүнәтәй.
(«Эскадрон», «Каз канаты», «Әтнә», «Уел», «Мәдинәкәй», «Әллүки» көйләре җырлана.)

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уртача тормышлы авыл өе.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрвәр ялгыз.

Сәрвәр *(ялгызы тәрәзә янында чигү чигеп, җырлап утыра)*.

Ефәкләрем төшми тамбур булып
Сөйгәнемә дигән сөлгегә.
Янды йөрәк, янды күмер булып,
Шулай янар микән мәңгегә.
Чигүләрем төшми ефәкләргә,
Тамбур инәкәем нечкәгәй.
Утлар капты ярсу йөрәккәйгә,
Басылмыйдыр иртә, кичләр дә.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль, Сәрвәр.
Исмәгыйль тәрәзәдән җырлый.

Исмәгыйль.
Кирге киереп кызлар, ай, чиккәндә,
Егет күзе төшә бармаккай.
Көмеш булса дәртле йөрәккәең,
Кызыкма син алтын балдаккай.
Сәрвәр.
Кызыкмыйм мин алтын балдакларга,
Күңелем төшкән ярлы егеткә.
Киндер күлмәк, кургаш балдакка да
Разыймын мин, егет, гомергә.
Исмәгыйль.
Көньягыннан үкереп болыт килә,
Әллә яңгыр, юкса боз микән?
Яшермә син, Сәрвәр, дөресен сөйлә,
Нәрсә сизеп ярсый йөрәгең?
Сәрвәр.
Тамбур энәләрем сөяк саплы,
Мимеч илләреннән алынган.
Ярсый күңелем, ярсый, урын тапмый:
Гыйшык уты аңар кабынган.
*(Оялып борыла.)*

И с м ә г ы й л ь. Сәрвәр җаным, сиңа сөенеч, үземә көенеч хәбәр китердем.

С ә р в ә р. Нәрсә, нинди хәбәр?

И с м ә г ы й л ь *(хат биреп).* Менә мәхдүмнән хат!..

С ә р в ә р. Мәхдүмнән?.. Миңамы?.. *(Хатны ала да укымакчы була.)* Юк, юк, миңа булмас, син ялгышкан.

И с м ә г ы й л ь. Сиңа, сиңа, ышан. *(Тәрәзәдән бүлмәгә керә.)*

С ә р в ә р *(хатны укып).* Булмас, булмас. Ялган!.. Син, мине сынар өчен, бу хатны китергәнсең, шулаймы, сынар өченме?

И с м ә г ы й л ь. Юк, юк, Сәрвәр. Кушканны эшләргә мин тиеш. Үземнең баемнан үз сөйгәнемә хат тапшырырга мин тиеш, күрәсең... Миңа ни кушсалар, мин шуны эшләргә тиеш. Мин ялгыштым, мин ялгыштым, Сәрвәр, сине сөеп мин ялгыштым. Миңа башканы, үз тиңемне сөяргә кирәк иде. Ә мин әрсезләндем. *(Күңелсезләнә.)*

С ә р в ә р. Юк, юк, Исмәгыйль, син ялгышмадың... Мин сине генә сөям. Мин мәхдүмне сөймим, сөя алмыйм. Аны кызгансам да сөя алмыйм. Бу инде аның йөз дә беренче хаты... Юк, мин аны сөя алмыйм...

И с м ә г ы й л ь. Менә хәзер Фәрхи әби белән монда килергә җыенып калдылар. Фәрхи әби, сине яучылап, синең белән мәхдүмне күрештерергә килә. Хәзер алар килеп җитәрләр, син күнәрсең. Алар сине җиңәрләр.

С ә р в ә р. Син миңа ышанасыңмы-юкмы?

И с м ә г ы й л ь. Ышанам, Сәрвәр, бик ышанам, шулай да без кавыша алмабыз. Мин аны беләм, әйе, без кавыша алмабыз. Сәрвәр җаным, гомере ятим булдым, гомере кеше кулында үстем, кеше эшләрен эшләп гомерем уза. Гомеремдә миңа синнән башка якты чырай күрсәткән, татлы сүзләр әйткән кеше булмады. Син минем атам-анам да, син минем байлыгым да, син минем барысы, барысы... Мин сине, сукадан арып кайтып яткач, төшемдә күреп уянсам да, яңадан йокыга китмәскә тырышып, сине уйлап таңнар аттырадыр идем. Минем бөтен рәхәтем, бөтен шатлыгым, бөтен кинәнечем син, синең хакында уйлау. Сине миннән аерганчы, мине бәреп үтерсәләр, миңа мең мәртәбә җиңелрәк булыр иде. Сәрвәр җаным, син үз рәхәтеңне кара. Чынлап та, миңа килеп уңмассың. Гомеребез кеше кулында хезмәттә үтәр. Синең авыр көн күрүеңә карап минем йөрәгем әрнер. Син, булмаса, мәхдүмгә чык. Мин алардан чыкмам. Ичмасам, һәр көн йөзеңне күреп

торырмын. Син мәхдүмгә чык. Юкса безне барыбер аерырлар. Безгә кавышу насыйп булмас.

Сәрвәр. Исмәгыйль, әйт, мине сөясеңме?

Исмәгыйль. Мин сине сөям дию генә аз... Менә мин сине... мин сине... юк бит, юк, аңлатырга сүз юк! Менә хәзер тотып үтер, мин риза, мин күңелемнән синең кулыңнан үләргә дә риза. Алай гына да түгел. Менә мин сине шулкадәр сөям, яратам, дус күрәм. Аңлатырга сүз генә таба алмыйм... Их, Сәрвәр, менә мондагы хәлемне аңлата алмыйм... Синең белән сөйләшә башлагач көләсем дә, елыйсым да килә. Йөрәкләрем кытыклана... Сине миннән аерып алулары күңелемә килгәндә, мин үләм... Юк, үзем үлмим, йөрәгем үлә. Син, Сәрвәр, тере кешенең йөрәге үлүнең авырлыгын белмисең... Менә ул өзелеп төшә. Юк, өзелеп тә төшми. Менә бөтенләй югала... Иреннәрем кибеп калтырый башлый. Тыным кысыла... Шулай уйлап катып торам-торам да тагын эшкә китәм. Тагын сине уйлыйм... Сөйгән кешегә йөрәк хәлен аңлату читен икән.

Сәрвәр. Исмәгыйль җаным! Күңелеңне тыныч тот... Мин дә шулай ук. Синнән аерылуны уйлаганда, минем дә шулай ук йөрәгем үлә. Безнең йөрәкләребез моннан соң үлмәсләр... Ышан, мин синнән башкага чыкмыйм... Валлаһи, чыкмыйм. Исмәгыйль җаным, алай мине азаплама!.. Юк-бар фикерләрне башыңа китермә. Менә көзгә туй итәрбез... Әби дә күнә. Безгә күчәрсең, үз йортыбыз, үз кәҗәбез булыр. Хәлләнә төшкәч, сыер алырбыз. Исмәгыйль, көзгә безнең, бәла-казадан үлмәсәләр, егерме дүрт баш казыбыз, унике үрдәгебез була. Туйда кунаклар ашасыннар гына, менә хәзердән үк тот та мине үз хатының итеп үк уйла. Мәхдүмгә мин ассалар да — чыкмыйм. Дөрес, мин аны бик кызганам. Зәгыйфь кеше, бичара.

Исмәгыйль. Ул да бәхетсез шул... Мин ятим, кеше кулында гомергә ялчы булуым белән бәхетсез. Ә ул үзенең зәгыйфьлеге белән бәхетсез.

Сәрвәр. Менә миңа өйләнгәч, бәхетле булырсың. Менә күр дә тор. Мин сине бәхетле итәргә тырышырмын. Үткән авыр көннәрең сагынып сөйләргә генә калыр.

Исмәгыйль. Юк, Сәрвәр, безгә кавышу насыйп булмас.

Сәрвәр. Сиңа ни булды? Ник тузга язмаганны сөйлисең? Кем безне аерсын?

Исмәгыйль. Белмим... Шулай да безне аерырлар. Тәгаен аерырлар. Мин төшемдә шулай күрдем. Өч тап-

кыр шул бер үк төшне күрдем. Берсе синең белән беренче күрешкән көнне булды. Икенчесе менә яулыкны биргән көнне булды. *(Яулыкны бүрек астыннан чыгарып күрсәтә.)* Өченчесен кичә күрдем... Их, Сәрвәр, уянгач, шушы яулыкны үбә-үбә елаганны белсәң иде. Бик каты еладым. Менә хәзер дә йөрәгем авыртып тора. Аерырлар безне, Сәрвәр, аерырлар. Белмим мәхдүм безне аера, белмим башкасы. Сәрвәр җаным, ике күзем, мин синнән башка ни эшләрмен?

Сәрвәр. Исмәгыйль бәгырем, яман төшләр күп вакытта хәерле дә була бит. Бәлки, безнең кавышуыбызгадыр. Каян беләсең аны?

Исмәгыйль. Шулай булса, ни генә әйтер идең. Булмас шул, булмас.

Сәрвәр. Йә әле, күргән төшеңне сөйләп кара әле, ничек күрдең?

Исмәгыйль. Без югары оч Таз Хисам, Мифтах, Чулак Сәләхи Шакиры, Тавык күз Минһаҗы, Каюм, тагын әллә нинди бик күп танымаган, гомердә күрмәгән егетләр шунда...

Сәрвәр. Йә, йә, йә, ничек күрдең?

Исмәгыйль. Төшемдә көзге караңгы төн, имеш. Күктәге йолдызлар шундый яктылар, имеш. Бөтен җир йөзен яктыртып, бик күп авыллар, шәһәрләр аларның нурларыннан яктырып, күренеп торалар, имеш. Безнең авылның өстендәге йолдызлар башка йолдызларга караганда яктырак, имеш. Кайдадыр, урман дисәң — урман түгел, кыр дисәң — кыр түгел, бер урында бик күп егетләр җыелганнар икән дә һәркайсы үзенә берәр йолдыз алганнар икән. Син дә шул арада үзеңә йолдыз сайлагансың, ди. Мәхдүм дә сайлаган, минем дә йолдызым бар икән. Менә кинәт аждаһа төсле бер нәрсә сызгырды да йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде. Тагын бик күп, бик күп егетләрнең йолдызлары сүнеп, күк йөзе корымлы кара таба төсле караңгыланып, каралып калды.

Синең белән бер тау астында торабыз, ди. Таудан кан ага, ди. Менә шул кан безне батыра, ди. Без тауга менәргә азапланабыз, ди. Бөтен киемнәребез, кулларыбыз кып-кызыл кан, ди. Үзебез тауга менә алмыйбыз, ди. Менә шуннан каннар белән бергә бик зур, әллә тагын кырык башлы бер аждаһа килеп чыкты да, ди, безне берәмберәм ашый башлады, ди. Сәләхине дә ашады, Шакирны да ашады, минем янымда торган Каюмны да ашады.

Авызын ачып мине кабам дип торганда, аның авызыннан син чыктың да, минем күкрәгемә бик зур пычак тыгып, йөрәгемне тартып чыгарып ашый башладың, авызыңнан, борыннарыңнан кан ага, ди... Үзең кычкырып көләсең, ди. Шуннан аждаһаның ике башы берьюлы икебезне дә кабып йотты. Шуннан соң...

Сәрвәр *(елап)*. Җитәр, җитәр, җитәр... Юк, юк, бу — ялган төш, бу дөрес түгел. Син һаман мине уйлаганга гына шулай төшеңә кергән. Юк, юк. Ышанма, бу — ялгыш төш.

Исмәгыйль. Юк, Сәрвәр, ышанмасам да, эч поша. Бу — дөрес төш. Өч тапкыр бит шулай күрәм, өч тапкыр. *(Пауза. Җырлый.)*

Төшләремдә күреп киләчәкне,
Бәхетсезлек көтеп торам мин.
Алда торган кара күрәчәкне
Күреп гүр иясе булырмын.

Сәрвәр.

Алданып син юк-бар, ай, төшләргә,
Үз бәхетеңне үзең кисәсең.
Синең белән бергә күрәчәккә
Батыраеп каршы барам мин.

Исмәгыйль.

Аждаһалар чорнап тирәбезне,
Сине миннән тартып алырлар.
Сине миннән, сине, Сәрвәремне,
Талап, мине мәхрүм итәрләр.

Исмәгыйль, Сәрвәр.

Сулар ага дулкын-дулкын,
Дулкыннарга каршы кем йөзәр.
Дулкыннарга каршы йөзә алган
Дусларың шулай кул сузар.
*(Бер-берсенә кулларын бирәләр.)*

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрвәр һәм Гөлнур.

Гөлнур *(тыштан)*. Көш, көш, көш, дим... Үз йортыңа кит!..

Исмәгыйль чыга, әби керә.

Сәрвәр бәбкәм, кызыл канатның оясын таптым. Келәт астына оялаган икән. Унбер йомырка... Берсен маяга кал-

дырдым. Салават койрык астына куярга кирәк. Теге Миңлиса тавыгы салмый башлаган, кырылдап йөри. Салкын су белән коендырып, баскыч астына ябып куйдым. Җим салырга оныттырма, оныттыра күрмә.

Сәрвәр. Әби, төштә йолдызлар сүнсә, ни була?

Гөлнур. Нигә?

Сәрвәр. Юк, болай гына сорыйм...

Гөлнур. Төшне һәрвакыт яхшыга юрарга кирәк. Төштә кан күрү, күз яше – кайгы, бәла-каза галәмәте.

Сәрвәр. Ә төштә тауга менә алмасаң, ни була? Аждаһа күрсәң, ни була?

Гөлнур. Ни булсын. Әгәр аждаһаны болыт күтәреп алып киткән булса – хәерлегә. Хәер, йокың туйса уянырсың. Мондагы чуар тавык йомыркалары кая соң?

Сәрвәр. Гөлҗамал тәтәйгә бурычка бирдем. Кияүләре килгән икән, тавык тутыралар.

Гөлнур. Әсхәпҗамал терелгән микәнни?

Сәрвәр. Терелгән, ди. Әби, аждаһа берәр кешене ашаса, ни була?

Гөлнур. Кара аждаһа – кабер, дигән. Кемне ашый, шул үлә. Кызыл аждаһа – янгын, сары аждаһа – ачлык, яшел аждаһа – үләт, ди... Ярабби, бәла-каза, үлем-җитемнән үзең сакла. Сәрвәр бәбкәм, мин Җиһаншага барам. Каты сабанымны кайчан сукаларга керешә икән? Аңар он бирергә кирәк. Бер умачлык та оныбыз юк. Каян алып бирергә инде? Икендегә кадәр кайтмасам, инешкә төшеп бәбкәләрне алып кайтырсың. Аннан соң...

Сәрвәр. Әби, төштә йолдызлар сүнгәнне күрсәң, ни була?

Гөлнур. Йолдызлар сүнсә...

Фәрхи керә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Фәрхи.

Фәрхи. Юлым уң булыр. Өйдә икәнсез. Саумы, Гөлнур, саумы, Сәрвәр бәбкәм. Буй кыз буласыңмы инде? Йә, бер дога кылыйк!.. *(Тәрәзәдән күренгән Надирга изи.)* Сәрвәр кызым, ятимлектә үссәң дә, ата-аналы кызлардан зифа, матур булып үсәсең. Бәхетең дә бар икән. Сөенчедән буш калдырмассың инде. Гөлнур, бик зур йомыш һәм бик зур илтифат белән килдем.

Гөлнур. Нәрсә алай? Игелек теләп йөрүеңә бик рәхмәт инде.

Фәрхи. Сүзне боргалап сыргалауда файда юк. Йомышым менә шул. *(Кулы белән Надирга изи.)* Сәрвәр бәбкәм, якынрак кил әле, менә нәрсә: хәзрәтебез Надир мәхдүменә Сәрвәргә яучы итеп җибәрде.

Сәрвәр *(сискәнеп)*. Нәрсә?!

Фәрхи. Бик бәхетле сәгатьтә тугансың икән, бәбкәм. Остабикә булырга тәкъдиреңдә язылган, күрәсең... *(Кулы белән Надирга изи.)* Менә шул, бөтен туй чыгымын хәзрәт үз өстенә ала. Бер тун, ике йон күлмәк, мамык шәл, читек-кәвеш, шәһәр юрганы, камзул, бер мамыклы, бер мамыксыз бишмәт, бирнәлекләр алырга дүрт йөз сум акча... Бәхетең бар икән, бәбкәм. Мәхдүмгә киләсе елга указ алып, үз янына имам итмәкче. Хәзрәт үзе дә өч-дүрт елдан артык тормас. Хәзердән үк эченә бик каты катулар чыга башлаган инде. Карт остабикәнең гомере әллә ни озак булмас. Шулкадәр дәүләткә үзегез хуҗа булып калырсыз. Йә Гөлнур, туйны кайчан билгелисез?

Гөлнур. Сәрвәр бәбкәм үзе ни әйтер бит.

Фәрхи. Сәрвәр – гакыллы кыз ул. Уйлап җавап бирер.

Гөлнур. Сәрвәр бәбкәм, ни әйтерсең? Ят җир түгел, үлгәндә, янымда булырсың.

Сәрвәр. Әби, мин мәхдүмгә чыкмыйм. Мин аны сөймим. Мин аны кызганам. Ул миңа атна саен хатлар язып торды. Мин җавап язмадым. Аны сөймим, минем... минем...

Фәрхи. Нәрсә? Синең әллә башка сөйгән егетең бармы?

Сәрвәр. Көзгә мин башка кешегә... Әбекәем жаным, мине мәхдүмгә бирмә. Минем сөйгән кешем бар. Әбекәем бәгырем, мине хур итмә!..

Гөлнур. Чү, чү, бәбкәм! Нигә елыйсың? Мин бит әле бирәм дигәнем юк. Үз бәхетең үзең өчен, теләсәң нишлә!

Фәрхи *(Надирга кулын изи)*. Сәрвәр, балакай. Акрын, бу сүзләреңне күрше-фәлән ишетә күрмәсен. Күзеңне ачтырмаслар, хәзрәткә килен булмыйча, әллә көтүче Гайнуллага килен булмакчы буласыңмы? Килгән нигъмәтнең кадерен бел!

Сәрвәр. Фәрхи әби, борчылып йөрүегезгә бик рәхмәт, мин мәхдүмгә чыкмыйм. Үлсәм дә, мин аңар чыкмыйм... Мин аңардан... мин аңардан... Әбекәем бәгырем, мине мәхдүмгә бирмә, мин аны сөймим.

Фәрхи. Никах, балакай, үзе мәхәббәт тудыра. Барыбыз да кыз булдык. Барыбыз да кияүгә чыкканда башта

сөймәдек. Еладык. Никахтан соң күгәрченнәр шикелле тордык. Никахта, балакай, җитмеш җиде мең намаз уку савабы бар, ди. Бәлки инде, син аның зәгыйфьлегеннән курка торгансыңдыр? Бер сугуда бүре үтерерлек көч бар аңарда. Ә белем, гыйлем дисәң инде — дәрья. Шәйморзада укыган бит. Менә ничә ел инде хәлфә булып тора. Алдыңа килгән нигъмәтне кайтарсаң, гомере игелек күрмәссең. Сөйгән егетең дә әллә кем түгелдер. Бер мужиктыр шунда. Ә боларның бит нәселе ун буыннан бирле мулла булып килә. Озакламыйча хәзрәт үзе мөридләр кабул итмәкче була, ди. Ишан килене булырсың.

Гөлнур. Кем, Фәрхи, Сәрвәр белән яхшылап сөйләш. Сәрвәр бәбкәм нәрсә дисә, мин шуңар риза инде. Минем Җиһаншага барасым бар иде. *(Тора.)*

Фәрхи. Юк, алай җиңелгә алырга ярамый. Хәзрәтнең хәтере калуы да бар бит. Бүген-иртәгә гүр иясе булырга торабыз бит. Җеназабызны укып тәлкыйн кылучы[1], ясин укучыбыз ул бит. Ахирәт ягын да уйларга кирәк.

Гөлнур. Мин Сәрвәр күңгәннең барысына да күнәм. Сәрвәрнең теләгенә каршы баралмыйм. Мәрхүм ата-анасының васыятьләре шулай. Сәрвәр бәбкәм, самавыр куй. Чәйгә кадәре мин кайтып җитәрмен. Фәрхи түтине чәй эчермичә җибәрергә ярамый... Хәзергә сау бул. Самавыр кайнаганчы кайтып җитәрмен. *(Чыга.)*

Фәрхи. Йә кызым Сәрвәр, син моңарчы юләр түгел идең. Алай намуссызланма. Санга санап каршыңа килгәннең кадерен бел. Мәхдүм сине бик сөя икән. Тәмам гыйшык булган.

Сәрвәр. Фәрхи түти, минем сүзем бер. Минем билгеле кешем, биргән вәгъдәм бар. Мин ике якка бүленә алмыйм.

Фәрхи. Соңгы сүзең шулмы?

Сәрвәр. Шул, Фәрхи түти.

Фәрхи. Мин илче, илчегә үлем юк, диләр. *(Надирга керергә ымлый.)* Алдыңа килгән оҗмах нигъмәтен кире какканың өчен, дөньяда ук үкенерсең. Син соң алдан егетләр хәзерләп куеп кияүгә чыгуны кемнән өйрәндең? Атаң-анаң да инсафлы кешеләр иде ләбаса. Бу сүзеңне икенче кешегә әйтә күрмә. Хур булырсың. Илдә күренмәгән мондый хурлыкны каян уйлап чыгардың?

Мәхдүм керә.

---

[1] Тәлкыйн кылу — мәетне җирләгәннән соң дога уку.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Надир мәхдүм.

Надир. Исәнмесез, Сәрвәр туташ!..

Сәрвәр куркып, калтырап чыкмакчы була.

Фәрхи *(каршы төшеп)*. Чү, чү, Сәрвәр, алай инсафсызланма. Каршыңда көтүче Сираҗи Гайнулласы түгел бит, мәхдүм тора. Алай әрсезләнергә ярамый.

Надир. Фәрхи абыстай, минем Сәрвәр туташка берике генә сүзем бар иде, мөмкин булса...

Фәрхи. Ярый, ярый, мәхдүм, мин дә чыгам. *(Чыга.)*

Сәрвәр. Фәрхи түти, чыкма. Юкса мин дә чыгам. *(Чыкмакчы була.)*

Надир *(каршы төшеп)*. Сәрвәр туташ, әгәр дә мин сезне телем яки кулым белән рәнҗетсәм, шушы якты кояшны күрү хәрәм булсын!.. Мин сезне ихтирам итәм. Мин, сезгә үземнең эч серләремне сөйләргә дип, яучым белән бергә килдем. Мине яратмавыгызны хатларыма җавап бирмәвегездән үк аңладым. Ләкин сез мине аңламыйсыз әле. Минем тышкы күренешем шәйтанга охшаса да, миндә җан, йөрәк бар. Бәлки, минем шул җанымны, йөрәгемне аңларсыз.

Сәрвәр. Мин сезне, Надир мәхдүм, кызганам.

Надир *(кызып)*. Юк, мин үземне сездән кызгандырырга килмәдем. Мине кызганган кеше минем дошманым. Мине Алла кызганмаган бит. Адәмнәр дә мине кызганмасыннар. Мин теләмим!.. Гафу итегез, мин сезнең белән тупас сөйләшәм. Менә мин, Сәрвәр туташ, Алла тарафыннан җәберләнгән, Сәлях хәзрәт баласы, зәгыйфь, шәйтан кыяфәтле, гурбун мәхдүм. Сезнең алдыгызда сезнең мәхәббәтегезне сорарга килдем. Мин сезне сатып алырга теләмим. Аз гына миңа ышанычыгыз, аз гына миңа илтифатыгыз булса, шул җитә. Сез мине бервакытта да янып, өзелеп сөя алмассыз. Анысы мөмкин дә түгел. Мине кешеләр түгел, шәйтан да, җен-пәриләр дә сөя алмаячак. Мин аны беләм. Сез миннән җирәнмәсәгез, шул җитә. Ә мин сезнең гомергә аяк астыгызда туфрак булыр идем. Мин сезне сөям. Мин сезнең кара кашларыгыз, зифа буйларыгыз белән бергә, мин сезнең җаныгызны, йөрәгегезне, мине сөйми торган йөрәгегезне сөям. Яңадан әйтәм, әгәр дә сез миннән җирәнмәсәгез, мине кызганмасагыз, шул җитә.

Сәрвәр. Мин сезне кызганам.

Н а д и р. Ярамый, ярамый. Мине кызганырга ярамый. Сез ялгышасыз, мин кызганыч түгел. Мин кызганыч түгел. Мине кызгану газаплы. Сез мине һичбер вакытта да кызганмагыз. Менә мин, мине яраткан көчләргә үч итеп, үземне кызгандырмыйм. Мине беркем дә кызганмас. Мин сездән башка бөтен дөньяга дошман, ачулы кеше. Сез мине хәзер дә, киләчәктә дә, һичбер вакытта да кызганмагыз... Мин сездән үтенәм, мине кызганмагыз. Миңа ул тәмуг газабы белән бер. Сезгә генә минем ачуым юк. Сез шуны аңлый алырга тиеш. Менә ике елдан бирле шул авылда диварга кадакланган шәмаил төсле торам. Сезнең өчен, сезнең өчен, Сәрвәр туташ. Бәлкем, минем шул кыяфәтем белән мондый сүзләрне сөйләү — ахмаклыктыр да, әрсезлектер дә. Анысын мин уйламыйм. Мине яраткан Аллам тарафыннан читкә кагылган төсле, кешеләр тарафыннан да читкә кагылган мәзлүм. Мин ялгыз идем. Аңлыйсызмы, егерме биш яшькә кадәр ялгыз идем, сез ул ялгызлыкның авырлыгын белсәгез иде... Әйе, бәхетле кешеләр ул ялгызлыкның авырлыгын һичбер вакыт хис итә алмаячаклар. Менә ике елдан бирле мин шул авыр газаплы ялгызлыктан котылып тора башладым. Сез коткардыгыз, Сәрвәр туташ. Хыялымдагы сезнең җисмегез мине шул ялгызлык газабыннан коткарды. Мин ике елдан бирле су буйларына, зиратларга, урманнарга барып җырлыйм. Егерме биш яшемә кадәр мин җырның нәрсә икәнен дә белмәгән идем. Сез миңа җан керттегез, сез миңа егерме биш яшемә кадәр күрә алмаган бәхетнең нурын күрсәттегез... Әйе, мин... җырлыйм... Җырлаганда, бөтен күңелем белән җырлыйм. Каршымда сезне фараз кылып җырлыйм. Дөрес, мин мөнәҗәтләрдән башка көй белмим... Менә шул мөнәҗәт көйләрендә үземнең хисләремне күрсәтә алам. Менә хәзер дә җырлыйсым килә. Сез миннән көлмәгез, мөмкин булса җавап бирегез. Орышыгыз, сүгегез, теләсә ни эшләтегез, тик җавап кына бирегез... Мин, бәлки, моннан соң җырлый алмам инде. *(Җырлый.)*

Һәр сәхәр вакытында төшемдә күрәм,
Мин сезне, мин сезне, Сәрвәр җан, сөям.
Сәрвәр, янам мин, аһ, әман[1], әман, әман!

И к ә ү б е р г ә.

Мин сезне, мин сезне, Сәрвәр җан, сөям!
Мин сезне, мин сезне, мәхдүм, сөя алмыйм.

---

[1] Ә м а н — мәрхәмәт кылыгыз.

С ә р в ә р.
Күбәләк гөлләрдә тәхетләр сайлый.
Мин сезне, мин сезне, мәхдүм, сөя алмыйм.
Мәхдүм, сөя алмыйм, аһ, әман, әман!
И к ә ү  б е р г ә.
Мин сезне, мин сезне, мәхдүм, сөя алмыйм.
Мин сезне, мин сезне, Сәрвәр җан, сөям.
Н а д и р.
Янган йөрәкләргә шифа даруын
Мин сездән, мин сездән, Сәрвәр, көтәм.
Сәрвәрем, янам мин, әман, әман, әман!
И к ә ү  б е р г ә.
Мин сездән, мин сездән, Сәрвәр, көтәм.
Мин сезгә, мин сезгә, мәхдүм,
бирә алмыйм.
С ә р в ә р.
Янган йөрәкләргә шифа даруын
Мин сезгә, мин сезгә, мәхдүм, бирә алмыйм.
Мәхдүм, бирә алмыйм, аһ, әман, әман!
И к ә ү  б е р г ә.
Мин сезгә, мин сезгә, мәхдүм, бирә алмыйм.
Мин сездән, мин сездән, Сәрвәр, көтәм.
Н а д и р.
Тәңреләр, кешеләр чит күргән җанны,
Ят күреп, ят күреп, читкә какмагыз.
Сәрвәр, янам мин, аһ, әман, әман, әман!
И к ә ү  б е р г ә.
Ят күреп, ят күреп, читкә какмагыз!
Ят булып, ят булып, шулай калыгыз!..
С ә р в ә р.
Мин сезне кызганам чын күңелдән.
Ят булып, ят булып, шулай калыгыз!..
Мәхдүм, сөя алмыйм, аһ, әман, әман, әман!
И к ә ү  б е р г ә.
Ят булып, ят булып, шулай калыгыз!
Ят күреп, ят күреп, читкә какмагыз.
Н а д и р.
Иң соңгы өметне сез үтермәгез,
Мин сезне, мин сезне, Сәрвәр җан, сөям.
Сәрвәр, янам мин, аһ, әман, әман, әман!
И к ә ү  б е р г ә.
Мин сезне, мин сезне, Сәрвәр җан, сөям.
Мин сезне, мин сезне, мәхдүм,
сөя алмыйм.

Сәрвәр.
Йөрәгем ачкычы башка кулында,
Мин сезне, мин сезне, мәхдүм, сөя алмыйм.
Мәхдүм, сөя алмыйм, аһ, әман, әман, әман!
Икәү бергә.
Мин сезне, мин сезне, мәхдүм, сөя алмыйм.
Мин сезне, мин сезне, Сәрвәр җан, сөям.

Исмәгыйль читтә җырлый. «Эскадрон» көенә.

Исмәгыйль.
Төшләремдә күрәм аждаһалар,
Өннәремдә кайчан күрермен?
Малга кызып анда җан саталар…
Хәбәрләрен кайдан белермен?

Сәрвәр, дәртләнеп, тәрәзәгә барып тыңлый. Надир тешләрен кысып, йодрыгын йомарлап, чырайларын сытып, бөтен нәрсәгә каһәр иткән кыяфәттә катып кала.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Фәрхи белән Гөлнур сөйләшеп керәләр.

Фәрхи. Алла, Гөлнур, нәрсә генә ашатып ул казларыңны болай симерттең? Берсеннән-берсе симезләр. Хан табынына куйсаң да, йөз кызарырлык түгел. Ничә баш үзләре?

Гөлнур. Егерме дүрт баш: икесе коега төшеп үлде, берсен тилгән урлады, берсен теге Хисами балаларының бурзай этләре буган.

Фәрхи. Нигә болай иртә йолыктырасың? Салкыннар да башланмаган бит әле.

Гөлнур. Калага җибәртеп сатарга уйладым. Көзне көтсәң, үткән елгы кебек, коры калуың да бар. Үзеңнең ничек?

Фәрхи. Быел минем әллә нишләп каздан бәхет булмады. Ике оядан барлыгы сигезе борнап чыкты. Икесе бәбкә чакларында инештә югалдылар. Икесен никрутлар суйганнар.

Г ө л н у р. Никрут дигәннән, Тавык Күз Зарифына ни булган? Нишләп сине тиргиләр?

Ф ә р х и. Яхшылык иткәнгә. Кешегә нихәтле яхшылык итәргә тырышсаң, шулхәтле сиңа дошман булалар икән. Алладан килгән казаны бәндәдән күрү үзе кяферлек, ди бит хәзрәт…

Г ө л н у р. Җен кагылганмы әллә чынлап та?..

Ф ә р х и. Җен шомлыгын миннән күрәләр. Шул Зарифлары, Фәрхи әби, зинһар, мине солдаттан калдыр, калдыр, дип ялынгач, барлыгы утыз пот арышка ишан хәзрәт даруын колагына гына салдым. Безнең мужик, надан халык, ни белә соң! Тәһарәте булмаган икән, шул, җен сугып авызлары кыйшаеп, телләрен зәхмәт сугып, хәзер үләргә ята. Менә шуны миннән күрәләр, янәсе, дару килешмәгән, имеш. Әнә Әфтах малае, Сыерчык Сибгат малае, Аткүз Гали малае, Чыпчык Җиһан малае солдаттан калдылар. Аю шикелле, суксалар тимерне өзәрлек булып йөриләр. Очраган саен, рәхмәт, Фәрхи әби, рус кулыннан коткардың, диләр. Ә боларга ярамаган. Әнә Аттеш Сәлях малаеның үлүен дә миннән күрәләр. Алла сакласын, башны Себер җибәрерләр. Алла тәкъдирен, ләүхелмәхфүз язуын миннән күрәләр… Син аларга яхшылык, изгелек теләп, тукта, мөселман кеше рус-улак арасында йөрмәсен, дуңгыз итләре ашап гөнаһлы булмасын, руска хезмәт итмәсен дип йөрисең. Ә алар сиңа баз казырга торалар. Тәүбә, тәүбә. Моннан соң берсенең дә колагын да, аягын да бозмыйм. Бүсер дә ясамыйм. Аларның кырык-илле пот арышларыннан башка да, ризык бетмәгән булса, торып булыр әле.

Г ө л н у р. Мескен, бик һәйбәт егет иде. Бер елны безнең җирләрне дә уртактан эшләп биргән иде. Бер дә хыянәте булмады.

Ф ә р х и. Тәкъдирендә язылган булгач, һәйбәт-начарлыкка карамый шул. Ләүхелмәхфүздә җен зәхмәте сугып үлүе язылган булгач, котылып булмый инде.

Г ө л н у р. Шулай ук үләр микәнни?

Ф ә р х и. Хәзрәт әйтә, ата кяфер җене кагылган, ди. Аның шифасы юк, ди… Кем, Гөлнур, сүз озая сүз чыгып, онытып китмим, дим… Мине хәзрәт тагы шул Сәрвәр турында сөйләшергә дип җибәрде бит. Нишлисең инде, нигә болай кире кагып торасыз? Аллага шөкер, быел казларың да күп, гөрләтеп туй гына итәсе бит. Мәхдүм инде тәмам саргаеп кибеп беткән. Алдыгызга килгән нигъмәтне нигә кире кагасыз? Әнә хәзердән үк халык Сәрвәр турысында әллә нәрсәләр чыгара башладылар…

Гөлнур. Нәрсә, нәрсә тагы? Ятим баланы кайсы тагын рәнҗетмәкче була?..

Фәрхи. Ишеткәнең юкмы? Бик сөйлиләр. Янәсе, Сәрвәр хәзрәтнең хезмәтчесе Исмәгыйль белән...

Гөлнур. Нәрсә, ни булган? Йә Ходай, кайсысының гына теле кортлаган икән? Йә, йә, нәрсә диләр соң?

Фәрхи. Янәсе, хәзрәтнең хезмәтчесе белән Сәрвәр арасында гыйшык бар, имеш. Исмәгыйль Сәрвәр янында кунып та чыккан, ди. Мин ышанмадым. Юк, юк, булмас, дим. Сәрвәр андый кыз түгел, дим.

Гөлнур. Кунып-нитеп йөрүләре юк. Анысы ялган. Сәрвәр Исмәгыйльне сөя. Анысы чын. Әйтсәм әйтим инде, ләкин, зинһар, бер кешегә дә чыгара күрмә. Бер-ике атнадан туй ясап, Исмәгыйльне йортка кертәбез. Кешегә сөйли күрмә. Мин дә ул баланы улым шикелле күрәм. Ата-анасыз, кеше кулында үссә дә, менә дигән тәүфыйклы егет. Менә шуңа күрә казларны йолкырга ашыктык.

Фәрхи. Алай, үзең дә әйтеп бирдең инде. Тәүбә, тәүбә! Гөлнур, син үз акылыңдамы? Әллә сиңа да җен шаукымы тигәнме?.. Тәүбә, тәүбә! Гөлнур, суфига барып зәгъфран яздырып эч, юкса... Мәхдүмгә бирмичә, ата-анасыз, җиде яттан туган табылдык Исмәгыйльгә кыз бирәләр. Тәүбә, мин аңар этемне дә бирмәс идем. Йорты бармы? Кардәш-кабиләсе бармы? Туган-тумачасы бармы? Кода-кодагый дип әйтерлек кеме бар? Әстәгъфирулла!.. Барыгыз да шашкансыз, кит, кит! Моннан соң сезгә килергә Алла сакласын... Хәер инде, ана-ата тәрбиясе күрмәгән кызга зимагур килешмичә кем килешсен. Остабикә булып түрдә утырырга теләмичә, тот та бер каткан зимагурга хатын бул, имеш... *(Тора.)* Ярый, хуш, сау бул, Гөлнур, чынлап әйтәм... Күзеңнең нуры беткән... Хуш, сау бул!.. *(Чыга.)*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гөлнур ялгызы.

Гөлнур. Ярабби, үзеңә тапшырдым... Нигә генә әйттем?! Нигә әйттем?! Хәзер инде бөтен дөньяга шау киләр. Алла сакласын, араларын боза күрмәсеннәр. Томран хатыныннан сихерләтмәсәләр ярар иде. Соң Исмәгыйль шикелле арысландай егет бар чагында, ничек итеп гурбун мәхдүмгә кыз бирергә кирәк... Башым катты. Мием череде. Тукта, тәһарәт яңартып, намазымны укып алыйм

да... Чынлап та, суфидан бер-ике тәлинкә яздырып алырга кирәк булыр. Бәла аяк астыннан чыга ул. *(Чыга башлый.)*

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гөлнур, Сәрвәр, Фатыйма.

Фатыйма. Гөлнур әби, ата-бабадан калган йоланы эшләмичә ярамый, диләр. Кичкә егетләр кертмичә моннан чыгу юк, диләр. Егетләр дә кертмәгәч, каз өмәсе буламыни?..

Гөлнур. Соң, бәбкәм, ни эшлик?

Сәрвәр. Әби, кертик инде. Кертмәсәң, кызлар үпкәләрләр.

Гөлнур. Чәй җитәрлек тә бит, шикәр азрак...

Сәрвәр. Без шикәрне кызлар алдына гына куярбыз. Йә, әби бәгырем, кертикме?

Гөлнур. Ата-баба йоласы инде, кертерсез.

Фатыйма. Менә рәхмәт, Гөлнур әби, бик рәхмәт. Әйдә, кызлардан сөенчесен алыйк. *(Чыга башлыйлар.)*

Гөлнур. Сәрвәр бәбкәм, шикәрне алырсың... Мин тәһарәтемне яңартам да суфига барам. Аннан Нәбаһарга керермен. Соңга калсам, юньле утырыгыз... Ярамаган эшләрегез булмасын.

Сәрвәр. Ярый, ярый, әби.

Фатыйма. Ярый, ярый, Гөлнур әби. Мулла кызлары шикелле инсафлы булырбыз. Тыныч бул!..

Гөлнур. Сәрвәр! *(Үзенә генә.)* Исмәгыйль дә буламы?

Сәрвәр. Вакыты булса, килергә булган иде. Берәр яры йомышка җибәрмәсәләр инде.

Гөлнур. Кеше кулындагы кеше шул. Туй турында сөйләшегез. Атыгыз-чабыгыз чыкмас борын, туйны тизрәк итеп калыйк. Йөрәгем менә әллә нәрсә сизгән төсле кайнап тора.

Сәрвәр. Борчылма, әби бәгырем. Килсә әйтермен.

Гөлнур. Бәбкәм, кара әле, күзләремнең нуры бетмәгәнме?

Сәрвәр. Юк, юк, әби, бернәрсә дә юк, гадәттәгечә.

Гөлнур. Булмаса ярый, шулай да бер-ике тәлинкә яздырып алырга кирәк. *(Тәлинкәләрен алып чыгалар.)*

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

И с м ә г ы й л ь *(ялгыз, тәрәзәдән карап җырлый)*.

Һаваларда тилгән, ай, очадыр,
Урын, урын сайлый кунарга.

С ә р в ә р күренә.

Мәҗлес корып, җанкай, ай, көтәдер,
«Сөям, иркәм!» диеп кочарга.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

И с м ә г ы й л ь һәм С ә р в ә р.

С ә р в ә р.

Күптән көткән тилгән безгә килгән,
Нинди хәбәр алып килгән ул?

И с м ә г ы й л ь.

Сине сагынып яткан, ай, егеттән
Илче булып сиңа килгән ул.

Йә, җаный, каз өмәсе ничек бара? Егетләр кертәсезме? Гөлнур әби рөхсәт итәме?

С ә р в ә р. Кертәбез, кертәбез, син килмичә калма. Кара аны! Әллә хәзер үк керәсеңме? Без инде егетләргә хәбәр җибәрдек. Хәзер килеп җитәрләр. Сиңа да Мәфтуханы җибәргән идем. Күрдеңме?

И с м ә г ы й л ь. Юк. Менә нәрсә, җаный, мәхдүмнең дә киләсе килә.

С ә р в ә р. Егетләр янынамы?

И с м ә г ы й л ь. Әйе.

С ә р в ә р. Юк, юк, кызлар разый булмаслар. Аннан соң мин аңар карый да алмыйм. Бер яктан, аны кызганам. Икенче яктан, елан күзләре төсле ялтырап торган күз карашларыннан куркам.

И с м ә г ы й л ь. Ул бик үтенгән иде. Читтә генә утырырмын, ди. Аннан соң, әгәр син аны кертмәсәң, ул мине күрше авылга йомыш белән җибәрәм, ди. Керт инде үзен. Мин дә кызганам ул бичараны. Ата-анасы белән дә бер дә тынышмый; соңгы вакытларда бөтенләй шашкан төсле йөри башлады. Керт инде.

С ә р в ә р. Ярый, алайса, килсен… Кызларга, егетләргә белдермичә генә килерсез.

И с м ә г ы й л ь *(китмәкче булып)*. Ярый, булды.

С ә р в ә р. Кара әле, Исмәгыйль, әби әйтә, атна-ун көн эчендә туй итеп алыйк, ди. Йөрәгем курка, ди. Арагызны боза күрмәсеннәр, ди.

И с м ә г ы й л ь. Ярый, ярый, миңа дисә, бүген үк туй итәргә мин разый... Теләсәгез кайчан булсын. Ертык бишмәтне култык астына кыстырам да очып кына киләм. Ну, малай, дошманнарның йөрәкләре янар соң...

С ә р в ә р. Синең шулай дошманнарың да бармы?

И с м ә г ы й л ь. Әллә тагын, югын юк та, синнән көнләшүчеләр булыр инде.

С ә р в ә р. Әйдә, көнләшсеннәр. Ике ятимне көнләшүләре кызык та... Ярый, ярый, хатыннар төсле очраган җирдә такылдап йөрмә. Соңга калмагыз.

И с м ә г ы й л ь. Очып кына килербез, һуп! *(Үбә.)*

С ә р в ә р. И-и, юньсез!..

Ф а т ы й м а керә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

С ә р в ә р һәм Ф а т ы й м а.

Ф а т ы й м а *(тәрәзәгә йөгереп бара-бара)*. Кем ул? Кем белән сөйләштең? Ай наян! Эшегезне сиздем. «Утсыз төтен булмый» дигәннәр шул бабайлар. Ил авызындагы сүз дөресме әллә?

С ә р в ә р. Дөрес, Фатыйма җаным, дөрес. Бер атнадан чыбылдык тегәргә килерсең.

Ф а т ы й м а. Ә?.. Хәерче бит ул.

С ә р в ә р. Аның йөрәге бай!

Ф а т ы й м а. Йөрәге генә булмаса шул инде... Йә, ярый, теләсәгез ни эшләгез. Егетләр хәзер киләләр бит инде. Ни эшлибез? Урындыклар кертәсе иде, кая утыралар?

С ә р в ә р. Әйдә, әйдә!

Чыгалар. Бераздан к ы з л а р белән керәләр.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

С ә р в ә р, Ф а т ы й м а һәм к ы з л а р.

С ә р в ә р. Кызлар, өйне бераз җыештырып алыйк әле. *(Өй җыештырышалар.)*

Ф а т ы й м а. Кызлар, егетләрдән бусага ялы түләтәбезме?

К ы з л а р. Түләтәбез, түләтәбез!

Ф а т ы й м а. Алай булса, канатлар алып керегез!..

Б е р к ы з, чыгып, бер кочак каз канатлары күтәреп керә.

Сәрвәр, бусагада үзебез торырбыз. Бу җебегәннәрдән булмас.

С ә р в ә р. Үзең сөйләш инде. Мин сүзләрен дә хәтерләп бетерә алмыйм.

Ф а т ы й м а. Теге шулай ук башыңны катырдымыни?

С ә р в ә р. Тс-с-с!..

Ф а т ы й м а. Бетте-бетте. Кая, сөлгеләр хәзерләргә кирәк. *(Фатыйма белән Сәрвәр сөлгеләр ишәләр.)* Кансыз бул. Никадәр нык суксаң, шулкадәр егетләрнең күңеле була. Йә кызлар, һәркайсыгыз үзегезгә канатлар алыгыз. Җебеп тормагыз. Акча салмыйча канат бирмәгез.

К ы з л а р *(һәркайсы кулларына икешәр канат алалар)*. Чү, киләләр, киләләр!

Ыгы-зыгы башлана. Еракта «Каз канаты» җыры башлана.

Ф а т ы й м а. Йә кызлар, урыннарыгызда булыгыз. Әйдә, Сәрвәр. *(Ишекне ябып, тотып торалар.)*

Е г е т л ә р *(ишек янында җырлыйлар «Каз канаты» көенә)*.

Каз канаты кат-кат була, ир канаты ат була.
Җаның сөйгән яр алдында җанга рәхәтлек була.

К ы з л а р.

Каз канаты кат-кат була, кыз канаты ак була.
Бусага ялын түләгән хөрмәтле кунак була.

Е г е т л ә р *(шау-шаулап ишеккә ябырылып)*. Кая, нигә кертмисез инде? Җебегән тавыклар. Ха-ха-ха!..

Ф а т ы й м а. Ашыкмагыз, авызыгыз ашка пешәр. Янчыкларыгызны капшап, берәм-берәм керегез!..

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р һәм б е р е н ч е е г е т.

Б е р е н ч е е г е т. Әссәламегаләйкем! Вәгаләмәлләдикем, казлар, и-и, казлар, юк ла, кызлар симез булсын!

К ы з л а р. Ха-ха-ха!.. *(Сөйләшкәндә, кызларда хәят белән бергә кызык сүзләрдән көлү, куштанлану күренеп торырга тиеш.)*

Ф а т ы й м а. Сиңа, егет, кем кирәк?

Б е р е н ч е е г е т. Кара кашлы кыз кирәк.

Ф а т ы й м а. Ни эшкә соң ул кирәк?
Б е р е н ч е е г е т. Әнигә килен кирәк.
Ф а т ы й м а. Егет, сиңа ни кирәк?
Б е р е н ч е е г е т. Миңа нечкә бил кирәк.
Ф а т ы й м а. Ни эшкә соң ул кирәк?
Б е р е н ч е е г е т. Ансыз яна яшь йөрәк.
С ә р в ә р. Сиңа, егет, ни кирәк?
Б е р е н ч е е г е т. Каз мамык ястык кирәк.
С ә р в ә р. Казларыбыз мамыксыз. Кызлар йоклый ястыксыз!..
Ф а т ы й м а. Шуны да син белмәгәч, йөрмә монда вакытсыз!.. *(Ишкән сөлгеләр белән кыйныйлар.)*
Б е р е н ч е е г е т. Ай, ай, ай... *(Барысы да көлешәләр, егет аркасын уып.)* Казларыгыз кыз... кызларыгыз каз. Башларыгыз таз. Күзләрегез тоз. Үзегез котсыз. Борыныгыз курнос.
Ф а т ы й м а.
С ә р в ә р. } И-и, тозсыз!.. *(Кыйныйлар.)*
С ә р в ә р. Сиңа, егет, ни кирәк?
Б е р е н ч е е г е т. Ак каз канаты кирәк.
С ә р в ә р. Ни эшкә соң ул кирәк?
Б е р е н ч е е г е т. Очарга.
С ә р в ә р. Ни эшләргә?!
Б е р е н ч е е г е т. Матур кызлар кочарга. *(Бер кызны кочакламакчы була.)*
Ф а т ы й м а. И-и, өтек карга, буш кул салма кызларга, акчаң кайда?
Б е р е н ч е е г е т. Акча сезгә кирәксә, менә ул тулы кесә.
К ы з л а р. Канат сатам. Канат сатам, канат сатам!..
Б е р е н ч е е г е т *(бер кыз каршына барып)*. Кая ул, мин алам.
К ы з. Акчаң җитәрме соң, үзең чибәрме соң?
Б е р е н ч е е г е т. Акчам тулы өй асты, үзем албасты.
К ы з л а р. Ха-ха-ха!..

Беренче егет кызны кочакламакчы була.

Кыз. Кагылма миңа, исәр!
Б е р е н ч е е г е т. И-и, юләр.
Б е р е н ч е к ы з. Егет үзәге — мунча өрәге. *(Гомуми көлү.)*
Б е р е н ч е е г е т. Кызлар теләге — йөрәк үзәге.
Б е р е н ч е к ы з. Кайда ялың?
Б е р е н ч е е г е т. И-и, йонлы Җамалым, салам түшәгем, күктә йолдызым, суда кондызым, сазда...

Фатыйма. Алаймы? *(Кыйный.)*

Беренче егет. Бетте, бетте, мә, ал! *(Акчасын тешләп муенын суза.)*

I кыз. Нәрсә ул?

Беренче егет. Ял.

Беренче кыз. Ярый, кал.

Фатыйма. Тешләсәң — тешең сынар, үбә алсаң — эшең уңар.

Беренче егет. Юк, элек ал!

Кыз үптермичә алырга тырыша, егет үбә.

Беренче егет. Ах! Иреннәре көйдерә язды.

Кызлар. Ха-ха-ха!..

Оркестр, җыр.

Каз канаты каурый-каурый,
Сәлам язарга ярый.
Ир канаты маллар даулый,
Кыз канаты яр сайлый.

Шул арада ишектән Шәйбәк керә.

Фатыйма *(аны тотып)*. Чү, чү, бусага ялың кая? Кара аны, ял түләмичә кермәкче була.

Сәрвәр. Ярый, ярый, ул көтүләрен оста көтә. Ял түләмичә генә керсен.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм икенче егет.

Фатыйма. Сиңа, егет, ни кирәк?

Икенче егет. Атаң башы.

Фатыйма.
Сәрвәр. } Алаймы? *(Кыйныйлар.)*

Икенче егет. Чү, чү, илчегә үлем юк... Менә егетләрдән сезгә, бусага ялын алыгыз, тамагыгызга ут булып керсен. *(Итәгеннән конфетлар, чикләвекләр бирә.)*

Фатыйма. Керегез!..

Егетләр шаулашып керәләр.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм егетләр.

Егетләр. Казларыгыз симез булсын, кызлар!

Фатыйма. Казларыбыз симез, үзебез игез!..

Икенче егет. Игезлектән йөдәгән миңа килер, әнигә килен булыр. Бикә булып түрдә торыр. Кыш җеп эрләр, җәй урак урыр, яз урын җәяр, көз мунча ягар!..

Фатыйма. Каян килгән тиле бояр! Атларың юк җигәргә. Сыерларың юк саварга. Утының юк ягарга. Киемең юк кияргә. Канатың юк очарга, и-и, өтек карга!..

Кызлар. Ха-ха-ха!..

Икенче егет. Син булсаң, утыны да булыр, мунчасы да ягылыр, канаты да табылыр!..

Кызлар. Канат сатам, канат сатам, канат сатам!..

Егетләр. Мин алам, мин алам, мин алам. *(Һәрберсе бер кыз каршына баса.)*

Кызлар. Канат хакы бер алтын.

Егетләр. Үзеңдә калсын. *(Борылалар.)*

Кызлар. Чын егет булса алсын!

Егетләр *(борылып)*. Йә?

Кызлар. Егет, сиңа кем кирәк?

Егетләр. Канатлы яшь кыз кирәк.

Сәрвәр һичберәүгә канат сатмый, егетләр каршына басмый.

Кызлар. Ни эшкә?

Егетләр. Канатыңда очармын, үзең сөеп кочармын.

Кызлар. Канат хакы йөз алтын.

Егетләр. Ала алган алсын!.. *(Тешләренә акчаларын кысалар.)* Йә, ал!

Кызлар. Нәрсә ул?

Егетләр. Ял.

Кызлар. Ярый, кал.

Егетләр. Юк, элек ал!..

Чыр-чыр килеп үбешәләр, кочаклашалар.

Барысы бергә.

Каз канаты каурый-каурый,
Сәлам язарга ярый.

Кызлар.

Яшь йөрәкләр ярлар сайлый.

Барысы бергә.

Карт йөрәкләр мал даулый.
Каз канаты каурый-каурый,
Хатлар язарга ярый.
Яшь чагында уйнамасаң,
Ул аннан нигә ярый?

Кызлар.

Каз канатын кызлар сата,
Ир канатын кем сата?

Барысы бергә.
Җан теләген кире какма,
Дошманнардан сынатма.
Кызлар.
Каз канаты йомшак, дибез.
Ир канатын белмибез.
Барысы бергә.
Казлар симез булсын өчен,
Каз канатын җырлыйбыз.
Егетләр.
Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була.
Барысы бергә.
Җаның сөйгән яр алдында
Оҗмахтан артык була.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Исмәгыйль белән мәхдүм.

Исмәгыйль. Әссәламегаләйкем, казлар, кызларыгыз симез булсын.

Егетләр. Алай булсын.

Гомуми көлү.

Беренче егет. Сыерның мөгезе, казның игезе, кызның симезе яхшы була ул.

Гомуми көлү.

Фатыйма. Сиңа, егет, ни кирәк?
Исмәгыйль. Кара кашлы кыз кирәк.
Фатыйма. Ни эшкә соң ул кирәк?
Исмәгыйль. Әнигә килен кирәк.
Беренче егет. Анаң юк ич синең.

Гомуми көлү.

Фатыйма. Сиңа, егет, ни кирәк?
Исмәгыйль. Миңа нечкә бил кирәк.
Фатыйма. Ни эшкә соң ул кирәк?
Исмәгыйль. Ансыз яна яшь йөрәк.
Сәрвәр. Сиңа, егет, ни кирәк?
Исмәгыйль. Каз мамык ястык кирәк.
Сәрвәр. Казларыбыз мамыксыз, кызлар йоклый ястыксыз.

Ф а т ы й м а. Шуны да син белмәгәч, йөрмә монда вакытсыз. *(Кыйныйлар, гомуми көлү.)*

С ә р в ә р. Сиңа, егет, ни кирәк?

И с м ә г ы й л ь. Ак каз канаты кирәк.

С ә р в ә р. Ни эшкә соң ул кирәк?

И с м ә г ы й л ь. Очарга.

С ә р в ә р. Ни эшләргә?

И с м ә г ы й л ь. Матур кызлар кочарга. *(Сәрвәрне кочакламакчы була. Фатыйма арасына төшә.)*

Ф а т ы й м а. И-и, өтек карга. Буш кул салма кызларга! Акчаң кайда?

И с м ә г ы й л ь. Акча сезгә кирәксә, менә ул тулы кесә.

К ы з л а р. Канат сатам, канат сатам, канат сатам!..

И с м ә г ы й л ь. Кая ул, мин алам. *(Сәрвәр каршысына баса.)*

Б е р е н ч е е г е т. Кара, кара, кая үрмәли!..

С ә р в ә р. Акчаң җитәрме соң? Үзең чибәрме соң?

И с м ә г ы й л ь. Акчам җитәр, үзем чибәр. *(Кочакламакчы була.)*

С ә р в ә р. Кагылма миңа, исәр!.. Кая ялың?

И с м ә г ы й л ь *(акча тешләп)*. Мә, ал!

С ә р в ә р. Нәрсә ул?

И с м ә г ы й л ь. Ял.

С ә р в ә р. Ярый, кал.

И с м ә г ы й л ь. Юк, элек ал!.. *(Үбешәләр, гомуми көлешү, шау-шу.)*

Җыр һәм оркестр.

К ы з л а р.

Каз канаты йомшак һәм ак.

Е г е т л ә р.

Каз канаты сөттән ак.

Б а р ы с ы б е р г ә.

Кыйгак, кыйгак, кыйгак, кыйгак!
Без барыбыз бүген шат.

Б е р е н ч е е г е т *(читтә боегып торган Надирга)*. Мәхдүм, син ничек болай монда киләсе булдың? Ясин укыргамы әллә?

Гомуми көлү.

Н а д и р. Юк, син наданны күрергә килдем.

И к е н ч е е г е т. Тешли ул безнең мәхдүм.

Б е р е н ч е е г е т. Мулла халкында теш тә булмаса, ул нигә ярый? Бөтен авылның казларын ашап бетерер өчен кирәк бит ул аларга.

Гомуми көлү.

Н а д и р. Ә син, егет, телеңә салынма. Бездә дә ул бар, менә ул. *(Үртәп телен чыгара.)*

Гомуми көлү. Сәрвәр уңайсызланып аптырап тора.

Б е р е н ч е е г е т. Коръән укый-укый шулай үскәнме, әллә бәлеш ашапмы?..

Көләләр.

Н а д и р. Син, егет, минем белән сынашып карарга уйлыйсың, ахры. Әйдә, көчеңне сынап кара. *(Җиләнен салып ташлап.)* Сугышасың киләме? Көрәшәсеңме? Әйдә...

Е г е т л ә р. Әйдә, әйдә, Гайфулла, курыкма!

Б е р е н ч е е г е т. Кибәнең ишелүдән куркам, мәхдүм.

Н а д и р. Нәрсә, нинди кибән?! *(Калтырана башлый.)*

Б е р е н ч е е г е т. Җилкәңдәге...

Гомуми көлү.

Н а д и р. Их син, бозау... *(Егетне кысып алып, астына салып, тезе белән баса. Бөтенесе аптырап калалар.)* Син нигә минем бөкремнән көләсең?.. Ул сиңа уңайсызламый бит. Нигә көләсең?.. Икенче авыз ачасы булсаң, бугазыңны өзәрмен! *(Җибәрә.)*

И к е н ч е е г е т. И-и Гайфулла, сүздә генә икәнсең. Бәлеш корсактан, зәгыйфь кешедән җиңдереп маташасың!..

Н а д и р. Син нәрсә дисең тагы? Нигә сез мине рәнҗетәсез? Нигә рәнҗетәсез?!

И к е н ч е е г е т. Сез муллаларны рәнҗетерсең!

Н а д и р. Мин мулла түгел. Менә мин, сезнең шикелле булыр өчен, монда килдем. Минем сезнең шикелле үк буласым килә. Аңлыйсызмы, сезнең шикелле үк.

И к е н ч е е г е т. Безнең шикелле булыр өчен бөкреңне юнасы бар әле.

Егетләр көләләр.

Н а д и р. Көлмәгез миннән, көлмәгез. Юкса мин сезне... *(Пәкесен чыгара. Кизәнә.)*

Е г е т л ә р. Ярамый, ярамый, мәхдүм!..

Кызлар чиношалар.

С ә р в ә р *(барып кулыннан тотып)*. Мәхдүм, сансызланмагыз. Мәҗлеснең ямен җибәрмәгез. Егетләр, мәхдүм минем кунагым... Аны рәнҗетерлек бер генә сүз әйтсәгез дә — бәхил түгел.

Н а д и р. Рәхмәт, рәхмәт, Сәрвәр туташ. Мин куям. Мин куям... Рәхмәт, сез мине аңладыгыз... Егетләр, туташлар, сез мине үз арагыздан бүген кумагыз. Менә шунда, почмакта гына утырырмын. Әйе, почмакта гына. Сез уйнагыз, көлегез, миңа карамагыз... Мин сезгә уңайсызламам. Сәрвәр туташ, менә шул почмакта гына утырырга рөхсәт итегез. Гайфулла, Шакирҗан, килегез, килешик. Миңа рәнҗемәгез. Минем ачуым чыкты. Сез әйтмәсәгез дә, бөкрелегемне дә, шәйтанга охшаган кыяфәтемне дә беләм бит. Менә, кызлар, сезгә бүләк. Менә бусага ялы... Миңа каз канаты кирәк түгел... Миңа аны сатучы булмавын белеп килдем. Уйнагыз, егетләр. Җырлагыз, биегез! Мин сезгә уңайсызламам. *(Почмакка утыра.)*

К ы з л а р. Мәхдүм, бүләкне бик күп алгансың... Рәхмәт.

С ә р в ә р. Мәхдүм, сез инде безнең шаяруларны гаепләмәгез!..

Н а д и р. Юк, юк, һич, уйнагыз, мине бөтенләй юк дип уйлагыз. Әйе, бөтенләй юк. Менә шулай. *(Утыра.)*

Б е р е н ч е  е г е т. Мәхдүм, без инде надан кеше, тупас телле булабыз. Мин бит болай уйнап кына, кызык өчен генә синнән көлдем. Рәнҗемә... Әйдә, безнең белән бергә уйна... Егетләр, мәхдүм уйнасын бит?

Б а р ы с ы  б е р г ә. Уйнасын, уйнасын!

Н а д и р. Рәхмәт, рәхмәт... Йә, әйдәгез, егетләр, биеп, җырлап алыгыз әле. Безнең Исмәгыйль бик нык баса гына!.. Әйдә, Исмәгыйль!..

Б а р ы с ы  б е р г ә. Әйдә, чык, чык, Исмәгыйль!..

Оркестр «Әтнә» көен уйный. Бию башлана, иң элек Исмәгыйль белән Сәрвәр бииләр. Башкалар да бии. Иң ахырдан мәхдүм бии.

Б е р е н ч е  е г е т. Мәхдүм, әйдә, бас әле, булмаса. Намаз укыган аяклар сыгылучан була ул.

Б а р ы с ы  б е р г ә. Әйдә, мәхдүм, әйдә, бас!..

Надир бии башлый. Ул биегәндә, с т а р о с т а, п и с а р ь һәм п ү н ә т ә й килеп керәләр. Кызлар йөзләрен яшерәләр. Аптырашып калалар. Сәрвәр Исмәгыйль янына килеп баса.

## УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р, с т а р о с т а, п и с а р ь, п ү н ә т ә й.

С т а р о с т а. Бу ни эш, мәхдүм?.. Килешми, килешми. Килешә торган эш түгел! Егетләр, туктагыз! Йомыш бар. Писарь, кәгазьгә карап кычкыра башла!

П и с а р ь. Гайфулла Шәмсетдинов…

С т а р о с т а. Гайфулла энем.

Б е р е н ч е  е г е т. Нәрсә?

С т а р о с т а. Бас шунда. Егетләр, исемнәрегез чыкканнар менә шунда килеп басыгыз!

П и с а р ь. Сирай Нәҗметдинов.

Ө ч е н ч е  е г е т. Монда.

П и с а р ь. Гатаулла Фәсхетдинов.

С т а р о с т а. Монда юкмы?

Е г е т л ә р. Юк.

П и с а р ь. Исхак Курамшин, Касыйм Галиев, Мифтах Алмаев, Исмәгыйль Әхмәдуллин, Мөбарәкша Салихов…

С т а р о с т а. Башкалар монда күренми. Егетләр, хәзер каравыл өенә әйдәгез. Иртәгә калага барабыз.

Н а д и р. Саттар агай!

С т а р о с т а. Син нишләп монда, мәхдүм? Килешми, килешми…

Н а д и р. Юк ла, болай гына. Нәрсәгә бу егетләрне калага алып барасыз?

С т а р о с т а. Чакырганнар.

Н а д и р. Приёмга иртә бит әле.

С т а р о с т а. Патшадан үрәдниккә хәбәр килгән. Киләсе елга караласыларны хәзер үк наборга чакыралар, ди. Ярман патшасы безнең патшага каршы сугыш ачкан.

Б а р ы с ы  б е р г ә. Сугыш!!!

Катып калалар, Исмәгыйль Сәрвәргә ташлана.

С т а р о с т а. Әйе, сугыш.

И с м ә г ы й л ь. Менә ул сүнгән йолдызлар каян килеп чыкты…

Сәрвәр катып кала.

С т а р о с т а. Йә, әйдәгез, егетләр!

Кызлар елашалар, е г е т л ә р чыгып китәләр.

Н а д и р *(шатланып)*. Сугыш, әһә, сугыш!.. Мин сугышка бармыйм, мин калам. Мин зәгыйфь, мин бөкре. Мин гурбун!..

Сикерә, шатлана. Сәрвәр урынында катып кала. Урамда егетләр җырлап китәләр.

Каз канаты мамыксыз,
Ир канаты бәхетсез.

Илдә ризык калган булса,
Исәнлектә кайтырбыз!..

Сәрвәр *(авыша-авыша тәрәзәгә барып)*. Исмәгыйль, Исмәгыйль! *(Каты елый.)*

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук өй.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гөлнур һәм Сәрвәр тәрәзәдән карап елап торалар. Урамда егетләр җырлыйлар. «Каз канаты» көенә.

Урамда егетләр.

Без китәбез бу илдән,
Аерылып нечкә билдән.
Безнең хәлне сорашырсыз
Кыйбладан искән җилдән.
Сандугачлар чут-чут сайрый,
Ярманнар[1] кылыч кайрый.
Сугышка киткән газиз баш
Туган илләргә кайтмый.

Гөлнур. И мескеннәр, суелырга барган хайваннар төсле тилмерәләр. Берни итәр хәл юк шул.

Сәрвәр. Әби, әнә Исмәгыйль егетләрдән аерылды. Монда килә.

Гөлнур. Килсен, бәбкәм, килсен. Икегез дә бәхетсез балалар икәнсез. Мин чыгыйм. Сөйләшеп калыгыз!.. Бәлки, артык күрешә дә алмассыз инде. Тәкъдир шулай, күрәсең, балакай, тәкъдир. *(Чыга.)*

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль һәм Сәрвәр.

Исмәгыйль *(керер, Сәрвәрне кочаклап)*.

Киек казның ак канатын
Кемнәр барып имгәткән?
Чит илләрдә җан биргәндә,
Кем итәр икән ярдәм?

---

[1] Ярманнар – германнар.

С ә р в ә р.
Кыйгак-кыйгак кыр казлары
Оча ерак илләрдән.
Кыр казлары үткән саен
Хәбәр көтәрмен синнән.
И с м ә г ы й л ь.
Сандугачлар чут-чут сайрый,
Ярманнар кылыч кайрый.
Сугышка киткән газиз баш
Туган илләргә кайтмый.
С ә р в ә р.
Саф-саф булып кыр казлары
Үтәр, язлар җиткәндә.
Кемнәр сиңа ясин укыр,
Газиз җаның чыкканда?.. *(Елый.)*
И с м ә г ы й л ь.
Елама, җаным, елама, Сәрвәр,
Елап уңгаймый эшләр.
Мин ятимне син сагынсаң,
Ешрак сәламең җибәр.
С ә р в ә р.
Көзләр үтеп, язлар җитәр,
Бакчада былбыл сайрар.
Кылыч чапкан җәрәхәтнең
Каннарын кемнәр юар?
И с м ә г ы й л ь.
Рушан йолдыз яктырамы
Айның ундүрт төнендә?
Сагынганда айга кара,
Син булырсың күңелемдә.
С ә р в ә р.
Зөһрә йолдызның нурларын
Каплар туплар төтене.
Синең өчен теләк теләп
Еlармын көне-төне.

Кочагына ташлана.

И с м ә г ы й л ь.
Хуш, бәхил бул, җанкисәгем,
Инде соңгы теләгем:
Үлгән хәбәрем ишетсәң,
Атнакич укы хәтем...

Кочаклашып үбешәләр, елашалар.

Сәрвәр. Юк, юк, җаным, сине җибәрмим. Син кайтмассың. Син үләрсең, сине үтерерләр. Мин, мин синсез нишләрмен? Барма. Барма, кач, идән астына, ындырга, кибән астына кач!

Исмәгыйль. Ярамый, ярамый, җаным. Без күрәсен барыбер башка күрмәс. Шулай язган, күрәсең. Әҗәл җитмәгән булса, бәлки, кайтырмын да.

Сәрвәр. Юк, кайтмассың. Кайтмассың... Безнең генә бәхетсезлегебезгә каршы явыз ярман сугыш ачкан икән. Аптырадым. Башым катты, йөрәкләрем кысыла. Фәрхи әби дә килми бит, ичмасам.

Исмәгыйль. Фәрхи әби ни эшкә?..

Сәрвәр. Дару китермәкче иде. Бәлки, шифасы булып каладан кире кайтыр идең.

Исмәгыйль. Кая инде безгә дарулану... Аны алырга акча кирәк бит.

Сәрвәр. Анысыннан эш тормас иде әле. Бөтен күлмәкләремне, сөлгеләремне — барысын бирер идем. Тик китерсен генә иде.

Исмәгыйль. Кирәк түгел, Сәрвәр. Гомер буена җыйган күлмәк, сөлгеләреңнең рәхәтен үзең күр. Минем инде тәкъдир шулай, күрәсең.

Сәрвәр. Син булмагач, миңа алар кәфенлеккәме?.. Син булмагач, миңа ак көн булыр дип уйлыйсыңмы? Баш сау булса, күлмәге дә, сөлгесе дә табылыр әле. Китерсен генә иде...

Урамда егетләр җырлый.

Исмәгыйль. Ярый, җаным, хәзергә хуш. Егетләр янына чыкмыйча ярамый.

Сәрвәр. Бәхилләшергә иртәрәк кил. Фәрхи әби даруын юнәтә алмасмы? Әйдә, мин дә чыгам. Фәрхи әбине күрергә кирәк.

Чыгалар, артта егетләр җырлый.

Егетләр.

Без китәбез бу илдән,
Аерылып нечкә билдән.
Безнең хәлне сорашырсыз
Кыйбладан искән җилдән.
Сандугачлар чут-чут сайрый,
Ярманнар кылыч кайрый.
Сугышка киткән газиз баш
Туган илләргә кайтмый.

Бөтен җыр ике мәртәбә җырлана. Г ө л н у р кереп елап тора. Яңадан чыгып китә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

С ә р в ә р һәм Ф ә р х и ә б и.

С ә р в ә р. Фәрхи әби, анам бул. Үтенечемне кире какма. Ни сорасаң, шуны бирәм. Даруыңны бир. Бәлки, шифасы булыр.

Ф ә р х и. Юк, балакай, булмый... Аны алданрак әйтү кирәк иде. Ышандырган кешеләремә дә җитми. Ул кое суы түгел бит. *(Чыга башлый.)*

С ә р в ә р. Фәрхи әби, җаным. Аяк астыңда туфрак булыйм. Дарула Исмәгыйльне, газиз башы әрәм булмасын. Гомергә онытмас идек.

Ф ә р х и. Чү, балакай, Сәрвәр, мине юлымнан туктатма. Елда бер килә торган урак өсте бит бу, дарулап сәдакаларын аласы кешеләрем анда тилмереп мине көтәләр. Җибәр, балакай, урак өсте бер килә ул.

С ә р в ә р. Фәрхи әби, йөрәк маем, аяк астыңда туфрак булыйм. Дарула Исмәгыйльне!

Ф ә р х и. Менә, кызым, картларны тыңларга кирәк. Мәхдүмгә чыккан булсаң, җаның тыныч, күңелең шат булыр иде. Ярман безнең авылга килгәндә дә, аны сугышка алмаячаклар. Хәзерге заманда шундый ир — үзе бәхет. Үзе хәзинә.

С ә р в ә р. Үткәннәрне оныт, Фәрхи әби... Мин Исмәгыйльдән башка барыбер тора алмас идем. Үткәннәрне онытып, бүген изгелегеңнән калдырма безне.

Ф ә р х и. Кара әле, Сәрвәр, бирсәм бирермен дә — бик кыйммәт бит. Синнән файда итүем түгел.

С ә р в ә р. Күпме теләсәң, шулкадәр ал. Шифасы гына булсын.

Ф ә р х и. Шифасы була инде... Үткән елны дүрт авылдан унбиш егетне калдырдым. Менә хәзер дә унлап егет көтеп тора... Кеше ризыгына кереп булса да бирәм. Бәясе кырык пот арыш булыр.

С ә р в ә р. Безнең арышыбыз юк. Менә туйга дигән күлмәкләрем. *(Сандыкны ачып.)* Мә, ал, менә сөлгеләрем, теләгәнчә ал!.. Шифасы гына булсын.

Фәрхи, күлмәкләр, сөлгеләрне сайлап алып, ашъяулыгына төрә.

Ф ә р х и. Ярый инде. Сүзеңне кире какмыйм. Ике күлмәк, унбиш баш сөлге. Бер ашъяулык алдым.

С ә р в ә р. Ал, ал, теләсәң, тагын ал.

Ф ә р х и. Ярый, тагын алыйм берәр сөлге, алайса, күбрәк бирермен. *(Сөлгеләр ала.)* Тәрәзә фәрдәңне төшер... *(Кесәсеннән бер шешә чыгарып.)* Үземнең даруларга вакытым юк. Унлап егет анда көтеп тора. Үзеңә генә өйрәтеп калдырам. Исмәгыйльне менә шунда ян белән яткыр. Уң колагы аста булсын. Каз канаты белән сул колагын арчып ал, шуннан соң менә шушы даруны колагына сал да менә монысын аның өстенә сал... Башын селекмичә торсын. Башта авыртыр, чыдасын... Шуннан соң колагы тишелеп ага башлар. Яисә авызы, күзе кыйшаеп калыр... Бисмилла әйтеп эшлә. Төшендеңме? Кешегә әйтәсе булма!

С ә р в ә р. Алла сакласын. Әйтәмме соң...

Ф ә р х и. Әгәр кеше белсә, сиңа да, миңа да, Исмәгыйльгә дә Себер булачак. Ишетсен колагың... Йә, кыямәт көнне дуңгыз булып кубыйм, кешегә әйтмәм, диген!..

С ә р в ә р. Валлаһи, таллаһи, кешегә әйтмәм.

Ф ә р х и. Кая, шифасы булсын, утыр, дога кылыйк... Аллаһы әкбәр. Бу — даруның сәдакасы гына; шифасы булып, Исмәгыйль кире кайтса, тагын түләрсез.

С ә р в ә р. Анысыннан эш калмас. Бик рәхмәт инде, Фәрхи әби. Даруларга үзеңнең вакытың юкмыни?

Ф ә р х и. Әйтәм лә бит. Урак өсте... Сау бул... Шифасы булсын! *(Чыга.)*

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

С ә р в ә р, Г ө л н у р.

Г ө л н у р. Нәрсә, бәбкәм?

С ә р в ә р. Әби, кеше-фәлән килсә кертмә, яме! Исмәгыйльнең колагына дару салабыз.

Г ө л н у р. Даруын кайдан алдыгыз?

С ә р в ә р. И теге... Әйтмәскә ант иттем, әбкәм бәгырем.

Г ө л н у р. Ярый, ярый, антыңны бозма. Илаһи, шифасы гына булсын инде. *(Сәрвәр даруны сандыкка сала.)* Бәбкәм, туйга дигән күлмәкләрең кая?!

С ә р в ә р. Бирдем, даруга бирдем, әбкәм җаным.

Г ө л н у р. Ярый, ярый. Баш сау булса, мал табылыр... Шифасы гына булсын инде.

С ә р в ә р. Әби, мин хәзер Исмәгыйльне алып киләм. Кем генә килсә дә, син өйгә кертмә инде.

Г ө л н у р. Ярый, балакай. Кертмәм.

Сәрвәр чыга. Урамда егетләр җырлый.

Егетләр.

Каз канаты каурый-каурый,
Сәлам язарга ярый.
Газиз башларны кисәргә
Германнар кылыч кайрый.
Каз канатын кызлар сата,
Ир канатын кем сата?
Ир канатын патша сата,
Туган илне елата.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гөлнур һәм Надир мәхдүм.

Надир. Исәнме, Гөлнур әби?

Гөлнур *(каушап)*. Мәхдүм, синмени?..

Надир. Исмәгыйль кая?.. Әллә Сәрвәр туташ та өйдә юкмы?

Гөлнур. Юк, өйдә... И, юк ла, өйдә юк иде шул...

Надир. Тиз кайтырмы соң?

Гөлнур. Юк, тиз кайтмас. Бүген бөтенләй кайтмас.

Надир. Кая алай китәсе булды?

Гөлнур. И-и... Теге нигә... Ничек әле... аты коргыры... Теге ни бар бит әле...

Надир. Инешкә суга төштеме әллә?

Гөлнур. Әйе, әйе, инешкә төште. *(Тәрәзәгә карана.)* Кем, мәхдүм, хәзрәткә сәдакам бар иде... Үзем бара алмадым, тиз генә шуны хәзрәткә илтеп тапшырсана. *(Акча бирә.)* Нәзер сәдакам иде... Кояш баеганчы бирәсе иде. Менә монысы үзеңә булсын, дога кыл. Бу кара тавык йомыркасы. *(Йомырка бирә.)*

Надир *(йомырканы алып өстәлгә куя)*. Әби, Исмәгыйль кайтса, безгә кереп чыксын әле. Әти әйтә, йомышым бар иде, ди.

Гөлнур. Ярый, ярый, барыр. Кайткач та әйтермен.

Надир. Ул кайтырмы соң?

Гөлнур. Сәрвәр белән хәзер кайтырга тиеш... Ә, юк, үзе генә кайтам, диде. Ә-ә, хәзер, әби, кайтам, диде.

Надир. Кайтса, безгә килсен! *(Чыга.)*

Гөлнур. Ярабби, җилкәмнән тау төшкән төсле булды... Исмәгыйльгә дип хәзерләгән сәдакамны алып китте бит. *(Тәрәзәгә карый.)* Әнә үзләре дә килә. Яхшы әле, озаттым үзен. Кеше кертмәскә кирәк. *(Чыга.)*

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль, Сәрвәр.

Сәрвәр. Әйдә, әйдә, ишекне яп! *(Сандыктан даруларны чыгарып.)* Менә шуны хәзер колагыңа салырга кирәк. Менә күр дә тор, каладан кире кайтарырлар үзеңне.

Исмәгыйль. Соң, бу үтермәсме?

Сәрвәр. Юк, үтерми... Шуны колакка салып, бик күп кеше калган.

Исмәгыйль. Каян алдың?

Сәрвәр. Соңыннан, соңыннан әйтермен. Вакыт уздырырга ярамый. Әйдә, менә шунда ят. *(Тәрәзә пәрдәсен кора.)* Йә, әйдә инде, җаным!..

Исмәгыйль. Әллә нишләп күңелем бер дә тартмый бит.

Сәрвәр. Соң, шулай итеп, мине гомергә елатырга уйлыйсыңмы? Мин бит синнән башка бер көн дә тора алмам... Бер киткәч, син анда, мин монда гүр иясе булырбыз... Чарасын күрергә кирәк. Әнә халык шулай колак бозып кала бит.

Исмәгыйль. Кем салыр аны? *(Даруны карый.)*

Сәрвәр. Үзем, үзем, бәгырем. Ни эшләргә икәнен беләм. Менә алдан каз канаты белән колагыңны арчырга кирәк. Шуннан соң менә монысын колагыңа салып, аның өстенә монысын салырга... Бераз авыртуы булыр инде булуын. Анысына чыдарсың инде, җаным.

Исмәгыйль. Ярый, тапшырдык... Алай-болай була калса бәхил бул.

Сәрвәр. Бернәрсә дә булмас. Бөтен ил эшли бит.

Исмәгыйль. Булса да, үкенеч юк. Анда барып та барыбер. *(Ята.)* Әйдә, үзеңә тапшырдык.

Сәрвәр *(канат белән колагын арчып)*. Шифасы гына булсын инде. Бисмиллаһ-иррахман-иррахим. *(Дару сала.)* Селкенмә, селкенмә, тик ят!..

Исмәгыйль. Аһ, аһ!.. Үтерә, яндыра!..

Сәрвәр. Чыда, чыда, бәгырем, икенчесен салам. *(Сала.)*

Исмәгыйль. Аһ, аһ! Үтерә, яндыра!.. *(Сөлек төсле иелә, сыгыла.)*

Сәрвәр. Бәгырем, чыда, чыда, бәгырем!.. *(Үзе кызганып калтыранып елый.)*

Исмәгыйль. Аһ, үтерә, күз алларым караңгылана! Аһ, аһ, аһ!.. *(Сәке буйлап тәгәри.)*

С ә р в ә р *(елап)*. Чыда, бәгырем, чыда!..

И с м ә г ы й л ь *(сикереп торып)*. Юк, юк! Чыдар хәлем юк! Үләм! Үләм, үләм!.. Хуш, Сәрвәр, хуш, бәхил бул! Үләм... *(Идән буйлап тәгәри.)* Аһ... Аһ!.. Бәхил бул!.. Бәхил бул!.. Безгә кавышу насыйп... булмаган икән... *(Сәкегә ята.)* Аһ!.. Аһ!.. Үләм! Яндыра!.. Яндыра!.. Сәрвәр, Сәрвәр, кил, кил... Бәхил бул... Бәхил бул... Үләм... Үләм... *(Зәгыйфьләнә. Сәрвәр аның күкрәгенә ятып елый. Исмәгыйль ыңгыраша.)* Аһ, аһ!.. Яндыра... Уф... Уф!.. *(Бәрелә, сугыла, кычкыра, ыңгыраша. Йөзләрен, күзләрен, авызларын җыера.)*

С ә р в ә р *(кинәт елавыннан туктап, Исмәгыйльне капшап)*. Аһ!.. Аһ!.. Үлде... Исмәгыйль... Исмәгыйль! Бәгырем! Бер генә... Бер генә сүз эндәш!.. Аһ!.. Үлде... Мин үтердем... Мин, мин...

Шулвакыт Надир тәрәзәдән карый.

Аһ!.. Аһ!.. Мин җанымнан артык күргән сөйгән ярымны үз кулым белән үтердем!.. Үз кулым белән... Мин үтердем. Мин үтердем!.. Ярдәм, ярдәм итегез. *(Ишеккә таба йөгерә.)*

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Н а д и р, С ә р в ә р һәм И с м ә г ы й л ь.

Н а д и р *(ишеккә каршы торып, Сәрвәрне кулларыннан тотып)*. Син үз-үзеңне харап итәсең!..

С ә р в ә р. Җибәр, җибәр!.. Мин үтердем, мин!.. Сөйгән ярымны үтердем. *(Исмәгыйльгә ташлана.)* Исмәгыйль, Исмәгыйль!.. Юк, юк... Син үлмәгән!.. Син тере... Исмәгыйль!.. Эндәш!.. Юк, юк, ул үлгән!..

Бик каты елап, һушыннан тая язып сулкылдый, ыңгыраша башлый. Шулвакыт урамда егетләр җырлаган тавыш ишетелә. Надир баскан урынында катып Сәрвәргә карап тора.

Е г е т л ә р.

Каз канаты каурый каләм,
Кем генә язар сәлам?
Миннән калганнар сау булсын,
Мин инде илгә кайтмам!

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук өй.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гөлнур һәм Фәрхи.

Гөлнур *(елап утыра)*. Суфидан тәлинкәләр дә яздырдым, курку да койдырдым. Ишан хәзрәттән дә өшкерттем. Шифасы булмады. Һаман шул бер килеш. Бигрәк тә яратышкан булганнар икән. Ике чын сөйгән кавыша алмый, диләр иде. Чындыр, ахрысы. *(Елый.)*

Фәрхи. Кара әле, тәрьяк ашатырга кирәк. Бик файдалы нәрсә. Яисә крипки вудки дигән нәрсәне суга салып эчерергә кирәк. Крипки вудки исеннән җеннәр кача, ди. Аннан соң идән астына ябып ашатмыйча, эчертмичә җиде көн, җиде төн тотарга кирәк. Җен зәхмәте уразадан курка, ди.

Гөлнур. Башым катты инде... Ашау-эчүенең дә бер дә рәте юк.

Фәрхи. Ашатмаска кирәк. Барыбер, ашаса да, җен корсагына китә бит. Кызу мунча ташына бастырып чаптырмадыгызмы?..

Гөлнур. Аның инде күргән газаплары да җитәрлек.

Фәрхи. Җенен качырырга кирәк. Кыйнаганыгыз бармы соң?

Гөлнур. Син ни сөйлисең? Кыйнарга ничек кул күтәрелсен?!

Фәрхи. Соң бит җеннәрен качырырга кирәк ләбаса, ахыры.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Җиһанша.

Җиһанша *(урамнан тәрәзә аркылы сөйләшә)*. Саумы, балдыз, ни эшләр бетерәсез, кодачаның хәле ничек?!

Гөлнур. Әйдә, җизни, өйгә кер, өйгә рәхим ит!

Җиһанша. Рәхмәт, монда да ярый, кунак булып килмәдем әле. Кодачаның хәле ничек, дим?!

Гөлнур. Беркөе, җизни, беркөе.

Фәрхи. Җиһанша, мин әйтәм, җеннәрен качырырга кирәк, дим, кыйнарга кирәк, дим.

Җ и һ а н ш а. Суярга кирәкмиме тагын? Ичмасам, син йөрмә шунда өстерәлеп. Сихереңдер әле бу да. Йөрмә, дим, монда, йөрмә, дим! Чынлап әйтәм сиңа, йөрмә, дим.

Ф ә р х и. Тукта әле, Җиһанша, сиңа ни булды? Әллә син дә...

Җ и һ а н ш а. Әй, куй әле, мин синең белән талашырга килмәдем. Балдыз, урак өсте җитә бит, шуңарчы кодача терелмәсә, ни кылырбыз, дим? Арышыңны кем урыр? Кешедән урдырсаң, ун поттан ким алмаслар. Сөргән, чәчкән өчен, миңа да бирәсең булыр. Минем өйдә дә артык кул юк. Ни эшләрбез икән, дим. Ай, уңган кыз балага күз тия шул. Уракка аңарга каршы чыгучы тирә-якта юк иде бит. Күз тия шул, күз тия. Уңган кулга күз тия, ди шул.

Г ө л н у р. Әйтмә инде, җизни, әйтмә инде. Улларыңнан хат-хәбәр юкмы?

Җ и һ а н ш а. Юк, балдыз, юк, юк шул. Сезнең имананы Мөхәммәтҗаным сөреп, чәчеп калдырган иде бит. Ә хәзер кая... Көлтәсен кертү насыйп булмаслыгы тәкъдиренә язылган, күрәсең, бер эш тә эшләп булмый шул... *(Пауза.)* Балдыз, каты сабаныңны бу юлы мин сөрә алмыйм бит, бөтен йортка бала-чага арасында бер башым калдым. Үземнекен ничек башкарырмын икән дип аптырап торам, һаман шул бер сүз инде. Уҗым чәчүеңне кемнән генә эшләтерсең икән, дим? Кеше тапмадыңмы әле?

Г ө л н у р. Чулак Шәрәфи уртактан сөреп уҗымны чәчәргә булды булуын да, Сәрвәр терелми бит.

Җ и һ а н ш а. Орлык та уртакмы?

Г ө л н у р. Орлык та уртак. Тик Сәрвәр ике имана арышын бу елдан ук урырга тиеш. Киләсе елга да урырга... Сәрвәр авырый. Ни эшләргә дә белмим. Аптырадым инде, җизни. Мием череде. Сәрвәр бәбкәм эшкә ярамагач, Шәрәфи дә чәчмәсә, капчык тагып илгә чыгарга гына кала. *(Елый.)*

Ф ә р х и. Гөлнур, бер дә кайгырма. Сәрвәрнең җен-нәре Чулак Шәрәфи кырын гына түгел, ярты авыл кырын урып ташларлар әле, җеннәр бит алар...

Җ и һ а н ш а. Куй әле син, үгез сабан сөргәндә, бака бугаз киерә, ди Мөхәммәтҗан карт. Син дә шул...

Читтән берәү сәлам бирә.

Ә, вәгаләйкемәссәлам, Ибраһим! Кайдан кайтыш? Ярый, балдыз, хәзергә сау бул, барып чык. Каты сабан җитте, уйлашырга кирәк. Барып чык әле. *(Китә башлый.)*

Гаепләмә инде, минем кулдан килми шул. Үз хәлем хәл. Әллә кемнәр файдасы өчен генә балалар сугыш кырларында газап чигәләр... Кемгә кирәк соң бу сугыш, кемгә кирәк?.. Ярый, хуш, балдыз. *(Китә.)*

Гөлнур. Ярый, Алла боерса, барырмын, үзең дә, җизни, ташлама инде. Алла каргаган сәгатьләр безгә дә җитте, күрәсең.

Фәрхи. Алла шул, Алла. Бик дөрес әйтәсең, Гөлнур. Алла ташламаса, бүре ашамас, дигәннәр. Аллага сыгынырга кирәк, Аллага. Әле шуны әйтәм, Гөлнур, җеннәр алар, бер иярләнсәләр...

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Фатыйма.

Фатыйма. Саумы, Гөлнур әби?

Гөлнур. Әйдә, Фатыйма, әйдә, бәбкәм...

Фатыйма. Сәрвәр кая?!

Гөлнур. Бәбкәләремне ашатырга чыккан идем. Шул арада әллә кая чыгып киткән. Коега-фәләнгә төшеп үлмәсә ярар иде.

Фатыйма. Нигә яхшылап сакламыйсыз? Хәле яхшырак түгелме?

Гөлнур. Һаман шул беркөе.

Фәрхи. Кара, кем, Гөлнур, ат селәгәе эчерергә кирәк. Ат исеннән җен кача, ди.

Фатыйма. Тагы ни калмаган, берсенең башына җиттең инде, монысын да үтермәкче буласыңмы? Убырлы карчык!

Фәрхи. Ай-һай, кызый, бик иртә сиңа тел чыккан. Кемне мин үтердем? Йә, әйт, кемне?.. Старшинага әйтеп арка тиреләреңне тунатырмын.

Фатыйма. Күп сөйләшмә, ичмасам, шәйтан карчык! Никадәр егетләрнең газиз башларын ашадың. Комсыз аждаһа.

Фәрхи. Кемнең башын ашадым, ә? Кемне мин үтердем? Әллә синең сөйгән уйнашчыңнымы?

Фатыйма. Минһаҗ Гайфулласын кем үтерде? Сәләхине кем үтерде? Исмәгыйльне кем үтерде?

Фәрхи. Әҗәлләре җитеп үлделәр. Белмәсәң, хәзрәттән барып сора.

Фатыйма. Барыгыз да сез бер чыбык белән сөрелгән.

Ф ә р х и. Хәзрәткә дә тел тидерә торган булгач сөйләшеп тә торасы юк инде... Марҗа булуың җиткән икән. Әллә күрше авыл мөгаллимәсеннән шундый һөнәрләр өйрәндеңме? И-и, яхшыдан яман туган нәрсә. Юньсез! Картларның фатихасын алу урынына рәнҗетеп ята.

Ф а т ы й м а. Фатиха дигән була тагы... Писарьлар белән аракы эчеп йөргән шәйтан карчыкларының фатихасы җитә торган булса, иртәгә үк кыямәт булыр иде.

Ф ә р х и. Кыямәт тә, ахырзаман да булыр... Әллә бу сугышларны тикмәгә дип торасыңмы?.. Барысы да менә сезнең шикелле урам этләренең гөнаһ шомлыгы!..

Ф а т ы й м а. Тукта, убырлы карчык!.. Юкса мин сине иңсәләп моннан чыгарырмын.

Г ө л н у р. Фатыйма бәбкәм, алай ярамый.

Ф ә р х и. Үз өеңә барсам куарсың, кеше өендә кабарынма!

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р һәм Н а д и р.

Н а д и р. Сәрвәр йоклыймы әллә?

Г ө л н у р. Юк, мәхдүм, качып чыгып киткән.

Ф ә р х и. Мәхдүм, Сәрвәргә тәрьяк ашатырга кирәк. Тәрьяк исеннән җеннәр кача, ди.

Н а д и р. Чык моннан, шәйтан карчык!.. Инде Сәрвәр башын ашарга йөрисеңме? Чык, дим, юкса... *(Өстенә бара.)*

Ф ә р х и. Чү, чү, мәхдүм. Әллә син дә җенләндеңме?.. Бу ни бу, боларның барысына да җен шаукымы кагылган. Тәүбә... тәүбә... Суфидан тәлинкә яздырып эч!..

Н а д и р. Чык, дим!.. Мәлгунь! *(Җилкәсеннән тотып чыгарып җибәрә.)*

Ф ә р х и *(чыгып барганда)*. Тәүбә, тәүбә, чынлап та саташкан, ахры. Җибәр, җибәр, дим, гурбун шәйтан! Җибәр, бөкре шәйтан!

Н а д и р. Ә шулаймы? Гурбун шәйтанмы?.. Менә сиңа, дәллял[1] карчык! Менә сиңа!.. *(Җиргә егып буа башлый, Фәрхи гырылдый.)*

Ф а т ы й м а. Чү, мәхдүм, нишлисең?

Г ө л н у р. Үтерәсең бит *(Аералар)*.

Ф а т ы й м а. Тынычланыгыз, мәхдүм... Шакшыга тисәң, исе чыга, ди.

---

[1] Д ә л л я л – арадашлык итүче, маклер.

Ф ә р х и. Менә кешегә ит яхшылык. Менә бөкре шәйтанга Сәрвәрне димләп...

Надир, җилкәсеннән тотып, ишектән этеп чыгара.

Каравыл, каравыл! Үтерәләр, үтерәләр! *(Ава.)*

Г ө л н у р. Мәхдүм, ярамый, ярамый, бәбкәм!..

Ф а т ы й м а. Утырыгыз, тынычланыгыз... *(Утырта.)* Ул убырлы карчыкның сүзләренә карамагыз. Явыз карчык ул.

Ф ә р х и *(тәрәзәдән)*. Яхшылыкка каршы син шулай җавап кайтарасыңмы? Гурбун шәйтан! Мин, юләр карчык, шул шәйтан кыяфәтле, җен алмаштырган нәрсәгә яучы булып йөрдем. Гурбун тәре. Мин сиңа кайтарырмын әле. Мин сиңа күрсәтермен әле!.. *(Тәрәзә яңагын кыйный.)* Шул кыяфәтең белән өйләнергә йөрисең тагын! Гурбун эт!

Ф а т ы й м а. Убырлы карчык, яхшылыкта китәсеңме?

Ф ә р х и. Кара әле!.. Аны яклаган була тагы... Бар, үзенә кияүгә чык. Гурбунын сыйпап тик торырсың. Һи-һи-һи. Маймыл авызы төсле авызыннан үбәрсең!.. Һи-һи-һи.

Ф а т ы й м а. Кит, дим, убырлы карчык!..

Ф ә р х и. Җикеренмә миңа, себерке!.. Инде шул гурбунга калдыңмы?

Н а д и р *(Фәрхи сөйләгәндә көчкә-көчкә генә чыдап, калтыранып тора. Соңыннан пәкесен чыгарып)*. Мин сине этне бугазлаган кебек бугазламасам... *(Тәрәзәгә ташлана. Фатыйма, Гөлнур аны тоталар.)* Җибәрегез, җибәрегез, мин аны!..

Ф ә р х и. Каравыл! *(Урамда.)* Каравыл, суялар, суялар, суялар, каравыл!..

Ф а т ы й м а *(мәхдүмне утыртып)*. Тынычланыгыз, тынычланыгыз! Гөлнур әби, салкын су китер!.. *(Гөлнур чыга.)* Шул хәшәрәтнең сүзләренә карамагыз. Котырган ул!..

Г ө л н у р *(керә)*. Менә, мәхдүм, су эч! Бисмиллаһ-иррахман-иррахим...

Н а д и р *(су эчә)*. Рәхмәт, Гөлнур әби. *(Бүлмә буйлап йөри.)* Әби, Сәрвәрнең хәле һаман беркөе дисеңме?

Г ө л н у р. Һаман шулай... Алга бармый. Үләр инде, ахры, мескенем. Бигрәк бәхетсез бала икән. Ата-ана мәхәббәтен күрә алмый үсте. Сөйгәненнән дә вакытсыз аерылды. Тәкъдире кара булган, күрәсең, бәбкәмнең... *(Елый.)*

Н а д и р. Елама, әби... Менә мин дә еламыйм әле... Минем кадәре аны сөюче, минем кадәре аны ихтирам итүче дөньяда түгел, җәһәннәмдә дә булмас. Шулай да еламыйм, хәер, минем гомеремдә дә елаганым юк... Нигә еларга... Барыбер мине аяучы булмас, мине Алла үзе дә аямаган бит.

Г ө л н у р. Тәүбә, диген, бәбкәм. Тәүбә, диген, Аллага тел озайтма!..

Н а д и р. Аңарга тел озайтмаскамы?.. Мин, әгәр дә минем кулымнан килсә... мин аны... Юк шул, юк. Көч юк...

Г ө л н у р. Бәбкәм, әллә син дә...

Н а д и р. Юк, әби, минем шашканым юк әле... Менә безне яраткан, мине яраткан Алла шашканга охшый.

Г ө л н у р. Чү, бәбкәм, тәүбә, диген. Лә илаһе иллаллаһ мөхәммәде расүлуллаһ, ләхәүлә, ләхәүлә...

Н а д и р. Укыма, әби... Әгәр дә ул юньле булса, менә минем шикелле, әнә теге агулаучы, ил өстенә әҗәл чәчеп йөрүче карчыкларны яратмаган булыр иде.

Г ө л н у р. Ләхәүлә, ләхәүлә... Моңар да җиткән икән... Ярабби, үзең мәрхәмәтеңнән ташлама... Ләхәүлә, ләхәүлә... Мәхдүм, бисмилла, диген!..

Н а д и р. Минем каршымда хәзер әнә теге дәҗҗал карчык белән сине яраткан Алла арасында аерма юк. Икесе дә — җинаятьчеләр алар. Йә, нигә мине шул кыяфәттә дөньяга яраткан? Әткә биргән матурлыкны да бит миннән кызганган. Әллә мине яраткан вакытта исерек булганмы ул? Мине яратса, дөнья җимерелер идемени?

Г ө л н у р *(Коръән күтәреп)*. Бәбкәм, Коръән тот, качарлар.

Н а д и р. Кемнәр, кемнәр?

Г ө л н у р. Җеннәрең, бәбкәм, җеннәрең. Бисмилла, диген.

Н а д и р. Ярый, әби, мин артык сүгенмәм инде. Барыбер файдасы юк. Шулай бит, Фатыйма туташ. Син дә Сәрвәрнең хәлен белергә килдеңме?

Ф а т ы й м а. Бик кызганыч, бичара.

Гөлнур, сәкегә намазлык җәеп, тәсбих тартып утыра.

Н а д и р. Кызганыч шул... Ә мин көннәр буе янында утырам... Менә шул шашкан Сәрвәр янында рәхәт табам. Ул минем белән сөйләшә. Җырлый, мин дә аңар кушылып җырлыйм. Читтән караган кеше мине дә, шөһбәсез, шашкан дип уйлар, ләкин мин гомеремдә дә шаша алмам, мин рәхәтләнеп шашар идем, ләкин булдыра алмыйм, булды-

ра алмыйм, булмый. Шашар өчен Сәрвәр төсле җаннар, Сәрвәр төсле кеше кыяфәтендәге фәрештәләр булырга кирәк. Ә мин гурбун шәйтан, шулай бит, гурбун шәйтан, эт бит, һи-һи-һи.

Фатыйма. Нигә алай уйлыйсыз?

Надир. Ничек уйлыйм соң? Алайса, бөкре пәри, мунча пәрие, һи-һи-һи... дөньяда нинди ямьсез нәрсә булса, шул ямьсезләрнең барысыннан да артыграк мин ямьсез. Шулай бит? Сәрвәр туташ алай дими иде: ул, мине кызганып, минем ачуымны китерә иде. Шулай да күземә туры карый ала иде. Башкалар минем күземә туры карарга җирәнәләр... Һи-һи-һи... Кызык бит, ә? Кешеләр синнән җирәнсен, имеш... Алланың рәхмәте нинди зур, ә?.. Һи-һи-һи... Кешеләрне берсен болай ярата, икенчесен тегеләй. Берсен матур итеп, икенчесен чирканыч итеп ярата. Балалар кузна уйнаган шикелле, безнең белән уйный. Һи-һи-һи... Бәлки, чынлап та, аның гаебе юктыр, бәлки, ул мине бөтенләй белми дә торгандыр... Бәлки, гаеп бөтенләй башкададыр... Мине шул кыяфәттә кем тудырган булса, шул җәһәннәмнең төбенә йөзтүбән китсен.

Фатыйма. Һәрнәрсәнең хикмәте була, диләр, мәхдүм.

Надир. Хикмәт. Һи-һи-һи... *(Пауза.)* Ә безнең Сәрвәр юк. Суга-фәләнгә төшмәсен.

Фатыйма. Бер бүген генә чыгып йөрүе түгел бит.

Надир *(«Уел» көенә җырлый)*.

Нигә генә мине ялгыз итеп
Дөньясына китергән бу Ходай?
Нигә мине, Ходай, читкә кагып,
Үксез, боек иттең син болай?
Ник яраткан Ходай дөньясына
Ярсыз, дуссыз сынгандай ят күңел?
Икеләй генә тилгән, һай, бер былбыл,
Нигә үлгән тилгәнләй мин түгел?

Сәрвәр белән без Исмәгыйльнең каберенә барабыз. Ул җырлый, мин Коръән укыйм. Мин һәрвакыт аның кабердә Коръән укыйм. Ул миңа хәзер якын туган төсле. Үткән җомганы урманга җиләк җыярга бардык. Шунда агач төбендә утырганда, Сәрвәр сүнгән йолдызлар хакында сөйләде. Бик һәйбәт җырлады. Ә беләсезме нәрсә, Сәрвәр хәзерге хәлендә миңа акыллы чагыннан да сөйкемлерәк. Ул минем белән сөйләшә. Минем күзләремә туры карый. Кулларымнан тота. Миннән чирканмый, ә бит терелсә, икенче төрле булуы мөмкин. Әйе, ул миңа

хәзер элеккедән дә сөйкемлерәк... Гөлнур әби, кара аны, Сәрвәрне сакла. Дәвалыйбыз дип, агу эчереп үтерсәгез, менә валлаһи дип әйтәм! *(Пәкесен чыгара.)* Ярты авылны суеп чыгармын. Мин чыдасы кадәр чыдадым инде... Хәзер Сәрвәр минеке... Аны миннән бер кеше дә аерып ала алмас. Их, Фатыйма, әгәр сез минем йөрәгемне ярып карасагыз, һушыгыздан таяр идегез. Җәһәннәм анда, чын җәһәннәм. Әгәр дә Алла эләксә, үзе дә янар иде анда, ихлас, янар иде, һи-һи-һи...

Ф а т ы й м а. Һаман Аллага тел озайтасыз, алай ярамый.

Н а д и р. Ярамый шул, тәүбә, тәүбә... Әйттем исә кайттым. Чынлап та, Аңар тел тидерергә ярамый. Гөлнур әби, шулай бит, Аллага тел тидерергә ярамый бит? Гөнаһ була, һи-һи-һи!..

Г ө л н у р. Менә әллә кайчан шулай кирәк иде. Көфер сүзләр сөйләргә ярамый.

Н а д и р. Дөрес, ярамый. Хәер, Алла мондый пүчтәкләрне генә кичерер, ярлыкый бит ул! *(Пауза.)* Фатыйма туташ, мәдрәсәдә минем бер шәригем бар иде. Шул кеше Алланы сүгә иде, Алла юк, ди, торган иде. Соңыннан шул кеше ишан булды. Меңнән артык мөриде булды... Менә дөньяда нинди кешеләр бар. Ә мине Фәрхи карчык гурбун эт ди. Шәп бит! Һи-һи-һи...

Ф а т ы й м а. Без надан кеше, бернәрсә дә белмибез.

Н а д и р. Шулай шул. Шуңар күрә сез бәхетле дә, ә мин менә надан да түгел, галим дә түгел. Кеше дә түгел, шәйтан да түгел... Урталыкта адашып калган. Аллага кызык кеше кирәк булган да мине яраткан. Һи-һи-һи...

Ф а т ы й м а. Сез тагын тотындыгыз.

Н а д и р. Әнә анда әби тәсбих тарта. Алтмыш елдан бирле ул аны тарта. Һаман туксан тугыз. Артмый да, кимеми дә – һаман беркөе, минем гурбуным төсле. Һи-һи-һи... Ә Сәрвәр туташны эзләргә кирәк. Коега батып куюы да бар бит... Ул чагында дөньяда торырлык калмый... Иң соңгы өмет тә югала. Дөньяда өметсез торып булмый. Барып эзләргә кирәк. *(Тора.)* Әби, күптән чыгып киттеме?

Г ө л н у р. Өйләдән соң чыгып китте.

Н а д и р. Сез бармыйсызмы, Фатыйма туташ?

Ф а т ы й м а. Юк, мин монда көтәрмен, кайтыр әле.

Н а д и р. Минем белән урамнан үтәргә хурланам диегез, һи-һи-һи... Зарар юк. Ә Сәрвәр хурланмый...

Еракта «Каз канаты» көенә Сәрвәрнең җырлаган тавышы ишетелә.

Чү, чү... бу аның тавышы... Ул кайта. *(Тәрәзәгә барып.)* Әйе, әйе, ул шул. Сез аны борчымагыз, үз иркенә куегыз!..

Сәрвәр *(пәрдә артыннан шул җырларны җырлый)*.

Сандугачлар чут-чут сайрый,
Ярманнар кылыч кайрый.
Сугышка киткән газиз баш
Туган илләргә кайтмый.

Каз канатлары, чәчәкләр, үләннәр, башаклы саламнар кочаклап, Сәрвәр керә. Күлмәге сәләмә, чәчләре тузган, яланаяк, чәчләренә үләннәр ябышкан, җырлый.

Каз канаты йомшак һәм ак,
Кыз канаты сөттәй ак.
Кыйгак, кыйгак, кыйгак, кыйгак,
Без барыбыз бүген шат.
Рушан йолдыз ялтырамый
Айның ундүрт төнендә.
Сагынганда айга кара,
Син булырсың күңелемдә.

Канатларын идән буйлап тарата. Шуларны рәтләп тезеп, каранып, аларга карап җырлый.

Саф-саф булып кыр казлары
Үтәр, язлар җиткәндә,
Кемнәр сиңа ясин укыр,
Газиз җаның чыкканда?

Канатны кочаклап.

Елама җаным, елама, канат,
Елап уңаймый эшләр.
Мин ятимне син сагынсаң,
Ешрак сәламнәр җибәр.

Канат сатам, канат сатам, канат сатам!.. Кая ул — мин алам... Кара... кая үрмәли, ха-ха-ха... Акчаң җитәрме соң? Үзең чибәрме соң? Мә, ал, нәрсә ул? Нәрсә ул?.. Ал... Ярый, кал!..

Каз канатын кызлар сата,
Ир канатын кем сата?
Җан теләген кире какма,
Дошманнардан сынатма!
Каз канаты төрле була,
Кыз канаты бер була.

Җаның сөйгән яр алдында
Оҗмахтан артык була.

Сиңа, егет, кем кирәк? Кара кашлы кыз кирәк. Сиңа, егет, кем кирәк?.. Каз мамык ястык кирәк. Казларыбыз мамыксыз, кызлар ята ястыксыз!.. Ууу… Ха-ха-ха…

Канатларын бәргәләп тарата. Яңадан җыя башлый.

Каз канаты йомшак, дибез,
Ир канатын белмибез.
Казлар симез булсын өчен,
«Каз канаты»н җырлыйбыз.
Кыйгак-кыйгак кыр казлары
Оча кыйбла ягыннан.
Кыр казлары үткән саен
Хәбәр көтәрмен синнән.

Нәрсә?! Сугыш! Ха-ха-ха… Менә сүнгән йолдызлар каян килеп чыкты… Юк, юк, мин сине җибәрмим. Син монда кал!.. Әйе, монда… Әйе, дару, дару, колагыңа дару салырмын! Аһһһ!.. Ул үлә… Ул үлә… Ярдәм итегез! Ул үлә!.. Юри, юри… Үлми, юри генә… Ха-ха-ха!..

Күзләр үтеп, язлар җитәр,
Бакчада былбыл сайрар.
Кылыч чапкан җәрәхәтнең
Каннарын кемнәр юар?

Торып, күзләрен зур итеп ачып, як-ягына карана.

Чү, чү, йолдызлар сүнәләр… *(Надирга.)* Йолдызлар, йолдызлар сүнә!.. Син кем, син кем?.. Әйе, әйе, син теге аждаһа ялчысы, кем әле?.. Сәлам әйт аңа… Каз өмәсенә килсен… Килсен… Мин аны кызганам… Мәхдүм, пычагыңны ташла. Мәҗлесне сансызлау килешми… Исмәгыйль, Исмәгыйль. Хәзер китерәм. Хәзер колагыңа салырбыз!.. Хәзер, хәзер…

Йөгереп чыга башлый. Мәхдүм тота, Сәрвәр ташлана, Фатыйма да тота.

Җибәрегез, җибәр! Соңга калам… Даруга соңга калам… Фәрхи әби, Фәрхи әби, аяк астында туфрак булыйм. Һичкемгә, һичкемгә, һичбер кемгә әйтмәм. Валлаһи, әйтмәм!..

Яткыралар.

Менә шулай, сул колагыңа, сулына!.. Әһә! Әһә… Чыда, җаным, чыда… Әһә… Аһ, аһ, аһ! *(Бик каты кычкыра, сирпелә.)* Ул үлә… Исмәгыйль үлә!.. Аһ, аһ, аһ!..

Н а д и р. Әби, су бир!.. *(Әби су бирә, эчерәләр.)*

С ә р в ә р *(тынычлана, урыныннан торып, идәндәге канатларга)*.

Зөһрә йолдызларның нурын
Каплар туплар төтене.
Синең өчен теләк теләп
Елармын көне-төне!..

Канатлары янына килеп, канатларны кочаклап елап кала.

Хуш, бәхил бул, җанкисәгем,
Инде соңгы теләгем:
Үлгән хәбәрем ишетсәң,
Атнакич укы хәтем!..

Гөлнур, Фатыйма елыйлар, Надир агарып катып Сәрвәргә карап тора.

Сәрвәр, тезләнеп, канатларны кочаклап елый.

А к р ы н  г ы н а  п ә р д ә  т ө ш ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зиратлык. Агачлар, каберләр, каберташлары.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

С и р а җ и һәм Ш ә й б ә к.

К ө т ү ч е  С и р а җ и, ялгызы чыбыркы очы ишеп, бер таш өстендә утыра.

Ш ә й б ә к зур паузадан соң чыбыркысын шартлатып керә.

Ш ә й б ә к. Бабай, көтүне урман авызына сөрикме? Анда үлән шәп булыр.

С и р а җ и. Нигә, монда әллә азык начармы?

Ш ә й б ә к. Монда да яхшы әле. Теге яңгырдан соң кырлар болын төсле булып китте. Үләннәр менә болай. Гөлнур әбинең мүкләк сыеры бух иткән, менә болай, көчкә тын ала. Җилене җиргә өстерәлә.

С и р а җ и. Рәхәтләнсеннәр, рәхмәт төшкерләре. Алла ул хайваннан ризык кызганмый.

Ш ә й б ә к. Бабай, Алла адәмнәрдән ризык кызганамы?

С и р а җ и. Кызганмый да, шулай да Алла каршында адәмнәр бер түгел. Берсен бәхетле ясый ул, икенчесен бәхетсез итә. Ә хайванны ул бертөсле күрә.

Ш ә й б ә к. Бабай, бу инде ярман патшасы белән безнең патша сугыша, ди. Шул инде ике патша үзләре алда торып сугышалармы?

С и р а җ и. Патшалар үзләре сугышмый, аларның халыклары сугыша.

Ш ә й б ә к. Нигә үзләре сугышмый?

С и р а җ и. Нигә сугышсыннар... Сугышу бит ул җиңел эш түгел.

Ш ә й б ә к. Нигә соң патшалар сугыша дип әйтәләр?

С и р а җ и. Патшалар алар халык башында тора. Халыкны сугыштыралар.

Ш ә й б ә к. Бабай, бу сугыш ни өчен чыга?

С и р а җ и. Патшалар ачуланышалар да, әйдә, халыкны куып сугыштыра башлыйлар. Үзләре читтә карап торалар. Җиңгәне җир ала, медаль ала, плен ала, шәһәр ала.

Ш ә й б ә к. Ул алынган җирләр, шәһәрләр кемгә була?

С и р а җ и. Кемгә булсын, патшага, байларга, купецларга, янаралларга була.

Ш ә й б ә к. Нигә, халык сугыша бит, халыкка булсын иде.

С и р а җ и. Андый закон юк шул.

Ш ә й б ә к. Ә теге җиңелгән патша үз җирләрен, акчаларын җиңгән патшага бирәме?

С и р а җ и. Ни эшләп үзенекен бирсен, халыктан җыеп бирә. Менә безнең авылдан җыелган иманалар шундый җирләргә китәләр.

Ш ә й б ә к. Бер кешенең сугышасы килмәс, сугышка ул бармаса ни?

С и р а җ и. Ни булсын, төрмәгә ябалар. Йә мылтыктан атып үтерәләр.

Ш ә й б ә к. Бабай, иртәгә терлекләрне Кушкаенга куарбыз. Анда үлән тездән, ди. Әйдә, хайваннар бер рәхәтләнеп калсыннар.

С и р а җ и. Алла боерса, диең.

Ш ә й б ә к. Соң, иртә булгач, боермаса да була инде.

С и р а җ и. Булмый шул. Алланың ачуы килсә, тотар да төнлә шул үләннәрне киптереп ташлар. Менә аннан соң куарсың Кушкаенга.

Ш ә й б ә к. Бабай, Алла шулай ачуланамыни?

С и р а җ и. Ачуландырсаң ачулана шул.

Ш ә й б ә к. Бабай, Алланы күргән кеше бар микән?

С и р а җ и. Ул күренми.

Ш ә й б ә к. Соң, күренмәгәч, Аның барлыгын каян беләләр.

Сираҗи. Менә шул агачлардан, кешеләрдән карап беләләр.

Шәйбәк. Бабай, бу каберне таныйсыңмы?

Сираҗи *(борылып)*. Кайсын?

Шәйбәк. Менә монысын. Менә, менә!.. *(Аягы белән кабергә төртә.)*

Сираҗи. Юк, кемнеке соң?

Шәйбәк. Исмәгыйль абзыйныкы.

Сираҗи. Кайсы Исмәгыйль?

Шәйбәк. Хәзрәттә хезмәтче булып тора иде бит. Сугышка бармас өчен, колагына дару салып үлгән.

Сираҗи. Аның кабере шулмы? *(Торып, чыбыркысын шартлата.)* Чыбыркысы да чыбыркысы... Елан төсле, һуп! *(Шартлата.)*

Шәйбәк. Кая, бабай, мин дә шартлатып карыйм. *(Алып шартлата.)* Син, бабай, очына кыл иш. Ныкка килә.

Сираҗи. Кыл булса шартламый. Аннан соң, акрын гына суксаң да, бик авырттыра.

Шәйбәк. Бабай, сугыш җирендә инде чыбыркылар очына тимер чыбык ишә торганнардыр?

Сираҗи. Анда сыерлар белән сугышмыйлар, ядрәдән яудыралар. Шарт та шорт, чыдап кына тор!.. *(Колагын тота башлый, Шәйбәк чыбыркы шартлата.)* Кил әле, улым, үлекләр рухына багышлап бер сузып алыйк.

Шәйбәк. Бабай, үлекләр безнең сөйләшкәнне ишетәләрме?

Сираҗи. Үзләре ишетми, рухлары ишетә, ди муллалар.

Шәйбәк. Ничек инде ул алай? Үзләре ишетмәгәч, рухлары ишетә?

Сираҗи. Анысы инде Алла эше.

Шәйбәк. Рух соң күзгә күренәме?

Сираҗи. Юк, өрәк кенә күзгә күренә.

Шәйбәк. Өрәк белән рух бер түгелмени?

Сираҗи. Юк, кая, сузып алыйк. Үлекләрнең дә күңеле булыр, ята-ята алҗып беткәннәрдер мескеннәр...

Шәйбәк. Үлекләр озакмы шулай тик ятарлар?

Сираҗи. Кыяматкә кадәр.

Шәйбәк. Ә ул кыямәт кайчан булыр соң?

Сираҗи. Кояш менә бу яктан чыккач... Әйдә, суз!.. *(«Мәдинәкәй» көенә курай уйный.)*

Шәйбәк.

Богдай гына чәчтем,
Богдай гына чәчтем, ай, уңмады,

Буразнасы аның тулмады.
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч.
Һичкемгә дә, дуслар, үпкәләмим,
Үз бәхетем минем булмады.
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч.
Аяз да гына булса, ай, айга көч,
Болыт та гынай булса, көнгә көч.
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч.
Кайда гына барсаң, шул бер кояш,
Күбәләктәй газиз җанга көч.
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Сафый.

Сафый. Әссәламегаләйкем!.. Моңланасызмы?

Сиражи. Вәгаләйкемәссәлам! Сафый, үлекләрнең күңелләрен бераз ачыйк, дидек.

Сафый. Үлекләр үлеп котылдылар. Менә исәннәрнең эше яман. Бер яктан, бала-чаганы сугышка алып киттеләр. Икенче яктан, иманага терлекләрне җыялар. Бу ярман патшасы бик яман икән. Безнекен бик нык кыздыра, ди. Төрекләр дә аның яклы икән.

Шәйбәк чыга.

Сиражи. Төрекләр аның ягында булса, аның эше җайлыдыр. Пләүнә төбендә Госман патша безнең дә кирәкне бирде. Ул тере булса, урысның эше кәкәй инде. Ядрәне яңгыр төсле сиптерә ул. Ә инде штыкка барганда, һич чыдар хәл юк. Кибәнгә көлтә ыргытамыни. Тәкбир әйтеп кереп китә, мин сиңа әйтсәм. Безнекеләрдән тузан гына оча.

Сафый. Ярый инде алай булгач, төрек белән бергә булгач, ярманга Алла куәт бирсен инде. Бу урыс артыграк узынып китте. Яхшылап борынын төшерсәләр, бәлки, мөселманга җиңеллек булыр. Югыйсә бит имана, набур белән теңкәгә тия. Төрекләр җиңсә, әллә җир дә артыр иде. Төрек әйтә икән, ди, әгәр дә, дип әйтә икән, ди, шул мордар урысны җиңсәм, иң элек мөселманга җиңеллек ясап, җир бирермен, имана түләттермәм. Рус белән бертигез ясармын. Мөселманча укырга юл куярмын. Зиратларның тирәләрен тимер рәшәткә белән тотармын, дип әйтә икән, ди.

С и р а җ и. Алла куәт бирсен. Нияте яхшыда икән, җир аз шул, бер көн эчендә көтү бөтен кырны урап чыга. Андый җирдә нинди азык булсын. Ә халык аны аңламый. Көтүчене гаепли. Ярый әле, менә яңгыр булып җиргә җан кертте. Яңгыр булмаса, Сираҗи терлекләрне карамый, дип күз дә ачырмыйлар. Җир инде мөселманына да, русына да кирәк инде. Ансыз булмый. Русның терлеге дә, үзе дә шундый ук Алла хайваны, Алла бәндәсе бит, мөселман төсле үк.

С а ф ы й. Дөрес, Сираҗи, дөрес. Дөньяга туган һәр җан иясенең торасы килә. Җаны булгач, җире дә булсын аның. Бу патшаны да әйтәм, мин сиңа әйтсәм, Алла биргән җирне русыннан, мөселманыннан кызгана. Әллә каберенә алып китмәкче буламы?..

С и р а җ и. Дөрес, Сафый, дөрес.

С а ф ы й. Кабер өчен күп җир кирәкми. Менә Алланың биргәненә шөкер, өч йөз илле алтынчы каберне башларга килдем. Бер колач җиргә староста да, старшина да сыя, патшага да артык кирәк түгел.

С и р а җ и. Кемне җирлисез?

С а ф ы й. Чулак Нуретдиннең улы сугыштан кулсыз, аяксыз кайтты. Тора алмаган, бичара, кичә төнлә белән җан биргән.

С и р а җ и. Кайсы улы?

С а ф ы й. Уртанчысы бугай.

С и р а җ и. Теге уллары исәннәр микән?

С а ф ы й. Зурысы үлгән, ди. Кечесе исән, ди, әле. Анысы да үләр инде. Ярманга һич чыдар хәл юк, ди, анда. Менә минем үземнең икәве анда. Зурысыннан өч ай хәбәр килгәне юк. Аллага тапшырдык инде. Бөтенләй кул-аяксыз калдырды бу патша. Ярый, каберне башларга кирәк. Хәзрәт базардан кайтса, бүген күмәрләр. Хи-хи-хи... Сөякләр сызлый. Әллә тагын яңгыр булыр инде.

С и р а җ и. Бирсен Алла, терлекләр бер рәхәтләнерләр иде.

С а ф ы й. Ярый, Сираҗи, сау бул. Каберне казырга кирәк. Үлекне көттерү – гөнаһ... *(Чыга.)*

С и р а җ и *(торып)*. Шәйбәк, Шәйбәк! У-у-у!.. Кара, әнә теге чуар тана арыш кырына китмәкче була. Кайтар үзен. *(Пауза)*. Ай, таяк белән бәрмә алай. Хайванны рәнҗетмә!.. Менә шулай... *(Борылып юлга таба барганда, Җиһанша керә. Сираҗи аны күреп.)* Саумы, Җиһанша агай?..

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сираҗи, Җиһанша.

Җиһанша *(кулын маңгаена куеп)*. Бу синмени, Сираҗи?.. Көтүне монда утлатасызмыни? Ничек соң, терлекләр туярлыкмы?..

Сираҗи. Бик рәхәтләнеп... Беркөнге яңгырдан соң җиргә җан керде. Хайваннар, рәхмәт төшкерләре, берничә көн эчендә җан алдылар. Зиратка килдеңме?

Җиһанша. Юк, игеннәрне карарга чыктым. Югары арыш кырын барып күрмәкче булам. Хәлләре ничегрәк икән? Кичә урман артындагы сабаннарны карарга барган идем. Җаннарым рәхәтләнеп китте күргәч. Куян капланырлык булганнар. Менә болай. Ул тарылар, мин сиңа әйтсәм. Куе булып чыкканнар. Хәзердән үк карга капланырлык ясмыклар, борчаклар да бик һәйбәт булып киләләр... Сабан яхшы. Беркөнге яңгыр, зәмзәм суы шикелле, сабакларны тергезеп җибәргән. Арышларны карарга барам. Хәлләре ничек икән. Югары оч Хисами күреп кайткан, ат күмәрлек булып, дулкын-дулкын булып торалар, ди. Атна-ун көннән серкә очырыр. Бирсен инде Ходай, хәере белән җыярга насыйп булсын. Югыйсә бит эшләр шәп түгел: балаларны сугышка кудылар, иген дә булмаса, ят та үл.

Сираҗи. Еллар авыр булып китте шул. Бирсен инде Ходай, иген дә булмаса, кортлар шикелле кырылырга гына кала.

Җиһанша. Әйтмә инде. Рәхмәтеннән ташламасын инде. Арышларга тагын берәр яңгыр булса җитә. Серкә очырганнан соң, берәр яңгыр булып, кыздырып җибәрсә, төшеме, орлыгы яхшы була. Ә сабанга кирәк әле. Ни булса да, хәере белән булсын инде.

Сираҗи. Улларыңнан хәбәр юкмы?

Җиһанша. Юк шул, бер хәбәр дә юк. Хисами малае гына «сугышка бергә керәбез» дип язган булган. Әйтмә инде, Сираҗи, тугыз кашык күтәрәбез. Йортта бала-чагадан башка ир заты юк. Җыен бала-чага, хатын-кыз белән утырып калдык. Игеннәрне хәере белән җыярга язсын инде. Булмады исә, егыл да үл. Ярый, Сираҗи, мин барып, арышларны бер күреп, җанны рәхәтләндереп килим әле. Терлекләр туя диген, алайса?

Сираҗи. Рәхәтләнәләр генә. Берничә көн эчендә тәнләнеп киттеләр. Көтү дә зур түгел хәзер. Казнага алалар да казнага алалар.

Җиһанша. Бирсен Ходай, бирсен. Ярый, барып карап кайтыйм әле.

Чыга, Шәйбәк керә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сираҗи, Шәйбәк.

Шәйбәк. Бабай, һавада карлыгачлар уйный. Төнгә тагын яңгыр булыр.

Сираҗи *(кулын маңгаена куеп күккә карый)*. Бирсен Ходай, карлыгачлар уйный шул. Болай булса, төнгә дә калмас.

Шәйбәк. Бабай, әнә урман артында болытмы ул, нәрсә ул?

Сираҗи. Кая? Ә-ә, болытмы, әллә янгынмы? Төтенгә дә охшый.

Шәйбәк. Бая аз гына иде, хәзер әнә ничек.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әүвәлгеләр һәм Мөрид.
Мөрид суфи кыяфәтле. Каберлеккә кереп, Коръән укый.

Сираҗи. Синең күзең үткенрәк бит. Төтенгә охшамыйммы?

Шәйбәк. Бер карасаң, төтенгә дә охшый. Икенче карасаң, болытка да охшый.

Сираҗи. Ярый, ни булса да, хәере белән булсын. *(Курай уйный башлый, «Әллүки» көенә.)*

Шәйбәк *(җырлый)*.

Ишеттем мин кичә: былбыл сайрый,
Канат кагып яфрак астында.
Әллүки, бәллүки, сагынып сәлам язган абзый
җаныкай.
Сагынганмы былбыл туганнарын, —
Әллә кайгы-хәсрәт башында?
Әллимсең, бәллимсең, кош теледәй язуын
җәллимсең?

Мөрид. Әссәламегаләйкем!..

Сираҗи. Вәгаләйкемәссәлам!

Мөрид. Зиратлар өстендә курай тартып, җырлашып утыру — гөнаһ, карт. Үлекләрне газаплау була. Муллагыз кем?

С и р а җ и. Муллабыз — хәзрәт.

М ө р и д. Исеме ничек?

С и р а җ и. Без, хәзрәт, дибез. Исемен каян беләсең. Мәҗлесләрдә очрашмыйбыз.

М ө р и д. Мәчеткә дә бармыйбыз, диең.

С и р а җ и. Барып булмый шул.

М ө р и д. Соң син, мөселман, бу курай тартып җырлауларның гөнаһысының зурлыгын беләсеңме?

С и р а җ и. Кайдан беләсең аны. Без укымаган, надан кеше.

М ө р и д. Белмәсәң, менә бел, алайса. Курай тарту, авыз күтәреп җырлау — хәрәм. Бик зур гөнаһ, зират өстендә шул гөнаһны кылу — гөнаһ өстенә гөнаһ. Үлекләрне рәнҗетүең — аның өстенә гөнаһ... Карт башың белән менә бу сабый балага шәйтан уены өйрәтү — шул бөтен гөнаһларың өстенә гөнаһ.

С и р а җ и. Абзый, бу гөнаһларың бигрәк күбәеп китте. Күтәреп булыр микән соң?

Ш ә й б ә к. Ялганлый ул, җырлау гөнаһ түгел.

М ө р и д. Кит син, чучка борын. Иблис малае! *(Таягы белән кизәнә, Шәйбәк чыгып китә.)* Менә сиңа гөнаһ түгелне күрсәтермен! Бу ниткән эш бу! Сакал сәлперәйтеп, зират өстендә курай тартып җырлап утыралар. Хәзрәтегез шундыйдыр, ахры? Соң син беләсеңме, бу гөнаһ өчен тәмугта күпме яначаксың?

С и р а җ и. Күпме?

М ө р и д. Җитмеш җиде мең ел. Ә инде сиратны үткәндә, җәһәннәмгә чәнчелеп төшәчәксең.

С и р а җ и. Менә анысы булмас инде, тора тор!

М ө р и д. Менә булганын баргач күрерсең.

С и р а җ и. Булмас шул. Хәзрәт, сиратны син, Сираҗи, яшен кебек тиз үтәрсең, ди... Менә шуның өчен мин аның терлекләрен буш көтәм. Хәзрәтнең дүрт сыеры, ике баш танасы, илле баш сарыгы — һәммәсе дә безне менә Шәйбәк белән сираттан җилтерәтеп кенә алып чыгарлар.

М ө р и д. Әгәр дә берәр кешенең фатихасын ала алсаң, мин анысына керешмим.

С и р а җ и. Менә инде ундүртенче ел хәзрәтнең терлекләрен бушлай көтәм. Шуның өчен хәзрәт фатихасын бирә.

Ш ә й б ә к керә.

М ө р и д. Алай булса, хәер, сүзем юк. Ә инде бу зират өстендә курай уйнавың өчен зобанилар кирәгеңне бирерләр. Анысыннан инде котыла алмассың!

С и р а җ и. Хәзрәт әйтә, көтүче хайваннарны рәнҗетмәсә, сөтен савып эчмәсә, аның урыны оҗмахта, ди. Муса атлы пәйгамбәр дә көтүче булган. Безнең урын анықы белән бергә буласы, ди. Ышанмасаң, барып, хәзрәттән сора.

Ш ә й б ә к. Икмәктер, шулай, миңа да әйтте. Син, абзый, үзең кем буласың?

М ө р и д. Мин Күсекәй авылыннан булам.

С и р а җ и. Кая барасың?

М ө р и д. Бозлы чишмәгә.

С и р а җ и. Ни йомыш белән?

М ө р и д. Ишан хәзрәткә кул бирергә барам.

С и р а җ и. Алай. Ул инде, кул биргәч инде, тегендә ничек инде аларның эше?

М ө р и д. Кайда?

С и р а җ и. Ахирәттә дигәнем.

М ө р и д. Анысы инде Алланың үзенә генә билгеле. Бу нинди авыл?

С и р а җ и. Югары Каенсар.

М ө р и д. Сезнең авылда мөридләр бармы?

С и р а җ и. Белмим, бардыр.

М ө р и д. Алай, иртә намазында ничә рәкәгать?

С и р а җ и. Мин яшь чакта дүрт иде. Хәзер ничәдер, белмим.

М ө р и д. Кяфермесән, мөселманмысән?

С и р а җ и. Элек мөселман идек.

М ө р и д. Сәнең мөселманлыгыңда мәнем шәкем бар.

С и р а җ и. Синең шәкеңдә минем ни эшем бар?!

М ө р и д. Бәхетең, карт. Син безнең авылда түгел. *(Китә.)*

С и р а җ и. Нишлим мин сезнең авылда!

Ш ә й б ә к. Бабай, теге кара нәрсә болыт булып чыкты. Кара, нинди килә.

С и р а җ и *(кулын куеп карый)*. Боз булмаса ярар иде. Бик гайрәт белән күкрәп килә. Әйдә, улым, көтүне авылга якынрак сөрик.

Чыгалар, ерактан күк күкри башлый.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

С ә р в ә р *(пәрдә артыннан җырлый)*.

Түтәл, түтәл гөлләр күрдем
Су буенда чирәмдә.

Дөньяда күп михнәт күрдем,
Унтугызга җиткәндә.

Дөнья караңгылана башлый. Сәрвәр, чәчәкләр, каз канатлары, саламнар кочаклап, җырлап, Исмәгыйль каберенә килә.

Кочак, кочак гөлләр җыйдым
Сөйгәнемә бүләккә.
Каз канаты тәкбир әйтә,
Кыйблаларга очканда.
Кыз канаты тәсбих әйтә,
Сөйгән яры кочканда.

Кабергә сибеп.

Кочак, кочак гөлләр җыйдым
Сөйгәнемә бүләккә.
Унтугызга җитәр-җитмәс
Ут кабынды йөрәккә.

Күк күкри.

Каз канатын кызлар сата,
Ир канатын кем сата?
Ир канатын патша сата,
Туган илне елата.

Елап.

Кыйгак-кыйгак кыр казлары
Оча кыйбла ягыннан.
Кыр казлары үткән саен
Хәбәр көтәрмен синнән.
Нурлар чәчеп күк йөзендә,
Алсуланып таң атар.
Ярсыз калган кыз баланы
Кемнәр генә юатыр?

Чү, чү, йолдызлар сүнә, йолдызлар сүнә, сүнәләр, сүнәләр. Йолдызлар сүнәләр…

Каты күк күкрәп, яшен ата.

Аh, аh, аh!!!

Бик каты кычкырып егылып үлә. Күк күкри. Яшен яшьни, яңгырява башлый. Күк күкрәве ераклашканнан-ераклаша. Күк йөзе ачыла башлый. Кояш чыга.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җиһанша кычкырып елап кайта.

Җиһанша. Ай Алла! Ай Алла!.. Инде нишләрбез? Кая барырбыз? Нинди гөнаһ шомлыкларыбызга каршы Алла бу бәлаларне җибәрде икән? Уу... Уу... Шулай ук, кортлар шикелле, ачлыктан үләрбез микән?.. Ай Алла, ай Алла... Нихәл итәрбез?.. Ничек көн күрербез?.. Уу!.. Уу!.. *(Елый.)*

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җиһанша, мулла, Надир, картлар.
Мулла, Надир, картлар җеназа күтәреп керәләр.

Надир. Ни булды сиңа, Җиһанша бабай? Нигә елыйсың?

Насыйр. Ни булды? Әллә, әллә...

Җиһанша. Әйтмәгез инде, әйтмәгез, ни хәл итәрбез, ничек көн күрербез? *(Елый.)*

Надир. Нәрсә, ни булган?

Җиһанша. Югары арыш басуын боз сугып эштән чыгарып китте.

Барысы бергә. Ә-ә-ә!!!

Җиһанша. Күз алдымда эштән чыгарып, балчык белән аралаштырып, бутка ясап китте.

Насыйр. Ничек, бик каты суктымыни?

Җиһанша. Эштән чыгарды. Аяк өстендә бер салам калдырмады. Ут шикелле кырып, себереп китте, и-и-их!!! Ниләр генә күрәсебез бар икән?!

Мулла. Әйдәгез, җәмәгать, үлекне көттерү — гөнаһ, ярамый.

Җеназаны алып китәләр.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Җиһанша, Насыйр.
Җиһанша белән Насыйр, каберташларына кара-каршы утырып, башларын салып калалар.

Җиһанша. Ниткән калу, чишмә башыннан наратлыкка кадәр буйлап себерде дә алды. Алпавыт кырына да читен эләктергән. Әйтәм бит, бер буразнаны исән калдырмады. Инде ни хәл генә кылырбыз икән? Ни белән кышны уздырырбыз икән?..

Н а с ы й р. Минем хәзердән үк бер уч игенем юк. Яңа игенгә чаклы дип, Саттар байдан урак өстенә кадәр алганны да төпләдек. Мине бетерде бу хәл.

Җ и һ а н ш а. Барыбызның да хәл бер инде!.. Өсәк төбен кырып-себереп, кичә генә төпләдек. Бөтен таяныч яңада иде.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р, м у л л а, Н а д и р, х а л ы к.
Һәммәсе, каберлекләргә таралып, кычкырып, Коръән укыйлар. Соңыннан, башларын чайкап, өметсезләнеп, җыелып, үзара сөйләшә башлыйлар.

Н а с ы й р. Хәзрәт, ни кылырбыз икән инде? Югары арыш кырын боз сугып эштән чыгарган, ди. Ни эшләрбез икән инде, хәзрәт?

М у л л а. Сабыр итәргә кирәк, сабыр итәргә. Алла сабыр итәргә куша. Гөнаһыбыз күбәйгән шул. Алланы оныттык. Намазга йөрмибез. Сәдака бирмибез, корбан чалмыйбыз, Алла күрә бит аны. Сәдака бирергә кирәк. Алла сабыр итәргә куша.

М у л л а һәм табутны к ү т ә р ү ч е л ә р чыгалар.

Н а с ы й р. Картлар, кырны барып карап әйләнеп чыгарга кирәк. Исән калган җирләре табылмасмы?

Җ и һ а н ш а. Бер буразна исән калмаган. Әйләнеп чыктым инде. Ни генә кылырбыз? Ничек көн күрербез?

С а ф ы й. Картлар, болытны җил кире кайтарды. Тагын монда таба килә.

Җ и һ а н ш а. Сабанны гына эштән чыгармаса ярар иде. Ух-ух, гөнаһларыбыз күптер шул.

Кырны карарга дип, икенче якка чыгалар.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М ә х д ү м ялгыз.
Мәхдүм, торып, Исмәгыйль каберенә таба килә.

Н а д и р. Бу ни бу?.. Сәрвәр мескен йокыга киткән. Йокла, нарасый, йокла. Тыныч йокла! Сөйгәнеңнең каберенә килдеңмени? Елый-елый йокыга киттеңмени? Йокла, нарасый, йокла. Рәхәтләнеп, иркенләп йокла. Төшләр күрә-күрә йокла, безгә хәзер синең белән төштә күреп юанырга гына калган бит, йокла, нарасый, йокла! Йокың туйганчы йокла! Уянсаң да, барыбер шатлык хәбәре көт-

ми. Югары арыш кырын боз суккан. Бәхетсезлекләр берсе артыннан берсе туа гына тора. Ә син йокла, йокла, нарасый... Чәчәкләр китердеңме? Яхшы, бик яхшы, чын сөешү шулай була ул, шулай!.. Ә менә мин үлгәч, минем каберемә кем килер икән? Һичкем, һичкем... Гурбун мәхдүм кабере дип әйтүче дә булмас. Рәхмәт, рәхмәт, Сәрвәр... Чынлап сөйгәч... Шулай сөяргә кирәк аны. Саф йөрәктән чыккан чын бүләкләр. Чәчәкләр, саф чәчәкләр... Ә миңа аларны китерүче булмас. Һич, һичкем китермәс. Минем бит беркемем дә юк. Мин ялгыз... Дөньяда да ялгыз, каберемдә дә ялгыз... Каберем дә, үзем кебек бөкрәеп, читтә боегып ялгыз торыр. Әйе, әйе... Туган көннән бирле ялгыз... Үлгәч тә ялгыз... Мәңге, мәңге... ялгыз... *(Җырлый. «Уел» көенә.)*

Ник яраткан Ходай дөньясына
Ярсыз, дуссыз сынганлай ят күңел?
Икеләй генә тилгән, һай, бер былбыл,
Нигә үлгән тилгәнләй мин түгел?

Мескен, чыланып беткән... *(Җиләнен салып каплый.)* Туңма, җаным, туңма. Сиңа җылы булсын... Менә шулай, менә шулай... Чү... Салкын!.. Сәрвәр, Сәрвәр!.. Өне юк... Күгәргән!.. Ул, ул үлгән... Сәрвәр үлгән!.. Ахры, иң соңгы өметем дә сүнде. Тагын ялгыз!.. Сәрвәр күгәрченем, урманнарга кем белән чыгармын, кем белән менә шул кабер янында утырырмын?.. Моннан соң «Каз канаты»н кем җырлар?! *(Елый.)* Юк-юк, елап булмый. Яшь каткан. Гомеремдә беренче мәртәбә күңелем тулып, йөрәгем кысылды... Юк-юк, елый алмыйм... *(Еpактан күк күкри.)* Хуш, хуш, күгәрченем, хуш, дөньядагы бердәнбер куанычым... Ходай, синең җаныңны алып, актык йолдызымны сүндерде... Сукырның актык таягын сындырды. *(Кинәт торып, чалмасын бөтереп.)* Хәзер мин үземә ни эшләргә кирәген беләм... Моның өчен һичбер кешенең мине шелтәләргә дә, көләргә дә хакы юк... *(Чалмасын агачка бәйли.)* Мин үземә үзем хуҗа!!! Ташлар, агачлар, каберләр, менә күрегез, шаһит булыгыз!.. Мин үземә үзем хуҗа!..

Асылынып үлә. Бик каты күк күкри, яшен яшьни, яңгыр ява. Яшен яктылыгында Надирның кара янып чыккан йөзе, асылынган теле күренеп-күренеп кала.

Пәрдә.

*1923 ел*

# ҖИЛКӘНСЕЗЛӘР

*Комедия*

*Сигез картинада*

УЙНАУЧЫЛАР:

Батырхан — зыялы.
Нуретдин — тәрәккыйпәрвәр, бай сәүдәгәр.
Давыт — Нуретдиннең улы, студент.
Дилбәр — Нуретдиннең кызы, гимназия бетергән.
Рөкыя — Нуретдиннең кызы, бөкре, зәгыйфь.
Гөлнар — Нуретдиннең кардәш кызы, алар тәрбиясендә.
Сергей Сергеевич Носов — генерал.
Зәйнетдин — Нуретдиннең кияве, нэпман.
Фәттах — вак кул бай, спекулянт.
Сөнгать — зыялы яшьләрдән, социалист.
Нияз — мөселман комитеты секретаре, офицер.
Мисбах хаҗи — зур сәүдәгәр, кара бай.
Сәхипгәрәй — Хәрби Шура вәкиле, офицер.
Фәтхи — эшче.
Рауза — хезмәткәр.
Наум Пахомич — зур бай.
Хатын.
Асрау.
Хәзрәт — мулла, мәхәллә имамы.
Голам әкә — лашман, үзбәк.
Байлар һәм эмигрантлар.

Вакыйга башлана 1910 елда, бетә 1923—1924 елларда.

## БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Бай кунак бүлмәсе.

I. Гөлнар, Сөнгать.

Гөлнар *(ишекләрне карап, тәрәзәгә килеп ымлап)*. Кер инде, кер, берәү дә юк. *(Тагын ишекләрне карый.)*

Сөнгать керә.

Ни булды сиңа, нигә мондый вакытта?

С ө н г а т ь. Бер нәрсә китергән идем, яшерә алмассыңмы?

Г ө л н а р. Нәрсә соң ул?

С ө н г а т ь *(чемодан кертеп)*. Менә!

Г ө л н а р. Мондый нәрсәләр белән нигә көндез киләсең?

С ө н г а т ь. Хәтәр эшләрне көндез эшләү уңайлырак.

Г ө л н а р. Моннан соң бу тирәдә күп күренеп йөрмә.

С ө н г а т ь. Нигә?

Г ө л н а р. Давыт кайтты.

С ө н г а т ь. Кайтты?!

Г ө л н а р. Бүген иртә белән.

С ө н г а т ь. Алайса, син моны *(кулындагы чемоданны күрсәтеп)* ышанычлырак урынга яшер.

Г ө л н а р. Авырга алма, Сөнгать, моннан соң сезнең бу хикмәтле нәрсәләрегезне саклый алмамдыр, ахры. Монысы актыгы булсын.

С ө н г а т ь. Нигә?!

Г ө л н а р. Бу йортта озак кала алмам күренә. Шулхәтле туйдым, шулхәтле туйдым, әллә кая баш алып китәргә риза булыр идем. Әллә кем мин монда! Асрау дисәң, асрау түгел. Хуҗа дисәң, хуҗа түгел, әллә нәрсә генә шунда. Кардәш дигән булалар, ансын да сизмим. Адым саен кырын караш, чәнечкеле сүзләр... *(Чемоданны күрсәтеп.)* Моны кайчан алырсың?

С ө н г а т ь. Атна-ун көнсез булмас. Ләкин, зинһар, ышанычлырак урынга куя күр. Юкса бик күп иптәшләрнең эзләре ачылачак.

Г ө л н а р. Тс-с-с!.. Харап булдык, Давыт керә.

С ө н г а т ь *(кулы белән ишарә ясап)*. Борчылма.

II. Г ө л н а р, Д а в ы т, С ө н г а т ь.

Д а в ы т керүгә, Гөлнар белән Сөнгать бер-берсенә карашып, сүзсез катып торалар.

Д а в ы т. Бу ничек болай, Сөнгать «иптәш», сез бездә?!

С ө н г а т ь. Менә туташ белән дә шул турыда сөйләшеп торадыр идек. С приездом! *(Күрешәләр.)* Кайтканыгызны ишеткәч тә килергә булдым.

Д а в ы т *(шикләнеп карый)*. Чемоданнар белән әллә берәр яры китәсезме?

С ө н г а т ь. Юк, бер яры да китәргә җыенмыйм.

Гөлнар борчыла.

Д а в ы т *(чемоданны күрсәтеп)*. Ә бу соң?

С ө н г а т ь. Яңа фатирга күчәм.

Д а в ы т. Нигә, әллә?..

С ө н г а т ь. Юк, ул яклардан полный тынычлык.

Д а в ы т. Нигә фатир алмаштырасыз?

С ө н г а т ь. Хозяйкалар белән тыныша алмыйм бит мин. Алар акча диләр, ә минем акчалар банкыда, хи-хи-хи!

Г ө л н а р. Давыт абый, сине зур әти сораган иде.

Д а в ы т. Күрдем.

Г ө л н а р чыгып китә.

Йә, нигә басып торасыз? Утырыгыз.

С ө н г а т ь. Рәхмәт.

Д а в ы т. Йә, ниләр бар монда, сездә, шәһәрдә? Мин бит әле кичә генә кайттым.

С ө н г а т ь. Ул-бу юк. Искечәрәк.

Д а в ы т. Үзгәргәнсез, ябыккансыз дип әйтимме?!

С ө н г а т ь. Гаҗәп түгел! Быел дачага чыкмадым, курортка баруны мәгъкуль тапмадым. Бүлмәдән кудылар, номерга кертмиләр, бурычка ашарга да бирмиләр, хи-хи-хи!

Д а в ы т. Шутник сез, да... Аттестат зрелостиегез ни хәлдә?

С ө н г а т ь. Губернатор канцеляриясендә хәл җыя.

Д а в ы т. Ничек?!

С ө н г а т ь. Шулай, быел имтиханга да кертмәделәр.

Д а в ы т. Сәбәп?

С ө н г а т ь. Неблагонадёжный.

Д а в ы т. Шул политикага катнашып, үзегезне генә харап итәсез. Политика белән чуала торган заманмыни хәзер, бигрәк тә безгә, татар яшьләренә. Бишенче елны шаярдык, балаландык, шул җитмимени!

С ө н г а т ь. Мин сезгә, Давыт әфәнде, бөтенләй башка йомыш белән килгән идем. Әмма үгетләргә килгәндә, әни карчыкны һич уздыра алмассыз. Гаҗәп кызык карчык. Бер елны үзенә читек алып кайткан идем — кимәде. Тула оек аякка рәхәтрәк, ди.

Д а в ы т *(коры гына)*. Шуннан соң?

С ө н г а т ь. Минем сезгә килүемнең сәбәбе, Давыт әфәнде, ни иде... Теге ни... Сезнең конторага счетовод кирәк дип ишеткән идем...

Д а в ы т. Нигә, сез урынсызмыни?

С ө н г а т ь. Урынсыз дию генә аз, бөтенләй Алла положениесендә калдым.

III. Сөнгать, Давыт, Нуретдин, Батырхан.

Нуретдин *(ерактан шау килеп керә)*. Сайлыйбыз, Алла боерса, сайлыйбыз, күңелеңне көр тот.

Давыт. Исәнмесез, Батырхан әфәнде!

Батырхан *(кулында чәчәкләрдән букет)*. Ә... Давыт әфәнде, исәнмесез, туган, исәнмесез!

Нуретдин *(бүлмә ишекләренә кычкыра, Сөнгатьне абайламый)*. Кызым, кызым, кызым, дим!

Рөкыя керә.

Рөкыя. Нәрсә, әткәй?

Нуретдин. Син түгел, йөрмә монда, кеше бар! *(Төрткәләп кире чыгара. Икенче бүлмәгә барып.)* Кызым Гөлнар, әй, тфү, Дилбәр, дим!

IV. Әүвәлгеләр һәм Гөлнар.

Гөлнар. Нәрсә, дәү абый?

Нуретдин. Син түгел лә... Нәрсә аяк астында буталасыз! *(Кулыннан тотып этеп җибәрә. Гөлнар чемоданга барып бәрелә. Батырхан белән Давыт үзара сөйләшәләр.)*

Гөлнар чемоданны алып чыгып китә.

V. Давыт, Сөнгать, Нуретдин, Батырхан, Дилбәр.

Нуретдин. Әйдә, кызым, әйдә, Батырхан әфәнде көтә.

Дилбәр. Исәнмесез! *(Реверанс ясый, туктап кала.)*

Батырхан. Хөрмәтле Дилбәр туташ, көмеш медаль белән бүген гимназияне бетерүегезне котлап шушы саф гөлләрне тәкъдим итәргә рөхсәт итегез!.. *(Букет бирә.)* Дилбәр туташ, милләтебез сезнең шикелле сөйкемле, зыялы, медальле туташларга мохтаҗ. Яшәсен Дилбәр туташ, яшәсен аның медале!

Сөнгать пырхылдап ала, Нуретдин аңа табан борыла.

Нуретдин. Бу кем?

Давыт. Минем танышым, шәһәребезнең яшьләреннән, таныш булыгыз!

Батырхан. Ә, Сөнгать әфәнде... Без таныш, исәнмесез!

Сөнгать. Исәнмесез!

Давыт. Бу — минем әтием.

Н у р е т д и н. Батырхан әфәнденең үзен һәм танышларын өебездә күрүгә без шат, исәнмесез!

С ө н г а т ь *(күрешә-күрешә)*. Сөнгать Сәйфетдинов!

Н у р е т д и н *(сискәнеп китеп)*. Син әллә теге җомганы бәскерәсиниягә алмаштыручы Ходайсыз Сәйфетдиновмы?

С ө н г а т ь. Җомга белән якшәмбедә минем эшем юк. Хезмәтчеләргә атнага бер көн ял көне бирелүен яклыйм.

Н у р е т д и н. Ярый, ярый. Шул икәнсең, үзе икәнсең, тай, нихәтле тәртәгә дошман булса да, ат булгач, тәртә эченә үзе керә башлый ул, энем. Үзе керә, үзе...

С ө н г а т ь. Әгәр дә тай тәртәне сындырып ташласа, ат булгач, анда керергә туры да килмәс иде.

Н у р е т д и н. Урманда агач бетмәгән, энем. Аннан соң бу заманда тәртәләрне тимерлиләр бит, чибәр егет. Тәртәне сындырам дип аяксыз калуы да бар бит аның, хи-хи-хи!..

Б а т ы р х а н. Ай-һай, Нуретдин әфәнде, телгә яман икәнсез, хи-хи-хи...

Н у р е т д и н. Нихәтле кабарынырга тырышсагыз да, егет, кызыл флагларыгыз белән ерак бара алмадыгыз. Бер атна эчендә җыеныгызны протестка керттеләр. Кояш та, шул иртә белән чыкмыйм-чыкмыйм дип нихәтле кызарынса да, өйлә вакытында агара шул. Үтә кызыл тиз уңа, дигәннәр бабайлар. Сез менә флагларыгызның бер читен яшел итегез, берсен ак, берсен сары... Менә шулай бергә-бергә булганда барып та чыгар ул. Җомга урынына бәскерәсиния тудырып, Ходай сүгеп кенә бернәрсә дә барып чыкмас, энем... Утырышыгыз, әфәнделәр!

Б а т ы р х а н. Менә, Сөнгать әфәнде, халык нәрсә ди. Ә сез, халыкның теләгенә колак салмыйча, эшчеләрне диктатор ясарга җыенасыз. Әгәр дә сезнең ул планнарыгыз тормышка ашса, дөньяга шундаен анархия туачак, бала — атаны, ата баланы танымас, кечкенәләр олыларны санламас.

С ө н г а т ь. Бик яхшы, танымасыннар. Без, гомумән, фетишизмга каршы.

Б а т ы р х а н. Ташыгызның кем бакчасына атылганын күрәм мин, Сөнгать әфәнде. Шулай да мин фетишизмны сезнеңчә аңламыйм. Бөтен җиһанны яратучы көч булырга тиеш бит. Сез инде аңа материя, атом, фәлән дисез. Менә шул атомнар белән идарә итүченең барлыгын аңлыйсыгыз килми. Мондый койрыксыз караш фәнни караш була алмый.

С ө н г а т ь. Атомнарга хозяин эзләү фәнни карашмы? Хи-хи-хи...

Н у р е т д и н. Әфәнделәр, атом-матомнарыгызны ташлап, үзебезчә, атышмыйча гына сөйләшик әле.

Б а т ы р х а н. Минемчә, Сөнгать әфәнде, дин аркылы да социализмга ирешергә мөмкин. Фәнгә, тигезлеккә, икътисади нигезгә нигезләнгән дин, мәсәлән, ислам дине аркылы интернационалга ирешергә бик мөмкин.

С ө н г а т ь. Оҗмахлы, тәмуглы Аллагыз шул интернационалның башында торырмы? Хәер, без андый интернационалга, андый социализмга да ышана алмыйбыз шул... Давыт, Нуретдин әфәндегә минем йомышны әйтсәгез, мин китәр идем.

Н у р е т д и н. Нинди йомыш?

Батырхан белән Дилбәр сөйләшеп террасага менәләр.

Д а в ы т. Сөнгать әфәнде урынсыз икән, счетоводлыкка сездә урын юкмы, ди.

Н у р е т д и н. Былгахтирия рәтләрен беләсеңме соң?.. Телгә үткен булсагыз да, эшкә чамалы буласыз шул.

С ө н г а т ь. Контора эшләрендә яхшы ук тәҗрибәм бар.

Н у р е т д и н. Ә-ә-ә! Булды, булды! Менә нәрсә, Сөнгать әфәнде... Юк, тукта... Гөлнар, Гөлнар! Бире чык әле.

VI. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Г ө л н а р.

Г ө л н а р. Нәрсә, дәү абый?

Н у р е т д и н. Менә Сөнгать әфәндегә әйбәтләп чәй эчерегез әле...

С ө н г а т ь. Рәхмәт, чәй эчәсем килми.

Н у р е т д и н. Эчәрсең, эчәрсең, Алла боерса... Без шул арада сине конторга алу турында үзара сөйләшеп карарбыз...

Г ө л н а р чыга.

Бар, бар. Рәхәтләнеп, ашыкмыйча, теләгән кадәр эч!.. *(Сөнгатьне чыгара.)* Кая, балалар, якынрак килегез, Батырхан әфәнде, сез дә. Бу малай башыма бер уй салды, сезнеңчә, зурлап әйткәндә, план.

Д а в ы т. План? Ни турыда?

Н у р е т д и н. Теге Кави шәкерт, үз энесен думага үткәрер өчен, бөтен байларны, муллаларны үзенә караткан. Яшьләр аркылы, менә бу маңка социалистлар аркылы Батырхан әфәндене думага үткәреп булмасмы, дим. Ба-

рыбер алар үзләре сайлана да алмыйлар, сайланырга правалары да юк. Әллә, мин әйтәм, Батырхан әфәндене юньләп сөйләшкәч сайларга да риза булырлар. Үзләре сайланмагач, аларга барыбер түгелмени!

Д а в ы т. Батырхан әфәнде үзе ни әйтер бит, алар ягыннан сайланып баргач, думада, алар файдасын карарга туры килер. Сәяси платформагыз сыйдырамы соң?

Н у р е т д и н. Сыйдырыр-сыйдырыр, уйлап эшләгәндә сыйдырыр, Алла боерса. Шулай бит?.. Сыйдырыр бит, Алла боерса?

Б а т ы р х а н. Бик күп сыйдырмаса да, беразын сыйдырса кирәк.

Н у р е т д и н. Әйттем бит сыйдырыр дип. Безнең Батырхан әфәнде башкалар төсле тар күңелле түгел, аларны гына түгел, башкаларны да сыйдырыр, Алла боерса.

Д а в ы т. Ничек инде ул алай?

Б а т ы р х а н. Менә ничек: мин анда, ягъни думада, бөтен татар милләтенең файдасы өчен тырышачакмын. Милләт эчендә эшчеләр дә, ярлылар да бар. Шулай булгач, үз платформама аларның платформасын да сыйдырган булам.

Н у р е т д и н. Менә барып та чыкты, сугып та екты, депутат, Алла боерса, первый гильди депутат.

Д и л б ә р. Кави шәкертләргә үч итеп булса да, Батырхан әфәндене депутат итәргә кирәк.

Н у р е т д и н. Ишетәсезме, нәрсә ди бу? Депутат итәргә кирәк, ди... Ай, сез яшьләрне, хи-хи-хи... Депутат, депутат, Алла боерса, расходларын үзем күтәрәм.

Б а т ы р х а н. Нуретдин әфәнде, сезгә расходлар тотарга ризалык бирә алмыйм. Мин Дилбәр туташны аңлыйм...

Н у р е т д и н. Аңлаганга депутат дим дә бит, Алла боерса.

Д а в ы т. Күндереп булса, бу эштә Сөнгать, чынлап та, бик зур ярдәм итә алачак.

Н у р е т д и н. Ике сүз белән авызын томаламасам, исемем протестка керсен минем.

Б а т ы р х а н. Ул мондагы социалистларның иң катыларыннан исәпләнә.

Н у р е т д и н. Әнә корыч нинди каты да, шулай да эретәләр. Ул яктан күңелне киң тот, Батырхан әфәнде...

Д а в ы т. Башта осталык белән җәясен тартырга кирәк. Булмаслык булса, серне ачудан хикмәт чыкмас.

Н у р е т д и н. Алайса, бар, син җәясен тарт. Монда кергәч, мин угын атармын... Бар, улым, бар... Ә мин

шул арада өйлә намазымны укып алыйм, сез сөйләшә торыгыз!..

Д а в ы т бер якка, Н у р е т д и н икенче якка чыгалар.

VII. Б а т ы р х а н, Д и л б ә р.

Д и л б ә р. Батырхан әфәнде, мин сездән бер нәрсә сорамакчы булам.

Б а т ы р х а н. Рәхим итегез!

Д и л б ә р. Бу сәясәт, милләт планнарыгыз бер дә ялыктырмыйлармы сезне?

Б а т ы р х а н. Профессиям шул бит, сөекле Дилбәр туташ. Минем башымда кайчагында йөзәр, меңәр план берьюлы тора. Кайчакларда шул планнар, микроблар төсле бер-берсен ашап бетереп, бөтенләйгә юкка чыгалар. Менә шундый чакларда башым бөтенләй сафланып кала да, йөрәгем белән акылым берләшеп фәкать бер генә нәрсә турында уйлый башлыйлар. Менә хәзерге шикелле тормыштагы шул сәгатьләрем иң якты, бәхетле сәгатьләрем була.

Д и л б ә р. Мин никадәр уйласам да, башымда бөтен бер план оештыра алмыйм. Нигә ул алай икән?

Б а т ы р х а н. Сезнең акылыгыз белән йөрәгегез тату торалар булырга кирәк.

Д и л б ә р. Нигә, әллә акыл белән йөрәк талашалар дамы?

Б а т ы р х а н. Талашу гына түгел, сугышалар да. Акылы белән йөрәген берләштерә алган кеше генә үзенчә тормыш кора ала.

Д и л б ә р. Сезнең акыл белән йөрәгегез ничек соң?

Б а т ы р х а н. Минем акыл белән йөрәкнең боткалары пешми.

Д и л б ә р. Нидән алай дип уйлыйсыз?

Б а т ы р х а н. Чөнки йөрәгем эшләгән кичәге эшне күп вакытта бүгенге акылым яратмый. Акылым уйлаган кичәге планны бүгенге йөрәгем эшкә ашырмый. Сәяси тел белән әйткәндә, йөрәгем анархист, акылым монархист.

Д и л б ә р. Бигрәк явыз дошманнар икән. Хи-хи-хи... Сез хәзер генә, йөрәгем белән акылым берләшеп, фәкать бер генә нәрсә турында уйлый башлыйлар, дигән идегез... Анархист белән монархистны берләштерә торган ул «бер генә нәрсә» нәрсә соң?

Б а т ы р х а н. Анархист белән монархистны берләштергән ул «бер генә» — сез, туташ!..

Д и л б ә р. Мин, ха-ха-ха...

С ө н г а т ь белән Д а в ы т керәләр.

VIII. Б а т ы р х а н, Д и л б ә р, С ө н г а т ь, Д а в ы т һәм Н у р е т д и н.

Д а в ы т. Әткәй монда юкмыни?

Н у р е т д и н *(дога кыла-кыла чыгып)*. Монда, монда, Аллаһы әкбәр... Әйдә, Сөнгать әфәнде, әйдә. Кем, Сөнгать әфәнде, үзара киңәшеп, сезне хезмәткә алырга булдык. Башка кешегә егерме сум биргәндә, Давытның дусы булгач, кирәк чагында безнең сүзне дә тыңлар әле дип, сиңа айга кырык биш сум куярга булдык. Тукта, кара әле... *(Чалбар төбенә күзе төшә.)* Тукта әле, тукта, синең чалбарыңның төбе бөтенләй протестка кергән ләбаса. *(Әйләндереп бастырып, Сөнгатьнең чалбар төбен капшап карый.)* Иртәгә үк, Алла боерса, кибеткә төшеп, җаның теләгән кисәктән бер чалбарлык кистереп ал... Чынлап әйтәм, җаның теләгән кисәктән үлчәт тә ал. Үзебезнең үк тегүчегә биреп тә калдыр... Болай протестка кереп, бөлгән чалбар белән, бөлгән бояр төсле йөрергә ярамый. Менә озакламый думага сайлаулар булыр. Җәмәгать алдына чыгарга туры килер. Бәлки, депутат булып Питергә дә китәрсең.

С ө н г а т ь. Анысы булмас.

Н у р е т д и н. Нигә, әллә синең сайланырга праваң юкмы?

С ө н г а т ь. Правам да юк. Правам булса да, мондый карагруһ думага депутат булып бармас идем.

Д а в ы т. Вакыт узмаган, либераль дума сайларга да мөмкин бит әле.

Н у р е т д и н. Дума дигәннән, кем, Сөнгать әфәнде, теге Кави шәкертләр үзара оешып җыен протестка кергән кешеләрне сайларга дип торалар. Алыйк, мәсәлән, Низам мулланы... Ул тыңкыш танау анда барып нишли алыр икән! Урысча түгел, татарча да сөйләшә белми бит ул. Хәзер бит эш яшьләр кулында. Үзегез даулап чыгарган дума бит. Милләт өчен файдалы кешеләрне сайларга кирәк. Синең яшьләр арасында сүзең үтә диләр... Әйдәгез, берләшеп, шул тыңкыш танауларга үч итеп, Батырхан әфәндене сайлыйк.

С ө н г а т ь. Бик яхшы, сайлагыз.

Б а т ы р х а н. Әфәнделәр, мәсьәләне ачык куярга рөхсәт итегез.

Н у р е т д и н. Ачык булсын. Эшнең бөтен әңгәмә-кәлтемәләрен Сөнгать әфәндегә төшендерергә кирәк.

Б а т ы р х а н. Сөнгать әфәнде, эш менә нәрсәдә, Дәүләт Думасына булачак сайлауларда агай-эненең кайберләре минем кандидатурамны куймакчы булалар. Ләкин үзүзеңне мактау әллә ничегрәк, килешми.

Н у р е т д и н. Нишләп килешмәсен, мактамыйча авыл агаена бер аршын ситсы да сатып булмый, ә бу бит милләт өчен депутат!..

Б а т ы р х а н. Платформага килгәндә, һәрхәлдә, Низам муллага караганда, мин сезгә якынрак торам.

С ө н г а т ь. Зарарлылык ягыннанмы?

Б а т ы р х а н. Дөресен генә әйткәндә, мин сезне аңлый алмыйм, Сөнгать әфәнде. Сез, бер яктан, икътисади, рухани һәм сәяси яктан изелгән халыкны азатлыкка чыгарабыз дисез, икенче яктан, үзегезне пролетариат киртәсе дигән киртә белән киртәлисез. Төрек-татар революционеры алдында беренче планда төрек-татар халкы интересы торырга тиеш. Ә сез бөтен дөнья күсәген күтәрергә маташасыз.

Н у р е т д и н. Суга алмаган зур күтәрер, дигәннәр картлар.

Б а т ы р х а н. Бөтендөнья пролетариаты дигән әкиятне, хыялны ташларга вакыт. Кулдан килгәнне эшләргә кирәк.

С ө н г а т ь. Шул бөтендөнья пролетариаты эченә татар пролетариаты кермимени?

Д а в ы т. Керер өчен иң элек пролетариаты булырга кирәк, кая ул?

С ө н г а т ь. Һе, пролетариаты булмагач, бәлки, буржуазиясе дә юктыр?

Б а т ы р х а н. Дөрес, бездә чын пролетариат булмаган кебек, чын капиталистлар да юк. Бөтен татар байларының капиталын бергә җыйсаң, Американың бер урта капиталисты капиталы кадәр капитал җыя алмассың. Шулай булгач, капитал, пролетариат мәсьәләсе татар дөньясына читтән адашып кына кергән бер мәсьәлә булып кала.

С ө н г а т ь. Ике сыйныфның интересларын бутарга без җыенмыйбыз, аңа яшелле-сарылы төс тә бирергә теләмибез. Безнең билгеле юлыбыз, программабыз бар, җиңгәнгә кадәр шул юл белән барачакбыз.

Н у р е т д и н. Бу галдиш ни сөйли бу?

Д а в ы т. Сөнгать әфәнде, акылга утырырга вакыт, ул юлларыгыз, ул программаларыгыз мөхаль – утопия бит.

Реальный тормышта реальный булырга кирәк. Гасырлардан соң булу ихтималы булган хыял белән баш ватканчы, бу көнге хакыйкатькә, фактка буйсыну артыграктыр, дип уйлыйм.

Сөнгать. Без, Давыт әфәнде, бүген туып, иртәгә үлә торган фактларга да, агымнарга да иярмибез, буй да сынмыйбыз.

Батырхан. Бу тәгассыб — фанатизм, Сөнгать әфәнде, алмашыну көннәрендә фанатизм колы булу ярамый. Һәрбер дәвернең үзенең гадәтләре, кануннары була.

Сөнгать. Без гадәтләргә койрык буласыбыз килми. Без үзебез дәвергә тон бирергә җыенабыз.

Нуретдин. Ярый, егетләр, тун да бирегез, миңа дисә толып та бирегез! Әкиятләрегезне башка вакыт, иркен чакта сөйләшерсез. Эшкә керешик. Болай да бүген милләт юлында йөри торгач, кибеткә дә төшә алмадым. Йә Сөнгать әфәнде, күзгә-күз карашып сөйләшик, Батырхан әфәндене депутат итеп сайлыйбызмы, юкмы?

Сөнгать. Сез сайлагыз, без — юк.

Нуретдин. Ярый, сез, мөселманнардан аерылып, миссионер дьяк малае Калатушкинны сайламакчы буласызмыни?

Сөнгать. Минем үземнең сайларга да, сайланырга да правам юк.

Нуретдин. Соң, алай булгач, үзең сайланмагач, Батырхан әфәнде депутат буламы, башкасы буламы, сиңа барыбер түгелмени?

Сөнгать. Миңа дисәгез бөтенләй думасы ук булмасын, Нуретдин әфәнде.

Нуретдин. Нәрсә? Болай булгач, тел талдырып, авыз күтәреп сөйләп торасы да юк. Дума тикле думаны да протестка керткәч, мәгъзүр, жалунияңне егерме сумнан арттыра алмабыз...

Рөкыя керә.

IX. Әүвәлгеләр һәм Рөкыя.

Рөкыя. Әткәй, кичәге юан абзый килде.

Нуретдин. Хәзер, хәзер, кабинетка кертегез! Сөнгать әфәнде, хуш, сау булыгыз, бүлмәгездә тагын бер кат яхшылап уйлап карагыз... Иртәгә хезмәткә чыккач, тагын бер кат сөйләшеп карарбыз. Чалбарлыкларның инглийскиләре бар... Ярый, хушыгыз!

Сөнгать *(барысына башын иеп)*. Хушыгыз! *(Чыгып китә.)*

Нуретдин. Әйдә, улым, кеше көтмәсен. Кызым, ашаталармы, эчерәләрме, ни эшлиләр икән анда?

Чыгалар.

X. Батырхан, Дилбәр.

Дилбәр. Батырхан әфәнде, сез бая йөрәгегез белән акылыгызның берләшүе турында нәрсәдер әйтмәкче идегез.

Рөкыя керә. Бүлмә җыеп маташа.

XI. Батырхан, Дилбәр һәм Рөкыя.

Батырхан. Ә, әйе... акылым белән йөрәгем берләшеп, фәкать... *(Рөкыяне күреп.)* Ә... исәнмесез, Рөкыя туташ!

Рөкыя. Аллага шөкер.

Дилбәр. Апа җаным, Гөлнар өйдә микән? Әткәй әйтә, хәзерләнделәрме икән, ди. Бар, белеп кенә кил әле.

Рөкыя. Үзең барырга аякларыңның риматизлары кузгалдымы әллә?

Дилбәр. Апа җаным, кеше алдында тәрбиялерәк булырга кирәк.

Рөкыя. Кемнән үрнәк алып тәрбияле булыйм икән?

Дилбәр. Батырхан әфәнде, гафу итегез, мин хәзер килермен. Апа, бер генә минутка чыгыйк әле, синдә йомышым бар иде. Апа, әйдә, чыгыйк, дим!

Рөкыя. Чыгасың килсә чык... Комганның суы бар, хи-хи-хи!..

Дилбәр. Апа.

Рөкыя. Ау-у-у!

Дилбәр. Бу издевательство, бу свинство, позор, скандал, ха-ха-ха!.. *(Гасабиланып чыгып китә.)*

Рөкыя *(артыннан үртәп)*. Ә-тә-тә-тә-тә! Хи-хи-хи!..

Батырхан уңайсызланып йөреп тора.

XII. Батырхан, Рөкыя.

Рөкыя. Һәрвакыт шулай ул, чыгымчы бия төсле хәзер тәртә сындырырга керешә. Хи-хи-хи... Өйләнгәч, мыекларыгызны йолкып бетерер, хи-хи-хи... Аның тагын бер яман гадәте бар, әйтсәм, чәчләрегез үрә торыр!.. Нигә эндәшмисез, әллә телегезне ломбардка салдыгызмы?

Батырхан. Гафу итегез, туташ, сүзләрегезгә төшенә алмыйм.

Рөкыя. Ярый, ярый, ландринланмагыз... Дилбәргә өйләнергә уегыз бармы, дим?

Б а т ы р х а н. Булса соң?

Р ө к ы я. Ә миңа? Минем байлыгым Дилбәрнекеннән бер дә ким түгел бит.

Б а т ы р х а н. Сез нәрсә сөйлисез?

Р ө к ы я. Сез бит әле кыш көне генә миңа өйләнмәкче булган идегез.

Б а т ы р х а н. Кем әйтте аны?

Р ө к ы я. Мин әйтәм. *(Хатлар чыгарып.)* Менә сезнең кул белән язылган шушы хатлар әйтәләр. Гыйшык хатлары, хи-хи-хи!..

Б а т ы р х а н. Кая? *(Хатларга ташлана.)*

Р ө к ы я. Ай, юк, сабыр итегез. Мин аларны үлгәнче үземдә саклаячакмын. Сездән башка миңа берәү дә гыйшык хатлары язмады, дисәм, хәер, сукыр Галләм суфи бер хат язган иде тагы...

Б а т ы р х а н. Сез нәрсә әйтергә телисез?

Р ө к ы я. Гомерегезне заигъ кылып йөрмәгез бу тирәдә. Сез жулик булсагыз, бездә сездән дә остарак жуликлар бар.

Б а т ы р х а н. Нинди үчегез бар миндә, нигә сез мине хурлыйсыз?

Р ө к ы я. Сезне хурларга уйлаганым да юк. Ләкин мәсьәләнең бер башы миңа да кагылганга, мин сезгә коточкыч бер серне ачарга тиешмен.

Б а т ы р х а н. Нәрсә?! Нинди сер тагын?

Р ө к ы я. Мин әйтте дип әйтмәскә сүз бирәсезме?

Б а т ы р х а н. Сез кешеме, шәйтанмы? Бөтен акылымны чуалттыгыз. Нәрсә бар, сөйләгез!

Р ө к ы я. Мин әйтте дип әйтмәскә сүз бирәсезме?

Б а т ы р х а н. Сөйләгез, дим.

Р ө к ы я. Мин әйтте дип әйтмәскә сүз бирәсезме?

Б а т ы р х а н. Югалыгыз каршымнан, юкса мин сезне буып ташлармын!

Р ө к ы я. Мин әйтте дип әйтмәскә сүз бирәсезме?

Б а т ы р х а н. Бирегез хатларымны, бирегез хатларымны! *(Рөкыягә ташланып, буа башлый.)*

Р ө к ы я. Каравыл, каравыл, үтерәләр!..

XIII. Б а т ы р х а н, Р ө к ы я, Н у р е т д и н, Д а в ы т, Д и л б ә р.

Н у р е т д и н. Ни бар, бу нинди тавыш?.. Батырхан әфәнде, сез нишлисез?

Р ө к ы я. Аның миңа нәрсә әйткәнен белсәгез, чәчләрегез үрә торыр, хи-хи-хи...

Н у р е т д и н. Син монда нәрсә буталып йөрисең, марш

моннан!.. *(Кулыннан алып бәреп җибәрә, Рөкыя идәнгә яткан килеш кала.)*

Батырхан. Нуретдин әфәнде, Дилбәр туташ, гафу итегез... Мин борчылдым, артык монда кала алмыйм... Гафу итегез!.. *(Ашыгып чыгып китә.)*

Барысы. Аңа ни булган?

Рөкыя. Саташкан! Хи-хи-хи!..

Барысы кинәт, борылып, Рөкыягә акаеп карап калалар.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Бик бай йорт эче. Кунак бүлмәсе.

I. Сөнгать, Гөлнар.

Сөнгать. Иртәгә безнең полкны фронтка озаталар. Ә инде атна-ун көннән, бәлки, полкның сәләмә флагы гына исән калыр.

Гөлнар. Син бит сугышка каршы, нигә күрәләтә үлемгә барасың? Нигә берәр оборон эшенә кереп калмыйсың?

Сөнгать. Оборон эшендә кулга мылтык та, бомба да бирмиләр, Гөлнар.

Гөлнар. Нигә кирәк мылтык, бомба?

Сөнгать. Кирәк, хәзер вакыты шундый.

Гөлнар. Әнә дәү абый, Давытны сугышка җибәрмәс өчен, сукно фабригы алырга йөри. Сиңа да, бәлки, шунда берәр урын табылыр иде.

Сөнгать. Юк, безгә хәзер кулга мылтык, бомба алырга кирәк. Мондый вакытлар йөз елларга бер генә туры килә. Хәзерге вакытта көч тә, корал да эшче-крестьян кулында. Немец, француз, итальян, төрек эшче-крестьяннары ни өчен, кем өчен үлемгә хөкем ителүләрен аңламыйлар дип беләсезме әллә?

Гөлнар. Алар аңлаудан ни файда, безнекеләр аңламагач.

Сөнгать. Безнекеләр дә аңлыйлар. Менә фронтка чыгачак безнең полкта 4000 кешедән 3900 е сугышны теләми.

Гөлнар. Теләмәү белән эш бетәмени?! Менә син дә бит сугышны теләми идең, җибәргәч — барасың.

Сөнгать. Безгә сугышка барырга кирәк. Әлбәттә, кирәк. Сугышны бетерер өчен, сугышка барырга кирәк.

Менә шулай, Гөлнар, якты көннәрне күрергә күп калмады. Гөлнар, менә шушы хатны Салих Ризвановка, зинһар, тапшыра күр, ул атна-ун көннән кайтыр. Хатны синнән килеп үзе алыр. Ләкин һичбер кем белмәсен иде.

Гөлнар. Тыныч бул, Сөнгать. *(Хатны алып күкрәгенә яшерә.)* Сез мине тәмам почта ящигы иттегез инде.

Сөнгать. Юк, син безнең өчен почта ящигы гына түгел, янмый торган тимер сандык.

Гөлнар. Сандыкмы, ящикмы, келәтме — анысы барыбер инде.

Сөнгать. Гөлнар, тагын бер дуслык үтенече бар.

Рөкыя керә.

II. Сөнгать, Гөлнар һәм Рөкыя.

Рөкыя. Нинди әфисәрме дисәм, өтек солдат икән, хи-хи-хи... Исәнмесез, Сөнгать әфәнде.

Сөнгать. Исәнмесез!

Рөкыя. Кара, кара, чын солдат төсле үк булгансың ич.

Сөнгать. Солдат булгач, муллага охшамам бит.

Рөкыя. Болай булгач, ай-вай дип җырлый да, сызгыра да белә торгансыңдыр?

Сөнгать. Һу! Ничек кенә әле... Мин сызгырганда, тәрәзә пыялалары дер-дер килә.

Рөкыя. Һәр көн таң белән безнең каршыдан шау-шу килеп, җырлашып, сызгырып әллә сез үтәсезме?

Сөнгать. Нигә, әллә вакытсыз йокыгыздан уяталармы?

Рөкыя. Тупас солдат җырлары безнең абразовный ландрин тартмаларының кәефләренә бер дә килешми. Таң белән солдатлар җырлашып үткән саен, нәкәс сыерлар төсле мөгри башлыйлар.

Сөнгать. Йокылары бүленә торгандыр шул.

Рөкыя. Кара әле, Сөнгать әфәнде, сугыш бетә, диләр, дөресме?

Сөнгать. Ишеткәнем юк.

Рөкыя. Сугыш бетә, дип ах-вах килүчеләр бар. Хи-хи-хи...

Гөлнар. Сугыш беткәнгә кем кайгырсын икән.

Рөкыя. Бар шул, бар, кайгыручылар бар.

Сөнгать. Фронтка баргач күрербез тагын.

Рөкыя. Син сугышка киткәнче, сугыш та бетәр. Бер елдан бирле китәм-китәм дисең, ә үзең һаман әле монда.

Сөнгать. Бу юлы инде тәгаен китәм. Иртәгә поход чыгабыз.

Рөкыя. Сугышкамы?

Сөнгать. Әйе, фронтка.

Рөкыя. Барырга булдыңмыни инде?

Сөнгать. Кушкач ни хәл итәсең.

Рөкыя. Тукта әле, тукта! Уен-көлке бер якта торсын, чынлап ук шулай сугышка китәсеңмени?

Сөнгать. Бик чынлап. Поход капчыкларыбыз да бәйләнгән.

Рөкыя. Кара әле, нишләп берәр оборонага кермисең, бөтен дөнья оборонага керә бит.

Сөнгать. Барыбыз да оборонага кергәч, кем сугышыр соң?

Рөкыя. Дурак гыйбдиләр беткәнмени!

Сөнгать. Менә мин дә шул гыйбдиләр белән бергә барырга булдым. Акыллылар монда калсын.

Рөкыя. Мин синең урыныңда булсам бармас идем.

Сөнгать. Нигә?

Рөкыя. Барлык адәм рәтле кешеләрне сугышка җибәреп юри үтертеп бетерәләр. Җыен усал, комсыз, оборона булып, монда кала.

Сөнгать. Сез мине шулай адәм рәтлеләр арасына кертәсезмени?

Рөкыя. Нигә кертмәскә... Бездә торган чакта, теге безнең ландрин тартмаларының каннарына тоз сипкәндә рәхәтләнә идем, ичмасам. Сез булмагач, бөтенләй рәхәтләнеп калырлар инде.

Сөнгать. Мин үләргә дип китмим... Ярый, Гөлнар, сау булыгыз. Хушыгыз, Рөкыя туташ!.. Ландрин тартмалары, дисезме әле?.. Хи-хи-хи... Насыйп булса, ул тартмалар тиздән бушарлар. Ярый, хушыгыз!..

Гөлнар. Сөнгать, хат яз. Мөмкин кадәр ешрак яз. Мөмкин кадәр ешрак!.. *(Елап борыла.)*

Сөнгать. Ярый, ярый, Гөлнар... Син нишлисең?! Менә!.. *(Аптырап, уңайсызланып кала.)* Ярый, хуш, сау булыгыз!..

Гөлнар аның артыннан елап кала. Рөкыя аның янына килә.

III. Гөлнар, Рөкыя.

Рөкыя. Ярый, җитәр, Гөлнар, алай сабырсыз булма. Сугышка киткән һәрбер кеше үләмени...

Гөлнар. Мондый бала җанлы, саф йөрәклеләр үләләр шул!..

Рөкыя. Бер дә үлмәс, күр дә тор, әфисәр булып кайтыр. Укыган бит ул. Төс итеп тотарлык берәр нәрсә бирдеңме соң үзенә?

Гөлнар. Авыр, Рөкыя апа җаным, авыр! *(Елый.)*

Рөкыя. Әй, шыңшыма әле, дөньяда җиңел нәрсә бармыни. Безнең ландрин тартмалары гына бит үзләренә үзләре сокланып, чыш-пыш йөриләр.

Гөлнар. Өч ел буенча күңелемдә асраган сүземне әйтә алмый калдым.

Рөкыя. Әйтмәвең, бәлки, хәерлегәдер әле… пошынма, җитәр.

IV. Гөлнар, Рөкыя һәм Дилбәр.

Дилбәр *(ашыгып пох-пох итеп кереп)*. Әткәй өйдәме?

Рөкыя *(ачулы)*. Юк!..

Гөлнар елавын яшерә.

Дилбәр. Кайда?

Рөкыя. Каенлыкта каймак ашый.

Дилбәр. Дорфа, тупас, хәшәрәт! *(Бәргәләнеп икенче якка чыга.)*

Рөкыя. Әтә-тә-тә!.. Кыланышларына карап мигрин булырсың, хи-хи-хи!.. Әллә нинди зур эш куптарган төсле тырт-пырт, шырт-фырт килеп, кызган майга салган суган төсле чаш-чош киләләр.

Дилбәр керә.

Дилбәр. Гөлнар, әткәй күптән чыктымы?

Гөлнар. Чыкканын күрмәдем.

Рөкыя. Нигә эт күргән мәче төсле бәбәкләреңне акайттың?! Әллә берәр әфисәреңне сугышка куалармы?

Дилбәр. Не твоё дело.

Рөкыя. Муну, муну… муну!..

Дилбәр. Карт дура!

Рөкыя. Үтү-тү-тү!..

Дилбәр. Зәһәр елан, крокодил!

Рөкыя. Әтә-тә-тә-тә!..

Дилбәр. Тфү!

Рөкыя. Тимәде, әлләли, бәлләли, тимәде!

Дилбәр, утырып, аякларын бәрә-бәрә елый башлый.

Гөлнар. Нуретдин абый нигә кирәк иде соң?

Дилбәр *(елап, сулышына кабып)*. Чернояровлар-

га... Заграничный ефәк килгән... Илаһи, халык, Илаһи, халык!.. Бер генә платьялык булса да алып каласы иде... *(Ялынган йомшак тавыш белән Рөкыягә килеп.)* Апа җаным, зинһар, илле сум биреп тор әле. Әткәй кайткач та түләрмен...

Гөлнар тирән сулап хәсрәт белән йончыгып чыга.

V. Рөкыя, Дилбәр.

Рөкыя. Алмасаң ни була?

Дилбәр. Заграничный ефәк бит. Тагын кайчан булыр... Әй Илаһым, алып бетерәләр, бетерәләр... Сугышы да бетмәде, чәнчелгере!.. Йә, бир инде, апа бәгырем, билләһи, әткәй кайткач та түләрмен.

Рөкыя. Түләрсеңме?

Дилбәр. Билләһи, түләрмен.

Рөкыя. Иманым кяфер, үзем мордар булыйм, түләрмен, диген.

Дилбәр. Иманым кяфер, үзем мордар булыйм, түләрмен.

Рөкыя. Унбиш ел укып син шулай әле, илле ел укысаң, нәрсәгә ярар идең икән?

Дилбәр. Апа җаным, мин синнән үтенәм, үзеңне дә тыңлармын.

Рөкыя. Дустым, бәгырем, диген.

Дилбәр. Дустым, бәгырем.

Рөкыя. Синнән дә якын дустым, ахирәтем юк, диген.

Дилбәр. Синнән дә якын дустым, ахирәтем юк. Бир инде.

Рөкыя. Моннан соң аяк астында туфрак булырмын, диген.

Дилбәр. И, бигрәк инде син тагын.

Рөкыя. Мин киясе ефәк түгел, ихтыярың.

Дилбәр. Азаплама, бир инде.

Рөкыя. Моннан соң аяк астында туфрак булырмын, диген.

Дилбәр. Йә, йә, моннан соң аяк астында туфрак булырмын.

Рөкыя. Кочаклап үп.

Дилбәр. Йә, күңелең булсын... *(Үбә.)* Бир!

Рөкыя. Тезлән.

Дилбәр *(тырылдап китеп, гасабиланып)*. Карт тә... карт тә... карт тә-тәтә...

Рөкыя. Нәрсә?

Дилбәр. Карт тәтәй, карт апай, карт, карт, апа бәгырем, җаным, бир инде…

Рөкыя. Тезлән.

Дилбәр *(тезләнә)*. Йә, бир.

Рөкыя. Акчам юк!.. Хи-хи-хи!..

Дилбәр *(сикереп торып, бәргәләнеп)*. Нахалка, идиотка, урод, тфү!

Рөкыя. Тфү! Ландрин!..

Дилбәр. Хулиганка, шпана, дура, тфү!..

Рөкыя. Тфү!.. Сыбызгы!..

Дилбәр. Тфү!..

Рөкыя. Тфү!..

Дилбәр төкеренә-төкеренә чыкканда, Нуретдин белән Давыт керәләр.

VI. Рөкыя, Дилбәр, Нуретдин һәм Давыт.

Нуретдин. Чү, чү, кызым, бу ни эшең? *(Йөзен сөртә.)*

Дилбәр. Гафу ит, әткәй, сиңа түгел, менә бу идиоткага! Тфү!..

Рөкыя. Тфү!..

Нуретдин. Балалар, бу ни эшегез?

Дилбәр. Бетте, бетте. Әткәй бәгырем, илле сум акча бир, бик кирәк, бик, бик!

Нуретдин. Ярый, карарбыз.

Дилбәр. Юк, юк, карап торырга вакыт юк, әткәй, хәзер кирәк, хәзер бир! Югыйсә ычкына, ычкына!

Нуретдин. Нәрсә ычкына?

Рөкыя. Кияве! Хи-хи-хи…

Нуретдин. Сиңа монда ни калган, марш моннан, көчек!

Рөкыя *(көйләп)*. Көчекнең атасы эт булыр дигән имди.

Нуретдин. Марш, югал күземнән, чатан дуңгыз!

Рөкыя. Мишәр әйтмешли, матур-матур чучкаларың белән кал. Хро-хро-хро! *(Китә башлый.)*

Нуретдин. Менә шашкан, аңгыра тавык!

Рөкыя. Тол әтәч, кикрику-ку-ку-ку!

Нуретдин. Вон моннан, кәкре кяфер! *(Һөҗүм итә.)*

Рөкыя чыга.

Дилбәр. Әткәй бәгырем, шул зәһәргә карап каныңны бозма, илле генә сум.

Н у р е т д и н. Әй, буталмасана... Нәрсәгә ул хәтле?

Д и л б ә р. Бер җирдә бик затлы заграничный ефәк бар. Бәясе дә бик арзан. Хәзер бармасам — ычкына...

Н у р е т д и н *(акча бирә-бирә)*. Менә шашкан, гурбон шәйтан, мә!

Д и л б ә р. Рәхмәт, әткәй бәгырем!.. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Н у р е т д и н. Башка бәлагә туган кәкре имгәк. Башаягы белән протестка кергере. Юньсез, бөтен зиһенне таратты... Кая, шутны бир әле... Күрсәтермен мин сиңа тол әтәчеңне, миең черегән нәрсә, тавык баш!

Давыт счёт бирә.

Н у р е т д и н. Җыенысы күпме, дисең?.. Һе, кәкре галдиш!

Д а в ы т. Дүрт йөз утыз мең.

Н у р е т д и н *(счётка сала)*. Безнең өлешкә күпмесе төшә?

Д а в ы т. Йөз дә кырык өч мең өч йөз сум.

Н у р е т д и н. Купчи кәгазьләре ничек була инде? Һе, кәкре галдиш.

Д а в ы т. Аларда да, бездә дә.

Н у р е т д и н. Әгәр сугыш туктап китсә, ул фабрикны кая куярбыз?

Д а в ы т. Сугыш яңа кыза гына әле, әткәй. Уһ-уһу... Бу сугыш туктаганчы, сумабыз өч өлеш булып кайтачак.

Н у р е т д и н. Кеше белән уртак эш итүне яратмыйм, аннан соң сугыш туктала калса харап бит.

Д а в ы т. Сугыш, Алла боерса, тиз тукталмый әле.

Н у р е т д и н. Шулаен шулай да, улым, әллә, мин әйтәм, теге урман подрәтен генә алыйкмы? Унбиш-егерме мең яна икән, чорт с ним, янсын. Җан тыныч булыр. Оборонда калырлык булгач, сиңа барыбер түгелмени?

Д а в ы т. Юк шул, әткәй, барыбер түгел. Урман подрәтендә күрәләтә торып егерме мең сумны суга ташларга туры килә. Ә бу фабрик эшендә, Алла биреп сугыш яңадан ике-өч елга тартылса, ике-өч йөз мең саф файдасы күренеп тора. Мондый чаклар йөз елларга бер генә килә. Файдаланып калырга кирәк.

Н у р е т д и н. Чыкылдаган йөз кырык өч меңне чыгарып салырга кирәк бит.

Д а в ы т. Әгәр дә безнең бәхеткә сугыш тагын бер өч елга сузылса, файдасына үзеннән зур фабрик корырга мөмкин булыр.

Нуретдин. Амин! Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре патшаның күңеленә ачу салсын инде!..

Батырхан офицер киемендә, Голам әкә үзбәк киемендә керәләр.

VII. Нуретдин, Давыт, Батырхан һәм Голам әкә.

Батырхан. Хәерле көн, әфәнделәр!
Нуретдин. Сөбханалла, машалла!.. Батырхан әфәнде!.. Күктәнме сез, җирдәнме сез?..

Күрешәләр.

Давыт. Урамда очратсам танымас идем мин сезне!..
Батырхан. Нигә?
Давыт. Сез гаскәри түгел идегез бит.
Батырхан. Бөтен Европаны чолгаган пожар вакытында һәрбер намуслы, ватанын сөюче граждан гаскәри булырга тиеш. Европаны бандаларның тимер йодрыкларыннан коткарырга кирәк! Европаның үзәгендә яшәүче сугыш аждаһасы җиһангир Герман бетәргә тиеш. Шул чагында гына Европада һәм бөтен дөньяда мәңгелек солых туачак...
Давыт. Бу кем?
Батырхан. Бу, – Голам әкә, лашман.
Давыт. Әһә...
Нуретдин. Рәхим итегез, кем, Батырхан әфәнде. *(Урын күрсәтә.)* Төрекләр дә Герман яклы бит, Герман җиңелсә, төрекләр дә бетәр бит.
Батырхан. Бөтен дөньядагы тынычлыкны саклау юлында Төркияне генә түгел, ярты дөньяны корбан итәргә мөмкин. Ләкин, асылда, Төркия бетмәс, Төркиянең Европада адашып калган өч-дүрт шәһәре китә икән, Европа тынычлыгы алдында ул – бик кечкенә мәсьәлә.
Давыт. Сез элек болай сөйләми идегез, Батырхан әфәнде!
Батырхан. Үткәнне искә төшерүченең күзе чыксын, диләрме әле... Бәндә сагышлый, Алла багышлый, дигәннәр бабайлар. Тарих тудырган бөек вакыйгалар алдында һәрбер намуслы граждан тез чүгәргә тиеш. Сугышларның сугышы булган бу бөек сугыш киләчәктә булу ихтималы булган бөтен сугышларның соңгысы булачак. Вак-төяк хөкүмәтләр бетә икән бетсен! Вак-төяк милли теләкләр корбан була икән булсын! Утыз-кырык миллион кеше үлә икән үлсен! Алтмыш-җитмеш миллиард һавага оча

икән очсын! Кызганыч түгел. Ләкин бу сугыштан соң бөтен дөньядагы изелгән милләтләргә якты көн, тигезлек, рәхәт тормыш туачак. Без шуның өчен тырышабыз, шуның өчен кан коябыз, шуның өчен үләбез... Үлгәндә дә яшәсен Европаның тынычлыгы, яшәсен мәңгелек солых дип кычкырып үләбез!..

Нуретдин. Алай... Батырхан әфәнде, бу сугыш тагын озакка сузылырмы икән?

Батырхан. Германиянең көле күккә очкан көнне мәңгелек солых кәгазенә имза ителер.

Голам әкә. Һәм шуттә көнне Айя-Суфия мәнарәсигә хач һәм куелырмы, ди, кү?

Батырхан. Һайт, Голам әкә, шәшмәң, җум булың!

Нуретдин. Нәрсә ди, нәрсә ди?.. Айя-Суфия, нәрсә ди?

Батырхан. Һәм шул ук көнне Айя-Суфия манарасына тәре дә кадалырмы, ди, ахмак.

Нуретдин. Юк, кем, Батырхан әфәнде, туры сөйли ул. Айя-Суфия түбәсенә тәре кадатырга без мөселманнар риза түгел.

Голам әкә. Һа, машалла, машалла, һәм чал нугай әкә дә җүдә түзек гәп буйды кү.

Батырхан. Шәшмәң!.. Лашман!

Нуретдин. Дөресен сөйли ул, бәрәкаллаһ...

Батырхан. Бөтен дөнья тынычлыгы алдында, бөтен милләтләр азатлыгы каршында ай-тәре мәсьәләләре — кечкенә мәсьәләләр. Айя-Суфия манарасына тәре куелу белән, төрек милләте нәрсәсен җуя? Төркиянең башына туган бөтен бәла дә әнә шул Айя-Суфия түбәсендәге айдан булды.

Нуретдин. Юк инде, ни булса да Айя-Суфия түбәсендә ай калсын иде инде. Тәре куелуына без риза түгел.

Давыт. Батырхан әфәнде, көтелмәгәндә каян болай килеп чыктыгыз?

Батырхан. Төркестаннан. Монда үтешли генә кердем.

Давыт. Кая үтәсез?

Батырхан. Фронтка.

Давыт. Фронтка?!

Батырхан. Әйе, лашманнар алып барам.

Давыт *(Голам әкәне күрсәтеп)*. Болар анда ни эшләрләр икән?!

Батырхан. Милләтләр азатлыгы өчен булган кө-

рәштә Төркестан кардәшләребез дә үзләренең ватанпәрәстлекләрен күрсәтсеннәр, дибез.

Д а в ы т. Хәзерге сугыш эшенә яраклылармы соң?

Б а т ы р х а н. Урман кисәрләр, юллар ясарлар, окоплар казырлар, тиз арада лашманнар дивизиясе төзеләчәк. Эшкә ярасалар, корпус төзергә дә уйлыйбыз әле.

Д а в ы т. Өйрәнмәгән һавага, күнекмәгән эшкә чыдый алырлармы икән, кырылып бетмәсләрме?

Б а т ы р х а н. Кырылсыннар, бетсеннәр, никадәр күп үлсәләр, шулкадәр ватан һәм Европа каршында төрек-татар милләтенең абруе күтәрелүгә сәбәп булыр. Нигә аңа эчең поша, Давыт әфәнде?

Д а в ы т. Юк, болай әйтәм, фабриктагы кара эшкә ничегрәк булырлар икән, дим. Барыбер ватанга хезмәт бит.

Д и л б ә р керә, кулында төргәк.

VIII. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Д и л б ә р.

Д и л б ә р. Өлгердем, әткәй, өлгердем!.. Ах, пардон!

Б а т ы р х а н. Исәнмесез, Дилбәр туташ!

Д и л б ә р *(катып карап тора)*. Батырхан әфәнде, бу сез? Әфисәр?!

Б а т ы р х а н. Шулай, Дилбәр туташ, шулай!

Д и л б ә р. Алай...

Б а т ы р х а н. Шулай... Гаскәри мундир кию һәрбер намуслы гражданга фарыз хәзер.

Д и л б ә р. Гаскәри форма сезгә нинди килешә...

Б а т ы р х а н. Рәхмәт.

Д и л б ә р. Әллә сугышта булдыгызмы?

Б а т ы р х а н. Юк, барабыз гына.

Д и л б ә р. Сугышка?!

Б а т ы р х а н. Әйе. Эшелоным вокзалда көтеп тора. Сезгә үземнең сугышка керер алдыннан булган сәламемне ирештерергә генә кердем.

Д и л б ә р. Сез пехоттамы, кавалериядәме?

Б а т ы р х а н. Берсендә дә түгел!

Нуретдин, Давыт, Голам әкә бергә сөйләшәләр.

Д и л б ә р. Артиллериядә?

Б а т ы р х а н. Түгел.

Д и л б ә р. Моряк, пилот дисәм, формагыз охшамый, кем соң сез?

Б а т ы р х а н. Лашман полыгының меңбашы.

Д и л б ә р. Лашман?

Б а т ы р х а н. Әйе.

Д и л б ә р. Кем, нәрсә ул?

Б а т ы р х а н *(Голам әкәне күрсәтеп)*. Әнә. Ярый, хушыгыз, фатихада булыгыз, лашманнарым минем көтә торганнардыр. *(Дилбәрнең кулын алып.)* Хушыгыз, Дилбәр туташ, үлсәм, Коръән укыгыз, исән булсам онытмагыз! Кайда гына булсам да, еракта, окопларда, туплар төтене арасында сезне уйлаучы, сезне сагынучы, сезне сөюче бер җан барлыгын исегездә тотыгыз!.. Хушыгыз, әфәнделәр!

Н у р е т д и н. Чәй дә эчә алмадыкмы, Батырхан әфәнде?

Б а т ы р х а н. Эшелоным көтә, гаскәри эштә җыйнак булырга туры килә. Голам әкә, кәлләмне бир!

Н у р е т д и н. Кая, Батырхан әфәнде, бер дога кылыйк.

Утырып дога кылалар.

Батырхан әфәнде, авырсынмыйча гына шуны алыгыз, берәр расходыгызга ярар шунда. *(Акча бирә.)*

Б а т ы р х а н. Рәхмәт, Нуретдин әфәнде, мин моны мөселман лазареты фондына бирермен! Хушыгыз! *(Голам әкә белән чыгалар.)*

Г о л а м  ә к ә. Хәй, хәй!..

Н у р е т д и н *(аптырап катып калып)*. Хәерле юл, хәерле юл!

Д и л б ә р *(һушыннан язган сымак)*. Ах!.. Китте!..

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Мөселман комитеты канцеляриясе. Диварда лозунглар. Каршыда уртасы яшел, өске чите ак, асты кызыл байракта «Яшәсен хөррият, мөсавәт[1], гадәләт!» дип язылган.

I. Н и я з һәм Н у р е т д и н.

Н у р е т д и н *(паузадан соң, каушап кереп)*. Кәмитетебезнең президиумы әгъзалары җыелып җиттеләрме?

Н и я з. Нишләптер бүген акрын җыелалар.

Н у р е т д и н. Батырхан әфәнде мондамы?

Н и я з. Килгәне юк әле.

Н у р е т д и н. Әгъзалар кая соң?

Н и я з. Әнә анда.

---

[1] М ө с а в ә т – тигезлек.

Х а т ы н керә, Н у р е т д и н чыга.

II. Н и я з, х а т ы н.

Х а т ы н. Кара әле, егет, миңа кәмитит кирәк иде.

Н и я з. Кайсы комитет?

Х а т ы н. Мөселман кәмитите.

Н и я з. Хуш, ни йомыш?

Х а т ы н. Әллә үзең буласыңмы?

Н и я з. Йомышыңны әйт!

Х а т ы н. Ыслабуд булганнан бирле, иремнән көн күрмим, аер дисәм, хәзер ыслабуды, ди, аермый. Расходка акча сорый башласам, ыслабуд тамагыңны туйдырсын дип ора, суга. Ярдәм сорап килүем иде. Йә ул мине аерып җибәрсен, аермый икән, торырга акча бирсен...

Ф ә т т а х керә.

Н и я з. Әнә шул бүлмәгә керегез... Казый аерып ташлар.

Х а т ы н. Ничек аерып ташлар?

Н и я з. Барыгыз, бар, әнә шунда керегез.

Х а т ы н чыга.

III. Н и я з, Ф ә т т а х.

Ф ә т т а х. Әссәламегаләйкем, исәнме-саумы?

Н и я з. Ни йомыш?

Ф ә т т а х. Чукрак Хәйдәр малае минем йортта фатирда тора, ыслабуд булган көннән бирле, фатир хакы түләми.

Н и я з. Нишләп түләми?

Ф ә т т а х. Шәйтан белсен аны... Хәзер ыслабуд, ди, патша да, закон да, чорт та юк, ди, күп шаулашсаң, ди, миңа әйтә, үз фатирыңа кереп утырырмын, ди.

Н и я з. Большевиктыр ул.

Ф ә т т а х. Шулайдыр, Саручида сату итә.

Н и я з. Большевик булса, без бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Социалистлар комитетына барыгыз. Большевикларны алар карый.

Ф ә т т а х. Миңа монда килергә куштылар.

Н и я з. Монда бездә хак мөселман агай-эне эшләре генә карала. Большевиклар эше бездә каралмый.

Ф ә т т а х. Аның большевикмы, түгелме икәнлеген каян беләсең, маңгаенда язылмаган бит.

Н и я з. Өстендә күн тужурка, билендә наган, күкрәгендә кызыл тасма булса, большевик булыр.

Ф ә т т а х. Андый нәрсәләре күренми.

Нияз. Алланы сүгәме?

Фәттах. Нишләп Алланы сүксен, мөселман ул. Үзе, юньсез булса да, җомгадан калмый.

Нияз. Квартал ясагын түлиме?

Фәттах. Безнең кварталның казначие мин, анысын алабыз. Менә шуңа булашып фатир акчасын түләми.

Нияз. Алайса, безнең тәбәга[1] икән. Әнә шул бүлмәгә казыйга кер. Ул карар.

Батырхан керә.

IV. Нияз, Фәттах һәм Батырхан.

Батырхан. Җыелдыларм ы?

Нияз. Акрын җыелалар.

Батырхан. Бу абзыйга ни кирәк?

Нияз. Абзый, барыгыз, казыйга керегез.

Фәттах. Суд юк, закон юк. Алла белсен, кем хуҗа? Ясак җыя беләләр. *(Чыга.)*

Батырхан. Нияз әфәнде, ишеттегезме, шомлы хәбәр.

Нияз. Нәрсә тагын?

Батырхан. Төркестанда хәлләр начар, ди.

Нияз. Булмас ла?!

Батырхан. Начар, ди, начар, ди, яшерен фонд спискаларын яндырыгыз. 25 сентябрь утырышының протоколларын яшерегез. Акча алынганлыкка бирелгән квитанцияләрнең корешокларын юкка чыгарыгыз. Тегеләр ягыннан килүчеләр булмадымы?

Нияз. Кемнәрдән?

Батырхан. Хәрби революционный комитеттан.

Нияз. Юк.

Батырхан. Бу буталыш ике-өч айга тартылыр төсле күренә. Авылларга бүгеннән калмыйча агитаторлар җибәрергә кирәк. Бөтен таяныч хәзер авылда. Дин ягын каерсыннар.

Асрау керә.

Нишләп газит чыкмаган, белмәдеңме?

Нияз. Наборщиклар җыймаганнар. Бүген эшкә дә чыкмаганнар.

V. Батырхан, Нияз һәм асрау.

Батырхан. Сволочьлар! Эт симерсә, иясен тешли, ди шул. Әнә Советларына барып карасыннар. Бүгеннән

---

[1] Тәбәга — кул астындагы халык.

үк базарда мал калмаган, яхшылыкны белмәсәләр йөрерләр шунда аяк туздырып, совет суганын суырып! Килүчеләр бармы?.. *(Борылып чыга башлый.)*

Нияз. Беркадәр генә...

Асрау. Абзый, прашениеләр карый торган кәмит шул буламы?

Батырхан. Әнә бу кешегә күрсәт. *(Нуретдин кергән бүлмәгә керә.)*

Нияз. Ни йомыш?

Асрау *(кәгазен биреп).* Мин элек Сабирҗан абыйларда торган идем, ул оборонга Иж заводына киткәч, Хәдичә апа, безгә асрау кирәкми, дигәч, Мисбах хаҗига кердем.

Нияз. Йомышыңны әйт, нәрсә кирәк?

Асрау. Йомышым шул инде. Кергән көннән башлап хаҗи абый миңа кул сала башлады.

Нияз. Йә?

Асрау. Шул, кул сала башлады: ул сала, мин алам, ул сала, мин алам... *(Кара савыт, китапларның тузаннарын сөртә.)*

Нияз. Ни кирәк соң сиңа?

Асрау. Кул сала торгач, беркөнне, Нәгыймә абыстай мөслимәләр җәмгыятенә дип киткәч, ишекләрне бикләп алды да, хәзер ыслабуд, теләсәм нишләтә алам мин сине дип... *(Елый.)* Кайткач, Нәгыймә абыстайга әйткән идем, иртәгесен куып чыгардылар.

Нияз. Беттеме?

Асрау. Юк әле... Күмәчче Мәңгәр Сәлахиендә, курсиларга килгән безнең авылның укытучысы Мәчтүрә апа фатирда тора...

Нияз. Ярый, җитәр, аңлашылды.

Асрау. Юк әле, абый, аңлашылып җитмәде әле. Шул Мәчтүрә апа әйтә, бу эшне болай калдырма, ди, хәзер хөррият, ди, менә язып өйрәтеп җибәрде.

Нияз. Ярый, беттеме?

Асрау. Хәзер бетә... Мәчтүрә апа әйтә, моның өчен аның арт сабагын тыңлатырлар, ди. Абый җаным, зинһар өчен, шул карт мордарның арт сабагын тыңлатыгыз әле...

Нияз. Аның арт сабагын тыңлатудан сиңа ни файда?

Асрау. Адәм рисвае булсын. *(Өстәл тузанын сөртә башлый.)*

Нияз. Бу кәгазең белән мөслимәләр җәмгыятенә бардыңмы?

Асрау. Юк. Мәчтүрә апа барырга кушмады. Ник

дисәң, Нәгыймә абыстай анда перчидәтел булып утыра икән. Карга карганың күзен чукымас, ди. Анда бернәрсә дә эшләмиләр, җыелышып, күлмәк модалары тикшереп, гайбәт кенә сөйләп утыралар, ди.

Нияз. Син тагы тотындың. Сөйләп бетерәсеңме инде?

Асрау. Бетте.

Нияз. Шаһитларың бармы?

Асрау. Нәгыймә апа белән Мәчтүрә апа беләләр.

Нияз. Ничек беләләр?

Асрау. Мин аларга бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем.

Нияз. Ул гына җитми... Кәгазең монда калыр, ә үзең әнә шул бүлмәгә кер.

Асрау. Әем, кермим мин анда. Мин азган-тузган кыз бала түгел.

Нияз. Эшеңне казый карар.

Асрау. Карамый торсын әле, карагыч кушарлар. Әйем, кирәкми!..

Нияз. Ихтыярың.

Фәтхи керә.

VI. Нияз, асрау һәм Фәтхи.

Асрау. Беләм мин сезне, мин алдалана торган кыз бала түгел. Кара син аны, песи-песи сөйләшкән булып, бүлмәгә кертеп, минем үк арт сабакны тыңлатмакчысыңдыр. Тыңлатмый тор әле... Тыңлаткыч кушарлар. Мәчтүрә апаны алып килсәм, үзеңнең арт сабагыңны тыңлатыр.

Нияз. Нәрсә саташасың, төш күрәсеңме әллә син?..

Асрау. Төш күрергә аяк өстемдә басып торам ла.

Фәтхи. Нәрсә, туташ, әллә бу катыргы муен абижайт итәме?

Нияз. Сезгә нәрсә кирәк?

Асрау. Прашиния белән килгән идем, бүлмәгә кер, ди, җирбит.

Фәтхи. Йөрмә монда, кызый, йөрмә юкка. Байлар кайгысын кайгыртучы кәмитит бит бу, син безнең кәмиткә бар.

Асрау. Ул кайда тагын?

Фәтхи. Мөселман социалистлар кәмитите дисәң, һәркем әйтер.

Асрау. Мәчтүрә апа белә торгандыр. Ничек дидең әле?

Фәтхи. Мөселман социалистлары кәмитите.

Асрау. Мөселман сәт, сәт...

Н и я з. Мөселман сәләмәләре кәмитите диең, ха-ха-ха…

Ф ә т х и. Без сәләмәлектән хурланмыйбыз, тәти егет, менә сезне сәләмәләндереп ташласак, ни эшләрсез икән, селәгәй авыз.

А с р а у чыга.

Н и я з. Абзый кеше, сүгенергә бу кабак түгел, йомышыгызны әйтегез дә юлыгызда булыгыз!

Ф ә т х и. Кабакта, ичмасам, эчеп исерәсең, ә сез монда эчми исергәнсез. *(Газета чыгарып.)* Минем фамилиямне кем рөхсәте белән монда бастырып чыгардыгыз, ә?

Н и я з. Кая?

Ф ә т х и. Койма башында. Бу нәрсә соң?

Н и я з. Фәтхулла Насыйров дөньяда бер сез генә дип beләсезме әллә?

Ф ә т х и. Минем өчен бер мин генә шул.

Н и я з. Кызганыч… Фәтхулла бай сезнең белән адаш булуына хурланса, бер хәл иде… Сезгә ни калган?

Ф ә т х и. Киләсе гәзитегездә, сабын заводының эшчесе Фәтхулла Насыйров белән буржуй Фәтхулла Насыйров арасында адашлык та, кардәшлек тә, туганлык та, чорт та юк, дип бастырыгыз! Мин моны сезгә яхшылык белән әйтәм. Бастырмасагыз үпкәләмәгез!.. Мин үземнең, чисный фамилиямне какой-то собака, буржуй фамилиясе белән бутыйсым килми. Менә шул!

Н и я з *(төкереп)*. Шпана!..

Ф ә т х и чыга, паузадан соң М и с б а х  х а җ и керә.

VII. Н и я з, М и с б а х  х а җ и.

М и с б а х  х а җ и. Җыелдылармы?

Н и я з. Бүген әллә нишләп бик акрын җыелалар, хаҗи әфәнде.

М и с б а х  х а җ и. Кара әле, кем, капка төбендә бер кыз очрады, урын-фәлән эзлиме әллә?

Н и я з. Юк.

М и с б а х  х а җ и. Ни эшкә соң ул монда буталып йөри?

Н и я з. Сезне эзләп килгән.

М и с б а х  х а җ и *(куркып)*. Мине?!

Н и я з. Әйе, сезне, хаҗи әфәнде.

М и с б а х  х а җ и. Нигә кирәк булдым икән мин аңар?

Н и я з. Менә гариза калдырып китте.

М и с б а х  х а җ и. Гариза?! Нинди гариза?

Н и я з. Сезнең өстегездән жалу белән килгән, хаҗи әфәнде.

М и с б а х  х а җ и. Минем өстән жалу белән?!

Н и я з. Ул сездә асрау булып торган икән.

М и с б а х  х а җ и. Йә, йә?

Н и я з. Бикәгез мөслимәләр җәмгыятенә җыелышка киткәч, сез, хаҗи әфәнде, ишекләрне бикләп, аның белән кети-кети уйнап алгансыз икән.

М и с б а х  х а җ и *(лап итеп утырып)*. Ә?! *(Кинәт торып.)* Йә, хуш, хуш, нәрсә ди?

Н и я з. Эшне зурга җибәрергә уйлый. Әгәр дә хаҗи абый ризаландырмаса, эшне болай гына калдырмыйм, мөселман социалистлары комитетына ирештерәм, ди.

М и с б а х  х а җ и. Хуш, ирештерде, ди, аннан ни булган, шаһитлары кая? Хуш, шаһитлары кая, йә?

Н и я з. Доктордан караткан.

М и с б а х  х а җ и. Ай, каһәр икән, Алла орган икән! Ризаландырыр өчен, үзенчә күпме сораган була?

Н и я з. Ул үзенә күп сорамый.

М и с б а х  х а җ и. Шулай да күпме ди?

Н и я з. Үзенә биш йөз, ди, аны бирәү котырта икән, аңа да бер-ике йөз кирәк булыр. Докторны да күреп сөйләшергә кирәк. Җыенысы мең сумга җыелыр.

М и с б а х  х а җ и. Мең сум?! Мең сумга, дурак, мин алма төсле унҗиде яшьлек мулла кызын гомерлеккә алам. Йөз сум бирсәм дә, түбәсе күккә тияр әле.

Н и я з. Мең сумнан ким бер тиен булса да алмаска кушты.

М и с б а х  х а җ и. Ничек кушты? Кемгә?

Н и я з. Миңа.

М и с б а х  х а җ и. Сиңа?!

Н и я з. Әйе, менә язуы.

М и с б а х  х а җ и. Ике йөзгә дә күнмәсме икәнни?

Н и я з. Күнәр төсле күренми... Вакыты бик уңайсызга туры килде. Ни әйтсәң дә, шәһәрдә көч большевиклар кулында бит. Эш аларга ирешсә, шуны бәһанә[1] итеп атып куюлары да бар.

М и с б а х  х а җ и. Һә, биш йөзгә дә күнмәсме икәнни?

Н и я з. Күнми, хаҗи әфәнде, күнми. Яхшы чакта бетерергә кирәк.

---

[1] Б ә һ а н ә — сылтау, сәбәп.

Мисбах хаҗи. Акча күрсәткәч, бәлки, алты йөзгә күнеп тә куяр.

Нияз. Ихтыярыгыз. Мең сум өчен атып куйсалар...

Мисбах хаҗи. Өркетмә, егет, өркетмә... Асрау өчен аталар ди, атмый ни...

Нияз. Шундый гына атып куярлар...

Мисбах хаҗи *(бүлдереп)*. Ярый, ярый... Аяк астыннан чыккан каза икән, хәерле булсын. Мең булса, мең булсын.

Нияз *(шатланып)*. Менә әллә кайчан шулай кирәк иде. Кая, рәхим итегез!

Мисбах хаҗи. Нәрсә?

Нияз. Мең сум.

Мисбах хаҗи. Ә, кем, акчаны үзенә үз кулым белән бирермен, син шаһит булырсың, яме!

Нияз. Ничек?

Мисбах хаҗи. Шулай. Мәслихәтләрең өчен рәхмәт. Җыелдылар дисеңме? *(Чыга.)*

Нияз. Алырсың шәйтаннан иман. *(Гаризаны карап.)* Әһә... Пеште генә. Адресы күрсәтелгән... Кызны алдан күреп йөзгә күндерсәм... калганын эһем, эһем, эһем... *(Кулларын уа.)*

Сәхнә артында шау-шу башлана, шаулашып чыгалар.

VIII. Нияз, Нуретдин, Батырхан, Мисбах хаҗи, Сәхипгәрәй һәм башка байлар.

Мисбах хаҗи *(чыгып китмәкче була, башкалар җибәрмиләр)*. Валлаһи газыйм, бер тиен бирмим. Алла боерса, бер тиен юк!

Батырхан. Хаҗи әфәнде, соңын уйлагыз!

Нуретдин. Бернәрсә булса, хәзер тәртәгә тибә башлый. Син тәртәгә тип, мин тәртәгә тибим, милләтне кем кайгыртыр?

Сәхипгәрәй. Деньги на кон, отец дьякон! Акча сездән, хезмәт бездән!

Батырхан. Хаҗи әфәнде, сез акыллы кеше, соңын уйлагыз! Дулый торган вакыт түгел. Әфәнделәр, утырышыгыз, мәҗлесне дәвам иттерәбез. Нияз әфәнде, утырыгыз.

Зур өстәл әйләнәсенә утырышалар. Нияз кәгазьләр алып утыра.

Мисбах хаҗи. Утырсам утырам, ләкин бер тиен бирмим, сүзем сүз! Болай да инде бирә-бирә бирәнгә сабышып беттем.

Н у р е т д и н. Ә мин бирмимме? Юрган хәтле гәзит чыгарам, шуның өстенә кәмититкә дә, Хәрби Шурага да, башкасына да синең белән тигез бирәм.

М и с б а х  х а җ и. Хөррият, милләт, кәмитит, шураларыгызның барысы да минем кесәгә көя төшерер өчен корылган тегермән. Бир дә бир, ал диюче юк.

Б а т ы р х а н. Гел алырга гына димәгәндер бит. Алган хәтлесенә шөкер итегез. Кайчагында бирергә дә кирәк бит, ахрысы. Безнең кемнәр өчен тырышканлыкны күрмисезмени, сезнең өчен бит, сезнең өчен, ягъни милләт өчен!

С ә х и п г ә р ә й. Безгә үз ихтыярыгыз белән бирмәсәгез, большевиклар кычкыртып алырлар.

Б а т ы р х а н. Мөселман комитеты президиумының нәүбәттән тыш фәүкылгадә утырышы дәвам итә. Каралачак мәсьәләләр: беренче – Хәрби Шураның матди ягын төзәтү; икенче – мөселман комитетының тышкы һәм эчке идарәсен автономияле итеп игълан итү; өченче – Совет властен тасдыйк итү-итмәү[1] мәсьәләсе; дүртенче – Төркестандагы соңгы хәлләр турында информация.

М и с б а х  х а җ и. Алай икән, сезгә акча да бир, шуның өстенә савитны да тасдыйк ит... Алай булса, без киттек, хушыгыз!.. *(Торып китмәкче була, тотып утырталар.)*

Н и я з. Сабыр итегез!

Б а т ы р х а н. Утырыгыз, сез мине аңламадыгыз, хаҗи әфәнде. Ул алай түгел.

Н у р е т д и н. Бу ниткән кирегә өстерәвең инде синең!

С ә х и п г ә р ә й. Деньги на кон, отец дьякон!

М и с б а х  х а җ и. Минем алдымда савит дигән сүзне телгә аласы булмагыз, рөхсәт юк! Җыен разбуйник, галах, зимагур, динсез сәләмәләр шайкысы бит алар. Савит, имеш, шайкы, шайкы, шайкы!.. У-у-у! Алла биреп, богауланган көннәрен бер күрсәм, тиреләрен үтмәс пычак белән үз кулым белән тунар идем. У-у-у! Алла боерса, у-у-у! Алла боерса!.. *(Өстәлне тукмаклап.)* Менә сезгә хөррият, менә сезгә ыслабуда! Менә сезгә магазин, менә сезгә кәнтрибуция!..

Б а т ы р х а н. Менә шул шатлыклы көннәрне күрәсегез килсә, хәзерге вакытта дәүләтегезне кызганмаска кирәк.

С ә х и п г ә р ә й. Бүген ун мең бирәсегез килмәсә, иртәгә йөз мең контрибуция түләрсез.

---

[1] Т а с д ы й к  и т ү – тану.

М и с б а х  х а җ и. Акчам юк дигәч, пычагыма кәнтрибуция саламыни ул!

С ә х и п г ә р ә й. Табарлар...

М и с б а х  х а җ и. Табар менә!.. *(Йодрыгын күрсәтеп.)* Килеп карасын, бирермен!..

IX. Ә ү в ә л г е л ә р  һәм  х ә з р ә т.

Х ә з р ә т. Әссәламегаләйкем!

Н у р е т д и н. Вәгаләйкемәссәлам, әйдүк, хәзрәт!

Б а т ы р х а н. Хәзрәт, соңга калыбрак килдегез.

Дога кылалар.

М и с б а х  х а җ и. Ашарга чакырсаң, вакытында килә алар, монда бит майлы бәлеш төбе көтми ашыгырга.

Х ә з р ә т. Никах мәҗлесе бар иде.

М и с б а х  х а җ и. Шундый кыяматтә кайсы диванасы өйләнергә уйлаган тагы?

Н и я з. Шулай инде, кайсы өйләнә, кайсыберсе бүлмәгә бикләп кети-кети уйный.

М и с б а х  х а җ и. Егет, май кап. Бетте!

Н у р е т д и н. Кемгә никах укыдыгыз, хәзрәт?

Х ә з р ә т. Ибраһим байга.

Н у р е т д и н. Чәйче Ибраһим байгамы?

Х ә з р ә т. Әйе, бикәсе бик күркәм, яшь кенә, йоны яңа чыгып килә торган үрдәк бәбкәсе төсле. Бик зифа, бик сылу, һөнәре дә бар икән.

Н и я з. Яшь башы белән алтмыш биш яшьлек картка чыккач, һөнәре бардыр шул.

Х ә з р ә т. Һөнәре бар, ди, бар. Тешләр ямаучы, ди.

М и с б а х  х а җ и. Яшь булгач, Ибраһим байның тешен дә, кесәсен дә берьюлы ямап куяр, Алла боерса, хи-хи-хи...

С ә х и п г ә р ә й. Байлар, карап торам да мин сезгә, эшнең, сәясәтнең кая таба барганлыгын төшенмисез, күрәм. Бөтен шәһәр Советлар кулында, урамнарда нәмаешлар[1], бүген-иртәгә реквизиция, конфискация, контрибуцияләр башланачак. Үлем куркынычы борын төбендә торган бер заманда мөселман комитеты президиум әгъзалары бикәчләп яталар. Болай булса, гафу итегез, байлар, үзегез дә бетәсез, безне дә бетерергә җыенасыз. Мин Хәрби Шураның вәкиле булуым сыйфаты белән тарихи вакыйгаларга сезнең болай салкын карашыгызга протест бәян итеп, мәҗлесегезне

---

[1] Н ә м а е ш — демонстрация.

ташлап китәргә мәҗбүрмен. Гафу итегез, байлар, сез безгә кирәк түгел, без сезгә кирәк, хушыгыз! *(Чыга.)*

Батырхан. Сәхипгәрәй әфәнде, Сәхипгәрәй әфәнде!..

Нуретдин. Бу ни булды бу?!

Батырхан. Мәсьәләнең ничек булганын төшендегезме инде, байлар?.. Сәхипгәрәй әфәнденең бу чыгышы — Хәрби Шураның бездән аерылуы дигән сүз.

Мисбах хаҗи. Ә сез шул койрыксыз саесканнар өчен бездән акча даулыйсыз.

Нуретдин. Тукта әле син, эшнең төбен аңламыйча лыгырдама әле!

Батырхан. Ит үзлегеннән кортлый, дигәннәр бабайлар, безнең кәмитит тә үзлегеннән кортлады, әфәнделәр. Менә күрәсез, комитетның фәүкылгадә җыелышына шундаен мөһим вакытта биш кеше килгән. *(Кычкырып.)* Бу ни эш бу!..

Мисбах хаҗи. Кычкырма, барыбер миннән бер тиен юк!

Батырхан. Бу эшебез белән үзебез муеннарыбызга бау салабыз.

Мисбах хаҗи. Син сал, мин салмыйм.

Батырхан. Йә, менә иртәгә большевиклар килеп барыбызны берәм-берәм суя башласалар?.. Кем яклар, таянычыбыз кемдә?..

Мисбах хаҗи. Өркетмә, егет, өркетмә... Алла барлыгын онытма, әфәнде! Син Аллага ышанасыңмы, әллә койрыксыз саескан Хәрби Шурагамы?.. Шулай бит, хәзрәт?..

Хәзрәт. Алла, саклanганны саклармын, дигән. Динебез, милләтебез бетмәсен дисәгез, иганәләрегезне кызганмагыз. Мал кызгана торган чак түгел.

Нияз. Әфәнделәр, бу фәүкылгадә мәҗлес булмады, бу фәүкылгадә ботка булды, протоколга ни язарга да белмим.

X. Әүвәлгеләр һәм Давыт.

Давыт *(шашынып керә)*. Харап, әфәнделәр, харап!
Барысы *(сискәнеп торып)*. Ни бар, ни булган?..

XI. Әүвәлгеләр һәм хатын белән Фәттах.

Фәттах.
Хатын. } Ни бар, ни булган?

Давыт. Милләт бетте!
Барысы. Бетте?!

Д а в ы т. Дин югалды!

Б а р ы с ы. Югалды?!

Д а в ы т. Дәүләт очты! *(Арып утыра.)*

М и с б а х  х а җ и. Очырмабыз, рөхсәт юк!

Б а т ы р х а н. Милләткә ни булган?

Д а в ы т *(кулын бутап)*. Харап!

Х ә з р ә т. Динне нишләткәннәр?

Д а в ы т. Харап!..

Н у р е т д и н. Дәүләткә ни булган?

Д а в ы т. Беттек, җәмәгать, беттек!

Х ә з р ә т. Ярабби, әльәман[1] ярабби, әльәман!

Б а р ы с ы. Ни бар соң? Ни булган?!

Д а в ы т. Югары урамда бөтен кибетләрне пичәтләп киләләр!

Б а р ы с ы. Ә-ә-ә?!

Д а в ы т. Түбән базарны патрульләр чолгап алганнар!

Б а р ы с ы. Сөбханалла, машалла!

Д а в ы т. Урам башларында пулемётлар...

Б а р ы с ы. Ләхәүлә, ләхәүлә...

Куркыналар, хәрәкәт.

М и с б а х  х а җ и *(Батырханга җикеренеп)*. Ишетәсеңме, правасыз атбакат, тол пистон. Кая милләтең, кая иттифакың, кая Хәрби Шураң?! Анда безнең кибетләрне талыйлар бит!.. *(Нуретдингә.)* Син кызыңа кияү эзләп шул шартлавыкны безнең арага тыктың! *(Батырханга.)* Кибетебезне талатыр өчен, җиде ай буенча бездән акча җыйдыгызмыни! Буш куык, шартлавык!.. *(Нуретдингә.)* Тайга карап азган ат, син нәрсә карадың, тол дүдәк!..

Н у р е т д и н. Җикеренмә миңа, юләр балык, юка баш!

Б а т ы р х а н. Әфәнделәр, сабыр, үпкәләшә торган чак түгел, холыксызланмагыз, сабыр! Бөтенләйгә өметегезне өзмәгез, бу эшләр вакытлы гына...

М и с б а х  х а җ и. Малым, дәүләтем таралганнан соң, аның мәңге булмавыннан миңа ни файда!

Б а т ы р х а н. Мал бетсә табылыр. Җанны саклап калырга кирәк.

М и с б а х  х а җ и. Мал булмагач, хәерче җан ни эшкә миңа? *(Шашынып.)* Кая, бирегез балта, бирегез күсәк, мылтык бирегез, дин юлында шәһит китәм, чукындырып шәһит китәм! *(Шашынып кешеләргә, урындыкларга бәйләнә.)*

[1] Ә л ь ә м а н — ярдәм ит, коткар.

Х ә з р ә т. Сабыр, хаҗи, сабыр, тынычланыгыз, утырыгыз! *(Утырталар.)*

М и с б а х  х а җ и *(елап)*. Ай малларым, җанкисәкләрем, малларым!..

Н у р е т д и н. Йә Батырхан әфәнде, инде ни эшлибез?

Х ә з р ә т. Ярабби, әльәман, ярабби, әльәман!..

Д а в ы т. Үзебез гаепле, үзебез. Куеныбызда еланнар асрадык!

Б а т ы р х а н. Әфәнделәр, шашмагыз, болай өметсез булырга ярамый... Ир булыгыз!..

М и с б а х  х а җ и. Әй кяфер, хәзергә кадәр мине хатын дип йөрдеңмени!.. *(Һөҗүм кыла, хәзрәт тота.)*

Х ә з р ә т. Сабыр, сабыр, хаҗи әфәнде!

М и с б а х  х а җ и. Хурлыгына чыдар хәлем юк, хәзрәт. Шул сакалым белән мине хатын исәпләп юләр саттырган бит ул... Ай малларым, җаннарым, малларым!.. *(Елый.)*

Б а т ы р х а н. Җәмәгать, әфәнделәр, урыннарыгызга утырышыгыз!.. Большевикларның мондый чыгышлары, күрегез дә торыгыз, үз башларына булыр. Шәһәребезнең большевиклар кулына күчкәненә күпме генә булды, базарда мал, икмәк, чәй-шикәр калмады. Бу эш кара халыкны үзен үк тынычсызландырачак. Бу афәттән котылырга юллар бар, ләкин һаман да шул бер нәрсә кирәк.

Б а р ы с ы. Нәрсә, нәрсә?!

Б а т ы р х а н. Милли сәрмая, акча кирәк.

М и с б а х  х а җ и *(урыныннан сикереп торып, Батырханга барып)*. Тагын акча!.. *(Кукиш курсәтеп.)* Менә монысы акча, ә менә монысы милли сәрмая!..

С ө н г а т ь һәм кораллы и к е  э ш ч е керә.

XII. Ә ү в ә л г е л ә р, С ө н г а т ь һәм кораллы и к е  э ш ч е.

С ө н г а т ь *(кереп, гаскәрләрне төрле урыннарга куеп)*. Әфәнделәр, бер шәһәрдә ике властьның яшәве мөмкин түгел. Революцион военный комитет исеменнән бирелүегезне үтенәм, коралларыгыз булса ташлагыз!..

Б а т ы р х а н. Сөнгать әфәнде, исәнмесез!.. *(Алга атлый.)*

С ө н г а т ь. Урыныгыздан кузгалмагыз!..

Мисбах хаҗи өстәл астына кача, башкалар катып кала.

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

Бай зал. Төнлә.

I. Давыт, Нуретдин, Мисбах хаҗи, Дилбәр, хәзрәт, Сәхипгәрәй, Фәттах һәм башка байлар.

Сәхипгәрәй. Итак, әфәнделәр, әгәр дә Хәрби Шура председателен 24 сәгать эчендә азат итмиләр икән, без коралга ябышырга мәҗбүр булачакбыз.

Барысы. Корал күтәрергә кирәк, мәслихәт.

Давыт. Корал күтәрерлек реальный көч җитәрлекме?

Сәхипгәрәй. Җитәрлек һәм тайяр[1].

Давыт. Шулаймы?

Сәхипгәрәй. Тимер дружина, беренче сигнал бирү белән, большевикларга каршы сугышка чыгарга тайяр тора. Тик бер айлык жалунияләрен алдан бирелүен сорыйлар.

Мисбах хаҗи. Кара син аларны, акыллы башлар икән. Сугышмас борын жалуния алмакчылар. Иң элек сугышсыннар, савитны җиңсеннәр, аннары алырлар. Без качып китмибез ич.

Давыт. Сугышка чыгарлык булсалар, сораганнарын бирергә кирәк.

Мисбах хаҗи. Моңарчы биргәннәребезне Алла кабул итсен. Алдан жалунияләрен алып бетергәч, нәрсәгә кызыгып сугышырлар икән алар! Без, энем, эш хакын кәләпүшчеләргә дә алдан биреп куймыйбыз. Бу сугыш эше, уен түгел. Бәлки, ул капкадан чыгуга үләр.

Сәхипгәрәй. Тимер дружинаның теләкләрен ирештердем, калганы ихтыярыгызда, байлар.

Нуретдин. Сәхипгәрәй әфәнде, сугыш эшендә хәйлә кирәк бит, хәстәрен күрдегезме?

Сәхипгәрәй. Бөтен планнар әзер.

Нуретдин. Шулай да?..

Сәхипгәрәй. Беренче, броневиклар үтә алмасын өчен, бөтен урамнар аркылы бүрәнәләр тезелеп ята. Зур йортларның чарлакларына, мәчет манараларына пулемётлар куелды.

Нуретдин. Туплар нинди урыннарда булачак?

Сәхипгәрәй. Шәһәр сугышында тупларның кирәкләре юк.

Нуретдин. Юк, юк, туплар кирәк. Гөрселдәтеп атып җибәргәндә гөж килсеннәр иде.

---

[1] Тайяр — әзер.

Мисбах хаҗи. Корал ягы ничек, корал ягы?
Сәхипгәрәй. Кемнең?
Мисбах хаҗи. Тимер дружинаның.
Сәхипгәрәй. Ышанычлы 800 штык, 12 мең патрон, 3 пулемёт, ләкин икесен төзәтергә кирәк булыр. Хәер, шәһәр сугышында пулемётның әһәмияте аз...
Давыт. Кавалерия буламы?
Сәхипгәрәй. Әлбәттә, хәзергә 35 баш ат, 28 ияр...
Нуретдин. Азрак икән...
Сәхипгәрәй. 19 сөңге, 96 кылычыбыз бар. Ләкин кавалериянең шәһәр сугышында кирәге дә шулкадәр генә.
Давыт. Әфәнделәр, бу кораллар белән генә сугыш башлау бәладән башка нәрсә тудырмас. 12 мең патронны бер сәгатьтә атып бетерергә мөмкин. Аннан соң ни эшләрбез? Манарадагы бер пулемёт та күгәрченнәр куркытудан башкага ярамас. Минем фикеремчә, үзара яңадан акча җыеп, беренче планда коралны ныгытырга кирәк.
Мисбах хаҗи. Тагын акча?! Акча белән корал ныгытырга дип уйласагыз, мине бөтенләй юк дип белегез. Ныгытасын ныгыттык инде, Алла кабул итсен.
Сәхипгәрәй. Сез байларның ярдәменнән башка ныгытып булмый.
Мисбах хаҗи. Милләтегез кая соң?.. Болай да бер елдан бирле милләт, дин ныгыттырдыгыз. Инде хәзер корал ныгытырга уйлыйсызмыни?.. Бигайбә, мәгъзүр, әфәнделәр. Әнә яшь бикәчкә өйләнгән Ибраһим байдан ныгыттырыгыз. Кәмититкә дә язылып кына түләмичә котылды. Ә үзе бер ай эчендә төгәл бер миллион сум патша акчасы җыеп алды. Нигә ул ныгытмый, ныгытсын!..
Хәзрәт. Җиһад[1] эшендә коралның нык, яхшы һәм көчле булуы, әлбәттә, кирәк. Ләкин сугышта иң кирәкле нәрсә — хәмият, гайрәт һәм иман. Алыйк, мәсәлән, Бәдер, Өхед сугышларын. Карыйк ибне Зиатның Әнделсне фәтхен...
Нуретдин. Хәзрәт, эш вакытында әкият сөйләмик.
Давыт. Мөселман полыгының ни хәле бар?
Сәхипгәрәй. Аны оештыру бөтен килеш Батырхан әфәндегә тапшырылды.
Давыт. Минемчә, безнең иң көчле терәгебез әнә шул мөселман полыгы булырга тиеш. Ул оешмаганда, сугыш башлаудан, бая әйткәнчә, бер мәгънә дә чыкмас.

---

[1] Җиһад — сугыш.

Тавыш.

Н у р е т д и н. Батырхан әфәнде кулында булса барып чыгар, Алла боерса.

Ф ә т т а х. Әле хәзер генә бу әфисәр әфәнде бүрәнә дигән иде. Хәзерге вакытта саллар юк, урман ерак. Аннан соң хәзерге вакытта шәһәрдән дә чыгып булмый бит. Уйлап-уйлап торам да, ул хәтле бүрәнәләрне каян табып бетерербез икән, дим? Әллә, мин әйтәм, бүрәнәләр урынына урамнар аркылы тирән-тирән чокырлар казу мәслихәт булырмы икән, дим? Кыргыч, көрәк, лом, Аллага шөкер, һәрбер йортта бар.

С ә х и п г ә р ә й. Телефон, телеграм баганалары хәзергә җитәрлек.

Х ә з р ә т. Бүрәнә дә булсын, чокыр да булсын... Бу инде, ягъни мәсәлән, гасре сәгадәттәге Хәндәкъ сугышы төсле...

Н у р е т д и н. Хәзрәт, вәгазеңне мәчеттә, иркен чакта сөйләрсең. Йә, хуш, хуш, тагы?

Д и л б ә р. Картлардан узып булса да, миңа да сүз бирегез әле.

С ә х и п г ә р ә й. Рәхим итегез!

М и с б а х х а җ и. Бу ниткән кош тагы?

С ә х и п г ә р ә й. Мөслимәләр җәмгыятеннән килгән вәкилә.

Д и л б ә р. Әфәнделәр, җәмәгать, картлар, сез кораллар, бүрәнәләр, чокырлар турында сөйләштегез. Әмма санитарлык турында һичберегез бер сүз әйтмисез. Мөслимәләр җәмгыяте мәҗрухларны[1] карау эшен үз өстенә ала. Без мөслимәләр җәмгыятенең бөтен әгъзаларын шәфкать туташлыгына мобилизовать иттек.

М и с б а х х а җ и. Минем карчыкны да туташ иттегезме, ха-ха-ха... Йөрмәгез юк белән саташып.

Д и л б ә р. Әгәр дә кирәк булса, хатын-кызлардан дружина төзергә сүз бирәбез.

М и с б а х х а җ и. Ә?! Ха-ха-ха!

Д и л б ә р *(каты)*. Әйе, юкка көләсез, хаҗи баба.

М и с б а х х а җ и. Соң бит безнең ирләрдән төзелгән тимер дружинабыз бар, хатыннардан агач дружина төземәкче буласызмыни?.. Маташмагыз юк белән кеше көлдереп... Энҗе калфаклы дружина, ха-ха-ха!..

Д и л б ә р. Хәер, хаҗи баба, сез әле һаман да хатын-

---

[1] М ә җ р у х – яралы, җәрәхәтле.

кызларга курчак итеп карамакчы буласыз икән. Ләкин ялгышасыз, Керенский төзегән ударный батальоннарны онытмагыз!.. Жанна д'Арк – Орлеанская деваны исегезгә төшерегез!

Мисбах хаҗи. Аруллы дифкыларыгыз да, калфаклы дружиналарыгыз да үзегезгә булсын, бәлагездән башаяк.

Дилбәр. Ай хаҗи баба, хатын-кыз дигәч тә, сезнең азиатлык пружинагыз басылды булырга кирәк.

Мисбах хаҗи. Тимер дружинага агач пружина куйсаң басылмый хәле юк аның, хи-хи-хи!..

Барысы. Юк эшкә кердегез, юк эшкә!..

Шаулашалар. Батырхан керә.

II. Әүвәлгеләр һәм Батырхан.

Батырхан *(честь биреп)*. Әфәнделәр, полк хәзер, фәрманыгызны көтә!

Барысы. Ура, ура!..

Нуретдин. Яшәсен мөселман полыгы, яшәсен Батырхан!

Барысы. Ура, ура!..

Батырхан. Яшәсен Чыңгыз әүлады!

Барысы. Ура, ура!..

Давыт. Яшәсен татарның Әнвәр пашасы!

Барысы. Ура, ура!..

Хәзрәт тәкбир әйтә башлый. Сәхипгәрәй авызын кулы белән каплый.

Батырхан. Әфәнделәр!..

Барысы. Тес, тес!..

Хәзрәт тәкбирен бүлә.

Батырхан. Мөселман полыгын большевикларга каршы сугышка чыгарыр өчен, өч нәрсә кирәк!

Барысы. Ун булсын, йөз булсын, барысын да үтибез.

Батырхан. Шул өч нәрсә булса, полк сезнеке!

Барысы. Үтибез, үтибез, теләкләре нәрсә соң?

Батырхан. Полк теләгән өч нәрсәнең беренчесе – акча!

Барысы. Алай!..

Пауза.

Батырхан. Икенчесе...

Пауза.

Нуретдин. Хуш?

Батырхан. Акча!

Мисбах хаҗи. Ишеттек!

Батырхан. Өченчесе һәм ахыргысы — акча!

Мисбах хаҗи. Безнең өчен файдалы сүз әйтәме дисәм, һаман шул иске куыкны шартлатуың икән, энем.

Батырхан. Йә әфәнделәр, мин җавап көтәм, акча буламы?

Мисбах хаҗи. Акча булса, мин милли мөселман полыгы түгел, кяферләр полыгы да төзи алам.

Батырхан. Булмый икән, бүген үк төнлә полк солдатлары авылларына таралачак.

Мисбах хаҗи. Сугышкан өчен оялмыйча акча сорарга алар милләт түгелмени?

Батырхан. Алар хәзер милләт тә, чорт та түгел, алар — сугыштан алҗыган солдатлар гына. Йә байлар, ни әйтәсез?!

Барысы тын кала, пауза.

Акча җыясызмы?

Барысы тын, пауза.

Акчагыз бармы?

Мисбах хаҗи. Юк!

Батырхан. Юк булгач, мәгъзүр, сау булыгыз!.. *(Китмәкче була.)*

Нуретдин. Тукта әле, Батырхан, тукта!

Батырхан. Байлар, мин ике сөйләшергә дип килмәдем, ахыргы сүзем, акча бирәсезме, юкмы?

Нуретдин. Күпме кирәк соң?

Батырхан. Жалуниягә сиксән мең, коралларга ике миллион.

Барысы. Алай-й-й!..

Давыт. Әфәнделәр, Батырхан мәсьәләне уртага салды, ни дисез?

Фәттах. Ул сораган хәтле булмаса да, кадәри хәл җыеп бирергә кирәк булыр.

Мисбах хаҗи. Миннән сукыр бер тиен юк. Болай да бирә-бирә бет басты инде мине.

Нуретдин. Син, кем, хаҗи, бер нәрсә булса, хәзер пузырьга керә башлыйсың, алай ярамый, син бирмә, мин бирмим, кем бирер?

Мисбах хаҗи. Милләт бирсен.

Нуретдин. Син, мин милләт бит инде.

Мисбах хаҗи. Алаймы, акча сораганда — милләт, магазиннарны пичәтләгәндә — имгәк!

Батырхан. Менә шул пичәтләнгән магазиннарыгызны ачтырыр өчен, йортларыгызны кайтарыр өчен, контрибуцияләр түләмәс өчен, төрмәләрдә газап чигүче каһарманнарны азат итәр өчен, акча кирәк.

Мисбах хаҗи. Магазиннарымны товарлары белән, йортларны зарарлары белән сугышып кайтарып алып бирсеннәр, бирермен. Юкса төче телләнеп, явачак карга, туңачак бозга ышандырып, җитәрлек каен терәттегез инде.

Нуретдин. Тукта әле, хаҗи, сөйлисең дә сөйлисең, башкаларга сөйләргә ирек бир. Хуш, Батырхан әфәнде, нишлик икән?.. Бик зур акча бит, җыеп булырмы икән?..

Батырхан. Йөз еллар буенча җыелган дәүләтләрегез тар-мар булсын дисәгез, акча бирмәгез! Мең өч йөз елдан бирле килгән динегез мәсхәрә ителсен дисәгез, акча бирмәгез! Никахлы хатыннарыгыз, буйга җиткән кызларыгыз хурлансын дисәгез, акча бирмәгез!

Мисбах хаҗи. Йөз еллардан бирле җыелган дәүләтем китте. Хур ителерлек кызым юк, яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган. Карчыгымны алалар икән, үпкәм юк, алсыннар.

Дилбәр. Милләтнең карт аталарына шундый тарихи вакыйгалар алдында мондый сүзләр сөйләү оят. Мең мәртәбә оят! Дөнья яралганнан бирле, коллыкта, хурлыкта яшәгәнбез, шәрык хатын-кызлары, бу көн җиткәч, намусыбызны саклап калыр өчен, актык тамчы каныбызгача көрәшеп корбан булырга хәзербез!.. Бернәрсәбез җәл түгел!.. Менә сезгә энҗеле калфагым, менә сезгә ридикюлем. *(Өстәлгә ташлый.)* Без бичара хатын-кызлардан тагын сезгә ни кирәк?.. Урамнарга чыгып сугышыгыз дисәгез, без хәзер! Үлегез дисәгез, үләргә дә без хәзер! Бирегез корал, корал бирегез!.. Корал, корал, корал!.. *(Һушыннан язган була.)*

Давыт белән Нуретдин әйләнәсендә йөриләр.

Сәхипгәрәй. Су бирегез, су!..

Нуретдин. Милләт юлында корбан булган кызым, кызым Дилбәр!..

Давыт. Әткәй, алып чыгыйк!..

Нуретдин. Кызым, кызым!

Култыклап алып чыгалар.
Дилбәр калфагын, ридикюлен алып чыга.

Батырхан. Әфәнделәр, күрдегезме бу каһарман туташны, шуны күреп тә күңелләрегез йомшармадымы?.. Оят сезгә, оят! Шулай ук хатыннардан да түбән калдыгызмыни?.. Кая соң сездә бабабыз Чыңгыз ханның гайрәте?!

Мисбах хаҗи. Калфак бәреп кенә гайрәт күрсәтү сиңа кирәк булса *(кәләпүшен кат-кат өстәлгә бәреп)*, менә сезгә кәләпүшем, алыгыз, ал! Кил, зинһар, акча гына сорамагыз!.. Һе, корал, имеш, кораллanasы килсә, тимер дружинага барсын... Ир-ат алдында кыз башы белән кәмит уйнамасын.

Шау-шу.

III. Давыт, Дилбәр, Нуретдин, башкалар һәм Зәйнетдин.

Зәйнетдин. Әссәламегаләйкем!

Хәзрәт. Вәгаләйкемәссәлам!

Сәхипгәрәй. Әфәнделәр, менә тимер дружинадан килгән вәкил, үзе белән сөйләшегез.

Зәйнетдин. Дөрес, җәмәгать, мин вәкилен вәкил, ләкин тимер дружинадан түгел.

Сәхипгәрәй. Кайдан?

Зәйнетдин. Мин үз йомышым белән генә килгән идем.

Сәхипгәрәй. Хуш?

Зәйнетдин. Миңа Фәттах абый кирәк иде, Фәттах абый, кил әле!

Фәттах *(торып)*. Минме?

Зәйнетдин. Әйе, кил әле!

Сәхипгәрәй. Җәмәгать, таралмагыз!..

Фәттах. Мин хәзер, хәзер... Йә, ни бар, Зәйнетдин?

Зәйнетдин. Әйдә, киттек, рәт чыкты.

Фәттах. Йә?

Башкалар үзара сөйләшәләр.

Зәйнетдин. Бер җирдә биш чиләк спирт калкып тора.

Фәттах *(шатланып)*. Булмас ла?!

Зәйнетдин. Билләһи газыйм... Әйдә!

Фәттах. Бәһа?

Зәйнетдин. Сорап та торма, мөф... Әйдә, киттек!

Фәттах. Мәҗлес бит, чыгармаслар, үзең генә рәтлә.

Зәйнетдин. Минем сума җитми шул, булмаса, акча гына бир!

Фәттах. Акча?.. Күпме кирәк?

З ә й н е т д и н. Ике чиләгенә үземдә дә рәт бар, калганына сума җитми.

Ф ә т т а х. Янымда ул хәтле юк шул, кем, Зәйнетдин.

С ә х и п г ә р ә й. Әфәнделәр, урыннарыгызга утырышыгыз, мәҗлес дәвам итә.

Ф ә т т а х. Хәзер, хәзер.

З ә й н е т д и н. Өеңдә бармы?

Ф ә т т а х. Табылыр.

З ә й н е т д и н. Әйдә, алайса, киттек.

Ф ә т т а х. Мәҗлес бит, милләт эшләре.

З ә й н е т д и н. Әй, дуракланмасана!.. Милләт кайгырта торган чакмыни... Биш чиләк бит!.. Әйдә!

Ф ә т т а х. Шулаймы?

З ә й н е т д и н. Нишләттең, әйдә, дим, инде!

Ф ә т т а х. Хәзер... Җәмәгать, минем хатын үлә икән, мәгъзүр, сау булыгыз!..

З ә й н е т д и н. Үлә генә түгел, шытты инде, шытты.

Чыгалар.

Б а р ы с ы. Таралмагыз, таралма, җәмәгать, бу ниткән эш бу?!

Н а у м  П а х о м и ч белән генерал Н о с о в керәләр.

IV. Ә ү в ә л г е л ә р, Н о с о в һәм Н а у м  П а х о м и ч.

Н а у м  П а х о м и ч. Керергә рөхсәтме?

Н у р е т д и н. Әйдүк, Наум Пахомич, әйдүк.

Н а у м  П а х о м и ч. Господа, таныш булыгыз, генерал Сергей Сергеевич Носов.

Н у р е т д и н. Сез соңладыгыз, Наум Пахомич.

Н а у м  П а х о м и ч. Менә генералны көттем, совещаниедә идек.

Н у р е т д и н. Йә, ничек соң сездә эшләр?

Н а у м  П а х о м и ч. Көткәннән дә артык булып чыкты. Сергей Сергеевич, аңлатыгыз!

Н о с о в. Господа, без сезнең белән ничә йөз еллардан бирле туганнарча тату, дус булып яшәп килдек. Татарлар моңарчы ватанга һичбер вакыт хыянәт кылганнары юк. Татар солдатлары сугышларда ватан өчен геройларча сугышканлыкка мин үзем шаһит. Бу турыда мин 1916 елны главный командующийга рапортта да белдергән идем. Без һәрвакыт сезгә ышанган төсле бу юлы да ышанабыз. Башлаган эшегез зур, Алла куәт һәм гайрәт бирсен! Большевикларга каршы көрәшү — хәзерге заманда һәрбер намуслы, ватанын сөюче гражданның бурычы. Без рус

офицерларыннан төзелгән өч меңлек көч белән сезгә булышырга хәзер торганлыгыбызны белдерер өчен килдек... Өч меңле офицер отряды к вашим услугам, господа.

Б а р ы с ы. Ура, ура, ура!..

Н о с о в. Сездә оста командирлар аз булганлыктан, командование эшен без үзебез алып барырга булдык.

Н а у м  П а х о м и ч. Сергей Сергеевич үзе главный командующий булачак.

Б а р ы с ы. Ура, ура, ура!..

Н о с о в. Бер атна эчендә бу шәһәрдә бер большевик та калмас. Бер айдан, күп булса, ике айдан Мәскәүдә булырбыз!..

Б а р ы с ы. Ура, ура!..

С ә х и п г ә р ә й. Йә җәмәгать, күпмешәр язылласыз?

Н у р е т д и н. Миннән ун мең языгыз!

М и с б а х  х а җ и. Миннән бер тиен дә юк.

Н у р е т д и н. Ярамый, хаҗи, ярамый.

М и с б а х  х а җ и. Хәзергә ярап торыр... Соң, үзең уйлап кара, Нуретдин, полыгына бир, шурасына бир, дружинасына бир, кәмититенә бир, мөхтәсибенә бир, квартал казначиена бир, чортына бир, муртына бир, бир дә бир!.. Мә дигән кеше юк, бирә-бирә бетмәскә, минем кесәм зәмзәм коесы түгел, егетләр.

Б а т ы р х а н. Менә иртәгә үк сәләмә кызылгвардеецлар, йортларыгызга кереп, көз көне казларны суйган кебек, берәм-берәм барыгызны суеп чыгачаклар. Исән калганнарга гомергә түләп бетерә алмаслык контрибуцияләр салып, җыенычгызны, богаулап, окоплар казырга алып китәчәкләр. Салкын кырларда, буран, бозлы яңгыр астында ач-ялангач килеш, адашкан этләр төсле кырылып бетәчәксез... Үләксәләрегез козгыннарга, ач бүреләргә азык булачак. Кәфен саручыгыз булмас, кабер казучыгыз булмас, җеназа укучыгыз булмас, сөякләрегезне тычканнар кимерер...

М и с б а х  х а җ и. Өркетмә, егет, өркетмә!.. Ярый, мең сум языгыз!

Н у р е т д и н. Миннән илле мең.

Сәхипгәрәй яза.

Х ә з р ә т. Бездән дә илле сум языгыз!

М и с б а х  х а җ и. Киткән-киткән икән, ике мең булсын.

Н у р е т д и н. Миннән алтмыш мең.

Башкалар тагы яздыралар.

Батырхан *(кыза барып)*. Хатыннарыгызны, сылу, зифа кызларыгызны плен алып, казармалар, күперләр юдырып, зимагурларның шакшы киемнәрен яматып, кызылгвардеецларга никахсыз загс ясап кияүгә бирерләр, әби-бабаларыгыз күмелгән зиратларны стадион ясап, эшчеләрдән футбол типтерерләр!

Нуретдин. Миннән йөз мең!

Мисбах хаҗи. Мин синнән киммени, язызыгыз ун мең!

Башкалар язылалар.

Наум Пахомич. Молодец, Мисбах Шакирич, молодец. Миннән егерме мең язызыгыз!

Мисбах хаҗи. Язызыгыз егерме биш мең!.. Әмма ләкин актыгы булсын.

Носов. Молодец, князь, молодец!..

V. Әүвәлгеләр һәм Нияз.

Нияз. Җәмәгать, җәмәгать!..

Барысы *(куркышып торалар)*. Ни бар, ни бар?!

Нияз *(тагы кычкырыныбрак)*. Җәмәгать!

Барысы куркышып, сискәнеп тайчаналар.

Җәмәгать!.. Финляндский полк килде, вокзалда совет агитаторлары аларны котырталар. Үз ягыбызга аударырга кирәк. Барысы да кораллы!

Мисбах хаҗи. Кеше куркытмыйча әйтсәң, авызың тузар дип курыктыңмы әллә, саескан!

Давыт. Әфәнделәр, ул полкны үз ягыбызга аударырга кирәк.

Мисбах хаҗи. Аларга да акчамы?..

Батырхан. Әфәнделәр, ул полкка әби-бабаларыбызның гадәте булган кунакчыллык күрсәтү — сезнең бурычыгыз. Хәзердән җөмһүриятнең бөтен урамнарына, тыкрыкларына фәрман таратырга кирәк. Һәрбер гаилә дүрт-биш солдатны кунак итсен!

Тавыш.

Һәм большевикларга каршы өндәү алып барсын.

Нияз. Аннан соң тупчылар казармасында булдым. Йөз меңгә егерме туп сатарга булдылар.

Нуретдин. Алырга кирәк, безгә туплар кирәк.

Барысы. Алырга кирәк!

Нияз. Алырга кирәк булса, хәзер, шул минут акча бирегез! Тизрәк, тизрәк. Вакыт үткәрмәгез!

Н у р е т д и н. Барысы күпме кирәк?

Н и я з. Йөз мең. Унбиш пулемёт мең ярым. Барысы йөз дә бер мең ярым.

М и с б а х  х а җ и. Сатулаш, бәлки, төшәрләр.

Н и я з. Шуннан ким бирмиләр.

Н у р е т д и н. Йә җәмәгать, бирә башлагыз. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим, менә егерме биш мең. *(Акча бирә.)*

М и с б а х  х а җ и. Көтәргә бирмиләрме?

Н и я з. Акча, акча кирәк, акча!

Н у р е т д и н. Кая, хаҗи, күпме саласың?

М и с б а х  х а җ и. Янымда барлыгы ун сум килгән.

Н у р е т д и н. Ярый, теге май хисабыннан синең өчен утыз мең бирәм.

М и с б а х  х а җ и. Нишләттең инде син?.. Карт көнеңдә син дә кызыл гвардин булдыңмы?..

Н и я з. Бирәсезме, юкмы?

М и с б а х  х а җ и. Ә, монда биш мең сум бар икән. Кая, җәмәгать, хәлле хәленчә сез дә салыгыз, безне генә саварга димәгәндер бит.

Башкалар да акча салалар.

Н у р е т д и н *(акча санап)*. Булды, менә нәкъ йөз дә бер мең биш йөз сум.

М и с б а х  х а җ и. Алган нәрсәләреңә яздырып счёт ал!

Н и я з *(акчаларны кесәсенә салып)*. Ярый, җәмәгать, теләктә булыгыз. Үлеп-нитеп калып кайтмасам, бәхил булыгыз!..

Б а р ы с ы. Бәхил, бәхил!..

Х ә з р ә т. Җәмәгать, йә, тәкбир!..

Тәкбир әйтәләр. Н и я з чыга. Еракта пулемёт тавышы. «За власть советов» көенә җыр тавышы ишетелә. Тәкбир акрынлана, куркынып бер-берсенә карашалар. Бик каты кычкырып Д и л б ә р керә.

Д и л б ә р. Киләләр, киләләр, матрослар киләләр!

Барысы куркышып катып калалар.

Б а р ы с ы. Тес-с-с!..

Кача башлыйлар. Пулемёт тавышы көчәя.

П ә р д ә.

## БИШЕНЧЕ КАРТИНА

Себер шәһәрләренең берсендә номер. Чемоданнар, кәрзиннәр хәзерләнгән.

I. Нуретдин, Мисбах хаҗи.

Мисбах хаҗи. Сез дурак, сез дурактан битәр мин дурак! Йә, ниемә калган, йорт-җиремне ташлап, чегән төсле, шәһәрдән шәһәргә сөрлегеп йөрү? Йә, ниемә калган?.. Үз иркең белән тот та, бөтен мөлкәтеңне ташла да дуадак күке төсле кит, имеш. Бу да булдымы эш, бу да булдымы акыл, бу да булдымы сәүдәгәрлек! Шулай шул. Алла берәүнең башына бәла җибәрим дисә, иң элек аның акылын алыр, дигәннәр... Бик дөрес... Менә хәзер бөтен мөлкәтеңнән колак кагып, кардәш-кабиләңнән аерылып, тол ата каз төсле, чемоданнар күтәреп йөр инде монда сөйрәлеп! *(Башын тукмаклап.)* Әй син, карт дурак, миңгерәү бүкән, ярык чүлмәк, буш барабан!.. Кайда идең соң син?! Ахыр гомеремдә шул дураклыкны күрсәтер өчен, мин сине алтмыш биш ел буенча муеным өстендә асрадыммыни, дурак, дурак!..

Нуретдин. Болай холыксызлану килешми, хаҗи, бер синең генә башка төшкән бәла түгел, ил белән күтәрәбез.

Мисбах хаҗи. Төкерәм мин синең илеңә! Илеңдә минем ни эшем бар, миңа рәхәт булмагач! Карт хәерче төсле, күпер төбендә үлгәндә, илең минем авызга су салырмы соң?

Батырхан керә.

II. Нуретдин, Мисбах һәм Батырхан.

Батырхан. Әссәламегаләйкем!

Нуретдин. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдүк, Батырхан әфәнде, утырыгыз, шатлыклы яңа хәбәрләр юкмы? Сугыш сафында ниләр бар?

Батырхан. Өфе киткән.

Мисбах хаҗи. Ишкән икән! Без аны синнән башка да ишеттек, киткәнне син әйтмәсәң дә, Аллага шөкер, ишетә торабыз. Алганны син әйт безгә. Моңарчы киткәннәрен Алла кабул итсен.

Нуретдин. Ярсыма, хаҗи. Хуш, хуш, Батырхан әфәнде, хуш.

Батырхан. Чиләбе төбендә бик каты сугышлар бара.

Нуретдин. Шулай укмыни?

М и с б а х  х а җ и. Өфесе дә китәр, Чиләбе дә китәр, Умский да китәр, бөтен Себере дә китәр. Безгә ни эш кала, безгә кая барырга?

Б а т ы р х а н. Тагын да ерагракка күчәргә туры килер.

М и с б а х  х а җ и. Рәхмәт киңәшеңә, акыллы сүзең өчен, Аллаһы Тәгалә келәвез хатынга дучар итсен үзеңне... Тапканнар бер сүз, күчәргә, имеш... Болай да инде күчә-күчә иске күчәр төсле шомарып беттем. Бөтен дөньяны алып бетерсәләр дә, һаман шулай күчерерсезме?..

Б а т ы р х а н. Шуннан башка чара юк, хаҗи әфәнде.

М и с б а х  х а җ и. Чарасы юклыгын синнән башка да беләм. Күчерә-күчерә агач атка атландыруыгызны азсынып, әллә инде йолдызларга атландырмакчы буласызмы?

Н у р е т д и н. Кит, хаҗи, тузга язмаганны, ичмасам, син сөйләмә. Бөтен дөньяны кем бирә аларга! Менә күрегез дә торыгыз, Чиләбе төбендә борыннарын сындырмасалар, башым протестка керсен!

М и с б а х  х а җ и. Бер кат протестка кергән башны икенче кат тагы, хи-хи-хи!..

Н у р е т д и н. Тукта әле, хаҗи, син төшенмисең!

М и с б а х  х а җ и. Төшенгән хәтлесеннән дә ычкына алмыйм, зинһар, яңа башыннан төшендерә күрмәгез инде.

Н у р е т д и н. Соң бит бөтен генераллар, барлык әфисәрләр, адвакатлар, докторлар бу якта. Вакыты җиткәч, шундый кыздыра башларлар, Алла боерса, ул кызыл шәйтаннар Мәскәүне ташлап киткәннәрен дә сизми калырлар.

М и с б а х  х а җ и. Үз сүзен сөйләгән дурак бер генә кат дурак, ди, башка дурак сүзләрен сөйләүче дурак йөз кат дурак, ди. Син, Нуретдин энем, бу юлы соңгысы булып калдың, бигайбә. Соң, кеше сүзен сөйли торган чакмыни!.. Ә менә мин генералларыгызга да ышанмыйм, кызылларыгызга да ышанмыйм. Үз кайгым кайгы. Нигә, миңа димәгәе, җыенысы шунда бергә җәһәннәмгә поход китми! Барысы да — безнең башка бәла булып туган имгәкләр... Инде эшнең төбен уйласаң, барысына да менә моның төсле шартлавыклар, тол пистоннар гаепле. Хөррият, кәмитит, чорт, горт дигән булып, җир өстендәге бәрәкәтне күтәрделәр. Патша начар булган аларга. Патшасыз, кәмитит булып көн күрергә уйлаганнар. Кырдыгыз!.. Туйдан соң дөмбергә дигәндәй, сез ашаганга авыз сөртеп, адашкан эт шикелле йөр монда өстерәлеп.

Н у р е т д и н. Бу шәйтан туе мәңгегә тартылыр дип беләсеңме әллә син?! Большевикларның нинди кош икәнлекләрен халык хәзер үзе дә аңлады инде. Менә, Алла

боерса, киләсе елга шул вакытта, Колчак хәзрәтләре Мәскәүдә патша булып утырмаса, башым протестка керсен!

Мисбах хаҗи. Аңарчы кызыллар муеныңны киссәләр, ни әйтерсең? Хи-хи-хи!.. Әй, нәрсәгә дип тел туздырып карт башың белән малай-салай сүзен сөйләп утырасың иренмичә. Мәскәү, имеш, барып кара, хәзерләгәннәр, ди. Исән-сау абынып, әби-бабайлар янына күмсәләр дә, рәхмәт укырсың әле. Әй син, пугач батыр, тол пистон, каһәр суккыры, нигә телеңне йоттың! Бик шапырына идең бит әле… Рәт калмадымыни! Кая милләтең, кая кәмититең, кая Хәрби Шураң!.. Ходаның хикмәте, бездә рәт бар чагында барысы да бар иде, бездә рәт күренмәгәч, керосин сибелгән кандалалар төсле, әллә кая юкка чыгып беттеләр. Кәмитит тә юк, шурасы да юк…

Батырхан. Ахмак сүзне атаң сөйләсә дә тыңлама, диләр.

Мисбах хаҗи. Ярый, хуш, акыллы сүз ишетик. Кая соң милли кәмитит, шураларың? Йә, кая?

Батырхан. Хәзерге вакытта Русиядәге бөтен татар-төрек милләтен оештыра торган, аларга юл күрсәтә торган Милли Идарә бар.

Мисбах хаҗи. Нәрсә, кем?

Батырхан. Моңарчы исемен дә ишетмәвегез тәәссеф[1].

Мисбах хаҗи. Себер җиленең шаукымыннан колакларым тонса да тонгандыр. Бигайбә, нәрсә, кем дидегез әле?

Батырхан. Милли Идарә.

Мисбах хаҗи. Алаймы?

Батырхан. Шулай.

Мисбах хаҗи. Ярый, ярый, бара торгач, милләткә дә койрык таккансыз икән, энем.

Нуретдин. Куй әле, хаҗи, юк-бар сүзләреңне. Хуш, Батырхан әфәнде, хуш?

Батырхан. Кичә генә әле Милли Идарәнең әгъзалары мөфти хәзрәт белән берлектә Колчак хәзрәтләренең эчке эшләр министры урынбасарының секретарен күреп сөйләштек.

Нуретдин. Хуш, хуш, нигә соң аны баядан бирле әйтми торасыз. Йә, хуш, нәрсә ди?

Батырхан. Эчке эшләр нәзарәте янында милләтләр

---

[1] Тәәссеф — үкенечле, кызганыч.

бүлеге дигән бер бүлек төзергә мөмкин булыр төслерәк сөйләште.

Нуретдин. Менә шул-шул, юньле булсаң, берәү дә читкә какмый. Яхшылап түбәнчелек белән сорый белгәч, бөтен хокукларны бирерләр әле, Алла боерса.

Батырхан. Ләкин хәзерге вакытта Милли Идарәнең матди ягы гаять начар. Тиз арада милләт ярдәм кулын сузмаса, бөтен милли теләкләр харап булачаклар.

Нуретдин. Хуш, ни эшләргә кирәк инде? Нинди ярдәм?

Батырхан. Милли хокуклар бирелсен дисәгез, милләт харап булмасын дисәгез, милли сандык файдасына...

Мисбах хаҗи. Тагын акчамы?

Батырхан. Әйе, акча бирегез!

Мисбах хаҗи *(торып)*. Мишәр әйтмешли, сыптырып каталатсаң үзегезне, яхшы түгел. Кара син, акыллы башлар, бумажникны азсынып, милли сандыкка укябышканнар.

Батырхан. Вакыт мөһим һәм куркынычлы. Акча булганда гына, милли иттифакны, милли мәнфәгатьне саклап кала алачакбыз.

Мисбах хаҗи. Алаймы?

Батырхан. Шулай, хаҗи әфәнде.

Мисбах хаҗи *(кукиш күрсәтеп)*. Менә монысы сәүдәгәр кукишы, ә менә монысы майлы кукиш. *(Ике кулыннан бер кукиш ясап.)* Ә менә монысы иттифаклашкан мәнфәгатьле кукиш!

Батырхан. Алаймы?

Мисбах хаҗи. Шулай!

Батырхан. Ә менә монысы мәдәни кукиш! *(Яңагына суга.)*

Нуретдин. Батырхан әфәнде, бу ни эшегез, сез ни эшлисез?!

Пауза.

Мисбах хаҗи *(Батырханның кулын алып)*. Тот кулны, рәхмәт, энем, билләһи газыйм, чын күңелдән рәхмәтләр укыйм. Бу аз әле. Без дуракларны җиргә яткырып суктырырга кирәк. Ник дисәң, дуракка йодрык кына акыл кертә ала... Без дурак булмасак, сезнең ише тол пистоннар артыннан лагун төсле тагылып йөрер идекме?.. Без дурак булмасак, патша да урынында утырыр иде. Дуракларны яңаклау гына аз. Аларны, яткырып, кабыргалары сынганчы әйтә-әйтә бүсәргә кирәк. Әле шунысына

рәхмәт әйтәм, кем, Нуретдин, яңакласа да, үз кеше яңаклый, большевик түгел. Ни әйтсәң дә, үзебезнең мөселман, милли йодрык, хи-хи-хи!..

Батырхан. Хаҗи әфәнде, зинһар, гафу итегез, кызулык белән булды...

Мисбах хаҗи. Бәхил, билләһи газыйм, бәхил. Береннән алып меңенә кадәр бәхил!.. Үзеңнең тегеләй бармакларың, каләм тотып кына тәрбияләнсәләр дә, шактый салмак икән, хи-хи-хи!..

Батырхан. Хаҗи әфәнде, зинһар, гафу итегез, мин сездән үтенәм.

Мисбах хаҗи. Үтенмә, энем, үкенечкә калырсың. Гомереңдә бер егетлек эшләгәнсең икән, май кап!

Офицер киемендә Давыт керә.

III. Әүвәлгеләр һәм Давыт.

Давыт. Хәерле көн, әфәнделәр!..

Күрешәләр.

Нуретдин. Улым, сугышлар Чиләбе төбендә бара, ди, расмы?

Давыт. Барса бара торгандыр.

Нуретдин. Бу ни була инде?

Давыт. Сугышта стратегиясез булмый.

Батырхан. Гомумән, хәлләр ничегрәк, Давыт әфәнде?

Давыт. Яхшы.

Батырхан. Соңгы көннәрдә хәбәрләр бик буталчык булып күренәләр. Әллә чынлап та?..

Давыт. Хуш?..

Батырхан. Әллә чынлап та киләләрме?..

Нуретдин. Алла сакласын, Алла сакласын. Сез ни сөйлисез, Батырхан әфәнде?

Давыт. Батырхан әфәнде, мондый сөальләр бирүегезгә гаҗәпләнәм. Бөтен мәдәни дөнья безнең белән булган чагында, бер төркем бандитларның үлем алдында тыпырчынуларын әле һаман да күрмисезмени?

Батырхан. Анысы шулай да бит, Уфаның китүе бик шомландыра.

Давыт. Күңелеңне тыныч тот, Батырхан әфәнде. Биш айдан соң Мәскәүдә, конституционный монарх исәнлегенә бокал күтәргәндә, бу көнге куркуларың өчен кызарырга туры килмәсен сиңа.

Б а т ы р х а н. Алаен алай да, яшерен хәбәрләргә караганда, Чиләбе төбендә алар искиткеч көч белән, коточкыч дәрәҗәдә сугышалар, ди.

Д а в ы т. Әнә аларның соңгы тыпырчынулары шунда инде. Безгә аларның бөтен көчләрен бер җиргә җыярга кирәк иде. Менә хәзер алар Чиләбе төбенә җыелып җиттеләр. Бүген-иртәгә безнең тарафтан бирелгән бер удар бөтен большевизмны Урал таулары итәгендә күмәчәк. Шуннан соң Мәскәүгә барып керергә генә кала. Соң, үзегез уйлап карагыз! Азыклары юк, киемнәре юк, кораллары юк; нәрсә белән сугышырга кирәк! Бөтен өязләрдә, авылларда сәнәкчеләр продналог отрядларын кырып бетергәннәр. Хәзерге вакытта Сембер, Самар, Воронеж, Тамбов губерналары сәнәкчеләр кулында. Мәскәү ут эчендә… Петроград камалган. Шулай, Батырхан әфәнде, яңа Россия яңартылган җир төсле яңарып, чистарып калачак… Әткәй, мин командировка алдым. Бәлки, тиз генә күрешә дә алмабыз. Миңа бераз акча кирәк иде.

Н у р е т д и н. Әллә фронтка озаталармы?

Д а в ы т. Юк. Безнең тылга берничә большевик бандитлары үтеп, партизан отрядлары төзегәннәр, авылларда коткы салып йөриләр икән. Шул бандитларны атарга, авылларны тынычландырырга безнең эскадронга приказ булды. Дилбәр кая?

Н у р е т д и н. Иртә белән чыгып киткән иде. Кайтмаган, күрәсең.

Ф ә т т а х керә.

IV. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Ф ә т т а х.

Ф ә т т а х. Әссәламегаләйкем, исәнме, байлар!

Н у р е т д и н. Әйдә, Фәттахетдин, әйдә, йә, ниләр бар?

Ф ә т т а х. Биш вагон дигәннәре ике генә булып чыкты. Менә образчыгы!

М и с б а х х а җ и. Кая, кая? *(Чәйне чәйнәп.)* Урта күренә. Бәһа?

Ф ә т т а х. Бәһа турында сорамагыз да, мөф инде, мөф!.. Ычкындырырга ярамый, байлар, башкалар сизмәс борын тибәргә кирәк.

Н у р е т д и н. Казна малы түгелдер бит?

Ф ә т т а х. Ниткән казна малы булсын. Вагоннарында кытайлары да утырып торалар.

М и с б а х х а җ и. Казна малы булса ни булган… Казна малында бәрәкәт тә хәзер…

Фəттах. Ниятегез булса ашыгыйк, байлар, извозчик көтеп тора.

Нуретдин. Карарга кирәк булыр. Улым, акча дигән идеңме?

Давыт. Әйе.

Нуретдин. Ярый, әйдә безнең белән, нинди чәй икән? Батырхан әфәнде, вакытыгыз сыйдырса бездә калыгыз. Озакламыйча Дилбәр дә кайтыр.

Батырхан. Ярый, ярый, минем язасы нәрсәләрем дә бар иде, хушыгыз, Давыт әфәнде, муаффәкыять[1] телим.

Давыт. Рәхмәт, хушыгыз! *(Чыгалар.)*

Батырхан, идән буйлап озак йөреп утыра. Язарга керешә. «Шарабан» җырлап, Сәхипгәрәй керә.

V. Батырхан һәм Сәхипгәрәй.

Сәхипгәрәй *(җырлый).*

А ну, лошадка, трогай, трогай
По сибирскою дорогой,
Ах, шарабан мой, шарабан,
Я мальчишка шарлатан...

Ә Батырхан әфәнде, җаныем, бәгырем, син һаман мондамыни әле? Исәнме, яхшымы, исәнме, матурым, саумы?

Куда ветер, туда я,
Галиябану сылуым-иркәм,
Балдызым, ялгызым, җизнәкәй...

«Шарабан» көенә.

Прощайте, други, я уезжаю
И шарабан мой я вам завещаю.
Ах, шарабан...

Кая соң болар? Хуҗалар кая? Дилбәр туташ, Давыт кая?..

Батырхан. Давыт хәзер генә монда иде, чыгып китте.

Сәхипгәрәй. Син өй саклап калдыңмы? Мин күрешеп, бәхилләшеп, исәнлектә-саулыкта, юл сәфәренә, юл сәфәренә, сәфәр чыкмакчы булып, сәфәрләшергә килдем... *(Җырлый.)*

Вместо сигар, эх, тарый-барый
Хотят дать нам коммунары.
Ах, шарабан...

*(Җыр ахырын җырлап бетерә. Елый.)*

---

[1] Муаффәкыять – уңыш.

Б а т ы р х а н. Сәхипгәрәй әфәнде, ятып йоклап алыгыз.

С ә х и п г ә р ә й. Булмый, булмый, йоклап та, елап та булмый… Беттек бит, беттек, хур булып, мәсхәрә булып, адәм көлкесе булып беттек бит, Батырхан әфәнде… Соңгы көннәрнең соңгы сәгатьләрен аракыга батырабыз… Мин гомеремдә аракыны авызыма алган кеше түгел… Сәламәтлегем югалмасын, дидем, гимнастика ясап, мускуллар үстердем… Таза, сау, шат булып дөньяда торасым килде… а вон поди, большевик үтермәкче була… Нигә ул мине үтерә, сукин сын? Мин бит гимназист чагымда социалистлар кружокларында эшләдем. Прокламацияләр тараттым, комитетларга, съездларга сайландым. Мин бит монархист түгел!.. Үткән көннәрнең күләгәләрендә үземнең собственный утарымда хәл җыясым килә… Мин укыдым, мин тырыштым, мин ватанга, патшага, халыкка хезмәт итәргә тиешме, түгелме?.. *(Җырлый.)*

Ах, шарабан мой…

Йә Батырхан әфәнде, шуннан соң?

Б а т ы р х а н. Ятыгыз, Сәхипгәрәй әфәнде!

С ә х и п г ә р ә й. Сез мине аңламыйсыз, аңламыйсыз! Уф-ф!

Б а т ы р х а н. Мин сезне аңлыйм. Матди һәм мәгънәви бөлгенлекне хис итүе авыр.

С ә х и п г ә р ә й. Әй, сезгә нәрсә, и так хорошо, и так недурно.

Б а т ы р х а н. Миңа яраган нигә сезгә ярамый?

С ә х и п г ә р ә й. Ярамый шул, ярамый. Ярамаганга ярамый… ярамый!.. Черньның[1] миңа баш булуын каным күтәрә алмый. Каппл дивизиясендә чагында Самар төбендә атылган крестьяннарның күз карашлары… ух, ул минутлар!.. Мин «җир – крестьяннарга» дип, менә шул куллар белән прокламацияләр таратучы мин! Шул ук крестьяннарның күкрәкләренә төзәлгән пулемётны менә шул ук кулларым белән борып тордым…

Б а т ы р х а н. Да!

С ә х и п г ә р ә й. Раз алда үлем, эчәргә кирәк, артта үлем, эчәргә кирәк. До победного конца эчәргә кирәк. Эчүдә генә табарсың син үз хакыңны! Дурак!.. Әйдә, акыллым, аек дурактан исерек дурак акыллырак, әйдә, киттек, дурак!.. *(«Шарабан» җырлап чыга.)*

Б а т ы р х а н *(идән буйлап йөри. Ширма артына караватка барып ята)*. Чынлап та, аек дурактан исерек

---

[1] Ч е р н ь – кара халык.

дурак акыллырак... Их, менә шулай ятып йокыга киткән иде дә йөз елдан уянсаң иде! Уһу-һу-һу!.. *(Йокыга китә.)*

Зур пауза.

VI. Батырхан, Дилбәр һәм Нияз.

Нияз. Нуретдин әфәнделәр кая болай төялеп киттеләр икән?

Дилбәр. Милли Идарәгә яисә берәр сәүдә эше белән киткәннәрдер. Йә Нияз әфәнде, хикәягезне сөйләп бетермәдегез бит.

Нияз. Хикәя түгел, Дилбәр туташ, үз башымнан кичкән вакыйга.

Дилбәр. Хуш?

Нияз. Шул... Алты пулемёт белән иллегә якын кызылармеецларны плен алып штабка китереп тапшырдым.

Дилбәр. Карагыз әле, Нияз әфәнде, үз шәһәребездә чакта мин сезне гаскәри дип тә белмидер идем. Ә сез чын каһарман әфисәр икәнсез ләбаса.

Нияз. Ерак сәфәр кешеләрне таныта да, дуслаштыра да, Дилбәр туташ. Ул чакларда мин дә сезгә якын барырга батырчылык итми идем. Сәфәр интересларының берлеге миңа көч, гайрәт бирде. *(Төргәккә күзе төшеп.)* Бу нәрсә?

Дилбәр. Бу — Америкадан килгән крепдешин, көчкә-көчкә генә бер платьелык алып калдым.

Нияз. Шулай ук бик зарурмыни?

Дилбәр. Мәскәүгә кайткач, без, эмигранткалар, барыбыз бертөсле платьелардан, бертөсле киенеп грандиозный бал ясамакчы булабыз. Вакыт җитеп бара. Иртәгә эмигранткаларның җыелышы булачак. Шунда фасон сайларга булдык.

Нияз. Кайчан Мәскәүгә кайтырбыз дип уйлыйсыз?

Дилбәр. Аермачык әйтүе кыен. Шулай да ике-өч айдан кайтырбыз дип уйлыйбыз. Анысы инде, Нияз әфәнде, сездән, әфисәрләрдән зависит... Ике атнадан кайтарасыз икән, без әзер.

Нияз. Мин дә әзер, Дилбәр туташ, Мәскәүгә генә түгел, дөньяның койрыгына кадәр сезнең белән барырга әзер. Мин, Дилбәр туташ, боргаланып-сыргаланып ике сөйләргә яратмыйм. Мин гаскәри кеше — раз, два и готово!.. Мин, Дилбәр туташ, сезне туганнан бирле яратып йөрим... Менә бу куллар, бу беләкләр... *(Үбә.)*

Дилбәр *(торып)*. Нияз әфәнде, ярамый!

Н и я з. Юк, ул ярарга тиеш. Сез минем гомерлек юлдашым булырга тиешсез! Мин, шул сөальгә җавап алмыйча, бу бүлмәдән чыгачак түгелмен. Җавап бирегез. *(Кочакламакчы була.)*

Д и л б ә р. Ярамый, ярамый, Нияз әфәнде. Мине бүлмәдән качарга мәҗбүр итмәгез!

Н и я з. Сез миңа бүген, хәзер катгый җавап бирергә тиешсез. Туган көннән бирле шашып яратуымның бүләген бүген сездән алырга тиешмен. Җавап бирегез...

Д и л б ә р. Акылыгызны башыгызга җыегыз, Нияз әфәнде.

Н и я з. Миңа хәзер акыл да, оят та, вөҗдан да — берсе дә кирәк түгел. Миңа сез кирәк, сез җавап бирегез! *(Кочаклап кыса.)*

Д и л б ә р *(кычкырып, ычкынып)*. Артыгракка китү инде бу!.. Үзегезне тота белмәгәч, мин сезнең белән бүлмәдә кала алмыйм!..

Чыкмакчы була. Нияз, аны көч белән тартып алып, ишекне бикли.

Н и я з. Менә күрәсез, ишекнең ачкычы миндә, сез хәзер чыга алмыйсыз. Әгәр дә минем мәхәббәтемә җавап бирмисез икән, мин моннан үз ихтыярым белән чыгачак түгелмен... Җавап бирегез!

Д и л б ә р. Ишекләр бикләп кенә, мине куркыта алмассыз!.. Ачыгыз хәзер ишекне! Югыйсә мин!..

Н и я з. Юк, юк, Дилбәр җаным. Мин сезне куркытырга теләмим, мин сезнең аяк астыгызда шулай, менә шулай утырасым гына килә. Дилбәр җаным, әйтегез, мине сөясезме? Әйтегез, сөясезме?

Д и л б ә р. Бүген мин сезгә бер сүз дә әйтә алмыйм.

Н и я з. Кайчан әйтерсез?

Д и л б ә р. Бер туры килгәндә.

Н и я з. Вәгъдәме?

Д и л б ә р. Әйе.

Н и я з. Вәгъдәгезнең ныклыгын менә шушы берлиант йөзегегез белән раслагыз!

Көчләп йөзеген салдырып үз бармагына кия.

Д и л б ә р. Сез нишлисез, Нияз әфәнде, акылыгыздамы сез?

Н и я з. Гафу итегез, җаным, вәгъдәгезнең ныклыгын раслау өчен кирәк ул миңа... Дилбәр бәгырем, Дилбәр акыллым... *(Энҗе бавы белән уйнап.)* Әгәр дә сез минем күңелемдәге уйларны белсәгез иде, әгәр дә белсәгез иде...

Юк, сез белмисез дә, беләсегез дә килми... Менә шушы энҗе бөртекләре шикелле тезелеп торган, тезелеп-тезелеп торган... *(Энҗене кинәт өзеп ала.)*

Д и л б ә р. Ах, бу ни эшләвегез!..

Батырхан уянып карап тора.

Н и я з. Тс-с-с!.. Сөйгәнлектән, бәгырем, сөйгәнлектән.

Д и л б ә р. Хәзер кайтарыгыз энҗемне, юкса...

Н и я з. Тс-с-с! Энҗеләрегезне заложник итеп алдым. Минем мәхәббәтемә җавап биргән сәгатьтә энҗеләрегез кире кайтачак.

Д и л б ә р. Шаяртмагыз, Нияз әфәнде! Сезнең бу кыланышларыгыз мине шөбһәләндерә башлады!..

Н и я з. Шөбһәләрегезне бетерергә мөмкин!..

Кочаклап, көчләп үбә. Диванга ега, тартышалар.

Карышмагыз, бирелегез, бирелегез!..

Д и л б ә р. Коткарыгыз, коткар! Караул!..

Н и я з *(авызын каплап)*. Карышмагыз, бирелегез!..

Б а т ы р х а н *(Ниязның җилкәсеннән эләктереп, ишеккә этеп җибәрә)*. Нахал, хулиган!

Н и я з *(наганын чыгарып)*. Сез кем?! Кузгалмагыз урыныгыздан! *(Ишекне ачып, бикләп чыгып китә.)*

Д и л б ә р *(бикле ишеккә бәрә-бәрә)*. Энҗеләрем, йөзегем, караул!..

Б а т ы р х а н. Куегыз, чуалмагыз шул хулиган бандит белән!.. *(Диванга утырта.)* Юк өчен борчылмагыз!..

Д и л б ә р *(елап)*. Рәхмәт, Батырхан әфәнде, рәхмәт, сез мине коткардыгыз!.. Ничек Алла сезне болай туры китерде.

Б а т ы р х а н. Тынычланыгыз, Дилбәр туташ.

Д и л б ә р. Энҗеләрем, йөзегем, әтигә ни әйтермен?! *(Елый.)*

Б а т ы р х а н. Берни дә әйтмәссез!.. Борчылмагыз!..

Д и л б ә р. Талады бит ул мине, талады, хулиган... Әнкәйнең төсе итеп саклаган йөзегемне... *(Елый.)* Ярый әле, сез булдыгыз...

Б а т ы р х а н. Яман эшкә караганда яхшы йокы хәерлерәк икән, Дилбәр туташ.

Д и л б ә р. Йокы?!

Б а т ы р х а н. Гафу итегез, Дилбәр туташ, мин монда йөз елдан соң уянырга дип яткан идем, йөз минут та үтмәде, уяттыгыз!

Д и л б ә р. Гафу итегез, Батырхан әфәнде, әфисәр булгач, бандит дип кем уйлар аны.

Б а т ы р х а н. Күрәсең ич.

Ишек артында Нуретдин тавышы.

Н у р е т д и н. Ачыгыз, ач!.. Харап, харап, ачыгыз, кем анда?!

Д и л б ә р. Әткәй тавышы... *(Ишеккә барып.)* Ах, хулиган, нахал, өстән бикләп киткән... Әткәй, әткәй!..

Н у р е т д и н. Ачыгыз, ач!.. Харап, харап!..

Б а т ы р х а н. Нуретдин әфәнде, Нуретдин әфәнде, әү!.. Ватып керегез, ватып!..

Ишек вата башлыйлар, Н у р е т д и н керә.

VII. Б а т ы р х а н, Д и л б ә р һәм Н у р е т д и н.

Н у р е т д и н. Харап, харап, кызым, харап!.. Батырхан әфәнде, кем бикләде, бу ни эш?! Харап, Чиләбе киткән!

Д и л б ә р. Киткән?!

Н у р е т д и н. Киткән, киткән, туры монда киләләр, ди. Алдагы юлны кызыл партизаннар кискәннәр, ди... Харап, харап! Әйдә, җый нәрсәләреңне, киттек!.. *(Чемоданнарын күтәреп чыкканда кире кайтып.)* Батырхан әфәнде, нәрсә карап торасыз, кызыллар килә бит!..

Б а т ы р х а н. Мин монда калам.

Д и л б ә р.<br>Н у р е т д и н. } Нәрсә?..

Урамда «Шарабан» җырлап офицерлар үтәләр.

Н у р е т д и н. Әйдәгез, әйдә, киләләр, киләләр! Керәләр!..

Батырхан өстенә чемоданнар өеп, шаулатып, буталып чыгалар.

М и с б а х *(чемоданнар күтәреп кереп)*. Тагын күчәргә!.. *(Чыгып китә.)*

П ә р д ә.

## АЛТЫНЧЫ КАРТИНА

Учреждениедә кабинет. Б а т ы р х а н эшләп утыра. Р а у з а керә.

I. Б а т ы р х а н, Р а у з а.

Р а у з а. Ситдиков иптәш. Исемегез турында тагы бер буталу чыкты. Яңа документларыгызда исемегез Батыр-

җан дип күрсәтелгән, бөтен иске документларыгызда Батырхан дип язылган. Шуларның кайсы дөрес?

Б а т ы р х а н. Ничек?

Р а у з а. Батырханмы? Батырҗанмы?

Б а т ы р х а н. Хан белән минем арада нинди мөнәсәбәт булуы мөмкин. Контр «х»ның астына кызыл нокта утыртканыма бер елдан ашып китте инде. Феодал хан белән интернационал «җан» арасында аерма булырга кирәк бит... Моннан соң документлар-фәләннәр дип волокита тудырасы булмагыз, Батырҗан Ситдиков, вәссәлам.

Р а у з а. Болай булгач, сезнең бөтен контр «х»ларыгыз астына кызыл ноктала куеп чыгарга туры килер.

Б а т ы р х а н. Туры килер түгел, кирәк булыр. Барыгыз!..

Р а у з а чыга, Д а в ы т керә.

II. Б а т ы р х а н, Д а в ы т.

Д а в ы т. Мөмкинме?

Б а т ы р х а н *(эштән башын күтәрмичә генә)*. Рәхим итегез!

Д а в ы т. Батырхан әфәнде...

Б а т ы р х а н *(башын күтәреп)*. Тукта, тукта, Давыт әфәнде!.. Сез ничек болай?.. Рәхим итегез, утырыгыз!..

Д а в ы т. Рәхмәт.

Б а т ы р х а н. Ничек болай?.. Кайчан кайттыгыз?.. Легальныймы... Әллә?..

Д а в ы т. Документлар буенча легальный, әмма үзем... *(Җилкәләрен уйната.)*

Б а т ы р х а н. Шулаймыни?.. Йә, шуннан?

Д а в ы т. Артык бетергән эш юк.

III. Б а т ы р х а н, Д а в ы т һәм Р а у з а.

Р а у з а. Батырҗан иптәш, кул гына куеп җибәрегез, регистратурага бирергә кирәк.

Б а т ы р х а н кул куя.
Р а у з а чыга.

Д а в ы т. Әллә исемегезне алмаштырдыгызмы?..

Б а т ы р х а н. Пышылдамыйча, теләгәнчә кычкырып сөйләшергә мөмкин, йә Давыт әфәнде, шуннан соң? Бик кызык очрашу булды бу. Дилбәр туташ та кайттымы?

Д а в ы т. Әйе.

Б а т ы р х а н. Йә, шуннан соң?

Д а в ы т. Мин, Батырхан әфәнде, теге вакыттан бирле урынсыз йөрим. Советлар иленең бер гражданы буласым килә һәм кулдан килгән хезмәтне — халык өчен дисезме, эшче-крестьян өчен дисезме — үтисем килә.

Б а т ы р х а н. Шулаймы?..

Д а в ы т. Минемчә, татар спецларына тоткарсыз эш бирелергә тиеш. Мәскәү бит хәзер спецларга бөтенләй икенче күз белән карый башлады.

Б а т ы р х а н. Мәскәү карар ул. Мәскәү ерак бит, Давыт әфәнде. Мәскәүдә һәрбер кызыл авыз кулына күсәк тоттырмыйлар. Ә монда бездә эшләр башкачарак. Малай-шалайлар белән көрәшеп көннәр уздырабыз. Кеше юк. Ярдәмчеләр, үз кешеләр кирәк.

Д а в ы т. Ничек уйлыйсыз, Батырхан әфәнде, миңа монда берәр яры урнашырга булырмы икән?

Б а т ы р х а н. Мин үзем белемнәре, эшләре белән безгә кирәк булган төрек-татар укымышлыларын һичбер вакыт читкә какканым юк. Ләкин безнең арабызда мәсьәләгә тар караштa булучылар да юк түгел.

Д а в ы т. Нигә инде ул алай?

Б а т ы р х а н. Янәсе, Советларга үч итеп бер тапкыр җимергән илне төзәтүне менә сезнең шикеллеләр кулына тапшырырга мөмкин түгел, имеш.

Д а в ы т. Минемчә, Советлар власте аерым кешеләрдән курку дәрәҗәсеннән узган инде хәзер.

Б а т ы р х а н. Сез шулай уйлыйсызмы?

Д а в ы т. Бүген шулай бит. Ә иртәгәге өчен алдан бернәрсә дә әйтеп булмый. Всё течёт, всё меняется, ди Гегель.

Б а т ы р х а н. Әйткәндер, әйткәндер. Ә сезнең үз карашыгыз ничек?

Д а в ы т. Миңа хәзер ачыктан-ачык контрреволюция ясаудан бер файда да юк. Мин алпавыт түгел, шулай ук кайтарачак йортларым да юк. Минем бөтен байлыгым, үзегезгә билгеле, товарда, оборотта иде. Переворот ясап, аны һичбер кемнән түләтә алмауга да күзем җитә.

Б а т ы р х а н. Дөрес, фикерегез туры... Шулай да... Әгәр дә сезгә мондый сорау куйсалар...

Д а в ы т. Хуш?

Б а т ы р х а н. Сезнең малларыгыз Колчакка хәтле үк киткән иде. Шулай да Колчакта карательный отряд башында торып, Себер авылларында крестьяннарны бугазлап йөргәнсез, дисәләр... ни әйтерсез?..

Д а в ы т. Мин ул эшләрне агымга ияреп эшләнгән акылсызлык дип кенә карыйм. Сезнең дә бит, Батырхан

әфәнде, үткәнегез, большевиклар күзеннән караганда, бик үк шәптән түгел.

Батырхан. Минем магазиннарым, фабрикаларым юк иде, Давыт әфәнде.

Давыт. Ә дин төзәтүче булу, Пуришкевич, Марков Второйлар белән бергә Дәүләт Думасында янәшә утырырга уйлау, шул ук Советлар властена каршы оештырылган агымнарның илһамчыларыннан берсе булу, Себердә Милли Идарә исеменнән Колчак ишеге төбендә большевикларга каршы милли полклар төзергә йөрүләрегез сезнең монда утыруыгызга уңайсызламаган күренә.

Батырхан. Кояшта да андый гына тап бар, Давыт әфәнде. Үткәндәге эшләремне искә төшерүдән теләгегез нәрсә икәнен белергә мөмкинме?

Давыт. Юк, һичбер яман теләгем юк. Сез минем Колчакта карательный отрядта эшләвемне хәтергә алгач, сүз уңае килеп әйтүем генә булды.

Батырхан. Сунарчы сунарчыны ерактан таный, дигәннәр бәхетле бабайлар димәкчесеңдер, шулаймы?

Давыт. Дөрес.

Батырхан. Буталчык суда балык тотуы уңайлырак, дигәннәр картлар. Безгә хәзер сезнең шикелле спецлар бик кирәк. Мин сезне үзебездә калдырырга тырышырмын. Булмаса, башка җиргә урнаштырырга да мөмкин булыр. Ләкин сез мине, мин сезне белмик. Хәтта без сезнең белән таныш та түгел. Шулай яхшырак булыр. Менә адресым, кичкә фатирыма килегез. Миңа баруыгызны өйдәгеләрегез дә белмәсеннәр. Хәзергә хушыгыз... Сәгать уннарда мин сезне көтәрмен. Менә шунда сезне легальләштерү турында да уйлашып карарбыз... Хушыгыз!..

Давыт. Рәхмәт. *(Кул биреп, чыгып китә.)*

Батырхан *(идән буйлап йөренә. Зур пауза. Телефонда)*. 8-16... Мәрдан, синме?.. Син кичкә миңа килә алмассыңмы?.. Ә?.. Утырыштан соң булса да кереп чык. Мин сине бер кош белән таныштырырмын. Ә?.. Ышанычлы, ышанычлы... Файдаланырга мөмкин булачак, ярый. *(Утырып яза башлый.)*

Мисбах шаулап, талашып керә.

IV. Батырхан, Мисбах хаҗи һәм Рауза.

Мисбах хаҗи. Тукта, кызый, канатларыңны бик җәймә алай. Син граждан булсаң, мин дә граждан. Әлхәмделилла, советский. Йомышым булгач, монда килми кая барыйм!

Р а у з а. Вакытында килергә кирәк. Күрәсез бит, сәгать өч инде.

М и с б а х  х а җ и. Сезнең шәйтан вакытларыгызда минем эшем юк. Үз вакытым вакыт. Өйләдән чыгып килешем.

Б а т ы р х а н. Җибәрегез, керсен!

М и с б а х  х а җ и. Әнә юньле кеше нәрсә ди. Әссәламегаләйкем!

Р а у з а чыгып китә.

Б а т ы р х а н. Йомышыгызны әйтегез!

М и с б а х  х а җ и. Хәзер әйтербез, Алла боерса, хәзер әйтербез. *(Утыра.)*

Б а т ы р х а н. Йә?

М и с б а х  х а җ и. Мин йортларны кайтара торган комиссиягә... Машалла!.. Чү, чү, сөбханалла!.. Син соң теге, кем, ни түгелме? Йә Ходай, син ич!

Б а т ы р х а н. Йомышыгызны әйтегез!

М и с б а х  х а җ и. Әйтербез, әйтербез, Алла боерса. Кая, кил, күрешик. Исәнме, саумы?.. Кызыл түрә дә булдыңмыни?.. Ярый, ярый, бәрәкаллаһ. Укыган кеше – ике яклы пычак шул. Тегеләй дә кисә, болай да юна, хи-хи-хи!.. Ярый, ярый.

Б а т ы р х а н. Сезгә ни кирәк?

М и с б а х  х а җ и. Юк, әле шуны әйтәм: теге чагында милләт дигән пычак белән кисә идең. Коммунист дигән пәкең дә бар икән ләбаса синең. Безнең өчен, ни әйтсәң дә, урыс түрәсеннән мөселман түрәсе яхшырак инде. Ике як белән кисәбез, диең, ә? Машалла, машалла... Ә менә без укымаган надан булгач, рәтен-чиратын абайламагач, утка кергән күбәләк төсле өтелдек тә калдык. Уңнан да өттеләр, сулдан да өттеләр; милләтегез белән дә өттегез, Колчак белән йонны теттегез. Шулкадәр өтелдек, кем, егет, тәмугта янарлык йоныбыз да калмады, хи-хи-хи!..

Б а т ы р х а н. Йомышыгыз нәрсә?

М и с б а х  х а җ и. Мин түбән урамдагы йортымның үземә кайтарылуын сорап йортларны кайтара торган комиссиягә прошение биргән идем. Юләр әйтмешли, бер ел үтте инде, прошением дә юк, җавабы да юк, йортым да юк. Бу ни хәл бу? Артыннан йөреп, менә Алла хәзер, ике кием киезката туздырдым.

Б а т ы р х а н. Йортыгыз зурмы?

М и с б а х  х а җ и. Кечкенә, бик кечкенә. Йорт дип әйтерлеге дә юк.

Б а т ы р х а н. Ничә катлы?

М и с б а х  х а җ и. Кат саны күп аның. Өч катлы, үзе кечкенә.

Б а т ы р х а н. Ничә квартиры бар?

М и с б а х  х а җ и. Саный башласаң, фатир саны да ишле аның, фатирлары кечкенә, шырпы тартмасы хәтле генә.

Б а т ы р х а н. Алай да ничә фатир?

М и с б а х  х а җ и. Бик каһәрләп санасаң, дүрт, биш, алты, җиде фатирга тулыр, бәлки.

Б а т ы р х а н. Ничә тәрәзәсе бар?

М и с б а х  х а җ и. Исәпкә күп. Ләкин аның биш тәрәзәсеннән бер зур тәрәзә чыгармы икән, валлаһе әгъләм.

Б а т ы р х а н. Ни өчен кайтармакчы буласыз?

М и с б а х  х а җ и. Күз-колак булмагач, искереп эштән чыгып бетә.

Б а т ы р х а н. Ярый, бер атнадан җавабына килерсез.

М и с б а х  х а җ и. Кем, син, зинһар, минем кулны тота күр инде. Мин, теге Ибраһим бай төсле, хөрриятттән файдаланып өйләнмәдем дә, милләтегезгә дә, шураларыгызга да, үзеңнең кәмититкә дә сораганын һаман бирә килдем.

Б а т ы р х а н. Ярый, ярый, бетте, чыгыгыз!

М и с б а х  х а җ и. Караштыра күр инде... Тау тау белән очрашмаса да, кеше кеше белән очраша, дигәннәр... Карый күр!.. *(Чыга.)*

Р а у з а ашыгып керә.

V. Б а т ы р х а н, Р а у з а, С ө н г а т ь һәм б а ш к а л а р.

Р а у з а *(каушап кереп)*. Үзәктән инструктор килгән, безнең бүлекне сораша.

Б а т ы р х а н. Үзәктән инструктор?!

Р а у з а. Әнә монда керәләр!

С ө н г а т ь берничә кеше белән керә.

С ө н г а т ь. Исәнмесез, иптәшләр!

Б а т ы р х а н. Исәнмесез, рәхим итегез!

С ө н г а т ь. Бүлек башлыгы мондамы?

Б а т ы р х а н. Юк. Урынбасары мин булам.

С ө н г а т ь. Таныш булыйк, Сөнгать Сәйфетдинов. *(Гаҗәпләнеп, аптырап кала.)*

Б а т ы р х а н. Батырҗан Ситдиков.

Сөнгать. Батырҗан, дисезме?! *(Гаҗәпләнеп карый.)*

Батырхан. Әйе, Батырҗан.

Сөнгать. Тукта, тукта, сез теге Батырхан әфәнде түгелме соң?

Батырхан. Әйе шул, Сөнгать иптәш, онытмагансыз икән.

Сөнгать. Сез алай тиз генә онытыла торганнардан түгел бит, Батырхан әфәнде… Ә… Монда эшлисезме?

Батырхан. Икенче ел инде.

Сөнгать. Икенче ел?!

Батырхан. Әйе, икенче ел.

Сөнгать. Бүлек башлыгы булыпмы? Ячейка секретаре белән директорыгызны чакырып килегез әле.

Башкалар чыгып китәләр.

Сөнгать. Гаҗәп!

Батырхан. Гаҗәп!

Сөнгать. Әйе, бик гаҗәп! Сезне бит, Семёнов отрядына кушылып Кытайга киткән, дигәннәр иде.

Батырхан. Уйлаганым да юк. Гомумән, Семёнов отряды белән минем һичбер вакыт һичбер төрле мөнәсәбәттә булганым юк.

Сөнгать. Милли Идарә әгъзалары башында генерал Семёновка ипи-тоз тотып сәдакать игълан итеп баруыгызны, бәлки, хәтерли торгансыздыр?..

Батырхан. Агымга иярелгән ялгышу гына ул. Хәер, ул ахмаклыкларның берсен дә Совет властеннан яшермәдем.

Сөнгать. Гаҗәп!..

Батырхан. Нигә болай гаҗәпләнәсез, Сөнгать иптәш? Акылы сәламәт кешегә, үткәндәге бөтен хаталарыннан кайтып, тәүбә итеп, туры юлга керергә ярамыймыни?..

Сөнгать. Нигә ярамасын, бик ярый. Ләкин ул ярау кешеләрнең йөрәкләре төсле үк серле һәм катлаулы була. Хәер, бу турыда икенче урында яхшылап сөйләшергә кирәк булыр… Рәхим итегез, нигә басып торасыз!.. Рәхим итегез! *(Урын күрсәтә.)*

Батырхан торып шашынып кала.

Пәрдә.

## ҖИДЕНЧЕ КАРТИНА

Бай кабинеты.

I. З ә й н е т д и н һәм Д и л б ә р.

З ә й н е т д и н *(язу өстәле янында утырып, язулар карый. Счёт сала)*. Хатын!.. Дилбәр, Диллүс!.. Баядирка, чукрак чучка, чык монда!..

Д и л б ә р *(кереп)*. Юньле кылан. Тупасланмасаң да, тупаслыгың җитәрлек.

З ә й н е т д и н. Ай Алла, Баядирка дию тупаслыкмыни? Баядирка дип үзең шаштың ич...

Д и л б ә р. Ярый, ярый, паяцланып утырмасана! Ни кирәк?

З ә й н е т д и н. Ай-яй, бер дә серкәң су күтәрми икән синең, болай булгач, карт хатынны кайтармый да булмас, ахры.

Д и л б ә р. Ярый, кайтарсаң кайтарырсың... *(Чыга башлый.)*

З ә й н е т д и н. Бетте, бетте, Баядирка җанкисәгем, сылуым, иркәм, бетте. Син булганда, карт хатыннар өшкергән инде.

Д и л б ә р. Нәрсә кирәк соң сиңа?

З ә й н е т д и н. Чәпчемә, чәпчемә, менә шул вексельне карап чык әле. Фәлшесе юкмы икән?

Д и л б ә р. Кара әле, Зәйнетдин, шул вексельләрең белән башымны катырмасана, рәтләренә төшенә алмыйм.

З ә й н е т д и н. Төшенә алмыйм, ха-ха-ха!.. Мин төшенәм ич, гимназияләрдә укымадым, университетка да кермәдем, простой школга да йөрмәдем... Вексель фәлшесен дә сизәрлек булмагач, гимназия бетерүеңдә ни файда соң?

Д и л б ә р. Әй, базар татары төсле башымны катырма әле.

З ә й н е т д и н. Базар татарында хикмәт, Биби Баядирка җанкисәгем, Дилбәрбану, сылуым, иркәм, базар татарында хикмәт. Сезнең тирәдән бәрәкәт очты инде хәзер. *(Күкрәгенә сугып.)* Нэп абзаңда хикмәт, нэпта!.. Давыт каенагайны әйтәм әле, Мәскәүдә укыган бит. Шулай булса да, сукыр бер тиенлек базар бәрәкәтен аңлый алмый. Хәзер шул вагонлап-вагонлап мал җибәреп торучы Коншоннар да, Морозовлар да, Сендельләр дә юк. Өшкергән хәзер алар, җанкисәгем, өшкергән. Хәзерге заманда җиде кат су, җиде кат ут кичеп товар табыла. Кая киттең инде!.. Утыр дигәч утыр!..

Д и л б ә р. Курчак төсле каршында утырырга эшем бар минем.

З ә й н е т д и н. Утыр, Нирон Лазаричка хат яз!

Д и л б ә р *(утырып)*. Йә?..

З ә й н е т д и н. Җибәргән малларыңны һәм дружеский вексельләреңне алдым, диген. *(Кашына.)* Атна-ун көн эчендә яңадан акча һәм соратканың хәтле дружеский вексельләр җибәрермен, диген. Ахырга «эс товарищеским приветом» дип куй. Кулны үзем куярмын. Менә, Алла боерса, киләсе баруда Мәскәүдән яза торган машина алып кайтырмын. Тәкелдәт тә тәкелдәт аннары. Фасоның да килә!.. Нәкъ коеп куйган... Машинада язуны булдыра torгансыңдыр бит.

Д и л б ә р. Әй, куй әле, зиһенемне таратма!

З ә й н е т д и н. Пианинода уйный ала торган бармаклар машинада да уйнар әле... *(Тәмәке каба.)* Кая, шырпы бир!

Д и л б ә р. Бер эшне бетерергә ирек бир!

З ә й н е т д и н *(кабызып)*. Совнаркомский, диең, ә?.. Ха-ха-ха... Зәйнетдин Гыйлаҗетдинең совнаркомскийны сайрата... Ә абразовный Давытка «даёшь всё» да тәтеми! Ха-ха-ха!..

Д и л б ә р. Тупасланмасана, Зәйнүш!

З ә й н е т д и н. Бетте, бетте, Диллүс... Бетте, Баядирка!.. *(Җырлый.)*

О, Баядирка, мы тебя любим.
О, Баядирка, через тебя страдаем...

Д и л б ә р. Булды, кул куй.

З ә й н е т д и н. Кая, мин әйткәнчә яздыңмы? *(Карый.)*

Д и л б ә р. Кара әле, Зәйнүш, бүген дә кинога бара алмыйча калдыкмыни?

З ә й н е т д и н. Ничә мәртәбә әйттем мин сиңа, шул «у» хәрефләрен чуалган дилбегә төсле язма, дип. *(Төзәтә.)*

Д и л б ә р. Әй, яратмасаң яздырмассың тагы!.. *(Чыга.)*

Пауза.

М и с б а х х а җ и керә.

II. М и с б а х х а җ и, З ә й н е т д и н.

М и с б а х х а җ и. Әссәламегаләйкем! Бай үзе дә өйдә икән!

З ә й н е т д и н. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, хаҗи абый, әйдә!

М и с б а х х а җ и. Кая, бер дога кылыйк. Ни хәлләр бар, Зәйнетдин энем? Бик байыйсыңмы?

З ә й н е т д и н. Сәвиттә кеше байыймыни?

М и с б а х  х а җ и. Байыйсыз инде, байыйсыз. Алла бирсен.

З ә й н е т д и н. Баетырлар болар. Иткән файдаң налогларны түләргә дә җитми.

М и с б а х  х а җ и. Ярый-ярый, Алла бирсен, әйдә, без, карт байлар, көя төшкән тире төсле, хикмәти Хода, куырылдык та калдык, һич хәлләнер хәл юк.

З ә й н е т д и н. Насыйп булса булыр әле.

М и с б а х  х а җ и. Булмый инде, булмый, биш йорттан берсен кайтармадылар бит, имансызлар, картлык белән рәтен белә алмаганбыз, күрәсең. Әнә Мифтах малае йортын кайтарып та алган, күмәчче Шәрифкә саткан да. Рәтли белгән, күрәсең.

З ә й н е т д и н. Дөрес әйтәсең, хаҗи абый, рәтли белүдә хикмәт зур. Хәзерге вакытта ишектән куып чыгарсалар, тәрәзәдән керергә кирәк, тәрәзәдән кусалар, ярыктан керергә кирәк.

М и с б а х  х а җ и. Шул-шул. Малай-шалай шул, һичбер сүзне төшендереп булмый үзләренә. Йөри-йөри өч кием киезката туздырдым, әле шуның өстенә төрмәгә эләгә яздым. Берсенә илле сумны төрткән идем, разбой сала башлады — атамы дип торам. Әллә илле сумны азсынуы булган инде.

З ә й н е т д и н. Төртә белергә кирәк, хаҗи бабай, төртә белүдә хикмәт. Сәдаканы да бисмилла әйтми бирсәң кабул булмый, ди. Төртә белүдә хикмәт!

М и с б а х  х а җ и. Шулайдыр, шулайдыр, бөтен дөньясы чәкмәрә килде, бөтен эш, бөтен нәрсә яңача булып китте... Карап торам да, Зәйнетдин энем, хәйранга калам. Кем идең, кем булдың! Ни әйтсәң дә, миндә кеше булдың син, миндә. Кем әйтеп кем ышаныр, кибеттәге өч тиенлек малай башың белән, бөтен дөнья хәерчелеккә калганда баедың да киттең. Нуретдин байның атбакатларга бикәчлеккә хәзерләнгән, гимназия бетергән кызын типтең дә куйдың. Дөньяның асты өскә килде. Әле, Зәйнетдин энем, шуның өчен дип кергән идем. Кибетеңдә миңа бирәр эш табылмасмы? Алла, хәзер менә фатирга түләрлек тә рәт калмады. Элек син миндә хезмәтче идең, хәзер мин булыйм. Әйләнгәч, әйләнеп бетәргә кирәк инде.

З ә й н е т д и н. Хәзерге вакытта күпләп хезмәтчеләр, приказчиклар тотарга ярамый. Аннан соң, турысын әйткәндә, син, хаҗи абый, хәзерге сәүдәнең хикмәтенә дә тө-

шенә алмассың. Хәзерге заманда, ай-һай-һай, хикмәтләп эш итәргә туры килә.

Мисбах хаҗи. Булмас шул, булмас. Үзем дә булыр дип ышанмаган идем. Ахшамнан чыгышлый, тукта, бер бәрелеп карыйм диеп кенә кердем. Өйдә утыра-утыра эч тә поша, йөрәк тә яна, ух-ух-х-х... Бетәсе булгач, бетәсең икән... Ярый, Зәйнетдин энем, сау бул, гаепләп калма! Үз кеше булгач кергән идем инде, ух-ух-х-х... *(Чыга.)*

III. Зәйнетдин, Дилбәр.

Зәйнетдин. Диллүс!.. Диллүс-с-с!

Дилбәр *(кереп)*. Нәрсә?

Зәйнетдин. Таныдыңмы абзаңны, хезмәт сорап кемнәр килә аңа, ха-ха-ха!.. *(Кочаклый.)*

Дилбәр. Канатларыңны җәймә, җибәр, җибәр! Какао кайнатам.

Зәйнетдин. Асрау кайнатсын! Нигә үзең эшлисең, Баядиркам, сылуым, иркәм... *(Әйләндерә.)*

Дилбәр. Әй, җибәрсәнә! *(Чыга.)*

IV. Зәйнетдин ялгыз.

Зәйнетдин. Мисбах хаҗи нәрсә ди?.. Нуретдин байның атбакатка гына бикәч булырга хәзерләнгән кызын типтең дә куйдың, диме?.. Тибәрбез әле без, бер аяк белән тибеп нинди хикмәтләр чыгарып торабыз, ике аяк белән тибә башласак күрерсез әле. Тибә белеп тибүдә хикмәт!

Дилбәр поднос белән какао һәм бисквитлар кертә.

V. Зәйнетдин һәм Дилбәр.

Зәйнетдин. Булдымы? Яратам шул какао дигән хикмәтне, американскийлар белми эчмиләр икән... *(Авыз итә.)* Әһә, барып чыккан бу!

Дилбәр. Яхшы булганмы?

Зәйнетдин. Первый сорт!..

Пауза. Эчәләр.

Ха-ха-ха!..

Дилбәр. Нәрсә шашасың тагы? Ашаган-эчкән чагында шаркылдап көлү неприлично.

Зәйнетдин. Атбаш Гыйлаҗи малае бисквитлап какао эчә, ә? Ха-ха-ха!.. Каршысында атбакатлар өчен үстергән Баядирка!.. *(Кикерә.)*

Дилбәр. Ярый, ярый, кыланма, юньле утыр!

З ә й н е т д и н. Бетте, бетте, Биби Баядирка җаныем, иркәм!.. *(Шопырдатып эчә.)*

Д и л б ә р. Шопырдатып эчмә. Неприлично.

З ә й н е т д и н. Шопырдаткач хикмәтлерәк була ул. Әткәй мәрхүмне каберennән торгызып шул хикмәтне күрсәтәсе иде. Ни эшләр иде икән?.. Теге театрдагыча күзләрен шар хәтле ачып шашыныр иде бугай, ха-ха-ха-ха... Театр дигәннән, безнең татарда да Баядирка төсле уен булырмы икән?

Д и л б ә р. Татарга тагын!

З ә й н е т д и н. Мин дә шулай уйлыйм. Ай-һай акырырга кирәк бит. Ул хәтле акырырга безнең агай-эне бугазы чыдамас. *(Чапылдатып ашый башлый.)*

Д и л б ә р. Сыер шикелле чаф-чоф килмә әле. Чапылдатмый ашарга өйрән, неприлично.

З ә й н е т д и н. Чапылдатмый ашасаң, тәме, ләззәте булмый аның. Чапылдатуда хикмәт. Кая, тагы бер стакан бир!

Д и л б ә р. Җитәр инде, какаоны күп эчмиләр, неприлично.

З ә й н е т д и н. Китер, китер, какао да үземнеке, корсак та собственный. Неприлично дигәнең үзеңә булсын! Давай!

Д и л б ә р. Давайламый юньләп сора!..

З ә й н е т д и н. Давай, давай!.. Китер...

Д и л б ә р чыга. Ишек кагалар.

Җыеп ал боларны, кеше бар... Керегез!

Н у р е т д и н, Б а т ы р х а н, Д а в ы т керәләр. Д и л б ә р чыга.

VI. З ә й н е т д и н, Б а т ы р х а н, Н у р е т д и н, Д а в ы т.

Н у р е т д и н. Әссәламегаләйкем!.. Өйдә икәнсең, кияү, бик яхшы.

З ә й н е т д и н. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, каенатай, хуш килдең! Саумы, каенатай!

Н у р е т д и н. Таныш булыгыз, бу безнең иске дустыбыз Батырхан әфәнде.

З ә й н е т д и н. Ишеткәнем бар, утырышыгыз, кунаклар.

Дога. Зәйнетдин тәмәке бирә.

Н у р е т д и н. Дилбәрнең кияве шул була инде, Батырхан әфәнде.

Б а т ы р х а н. Бик яхшы, бик яхшы.

З ә й н е т д и н. Кунаклар, чәй эчәсегез киләме, әллә какаомы?

Н у р е т д и н. Юк, кияү, рәхмәт, чәйләр эчә-нитә тормабыз. Без зур гына йомыш белән килгән идек.

З ә й н е т д и н. Алаймы?

Д и л б ә р керә.

VII. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Д и л б ә р.

Д и л б ә р. Исәнме, әткәй?

Н у р е т д и н. Үзең саумы, кызым?

Б а т ы р х а н. Исәнмесез, Дилбәр ханым, мөбарәк булсын!

Д и л б ә р. Рәхмәт!.. Нихәл, Давыт, нишләп торасың?

З ә й н е т д и н. Кунакларга чәй дигән идем, эчмибез, диләр.

Д и л б ә р. Сөйләшә-сөйләшә эчәрбез әле.

Н у р е т д и н. Юк, кызым, рәхмәт, кирәк түгел. Без кияүгә эш белән генә килдек.

Д и л б ә р. Сөйләшә-сөйләшә эчәрбез әле... Фатыйма, Фатыйма, самавыр куй.

Н у р е т д и н. Йә яшьләр, башлагыз, Батырхан әфәнде, сез башлагыз!

Б а т ы р х а н. Безнең сезгә килүебез, Зәйнетдин әфәнде, яңа икътисади сәясәткә бәйләнгән.

З ә й н е т д и н. Ничек бәйләнгән?

Б а т ы р х а н. Ягъни нэп турында сөйләшмәкче булабыз.

З ә й н е т д и н. Була, була, сөйләгез, сөйлә.

Б а т ы р х а н. Большевиклар властьны алу белән, бөтен сәнгать, сәүдә эшләрен дә үз кулларына алып караганнар иде, ләкин эш чыкмагач, сәүдә, сәнгать эшләрендә нэп уйлап чыгарган булдылар. Хәзерге заманда кулларында беркадәр капиталлары булган яшь сәүдәгәрләргә шул нэпнең бөтен серләренә төшенеп эш күрергә кирәк.

З ә й н е т д и н. Әйе, әйе, сергә төшенүдә хикмәт. Хуш, хуш?..

Б а т ы р х а н. Бу мәсьәләдә без фәнгә, белемгә, сәясәткә таянмасак, гомергә Совет властеның жалуниясез приказчиклары булып калачакбыз. Большевикларның бөтен теләгәннәре дә шул.

Д и л б ә р. Гафу итегез, сүзегезне бүлдем. Сез үзегез дә большевик бит, Батырхан әфәнде!

З ә й н е т д и н. Большевик?

Н у р е т д и н. Айныды инде, айныды, күптән айныды, хи-хи-хи…

Б а т ы р х а н. Тормышта адәм баласының башыннан төрле хәлләр үтүе бик мөмкин, Дилбәр ханым. Ләкин шул хәлләрдә мәңгегә харап булып калмас өчен, яхшыдан яманны аерырга дип, Аллаһы Тәгалә адәмгә акыл биргән.

Д и л б ә р. Димәк, сезнең большевиклыгыгыз факт?

Б а т ы р х а н. Дөрес, мин бер елга якын большевик булып ахмакланып, җил куып йөргән идем. Ләкин хәзер, Аллага шөкер, ул афәттән котылдым.

З ә й н е т д и н *(читкә чакырып)*. Каенатай, бире килегез әле.

Н у р е т д и н. Ни бар, кияү?

З ә й н е т д и н. Бу әфәндегез өч хәреф түгелме икән?

Н у р е т д и н. Юк, юк. Ул яктан тыныч бул, кызым Дилбәр дә аны бик яхшы белә, баштанаяк үз кеше, тыныч бул. *(Кайтып.)* Дәвам итегез, Батырхан әфәнде!..

Б а т ы р х а н. Ә… әйе… бер елга якын большевиклар арасында кайнаганлыктан, аларның тоткан сәясәтләренең төбенә төшендем.

З ә й н е т д и н. Бик дөрес, төбенә төшенүдә хикмәт. Кем, исемегез ничек әле?

Б а т ы р х а н. Батырхан.

З ә й н е т д и н. Дөресме, Батырхан әфәнде, бу нэп дигән нәрсә вакытлы гына булачак, ди, имеш, яшергән малларны чыгартыр өчен корылган хикмәт кенә, ди, имеш, дөресме?

Б а т ы р х а н. Дөресен әйткәндә, ул нэпта сез аңлый алмаган кайбер серләр бар.

Н у р е т д и н. Кияү, бу кеше – бөтен нәрсәнең төбеннән белеп сөйли торган кеше.

З ә й н е т д и н. Әлбәттә, әлбәттә, төпне белүдә хикмәт. Минем мәрхүм бабай әйтә торган иде, «белеп сөйләүдә бер хикмәт булса, белеп эшләүдә йөз хикмәт» ди торган иде. Сөйләгез, сөйлә!

Б а т ы р х а н. Нәрсә сөйли идем әле мин?

Д а в ы т. Нэпның мәгънәсе болай, кияү. Нэп, тышкы яктан хосусый капиталга юл ачу булган төсле күренсә дә, төбе аның башкада. Әнә шул большевиклар уйлаган башканы җимерергә кирәк.

З ә й н е т д и н. Җимерү мәслихәт. Большевикларның үзләрен җимерүгә дә мин каршы түгел. Хуш, каенагай, шуннан соң?

Д а в ы т. Әнә шул зур эшләрне башкару өчен, акча кирәк.

З ә й н е т д и н. Хикмәт әнә шул акчада шул. Акчасыз, Ходаның хикмәте, бер хикмәт тә чыкмый. Әнә шуңа күрә тырышкан булабыз да.

Д а в ы т. Тырышу гына җитми, көрәшергә кирәк. Көрәшү өчен, барлык мөмкинлекләргә хуҗа була белергә кирәк. Төшенәсезме, кияү?

З ә й н е т д и н. Төшенүен төшенәбез, каенагай, төшенүдә хикмәт.

Д а в ы т. Безнең план зурдан.

З ә й н е т д и н. Әнә шул сезнең зур планнарыгыз минем кечкенә планнарыма туры килеп бетми шул. Миңа бер тиенем ун тиен китереп тора икән, мин шуңа канәгать.

Д а в ы т. Большевиклар яшәгәндә, ул һаман шулай булып торыр, дип уйлыйсыңмы әллә?

Б а т ы р х а н. Миллионнар үзләре кычкырып торганда, хәрәкәтсез ятарга ярамый, Зәйнетдин әфәнде.

З ә й н е т д и н. Кая миллионнар кычкыра?

Б а т ы р х а н. Кая, дисеңме? Зәйнетдин әфәнде, менә эш нәрсәдә... Сездә капитал бар. Бездә белем бар. Ягъни сәяси белем. Менә шушы ике көчне бергә кушарга кирәк.

З ә й н е т д и н. Әһә... бергә кушарга?!

Б а т ы р х а н. Әйе.

З ә й н е т д и н. Мин надан кеше, сезнең шикелле хикмәтләп сөйләшә дә белмим. Минем надан акылым миңа болай ди: капиталсыз коры белем белән бер телем икмәк тә алып булмый, каенагай. Белемсез капитал белән бөтен дөньяны сатып алырга була, каенатай. Акча үзе абразавный шул, әфәндем... төрле телне белә. Мең төрле эшләрне хикмәтләп чыгара. Сез белемегезне минем капиталга алмаштырырга теләсәгез дә, мин капиталымны сезнең белемегезгә алыштырасым килми. Мин, Дилбәр әйтмешли, американский уйлыйм. Американский эшләргә уйласагыз, әйдәгез, эшлибез.

Б а т ы р х а н. Ничек американский?

З ә й н е т д и н. Яңа эшегезгә мин күпме капитал куйсам, сез дә шулхәтле үк куясыз. Файда итсәк тә уртак, хикмәтләнсәк тә уртак, барамы?..

Д а в ы т. Ә безнең белемебезне кая куясың?

З ә й н е т д и н. Сезнең белемегез үзегездә, минем наданлыгым үземдә калыр. Аларны компаниягә кертмәбез.

Б а т ы р х а н. Соң, сез бит безнең нинди эш башларга теләгәнлекне белмисез.

З ә й н е т д и н. Белү генә түгел, мин андый миллионнар тудыра торган эшләрне белеп оныткан инде. Миңа

һәр көн байны баетучы хәерче абразавныйлар йөреп тора. Һәммәсе миллионнар күрсәтәләр. Ә үзләренең кесәләрендә грошлары да юк. Хикмәти Хода, барысы да мине баетмакчы булалар. Теге бер тиен сәдакага мең сум теләгән теләнчеләр төсле. Ха-ха-ха!..

Нуретдин. Мин бай чагымда андый гына суманы милләт файдасына да бирә торган идем.

Зәйнетдин. Сез бай чакта сезнең милләтегез булган. Ә без, каенатай, интернационал, ха-ха-ха!.. Бездә милләт тә, чорт та юк. Милләт, кесәңдә булса — милләт, кесәңдә булмаса — имгәк, ди, ул, Мисбах хаҗи.

Давыт. Молодец, кияү, үз ягыңны кара.

Нуретдин. Бу нәрсә булды инде?

Давыт. Иләк белән су ташуны ташларга кирәк, әткәй!

Батырхан. Дилбәр ханымның фикерен ишетмәдек әле.

Зәйнетдин. Какао эчәсегез килсә, Дилбәр ханым аны бик оста булдыра, ирләр эшенә катнашырга большевик та, комсомол да булганы юк әле аның.

Батырхан. Шулай укмыни, Дилбәр ханым?!

Дилбәр. Шулайрак, Батырхан әфәнде.

Батырхан. Гаҗәп!..

Нуретдин. Сез тагын борынгы әкиятләрегезгә керештегез. Мәсьәләгә кайтыйк, эш турында сөйләшик.

Давыт. Мәсьәләгә яңабаштан кайтканчы, өйгә кайту артыграк булыр, әткәй. *(Урыныннан торып җыена башлый.)*

Батырхан. Минемчә дә, бу мәсьәләне бүгенгә калдырыйк. Минем дә бүген кәефем юк. Йөрәгем уйнап, башларым әйләнә башлады. Әллә инде, Дилбәр ханым, сезнең һавагыз килешмәде?..

Дилбәр. Гаҗәп түгел.

Нуретдин. Кайтасы булсагыз кайтыйк!

Дилбәр. Туктагыз, чәй эчәрбез, әткәй.

Нуретдин. Рәхмәт, кызым, рәхмәт!

Зәйнетдин. Утырыгыз, каенагай, чәй эчәрбез, каенатай!

Батырхан *(Дилбәрнең кулын алып)*. Шулай, Дилбәр ханым, кояш баегач кына, без аның кадерен сизәбез икән!..

Дилбәр. Ул кояш турында уйламагыз, Батырхан әфәнде, ул яңадан һичбер вакыт чыкмас!..

Зәйнетдин. Нигә чыкмасын?.. Менә юләр! Кояш чыгар, хикмәт чыкмас, диең син аңар!

Нуретдин. Ярый, Аллага тапшырдык, балалар, хушыгыз!

Дилбәр. Хуш, әткәй, хуш!.. Килеп утырыгыз!

Зәйнетдин. Бигайбә, каенатай, һәркемнең дә бармаклары үзенә таба бөгелә... *(Озата чыга. Пауза. Кире керә.)* Кара син аны, тол саескан, хикмәтләп «кояш» чыгарырга килгән. Бер кат күзлек белән генә күзләрең күрмәсә, фонарьлар куеп җибәргән өчен дә кыйммәт алмам мин!..

Дилбәр керә.

Дилбәр. Нәрсә дисең?

Зәйнетдин. Әле теге әфәнденең кояшы турында әйтәм... Уһу-һу-һу, сәгать ун булган. Урын җәйгәнме?

Дилбәр. Җәйгән.

Зәйнетдин. Ай сине, Баядирка дисәң Баядирка. Бөтен дөньяның күзе кыза бит үзеңә, ә?.. *(Төрткәли.)*

Дилбәр. Кыланмасана!

Зәйнетдин. Теге әфәнде кояш чыгарсын, ә без утларны сүндерик, ә? Ха-ха-ха... *(Утларны сүндерә.)* Әйдә!..

О, Баядирка, мы тебя любим,
О, Баядирка, через тебя страдаем.

Вальс биеп бүлмәгә керәләр.

Пәрдә.

## СИГЕЗЕНЧЕ КАРТИНА

Ярлы подвалда фатир.

I. Нуретдин һәм Рөкыя.

Нуретдин, тәбәнәк өстәл янында утырып, иске киез итекләргә ас сала. Рөкыя баскан килеш җепкә сумала сыдыра.

Нуретдин. Кызым, чәй эчеп аласы иде, булмаса.

Рөкыя. Күмер юк, күмер юк!.. *(Чыгып китә.)*

Нуретдин. И-хи-хи-хи!.. Бер кирегә китсә китә икән. Таудан тәгәрәгән таш төсле һаман әле аска таба тәгәрибез.

II. Нуретдин, Давыт, Рөкыя.

Давыт яшеренеп керә. Тынычсызлана. Зур пауза.

Нуретдин *(кинәт Давытны күреп сискәнеп)*. Йә!.. Син икәнсең, улым. Котны алдың.

Д а в ы т. Әти, ул-бу юкмы?

Н у р е т д и н. Хәзергә тыныч әле.

Д а в ы т. Мине сораучылар булмадымы?

Н у р е т д и н. Яңалардан юк. Күк күзлекне күргәнсеңдер.

Д а в ы т. Күрдем.

Н у р е т д и н. Үзеңдә ниләр бар, улым?

Д а в ы т. Батырхан әфәнде килмәдеме?

Н у р е т д и н. Юк... Әй замана, замана!.. Первый гильди купецтан тишек киез итекләр яматалар.

Д а в ы т. Коммерческий институт бетергән улыңа киез итекләр ямарга да мөмкинлек бирмиләр.

Н у р е т д и н. Бу да булдымы хөррият! Бу да булдымы тигезлек!

Д а в ы т. Куеныгызда елан үскәнне сизмичә, күгәрченнәр ашатуыгызның җәзасы. Шулай кирәк. Алар урынында мин дә шулай эшләр идем. Хәер, ул көннәрнең шәүләләре... Ничек әле, әти, ике кучкарның башы бер казанга сыймый, диләрме?

Н у р е т д и н. Кучкар, кучкар... хәерче, кустарь, дисәң бер хәл.

Д а в ы т *(онытылып, көч белән)*. Ләкин мин чәнчеләп ачка үлсәм дә, властьны хезмәт кулына бирү ягында түгел. Чөнки ул караш дөрес караш түгел. Капитализм үзенең гегемон дәверен уздырырга тиеш.

Р ө к ы я. Һаман сүз, һаман сүз!.. Сөйләгән сүзләрегезнең меңнән бер өлеше генә эшкә ашкан булса да, хәзер инде җир йөзендә бер большевик та калмаган булыр иде.

Н у р е т д и н. Үз почмагыбызда сөйләшергә дә ярамый башладымы әллә инде?!

Р ө к ы я. Аналап-әбиләп сүгенеп тә ал, булмаса.

Н у р е т д и н. Сүгенермен дә шул. Син үк бит, чәй, дигәч, күмер юк, дисең.

Р ө к ы я. Юк шул. Күмер дә юк, шикәр дә юк... Вареньены әйтмим дә, хи-хи-хи!..

Н у р е т д и н. Тукта, дим мин сиңа!

Р ө к ы я. Әтә-тә-тә!.. Большевик ачуын миннән ала.

Н у р е т д и н. Тукта, дим!

Р ө к ы я. Күмер юк!

Н у р е т д и н. Һе, бөкре җабага... дәргяһтан сөрелгән шәйтан анасы!..

Р ө к ы я. Бай кызыңа бар. Какаолар хәзерләп көтеп тора, ди, хи-хи-хи!..

Н у р е т д и н. Канымны бозма, кәкре галдиш!

Р ө к ы я. Җикеренмә миңа, карт дурак!

Н у р е т д и н. Туктыйсыңмы, юкмы!.. *(Калып белән кизәнә.)*

Д а в ы т *(бик каты кычкырып)*. Шаулашмагыз!.. Сезнең тавышыгызны сагынып килмәдем әле!

Н у р е т д и н. Бер хәл булса, җелегемә үтеп, эчәгеләремне саварга тотына.

Р ө к ы я. Шулаймы?

Н у р е т д и н. Туктыйсыңмы, юкмы?.. *(Кизәнә.)*

III. Ш у л а р у к һәм З ә й н е т д и н, Д и л б ә р.

Д а в ы т. Җитәр!.. Җитәр сезгә!..

З ә й н е т д и н. Әссәламегаләйкем!.. Исәнме, каенатай!.. Саумы, каенагай. Нихәл, каенигәч!.. Сау гына хикмәтлисезме?..

Н у р е т д и н. Түрдән узыгыз, балалар.

Д и л б ә р. Нишләп торасыз, әткәй? Рөкыя апа безгә килеп тә карамый инде. Безне бөтенләй чит күрә.

Р ө к ы я. Нишлим мин сездә?!

Н у р е т д и н. Балалар, чәй куйсак эчәрсезме?

Р ө к ы я. Маташма, күмер юк.

З ә й н е т д и н. Юк, юк, борчылмагыз, каенатай. Кирәк түгел. Мин хәзер, хикмәти Ходა, чәйне бик аз эчә башладым. Дилбәр ханым какао белән хикмәтли хәзер.

Р ө к ы я. Безнең әти дә, какаоны бик яратам, ди.

Н у р е т д и н. Телеңә тилчә төшкере, галдиш!..

Д а в ы т. Утырыгыз, нигә басып торасыз?

З ә й н е т д и н. Мин, каенатай, сезгә хикмәт белән, йомыш белән кергән идем.

Н у р е т д и н. Алаймы, ярый, ярый. Утырып сөйләшик, кияү. Йомыш, дисеңме, хуш, кияү, хуш?

З ә й н е т д и н. Мин бу йортыма капитальный ремонт ясатырга уйлыйм. Юкса күгәреп, череп эштән чыга. Сезгә дә җайсыздыр.

Н у р е т д и н. Рәхмәт, кияү. Ремонтлар ясап безнең өчен борчылмагыз.

З ә й н е т д и н. Төбендә ул ремонт сезнең өчен... түгел, каенатай.

Н у р е т д и н. Алаймы?

З ә й н е т д и н. Мин бу подвалны цементлап, яхшылап төзәттереп, склад ясарга уйлыйм. Фатирчылардан хикмәт чыкмый, каенатай. Аскы катта барлыгы алты фатир бар. Шул фатирлардан айга ун сум җыяр хәл юк. Кайсы эшче,

ди, кайсы эшсез, ди, кайсы хикмәт, ди. Склад булса, азында айга алтмыш-җитмеш сум китереп торыр.

Н у р е т д и н. Һе, алай икән. Шуннан соң, кияү?

З ә й н е т д и н. Сезгә бу фатирдан күчәргә туры килер, каенатай. Ай башына хәтле үзегезгә фатир табып хикмәтләп куйсагыз, яхшы булыр иде.

Н у р е т д и н. Анысы алаен алай да бит. Тиз арада гына арзанлы фатир табуы читенрәк булыр, кияү.

Д а в ы т. Табарбыз. Кайчанга бушатсыннар?

З ә й н е т д и н. Ай башыннан калмыйча ремонтка керешмәкче булам.

Д а в ы т. Ярый, өч атнадан фатирың бушаган булыр. Башка хикмәтләрең юкмы?

Н у р е т д и н. Улым, алай кырт кисеп куйма. Фатир табулары җиңел эш түгел хәзер.

Д а в ы т. Тиреслек башына күчәрбез. Анда тишек киез каталар да, кыргаяклар да күбрәк.

З ә й н е т д и н. Тынычрак булыр... Синең өчен, дим, каенагай...

Р ө к ы я. Бу хәтле карун чучка булырсың икән, кияү.

Н у р е т д и н. Катышма, синең эшең түгел.

Д и л б ә р. Килмисез, йөрешмисез дип үпкәлисез. Килсәң, Рөкыя апа зәһәрләнә башлый.

Р ө к ы я. Фатирдан куарга килүегез өчен кулларыгызны үбәргә кушар идегезме тагын!

Д и л б ә р. Кирәк булгач, берни итәр хәл юк. Бер сез генә тормыйсыз бит бу йортта. Үз кешеләрне башта чыгармасаң, башкалар чыгарлар дип беләсеңме?

З ә й н е т д и н. Эшне шулай куймаганда, хикмәт чыгарып булмый, каенигәч. Ярый, туры килгәндә, үзегез дә керә-чыга йөрегез, каенатай. Чынлап әйтәм, каенагай, баргалап, кергәләп, чыккалап йөрештерегез. Сөйләшеп утыру кызык ич. Бездә тыныч та. Ярый, бары шунда инде, кинога үтешли генә кергән идек. Бик хикмәтле картина, ди, бүген. Дугасмы, Пугасмы, ди, шунда, гаҗәп хикмәтле, ди. Ярый, исән булыгыз!

Д и л б ә р. Хуш, әткәй. Менә аз булса да чәй янында кабарсыз. *(Кәгазьгә төргән паштет кисәге бирә.)* Хуш, Давыт! *(Чыгып китәләр.)*

Зур пауза.

Н у р е т д и н *(төргәкне сүтеп карап, Рөкыяга сузып)*. Кызым, алып куй, чәй янында ашарбыз.

Д а в ы т. Менә, әти, сезнең сәүдәгәрлек калдыгы без-

нең Дилбәрдә һаман бетмәгән әле. Ул паштет кисәге белән вөҗданын аклап, күңелендәге курку хисен басмакчы була. Хәзерге тормышта бай булып яшәргә үзен хаклы дип тапкан безнең кияү алай маташмый. Алты сумлык доходны алтмыш сумга күтәрер өчен, никахлы хатынының атасын урамга ташларга кирәк икән, ул аны эшли. Аның планы метр белән үлчәнә. Яшәү өчен көрәшкәндә, шулай булырга кирәк тә. Черек сентиментальностьларның эзләрен ком бураны күптән күмеп киткән инде. Ә сез, күгәрченнәр ашатып, кулыгыздагы властьны ялчыларыгыздан алдырдыгыз!..

Р ө к ы я. Һаман сүз, һаман әкият. Ә күмер юк. Күмер кирәк, күмер кирәк!.. *(Чыгып китә.)*

Паузадан соң М и с б а х  х а җ и керә.

Д а в ы т. Тс-с-с, кеше бар!.. *(Яшеренә.)*

IV. Н у р е т д и н, М и с б а х  х а җ и.

М и с б а х  х а җ и *(сәләмә киемнән. Кулында сыңар киезката, черек киез кисәге һәм иске читек балтырлары)*. Әссәламегаләйкем!

Н у р е т д и н. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, хаҗи!

М и с б а х  х а җ и. Кем, Нуретдин, болар сиңа батмыймы?

Н у р е т д и н *(бик җентекләп карап)*. Кая, эһем... Монысын көя эштән чыгарган икән. Күпме сорыйсың?

М и с б а х  х а җ и. Икесенә сиксән тиен бирерсең.

Н у р е т д и н. Монысын көя эштән чыгарган бит, хаҗи.

М и с б а х  х а җ и. Көя кисмәгән булса, йөз егерме тиен дә бирер идең.

Н у р е т д и н. Кырык тиенгә риза булсаң калдыр.

М и с б а х  х а җ и. Кем, Нуретдин, сумасы илле тиеннән.

Н у р е т д и н. Көя кискән бит. Һу!.. Бу җирен күрми дә торам икән, син әйткән бәһагә батмас, хаҗи.

М и с б а х  х а җ и. Күпме дисең соң, тиярен бир!

Н у р е т д и н. Икесеннән тартып-сузып бер киемгә аслык чыкса чыгар.

М и с б а х  х а җ и. Кысмыйча гына тиярен бир дә алып кал.

Н у р е т д и н. Ярый, илле тиенгә калдыр.

М и с б а х  х а җ и. Ихлас әгәр, сумасы илле тиен. Бишүн тиен дә файдасы булмагач булмый бит инде. Кысма син мине.

Н у р е т д и н. Илле биш тиеннән артык бер тиен дә бирә алмыйм, хаҗи.

М и с б а х  х а җ и. Ярый, игелеген күр... Болары батмыймы?

Н у р е т д и н *(балтырларга карап)*. Юк. Акчасына иртәгә керерсең.

М и с б а х  х а җ и. Бүген булмыймыни?

Н у р е т д и н. Бүген булмый, юк.

М и с б а х  х а җ и. Иртәгә тәгаен булырмы соң?

Н у р е т д и н. Тәгаен булыр, Алла боерса. Йә, ни эшләр бетереп торасың, хаҗи?

М и с б а х  х а җ и. Ипие булса, бәрәңгесе юк, чәе булса, шикәре булмый. Без бай чагында, Ходаның хикмәте, бөтен дөнья тук иде. Дөньясы чәкмәрә килде. Үлеп тә булмый. Беттек инде, Нуретдин, аръягына чыгып беттек. Булмаса, боларны да алып кал, читек балтырларын, дим.

Н у р е т д и н. Боларга бит өр-яңа башлар кирәк. Хәер, баш сабарлык җире дә калмаган икән.

М и с б а х  х а җ и. Алып кал, берәр ямауга ярар шунда. Тузган булсалар да, читек балтырлары бит.

Н у р е т д и н. Юк, хаҗи, болар эшкә ашырлыклар түгел. Үзләре черегән, үзләре... юк, батмый.

М и с б а х  х а җ и. Әйе, яңа башлар кирәк шул, яңа башлар.

V. Ш у л а р  у к  һәм  Б а т ы р х а н.

Б а т ы р х а н. Исәнмесез, әфәнделәр!

Н у р е т д и н. Әйдә, Батырхан әфәнде, рәхим ит.

Б а т ы р х а н *(Мисбахка)*. Исәнмесез!

М и с б а х  х а җ и. Хәлләр хәстә булгач, коры исәнлектә генә хикмәт аз икән, егет.

Н у р е т д и н. Берәр җиргә киткән идегезме әллә, күренмәдегез?

Б а т ы р х а н. Заманасы шундый бит, әфәнделәр.

М и с б а х  х а җ и. Менә, кем, әфәнде, безне генә эштән чыгардыгыз. Барыбер үзегезгә дә булмады. Безне генә харап иттегез. Хәер, Алла ул чыдап тора-тора да бер каптыра. Таладыгыз, таладыгыз, барыбер байый алмадыгыз. *(Читек балтырларын җиргә ташлый.)*

Б а т ы р х а н. Мин үзем дә шул турыда төннәр буе уйлап чыгам.

М и с б а х  х а җ и. Туйдан соң дөмбергә дигәндәй, беткәннән соң уйлавыңда ни файда! Хәер, сиңа нәрсә, элек тә хәерче идең, хәзер дә шул ук. Һе, дөньяны тигезләргә уй-

лаганнар. Җыен катржан җыелып алганнар да тигезләргә керешкәннәр!

Нуретдин. Бәйләнмә аңа, ул алардан түгел.

Мисбах хаҗи. Җыенысы — бер себерке белән себерелгән чүп. Йортымны кайтарырга баргач бит, әллә кем булган, рәтләп сөйләшмәгән дә була.

Нуретдин. Ул күптән айныды инде.

Мисбах хаҗи. Йортым кайтмагач, аның айнуыннан миңа ни файда! Ярый, хуш, Нуретдин. Сөйләшә башласам, йөрәгем бозыла. Иртәгә керермен. *(Китә башлый. Кире кайтып.)* Читек балтырларын онытып китәм ләбаса... Иртәгә кәҗә базарына чыгарып карармын... *(Балтырларны күтәреп бер-берсенә бәреп.)* Иһи-һи-һи!.. Заманында болар да кәҗүл булганнар бит... Ярый, хуш, Нуретдин!.. *(Чыгып китә.)*

Нуретдин. Давыт, Давыт!..

VI. Нуретдин, Батырхан, Давыт.

Давыт *(чыгып)*. Исәнмесез, Батырхан әфәнде! *(Сәгатенә карый.)*

Нуретдин. Батырхан әфәнде, инде ни эшләргә?.. Ни эшлибез? Шулай ук бөтен бөлгенлекләрнең чигенә җиттекмени?!

Давыт. Юк. Минемчә, романның беренче бүлеге генә бетте әле. Минем уйлавымча, куелган бу нокта, кызыл нокта романның икенче бүлеген башларга вакыт җиткәнлеген күрсәтә. Ә инде романның икенче бүлеге беренче бүлегеннән дә кызыграк булыр төсле. Шул турыда фикерегезне ачык белер өчен, мин сезне чакырган идем... Әти!.. *(Рөкыяне чыгарырга ымлый.)*

Нуретдин. Кызым!

Рөкыя. Нәрсә?

Нуретдин. Тышкы ишекне бикләә. Кеше-кара сизелсә, тиз генә кереп әйтерсең.

Рөкыя. Тагын сүз, тагын сүз, ә күмер һаман юк. Күмер кирәк, күмер!..

Нуретдин. Бар, кушканны эшлә.

Рөкыя чыгып китә.

Батырхан. Шулай, әфәнделәр. Алда торган мәсьәләләргә тирәнтенрәк карый башларга вакыт җитте бугай инде. Безгә бөтен төрек-татар дөньясын, хәтта бөтен мөселман дөньясын...

Д а в ы т. Марксизм-ленинизм чиреннән саклап калырга кирәк, дисезме?

Б а т ы р х а н. Әйе, әйе, бу — безнең мөкатдәс бурычыбыз. Бу зур эшне, әлбәттә, үзебез генә башкарып чыга алмабыз.

Д а в ы т. Руслардан һәм чит илләрдән ярдәмчеләр кирәк, дисезме?

Б а т ы р х а н. Әйе, әйе, без алар белән бер саф булып большевизмга каршы көрәшергә тиешбез.

Д а в ы т. Соңгы заманның иң зур даһисы Муссолини Европада марксизмга каршы…

Б а т ы р х а н. Әйе, әйе… Безгә дә төрек-татар мөселман дөньясын марксизм-ленинизмнан коткарырга кирәк. Моның вакыты җитте. Әгәр дә без бу көрәшкә хәзерлекне хәзердән башламасак, төрек-татар тарихы алдында зур җинаять эшләгән булырбыз.

Д а в ы т. Әһә, аңлыйм, аңлыйм.

Н у р е т д и н. Нигез ныкмы соң?

Б а т ы р х а н. Нигез бар. Тамырлары бөтен төрек-татар җөмһүриятләренә җибәрелгән. Кайбер партбилетлылар арасында да фикердәшләр бөтенләй үк юк түгел.

Д а в ы т. Чит илләр белән дә бәйләнеш бар. Кыскасы, Батырхан әфәнде, менә шул: Европа өстендә йөргән марксизм шәүләсенә каршы, анда хәзер фашизм гәүдәсе… Менә шул эшләр белән иртәгә мин…

Н у р е т д и н. Чү!..

VII. Ә ү в ә л г е л ә р һ ә м Р ө к ы я.

Р ө к ы я *(каушап йөгереп кереп)*. Ишектә кешеләр бар!..

Б а т ы р х а н. ГПУ!..

Н у р е т д и н. Кертмә, ярамый!..

Д а в ы т *(идән тактасын ачып)*. Әйдәгез, Батырхан әфәнде, бу юл безне коткарыр!..

Идән астына төшәләр.
Нуретдин, ишеккә таба омтылып, керүчеләрне көтеп торган хәлдә кала.

Р ө к ы я *(чабып кереп)*. Керделәр!..

Икесе дә, карашларын ишеккә юнәлтеп, керүчеләрне көтеп омтылып калалар. Өйалдында ишек тимеренең чыңлаган тавышы һәм кереп килә торган аяк тавышлары ишетелә.

П ә р д ә.

*1926 ел*

# ЗӘҢГӘР ШӘЛ

*Мелодрама*

*Биш пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

М ә й с ә р ә — ятимә кыз.
Җ и һ а н ш а — Мәйсәрәнең атасы белән бертуган.
Б у л а т — Мәйсәрәнең сөйгәне, шахтёр.
З а һ и р ә — Булатның сеңлесе.
Ф а т ы й м а, С а җ и д ә, Н ә с и м ә — Мәйсәрәнең дус кызлары.
Н у р ы й, Ә п т е р и — авыл егетләре.
И ш а н.
Х ә д и ч ә, М ә р ф у г а, С а б и р а, Ф а з ы й л ә — ишанның хатыннары.
Г а л ә в и — ишанның хезмәтчесе.
М а л а й.
Ш ә й х и б а б а й.
П ә т р ә й.
М и ң л е г а л и.
Т и м у ш.
Х ә й р и.
М и ш к а.
К а ч к ы н н а р.
К а р т л а р.
К а р ч ы к л а р.
Б а й г у р а.
Е г е т л ә р, к ы з л а р.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урта тормышлы авыл йорты. Кое. Өйгә керә торган ишек. Капка. Эңгер-меңгер вакыт. Мәйсәрә ялгыз, коедан су ала. Артта хор белән «Газизәкәй балдыз» көенә җырлыйлар.

I. Мәйсәрә ялгыз.

Хор.

Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз.

Мәйсәрә.

Саф-саф кынай булып киек казлар
Үткән саен хәбәр көтәмен.

Хор.

Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз.

Мәйсәрә.

Киек казлар төсле очар идем,
Белсә идем торган җирләрен.

Хор.

Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз.

Мәйсәрә.

Әйтсәгез лә миңа, юлаучылар,
Сөйгән ярым исән калдымы?

Хор.

Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз.

Мәйсәрә.

Күрдегезме аны, казкайларым,
Биргән вәгъдәләрен саклыймы?

Хор.

Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз.

II. Мәйсәрә, Җиһанша.

Җиһанша *(чыга).* Нәрсә, шыңшып утырасың, эшең беттеме? Кортлы баш! Кяфер!

Мәйсәрә. Җиһанша абый, нигә мине рәнҗетәсең? *(Елый.)*

Җ и һ а н ш а. Нәрсә?.. Әллә атаң урынына калган абзаңа тел кайтармакчы буласыңмы, кәкре танау! Мәккә кяфере! Түк бу суларың, бисмилласыз су тәһарәткә дөрес түгел. Нәрсә каттың? Сиңа әйтәм бит. *(Мәйсәрәне төртеп җибәрә, суы түгелә.)* Мордар, яәҗүҗ-мәәҗүҗгә азык булгыры! Көтүдән терлекләр кайтуга суларың соскан булсын, ишетсен колагың. Әрәмтамак, бинамаз, үләт! *(Чыгып китә.)*

М ә й с ә р ә *(елап, су ала. «Салкын чишмә» көенә җырлый).*

Кыраулар тигән, ай, ак гөлдәй
Ятимлектә сула яшь җаным...

К ы з л а р керәләр.

III. М ә й с ә р ә һәм к ы з л а р.

Х о р.

Тау астында салкын чишмә
Чылтыр-чылтыр агадыр.
Дөньясында ямь күрәлми,
Гомереӊ үтеп барадыр.

К ы з л а р.

Оясын җуйган, ай, аккоштай
Нигә, ахирәт, болай моңландың?

Х о р.

Тау астында салкын чишмә
Чылтыр-чылтыр агадыр.
Дөньясында ямь күрәлми,
Гомереӊ үтеп барадыр.

М ә й с ә р ә.

Борылыптай үскән камыштай,
Сәлам хатың көтеп саргаям.

Х о р.

Тау астында салкын чишмә
Чылтыр-чылтыр агадыр.
Дөньясында ямь табалмый,
Гомереӊ үтеп барадыр.

К ы з л а р.

Моңланма болай, тукта, ахирәт,
Сабан тургайларын тыңлап кал.

Х о р.

Тау астында салкын чишмә
Чылтыр-чылтыр агадыр.
Дөньясында ямь күрәлми,
Гомереӊ үтеп барадыр.

З а һ и р ә *(ашыгып, шатланып керә).* Мәйсәрә ахирәт, сөенеч, сөенеч, сөенеч!

IV. Ш у л а р  у к  һәм З а һ и р ә.

М ә й с ә р ә. Сөенеч?..
З а һ и р ә. Сөенеч, билләһи, ахирәт, бик зур сөенеч.
М ә й с ә р ә. Ай, куй, ахирәт, йөрәгем-йөрәгем, уф! Әйтә дә алмыйм.
К ы з л а р. Менә. Ха-ха-ха!..
З а һ и р ә. Йә ахирәт, сөенечкә ни бирәсең, тиз бул инде, үземнең дә йөрәгем, уф!
К ы з л а р. Менә. Ха-ха-ха!..
М ә й с ә р ә. Синең йөрәгең нәрсә ул, менә минем йөрәгемне син тотып кара әле. Уф!
З а һ и р ә. Синең йөрәгеңдә эшем юк, үз йөрәгем йөрәк, уф!
К ы з л а р. Менә. Ха-ха-ха!.. Сезгә карап безнең йөрәкләр дә, уф! Ха-ха-ха!..
М ә й с ә р ә. Шул-шул. *(Кызларга.)* Менә тотып карагыз әле, тотып карагыз.
З а һ и р ә. Сөенечне ишеткәч, йөрәгең түгел бәгырькәйләрең сикерер, тавык борын.
К ы з л а р. Йә, әйт инде, Заһирә,маташтырма!
М ә й с ә р ә. Үземә генә әйт, Заһирә.
З а һ и р ә. Сөенечкә ни бирәсең, ике урам бушка гына чаптыммыни!
М ә й с ә р ә. Сөенечкә үз колагың үзеңә булыр.
К ы з л а р. Менә. Ха-ха-ха!..
З а һ и р ә. Нәрсә, чынлап әйтүеңме?
М ә й с ә р ә. Нинди сөенечтер бит әле.
З а һ и р ә. Сөенечнең иң зуры, тегермән ташы хәтлесе. Мин, синең урыныңда булсам, көмеш колак алкамны да кызганмас идем.
Н ә с и м ә. Йә, тиратайланма инде, Заһирә, әйтсәң әйт.
М ә й с ә р ә. Әйт инде, ахирәт, әйт инде, сөенечең, чынлап та, тегермән ташы хәтле зур булса, менә шул йөзегем сиңа булыр.
З а һ и р ә. Кая, бир!
М ә й с ә р ә. Менә әйтмәс борын бирәләрмени?
З а һ и р ә. Вәгъдәме?
М ә й с ә р ә. Вәгъдә, билләһи, вәгъдә.
Н ә с и м ә. Сөенечне безгә ишетергә ярый торгандыр бит, әйе бит, Заһирә?

З а һ и р ә. Ярый-ярый, нишләп ярамасын, сер түгел. *(Мәйсәрәне читкә алып китеп.)* Абый кайтты.

М ә й с ә р ә. Ә? Уф, йөрәгем!

К ы з л а р *(ташланып.)* Нәрсә ди?..

З а һ и р ә. Кәбестә ди. Йә, вәгъдәң кая?

М ә й с ә р ә *(йөзеген салып).* Мә, мә, теге сөяк саплы тамбур энәмне дә бирермен.

З а һ и р ә. Чынлап та, йөрәгең уф икән. Сиңа шатлык булгач, миңа да шатлык түгелмени! Мә, мә, җүләр. *(Йөзеген кайтара.)*

К ы з л а р. Нәрсә ди, нәрсә ди?

Н ә с и м ә. Нәрсә ди?

Мәйсәрәне тарткалыйлар.

Ф а т ы й м а. Ник дәшмисең?

С а җ и д ә. Нинди сөенеч?

К ы з л а р. Кара, кара, качмакчы була.

Н ә с и м ә. Ник дәшмисең?

Ф а т ы й м а. Кара, кара, оялмый да.

С а җ и д ә. Әйт инде, хәйләкәр җен.

Кызлар Заһирәне тарткалыйлар.

Н ә с и м ә.Нәрсә әйттең?

З а һ и р ә. Кәбестә!

Ф а т ы й м а. Нигә бездән яшерәсез?

З а һ и р ә. Кирәккә.

С а җ и д ә. Әйтмәслек булгач, нигә көттердең?

З а һ и р ә. Пәрәмәч, мин көттердеммени!

К ы з л а р. Әйт дигәч әйт инде.

Тарткалыйлар.

М ә й с ә р ә *(Заһирәгә).* Әйтмә, әйтмә.

Тарткалашалар.

З а һ и р ә *(утырып).* Әйтмимен.

Җыр «Айхайлүк» көенә.

К ы з л а р.

Сөенчеңне әйтмәс булгач,
Ник көттердең, ахирәт, ялганчы.

З а һ и р ә.

Әйтмимен.

М ә й с ә р ә.

Ахирәтем, Заһирә дус, итмә фаш.

Кызлар.
Бу эшеңне онытмабыз, тузган баш.
Тукта әле, йомышларың
Төшмәс микән безгә дә, ялганчы.
Заһирә *(чакырып ала).*
Нәсимә!
Чит илләрдән абыем кайтты туйга дип.
Сажидә.
Кара, кара, серен аңа да әйтте бит.
Фатыйма.
Безне генә читкә кагып,
Нишләвең бу, Заһирә, ялганчы!
Заһирә.
Фатыйма!
Чит илләрдән абыем кайтты туйга дип.
Сажидә.
Кара, кара, безгә генә әйтми бит.
Башкалардан без киммени,
Безне генә калдырдың, ялганчы.
Заһирә.
Дусларым, чит илләрдән абыем кайтты туйга дип.
Кызлар.
Сөйгән егетен яшергән була тагын, чутыр бит.
Кызлар.
Кара аны нинди егет,
Алдан сайлап куйган бит, хәйләкәр.
Мәйсәрә.
Дусларым, чыгара күрмәгез уймак уеннан.
Кызлар.
Чыгармабыз, калдырмасаң туеңнан.

Егетләр җырлап киләләр.

Заһирә. Чү, егетләр, тәгаен сиңа сабан сөлгесенә килә торганнардыр, кызык булсыннар әле.

Җыр башлана.

V. Шулар ук һәм егетләр.

Егетләр.
Абзый, сары атыгыз ла
Безнең болын буенда.
Безгә дигән матурларның
Кояш уйный битендә.
Сабан тургайлары сайрый,
Мактап Сабантуйларын.

Сукагa җиксәң ярарлык
Безнең авыл кызларын.

К ы з л а р.

Безнең урам түбән таба
Алма тәгәрәтергә.
Егетләрнең хәтере калган,
Кирәк бәхилләтергә.

Б а р ы с ы  д а.

Ай яктысы якты диеп,
Ташка басып су алма.
Минем җаныем читтә диеп,
Ятлар белән чуалма.

Егетләр сөлгеләр белән капка ягында, кызлар эчтә.

Ә п т е р и. Сәләмә-сөләмәне алып саттык. Кем?

З а һ и р ә. Вәли белән Маликкә бер кибән салам.

Б а р ы с ы  д а. Ха-ха-ха!..

Ә п т е р и. Матур кызлар, кодачалар, киленнәр, апалар, сеңелләр, җиңгиләр, әниләр, әбиләр һәм бишектәге бәбиләр...

З а һ и р ә. Капка кагып, ил уятып нәрсә эзләп йөрисең?

Ә п т е р и. Сөлге.

К ы з л а р. Ха-ха-ха!..

Ә п т е р и. Әйе.

З а һ и р ә. Сөлгегә сүсебез юк.

Ә п т е р и. Яулык та ярый.

З а һ и р ә. Яулыгыбыз ямаулы.

Ә п т е р и. Бир, булмаса, тастымал.

З а һ и р ә. Үзең сатып ал.

Ә п т е р и. Синеме?

З а һ и р ә. Какма кеше капкасын, үз капкаңны кагарлар.

Ә п т е р и. Кагарлык капкам булмаган, сөйгән ярым уңмаган, яулык чигеп куймаган, сөлгесен тукымаган, тастымалын юмаган, иртәгә сабан.

З а һ и р ә. Әй надан, нәрсәң генә бар соң синең?

Ә п т е р и. Сабанда узарлык атым бар, мәйданга чыгарлык даным бар.

З а һ и р ә. Батыр икәнсең, кунак бул. *(Капка ача.)*

Керәләр.

Ә п т е р и. Илчегә үлем юк, көнчегә кием юк, ди.

З а һ и р ә. Илчегә үлем, көнчегә кием бездә бар.

Ә п т е р и. Әй матур яр, киемең тар булыр, кисәм күзең шар булыр.

Көләләр.

З а һ и р ә. Йә, ни бар?

Ә п т е р и. Инештә сулар шаулый, сабанда тургай сайрый, ил егете ил кызыннан чүпләмле сөлге даулый.

З а һ и р ә. Инештә су шауласын, кырда тургай сайрасын, ил егете ил кызыннан сөлгесен түләп алсын.

Ә п т е р и. Кыз булса, кыз булсын, күктәге йолдыз булсын, җир төсле юмарт булсын, егетнең күңелен күрсен.

З а һ и р ә. Кыз булса, кыз булсын, күктәге йолдыз булсын, җир төсле сак булсын, егеткә алданмасын.

Ә п т е р и. Кыз булса, кыз булсын, күктәге йолдыз булсын, кояштай юмарт булсын, сөлгесен кызганмасын.

Н у р ы й. Ак кашкалы аргамак сабанда узам диде, ил батыры нык беләк сабанда җиңәм диде. Ил матуры ак беләк хәзерләсен бер бүләк.

М ә й с ә р ә. Ак кашкалы аргамак бәйгедән алда килсә, ил батыры нык беләк мәйданда өстен чыкса, ил матуры ак беләк хәзерләп куяр бүләк.

Н у р ы й. Аргамагым канаты бар, һәр көн сыйпыйм таң белән, үземнең сәләтем бар, алып салам ян белән.

М ә й с ә р ә. Егет булса, мут булсын, ике күзе ут булсын, сөлге хакын түләмәсә, күз алдымнан юк булсын.

Н у р ы й. Кыз булса, кыз булсын, синең төсле шук булсын, сөлгесен бирмәсә, иртәгә үк җир йотсын.

Е г е т л ә р. Йотмасын, йотмасын, коткарыгыз кызларны!

Егетләр белән кызлар аралаша, «Төймә» көенә җыр башлана.

Е г е т л ә р.

Киек казлар җырлап узды,
Килә диеп Сабантуй,
Их, Сабан туе безнең туй,
Сөлге-яулык сайлап куй.

К ы з л а р.

Сабан туе безнең туй,
Чалгы-урак кайрап куй,
Их, кайрап, кайрап, кайрап куй.

Б а р ы с ы д а.

Һаваларда моң тургайлар
Болытка юл тотканнар,
Их, Сабан туе безнең туй,
Чалгы-урак кайрап куй.

Сабан туе безнең туй,
Сөлге-яулык сайлап куй,
Их, сайлап, сайлап, сайлап куй.

Барысы да парлап биеп китәләр. Нурый Булат килгәнен күрә.

Нурый. Егетләр, карагыз әле, бу кем бу? Әллә монда килә?

Әптери. Булат ич бу.

Барысы да. Булат?

Әптери. Әйе, бүген кайткан дигәннәр иде, йөрәге түзмәгән егетнең.

Кызлар карый.

Нурый. Өс-башына кара малайның, писермени?

Нәсимә. Ә сез авылда күгәреп әниләрегез куенында ятасыз. Әнә кеше нишләтә!

Нурый. Барыбыз да читкә китсәк, үзегезгә үк күңелсез булыр бит, прәннек борын.

Нәсимә. Мәйсәрә, аяк атлауларын кара, нинди генә, ха-ха-ха...

Барысы да. Айһай-айһай, шәп икән, малай.

Нурый. Кеше төсле үк, түбәсе өстеннән йөрми әле.

Нәсимә. Йөрәгең янамыни, туң күчән.

Булат «Шахта» көенә җырлап керә.

VI. Шулар ук һәм Булат.

Хор.

Булат, Булат кайткан.
Бүләк алып кайткан.
Сабан җилен каян,
Каян сизгән наян!
Сабан таңда, сабан,
Бүләкләр дә алган.
Сабан җилен каян,
Каян сизгән наян.

Булат.

Дусларым, каңгырып кайттым,
Дусларым, ерак илләрдән.
Шахтёрлар — батыр егетләр,
Дусларым, сәлам әйттеләр:
Матур кызларга, якын дусларга,
Син дә, кодача, өлешсез калма.
Анда юк урак, анда юк сабан,
Анда икмәкне алалар сатып.

Эшчеләр санын номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар анда. Һай!..

Х о р.

Булат, Булат кайткан... *(Ахырына кадәр.)*

Б у л а т.

Сөйгән яр, бәгырем, хәлеңне,
Сөйгән яр, белә алмыйча,
Зарыгып үскән җилләргә,
Зарыгып чит-ят илләрдә
Сәгатьләр үтте ай-еллар булып,
Раушандай йөзең күрә алмыйча.
Анда юк урак, анда юк сабан,
Анда икмәкне алалар сатып.
Эшчеләр санын номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар анда.

Х о р.

Булат, Булат кайткан... *(Ахырына кадәр.)*

Б у л а т.

Егетләр, мин йөргән җирләр,
Егетләр, мин күргән илләр
Еракта, җылы якларда.
Еракта — кыш булмый анда.
Батыр шахтёрлар ай яктысында
Тимер, күмерләр казыйлар анда.
Анда юк урак, анда юк сабан,
Анда икмәкне алалар сатып.
Эшчеләр санын номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар анда.

Х о р.

Булат, Булат кайткан... *(Ахырына кадәр.)*

Б у л а т.

Менә шул таза эшчеләр
Менә шул җирдә эшлиләр.
Дусларым, нык билләренә,
Дусларым, фонарьлар тагып,
Тезләнеп ятып тирән базларда,
Кәйлә уйнатып эшлиләр анда.
Анда юк урак, анда юк сабан,
Айда икмәкне алалар сатып.
Эшчеләр санын номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар анда.

Х о р.

Булат, Булат кайткан... *(Ахырына кадәр.)*

Ә п т е р и. Ну, Булат, малай, егет икәнсең, йөрәктәгене

әйттең дә салдың бит. Булмаса булган икән, киткәндә, мине дә үзең белән алып кит, мин дә шахтёр булам, малай.

З а һ и р ә. Сиңа тагын шахтёр булу, кыйшык танау.

Көләләр.

Ә п т е р и. Әллә булмас дисеңме?

З а һ и р ә. Булды, ди, сине генә көтәләр, ди, анда.

Ә п т е р и. Булат, шулай диең, эшчеләрне меңләп кенә саныйлар диең анда. Алай булгач, мине дә үз арагызга сыйдырырсыз әле шунда... Энекәш тә үсеп җитте инде, бер колач җирдә ике егеткә эшләрлек эш тә юк монда. Киләсе язга Сабан туена бергәләп кайтырбыз, булды гына, мин дә шахтёр булам. *(Җырлый.)*

Анда юк урак, анда юк сабан,
Анда икмәкне алалар сатып.
Номерлар тагып, эшчеләр санын
Меңәрләп кенә саныйлар анда. Һай!..

З а һ и р ә. Әй надан, кыйланышы. Ха-ха-ха.

Көлешәләр.

Ә п т е р и. Синең шикелле писер булып кайтам да Заһирәне ябыштырып чыгарам.

Б у л а т. Уе яман түгел егетнең. Шулай да ярый ла эш барып чыкса уңайга, мин дә авылдан киткәндә шулай уйлаган идем дә, менә кайткач, муенга асылынмыйлар әле. Алып кайткан бүләкне кире алып китәргә туры килмәсен дип курка башладым...

Н у р ы й. Хәбәрне салды бу.

Көлешәләр.

Н ә с и м ә. Бүләге нәрсәдер бит әле, Мәйсәрә, әйеме?

Н у р ы й. Төтене бу якта икән. *(Мәйсәрәне күрсәтә.)*

Ә п т е р и. Төтен генәме, Мәйсәрәнең битләрендә утлар күренә, яулыгына капмаса ярар иде.

Көлешәләр.

Н ә с и м ә. Бүләкне аны муллага сәдака биргән төсле яшереп бирмиләр. Җырлап, биеп бирергә кирәк аны.

Н у р ы й. Тарт колагын, Гыймади, без дә күрик тамашаны.

Б у л а т. Алай барып чыкмас, кызлар! Минем бүләгем бер генә бит.

Н ә с и м ә. Сөйгән кызың ничә соң синең?

К ы з л а р. Ха-ха-ха!

Ә п т е р и. Булат дус, авызларына саескан төкергән бу халыкны сүз белән җиңә алмассың.

М ә й с ә р ә. Алай димә, Әптери, бүләге нәрсәдер бит әле.

Ә п т е р и. Кара, кара, моның да теле чыкты.

Көлешәләр.

Н ә с и м ә. Алай да, Булат абый, бүләк-бүләк, дисең, бүләгеңне күрсәтмисең.

Б у л а т. Бүләкне бүләк багу мәҗлесендә генә күрсәтәләр бит аны.

М ә й с ә р ә. Күз тиярлек бүләк түгелдер әле.

Ә п т е р и. Кара, кара, бу кошның да теле ачылды. Булмаса булган икән, бүләгеңне күрсәт үзләренә.

Б у л а т. Болай гына бушка күрсәтә торган бүләк түгел.

М ә й с ә р ә. Шахтёр бүләге әллә ни булмас, корымлы яулыктыр әле.

Б у л а т. Корымлымы, корымсызмы — анысы икенче эш, ләкин бушлай күрсәтү юк.

Н ә с и м ә. Кемгә соң ул бүләк?

Б у л а т. Аңа.

К ы з л а р. Кемгә?

Б у л а т. Аңа.

К ы з л а р. Кемгә?

Б у л а т. Аңа.

Н ә с и м ә. Юри маташтыра ул, иске чабата төреп килгәндер әле.

Б у л а т. Чабатамы?

Н ә с и м ә. Чабата.

Б у л а т. Чабатамы?

Н ә с и м ә. Чабата, дим ич.

Б у л а т. Чабатамы?

Н ә с и м ә. Чабата, чабата, чабата...

Б у л а т. Чабатаңны күрсәтим әле мин сиңа. *(Шәлне күрсәтә.)* Менә.

Б а р ы с ы  д а. Шәл — зәңгәр шәл!..

Б у л а т. Чабатамы, киермә борын!

Н ә с и м ә. Кемгә бу шәл?

Б у л а т. Кемгә, дисеңме?

Н ә с и м ә. Әйе, кемгә, дим.

Б у л а т *(шәлне җәеп).* Кемнең кулы җитсә — шуңа.

Н ә с и м ә. Ничек кулы җитсә?

Б у л а т. Менә шулай. Кызлар, бер кызык күрәсегез киләме?

Барысы да. Йә, йә!..

Булат. Егетләр, менә кызларны хәзер биетәбез. Мин шулай басып торам, кем дә кем, биеп, кулымдагы шәлне алса, шәл шуңа булыр.

Заһирә. Валлаһи, диең.

Булат. Валлаһи.

Нәсимә. Таллаһи, диең.

Булат. Таллаһи!

Әптери. Ну, усал икәнсең, Булат малай, кызларны шүрләттең бит.

Нәсимә. Шүрләгән кеше юк әле монда. Биибезме, кызлар?

Кызлар. Биибез, биибез.

Әптери. Тарт колагын, Гыймади, әйдә, кызлар, подходи!

Балет.
Биеп беткәндә, Мәйсәрә шәлне урап ала.

Барысы да. Һап!..

VII. Шулар ук, Җиһанша.

Җиһанша *(керә).* Бу нинди эт көтүе! Югалыгыз хәзер, мәккә кяферләре!

Барын да куып чыгара. Мәйсәрә белән Булат качып кала.

Ишан хәзрәтне каршы алу юк, чиркәү сакчылары, кяферләр... Йортымда шәйтан туе ясап яталар... Шәйтан ялчылары... *(Чыга.)*

Мәйсәрә. Харап булабыз, Булат җаным, җибәр.

Булат. Кайда күрешәбез?

Мәйсәрә. Кичкә кил, көтәрмен.

Качалар. Җиһанша керә.

Җиһанша *(тегеләрне күреп).* Сез монда ни эшлисез, мәккә дуңгызлары? *(Мәйсәрәне тартып ала.)* Ах, син, имансыз, тәре тактасы, югал күземнән!.. Ә син, шахта шәйтаны, кяфер, җаныңа сусаган булсаң, мордар!.. *(Күсәк күтәрә.)*

Булат *(чыгып).* Йә?

Җиһанша *(шәлне ташлап).* Мәккә кяфере, вон моннан, минем йорттан!

Булат. Шулаймы?

Җиһанша. Тәре ясаучы шахта шәйтаны, кяфер башың исән килеш чык моннан!

Булат. Җиһанша агай, синең белән исәнләшкән дә

юк бит әле. Хаҗиларча бер исәнләшеп алыйк, булмаса. *(Каршы бара.)*

Җиһанша *(куркып).* Ах, мәккә кяфере. Ишан хәзрәт, ишан хәзрәт. *(Кача.)* Караул, караул, караул!..

Булат чыгып китә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урта тормышлы татар крестьяны йорты. Киртә койма, киртә капка, бер почмакта кое, өйгә керә торган ишек һәм каралтылар. Карчыклар капкадан керә-керә җырлыйлар.

I. Карчыклар, картлар һәм Байгура.

Карчыклар.

Ишан хәзрәт килгән, ди,
Фатихасын бирә, ди,
Сулышы шифалы, ди,
Сүзләре хикмәтле, ди.

Ишан хәзрәт догасын,
Ихласын алыр өчен,
Нәзер сәдакаларын
Аңа китергән идем.

Капкадан картлар керә.

Картлар.

Ишан хәзрәт кая соң?
Аласы иде догасын.
Карабодай ярмасын
Аз-маз китергән идем.

Карчыклар.

Ишан хәзрәт яткан, ди,
Аштан арып кайткан, ди,
Тавышланып кычкырып
Истихарәсен[1] бозмыйк.

Бергә *(шыпырт тавыш белән).* С-с-с-с!..

Картлар. Ш-ш-ш-ш!.. Менә шунда тавышсыз утырышып сөйләшик.

Утыралар.

---

[1] Истихарә — төш күрү.

Бергә.

Ишаннарның эше рәт,
Эшләре тәрәт-мәрәт.
Дөньяда да рәхәт,
Ахирәттә дә җәннәт.

Кияләр төлке тамак,
Җиккәннәре — аргамак,
Ашаганнары дисәң —
Каймак та кайнар коймак.

Картлар.

Хатын дисәң, дистәләп,
Берсе берсеннән шәп,
Ул яклардан эш рәт
Шәригатьчә торалар.

Җиһанша керә.

II. Шулар ук һәм Җиһанша.

Бергә.

Ә, кем, кара, Җиһанша,
Килгән идек ишанга.
Сәдакабыз бар иде,
Ишан хәзрәткәй кайда?

Җиһанша.

Бир монда.

Беренче карчык.

Сыерыбыз чирләде,
Җәй буе сөт бирмәде,
Менә шушы печәнгә
Ишан өшкерсә иде.
Өй тулы яшь балалар
Сөткә тилмереп торалар.
Менә шушы күкәйләр
Сәдакасыннан булыр.

Икенче карчык.

Атыбыз арт тоягын
Бәреп каерган тагын.
Кара сыер каймагын
Ишанга дигән идем.

Беренче карт.

Быел иген уңмады,
Гошер биреп булмады.
Өсәк төбен сыпырып,
Капчыгым да тулмады.

Икенче карт.

Зинһар, әйт, кайтармасын,
Аласы иде догасын.
Карабодай ярмасын
Аз-маз китергән идем.

Өченче карчык.

Шушы тавыктан башка
Байлыгым юк йортымда.
Нәзер сәдакам иде,
Эче тулы йомырка.

Дүртенче карчык.

Шушы сөлгедән башка
Бирә алмыйм сәдака.
Быел көзгә кече улым
Караладыр солдатка.

Җиһанша *(тавыкка).* Кагынма, кяфер!.. Башыңны борып ташлаганны көтәсеңме әллә. Гөлҗамал әби, бу йомыркаңны ишан хәзрәт алмас, чәберчекләнгән, сәдаканы китергәндә карап китерергә кирәк. Саттар агай, кая сәдакаңны мондарак китер!

Байгура. Бу ярлы-ябага сәдакасы түгел, төгәл биш пот бодай. Үз кулым белән ишан хәзрәткә бирермен, Алла боерса.

Беренче карчык. Ничек кенә булды инде? Кара тавык йомыркасы иде. Ярый, алмаштырырмын, бәбкәм.

Җиһанша. Картлар, ишан хәзрәт хәзер чыгар, тәрәт кенә яңарта. Килгән кире китмәсен. Нишләп монда халык аз күренә. Атна саен ишан китереп булмас, килгәндә кадерен белеп, фатихасын алып калырга кирәк... Мөхәммәтҗан агай, бар, хәзер түбән оч мәккә кяферләренә әйт, ишан хәзрәткә сәдака китерсеннәр, ашка чакырсыннар, фатихасыз утырмасыннар. Ишан хәзрәт, иртәгә иртә белән кайтып китәм, ди. Ә менә ишан хәзрәт үзе дә чыга.

Ишан керә.

III. Шулар ук һәм ишан.

Картлар. Әссәламегаләйкем. *(Кулын үбеп күрешәләр.)*

Ишан. Вәгаләйкемәссәлам.

Пауза.

Болар сезнең сәдакалармы? Аллаһы әкбәр. Теләгән моратларыгыз булыр, фәрештәләр шулай ди.

Б а й г у р а. Менә монысы минем сәдака — биш пот бодай, төп-төгәл. Ышанмасаң, кайткач үлчәп карарсың, төгәл биш пот. Монысы — Ишморатовлар чәе. Мунчадан соң әйбәтләп эчәрсең. Сәдакасына күрә фатихаңны бөдә.

И ш а н. Бу печән кайсыгызныкы?

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Өшкереп кенә бирсәгез лә, ишаным.

И ш а н. Соң ничек, ягъни мәсәлән, эш нидә?

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Сыерыбыз сөт бирми, ятим балалар ач торалар.

И ш а н *(Җиһанша белән колактан-колакка сөйләшә).* Алла сакласын, кем, кортка, сыерыгызның хәле яман. Сезнең сыерыгыз хайваннарның кяфере икән, Алла сакласын, Алла сакласын. Ягъни мәсәлән, Әбүҗәһел сыерының нәселеннән килгән сыер икән. Аның сөтен төннәрдә шәйтаннар, йорт ияләре, шүрәлеләр вә һәм дә төрле-төрле гыйфрит һәм пәриләр савып эчәләр икән. Өшкерергә кирәк, өшкерергә, Алла сакласын, Алла сакласын. Хуш. Ә, ягъни мәсәлән, фараз кылдык, бозавы ни хәлдә, бозавы?

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Бозавы бик таза, бик көр, көтүдә бер бозау.

И ш а н. Менә бөтен хикмәт шул бозауда инде, ягъни мәсәлән, ул бозау  бозау түгел инде.

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Бозау, хәзрәткәем, бозау, бик һәйбәт, бик көр бозау.

И ш а н. Күрер күзгә генә ул бозау, асылда, бозау түгел... шәйтан, ягъни мәсәлән, пәри ул...

Б а р ы с ы б е р г ә. Пәри!.. Кара син Ходайның хикмәтен.

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Булмас, ишанкаем, булмас, пәри булмас. Бозау төсле үк, синдәй-миндәй бозау ул, сикерә дә, акыра да.

И ш а н. Пәри ул, мотлак пәри... Бозау кыяфәтендәге кяфер пәрие асраган кеше оҗмах йөзе күрмәс, дигән китап. Алла сакласын, Алла сакласын, хикмәти Ходa, елдан-ел дөньялар бозыла бара. Моңарчы сыерлар кяфер пәриләр бозауламыйлар иде, хәзер ул да булды. Ахыры заман алдында кяфер бозаулар дөньяны каплар, дигән китап, гөнаһларыгыз күп. Сәдака бирергә кирәк. Мондый хәлләр фиргавен заманында гына булган бит. Хуш, ягъни мәсәлән, фиргавен сыерлары кяфер пәриләр бозаулый торган булганнар. Менә шул кяфер бозауларга фиргавен токымы бара-бара сәҗдә кыла башлаган. Кяфер бозау-

ларны асрау гөнаһларның да иң әшәддесе[1]. Хак мөслимә, мөэминәләргә мөселман бозаулар асрарга кирәк. Сарыкларның гына Алла иманнарын саклый күрсен, Алла сакласын, Алла сакласын.

Беренче карчык. Хәзрәткәем, соң ул кяфер бозавын нишләтәбез инде?

Ишан. Бернәрсә дә әйтә алмыйм, кем, кортка. Шәйтаннар, кяфер, пәриләр белән талаша-талаша картаеп та, арып та киттем инде, Алла сакласын.

Беренче карчык. Хәзрәткәем, зинһар, берәр чарасын күрегез, ул кяфер бозау бәласеннән безне коткарыгыз.

Ишан. Сәдака кирәк, сәдака, Алла сакласын, Алла сакласын.

Беренче карчык. Хәзрәткәем, без наданнарга юл күрсәтүче сез бит инде. Килеп, Алла хакы өчен, шул кяфер пәри бозау бәласеннән коткарыгыз безне.

Ишан. Ярый әле, кортка, бәхетең бар икән, шунысына Аллага шөкранә кыл, әгәр дә шул кяфер бозау үсеп сыер булса иде дә, сөте булып, сөтен эчкән булсагыз иде, ахирәттә кәүсәр шәрабыннан мәңгегә мәхрүм булып калыр идегез. Хуш. Са-Са дигән бер изге карт булган, мең ел тоташтан тау тишегендә бер ялгызы Аллага гыйбадәт кылган, ахыр гомерендә шәйтанның кяфер сыерының сөтен эчү белән, әлеге шул карт оҗмахка керә алмаган, Алла сакласын, Алла сакласын.

Барысы да. Кара син аны!..

Беренче карчык. Соң, хәзрәткәем, ул бозауны кая куярбыз инде?

Ишан. Аны өшкереп, иманга китереп, суеп, сөякләрен кафнун-вәләззаллин догаларын укып, җиде фәрсах кадәр тирәнлектә күмәргә кирәк. Шуннан башка чара юк.

Беренче карчык. Әй Илаһым, гөнаһ дигәнең аяк астыннан көтмәгәндә чыга икән. Ишан хәзрәткәем, нишләрбез икән?

Ишан. Әгәр дә тәүбә, иман, Коръән чыгу сәдакаларын бирә алсагыз, мин аны иманыгызның ныклыгын саклап калыр өчен эшләрмен, Алла сакласын, Алла сакласын. Аның сәдакасы дүрт аяклы мал булырга кирәк, дигән, төя, фәрәс, бәкарь үгез булса да ярый. Бәгъзе риваятьләрдә филне дә дөрес күргәннәр. Кяфер җирендәге ярлы халык өчен ике яшьлек сарык яки утыз си-

---

[1] Әшәд – яман.

гез кадактан ким булмаган бәрән дә дөрес, дигән кыйль бар.

Беренче карчык. Сәдакасыннан тормабыз, ишанкаем, бирербез. Кил, Алла хакы өчен, башыбыздан ул бәлане ала күр инде...

Ишан. Китап мондый эшләрне ашыгычлык белән эшләргә куша. Озакка калганда, ул кяфер бозауның ябалак, ярканат булып очып китү куркынычы да бар, Алла сакласын, Алла сакласын.

Беренче карчык. Хәзрәткәем, ул кяфер бозауны хәзердән үк сезнең кулыгызга тапшырсак, сез аны догалар белән богаулап куеп, ярканат булып әверелергә ирек бирмәс идегез.

Ишан. Мәслихәт, хәтта моның савабы да булыр. Сез аны, беренче әтәч кычкырганда, менә шунда китереп бәйләп калдырыгыз, мин ул кяферне үз йортыма алып кайтып, бая әйткәнчә, иманга китерермен. Аллаһы әкбәр. Ярый, хәзергә өйләрегезгә китеп торыгыз, мин тәһарәт яңартып, нәфел намазларымны укып алыйм. Без иртәгә иртә намазыннан чыгуга кайтырга булдык. Нәфел сәдакалар булса, шул вакытка кадәр китереп бетерегез вә дәхи безнең мондалыгыбызны ишетмәгән мөселманнарга әйтегез, фатихадан мәхрүм калмагайлар иде. Алла сакласын, Алла сакласын.

Байгура. Ишан хәзрәт, намаздан соң безгә рәхим ит. Бик һәйбәт каклап куйган казым бар. Юри сиңа сакладым. Җелек инде, табынга куярга да кызганыч, Җиһанша, син дә кер, рәт тә бар. Төрек малае, дим, хи-хи-хи...

Ишан. Син, кем, Җиһанша, миңа су бирергә куш. Ерак булмаса, үзең шул кяфер бозауны барып кара, Алла сакласын, Алла сакласын.

Барысы да чыгалар.

Җиһанша. Баш өсте, хәзрәт, ерак түгел, күршедә генә *(ишектән кычкыра).* Ишан хәзрәткә тәрәткә су чыгарыгыз. *(Капкадан чыга.)*

Ишан. Алла сакласын, Алла сакласын... Бозавы яхшы булса, токымга калдырырбыз, симез булса, суеп ашарбыз, хи-хи-хи... Алла сакласын, Алла сакласын.

Мәйсәрә чыгып, комган һәм сөлге тотып, йөзен каплап басып тора.

IV. Ишан һәм Мәйсәрә.

Ишан *(як-ягына каранып).* Лә илаһе илләллә... буй-сыны җәннәт хурларыныкы төсле нәкәснең, кая, кы-

зым. *(Мәйсәрәнең беләгеннән тотып.)* Китап тәһарәтне аулаграк җирдә алырга куша. *(Йорт почмагына барып, Мәйсәрәгә карый-карый тәһарәт ала.)* Бисмилләһир-рахмәнир-рахим, чибәр кыз, исемең ничек синең?

Мәйсәрә. Мәйсәрә.

Ишан. Бәрәкаллаһ, күркәм исем, Сөләйман пигамбәрнең дә бишенче хатыны Мәйсәрә атлы булган, ди китап. Алла сакласын, Алла сакласын. Җиһаншаның кардәше буласыңмы?

Мәйсәрә. Әйе. Җиһанша абый белән минем әти бертуган.

Ишан. Хуш, мәрхүм Мифтахетдин кызымыни син?

Мәйсәрә. Әйе.

Ишан. Бәрәкаллаһ, бәрәкаллаһ, әтиең бик әйбәт мужик иде, урыны оҗмахта булсын, амин, Аллаһы әкбәр... Йөзеңне ач, чибәр, ишаннар алдында һәрнәрсәне ачарга китап рөхсәт итә. Менә шулай. *(Йөзен ача.)* А, а, а, бәрәкаллаһ, бәрәкаллаһ!.. Тәмам пешеп җиткән икәнсең. Ягъни мәсәлән, мисле пешкән кура җиләге... Алла сакласын, Алла сакласын. *(Мәйсәрәне сыйпый.)* Мәйсәрә, Мәйсәрә, Мәйсәрә... Бәрәкаллаһ, бәрәкаллаһ. Хуш, йөзеңә караганда, синдә күкрәк авыруы булырга охшый. Өшкерергә кирәк сине. Хуш, күкрәкләрең сызламыйммы?

Мәйсәрә. Юк, хәзрәт, бер җирем дә сызламый.

Ишан. Юк, чибәр, алай кырт кисеп куйма, авыру төрле-төрле була, ди китап, ягъни мәсәлән, әшкарә[1] авыру, батыйн[2] авыру. Эчке авырулар күп вакытта серле булалар. Алла сакласын, Алла сакласын, мотлак өшкерергә кирәк. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим... *(Күкрәкләрен капшый.)* Эһем, эһем, бар шул, бар.

Мәйсәрә. Ни эшлисез, хәзрәт! *(Тартына.)*

Ишан. Күкрәкләреңә җен оялаган, күрекле, Мәйсәрә, аны тузгытырга кирәк. Кая, тагын карыйм әле...

Мәйсәрә. Нишлисез, хәзрәт!

Ишан. Андагы җен оясын тузгытырга кирәк, иманыңны кимереп ята бит ул анда. Ул кяферне кысып чыгарырга кирәк аннан...

Мәйсәрә. Хәзрәт, болай ярамый, мин кычкырам.

Ишан. Алла сакласын, Алла сакласын, әнә күрәсеңме, җенең кычкыртмакчы була. Тыңлама син аны... *(Томмакчы була.)*

---

[1] Әшкарә — тышкы.
[2] Батыйн — эчке.

М ә й с ә р ә. Кагылма миңа, хәзрәт, кагылма, дим...

Кача башлый, Ишан куа.

И ш а н. Җенен качырыйк, ахмак, җенен качырыйк...

М ә й с ә р ә өйгә кереп китә.

И ш а н *(чалма, чапаннарын кия-кия).* Алла сакласын, Алла сакласын, бу нәкәсне мотлак өшкерергә кирәк булыр. *(Тәсбих тарта башлый.)*

Җ и һ а н ш а кайта.

V. И ш а н һәм Җ и һ а н ш а.

Җ и һ а н ш а. Ишан хәзрәт, теге кяфер бозауны карадым, бик көр, симез, таза бозау. Ыруга калдырырга да яраrлык.

И ш а н. Хода кулындагы эш, бәлки, ыруга да калдырырбыз.

Пауза.

Әле, Җиһанша, сиңа сөйләргә дә оныткანмын икән, бая аштан соң яткач, гаҗәп хикмәтле төш күрдем.

Җ и һ а н ш а. Хәерлегә булсын инде, хәзрәт.

И ш а н. Ишаннарга һичбер вакыт шәйтани төш иңми, шаять, хәерле булса кирәк. Төшемдә синең белән икәү йортта менә шулай утырабыз, имеш, алдыбызда ап-ак бер күгәрчен җим җыеп гөлдерәп йөри, имеш... Шуннан соң әнә шул иннектән Хозыр галәйһиссәлам чыкты да, яшел таягын сиңа таба күтәреп: «Әй син, Алла бәндәсе, Мөхәммәт өммәте Җиһанша», — диде.

Җ и һ а н ш а. Хуш, хәзрәт, хуш!

И ш а н. Шуннан соң әлеге ак күгәрченне күрсәтеп, әнә шул күгәрченне ишан хәзрәтеңә, ягъни мәсәлән, мине күрсәтеп, шушы әүлия бәндәгә тотып һибә итеп бир, диде. Ходаның хикмәте, син шул ак күгәрченне тоттың да, минем каршыма килеп: «Хәзрәт, менә шушы күгәрченне сиңа тапшырам, кабул итеп алдыңмы?» — дидең. Мин: «Кабул итеп алдым», — дидем. Шуннан соң биш данә көмеш тәңкә чыгарып мәһәр бирдем, имеш... Шул арада Сөләйман пигамбәр, капкадан кереп, әлеге күгәрчен белән миңа никах укыды. Никах укылгач, Ходаның хикмәте, карасам, әлеге ак күгәрчен, синең тәрбияңдә үскән мәрхүм Мифтахетдин кызы Мәйсәрә булып чыкты.

Җ и һ а н ш а. Бу төш, — Хәзрәт, чынлап та хикмәтле төш.

И ш а н. Мин үзем шулай дип уйлыйм. Алла язганнан узып булмас, дим, ләүхелмәхфүздә безгә кардәш булырга язган булса, аны бозып булмас. Моның өчен миңа карт хатынымны аерырга туры килсә дә, бер хәл итеп булмый инде. Чөнки мөселман кешеләргә берьюлы биш хатын белән тору бик үк мәмдух[1] түгел, мөстәхәбе[2] аның дүрт, дигән китап. Ярый, ястүгә барыйк, тәһарәтең бармы?

Җ и һ а н ш а. Бар, хәзрәт, бар.

И ш а н. Булса яхшы, ястүдән соң шул турыда яхшылап бер киңәш кылырбыз. Китап киңәш белән эш күргәнне күркәм таба.

Җ и һ а н ш а. Ләббәйкә, тәкъсир... Сез ни теләсәгез, шул булыр, китап кушса, үз хәләл хатынымны, аерып, сезгә бирергә риза, калганын үзең кара инде, хәзрәт.

И ш а н. Бәрәкаллаһ... Фикерең бик күркәм, бик күркәм.

Чыгалар. Җиһанша капканы бикли.

Алла, сакланганны саклармын, дигән, капканы бикләп куеп күркәм итәсең, бәрәкаллаһ, бәрәкаллаһ...

Китәләр. Зур пауза.
Музыка.

VI. Б у л а т һәм М ә й с ә р ә.

Б у л а т *(җырлый).*

Канаткайлар кагып очып килдем
Сине сагнып, сине сагнып,
Абау, җаныем, чит илдән.

М ә й с ә р ә керә.

Ал яулык, зәңгәр шәл,
Уңай чакта күршеп кал.

Сандугачларның җырларын
Яшь чагыңда тыңлап кал.

М ә й с ә р ә *(җырлый).*

Керфеккәйләр кагып, ай, саргайды
Сине көтеп, сине көтеп,
Абау, җаныем, чит илдән.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл.

---

[1] М ә м д у х — мактанган, хуп күрелгән.
[2] М ө с т ә х ә б — гүзәл, яхшы.

Бергә-бергә урак урып
Көн итәргә илдә кал.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.
Килерсеңме бүген, көткән ярым,
Әллә син дә, әллә син дә,
Баш каердыңмы миннән?
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.
Раушан йолдыз күптән балкый,
Булатым юк, бу ни хәл?
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.
Кара гына күзең, ай, түнкәреп
Ник моңландың караганда,
Абау, җаныем, күземә?
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.

Б е р г ә.

Бергә-бергә көн итәргә
Кочагыңа мине ал.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.

Б у л а т.

Әйтер сүзең булса әйт үземә,
Һич карамам дошманнарның,
Абау, җаныем, сүзенә.
Башың ялангач икән,
Бөркән зәңгәр шәлеңне.

Б е р г ә.

Чит илләрдә бик күп йөрдем,
Белә алмыйча хәлеңне.

М ә й с ә р ә.

Ал яулык, зәңгәр шәл.

Б е р г ә.

Үткән гомер бигрәк жәл.

Үбешәләр.

М ә й с ә р ә. Булат бәгырем, озакка кайттыңмы?

Б у л а т. Ничек кунак итәрсең бит әле, карап карыйк. Йә, үзегездә Мәйсәрә, ни хәлләр бар?

М ә й с ә р ә. Булат бәгырем, илдә кал. *(Елый.)*

Б у л а т. Син елыйсың, бу ни хәл?

М ә й с ә р ә. Юк, юк, болай гына, шатланганга, куа-

ну гына, белсә иде{ң}, Булат абый, Булат җаным, Булат бәгырем, шулхәтле сагындым; шулхәтле сагындым. *(Сыена.)* Ике ел бит. Хатларыңны кат-кат укып, төннәр буе елап үткәрә идем. Сине күрә алмыйча үләрмен төсле була идем. Заһирә синең кайтканыңны әйткәч, шашам дип торам, тыннарым кысылды, башларым әйләнеп, чакчак кына аяк өстендә кала алдым. Булат бәгырем, безгә монда озак калырга ярамый, хәзер ястүдән кайтырлар. Беләсеңме, син ни эшлә... бар, су буена төш, бераздан мин дә шунда барырмын.

Булат. Әйдә, хәзер үк шунда барыйк.

Мәйсәрә. Юк, ярамый, әйтәм ләсә, хәзер ястүдән кайталар, дип. Аларга самавыр хәзерләп куеп, өстәл хәзерләргә кирәк. Алар яткач та, мин барырмын.

Булат. Аларга?! Карап-карап торам да, Мәйсәрә җаный, борчылып куям. Мин юк чагында монда ала каргаларыгыз, кодаларыгыз, кунакларыгыз, дусларыгыз, күбәебрәк киткән төсле күрәм. Һе, имеш, аларга... Яныңда лачын булганда төкер син ул каргаларга.

Мәйсәрә. Юк ла, ишан хәзрәт белән абый гына, шуларга.

Булат. Ул ишаныгыз әле һаман да Сабан туе саен искечә соранып йөримени? Кая куймакчы байлыгын! Шахта базына төшереп, иманын яңартасы иде кяфернең.

Мәйсәрә. Булат бәгырем, ул ишан хәзрәткә быел әллә ни булган... Әллә саташа башлаган...

Булат. Нигә?

Мәйсәрә. Бая, күзләрен тозландырып, миңа әллә нәрсәләр сөйләп маташа.

Булат. Нәрсә ди?

Мәйсәрә. Әллә нәрсәләр ди... Кулларымны да тота, күкрәкләреңә җен-пәриләр оялаган, ди.

Булат. Аның үзенең чалмасына җеннәр оялаган, карт шәйтанның.

Мәйсәрә. Көчкә качып котылдым, өшкерергә кирәк, ди.

Булат. Ул карт аюның үзен өшкерергә кирәк. Минем кулыма эләксә өшкерермен мин аны.

Мәйсәрә. Булат бәгырем, бу йортта торырлык хәл калмады. Бер яктан, төрле начар сүзләр белән Җиһанша абый тирги, кыйный, икенче яктан, төннәрдә әллә нинди шикле кешеләр килеп, эчеп, сугышып бетәләр, төрлечә мине мыскыллыйлар.

Булат. Җиһанша абзаң әле һаман шул ат караклыгын

ташлый алмыймыни? Аны әллә кайчан, приговор җыеп, авылдан озатасы иде…

Мәйсәрә. Төрмәдә утырган чагында, җаным бер тынычлап киткән иде. Менә шул ишанга кул биргәч, бигрәк тә явызланып китте.

Булат. Мин ул ат карагына күрмәгәннәрен күрсәтермен әле… Менә нәрсә, Мәйсәрә җаным, мин туй итәргә дип кайттым. Туйлар уздырырлык акчам бар, синең уең искечәме?..

Мәйсәрә. Мин әйтергә дә оялам инде, бүген алып китсәң дә риза…

Булат. Алайса, булды гына, берәр атнадан шаулатып туй ясыйбыз икән. Их, Мәйсәрә, ике ел буена йөрәктән китмәдең бит. Караңгы күмер базларында эшләгән чакта, кулларым күмер куптара, күңелем сине уйлый иде. Туйлык сума ясар өчен, ике ел буена ике сменада эшләдем. Минем хәлдән таймый шулай эшләвемә утызар ел шунда эшләүче карт эшчеләрнең дә исләре китә иде.

Мәйсәрә. Мескен, бик кыен булгандыр.

Булат. Эш эш инде, эштән курыккан юк, тик менә ялгызлык бик авыр. Күпме йөрдем, Мәйсәрә җаный, үзебезнең авылдан матур җирне, синнән матур кызны күрә алмадым. Безнең авыл өстенә ай да әллә ничек матур, яктырак булып ялтырый. Әнә шул айга карыйм да, җаннарым рәхәтләнеп китә. Менә шуның шикелле сандугач, тургай тавышларын акча түлим дисәң дә ишетеп булмый анда. Сандугач сайраулары түгел, бака тавышлары да юк анда. Машина шыгырдый да тора, ә күңел һаман сине уйлый иде, малай… Их, мин әйтәм…

Мәйсәрә *(кое бурасыннан сикереп торып).* Харап булдык, кайттылар!

Булат. Су буена төш, күтәрмен.

Мәйсәрә. Ярый, ярый. *(Йөгереп кереп китә.)*

Ишан, Җиһанша Булатны күреп калалар.

VII. Ишан һәм Җиһанша.

Ишан. Бу ни хәл бу, Җиһанша, күгәрченнең карчыгасы бармы әллә?

Җиһанша. Кайгырма, хәзрәт, карчыгасы булса, аучысы да бар аның… *(Күсәк алып урамга чыга.)* Караул, карак, карак! Тотыгыз, тот! Караул!.. *(Куа китә.)*

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Агач келәт. Крестьяннар өчен кирәкле нәрсәләр. Бикәч урыны хәзерлиләр. Кызлар, җырлашып, чыбылдык тегәләр. Урын янында өстәл, урындыклар. Мәйсәрә бер читтә кайгылы утыра, шәле салынып төшкән, башы ялангач. Заһирә, бакчага карап, келәт бусагасында утыра, кызлар «Мәйсәрә» көенә җырлыйлар.

I. Мәйсәрә, Нәсимә, Заһирә, Фатыйма, Сәҗидә һәм кызлар.

Чыбылдыгың чуп-чуар,
Эчләрендә кем кунар.
Сызылып моңсу, якты таңнар аткан чакта,
Мамык мендәр тешләп, кем елар.
Үкси-үкси, Мәйсәрә җан,
Яшь урынына түкмә кан,
Яшь урынына түкмә кан.
Чыбылдыгың бизәген
Ука белән бизәдең.
Бәхилләшеп аерылганда, елый-елый,
Ал яулыгың болгап изәдең.
Үкси-үкси, Мәйсәрә җан,
Яшь урынына түкмә кан,
Яшь урынына түкмә кан.

Чыбылдыгың ак чугын
Бәйрәмнәрдә тагарсың.
Сөйгән ярың, Булат бәгъреҢ исеңә төшсә,
Төнлә ялгыз айга карарсың.
Үкси-үкси, Мәйсәрә җан,
Яшь урынына түкмә кан,
Яшь урынына түкмә кан.

Артта казаклар җырлаган тавыш ишетелә.

Заһирә. Чү, туктагыз әле, кызлар, җыр тавышы.

Барысы да туктыйлар, ишеккә таба баралар.

Заһирә. Әй кызлар, карагыз, кара, атлы казаклар үтә.
Кызлар. Әй Илаһым!..

Казаклар җырлап үтәләр.

Нәсимә. Карагыз, кара, алдагысы ак мыеклы.
Заһирә. Әбәү, мәхәббәтсез, нинди турсаеп утырган, патшамыни!
Фатыйма. Атлары арганнар, мескеннәр.

Саҗидә. Абау, сөңгеләре бигрәк озын, нинди үткеннәр.

Нәсимә. Карагыз, кара, барысының да җилкәсендә мылтык. Болай кораллланып кая баралар икән болар? Әллә төрек солтаны сугыш ачтымы икән?..

Зариһрә. Каратун авыл боярының урманын кискәннәр, ди, шуңа бара торганнардыр, мәхәббәтсезләр.

Нәсимә. Кем әйтә аны?

Заһирә. Абый базардан ишетеп кайткан.

Саҗидә. Әй Илаһым, авыл халыкларын атарга баралармы икәнни, килбәтсезләр.

Заһирә. Шулай шул, базарда шулай дип сөйләгәннәр. Питердан бик күп атлы казаклар киләсе икән, дип сөйләгәннәр.

Нәсимә. Карагыз, кара, каравыл өе алдына туктадылар.

Заһирә. Әй Илаһым, яхшылыкка гына булсын иде инде, бөтен авылны суеп чыкмасалар ярар иде.

Нәсимә. Чү, Заһирә, авызыңнан җил алсын, тузга язмаганны сөйләмә.

Заһирә. Шулай шул, авыл халыкларын камчы белән суктырып, мылтыктан аттырыр өчен генә, ул казакларны асрый, ди, патша.

Саҗидә *(елап)*. Әй Илаһым, монда килеп, безне суеп китмәсләрме икән?

Заһирә. Суйдырды, ди, суйдырмый ни, шул имансызлардан гына суйдырасы калган, ди. Килеп кенә карасыннар — энә белән күзләрен казып чыгарырмын.

Фатыйма. Карагыз әле, кызлар, араларында безнең авыл егетләре юкмы икән?

Заһирә. Булган, ди, булмый ни. Безнең авыл егетләре нишләп авыл халыкларын атып йөрсеннәр?!

Фатыйма. Кушсалар, атмый нишләрсең.

Заһирә. Шул пумала башлардан аттырып торам, ди, менә хәзерләп куйган, ди, кил, ат менә. *(Кукишен күрсәтә, сызгыра.)*

Саҗидә. Син ни эшлисең, Заһирә, күрсәләр, харап итәсең бит...

Заһирә. Күрсеннәр, берәү аз булса, менә икенчесе дә бар. *(Ике кукишен күрсәтә.)* Менә, менә, менә, әй казак, собака, чучка...

Саҗидә. Куй, зинһар, куй, курыкмыйм дигәч тә, монда берүзең генә түгел. Алай курыкмый торган булгач, араларына барып кер...

З а һ и р ә. Казак, собака, дурак. *(Йодрыгын селкеп.)* У-у-у-у!..

Атларга менгән, сөңгеләр күтәргән к а з а к л а р җырлап үтәләр.

Н ә с и м ә. Арттырасың, Заһирә, бер котыра башласаң, чамадан чыгасың.

З а һ и р ә. Әй куян җаннар, сасы казаклардан котлары очты, ха-ха-ха...

Кызлар куркып карыйлар, Заһирә Мәйсәрә янына килә.

Мәйсәрә җаным, болай җебеп торуың бер дә килешми инде, сиздерерсең. Син булдыра алмасаң, үзем яңаклап чыгарырмын моннан, ишан дип тормам.

Н ә с и м ә. Мәйсәрә, нигә болай кайгырасың? Атлы казакларны да карамадың. Озакламыйча, ишан хәзрәт тә килеп җитәр. Чыбылдыкларың да нинди матур булды.

З а һ и р ә. Мин Мәйсәрә урынында булсам өйрәтер идем ул сасы дуңгыз түшен.

Н ә с и м ә. Кемне?

З а һ и р ә. Кемне булсын, сасы тәкә, җитмеш яшьлек ишан киявегезне.

Н ә с и м ә. Тәүбә, диген, Заһирә, ни сөйлисең!.. Ишан хәзрәткә, тәкә, дисең, дуңгыз, дисең... Тфү, тфү, тфү! Тәүбә, диген, җир йотар үзеңне.

З а һ и р ә. Йотты, ди, йотмаган ни. Кан елатып берәүнең яшь гомерен харап иткәне өчен, аның үзен җир йотар әле.

Н ә с и м ә. Булат абзаң сүзләрен сөйлисең. Аңа карасаң, ерак бара алмассың. Алай ярамый, Заһирә, ишан кеше — изге кеше. Бәддога кылса, телең корыр, Алла сакласын.

З а һ и р ә. Минем телем болай да бик коры әле, селәгәем агып тормый. Изге, имеш, аның ише изгеләр Арча базарында көн саен тулып яталар... исерешеп.

Н ә с и м ә. Телгә оста мин дигәч тә, алай чамадан тыш булырга ярамый. Усалмы, яхшымы, Мәйсәрәнең кияве бит ул.

М ә й с ә р ә *(кычкырып елап).* Түгел, түгел, ул минем киявем түгел. Дусларым, үтерегез мине, аның куенында булганчы, җаным тәнемнән чыксын... Коткарыгыз мине, коткарыгыз!

К ы з л а р. Мәйсәрә, Мәйсәрә, нишлисең, болай ярамый.

З а һ и р ә *(Мәйсәрәнең колагына килеп).* Борчылма, Мәйсәрә, борчылма, Булат абый борчылмаска кушты.

Пауза. Мәйсәрә «Зәңгәр шәл» көенә җырлый.

Мәйсәрә.

Газиз башкаемны, ай, саттылар
Суелырга хәзерләнгән,
Абау, җаныем, мал кебек.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Бигрәк читен безнең хәл.

Кызлар.

Сөйгәнеңә кауша алмадың,
Бичаракай, елап кал.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Бигрәк читен безнең хәл.

Мәйсәрә.

Булатымнан башка кибәчәкмен
Сусыз чүлдә корып калган,
Абау, җаныем, тал кебек.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Бигрәк читен безнең хәл.

Кызлар.

Сөйгәнеңә кауша алмадың,
Бичаракай, елап кал.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Бигрәк читен безнең хәл.

Бала *(йөгереп керә).* Апа, әнкәй, хәзер кайтсын, диде, өебезгә атлы казаклар керделәр.

Сажидә. Әй Илаһым, бу ниткән эш тагын?! *(Кайтырга җыена.)*

Тавыклар куып, Җиһанша керә.

II. Әүвәлгеләр һәм Җиһанша.

Җиһанша *(Заһирәгә барып).* Син явыз, кяфер, нишләп монда кеше котыртып торасың! Кем сине монда чакырды, кем чакырды, дим, ә?.. *(Кизәнеп.)* Һу, һу, һу, бетле күз, себерке!

Заһирә. Җикеренмә миңа! Котырган эт төсле, күзләреңне акайтма!

Җиһанша. Ах, син, урам тастымалы, себерке, хәерче, исән чакта югал күземнән! Юкса кабыргаларыңны тетеп, үләксәңне этләргә ташлармын.

Заһирә. Ах, харап, дерелдәп төштем, ди, ха-ха-ха!

Җиһанша. Яхшы чакта чык, дим, кяфер! Уйнаштан туган, ил калдыгы, чык, дим, моннан, вон! *(Җикеренә.)*

З а һ и р ә. Канатларыңны җәймә миңа, мин Мәйсәрә түгел… Мин кайтарып та бирә белермен.

Җ и һ а н ш а. Разбойник Булат абзаң белән минем тирәдә күп йөрсәгез, урәтниккә әйтеп, каеннар санатканга да кыйбат алмам… Чучка борын, кяфер… Йә, нәрсә каттың, чык, дип сиңа әйтәләр бит, чык!.. Әй, үз теләгең белән чыкмасаң, мин сине. *(Һөҗүм кыла.)*

Мәйсәрә уртага төшә.

М ә й с ә р ә. Абый, тимә аңа, ул миңа килгән, минем кунагым.

Җ и һ а н ш а. Нәрсә? Сиңа килгән? Ә-ә-ә… ишан хәзрәт урынына бетле Булатны кияү итеп кертергә җыенабыз, диген, ә!.. Син шул хәерче зимагур Булатлар көненә калдыңмыни, себерке!.. Юк, тора тор. *(Мәйсәрәне алып.)* Менә шунда дөмегеп тор әле, синең белән соңыннан сөйләшербез. Ә син, чучка борын, ана көчек, шәйтан пумаласы, хәзер моннан чыгып кит! Чык, дим мин сиңа, вон, чык! *(Бәрә.)*

З а һ и р ә. Кагылма миңа, карак баш.

Җ и һ а н ш а *(ябышып).* Ах, чучкадан туган үләт, кайчан тоттың, кайчан тоттың! *(Кыйный.)* Нәрсәңне урладым, йә, нәрсәңне урладым!

Кызлар чыркылдыйлар, Мәйсәрә аерырга маташа, Җиһанша Заһирәне кыйнап чыгара.

Ә сез ни дип котырган чучкалар төсле чиныйсыз, әллә сезгә дә кирәкме? *(Кызларга ташлана.)*

К ы з л а р чыгып качалар.

Эзегез булмасын монда, үләт калдыклары, кяферләр!.. Син кая китәсең, кал урыныңда! *(Этеп ега.)*

Мәйсәрә елый.

Нәрсә шыңшыйсың, эттән туган… Пигамбәр урынына калган әүлия ишанга кияүгә биргәннең кадерен белмичә, хәерче зимагур белән уйнаш кылып ята. Кара аны, кызый, мин сине ишан кәләше дип тормам, дуңгыз урынына кисеп, чәчләреңнән аркан ишәрмен. Иртәгә никах, ә ул җыен эттән туган зимагурлар белән маташа. Минем икмәгемне ашап, пәрвасыз[1] кяфер зимагур Булат белән маташа, һуу!

---

[1] П ә р в а – курку, тартыну.

Мәйсәрә. Абый... *(Кычкырып елый.)*

Җиһанша. Ша!.. Шыңшыма, корчаңгы чучка! Кара аны, алай-болай качарга уйласаң, балта белән башыңа бер генә бирермен, анаңа юлдаш булырсың. Сезнең шикелле үз кадерләренә үзләре төкереп йөргән этләрне үтергәнгә суд та юк, закон да юк!.. Балта түтәсе синең башыңны ярырга гына чыдар әле.

Мәйсәрә *(каты кычкырып, ташланып).* Үтер, үтер, хәзер үк үтер. Мин ишанга бармыйм, барыбер качармын, никахтан соң качармын... Хәзер үк җанымны ал, ал, җанымны, газраил!

Җиһанша. Ша!.. Чучка танау!..

Мәйсәрә. Анамны сугып үтердең, мине дә үтер.

Җиһанша *(котырынып, ташланып).* Чәнчел, булмаса, бетерәм хәзер сине дә, бетерәм.

Еракта «Анда юк урак» көенә җыр ишетелә, Җиһанша Мәйсәрәне куып йөреп кыйный.

Мәйсәрә. Булат, Булат, коткарыгыз!.. Коткарыгыз!..

Җиһанша. Әле һаман чукынасыңмы!.. *(Өстенә атланып кыйный.)* Барасыңмы ишанга?

Мәйсәрә *(хырылдап).* Юк.

Җиһанша. Ризамы, кяфер, ризамы?

Мәйсәрә *(хырылдап).* Юк.

Җиһанша. Ишанга барырга ризамы, себерке?!

Мәйсәрә *(көчкә генә).* Юк.

Җиһанша. Юк булса, менә бу бар. *(Кыйный.)* Ризамы, ризамы, ризамы?! Тыныңны чыгарма, кяфер, тәбегә эләккән тычканны бетергән төсле изеп ташлармын. Әгәр ишанга бармасаң, исән килеш бусаганы атлап чыгу юк сиңа!.. Менә сиңа актык сүз, корчаңгы чучка... Ишан хәзрәткә чыкмасаң, җеназаң шул келәттән күтәрелер. *(Чыгып китә.)*

Мәйсәрә ялгыз кала, елый. Җыр һаман ишетелә, Җиһанша арттан кычкыра.

Нәрсә монда җыелдыгыз, кяферләр, югалыгыз моннан!..

Мәйсәрә *(ишеккә ташлана).* Булат, Булат, коткарыгыз, коткарыгыз!..

Җиһанша *(кереп).* Әле һаман Булатмы?

Мәйсәрә *(йөгереп).* Булат, Булат, коткарыгыз, коткарыгыз!..

Җиһанша. Тыныңны чыгарма, чучка! *(Балта алып.)* Актык сүз, ризамы?!

М ә й с ә р ә. Коткарыгыз! Коткарыгыз!

Җ и һ а н ш а. Чукын, булмаса! *(Балтаны атып бәрә, балта тими.)*

Җ и һ а н ш а, шәлне алып, буарга хәзерләнә. М ә й с ә р ә кача. Җиһанша тотып буа башлый, озак көрәш.

Җ и һ а н ш а. Ризамы?!

М ә й с ә р ә. Юк, юк!..

Җиһанша ыржаеп буып, үлгән дип белеп, ташлап чыгып китә. Җыр һаман дәвам итә. Бераздан Мәйсәрә һушына килә башлый, торып ишеккә бара, артта Б у л а т тавышы.

М ә й с ә р ә. Булат, Булат! *(Елый.)*

Б у л а т керә.

III. М ә й с ә р ә һәм Б у л а т.

Б у л а т. Кайда ул, ил корткыч, карак баш, кайда ул?!

М ә й с ә р ә *(ташланып).* Булат, коткар, коткар!

Б у л а т. Мәйсәрә, ни эшләдең син? Авызың-борының кан!

М ә й с ә р ә. Булат, Булат, коткар, коткар!.. Качыйк, качыйк... Кайтып килсә, икебезне дә харап итәр, качыйк...

Б у л а т. Юк, тукта, Мәйсәрә, киткәндә, ул ат карагы белән исәпне бетереп китәргә кирәк. Анда Заһирәне канга батырып эштән чыгарган, монда сине. Юк, юк, ул котырган эт белән алыш-бирешне өзәргә кирәк булыр... Кайда ул?..

М ә й с ә р ә *(ялынып).* Булат бәгырем, мине дә, үзеңне дә харап итмә, әйдә, качыйк, качыйк.

Б у л а т. Барыбер ул эт моның җәзасын татыр, әйдә!

Чыга башлыйлар.

Җ и һ а н ш а *(каршы очрап).* Ә, менә ничек икән, мин сине, егет, күптән көткән идем. *(Ишек ябып, балтасын күтәреп ташланырга тора.)*

Б у л а т *(зур пычагын чыгарып).* Шулаймы?

Тавышсыз һөҗүм бара, әйләнеп йөриләр.

М ә й с ә р ә *(катып торып, тиз генә ишектән чыгып кычкыра).* Караул! Үтереш, караул! Ярдәм, ярдәм!..

Җиһанша балта белән чабам дигәндә, Булат пычагын Җиһаншаның йөрәгенә кадый.

Җ и һ а н ш а. Караул!.. Кар... *(Егылып үлә.)*

Б у л а т *(шашып Җиһаншага карый, артта тавышлар ишетелә, борылып).* Мәйсәрә!.. *(Карана да чыгып йөгерә.)*

Артта шау-шу. «Тот! Пычагын ал!..» дигән тавышлар ишетелә.

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кара урман эчендә яланда шалашлар, землянкалар. Төн уртасы. Зур ут янып тора. Чиләкләр, казаннар асылган. Качкыннар төрлесе төрле якта утырышканнар, ятканнар. М и ң л е г а л и ут яга, П ә т р ә й чабата тукый, Ш ә й х и б а б а й бүрек ямый. Б у л а т ялгыз читтә утыра. Тәмәке тарталар. Кызыл ут шәүләсе аз гына яктырта, тирә-як караңгы. Булат җырлый.

I. Б у л а т, М и ң л е г а л и, П ә т р ә й, М и ш к а, Ш ә й х и б а б а й, Х ә й р и һәм башка к а ч к ы н н а р.

Б у л а т *(җырлый).*

Кара урман шаулый, ирек даулый,
Ирек даулый качкын егетләргә.
Кара урман төсле шаулый-шаулый,
Дошманнарның көнен төн итәргә.
Кара урман шаулый,
Йөрәкләр ярсый
Токтын җәнлектәй.

Кара урман шаулый,
Эчтә ут кайный,
Эчтә ут кайный,
Кайда син, бибкәй?

Кара урман кара күләгәсе
Яшерә алмый качкын эзләрен.
Кара йөрәк — патша күрәзәсе
Эттәй чаба качкын эзеннән.

Кара урман шаулый,
Йөрәкләр ярсый,
Йөрәкләр ярсый,
Тоткын җәнлектәй.
Кара урман шаулый,
Эчтә ут кайный,
Эчтә ут кайный,
Кайда син, бибкәй?

Их, егетләр, белмисез йөрәк хәлләрен, аңлата алмауның авырлыгын белмисез!

Ш ә й х и. Булат улым, карап торам-торам да сиңа, тагын бер карап куям. Уйлап, уйланып торасың-торасың да, тагын бер моңланып, үкереп куясың. Качкын димәсәң, хәтерең калыр, чынлап әйткәндә, качкын даны әрәм сиңа. Сөйгән кызың дию пәрие кочагында аунаганны күрә торып, моңланып, уйланып тору батыр егеткә килешми. Тәндә җан барында көрәшергә, сугышырга, чәйнәшергә кирәк. Көрәшмәгәндә, сугышмаганда, сиңа дигән ризыклар ятлар кулында булачак. Хатын-кызга бер бәйләнсәң, шулай була инде ул. Син егет булсаң, икенче берсен тот йә аны онныт. Оныта алмыйсың икән — монда алып кил.

Б у л а т. Хәбәр биргәнемә ике атна булды, үзе килеп чыкмасмы, дип көтәм.

Ш ә й х и. Килер, тот капчыгың. Ишанның пулатларын ташлап, качкыннар оясына, синең тишек түбәле шалашыңа килде, ди, килми ни!..

Б у л а т. Ул андый түгел.

Ш ә й х и. Хатын-кыз — хатын-кыз инде ул, патша булса да хатын була, чурт булса да хатын була. Кәнфит, прәннек, тәти яулыкка иманнарын саткан халык бит алар.

Б у л а т. Юк, ул андый породадан түгел.

Ш ә й х и. Аларның породалары бер инде. Ул халык бит оҗмахта да маташтырмыйча чыдый алмаган. Их, картаеп киттем, егетләр, уйлану, моңлануларны яратмый торган идем мин. Башка нинди уй килсә, шуны башкаручы егет идем лә мин…

П ә т р ә й. Булат молодец ул, аны обижать итәргә ярамый. Пин дә Марияне сагынып җырлый торган идем, только ул начар хатын булып чыкты, пине ташлап качты. Та, та, та… Пин дә җырлый торган идем.

Т и м у ш. Җырлый идем, дигән була тагын, хөлдерүш танау.

П ә т р ә й. Җырлый идем жул. Ә вот син җырлый белмисең, җырлар өчен, туша кирәк. Булатта туша пар, пиндә дә туша пар, синдә туша юк. Син начар, уңмаган пальшивый монетчик кенә.

Т и м у ш. Ә син кем?

П ә т р ә й. Пин чисный кеже, пин пальшивый монет ясап халыкны алдамыйм. Пин чисный кеже, пин чапата тукыйм, скрипкәдә уйныйм, пашкаларга пиндә усаллык юк. Закон чыкса, пин авылга да кайтырмын, мир пине какмас, ә син авылга кайта алмыйсың.

Т и м у ш. Авылга кайтып бояр урманыннан ун тиенлек юкә урлап, яңадан төрмәгә керерсең, урманнарда хәзерге төсле кырмыска туйдырып йөрерсең.

П ә т р ә й. Син дә пит пулатта тормыйсың.

Т и м у ш. Мин кайчан да булса бер пулатта торачакмын. Минем юлым йә пан, йә пропал. Мин кадалып, шул урманда асылып үлсәм үләрмен, авылга кайтып чабата тукымам. Закон чыгып, иреккә чыгарга туры килсә, иң элек егерме бишәр сумлык, аннан йөзәр сумлык, аннан бишәр йөз сумлык акча суга торган станоклар ясап, дөньясын шундый кыздырыр идем, төтене күккә күтәрелер иде. Ул чагында мин первый гилди миллионер: полиция минем кулда, суд минем кулда, губернатор минем кулда, даже патшаны да кулга алырга була. Ә син, бояр урманыннан ун тиенлек юкә урлап, төрмәдә черерсең, ха-ха-ха!..

Х ә й р и. Тимуш агай, бәр фараз, закон чыгып, безгә авылга кайтырга рөхсәт булса, бәр фараз, син чынлап та баесаң, син миңа бер мең сум биреп торырсыңмы?

Т и м у ш. Юк, бирмәм!

Х ә й р и. Ни өчен?

Т и м у ш. Сиңа мең сум акча бирергә, әллә син минем үги улыммы?

Х ә й р и. Юк, менә танышлык өчен, бергә урманда торганга гына.

Т и м у ш. Әгәр дә мин урмандагы, төрмәдәге, каторгадагы бөтен танышларга меңәр сум бирә башласам, акча ясарга бөтен дөньядагы акча кәгазе түгел, тәмәке кәгазе дә җитмәс. Син, шәкерт, кеше кулына карап көн итәргә маташма, алданырсың.

М и ң л е г а л и. Молодец, Тимуш, ата-ана үгете бирдең шәкерткә. Бу укыган-чукынган халыкны әйтәм әле, кеше кулы белән утлы көл көрәргә яраталар. Син, шәкерт энем, егет кеше буласың килсә, минем арбага утыр. Валлаһи газыйм, мин сине кеше итәрмен. Мин сине шундый аргамакларга атландырырмын, оҗмахта да андый атлар күрә алмассың. Их, егетләр, ат урлауның тәмен, рәхәтен белмисез сез… Монысы юкә урлый, ә монысы шәкерт башы белән солдаттан качып, кара урманда төн саклап ята. Эшмени бу!.. Юк, егетләр, монда ятып күке тавышын тыңлаудан файда чыкмас, ахры, иртәгә миңа фатиха бирерсез, күрәм. Аллага тапшырып, теге Солтангәрәй мирзаның үзе белән хаждан алып кайткан аргамагын сынап карарга туры килер, ахрысы… Йә, бәхетең сынап, минем белән барасыңмы, корчаңгы?

Хәйри. Булмас, куркам мин.

Миңлегали. Куркасыз шул, куркак булгач, дөньяда ук тормаска кирәк иде дә бит сезгә. Сезнең бәхеткә дураклар күп шул дөньяда.

Пәтрәй. Яхшы кеше ат урламый...

Миңлегали. Их, егетләр, ат дигәч тә, йөрәкләргә зәмзәм сулары койган төсле булды. Белмисез, егетләр, ат урлауның рәхәтен, ләззәтен белмисез. Менә караңгы төн, ди. Ындыр аркылы корсак өстеннән килеп, сырт капканың алдына туктыйсың. Йортта эт өрә башлый, син, тыныңны чыгармыйча, күләгә төсле тын торасың. Шул арада аргамак җаныем абзарында пошкырып куя, йөрәкләр тиздән кавышуны сизгәнгә кытыкланып китә, сулышлар кысыла башлый. Капка астын казып йортка керәсең дә, салават укып, агуланган икмәк, ит кисәкләрен эткә ташлый торасың. Бер ярты сәгатьтән Аллага тапшырып эт тончыга. Аргамакның ишегендә чабата хәтле бикләнгән йозак була. Бисмилла әйтеп, отмычка белән келт итеп бер борасың да, йозак шылт итеп борынын күтәреп куя. Абзар ишеге ачылуга, карабодай басуындагы төсле хуш исләр аңкып китә. Аргамак җаныем, көяз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек, шыгыр-шыгыр печән кимереп ята, сылу кызлар көлгән төсле, көязләнеп пошкырып куя. Барып ялыннан тотып сыйпагач, бәгырем, килдеңме, дигәндәй пуф итеп бер сулап ала. Шуннан иренен боргычлап, акрын гына сырт капкадан чыгарасың да, әгузе-бисмилла әйтеп атланып, әйдә... Тфф! Менә шул чагындагы рәхәтне әйтәм, кыз куенына керүләрең бер якта кала шул. Калтырап, дерелдәп торган нык гәүдәсен аякларың белән шундый итеп кочаклыйсың, Таһир Зөһрәсен дә алай кочаклый алмагандыр, йөрәкләрең оҗмах рәхәтләрен сизә инде шул чагында. Сикергән саен, бөтен гәүдәсе уналты яшьлек кызның күкрәкләре дерелдәгән төсле дер-дер килә. Менә шул дерелдәүләрдән йөрәк майларың эреп китә, әйтерсең зәмзәм күлендә йөзәсеңмени, малай... Аның көчле күкрәгеннән болыт-болыт булып чыккан сулышларын, дулкын-дулкын булып җилбердәп уйнап торган ялларын, тояк тавышларын, матур кызлар кулында уйнаган кайчы төсле колак уйнатуларын — барысын-барысын да йөрәк белән сизеп торасың. Шул чакларда үзеңнең гәүдәңне аның гәүдәсе белән бергә туып үскән төсле сизәсең, аның җаны синең җаныңа тоташып, ат белән кеше бер була да кала, шулкадәр җанлы якынлык була... Их, егетләр, ат урлауның

тәмен, ләззәтен белмисез. Ул әле сезнең борыныгызга кермәгән. Их, шәйтан алгыры, тел юк аны аңлатырга!.. Шуңа күрә бик күп кеше аның тәмен дә белми...

Булат. Тотылып, кабыргаларың сынганда нәрсә уйлыйсың?

Миңлегали. Дурак син, болай булгач, синнән ир дә тумас, кыз да тумас, туса да тормас. Әй, ат күргәнең бармыни синең! Бер кыз өчен суешып, кешеләр үтереп йөргәнсең, дуракланып. Әйтерсең лә дөньяда аңа кыз беткән. Андый аргамаклар өчен кабырга түгел, баш та жәл түгел, белдеңме аны, мокыт...

Шәйхи. Карап торам-торам да, егетләр, тагын бер карап куям мин сезгә. Безнең авылның Хәйдәр карт бар иде, шул мәрхүм, бер кешедә ярамаган эш күрсә: «Синең әле, энем, Лаеш шулпасы эчкәнең юк»,— дип әйтә торган иде. Лаеш шулпасы нәрсә соң ул, дисәң, күзләрен кан баса: «Бабаларыңа Грозный патша укыткан әбҗәд[1]», — ди торган иде, мәрхүм. Менә шуның төсле сезнең сүзләрегезне түбәтәем астына салып уйлап карыйм-карыйм да тагын бер уйлап куям. Бәрәкәтсез, төпсез сүзләр сөйлисез, балалар. Берсе ат урлау белән мактана, икенчесе ялган акча сугып дөньяның төтенен күккә күтәрмәкче була, шәкерт һавада очып барган торнадан күкәй сал, күкәй дип, күктән күкәй көтеп ята. Пәтрәй — ул инде юкә белән бергә яралган халык... Я, ярый, син аргамак урладың, ди, син миллионер булдың, ди, шуннан ни була, илгә ни файда?

Тимуш. Илдә минем ни эшем бар, үз рәхәтем миңа рәхәт.

Шәйхи. Шул-шул, Хәйдәр карт әйтмешли, сезнең әле Лаеш шулпасы эчкәнегез юк күренә. Сезнең ул һөнәрләрегез — коры матурлык кына, үзегез — коры юлбасарлар гына.

Миңлегали. Ә синең урәтник, стражник үтергәнеңнең кемгә файдасы бар?

Шәйхи. Илгә файдасы булды, илгә. Әгәр дә мин ул вакыт стражник белән землямерны чәнчелдермәгән булсам, безнең түбән болын боярга китә иде. Ил өстенә төшкән бәлане бер ялгызым күтәрдем дә илне бәладән коткардым. Минем артымда улым да, кызым да, чуртым да юк, ил өчен эшләдем. Закон чыкса, мине илдә ике куллап каршы алырга торалар. Шөкер, моңа кадәр бер җыеннан калдырганнары юк, бер дә качкын дип тормыйлар,

---

[1] Әбҗәд — алфавит, әлифба.

җыенда авылда кунак булам, ә сез ил йөзенә кызыллык кына китерәсез.

Мишка. Правильно, Шәйхи бабай!

Тимуш. Правильно, дигән була, чучка танау, авылыңа кайтсаң, приговор җыеп, аягыңнан асып куячаклар бит сине.

Мишка. Никогда мин авылга зарар китерде юк, мин бояр имениесен яндырган, ещё яндыра. Понимаешь, мин ул боярны бетерә, мин авылга кайтса, тагын боярны яндыра, тагын урманга кача. Мин ундүрт боярны яндырган, ә син жулик, фальшивый монетчик, вот кто син!

Тимуш. Ничек мин жулик, ничек жулик, чучка танау? Нәрсәңне урладым? *(Ябыша.)* Әйт, нәрсәңне урладым, сукин сын?!

Мишка. Брось, Тимуша, брось!

Миңлегали. Сал берне кяфернең салма савытына.

Сугыш.

Пәтрәй. Господи боже мой, господи боже мой... Караул... *(Кача.)*

Булат *(араларына кереп аера).* Туктагыз, Тимуш дус, көннән-көн син канатларыңа ирек бирә барасың, вон моннан! *(Этеп җибәрә.)*

Тимуш. Этмә син мине, сукин сын!

Миңлегали. Тимә син аңа, син кем булдың ул хәтле?

Булат. Молчать!

Тимуш *(Булатның каршына барып).* Нәрсә?

Булат. Тимуш дус, яхшы чакта күз алдымнан югал, вон!

Тимуш *(сызганып).* Югалмасам ни эшләтерсең?

Булат. Югалмасаң, менә шулай тотармын да, вон!..

Тотып этеп җибәрә, Тимуш егыла.

Миңлегали. Теш казнасын кулына тоттыр маңканың.

Тимуш. Ах син, кеше үтерүче каторжник! Син әле монда командовать итәргә уйлыйсың икән. Ах, сволочь, негодяй, сукин сын, мин сине тәкә бугазлаган төсле бугазламасам, исемем Тимуш булмасын! Ах син, бродяга! *(Пычагын ала.)*

Булат *(пычагын чыгарып).* Әйдә, сынашып карыйк.

Әйләнә башлыйлар.

Б а р ы с ы  д а. Ташлагыз пычакларыгызны, ташлагыз!

Аралый башлыйлар.

М и ң л е г а л и. Аралама, ул маңка малай җанына сусаган! Тимуш, када бугазына, када!

Ш ә й х и *(урталарына кереп, салкын кан белән).* Балалар, куегыз, куй!..

М и ң л е г а л и. Тыгылма син, карт шәйтан! *(Төртә.)*

Ш ә й х и *(кычкырып).* Югал күземнән, босяк!

Б а р ы с ы  д а. Син урыныңда утыр, карак баш.

Миңлегалине камыйлар. Хәйри, Шәйхи, Булат Тимушны камап пычагын алалар.

Ш ә й х и. Таралыгыз, балалар, болай ярамый, ярамый... Кара урман уртасында нәрсә бүләргә калган сезгә!

Т и м у ш *(Булатка килеп).* Бир пычагымны!

Б у л а т. Тимуш дус, икенче бу эшеңне күрсәм, синең белән икенче төрле сөйләшермен, аңлап тор. *(Пычагын җиргә ташлый.)*

Т и м у ш *(пычагын җирдән ала-ала).* Карарбыз, минем бу пычак синең эчеңне актарып чыгарырга да кыйммәт алмас. Синең күк сукин сыннарны мин күп күргән.

Ш ә й х и *(каты кычкырып, Тимушка кизәнеп).* Җитәр сиңа, дуңгыз, югал күземнән, босяк!

Тынлык. Пауза. Паузадан соң йомшак тавыш белән.

Ярамый, балалар, ярамый, үзара кырылышу ярамый. Татулык кирәк, татулык. Качкын башларыгыз белән урманда сыеша алмасагыз, белмим инде, кем генә сезне юньгә кертер икән.

Пауза.

Йә, утырышыгыз, бәрәңге дә булган.

Ут тирәсенә утырышалар. Берсе ипи кисеп тарата. Һәркайсы үз кашыкларын төеннәреннән алып килә. Пәтрәй чукына, Миңлегали кычкырып бисмилла әйтә. Ашый башлыйлар. Пауза.

Хәйри энем, Пәтрәй белән икәүләп иртәгә бәрәңгегә барырсыз. Ә сез, Миңлегали энем, Тимуш белән икәүләп ипигә барырсыз. Саламлыга бармагыз, анда сак куелган. Өч-дүрт көннән тагын да эчкәрәк күчәргә туры килер. Ә сез, Мортай белән Иван, иртә таң беленгәч, алпавыт көтүенә барырсыз, сарык, бозау, сыер булса да сыяр, буш кул белән кайтасы булмагыз. Кышны Соры урманында уздырырга туры килер.

Пауза. Ашыйлар.

Булат энем, син соңгы көннәрдә бөтенләй боегып, каңгырып калдың.

Т и м у ш. Әнисен сагынган ул.

Б у л а т. Сагындым шул, әллә мине дә үзең шикелле туң йөрәк дип белдеңме?

Т и м у ш. Ә синдә туңы да, чие дә, пешкәне дә, берсе дә юк. Менә өеңдә булсаң, ботка ашар идең.

Ш ә й х и *(коры гына.)* Балалар, ашагыз!

Пауза.

П ә т р ә й. Без, христианнар, үлгәч, Алла теге дөньяда бәрәңгене пюре итеп, майга бутап ашатыр, ди безнең поп...

М и ң л е г а л и. Әпине балга манчыпмы?

Ш ә й х и. Безгә, Пәтрәй дус, теге дөньяда урманнарда гына качып йөрергә туры килердер. Син түлке иртәгә күбрәк бәрәңге алып кайтырга тырыш, теге аракы заводы кырыннан сыптыр.

Х ә й р и. Син, Шәйхи бабай, юкка алай уйлыйсың, без барыбыз да мәзлүмнәр[1], ә мәзлүмнәр оҗмахлы булыр дигән китап.

Б у л а т. Әй, куйсана әкиятләреңне, без кая да, оҗмах кая! Дөньясы тәмуг булгач, оҗмахы пычагымамыни аның үлгәч...

Х ә й р и. Булат абый, ачуланма, син надан кеше, син Ходайның кодрәтләрен белмисең.

Б у л а т. Син беләсеңме?

Х ә й р и. Мин китаптагыны әйтәм.

Б у л а т. Китаптагыны сез күп әйтәсез. Әнә минем кәләшне бишенче хатынлыкка кычкыртып, кан елатып, урлап алып киткән кабан дуңгызы төсле симез ишан да гел китаптан гына карап сөйли. Китап ул бит сыйпап көн итүчеләргә китап, ә безгә ул итек подмёткасына да ярамый.

Ш ә й х и. Рас та, Булат. Карап торам-торам да мин сиңа, тагын бер карап куям. Егет дисәң, егетләрнең асылы, ир дисәң, ирләрнең батыры, кеше дисәң, кешеләрнең әүлиясы...

Т и м у ш. Әүлия кеше үтерәмени?!

Б у л а т. Минем урынымда булсаң, син кешене түгел, Алланы да үтерер идең.

---

[1] М ә з л ү м – рәнҗетелгән.

П ә т р ә й. Алла үтерергә син евреймены?

М и ң л е г а л и. Син, Булат энем, телеңне кыскарт, Алла белән маташма! Баядан бирле тыңлап торам да, һаман Алла белән булышасың. Синең үзеңнең динсезлегең җиткәч тә, монда мөселманнар бар.

Б у л а т. Синең мөселманлыгың ат урларга гына ярый бит.

М и ң л е г а л и. Тукта, дим, чучка, юкса иманым кяфер булып чәнчелеп китсә китәр, Алла өчен чукынып китәрмен. Бел аны!

Б у л а т. Чукын.

М и ң л е г а л и. Тукта, дим!

М и ш к а. Поптан курка ул.

П ә т р ә й. Поп Алла урынына калган бит.

Б у л а т. Алла кая киткән?

П ә т р ә й. Как кая киткән. Еврейлар аны үтергәннәр.

Б а р ы с ы д а. Ха-ха-ха!..

М и ш к а. Всех попов үтерсә була яхшы.

Б у л а т. Ишаннарны да шулар белән бергә.

М и ш к а. Була яхшы.

М и ң л е г а л и. Син әнә үз побыңны үтер, анда эшем юк, безнең мөселманнарга, ишаннарына тиясе булсаң, менә моны күрәсеңме! *(Йодрык күрсәтә.)*

М и ш к а *(йодрыгын күрсәтеп).* Миндә дә ведь ул бар.

М и ң л е г а л и. Егетләр, Алланы мыскыл итәргә рөхсәт юк, белегез аны, юкса чукынып шаһит китсәм китәрмен... *(Тора башлый.)* Бер Алланы хурларга ирек бирмәм.

Көләләр.

Ш ә й х и. Йә егетләр, тавышланмагыз. Миңлегали энем, дулама, үртәгәнне аңламаска бала түгел лә син.

М и ң л е г а л и. Үртәтермен мин аларга.

Х ә й р и. Их, менә хәзер пылау ашасаң иде.

Ш ә й х и. Әнә кычкырып яткан күкенең койрыгы астында сиңа дигән пылау парланып ята, ди, әнә бар...

Барысы да көлә.

Аллаһы әкбәр. Бүген дә көн үтте.

Тарала башлыйлар.

Б у л а т. Да, егетләр, уен да көлке. Көннәр атналарны, атналар айларны куа, айлар елларны тутыра, гомер уза, киләчәкнең башы-аягы күренми.

Барысы да *(авыр сулап).* Да, күренми.

Пәтрәй. Та-та-та... күренми.

«Яңа кара урман» көенә җырлыйлар.

Хәйри *(башлый).*

Җитәсе ләй җиргә җитә дә генә алмыйм...

Хор.

Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Хәйри.

Канаткайлар гына куеп, ай, оча алмыйм...

Хор.

Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Хәйри.

Туган-үскән илләр, ай, күренми икән...

Хор.

Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Хәйри.

Зарыгып көткән хәбәр, ай, ирешми икән...

Хор.

Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Булат. Кайчанга хәтле соң без шулай, бүреләр төсле, кара урманнарда качынып йөрербез? Кайчанга хәтле иртәгә ни буласын, ни күрәсен, нәрсә белән тамак туйдырасын белмичә, аучы этләреннән качкан куяннар төсле, кеше аягы басмаган яланнарда яшәрбез? Кайчанга хәтле бәхетебезне, көчебезне кара урманнарның караңгы күләгәләренә күмеп, илдән, кешеләрдән аерылып, качкын булып йөрербез? Кайчанга чаклы безне пүнәтәйләр, стражниклар, үрәтникләр, шулай аулап торырлар? Бу сүзләргә җавап табасым килә, сез, егетләр, бу турыда ни уйлыйсыз?..

Пәтрәй. Патшаның закон чыгарганын көтәбез.

Булат. Барыбызны да берәм-берәм тотып, шул агачларга асар өченме? Закон, закон!.. Качкыннар файдасына закон чыгартырга әллә син аларны дурак дип белдеңме?! Безнең шул урман эчләрендә ачка яки туңып үлүдән патшаның нәрсәсе кими?! Безнең урында бездән башка да дураклар табылмасмыни? Их, куегыз законын!

Пәтрәй. Может быть, наследник туар, может быть, война булыр?

Х ә й р и. Әллә, мин әйтәм, түрәләр каршына барып, баш иясеме икән, дим?

Б у л а т. Шуннан соң?

Х ә й р и. Бәлки, кызганып азат итәрләр иде.

Б у л а т. Шәйтаннан иман алырга уйлыйсың син, шәкерт. Барып кара, кызганырлармы икән!.. Сине, солдаттан качкан өчен, иң азында алты елга дисциплинарный батальонга олактырырлар. Тимушны, ялган акчалар сугып, каторгадан качкан өчен, гомерлеккә каторгага сөрерләр. Ат урлап өч кат төрмәдән качкан өчен, Миңлегали агайны сигез елга каторгага пәчнәтерләр. Шәйхи бабайны гомерлеккә каторгага, Мишканы, алпавыт имениеләрен яндырган өчен асарга дип, дар агачы көтеп тора... Шәп бит эшләр, ә? Ха-ха-ха!

Т и м у ш. Син үзеңә өлеш чыгармадың, энекәш. Кеше үтергән өчен, сине дә галава итеп куймаслар.

Х ә й р и. Анысы шулаен шулай да бит, мәңге урманда торып булмас. Ун елдан соң булса да иреклe булып, каторгадан кайтып булыр иде, дим.

Б у л а т. Каторгадан срок тутырып кайткан кешеләр меңгә берәү генә очрый. Катор куркынычлы булмаса, Тимуш та аннан качмас иде. Их, егетләр, йомгакны чуалтуы ансат, сүтүе кыен икән!

М и ш к а. По-моему, вот нәрсә. Урманнарда полно качкыннар. Вот барлык качкыннар бергә җыелып, крестьяннар белән бергә бунт чыгарган, имениеләрне яндырган, помещикларны, урядникларны к чорту матери үтергән, даже чорт с ним патшаны да төшергән, только тогда көн булган, иначы пропала башка.

Т и м у ш. Патшаны үтергәч, атаң башы каламыни? Патшасыз ничек тормакчы буласың, чучка танау? Патша булмагач, кем закон чыгарыр, акча кем сугар?

Ш ә й х и. Юк өчен кайгырасың, Тимуш энем, муены булса, камыты табылыр, этне үтергән белән, аның токымы бетми бит әле.

М и ш к а. Ну да, ну да, ну да, вот, например, Болотников, Булавин, Степан Разин, Пугачёв... беләсез ни эшләгән, всех помещиков, чиновников, дворян суйган.

Т и м у ш. Азактан үзләрен суйганнар.

М и ш к а. Ну так что же! Барыбер безгә көн калмаган, бүген суйган, иртәгә суйган, не всё ли равно кайчан суйган?! А вдруг если победа, ул чагында у-һу-һу!..

Т и м у ш. Әллә патша булмакчы буласыңмы, чучка танау?

М и ш к а. Зачем патша, ул вакыт патша булмас, кирәкмәс.

Пәтрәй скрипкасын сызгырта башлый.

Ш ә й х и. Йә егетләр, урыс әйтмешли, утро вечера мудренее. Үз бәхете үз ризыгы белән килер, күтәргә кирәк. Алай-болай була калса, уң кулга кистәнне, сул кулга күсәкне, билгә балтаны кыстырып, тәндә җан барында поход чыгарга ризамын... Бу көннән, егетләр, бу көнге иректән, сезнең шикелле егетләрдән аермаса, шушы кара урманда үләргә дә ризамын... Уйлап-уйлап торам да, егетләр, тагын бер уйлап куям: староста, старшина, урәтникләр табаны астында изелеп ятудан кара урман уртасында үз ирекле качкын булып яшәүне артык табам. Унике ел качкын булып торам, калган гомерне дә шушында уздырырмын, ахрысы. Егетләр, мин үлгәч, шушы хәзер җырлаган үзебезнең җырны җырлап, үзем төсле карт имән төбенә мине күмәрсез. Имәннең каерысын юнып, ил өчен шушы хәтле, шушы хәтле, ел качкын булып, шушы урманда картаеп үлүче Шәйхи бабайның кабере шушы була инде дип, шәкерт, син язып куярсың. Дөньяның тәгәрмәче бер борылыр әле, шул чагында безне дә искә алучылар табылыр.

М и ш к а. Правильно, Шәйхи бабай!

Б у л а т. Егетләр, минем дә сезгә бер йомышым бар. Шәйхи бабай, син дә яхшылап тыңла: мин авылдан качканнан соң, минем кәләшем Мәйсәрәне әлеге ишан дуңгыз бишенче хатынлыкка алып китте. Менә шул Мәйсәрәгә ике атна элек Мишка аркылы хат язып, үзен монда чакыруым да сезгә билгеле... Менә күрәсез, ул әле һаман юк.

М и ң л е г а л и. Остазбикәлеген ташлап, кара урманга, озынборын туйдырырга сиңа килергә, әллә син аны үзең төсле дурак дип уйлыйсыңмы?

Б у л а т. Сүземне бүлдермә әле. Значит, ул ишан тозагыннан ычкына алмый яисә ишанның зур пулатлары, ефәк күлмәкләре мине оныттыргандыр. Менә, егетләр, Мәйсәрәне ишан тозагыннан коткарырга кирәк, мине оныткан булса *(пычагын чыгарып),* менә шушының белән исенә төшерергә кирәк. Бүген мин шул сәфәргә керешмәкче булам. Кайсыгыз кияү егете булып барырга риза?

Б а р ы с ы  д а. Барабыз, барабыз!

Ш ә й х и. Мин ишанның йортын, капкаларының кайсы якка ачылганлыгын яхшы белгәнгә күрә, минем баруым да кирәк булыр.

М и ш к а. Ишанның йортын яндырырга уйласагыз, минсез эшегез барып чыкмаган. Яндыру минем специальность, значит, мин дә барам.

Х ә й р и. Шәйхи бабай, бәрәңгене ишан бакчасыннан казыганда ничек булыр?

Ш ә й х и. Барып чыкмас. Ни әйтсәң дә, шәкерт шул син, шәкерт, Лаеш шулпасы эчкәнең юк әле шул синең...

Х ә й р и. Кияү егете булып минем дә барасым килә.

Ш ә й х и. Ярый, ярый, барырсың.

П ә т р ә й. Значит, пин тә парам.

Б а ш к а л а р. Без дә барабыз!

М и ң л е г а л и. Мин бармыйм.

Ш ә й х и. Ни өчен?

М и ң л е г а л и. Ишан хәзрәтнең бәддогасыннан куркам.

П ә т р ә й. Куркак ул, трус ул.

М и ң л е г а л и. Тик тор син, побыңны таларга мине чакырып кара, курыкканымны, курыкмаганымны күрерсең...

Ш ә й х и. Туктагыз, балалар, тавышланмагыз. Кайчан юлга чыгабыз? Мин үзем тимерне кызуында сугу ягындамын.

Б у л а т. Хәзер чыгарга кирәк булыр, подрәткә алган эшебез юк ла безнең.

Ш ә й х и. Шулай шул, хәзер чыкканда да иртәгә төнгә генә барып җитәрбез, йә егетләр, юл кешесенең юлда булганы яхшы, хәзерләнегез! Ә син, Тимуш, Миңлегали белән икмәккә барырсың. Булатның туена шәйтан зәмзәме таба алмассызмы, тырышып карагыз! Ә сез алпавыт көтүенә барырсыз! Ә син, Чимон, ояны сакларсың, андый-мондый хәл була калса, елан куаклыгына безгә каршы килерсең. Без берсекөнгә төнлә кайтып җитсәк кирәк.

Б у л а т. Егетләр, минем туйны шундаен итәрбез! Кызыл әтәч койрыгының шәүләсеннән бөтен дөнья ялтырар, шулай бит, Мишка?

М и ш к а. Думаю, что ишанның пулаты яхшы янар.

Ш ә й х и. Йә егетләр, булган булсагыз утырышыгыз.

Юлга чыгучылар кайсы күсәк, кайсы кистән яки берәр башка нәрсә тотып утырышалар. «Качкыннар» көенә җыр башлана. Музыка.

Б у л а т *(җырлый).*

Туган илләреннән аерылып,
Киек-җәнлек төсле боегып,
Гомерләре сүнә качкыннарның,
Кара урманнарга сыенып.

Х о р.
Без качкыннар, киек-арысланнар,
Урман — безнең ватаныбыз, илебез. *(Тагын бер кат.)*

Б у л а т.
Зур калалар безгә

Х о р.
Кара урман.

Б у л а т.
Ташпулатлар безгә

Х о р.
Киң ялан.
Аргамаклар, йон түшәкләр,
Кама бүрек, пустау камзул кирәкми,
Падишаның сенаторы, үрәтниге,
Прокуроры кирәкми.
Чум, чум, чум, чум — закон безгә нипочём.

Б у л а т.
Биек тә биек тау менеп,
Лачын төсле үткен күз сирпеп,
Күзләсә дә туган илкәйләрен,
Күрә алмый качкын, зар егет.

Х о р.
Без качкыннар, киек-арысланнар,
Урман — безнең ватаныбыз, илебез.

Б у л а т.
Зур калалар безгә

Х о р.
Кара урман.

Б у л а т.
Ташпулатлар безгә

Х о р.
Киң ялан.
Аргамаклар, йон түшәкләр,
Кама бүрек, пустау камзул кирәкми,
Падишаның сенаторы, үрәтниге,
Прокуроры кирәкми.
Чум, чум, чум, чум — закон безгә нипочём.

Җыр кабатланып, бию башлана. Әүвәл берәм-берәм, аннары бары бергә биешәләр. Шау-шу, ыгы-зыгы.

П ә р д ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур бакча. Уңда ярым бояр, ярым шәрык стилендә эшләнгән йортка керә торган терраса һәм баскычлар. Сулда каралтылар. Бакча рәшәткә койма белән ихаталы. Уртада капка. Капканың ике ягында фонарьлар. Артта авыл мәчете, тегермәннәр һәм авыл күренә. Мәйсәрә эскәмиядә утыра, җилкәсендә зәңгәр шәл.

«Зәңгәр шәл» көенә җырлый.

I. Мәйсәрә ялгыз.

Мәйсәрә.

Башкынаем ялгыз, күңелем боек,
Далаларда ялгыз калган,
Абау, җаныем, тал кебек.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл.
Базарларда сатыла торган
Маллар төсле үк безнең хәл.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл.
*(Ак чәчәк канатларын йолкый.)*

Беребез генә анда, беребез монда,
Закладларга гына салган,
Абау, җаныем, мал кебек.
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәү, алты, җиде генә,
Сигез, тугыз, ай, ун гына,
Сөйгән ярым ул гына.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл.

II. Мәйсәрә һәм Хәдичә.

Хәдичә *(чыгып).* Бу ниткән эшең, оятсыз. Көпә-көндез ишан йортында, урактан кайтучы хатын төсле, авыз күтәреп улап ятасың. Яшь хатын дигәч тә, бик иркәләнеп китмә әле. Менә җирбит, остазбикә башы белән оялмыйча җырлап утыра, халык икендегә җыела. Тапкан эш, оятсыз. Ни әйтсәң дә шул, мажик кызы мажик кызы була икән.

III. Мәйсәрә, Хәдичә һәм Мәрфуга.

Мәрфуга *(чыга).* Дөньяларын онытып, җәелеп утырырга нинди рәхәт урын тапканнар. Гайбәтемне чәйнәргә шуннан да уңайлырак урын тапмадыгызмыни, мескеннәр,

әй үләтләр!.. Берсе кабер якасына баскан, икенчесе — кеше үтерүче калдыгы, шулай да кеше тикшергән булалар бит, еланнар.

Хәдичә. Сине ялчы Галәви тикшерсен, без сине тикшерергә калмаган, кирәгең дә шулкадәр генә. Ишан хәзрәтнең фатихалы йортын уйнаш йорты итеп бетердегез инде, оятсызлар.

Мәрфуга. Әй карт үләт, убырлы карчык, фатихалы йорт дигән була тагын. Әгәр син юньле булсаң, өстеңә дүрт көндәш алмаган булыр идең. Дәҗҗал карчыгы, шәйтан анасы, мунча пәрие...

Хәдичә. Җикеренмә миңа, себерке, мин синең шикелле ялчыдан ялчыга, көтүчедән көтүчегә күчеп йөрмим...

Мәрфуга. Тоттыңмы, шакшы танау! Йә, әйт әле, кем белән тоттың?! *(Төрткәли.)*

Мәйсәрә. Туктагыз, кешедән оялыгыз! *(Аермакчы була).*

Мәрфуга *(Мәйсәрәгә).* Нәрсә?.. Нигә син безнең эшкә тыгыласың, себерке... Без сугышырбыз да, килешербез дә, бездә эшең булмасын.

Хәдичә *(Мәйсәрәгә).* Төшкәненә көн булмаган мажик башы белән хуҗалык итмәкче була, кортлы баш.

Мәрфуга. Син яшь хатын дип бик кәпрәймә, тутый кош, безнең юлбасар сөяркәләребез юк.

Мәйсәрә. Туктагыз, юкса мин сезне! *(Ташлана.)*

Мәрфуга. Ай-һай-һай, синең кеше үтерергә осталыгың бармы әллә?

Хәдичә. Кеше үтерергә теләсәң, бояр урманына бар, сөяркәң янына.

Мәйсәрә. Туктагыз!.. Нигә сез мине болай рәнҗетәсез, нигә сез хатын була торып, хатын йөрәген аңлый алмыйсыз! *(Елый.)*

Мәрфуга. Елаган булып кызгандырмакчы була, чегән марҗасы.

Хәдичә. Җыен юлдан язган, җыен эштән чыккан, җыен урам себеркеләре безгә җыелган.

Мәрфуга. Каян килгән мунча әүлиясы... Безне сукыр суфи белән тоткан кеше булмады әле.

Хәдичә. Тукта, дим, уйнашчы!

Мәрфуга. Кычкырма миңа, корчаңгы эт!

Хәдичә. Тукта, дим!

Мәрфуга *(кукиш күрсәтеп).* Менә туктады, ди, менә, менә!

Х ә д и ч ә. Тукта, дим.

М ә р ф у г а. Җикеренмә миңа, карт убыр!

IV. Ш у л а р  у к  һәм С а б и р а.

С а б и р а *(чыгып).* Бу ни эшегез, җирбитләр, хәзрәткә йокларга ирек бирмисез!

М ә р ф у г а. Әй, сәләмә борын, кыланышыннан үләрсең бит.

Х ә д и ч ә. Алай.

С а б и р а. Көнләшәбез, диген, әй мескеннәр.

М ә р ф у г а. Бик исебез китте инде. Яфрак асты Рамазан кызыннан көнләшеп торабыз, ди, кыланышыннан үләрсең, ха-ха-ха...

Х ә д и ч ә. Алай, дөньяга сыя алмый, карак!

С а б и р а. Карак булып нәрсәләреңне урладым, нәрсәләреңне урладым? *(Бәйләнә.)*

Х ә д и ч ә. Канатларыңны җәясе булма, бер тешеңне калдырмам.

С а б и р а. Син коярлык тешләр чыкмаган әле... Әй бетле бикә, карт пәри.

М ә р ф у г а. Тукта әле, ни дип болай күперенәсең, шакшы, карак, хәерче!

С а б и р а. Ә син ана мәче!

Х ә д и ч ә. Барыгыз да бер, бер-берегездән артык җирегез юк. Берегез карак, берегез уйнашчы, берегез юлбасар калдыгы — барыгыз да бер.

М ә р ф у г а. Нәрсә?

Бергә бәйләнәләр, төрткәлиләр.

С а б и р а. Кайчан тоттың, карт пәри, кайчан тоттың?

Кыйныйлар.

М ә й с ә р ә *(аерып).* Туктагыз, туктагыз!.. Ярабби, нинди хурлык, оялыгыз. Әнә картлар икендегә бара, туктагыз, оятсызлар!

М ә р ф у г а, С а б и р а, Х ә д и ч ә *(сугышуларыннан туктап, бергә).* Ай-һай-һай!.. Каян килгән хан кызы соң син, ә? Аның карагы иде, сөйгән егетең — кеше үтерүче-юлбасар.

С а б и р а. Юньле булсаң, дүрт көндәш өстенә, сәлперәйгән картка да чыкмас идең.

Х ә д и ч ә. Байлык кирәк булган аңа, ишан хәзрәтне юлбасар сөяркәсе белән бергәләп үтереп, баерга уйлаганнар, бетле баш, остазбикә буласы килгән, корчаңгы.

Мәйсәрә. Зинһар, туктагыз.

Мәрфуга. Төшкәненә бер көн булмаган, нинди чәпчегән була, зимагур калдыгы, юлбасар үләксәсе.

Хәдичә. Ташландык, тастымал.

Сабира. Мунча ләгәне.

Мәрфуга. Кеше үтерүче.

Мәйсәрә *(аяк тибеп, бик кычкырып).* Туктагыз яхшы чакта!

Мәрфуга *(өстенә барып, төртеп).* Туктамасак ни эшләтерсең? Менә мә! *(Кукиш күрсәтә.)*

Хәдичә *(чеметеп алып).* Азгын эт.

Сабира. Башкисәр.

Мәйсәрә *(барын бәреп).* Кагылмагыз миңа!

Мәрфуга. Ә, алаймыни, безне кыйнамакчы буласың икән әле!

Хәдичә. Менә сиңа, менә сиңа!

Мәйсәрәне кыйный башлыйлар.

Мәйсәрә *(каты кычкырып).* Үтерәләр, үтерәләр, коткарыгыз!..

V. Шулар ук һәм ишан.

Ишан, камчы тотып чыгып, барысын да камчы белән кыйный башлый. Мәйсәрә егылган җирендә кала, аны да кыйный.

Ишан. Кяферләр, шәйтан арбалары, иблис ялчылары, рәхәтләнеп йокларга да бирмиләр. Әрәмтамаклар! Сиңа ни җитмәгән тагын, мордар, хәерче, хинзир[1], күн тәпи, зимагур калдыгы. Алла сакласын, Алла сакласын, хуш...

Мәйсәрә. Үтер мине, үтер, синең йортыңда яшәгәнче, кабер газабы артыграк булыр.

Ишан. Чинама, юньсез! Бар, бар, дуңгыз, бар!.. *(Мәйсәрәне кыйнап кертә, үзе дә керә.)*

Пауза.

Малай *(капкадан кереп).* Әссәламегаләйкем. *(Якягына карана.)* Кеше юк икән... *(Терраса ишегенә барып.)* Карт абыстай! Ау-у, карт абыстай, дим. Нишлиләр анда?.. Кемнәрдер кыйныйлар бугай. Инде нишләргә кирәк? Керсәң, мулла абзый кыйный, өйгә кайтсаң, әни кыйный... Менә ничек сука ташка терәлә икән ул. Карт

---

[1] Хинзир – дуңгыз.

абыстай, карт абыстай!.. Галәви агай, Галәви агай!.. *(Йорт буйлап кычкыра.)* Галәви агай, дим!.. *(Кулларын авызына куеп.)* Галәви ага-ай!.. Ни булган боларга? Чукынды, хатын, тот кәҗәне – шул була, күрәсең!.. Абыстайларны күрмичә китү юк, үлмәгәннәр булса, бер чыгарлар әле. *(Террасага менеп.)* Карт абыстай! Икенче абыстай, дим!.. Өченче абыстай, дүртенче абыстай, бишенче яшь килен абыстай!.. Юк, әллә чебен даруы ашап дөмеккәннәрме икән?.. Галәви агай!..

VI. Малай һәм Галәви.

Галәви *(килә).* Нәрсә акырасың, маңка малай, үлгәннәр дип белдеңме әллә!

Малай. Әссәламегаләйкем.

Галәви. Бар, бар, үкчәң күтәр!

Малай. Аш өстәлгә куелды, абыстайларны көтәләр иде. Әни әйтә, хәзер килеп җитсеннәр, токмачым куера, ди.

Галәви. Бар, үзләренә әйт.

Малай. Өйдә кеше юк бугай. Кычкырдым инде, эндәшмиләр. Әни әйтә, хәзер килсеннәр, ди. Өченче кат килүем инде.

Галәви. Тыгынасылары килсә барырлар.

Малай. Менә, Галәви агай!..

Галәви. Акырма, дим, кунакчадагы тавыкларны куркытасың, бар, ишекне дөбердәт! *(Китә.)*

Малай *(ишекне дөбердәтеп).* Абыстайлар, әй абыстайлар! Карт абыстай, икенче абыстай, өченче абыстай!..

Ишан чыга.

VII. Ишан һәм малай.

Ишан *(малайны ишек белән бәреп).* Нәрсә акырасың, дуңгыз малай?

Малай. Әссәламегаләйкем.

Ишан. Дуңгыз, сафсата! *(Таягы белән малайга суга.)* Ишектән тыңлап йөрүең өчен күрсәтермен мин сиңа, чучка, сафсата! Югал, дуңгыз малай!

Малай *(каушап, елап, аркасын кашый-кашый).* Әни әйтә, абыстай куера, ди, токмачлар килсеннәр, ди, әни... Әй, әни әйтә, абыстайлар...

Ишан. Нәрсә туглыйсың, сафсата!

Малай *(бөтенләй каушап).* Әни әйтә, абыстайлар өстәлгә... Әй, ни, токмач куера, ди... *(Елый.)*

И ш а н. Эшсез фиргавеннәр токымы, монда чыгыгыз! Алла сакласын, Алла сакласын. *(Чалма, чапаннан намазга китә.)*

А б ы с т а й л а р берәм-берәм чыгалар.

VIII. М а л а й һәм Х ә д и ч ә.

Х ә д и ч ә *(чыгып).* Нәрсә бар?

М а л а й. Әни әйтә, хәзер килсеннәр, ди, токмачым куера, ди.

Х ә д и ч ә. Мине генә чакырдымы? Карт абыстаң килсен, дидеме?

М ә р ф у г а чыга.

IX. Ш у л а р  у к  һәм М ә р ф у г а.

М ә р ф у г а. Сине генәдер шул. Сине үзеңне генә әнә зиратка чакыралар, ди, кабер дә хәзерләнгән, ди...

С а б и р а чыга.

X. Ш у л а р  у к  һәм С а б и р а.

С а б и р а. Юк инде, алай икәү генә сыйланып йөрмәгез, бу юлы минем нәүбәтем.

М а л а й. Әни әйтә, барысы бергә, көтүләре белән җыйналып килсеннәр, ди, аш җитәрлек, ди.

М ә р ф у г а. Яшь абыстагыз авыру, бара алмый, дүртенче абыстагыз өйдә юк, башкалары хәзер киләләр, диген.

XI. Ш у л а р  у к  һәм Ф а з ы й л ә.

Ф а з ы й л ә *(күчтәнәчләр күтәреп керә).* Нишләп өйдә булмыйм, өйдә ич мин, өйдә. Менә мин. Ялганлый ул карт убыр, барысы да җыйналып, көтүләре белән киләләр, диген... Син нишләп минем өчен атвокат буласың, нигә мине генә һаман читкә кагасыз?

Х ә д и ч ә. Соң өйдә юк идең ләбаса.

Ф а з ы й л ә. Менә кайттым ич.

Х ә д и ч ә. Кайтсаң барырсың.

Ф а з ы й л ә. Барырмын шул. Ашыйсым да, эчәсем дә бер генә дә килми, юри сезгә үч итеп барам... Әнкәй шулкадәр сыйлады үземне, тутырган тавык, пилмән, гөбәдия, бәлеш, ике төрле паштет, ак майга гына пешкән коймак, бал, конфет, варение, чикләвек. Шартлыйм дип торам.

М ә р ф у г а. Юкка шартламагансың.

Ф а з ы й л ә. Билләһи газыйм, шартлыйм дип торам, уф!.. Хәзер дә көчкә-көчкә генә тын алам, уф! Безнең

әни ашны бик тәмле пешерә, ишан хәзрәткә дә күчтәнәч алып кайттым.

Малай. Токмач куера, ди.

Хәдичә. Хәзер, хәзер киләләр, диген, бар, акыллым.

Малай китә.

Сабира. Бу юлы Коръән мин укырмын.

Мәрфуга. Ай-һай, каян килгән мулла кызы! Тот капчыгыңны, минем нәүбәтем, сәдака да миңа.

Сабира. Синнән сорамыйлар, бу юлы сәдака миңа булыр.

Фазыйлә. Коръәнне теләсәгез кайсыгыз укыгыз, анда минем эшем юк, сәдакасы миңа булыр…

Мәрфуга. Коръән уку миңа, сәдакасы синамыни? Ай-һай, акыллы баш икәнсең, кем кызы соң син?

Хәдичә. Тагын тотындылар. Наданнар белән надан булыр хәлем юк, сәдаканы үзем алам…

Мәрфуга. Кадалып кит, гүр сәдакаң булсын.

Төртешә-төртешә, өйгә кереп китәләр. Пауза. Заһирә яшеренеп капкадан кереп карана.

Заһирә. Йортлары шул диделәр, үзе күренми. *(Тәрәзәләрдән карый, тавыш ишеткәч, агачлыкка кача.)*

Хәдичә *(өй эченнән кычкыра).* Галәви, Галәви!

Галәви. Ни бар? Хәзер.

XII. Галәви һәм Хәдичә.

Бер яктан Галәви, өйдән Хәдичә чыга. Музыка. Җыр. Хәдичә, кулы белән Галәвигә изәп, эскәмиягә утыра.

Хәдичә *(җырлый).*

Галәветдин, кил утыр,
Йорт буш кала, белеп тор,
Шушы нык йозак белән
Капкаларны бикләп тор.

Исеңдә тот ныгытып,
Йөрмә дөньяң онытып.
Менә сиңа әчкечләр,
Бөтенесен бикләп тот.

Без китәбез мәҗлескә,
Мәйсәрә кала эчтә,

Кача-нитә күрмәсен,
Китеп йөремә читкә.

Барысы да киенгән-ясанганнар, чапаннар бөркәнгәннәр. Берәм-берәм чыгалар.

XIII. Шулар ук һәм Мәрфуга.

Мәрфуга.
Нигә яптың шәлемне,
Һә, үз шәлең җәлмени?
Кая, сал-сал, карт убыр,
Шәлсез дә син бик матур.

Хәдичәнең шәлен йөзенә ташлый, үз шәлен алып ябына.

XIV. Шулар ук һәм Сабира.

Сабира.
Ниткән эшегез бу тагын,
Кайсыгызда чапаным?
Ник дәшмисең, себерке,
Ник монысын алмадың?

Кулындагы чапанны Мәрфугага ташлый, Мәрфугадан чапанын алып бөркәнә.

XV. Шулар ук һәм Фазыйлә.

Фазыйлә.
Кәвешемнең сыңгарын
Кайсыгыз кигән тагын?
Синдә ич, әйт, кигәндә
Нәрсә генә карадың!

Кулындагы кәвешне ташлый. Сабираның аягыннан кәвеш алып кия.

Хәдичә.
Төпсез, тузган әрҗәләр
Юк өчен әрләшәләр,
Килбәтләрен күр инде,
Нәкъ кысыр, мут кәҗәләр.
Барысы да.
Ә син елан, карт убыр,
Үзеңне бел, тик утыр.
Галәви.
Их, маллары, маллары,
Берсеннән-берсе матур.
Мәрфуга.
Күлмәгем килешкәнме?

С а б и р а.
Кершәнем шәп төшкәнме?
Ф а з ы й л ә.
Сөрмәм барып чыкканмы?
Х ә д и ч ә.
Теш кынам шәп кунганмы?
Б а р ы с ы  д а.
*(Мәрфугага)*
Күлмәгең килешмәгән.
*(Сабирага)*
Кершәнең шәп төшмәгән.
*(Фазыйләгә)*
Сөрмәң барып чыкмаган.
*(Хәдичәгә)*
Кынаң бер дә кунмаган.
Х ә д и ч ә *(ачуланып).*
Ярый, сез генә матур.
Б а р ы с ы  д а.
Тик кенә тор, карт убыр!
Г а л ә в и.
Җыеныгызның хакы
Сукыр груш — бер бакыр.
Б а р ы с ы  д а *(Галәвигә).*
Хәерче эт, син тик тор,
Каян килгән йон батыр!
Г а л ә в и.
Потка салсаң, бәягез
Бакыр шул — сукыр бакыр.
Хи-хи-хи!..

Хәдичәдән башкалары борылып, пыр итеп китәләр.

Х ә д и ч ә. Туктагыз, дим, мине көтегез!

Борылалар.

Галәви, дим!
Г а л ә в и. Әү, дим.
Х ә д и ч ә. Без Колаксыз Зариф хатынына ашка барабыз.
Г а л ә в и. Барыгыз, рөхсәт.

Пыр итеп китәләр.

Х ә д и ч ә. Туктагыз, дим, туктагыз, мине көтегез!

Кире киләләр.

Кеше көлдереп, адашкан киек казлар төсле таралышып йөрмик. Төшендеңме, Галәви?

Г а л ә в и. Хәзергә юк әле.

Х ә д и ч ә. Туң баш, Мәйсәрә йортта ялгыз кала, дим, капкаларны яхшылап бикләә, ишан хәзрәтнең әмере шулай... Йә, әйдәгез инде.

Тезелеп китә башлыйлар.

Туктагыз! *(Әйләнеп Галәвигә килә.)*

Башкалар аның артыннан киләләр.

Төшендеңме?

Г а л ә в и. Төшенмәслек нәрсә бар соң монда?

Х ә д и ч ә. Йә, әйдәгез.

Китәләр, кинәт туктап.

Юк, туктагыз! *(Галәвигә.)* Яхшы бикләә, ачкычны җуя күрмә!

Г а л ә в и. Ярар. *(Мәрфуганы төртә.)*

Мәрфуга бармак яный.

Х ә д и ч ә. Йә, әйдәгез! *(Китәләр. Капка төбендә кинәт туктап тора да Галәвигә килеп караша.)* Әйдәгез! *(Чыгып киткәндә.)* Туктагыз!

Музыка.

Х ә д и ч ә.

Юл уң булмас кудырып,
Дога кылыйк утырып.

Б а р ы с ы  д а.

Йөри шунда котырып,
Белер-белмәс укынып.
Әй Ярабби, Ходаем,
Насыйп иткел уңаен.

Гошер һәм фитырларга
Җибәреп тор бодаен.
Юлларыбыз киң булсын,
Сәдакалар мул булсын,
Әнваг-әнваг нигъмәткә
Өстәлләр тулып торсын.

Әй Ходаем, син үзең
Мажикларның ач күзен,

Мәҗлесләр булып торсын,
Җәй, кыш, язын һәм көзен.

Йортка бәрәкәт җибәр,
Тиздән ишан да үләр.
Яшь, чибәр кияү җибәр.
Амин, Аллаһы әкбәр!..

Тезелешеп чыгып китәләр, музыка уйный,
Галәви телен чыгарып үртәп кала.

Г а л ә в и. Их-хи-хи-хи, убыр кулында никадәр мал әрәм ята бит?! Сабанга җиксәң, сабан тартырлык хатыннар, мин сиңа әйтим, әрәм яталар, их-хи-хи-хи. Алтын Иванда, хатын ишанда, диләр шул. Яшь бишенчесе рәтле күренә, ни өчендер, бер дә күз атмый. Гомер булса, бәлки, ишан хәзрәт анысыннан да гошер чыгарыр әле. Бер башына бишәү бит, чукынган! *(Каралтылар арасына кереп югала.)*

Караңгылана башлый. М ә й с ә р ә чыга да паузадан соң «Зәңгәр шәл» көенә җырлый.

XVI. М ә й с ә р ә ялгызы.

М ә й с ә р ә.
Очып кына узган киек казлар.
Әйтсәгез лә Булатымның,
Абау, дуслар, хәлләрен.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Узган гомер бигрәк жәл.
Базарларда сатыла торган
Маллар төсле безнең хәл.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.

Күрдегезме аны, кошкайларым,
Әллә үләннәр басканмы,
Абау, җаныем, каберен.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.
Базарларда сатыла торган
Маллар кебек безнең хәл.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.

XVII. М ә й с ә р ә һәм З а һ и р ә.

З а һ и р ә *(куак артыннан).* Мәйсәрә!

М ә й с ә р ә *(куркып).* Син кем?

З а һ и р ә. Акрын, Мәйсәрә, хәбәр китердем.

М ә й с ә р ә. Тукта, саташаммы юкса мин? Заһирә җаным, ничек киләсе булдың?

З а һ и р ә. Абыйдан хәбәр алдым.

М ә й с ә р ә. Булат бәгырем исән? Йә, йә, тизрәк-тизрәк сөйлә, кайда, ни эшли?!

З а һ и р ә. Ул хәзер казна урманында икән.

М ә й с ә р ә. Үзе генәме? Ай, мескен!

З а һ и р ә. Алар анда күпләр, ди.

М ә й с ә р ә. Йә, йә, миңа ачуланмыймы, минем хәлне ишеткәнме? Заһирә бәгырем, тиз бул, сөйлә, сөйлә.

З а һ и р ә. Ишеткән. Язган хаты синең турыңда.

М ә й с ә р ә. Йә, йә, кая хаты?

З а һ и р ә. Хәзер. *(Хатны чыгара, Мәйсәрәгә бирә.)* Бу хатны алганыбызга ике атна булып узды.

М ә й с ә р ә. Ике атна!.. Үзе китердеме?

З а һ и р ә. Юк, хәерче булып сакаллар куйган иптәше китерде.

М ә й с ә р ә. Ике атна!

З а һ и р ә. Вакытында тапшыра алмадым шул. *(Елый.)* Әни үлде. Аны җирләдек. Урак җитте.

М ә й с ә р ә. Фатыйма җиңги үлдемени?

З а һ и р ә. Җирләгәнебезгә ун көн булды. Калага алдырып, абыйның кайдалыгын әйттерер өчен кыйнаганнар иде, шуннан соң хәленә килә алмыйча, гүр иясе булды. Мине дә кыйнадылар. *(Елый.)*

М ә й с ә р ә. Әй мескеннәр, әй мескеннәр!.. Ярый әле, Булат исән икән, үтергәннәрдер дип уйлый-уйлый, акылдан шаша яздым. Хатында үзенең кайда икәнлеген дә әйтмәгән бит.

З а һ и р ә. Аны хатны китергән иптәше әйтте, ул сине үз янына чакырган.

М ә й с ә р ә. Чакырган?..

З а һ и р ә. Әйе. Ул сиңа Сыерчык авылы янындагы бояр урманы авызына килергә кушкан, шунда көтәрмен, дигән. Ерак түгел — бер көнлек юл.

М ә й с ә р ә. Көткәндер-көткәндер дә Мәйсәрәнең киләсе килми дип кайтып киткәндер.

З а һ и р ә. Хатны вакытында китереп тапшырырга мөмкин булмады шул.

М ә й с ә р ә. Ярый, хәзер дә соң түгел әле. Әйдә, хәзер китәбез. Бик уңай чакка туры килде, берсе дә өйдә юк... Әйдә, китәбез.

З а һ и р ә. Ничек чыгабыз, капка бикле бит.

М ә й с ә р ә. Көтеп тор шунда, карт үләтнең баш астында ачкычлар ята, берәрсе ярамасмы?

М ә й с ә р ә, ашыгып, өйгә кереп китә. Кайтып килә торган ишанның Галәвигә кычкырган тавышы ишетелә. Заһирә, посып, тәрәзә астына кача.

XVIII. И ш а н, Г а л ә в и һәм З а һ и р ә.

И ш а н. Галәви, Галәви, дим, чукрак ишәк. Алла сакласын, Алла сакласын. Галәви, дим, дуңгыз!

Г а л ә в и *(еракта́н).* Әү-ү!

И ш а н. Капканы ач, хайван!

Г а л ә в и. Ярар.

И ш а н. Кая дөмектең, чукрак, кяфер, бөтен йортны урлап китсәләр дә сизмәссез. Алла сакласын, Алла сакласын... Кем, Галәви, фонарьларны яндырып куярсың. Дөнья буталып тора, казна урманында качкыннар пәйда булган, ди. Аннан соң менә нәрсә тагын, иртәгә, Алла боерса, тәрәзә капкачларын яхшылап ныгытып куй. Менә бу тәрәзәнең бер капкачының тупсасын рәтләп куярга кирәк. *(Заһирәне күреп, аптырап, сискәнеп, куркып кала.)* Ләхәүлә, ләхәүлә... Галәви, бу кем?

Г а л ә в и. Җир упсын, хәзрәт, мин белгән кеше түгел.

И ш а н. Бу кем, дим сиңа, дуңгыз?

Г а л ә в и *(Заһирәгә).* Син кем?

З а һ и р ә. Сәдака сорап, абыстайларга килгән идем.

Г а л ә в и. Мулла йортында сәдака сорыйлармыни, дурак. Сәдака китердем, дисәң, бер хәл иде, бар, чык моннан...

И ш а н. Урлашырга кергәнсеңдер әле, кяфер. Галәви, тенте үзен.

Г а л ә в и. Дөрес әйт, берәр нәрсә чиертмәдеңме, барыбер тапмый калмам. *(Тенти.)*

З а һ и р ә. Юк, абзый, урламадым.

И ш а н *(кинәт исенә төшеп).* Тукта әле, тукта, капка бикле булгач, син ничек монда керә алдың, кем кертте сине?

З а һ и р ә. Койма аркылы.

И ш а н. Койма аркылы? Галәви, ишеттеңме, син нәрсә карап тордың, ганка? Бар, урәтниккә илтеп тапшыр үзен! Тикшерсеннәр. Бар! Алла сакласын, Алла сакласын. *(Өйгә кереп китә.)*

XIX. З а һ и р ә һәм Г а л ә в и.

Г а л ә в и. Әй малай, чынлап та, син ничек керәсе булдың?

З а һ и р ә. Койма аркылы.

Г а л ә в и. Мин күрмәдемме?

З а һ и р ә. Юк.

Г а л ә в и. Юк шул, күргән булсам, сыйрагыңнан тотып, җиргә бер генә бәрер идем, бәхетең, күрмәгәнмен. Әйдә!

З а һ и р ә. Кайда?

Г а л ә в и. Үрәтниккә.

З а һ и р ә. Абый җаным, мине үрәтниккә илтмә, бер көн бушлай урагыгызны урыр идем.

Г а л ә в и . Әйдә, дигәч, әйдә, диләр.

З а һ и р ә. Абый бәгырем, зинһар, хур итмә.

Г а л ә в и. Әйдә, дим, әллә өстерәп алып барганны көтәсеңме? *(Кочаклый, кинәт йомшарып.)* Синең, малай, билләрең нечкә генә икән, хәер сорап юкка әрәм булып йөрисең, ишан хәзрәткә алтынчы хатынлыкка чыксаң, тамагың тук булыр иде.

З а һ и р ә. Без аңа тиң түгел.

Г а л ә в и. Чынлап әйтәм, икәү рәхәтләнеп торыр идек.

З а һ и р ә. Булмый, ярамый. Урагыгызны бушлай урырмын.

Г а л ә в и. Урырсыңмы?

З а һ и р ә. Урырмын, абый, тик җибәр генә.

Г а л ә в и. Алайса, әйдә печәнлеккә.

З а һ и р ә. Юк, абый, син мине моннан чыгар, иртәгә әтәчләр белән бергә килермен.

Г а л ә в и. Әтәчләр белән мин сине чыгарып җибәрермен, төшенәсеңме? Риза булмасаң, әйдә үрәтниккә.

Ш у л а р у к һәм и ш а н.

И ш а н *(чыгып).* Галәви, кайттыңмы?

Г а л ә в и. Киткәнем дә юк әле.

И ш а н. Киткәнем дә юк?

Г а л ә в и. Әйе, үрәтниккә бармыйм, ди.

И ш а н. Өстерәп илт.

Г а л ә в и. Бер көн бушлай урагыгызны урырмын, ди.

И ш а н. Карак урак ура беләмени!

Г а л ә в и. Каракка охшамый, ишан хәзрәт, әллә калдырыйкмы, дим... Печәнлектә кунар иде.

И ш а н. Печәнлектә, дисеңме, Алла сакласын, Алла сакласын! *(Заһирәгә якын килеп карый, тоткалый.)* Хуш... Син, фаразан, кызмы, киленчәкме? Алла сакла-

сын, Алла сакласын... Кызмы, киленчәкме, дим мин сиңа, ахмак? Хуш...

Заһирә. Кыз, хәзрәт.

Ишан. Хуш, үзең кыз да икәнсең, чибәр дә икәнсең, көяз дә икәнсең, койма аркылы йортларга керү ярамый, гөнаһ була. Хуш, синең күкрәкләреңдә җеннәр оялаган булырга кирәк... Бинабәрин[1], өшкерергә кирәк. Алла сакласын, Алла сакласын. Галәви, мунча ишеге ачыкмы?

Галәви. Бикле, хәзрәт.

Ишан. Ачкычы синдәме?

Галәви. Абыстайларда.

Ишан. Бар, хәзер алып чык!

Галәви. Тапсам алып чыгармын.

Ишан. Бар, тиз йөр!

Галәви кырын-кырын карап, кереп китә.

Алла сакласын, Алла сакласын... Хуш, чибәр кыз, фаразан, күкрәгеңдә җен ояласа, яман була, ул кяферләр иманны кимереп яталар. Җеннәрне мотлак куарга кирәк. *(Тоткалый, кочмакчы була.)* Алла сакласын, Алла сакласын, мотлак куарга кирәк.

Заһирә ишанны бәреп егып кача, ишан тора алмый кычкыра.

Галәви, Галәви, качты, качты, кяфер, тот!..

XX. Ишан һәм Галәви.

Галәви. Ни булды, хәзрәт?

Ишан. Качты, качты, кяфер, тот!..

Галәви. Качты!.. Тотыгыз!.. Тот, карак, карак!.. *(Куып китә.)*

Остазбикәләр кайтып керәләр.

Хәдичә *(ишанны торгыза-торгыза).* Сөбханалла, сөбханалла...

Мәрфуга.<br>Сабира. } Ни булды, хәзрәт?

Ишан. Качты, кяфер, качты, тотыгыз, тот! *(Хатыннарын куа башлый.)*

Хәдичә. Кем качты?

Ишан. Карак, карак.

Барысы да. Карак?

---

[1] *Бинабәрин* – шуңа күрә.

И ш а н. Кая дөмегеп йөрисез, ахмаклар, йортка монда караклар ияләшкән.

Х ә д и ч ә. Кайда?

И ш а н. Менә кесәмдә... Ахмаклар, карак күзгә күренеп торамыни! Качты.

Б а р ы с ы д а. Качты?

И ш а н. Карагыз, аң булыгыз, карагыз, моннан соң мунча ишеген биклисе булмагыз!

Х ә д и ч ә. Йә, шәйхем, мәдәд, минем генә нәрсәләргә тимәгән булса ярар иде. *(Кереп китә.)*

М ә р ф у г а. Гөнаһ шомлыгына каршы, сандыгымны бикләмичә киткән идем ләбаса. *(Йөгереп кереп китә.)*

С а б и р а. Калфагым гына исән булса ярар иде. *(Ашыгып кереп китә.)*

И ш а н. Алла сакласын, Алла сакласын. Картая башлаганмын, ахрысы, кулдан ычкынды бит, кяфер.

Г а л ә в и керә.

Йә, хуш, тоттыңмы?

Г а л ә в и. Каян тотасың аны, җиргә сеңгәндәй, эзе дә юк.

И ш а н. Шул каракны да тота алмагач, нигә асрыйм мин сине, кяфер!

Г а л ә в и. Әй хәзрәт, карагы яхшы иде, печәнлеккә генә ябасы калган.

И ш а н. Алла сакласын, Алла сакласын. Бәлки, ул шунда гына качкандыр.

Караналар.

Әй син, фаразан, карак кызый, чык, монда кил, барыбер эзләп табарбыз!

Г а л ә в и. Әй хәзрәт, кулдан очкан кошны тоту юк инде ул. Үзеңә дә булмады, фәкыйрегезгә дә булмады. Нинди һәйбәт карак тотып биргән идем бит.

И ш а н. Чибәр иде шул, ахмак, бик чибәр карак иде, Алла сакласын, Алла сакласын. Кем, Галәви, бүген төн йокламассың, шакылдавык белән йорт тирәсендә әйләнеп йөрерсең. Явызларның ниятләрен белә алмассың, Алла сакласын, Алла сакласын. Карак кызыйны тотсаң, мине уятырсың... Фонарьларны яндырып куй, китап яктылыкны ярата, Алла сакласын, Алла сакласын. *(Кереп китә.)*

Г а л ә в и икенче якка керә.
Ерактан «Зәңгәр шәл» көенә җырлаган җыр тавышы ишетелә. Зур паузадан соң Галәви такылдавыкны шакылдатып чыга.

Г а л ә в и. Бәхетсезнең итәгенә бодай салсаң, карга чүпләр, ди. Нинди һәйбәт каракны кулдан ычкындырды бит, карт юләр. Чынлап карасаң, карак та булмагандыр әле, абыстайларга егетләрдән хат китерүче булгандыр. Мин дурак, миннән битәр ишан хәзрәт юләр, фил кадәр гәүдәсе белән шуны ычкындырган бит, карт тәре! *(Шакылдатып, капкадан чыгып китә.)*

Зур паузадан соң и к е к е ш е акрын гына дүрт аякланып капкадан керәләр, караналар, салмак кына сызгыралар, Галәви ишетә.

Г а л ә в и *(ерактан кычкырып)*. Кем ул? *(Шакылдатып керә, курыкканлыгы бөтен гәүдәсендә сизелә.)* Кем ул? Кем ул, дим? Ә, теге юньсез яңадан кергәндер әле… Әй син, карак кызый, яхшы чакта карышма, чык, барыбер эзләп табармын, чык!.. Әй, кулыма эләксәң, урырмын урагыңны, малай, яхшы чакта чык, дим. *(Караклар качкан куак төбенә килә.)* Ә син, карак кызый, яхшы чакта чык, дим, барыбер эзләп табармын, яшеренгән җиреңне беләм бит… Ә менә сиңа, кызый, актык сүз, оч кат чык диюгә чыкмасаң, шакылдавык белән башыңны ярырмын. Чыгасыңмы?.. Ә? Бер булды. Чыгасыңмы? Ә?.. Ике булды. Актык кат әйтәм, чыгасыңмы?

Б у л а т белән б е р к а ч к ы н Галәвине артыннан кочаклап эләктереп алалар, авызын куллары белән каплыйлар.

XXI. Б у л а т, П ә т р ә й, Х ә й р и, М и ш к а, Г а л ә в и һәм башка к а ч к ы н н а р.

Б у л а т. Тыныңны чыгарсаң, үлемеңне шунда табарсың. *(Хәнҗәрен терәп.)* Бу кем йорты, Котдүс ишан йортымы? Котдүс ишан йортымы, дим?!

Г а л ә в и *(куркып)*. Ә, ә, ә… шул.

Б у л а т. Котдүс ишан йорты шулмы, йә?

Г а л ә в и *(шыпырт)*. Шул.

Б у л а т. Кычкырыбрак әйт.

Г а л ә в и. Шул.

Б у л а т. Мәйсәрә өйдәме?

Г а л ә в и. Өйдә.

Б у л а т. Кайсы тәрәзә турында йоклый?

Г а л ә в и. Тәрәзәсез бүлмәдә.

Б у л а т. Өйдә кемнәр бар?

Г а л ә в и. Барысы да.

Б у л а т. Ирләрдән кемнәр бар?

Г а л ә в и. Без генә.

Б у л а т. Ничек сез генә?

Г а л ә в и. Әйе инде, без генә... хәзрәт тә мин...

Б у л а т. Яңадан әйтәм, тавышыңны чыгарсаң, беттем дип бел!

Галәвинең кулларын бәйләп, агачка бәйлиләр. Булат сызгыра, к а ч - к ы н н а р керәләр.

Егетләр, эшегезне белегез!

Барысы да йорт тирәсенә тарала. Мишка ут сала, Булат берничәсе белән өйгә керә. Өйдә чыр-чу башлана. Йорт яна башлый. Б у л а т М ә й с ә р ә н е кочаклап алып чыга, алар артыннан к а ч к ы н н а р чыгалар. Ыгы-зыгы.

Б у л а т *(Мәйсәрәгә).* Бөркән зәңгәр шәлеңне!

Ишан һәм хатыннары эчке күлмәкләрдән, кычкырышып, мендәр-ки-ем күтәреп чыгалар. Йорт яна. Качкыннар качалар. Ишан күлмәк-ыштаннан чаба.

И ш а н. Галәви, Хәдичә, Сабира, Мәрфуга, Фазыйлә, тотыгыз, тот кяферләрне!

Хатыннар барысы да эчке күлмәктән, шашынып ишан итәгенә ябышып әйләнәләр. Галәви бәйләп салган җиреннән тора алмый тарткаланып ята.

И ш а н. Галәви! Караул!..

Х а т ы н н а р ы. Янабыз, янабыз, янабыз!..

П ә р д ә.

*1926 ел*

# ХИКМӘТЛЕ ДОКЛАД

*Көлке-мәзәк*

*Дүрт пәрдәдә, биш күренештә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Мортаза – «Кызыл сандал» артеле идарәсенең рәисе.
Бану – Мортазаның хатыны.
Гөлҗамал – аларның асравы.
Низам – идарә әгъзасы.
Хәмит – идарәнең эш башкаручысы.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мещаннарча уртакул җыештырылган квартира. Телефон, радио, диварда зур сәгать.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Бану.

Мортаза *(бүлмәгә кереп, борчылып эзләнеп йөри).* Һе, юк... Монда да юк... Абайламый йөрсәң, башыңны югалтырлар болар, дурак, юк бит, юк!.. Һе, менә кызык!.. *(Бүлмәгә кычкыра.)* Бану, тапмадыңмы?

Бану *(бүлмәдән).* Юк, юккк!..

Мортаза. Тапмаска, җир йотмагандыр бит аны. Гөмбә дисәң гөмбә... Бану, дим, гөмбә, нәрсә дөмектең анда!..

Бану *(чыгып).* Нәрсәгә акырынасың, шашкан ишәк төсле?..

Мортаза. Сез гөмбәләр белән шашу түгел, башың Соловкига китәр, дурак. Йә, кая дөмектердегез, кая куйдыгыз?! Сәгать ун тула бит.

Б а н у. Кара әле, сиңа әйтәм, алып кайттыңмы соң?.. Берәр җирдә онытып калдырмадыңмы икән? Күзгә-башка бер дә күренмәде.

М о р т а з а. Алып кайтмаган булсам сорап та тормас идем. Күлмәклегеңне шуннан алып бирдем бит, гөмбә. Йә, кая олактырдыгыз… Җир астыннан булса да, хәзер табып чыгар!

Б а н у. Каян табыйм мин аны? Әйтәм ләсә, күзгә-башка күренгәне юк дип.

М о р т а з а. Харап итәсез бит, гөмбә, харап итәсез… Иртәгә артельнең конференциясе, беренче нәүбәттә минем доклад тора. Йә, кая куйдыгыз, дим, миегез черегән нәрсәләр! Харап итәсез бит. Докладсыз калдырасыз.

Б а н у. Юләр балык төсле, нигә дип миңа җикеренәсең? Мин яшергәнмени аны. Кая куйган булсаң, шуннан ал да башымны катырма.

М о р т а з а. Доклад бит, саботаж, доклад бит, гөмбә!

Б а н у. Доклад, доклад. Нигә чәнчелмисең докладларыңны башыңа каплап. *(Ишеккә барып.)* Гөлҗамал, Гөлҗамал, монда кер. Үзенең бер рәте юк. Бөтен нәрсәләрен анысын анда, монысын монда тол кәккүк төсле ташлап йөри дә *(үчекләп)*, доклад, доклад дип, башны катырырга керешә.

Г ө л җ а м а л керә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Б а н у һәм Г ө л җ а м а л.

Г ө л җ а м а л. Нәрсә?

Б а н у. Түрә иптәш, абзаңның ниен күрмәдеңме?

Г ө л җ а м а л. Ниен?

М о р т а з а. Портфелем кая, гөмбә?..

Г ө л җ а м а л. Белмим.

М о р т а з а. Белмим дип торырга, әнәмени ул. Менә сезгә биш минут вакыт. Тапсагыз табасыз, тапмыйсыз икән, миңа үпкәләмәгез. Милициягә барам да әйтәм. Сине дә хатыным дип тормам.

Б а н у. Тотынды инде, тотынды җил тегермәне. Гөлҗамал, өстәл җыйганда, савыт-саба белән ялгыш алып чыкмадыңмы?

Г ө л җ а м а л. Җир упсын, алып чыкмадым, песидән куркып, берәр яры качмаган булса гына тик.

М о р т а з а. Нәрсә саташасың син, гөмбә?

Б а н у. Тукта әле, җикеренмә, яхшылап аңлат. Абзаңның нәрсә эзләгәнен төшенәсеңме?

Г ө л җ а м а л. Төшенмәскә, син тагы бигрәк инде. Риҗинфилне дә белмәскә.

М о р т а з а. Риҗинфил түгел, портфель, гөмбә. Сөйләшергә өйрән.

Б а н у. Тукта әле, такылдама. Аның эчендә кирәксез кәгазьләрдән башка бернәрсә дә юк, Гөлҗамал. Бар әле, мендәр астында, түшәк астында юк микән, барып карап кына кил әле.

Г ө л җ а м а л чыга башлый.

М о р т а з а. Тукта әле, без йоклаганда, күмерчегә, авыл агай-энеңә ялгыш бумажник яисә кулъяулыгы дип биреп җибәрмәдеңме?

Г ө л җ а м а л. Юк.

Б а н у. Чүпләр белән чүплеккә-мазарга ташламадыңмы?

Г ө л җ а м а л. Юк.

М о р т а з а. Утынлыкка-фәлән чыгарып яшермәдеңме?

Г ө л җ а м а л. Ә?!

Б а н у. Без йоклаганда, берәр кеше монда кермәдеме?

Г ө л җ а м а л. Юк.

М о р т а з а. Иске жилет дип шурум-бурумчыга ялгыш сатмадыңмы?

Г ө л җ а м а л *(еламсырап).* Сез мине юләр дип беләсезме әллә... *(Чыга башлый.)*

М о р т а з а. Тукта, тукта, кая чыгасың?

Б а н у. Иске керләр тутырып ташламадыңмы?

Г ө л җ а м а л. Юк, дим ич инде. Күргәнем дә юк ул нәмәрсәкәегезне.

М о р т а з а. Эчендә акчасы бар дип, ялгыш чәлдермәдеңме?

Г ө л җ а м а л *(кычкырып).* Урлашырга мин каракмыни... Кулакмыни!

М о р т а з а. Тукта, гөмбә, тукта, илермә. Сине карак дигән кеше бармыни монда.

Г ө л җ а м а л. Әйттең, әйттең. Карак дип бәла яптың.

Б а н у. Ялганлама, Гөлҗамал, сиңа карак дигән кеше булмады.

Г ө л җ а м а л. Чәлдергәнсең, дип әйтте ич.

М о р т а з а. Чәлдерү карак дигән сүзмени ул, гөмбә.

Г ө л җ а м а л. Нәрсә соң ул синеңчә, сәдака буламыни?

Бу хурлыкка чыдар хәлем юк. Хәзер Советка барып, өстегездән жалба бирәм, судка бирәм.

Мортаза. Тукта, дивана, тукта, гөмбә!

Бану. Алны-артны абайламый сөйләшкәч, шулай була ул.

Мортаза. Тукта әле син, миең черегән саботаж гөмбә.

Гөлҗамал *(кәпрәеп).* Нәрсәңне мин урладым? Нәрсәңне мин чәлдердем? Хәзер үк алдан бер айлык жалуниям белән пашпортымны бирегез. Советка жалба белән барам. Женотделга да барам, комсомолга да барам, трудсессиягә дә барам. Бу хурлыкка чыдар хәлем юк. Буржуй, кулак, куштан булам дигәч тә, пролетарны рәнҗетергә димени...

Мортаза. Төш күрәсеңме әллә син?

Гөлҗамал. Жалуниямне бир.

Бану. Шаштыңмы әллә син?

Гөлҗамал. Пашпортымны бир!..

Мортаза. Тукта, дим!

Гөлҗамал. Иманым кяфер булсын, судка бирәм.

Бану. Юньле кылан, Гөлҗамал.

Гөлҗамал. Милициягә барам.

Мортаза. Менә дивана.

Гөлҗамал. Ялган бәлаләр таккан өчен төрмәдә черетмәсәм, атым Гөлҗамал да булмасын... *(Аяк тибеп кычкырып.)* Бирегез жалуниямне! Бирегез пашпортымны! Милисийски җизнигә барып, барысын да әйтәм. Бәйрәм иткәнегезне дә әйтәм, мулла чакырганыгызны да әйтәм, пылау ашаганыгызны да әйтәм, аракы эчкәнегезне дә әйтәм. Лото уйнаганыгызны да әйтәм. Һәр көн ястү вакыты җиткәч, әнә тегенең морҗасыннан Алла, Алла дип азан әйттергәнегезне дә әйтәм.

Мортаза. Әһә-һә-һә!.. Әле син шулай икән. Алай булса, күн тәпи, мин дә синең белән икенче төрле сөйләшермен. Син, мине «Кызыл сандал» правлениесенә сайлатмас өчен, доклад портфелемне миңа каршы группаларга саткансың икән. Елаган булып милисийски җизнәң белән куркытып, тегермән корып, заговор ясап, продукциянең яхшы чыгуына каршы килмәкче буласың икән. Эшләп чыгару эшләрен машиналаштыру, электрлаштыру, радиолаштыруга каршы килеп, кулаклар җырын җырлап, иген хәзерләү эшендә саботаж кормакчы буласың икән. Юк, тора тор, кызый, бәрәңге авыз, күн тәпи, элек менә мин сине милициягә озатыйм әле. *(Телефонга барып.)* Икенче район милицияне бирегез!.. Чыгарма, чыгарма!..

Г ө л җ а м а л *(ялынып Мортазага ябышып).* Түрә иптәш, абзый, җаным! Зинһар, харап итә күрмә. Җалуниям дә кирәкми, күлмәклек тә кирәкми... Харап кына итә күрмә.

М о р т а з а. Әһә-һә!.. Жалуния дә кирәкми, күлмәклек тә хәзер кирәкми башладымыни?.. Йә, әйт, күпмегә саттың?.. Кемгә саттың?..

Г ө л җ а м а л. Җир упсын, шул кояшны күрмим, акчагызны алган булсам.

М о р т а з а. Мин синнән акча сорамыйм, портфель сорыйм, доклад сорыйм. Кая портфелем?..

Г ө л җ а м а л. Күргән булсам, ике күзем шартлап чыксын. Тоткан булсам, ике кулым терсәк тиңентен корып төшсен! Харап итмә!

М о р т а з а. Син үзең мине харап иттең, кая портфелем?

Б а н у. Җыен дивана, җыен алатыр, җыен радио бугаз безгә җыелган. Алладан оялмасагыз, әнә телефоннан, радио морҗасыннан оялыгыз, ичмасам. Бер юләр җуйган, икенче юләре таба алмый. Тавышыгыз башыма капты. Мигринем кузгалды. Эчемдәге катуым чыкты. Хәзер табып китерәсе булыгыз!

М о р т а з а. Син ни дип шыңшыйсың, юләр гөмбә? Ни дип шыңшыйсың, миңгерәү тавык?

Б а н у. Акырма миңа, юләр ишәк!.. Ай-ай-ай, катуым чыкты, катуым чыкты, үләм, үләм!..

Г ө л җ а м а л. Әй Илаһым, үлә ич!..

М о р т а з а. Портфелемне тапмыйча, үләргә рөхсәт юк!

Б а н у. Ай-ай-ай!

М о р т а з а. Кая портфелем?

Г ө л җ а м а л. Үлә ич!..

М о р т а з а. Харап иттеләр, докладсыз калдырдылар!..

Б а н у. Ай-ай-ай!..

Г ө л җ а м а л *(кычкырып елап).* Пашпортны бирегез, пашпортны бирегез!

Б а н у. Ай эчем, ай эчем! Ай-ай-ай!..

М о р т а з а. Докладсыз калдым, пычаксыз суйдылар.

Соңгы җөмләләр бергә әйтелә. Шау-шу, кычкырыш. Н и з а м керә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Б а н у, Г ө л җ а м а л һәм Н и з а м.

Н и з а м. Бу нинди тавыш? Нәрсә? Ни бар?

М о р т а з а. Харап булдым. Низам брадәр, бу гөмбәләр харап иттеләр.

Б а н у. Ай-ай, эчем! Ай, ай!.. *(Гөлҗамалга таянып чыгып китә.)*

Н и з а м. Ни булды?!

М о р т а з а. Докладсыз калдым.

Н и з а м. Ә?!

М о р т а з а. Портфелем белән докладымны пышкыртканнар.

Н и з а м. Бу нәрсә булды инде?

М о р т а з а. Нәрсә булсын — ак билет. Миңа да ак билет, сиңа да ак билет. Барыбызга да ак билет!

Н и з а м. Чү әле, чү әле, ни сөйлисең син?!

М о р т а з а. Барлык таяныч докладта иде. Аны пышкыртканнар.

Н и з а м. Шуннан соң?

М о р т а з а. Портфелем күз алдымда юкка чыкты. Эчендә доклад иде. Мәскәүгә җибәрсәң дә батарлык иде. Мәгънәсе дисеңме, тәртибе дисеңме. Слогы дисеңме, идеологиясе дисеңме...

Н и з а м. Әәәммм!..

М о р т а з а. Шыр ялангач калдым, Низам брадәр, шыр ялангач. Правление дә, сәясәтләр дә, планнар да, тегермәннәр дә һавага очты. Унике ай буенча хәзерләнгән доклад бер минутта юкка чыкты да китте.

Н и з а м. Монда теге группаларның кулы йөргәнлек сизелә.

М о р т а з а. Алар эше, тәгаен алар эше. Правлениегә үрмәләүләрен әллә кайчаннан бирле сизенеп киләм мин. Бөтен таяныч докладта иде. Алар аны сизгәннәр булырга кирәк.

Н и з а м. Чү әле, чү, монда акыл, сәясәт, дипломатлык кирәк. Милициягә, угрозыскка, союзга хәбәр итәргә кирәк. Шулай иткәндә, бәлки, конференцияне дә кичектереп булыр.

М о р т а з а. Анысы батмас. Тыңламаслар.

Н и з а м. Югыйсә теге группалар безгә каршы бик каты оешалар. Кичә генә әле Күсе Фәттах белән Шәкүр Гыйлаҗы ике группа иде, ә бүген бергә очрашканнар да өченче группа оештырганнар.

М о р т а з а. Ничек инде ул алай була — ике кеше өч группа?

Н и з а м. Безнең агай-эне булдыра икән шул. Үземнең дә исем китте. Фәттахы, җыелышка килмәс өчен, уң күзен бәйләп йөргән була. Гыйлаҗ, аңа үч итеп, сул күзен

бәйләп килми. Төбендә Фәттахы да сукыр түгел, Гыйлаҗы да күзсез түгел. Кичә бергә кинода очрашканнар да, икәвесенә тагы өр-яңа бер группа төзегәннәр.

М о р т а з а. Иске уйларыннан кайтканнармы?

Н и з а м. Юк, кайтмаганнар булырга кирәк. Татар барда хәтәр бар дигәндәй, дөнья булгач, хәйләсез, группасыз торуы мөмкин түгел бит. Менә мин дә әле шул турыда сөйләшеп аңлашырга дип килгән идем. Безгә дә Фәттахлар юлын тотмыйча булмас.

М о р т а з а. Ягъни?

Н и з а м. Группалашырга кирәк.

М о р т а з а. Синең группага күчәргәме?

Н и з а м. Мәсьәлә мөһим, конференция борын төбендә.

М о р т а з а. Анысы батмас, Низам брадәр.

Н и з а м. Син уйлаганча түгел ул.

М о р т а з а. Син уйлаганча да түгел.

Н и з а м. Яңа план уйладым әле мин.

М о р т а з а. Йә?

Н и з а м. Фәттахлар, Гыйлаҗлар группасына каршы көрәшер өчен, бер чара кирәкме, юкмы?

М о р т а з а. Әлбәттә, кирәк. Ләкин ул чара минем группа файдасына зарар китерә торган булса кирәкми.

Н и з а м. Менә эшнең кендеге шунда инде.

М о р т а з а. Йә, йә.

Н и з а м. Синең дә группа исән калырга тиеш, минем группа да исән калырга тиеш. Син миңа, мин сиңа искечә полный дошманнар булып калабыз. Хәзерге заманда үзара тартышуда хикмәт, үзара сугышуда бәрәкәт.

М о р т а з а. Ләкин минем үз фикерем фикер. Үз группам группа.

Н и з а м. Минем шулай ук. Үз фикерем фикер. Үз группам группа. *(Кинәт исенә бернәрсә төшеп, кулын маңгаена бәреп.)* Һәйт!!! Менә сиңа чүлмәк баш... Мин бит сиңа ялгыш кергәнмен. Сәгать унбердә мин тегендә булырга тиеш.

М о р т а з а. Кайда?

Н и з а м. Минем бит анда бер хикмәт, группа оештырасым бар... Ярый, хуш. Өйлә вакытларында кабинетыңа барып чыгармын, шунда яхшылап аңлашырбыз. Хуш!.. *(Китә, портфелен онытып калдыра.)*

М о р т а з а. Хуш, хуш... Акыллы кеше, дипломат кеше, лидер кеше, иске заман булса, голова, депутат булырлык кеше.

Кычкырып, Б а н у керә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Б а н у.

Б а н у. Таптым, атасы, таптым.
М о р т а з а. Ә?!
Б а н у. Портфелеңне таптым.
М о р т а з а. Таптың, кая?
Б а н у. Уф, тукта, шатлыгымнан мигринем кузгалды.

Н и з а м керә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Б а н у һәм Н и з а м.

Н и з а м. Менә кызык! Портфелемне оныткანмын.

Б а н у. Ә, исәнмесез, Низам әфәнде! Фаизә апа исән торамы? Балалары исәннәрме? Җыенга кайтасызмы?

Н и з а м. Апа кайтам дип тора. Минем вакытым юк.

М о р т а з а. Портфель кая?

Б а н у. Тукта әле, Мортаза. Юньле кылан, кеше-фәлән белән исәнләшергә ирек бир. Фаизә апаның биле нихәл? Профессорның даруы килештеме?

М о р т а з а. Портфелем кая, дим?! Сәгать унбер була.

Б а н у. Бу ни эшең инде, Мортаза? Авыл агайлары төсле кыланасың... *(Низамга.)* Югары урамда Америкта укыган бер доктор бар икән, кай җиреңавыртканлыкны сорамыйча, үзе таба икән. Әллә нинди колак ишетмәгән авырулар таба икән.

М о р т а з а. Портфель!..

Б а н у. Утырыгыз, Низам әфәнде, рәхим итегез!

М о р т а з а. Портфель!..

Б а н у. Шул портфелең белән шашмасаң ярар иде. Шашу дигәннән, Шаһит Хаҗиның кызы шашкан бит. Фаизә апа ишеттеме икән? Шумашушный домга озатканнар.

Н и з а м. Исән булыгыз, Бану ханым! Барып утырыгыз.

Б а н у. Сәламәт булыгыз... Әй, онытып та торам икән әле. Коммунхоз Нәгыймәсе игез бала китергән. Берсе ул, берсе кыз икән. Улы тугыз кадак, ди, кызы алты кадак та унике мыскал ярым, ди.

Телефон шалтырый.

Н и з а м. Сәламәт булыгыз... *(Ашыгып чыга.)*

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Бану.

Мортаза. Портфель, портфель, портфель!

Бану. Теңкәмә тидең портфель белән. Кеше белән рәхәтләнеп сөйләшергә дә ирек бирми. Гөлҗамал, Гөлҗамал!

Мортаза. Әйе... Хәзер барам. Хәзер, хәзер...

Гөлҗамал керә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза, Бану һәм Гөлҗамал.

Гөлҗамал. Нәрсә?

Бану. Кая дөмектең!

Гөлҗамал. Мич ягам ич.

Бану. Керт!

Гөлҗамал. Нәрсәне?

Бану. Әйттем ич.

Гөлҗамал. Ә, тегенеме?..

Бану. Соң.

Гөлҗамал. Хәзер. *(Чыга.)*

Мортаза. Кая, буласызмы инде? Әллә юри юләр саттырасызмы?

Бану. Гөлҗамал, тиз бул инде.

Гөлҗамал *(чүлмәк өстенә капланган портфельне чүлмәге белән алып керә).* Менә!..

Мортаза *(ашыгып портфелен алып).* Икенче кагыласы булмагыз. Чүлмәк капкачы дип белдеңме әллә син, гөмбә!

Бану. Дивана дисәң — ачуың килә, Гөлҗамал, тиле дисәң — үпкәлисең, чебен чеметерлек акыл әсәре юк үзеңдә... Йә, нәрсәгә дип чүлмәкне алып кердең, бар, алып чык.

Гөлҗамал чыга.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Бану.

Мортаза *(портфелен актарып).* Тукта әле, тукта, монда юк ич.

Бану. Нәрсә юк тагы?

Мортаза. Доклад монда юк ич!..

Бану. Шашмасаң ярый инде шул докладың белән. Яхшылап кара, кая китсен.

Мортаза. Юк шул, юк!.. Юк, юк, Бану, юк бит. Гөлҗамал, Гөлҗамал!..

Бану. Яхшылап кара, шундадыр. Мин кирәксез кәгазьләрне генә алырга әйткән идем.

Гөлҗамал керә.

Мортаза. Ә-ә-ә-ә.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мортаза, Бану һәм Гөлҗамал.

Гөлҗамал. Нәрсә инде, мичем уза.

Мортаза *(портфелен бәрә-бәрә).* Гөлҗамал, кая мондагы доклад?

Гөлҗамал. Нәрсә...

Мортаза. Доклад!..

Гөлҗамал. Әй, шаяртасыз икән лә, мин тагын... *(Чыга башлый.)*

Мортаза *(ябышып).* Тукта, дим мин сиңа, кая куйдың, кемгә саттың, күпме алдың?

Бану. Ләгънәт кенә икән. Әллә кирәкле кәгазьләре эләккән? *(Чыга.)*

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Гөлҗамал.

Гөлҗамал. Нәрсә...

Мортаза *(чайкалып, борылып).* Менә мондагы, мондагы... Уф, үләм! Нигә син, нигә син! Уффф!.. *(Урындыкка ава.)*

Гөлҗамал. Менә кызык эш тапканнар: тоталар да миңа бәйләнәләр, тоталар да миңа бәйләнәләр. Чүлмәк капкачларыгыз юкка мин гаеплемени?!

Мортаза. Ә?!

Гөлҗамал *(кызып).* Чүлмәк капкачларыгыз юк. *(Киерелеп.)* Чүлмәк өстенә үзем менеп утырмам бит. Менә шул, чүлмәк капларга алып чыккан идем.

Мортаза. Тукта, кызый, тукта. Маташтырма. Ә нигә соң син сораганда әйтмәдең? Антлар итә-итә, күргәнем дә, тотканым да юк, дидең, йә?

Г ө л җ а м а л. Сез бит миннән аңлатып сорамадыгыз, әллә нәрсә дауладыгыз. Күн букча дип сораган булсагыз, әллә кайчан керткән булыр идем.

М о р т а з а. Моның эчендәге кәгазьләрен кемгә бирдең?

Г ө л җ а м а л. Ни эшләп мин бирим. Бану апа үзе бирде.

М о р т а з а. Ә-ә-ә...

Г ө л җ а м а л. Җир тотсын, үзе бирде.

М о р т а з а. Үзе!.. *(Каранып.)* Кая соң үзе качкан! Гөлҗамал, биклә ишекләрне. Каравыл, каравыл!..

Б а н у керә.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Б а н у һәм Г ө л җ а м а л.

Б а н у. Бу ниткән яңа һөнәр тагын!..

М о р т а з а. Әһә, кача алмадыңмы?.. Гөлҗамал, шаһит бул: бу хатын минем фатирымда экономический контрреволюция, саботаж тегермәне корып...

Б а н у. Шаштыңмы әллә син?!

М о р т а з а *(буылып).* Гөлҗамал, турысын сөйлә. Ике кием первый сорт сандал бирермен.

Б а н у. Нишлисең син!.. Әллә драма түгәрәгенә язылдыңмы?

М о р т а з а. Молчать, халыкара саботаж!..

Б а н у. Мортаза, дим.

М о р т а з а. Молчать!.. Гөлҗамал, турысын сөйлә.

Г ө л җ а м а л. Нәрсә сөйлим?

М о р т а з а. Менә моның эчендәге кәгазьләрне менә бу халыкара... чүпрәк баш кемгә бирде, сөйлә, кемгә бирде?

Г ө л җ а м а л. Миңа бирде.

М о р т а з а *(аптырап).* Сиңа?!

Г ө л җ а м а л. Әйе. Менә шул кояштыр, миңа бирде.

М о р т а з а. Нәрсә дип ул аларны сиңа бирде?

Г ө л җ а м а л. Мич кабызырга.

М о р т а з а *(каты кычкырып).* Ә-ә!!!

Б а н у. Пычак кергере...

Г ө л җ а м а л. Пычак шул, пычак. Ничә әйттем, чыра пычагы, чыра пычагы, чыра пычагы алыгыз дип, сүземне тыңламадыгыз, чыра пычагы алмадыгыз.

М о р т а з а *(аптырап).* Тукта, тукта, мин шашаммы? Әллә болар шашканнармы?.. *(Бануга ташланып.)* Ах,

син, бәйнәлмиләл, мещанка, койрык сөяге, кәкре сыйрак, чүпрәк баш!

Б а н у. Мортаза!..

М о р т а з а. Ах син, ташаяк таш курчагы, гайбәт чеховозы, волокита кәбестәсе, бүкән бәбәк!..

Б а н у. Тиле күркә төсле кабарынма миңа!..

М о р т а з а. Молчать, алты-биш!

Б а н у. Әйтерсең лә конторда кәгазь беткән, юк өчен кыямәт куптара.

М о р т а з а. Молчать, чүпрәк сандал!.. Ә син, халык аралаш бетле баш, гөмбә танау, нәрсә карадың? Соң син, миңгерәү ябалак, докладтан чыраны да аера алмагач, син нинди пролетарка!.. Мәмләкәт белән идарә итәргә шулай өйрәнәсеңме? Соловки, Соловки, икесен дә Соловкига! Икесе дә миңа контр!.. Уф... Уф!..

Г ө л җ а м а л. Син үзең контр, син үзең собака! Кая чыра пычагыгыз?! Кая чүлмәк капкачларыгыз?..

Б а н у. Ай, ай, мигринем кузгалды. Ай, эчем, эчем, ай-ай!..

М о р т а з а *(телефонга барып).* Район, икенче район, милиция. Каравыл, таладылар, таладылар.

Г ө л җ а м а л. Пашпортымны бирегез, пашпортымны бирегез!..

Б а н у. Ай-ай-ай, эчем, ай-ай.

Шау-шу.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кабинет. «Кызыл сандал» артеле идарәсе.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Х ә м и т.

М о р т а з а *(ишекне яба-яба).* Юк, дим, юк. *(Һаман телефон шалтырый. Мортаза җавап бирми, трубканы алып кына куя.)* Бүген бер кешене дә кабул итмим. *(Ишекне ябып.)* Дөньяга союзга язылган мещаннардан да кляуз, сагыз халык булмас. Сознательность дигән нәрсә ана сөте белән кермәсә, артель сөте белән керми икән... *(Звонок бирә.)*

Х ә м и т керә.

Х ә м и т. Нәрсә, Мортаза иптәш?

М о р т а з а. Бар, әнә шул койрык сөякләренә бүген бер кеше дә кабул итмәвемне аңлат.

Х ә м и т. Барысын булмаса да, кайберәүләрен кабул итү кирәк иде. Срочно эшләр белән килүчеләр бар.

М о р т а з а. Ә минем докладым срочно түгелмени?

Х ә м и т. Беренче мастерскойда олтан беткән, өченчесендә бер данә йөзлек калмаган, ди. Иртәгә конференция.

М о р т а з а. Һәм минем доклад.

Х ә м и т. Булса ни, әзер бит ул.

М о р т а з а. Әзер булса, мин правлениегә сәгать унбердә килмәс идем.

Х ә м и т. Нигә, кичә бит…

М о р т а з а. Куй, ичмасам, син канга тоз салма.

Х ә м и т. Соң кичә бит…

М о р т а з а. Куй, сөйләмә, дим, йөрәк яндырып. Болай да көчкә-көчкә генә креслода утырып торам. Нервларым телефон чыбыклары төсле өзеләм-өзеләм дип кенә торалар.

Х ә м и т *(җилкәләрен уйнатып).* Һичнәрсә аңламыйм.

М о р т а з а. Өйләнмә, туган, акылың булса өйләнмә. Алиментларыңны үзем түләшермен. Инде ялгышлык белән юләрләнеп өйләнәсең икән, фатирда торма. Исерек баштан фатирда тора башлыйсың икән, сак бул, зинһар, сак бул, асрау алма… Инде күрәчәгеңә каршы асрау тотасың икән, чыра пычагы белән чүлмәк капкачларын алдан алып куй.

Х ә м и т. Гафу итегез, һичнәрсә аңламыйм.

М о р т а з а. Башыңа төшсә, шундый аңларсың, брадәр, бәрәкәте кабереңә хәтле барыр.

Х ә м и т. Кызык.

М о р т а з а. Кызык түгел, фаҗига, фаҗига! Ә мин, исәр, миңгерәү ябалак, шул юләрлекләрнең барысын да эшләдем. Хатын, фатир, асрау алдым. Фатир тормышы өчен иң мөһимен, иң кирәген — чыра пычагы белән чүлмәк капкачларын алмаганмын.

Х ә м и т. Чыра пычагы, чүлмәк, честное слово, һичнәрсә аңламыйм!..

М о р т а з а. Гаиләне машиналаштыру эшендә чыра пычагы белән чүлмәк капкачларының иң мөһим факторлар икәнлеген төшенә алмаганмын.

Х ә м и т. Нәрсә әйтергә телисез соң?

М о р т а з а. Век живи, век учись, дураком помрёшь.

Х ә м и т. Верно!

М о р т а з а. Менә шул хакыйкатьне бүген йөз процентны белән аңладым, брадәр.

Х ә м и т. Нәрсәгә мине чакырдыгыз?

М о р т а з а. Правлениенең бөтен ишекләрен бикләп, тәрәзә пәрдәләрен төшер, бөтен хезмәткәрләрне агяһландыр[1].

Х ә м и т. Хуш!

М о р т а з а. Доклад хәзерлибез.

Х ә м и т. Доклад!..

М о р т а з а. Уф, бу нагрузкадан башым ярылмаса ярар иде.

Х ә м и т. Ә кичәге доклад соң?

М о р т а з а. Аның турында сорашма.

Х ә м и т. Ничек?!

М о р т а з а. Шулай, ул очты.

Х ә м и т. Кая?

М о р т а з а. Мичкә, брадәр, мичкә!

Х ә м и т. Ничек мичкә?! Төшенмим.

М о р т а з а. Хатын, фатир, асрау алып тора башласаң — төшенерсең. Ярый, сүз көрәштереп ботка да пешмәс, сандал да тегелмәс. Кушканны эшлә. Мин правлениегә председатель булып сайланган көннән бирле җыелган материалларны доклад өчен бүген хәзерләп бетерәсез, менә шул. Бар!

Х ә м и т. Мортаза иптәш!

М о р т а з а. Бар, дим, бар. Кушканны эшлә.

Х ә м и т. Срочно эшләр белән килүчеләрне ни эшләтәбез?

М о р т а з а. Куып чыгар.

Х ә м и т. Олтанлыклар турында...

М о р т а з а. Кирәкми.

Х ә м и т. Йөзлекләр беткән, эшчеләр эшсез торалар, ди.

М о р т а з а. Эшсез торган сәгатьләрен бәйрәм сәгатьләренә күчерерсез.

Х ә м и т. Закон буенча бит...

М о р т а з а. Кирәкми, кирәкми, законнарыгыз да, эшчеләрегез дә, сандалларыгыз да, артельләрегез дә, срочныйларыгыз да, бессрочныйларыгыз да — берсе дә кирәк түгел. Миңа доклад кирәк, доклад, доклад!.. Бар, дим, бар, кушканны эшләгез, волокита тудырып каршымда эшсез тормагыз!

---

[1] А г я һ л а н д ы р у — искәртү, белдереп кую.

Х ә м и т *(җилкәләрен уйнатып).* Ихтыярыгыз. *(Чыгып китә.)*

М о р т а з а *(өметсез тавыш белән).* Дөньядагы хәлләргә карап хәйран каласың. Адәм баласы саковой олтанлы сандал төсле ышкыла, ышкыла, ышкыла да тузып җир йөзеннән югала. Бөтен дөньяны канга батырган сугышлар, талаулар, газаплар, революцияләр, контрреволюцияләр, җыелышлар, конференцияләр... Әрсез адәм баласы талаша-талаша, үз туганы белән бугазга-бугаз килеп чәйнәшеп дөнья куа... Куа, куа да үлә дә китә. Барысы бетә. Мичтә янып көлгә әверелгән доклад төсле юкка чыга... Берәр ай, берәр ел, унар ел, йөзәр ел хәзерләнгән докладлар дөньяның вафасыз мичендә көлгә әвереләләр...

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Г ө л җ а м а л.

Г ө л җ а м а л. Түрә иптәш, абзый!

М о р т а з а *(йомшак тавыш белән).* Ә, син икәнсең, Гөлҗамал, кил, утыр.

Г ө л җ а м а л. Утырырга вакытым юк.

М о р т а з а. Утырып кал, Гөлҗамал, утырып кал, син түгел, меңәр ел яшәгән мәмләкәтләр дә юкка чыкканнар. Вафасыз дөньяны куып җитә алмассың. Утырып кал, Гөлҗамал, утырып кал.

Г ө л җ а м а л. Базарга барасым бар.

М о р т а з а. Базарга да барырсың, мич тә ягарсың, аш та пешерерсең. Барыбер үләргә туры килер. Син түгел, еллар буе том-том докладлар язган зур философлар, даһи председательләр дә үлгәннәр. Исәннәре дә үләчәкләр. Шулай, Гөлҗамал брадәр, бик вафасыз бу дөнья. Шуның өчен, базарга барганда, чыра пычагы белән чүлмәк капкачлары алырга, зинһар, оныта күрмә. Көннәрнең берендә йолдызлар конференциясе аны да урыныннан бәреп төшерәчәк.

Г ө л җ а м а л. Түрә иптәш, абзый, иткә акча кирәк иде.

М о р т а з а. Адәм баласының миен череткән шул агуны, акчаны, тәки бетерә алмадылар бит. Хәер, социализм булгач...

Г ө л җ а м а л. Суган белән кәбестә дә кирәк булыр.

М о р т а з а. Социализм булгач, Алла боерса...

Г ө л җ а м а л. Күмәчкә дә чират торырга кирәк булыр.

М о р т а з а. Социализм булгач...

Гөлҗамал. Кая, акча бир дә, мин китим... Болай да, озак йөрисең дип, Бану апа һаман тирги.

Мортаза. Син әле, Гөлҗамал, бөтенләй нараси икәнсең. Акча бит ул первая необходимость та, кыйммәт иясе дә түгел, первая необходимость нәрсәне алыр өчен алмашка йөртелә торган билге генә. Шуның өчен син итне дә, чыра пычагын да, чүлмәк капкачларын да бурычка ал, әйе, бурычка.

Гөлҗамал. Кем бирсен бурычка?

Мортаза. Бирерләр, бирерләр. Сознательный, Аллага ышанган кибетчеләр бирергә тиеш. Только, зинһар дип үтенәм, Гөлҗамал, чыра пычагы белән чүлмәк капкачлары алырга оныта күрмә. Ник дисәң, кичкә яңа докладның өлгерүе бик мөмкин... Хәзер мин шул эшкә керешәм. Үткән эшкә салават, ди картлар. Син теге, янып харап булган доклад өчен кайгырма. Дөнья вафа кылса, яңадан хәзерләрбез, Алла боерса. Дөньясы булгач, икмәге дә, һавасы да, чыра пычагы да, докладлы да бер дәрәҗәдә үк. Зарур бит. Бар, акыллым, бар.

Гөлҗамал. Бурычка бирмәсләр.

Мортаза. Бирмәсәләр алмассың...

Гөлҗамал. Ярый.

Мортаза. Мин бүген, бәлки, төнсез өйгә дә кайта алмам. Бануга сәлам әйт, борчылмасын... Яңа доклад хәзерләргә керешкәннәр, диең. Бар.

Гөлҗамал. Ярый. *(Чыга.)*

Мортаза. Мескен... Бер уйлаганда, несознательный булуы яхшы. Дөнья бәясенә алмаштырмаслык докладны харап итүе турында исенә дә алмый. Базар, ди, ит, ди, кәбестә, ди. Вөҗдан газабын күңеленә дә китерми.

Хәмит керә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Хәмит.

Хәмит. Докладның башлангычы һәм эшләнгән эшләр турында, информация турында ни эшләрбез икән?

Мортаза. Ягъни?

Хәмит. Копияләре юк.

Мортаза Ничек?!

Хәмит. Копияләре калмаган.

Мортаза. Сез мине җыйнаулашып үтерергә җыенасызмы әллә?

Х ә м и т. Үзегез копияләрен калдырырга кушмадыгыз.

М о р т а з а. Минем күрәчәгемә каршы, бер генә булса да кушкан эшне эшләгәнсез икән... Йә, ни эшләргә инде хәзер?..

Х ә м и т. Яңабаштан бөтен материалларны җыярга кирәк булыр.

М о р т а з а. Тагы яңабаштан.

Х ә м и т. Башкача мөмкин түгел.

М о р т а з а. Тазландырасыз башны, егетләр, тазландырасыз. Тыңла, сәгать дүрткә хәтле доклад өчен бөтен материаллар җыелып беткән булсын!.. Булмый икән, үзем дә бетәрмен, сезнең дә башыгызга җитәрмен. Бар!..

Х ә м и т. Мөмкин түгел, сәгать унике тула.

М о р т а з а. Приказываю!.. *(Хәмит чыга башлый.)* Тукта!.. Хәзер бөтен мастерскойларга телефонограмма бирегез. Конторадагы бер еллык бөтен кәгазьләрне бер сәгать эчендә җыеп миңа китерсеннәр. Бар!.. Тукта!.. Мастерской заведующийларына срочно телефонограммалар бирегез... Беренче: бер ел эчендә эшләгән эшләр, киләчәктәге перспективалар һәм бишьеллык план турында бер сәгать эчендә тулы докладлар хәзерләп миңа килсеннәр. Икенче: эшләп чыгару эшләрен арзанлаштыру, машиналаштыру, электрлаштыру, радиолаштыру турында сәгать ярым эчендә мөкәммәл проектлар хәзерләсеннәр. Бар! Тукта... Бөтен мастерскойларга телефонограммалар таратып, ике сәгать эчендә барлык мастерскойларда гомуми җыелышлар һәм доклад хәзерләү кампанияләре үткәрелсен... бар... Юк, тукта!.. Производство киңәшмәләренә хәзердән үк отношениеләр, положение, директива һәм перспективалар бирегез. Бетте, бар!.. Тукта, доклад өчен кирәкле ударный мәсьәләләр тагы бармы?

Х ә м и т. Белмим.

М о р т а з а. Белергә кирәк, брадәр, белергә кирәк, шул эшләр турында бер сәгатьтән миңа доклад белән керерсең. Бар!

Х ә м и т чыга.

М о р т а з а. Бер шырпы бер еллык эшне бер минут эчендә... Уйласам, күз алларымда утлы сандаллар әйләнә башлый. Минем кәгазьләргә кагыласы булма дип, әллә ничә кат строгий директивалар бирдем бит үзенә. Ул халык аралаш чүпрәк баш, мисез тавык, кыр казы үзенең мещанлык контрреволюциясен кора да тора. Ай, Соловки безнең артель карамагында түгел, бөтен мещанизм, хаты-

низм, фатиризм, чыра-пычагыйзмнар белән көрәшә белер идем. *(Звонок бирә.)*

Хәмит керә.

Хәмит. Нәрсә, Мортаза иптәш?

Мортаза. Минем хатынга хәзер срочно телефонограмма бирегез. Беренче: бүген көндезге ашка кайта алмам, көтмәсен. Икенче: кичкә фатирда лото мәҗлесе җыймасын. Бар!.. Тукта. Хәзер бөтен мастерскойлардагы культкомнарга хәбәр бирегез, доклад кампаниясе үткәрү уңае белән, өч чирек сәгать эчендә стенгазета чыгарсыннар. Баш мәкаләне үзем язармын. Бар!.. Юк, тукта... Хәзер мәркәз клубының идарәсенә отношение җибәрегез, клуб көтепханәсе бүлмәсендә безнең производствоның күргәзмәсен, конференциягә каратылып өч сәгать эчендә оештырсыннар. Теге посредрабистагы минем баҗай Гайнуллага минем исемнән хат язып, конференция өчен һәйбәт кенә сигез-тугыз кешелек симфонический оркестр оештырып җибәрүен сорагыз. Заграничный көйләргә уйный алсыннар. Сакай маршы белән Сания ариясеннән дә уйнарлар. Беркөнге төсле, зур быргысыз, барабансыз килмәсеннәр. Бәясен үзем сөйләшермен. Бар!..

Хәмит чыга.

Уф, бу нагрузка өчен спецставка гына түгел, полпред ставкасы кирәк. Ярый, мәкалә хәзерли башларга кирәк. *(Утыра.)* Хуш, мәкаләнең исемен ничегрәк куярга кирәк икән?.. Артельне машиналаштырумы, әллә «Кызыл сандал»ның җиңүе, дипме?.. *(Звонок бирә.)*

Хәмит керә.

Хәмит. Нәрсә?

Мортаза. Ярты тиенлек инициативагыз юк. Барысын да мин әйтеп торырга кирәк. Иң кирәкле эш калган бит.

Хәмит. Нәрсә тагын?

Мортаза. Драма түгәрәгенә хәзердән үк рәсми кәгазь җибәрегез, иртәгә, конференция ачылу уңае белән, биш-алты пәрдәлек һәйбәт кенә бер пьеса хәзерләсеннәр. Спектакль чыгымнарына кассадан сум утыз тиен акча җибәрелсен. Аң-белем, матур сәнгать эшләренә әһәмият итмичә ярамый. Культурный революция бит. Бар.

Хәмит чыга.

Хуш. *(Утырып.)* Әллә илне радиолаштыру турында һәйбәт кенә берәр нәрсә язасы микән? Әллә халык аралаш хәлләр турында бер сәяси мәкалә җибәрәсеме икән?

Н и з а м керә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Н и з а м.

Н и з а м. Фу, шәйтан алгыры. Ишек кага-кага, кулларым кабарып бетте. Осадный положениеме әллә? Бөтен ишекләр бикле. Өстәлләргә бөтен дөнья кәгазьләре өелгән. Шау-шу, ыгы-зыгы, тузан. Әллә ревизия-фәлән төштеме?..

М о р т а з а. Ревизия эшмени ул! Ревизия генә булса, бер хәл иде. Зуррак мәсьәләләр туып тора әле.

Н и з а м. Ликвидация түгелдер бит?

М о р т а з а. Ликвидация булса ябар идең дә, эш тә шуның белән бетәр иде. Көтелмәгәндә зуррак эшләр чыгып китте әле монда.

Н и з а м. Әллә шахтинский вакыйгаларның сөреме безгә дә...

М о р т а з а. Зуррак, дим, зуррак!..

Н и з а м. Җинаять, янгын, заговор, контрреволюция?!

М о р т а з а. Зуррак, дим мин сиңа.

Н и з а м Төшенмим.

М о р т а з а. Доклад хәзерлибез.

Н и з а м. Ишекләр бикләпме, ха-ха-ха!.. Ә соң кичәге доклад?

М о р т а з а. Юк ул хәзер.

Н и з а м. Ничек юк?

М о р т а з а. Син сорама, мин әйтмим.

Н и з а м. Югалды?

М о р т а з а. Юк.

Н и з а м. Урланды?

М о р т а з а. Юк, дим, юк.

Н и з а м. Ничек инде, югалмаган да, урланмаган да, ә үзе юк. Чемберленга җибәрмәгәнсездер бит?

М о р т а з а. Кеше булып торасың килсә өйләнмә, туган, зинһар, өйләнмә. Алиментларың булса, үзем түләшермен. Алай-болай мәҗбүри өйләнә калсаң, фатирда торма. Инде жакт председателе якын дусың булып, алай-болай фатирга эләгә алсаң, асрау тотма. Инде авылдагы берәр

кардәшеңнең кызын укытырга, тәрбияләргә дип, ялгышлык белән асрау итеп аласың икән, чыра пычагы белән чүлмәк капкачларын алдан алып куй. Юкса портфелең белән чүлмәк капларлар... Эчендәге доклад белән токмач пешерерләр.

Н и з а м. Димәк, докладың юк?

М о р т а з а. Юк, дию генә аз: һәбаән мәнсүра[1] булып очты.

Н и з а м. Бу ничек була инде?! Иртәгә конференция, ә синең докладың юк. Янабыз бит, Мортаза туган, дөрләп янабыз. Йә, нинди чаралар күрәсез, хуш?

М о р т а з а. Бөтен правление әгъзаларына, мастерскойларга, месткомнарга, культкомнарга, драма түгәрәкләренә доклад хәзерләү кампаниясе үткәрү турында фәрманнар тараттым.

Н и з а м. Эш җайлы гына барганда, менә сиңа!..

М о р т а з а. Күрәсеңне күрмичә гүргә кереп булмый дигәндәй, мәсьәләгә алай бик үк өметсез карамыйм мин. Ашамам, эчмәм, көн йокламам, төн йокламам, әмма доклад булыр. Дөрес, бәлки, янган доклад төсле үк булып чыкмас, шулай да дошманнарның кикрикләрен төшерерлек булыр. Үлсәм үләрмен, конференциягә докладсыз бармам.

Н и з а м. Докладсыз конференциягә бару бит балтасыз урманга бару дигән эш.

М о р т а з а. Үзеңнең конференцияне оештыру эшләрең ничек бара?

Н и з а м. Ул яктан эшләр ал да гөл. Конференциядә барлыгы йөзгә якын кеше катнаша. Шулардан хәзергә билгеле булганы Фәттахлар, Гыйлаҗлар группасы... Күп булса, биш кеше булыр. Синең группа белән минем группаны кушсак, барлыгы җиде кеше, биш группа булабыз. Ул яклардан эшләр рәтле, Алла боерса.

М о р т а з а. Безнең яктан торучы группалар күренмиме?

Н и з а м. Торып-торып кызык та сүз әйтеп куясың тагы. Бер группа икенче группаны яклый торган булгач, пычагымамыни группаларның кирәге! Менә шуның өчен дә массага юл куймас өчен, безгә икебезгә яңадан өченче бер группа оештырмыйча булмый.

М о р т а з а. Мин, әсасән[2], ул фикергә каршы түгел.

---

[1] Һ ә б а ә н  м ә н с ү р а – һавага очкан тузан.

[2] Ә с а с ә н – нигездә.

Ләкин минем асыл үз группамның фикере — фикер, үз юлы — юл. Үз планы — план.

Низам. Минем дә үз группам үземдә калачак. Конференциядә идарәгә яңадан үтсәк, ул сәгатьтән үк яңа төзелгән өченче группаны таратырбыз да, искечә ике группа калып, үзара тик акрынлап кына талашырбыз, тартышырбыз, Алла боерса.

Мортаза. Әсасән, мин риза. Только яңа группаның программасын, планын син төзерсең, минем конференциягә хәтле тын алырга да вакытым юк.

Низам. Анысы аның — кечкенә мәсьәлә. Үзем төзермен. Конференциягә барганда карап чыгарсың да, шуның белән эш тә бетәр.

Мортаза. Димәк, конференциягә дә икәү өч группа булып катнашабыз булып чыга.

Низам. Шулай итмичә мөмкин түгел бит. Бөтен хикмәт группада. Ул теге масса дигән булып җыен неграмотный мокытларга юл куярга ярамый. Ярый, хәзергә хуш. Минем тагы берничә группа оештырасым бар әле! *(Чыга.)*

Мортаза. Изге сәгатьтә!.. Ярый, эшләр акрын-акрын җайлана башлады. *(Звонок бирә.)*

Хәмит керә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Хәмит.

Хәмит. Нәрсә?

Мортаза. Эшләр ничек бара?

Хәмит. Бара дип...

Мортаза. Йә, йә?..

Хәмит. Барысын да сәгать дүрткә хәзерләп җиткереп булмас.

Мортаза. Сверхурочный түләрбез. Төн буе эшләсеннәр. Хәзер син кучерларга һәм йөкчеләргә телефонограмма җибәр. Бөтен йөкле арбалар туарылып, пролёткаларга җигелсеннәр. Үзеңә бер ат ал, Ивановка берсен бир. Миңа ике ат калдыр. Аннан соң хәзер үк тиз генә беренче мастерскойга барып доклад өчен кирәкле бөтен кәгазьләрне алып кил. Бар! Тукта! Чәй вакытына теге ярты сәгатькә бүген туктамасыннар. Шул турыда приказ чыксын. Сверхурочный алырлар. Урак өсте елга бер килә, брадәр. Конференция дә елга бер генә була. Тырышсыннар... Тырышыгыз!

Х ә м и т чыга.

Фу, һич бушар хәл юк. Мәкаләне яза башларга кирәк. Хуш, башын ничек куярга булдым әле? Һе, эшләп чыгару эшләрен машиналаштыру, электрлаштыру турында радионың тоткан урыны — бу бик кирәк мәсьәлә. Әллә һәрбер артель әгъзасын радиолаштыру дип куйыйммы икән?..

Шаулашып, Б а н у, Г ө л җ а м а л керәләр.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Б а н у һәм Г ө л җ а м а л.

Б а н у. Бу ниткән эшең тагын, җирбит! Әллә безне ачка үтерергә җыенасыңмы?.. Үзегез теге көнозын тыгынып йөргәч тә, безне әллә һава иснәп туялар дип уйладыңмы!..

М о р т а з а. Бурычка бирмәделәрмени?

Г ө л җ а м а л. Кем, сөйләшмиләр дә.

М о р т а з а. Һе, бирмәделәр, диең.

Г ө л җ а м а л. Бирмиләр, Сиркәкәгә кердем, кооперативка да кердем. Татмәскә дә кердем, Татмедторгка да кердем, Татиздатка да кердем — барысына да кердем. Бирмиләр, җитмәсә, көләләр генә, мыскыл итәләр. *(Елый.)*

М о р т а з а. Борчылма, Гөлҗамал, борчылма. Барып сораганның кадерен белмәсәләр, социализм булгач, үзләре китереп бирерләр әле, Алла боерса...

Б а н у. Китереп биргәнгә хәтле, сез бирәннәрне туйдырырга кирәк бит әле. Кая, нәрсә карачкы төсле күзлекләреңне акайтып торасың. Акча бир!

М о р т а з а. Күпме кирәк соң?

Б а н у. Көн дә, көн дә акчага төшеп булмас. Үзең калдыра белмисең. Кырык-илле сум кирәк булыр. Анда теге хатын тагы сөт, май китергән. Күмерче бер айдан бирле йөри. Аңарга да түләргә кирәк. Җөйчегә дә бирәсем бар. Сабын да беткән, керосин да кирәк. Өченче көн инде киного да барганым юк. Гөлҗамалны да мунчага җибәрергә кирәк. Әчеп беткән. Фатир, электр, радио, телефон өчен үзең түләрсең. Әллә нихәтле җыелган. Чәй-шикәр дә беткән. Борыч та юк. Йортка он кермәгәнгә ай буладыр. Докторга да икенче атна инде күренгәнем юк. Теш докторына да түлисем бар. Ашаган белми, тураган белә, дигәннәр олылар.

М о р т а з а. Беттеме?

Б а н у. Синең белән кеше төсле сөйләшеп буламыни.

Бер бөтен ыштаның, бер юньле оегың калмаган. Йөрисең шунда җил куып. Мендәр тышлары да тузып килә. Быел юрган сырдырмасаң, миңа үпкәләмә. Миңа дисәң, нигә пальтоңны ябынып йокламыйсың шунда.

Мортаза. Беттеме?

Бану. Миңа димәгәең, нигә чәнчелеп босяк булып йөрмисең шунда. Ачуымны күп китермә, әткәйләргә кайтырмын да китәрмен.

Мортаза. Беттеме?

Бану. Нигә каршымда әтәч төсле ырылдап торасың?

Мортаза. Гөлҗамал брадәр, әйт әле, зинһар, мин ырылдыйммы, ул ырылдыймы?

Гөлҗамал. Икегез дә...

Бану. Тик тор син, пешмәгән камыр, чүмәлә.

Гөлҗамал. Үзең кем булдың соң ул хәтле?

Бану. Кабарынма, әчегән чәүкә.

Мортаза. Беттеме инде, нәрсә кирәк?

Бану. Акча, дим ич.

Мортаза. Бар, кассадан кирәк хәтле ал.

Бану *(йомшап).* Әллә кайчан шулай диләр аны. Сүз көрәштереп утырган буласың. *(Гөлҗамалга.)* Утырып тор шунда. *(Китә.)*

Мортаза. Гөлҗамал брадәр, акылың булса, кияүгә чыкма. Зинһар, чыкма. Алимент кирәк булса...

Атылып-бәрелеп, Бану килеп керә.

Бану. Атлаган саен үзеңнең мыскыл итүең җитмәгән, инде конторщикларың алдында мыскыл итәргә уйладыңмыни? Һу-һу-һу, олтан бит, председатель булам дигәч тә, миңа председатель булганың юк бит әле...

Мортаза. Нәрсә бар тагын?

Бану. Акча бирмиләр ич.

Мортаза. Беттеме?

Бану. Син әле һаман...

Мортаза. Тесс!.. *(Телефон трубкасын алып.)* Сәгыйт, минем хатынга акча бирегез. Ә... Кырык сум.

Бану. Илле, илле булмаса, өйгә дә кайтмыйм.

Мортаза. Кара әле, илле булсын. Бар, бар, илле сумың белән чәнчел.

Бану. Чәнчел дигән була тагы, саботаж сакал!.. Әйдә, Гөлҗамал. *(Китәләр.)*

Мортаза *(сәгатен карап).* Уһу, сәгать өч тула. Әллә баш мәкаләне язмаскамы икән?

Хәмит кочак тулы кәгазьләрне, күтәреп кереп, өстәлгә ташлый.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Хәмит.

Хәмит. Уфф!.. Булды бу... *(Йөзеннән тирен сөртә-сөртә.)* Боларны карап чыга-чыга... Уф!..

Мортаза. Бөтенесе шундамы?..

Хәмит. Бернәрсә калдырмадым.

Мортаза. Ярый, рәхмәт. Син хәзер бөтен материалларны бүлеге-бүлеге белән, статьясы-статьясы белән тәртипкә китерә башла. Әзер булгач, миңа өйгә, фатирга китерерсең. Кич дип, төн дип торма, мин көтәрмен.

Хәмит. Фатирыгыз кайсы урамда соң?

Мортаза. Әүвәл Тегәрҗеп иде, хәзер Кызыл җеп, 84. Өйдә булмасам, хатынга бирә күрмә, юкса мунча ягарга керешерләр. Хатын белән таныштырсың бит?

Хәмит. Каян таныш булыйм, күргәнем дә юк.

Мортаза. Хәер, үзем өйдә булырга тырышырмын. Ә!.. Анан соң, эшләп чыгару эшләрен машиналаштыру турында, радионың тоткан урыны турында стена газетасына баш мәкалә яз. Имзасы, имзасы минеке булсын. Ә-ә... мин хәзер мастерскойларга доклад хәзерләү кампаниясе үткәрергә барам. Ә-ә... менә нәрсә икән тагын... Низамны кәгазьләргә якын җибәрмә. Дөнья эшен белмәссең.

Хәмит. Сезнең икегез ике группа икәнлегегезне беләм ич мин.

Мортаза. Бүгеннән икебез өч группа инде. Шулай да кәгазьләр тирәсендә чуалмасын. Мин киттем. *(Китә.)*

Хәмит. Гаҗәп: ике кеше — өч группа!.. Бу — яңа теория, яңа кәшеф[1], яңа уңыш!.. Математически болай булып чыга икән: бер татар шурум-бурум, ике татар өч группа. Өч татар толчок. Дүрт татар, дүрт татар, дүрт татарның хәле, малай, хәтәр!.. *(Уйга кала.)*

Пәрдә.

---

[1] Кәшеф — ачыш.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәгечә. Шул ук җиһазлар. Утлар сүнгән.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бану һәм Гөлҗамал.

Бану *(кереп, утлар яндырып, иснәп).* А-а-аһ!.. Әле һаман кайтмаган, Гөлҗамал, Гөлҗамал!.. *(Утыра.)* А-а-аһ!..

Гөлҗамал *(кереп, иснәп).* А-а-аһ... нәрсә?

Бану. А-а-аһ!.. Түрә иптәш абзаң кайтмадымы?

Гөлҗамал. А-а-аһ... Юк.

Бану *(киерелеп, иснәп).* Кара әле, сәгать ничә?

Гөлҗамал *(сәгать каршында озак киерелеп, килеп).* Беренче.

Бану. Радио уйный микән, кара әле, а-а-аһ!..

Гөлҗамал *(радио тирәсендә әйләнеп, кире килеп).* Беткән, а-а-аһ!

Бану. Каршымда иснәп тормасана, йокы китерәсең, а-а-аһ! Ни эшләп алай бүген иртә беткән икән?

Гөлҗамал *(киерелеп, иснәп).* Йокларга яткандыр.

Бану. А-а-аһ!.. Радио йокларга яткан инде, ул һаман юк. Самавырың кайнап торсын.

Гөлҗамал. Кайнап тора.

Телефон шалтырый.

Бану. Түрә иптәш абзаңны сорасалар, өйдә юк, доклад җыелышында, диең.

Гөлҗамал. Ә... Нәрсә кирәк? Нет, нет.

Бану. Дома нет, доклад пошёл, диең.

Гөлҗамал. Дома нет, доклад пошёл. Ә... чичтрасы да дома нет, доклад пошёл? Ә... Гупчим нет! Бану апа, үзең сөйләш әле. Әллә ничә ачулы тавышлар «чичтра», «чичтра» диләр.

Бану. Кем кирәк?.. Чего?.. центральный тәк центральный, шалтырат!.. Ә... не центральный, наш фатир это... Исерекләрдер, сүз аңламыйлар. Түрә абзаң кайткач, өч йомыркадан гына тәбә салып бирерсең. Мине уятмагыз.

Гөлҗамал. Сөт әчегән бит.

Бану. Күзле генә итәрсең, а-а-аһ!

Гөлҗамал. А-аһ! Ярый. *(Чыга. )*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Б а н у ялгыз.

Б а н у. Бу доклад җыелышларының бер бетәсе көне булырмы икән? Иртә доклад, кич доклад, төн доклад. Төнге докладлары өчен аерым жалуния түләсәләр, бер хәл иде. Бушка бит, бушка йөреп, шунда вакытын уздыра. Доклад ди-ди саташып, командировкага баруын да онытты инде. Әнә Фатиханың ире Зариф әфәнде, докладлар белән саташмаса да, ай саен диярлек командировка ала. Фатиханы бүләкләп кенә тора. Соңгы командировкасыннан Фатихага пальтолык кабиркот, заграничный ислемай, ефәк оеклар, модный беләк сәгате дә алып кайткан. *(Әтәч кычкыра. Иснәп.)* А-а-аһ... Беренче әтәч тә кычкырды инде. А-аһ... Менә киерелеп, җәелеп йокласаң иде... Фатиха рәхәтләнеп йоклый торгандыр. Нәрсә генә җитми торгандыр моңар? Жалуниясе бар, ат бирәләр. Фатиры бар, телефоны бар, радиосы бар. Рәхәтләнеп йоклыйсы урынга, әллә кайларда дөмегә. Дан өчен, дәрәҗә өчен йөри дисәң, Советта барыбер медаль бирмиләр. *(Звонок.)* Әбәү, пычак кергере. Котымны алды... Гөлҗамал, Гөлҗамал, түрә абзаң кайтты, ишек ач... *(Звонок.)* Гөлҗамал, ишек ач, дим! Тукта әле, керүенә докладларын башына каплыйм әле. Һаман дагын, һаман дагын юаш булсаң, бөтенләй дә онытыр бу юләр.

Бер кочак кәгазьләр күтәреп, Х ә м и т керә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Б а н у һәм Х ә м и т.

Б а н у *(үпкәләп, Хәмиткә арты белән торып).* Сәгатьне күрәсеңме ничә булган, олтан бит? Кая дөмектең, оятсыз? Төннәр буе йокламыйча көтәргә мин сиңа кем?

Х ә м и т. Өлгереп булмады...

Б а н у *(үртәп).* Өлгереп булмады, өлгереп булмады, һе, бозау!..

Х ә м и т. Ә?!

Б а н у. Төннәр буе дөмегәсе булгач өйләнмиләр аны... Белгәне доклад, җыелыш, җыелыш, доклад. Менә сиңа актык сүз, мине хатын дисең икән, вакытында өйгә кайт. Инде һаман да шулай доклад дисең икән, миңа үпкәләмә, мин дә үземә докладчылар табармын. Менә шул.

Х ә м и т. Гафу итегез, Мортаза иптәш йоклыймы әллә?

Б а н у *(сискәнеп).* Әстәгъфирулла, тәүбә, тәүбә, тфү, тфү! Син кем?.. Нигә син монда кердең?

Х ә м и т. Мортаза иптәш...

Б а н у. Гөлҗамал, Гөлҗамал! Сукыр тавык!.. Хәзер чыгып кит. Юкса мин...

Г ө л җ а м а л самавыр күтәреп керә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Б а н у, Х ә м и т һәм Г ө л җ а м а л.

Б а н у. Гөлҗамал, дим, сукыр тавык! Ишек ачканда, күзең кайда иде!..

Г ө л җ а м а л. А-а-аһ... Әү!

Б а н у. Сукыр бозау, кара, кемне керткәнсең...

Г ө л җ а м а л. Әтәч!..

Б а н у. Кемне керттең?..

Г ө л җ а м а л. Җир йотсын, күргән кешем түгел... Түрә иптәш абзый дип кергән, күрәсең...

Х ә м и т. Ханым иптәш, мин Мортаза иптәшкә срочно йомыш белән...

Б а н у. Яхшы чакта чыгып кит!..

Х ә м и т. Ханым иптәш...

Б а н у. Чык, дим!.. Гөлҗамал, уклау китер!..

Г ө л җ а м а л чыга.

Х ә м и т. Ханым...

Б а н у. Башың исән килеш чыгып китәсеңме, юкмы?!

Х ә м и т. Гафу итегез, әллә бу Мортаза иптәш фатиры...

Б а н у. Әллә иремне уятканны көтәсеңме?

Х ә м и т. Мөмкин булса, Мортаза иптәшне, зинһар, уятыгыз. Срочно эш.

Г ө л җ а м а л уклау, саплы щётка алып керә.

Б а н у *(уклау алып).* Чыгасыңмы, юкмы? *(Кизәнә.)*

Х ә м и т. Мортаза иптәшкә доклад өчен...

Б а н у. Нәрсә өчен?..

Х ә м и т. Доклад өчен материаллар...

Б а н у. Гөлҗамал, докладла үзен!..

Г ө л җ а м а л *(щётка белән төрткәләп).* Әйдә, әйдә, табан ялтырат!

Х ә м и т. Сез ни эшлисез?

Бану *(уклау белән бәргәләп).* Яхшы чакта чыкмасаң...
Гөлҗамал *(кизәнеп).* Чык, башың ярылмас борын!
Хәмит. Туктагыз әле, менә минем документым. *(Кәгазьләрен идәнгә ташлап, кесәсенә керә башлый.)*
Гөлҗамал *(читкә китеп.)* Мылтыгын чыгара, мылтыгын чыгара!..
Бану. Ә?! *(Чигенеп, телефон трубкасын алып.)* Каравыл, каравыл!.. Бандит, бандит!..
Хәмит. Менә, рәхим итегез!..
Гөлҗамал. Апа, мылтыгы юк!.. *(Щётка белән кыйный башлый.)*
Бану. Ә, куркырлар дип белдеңме!.. *(Кыйный.)*
Хәмит. Каравыл, каравыл!..

Звонок.

Бану. Гөлҗамал, тот, тот, качмасын!

Звонок. Гөлҗамал, Бану, Хәмит бер-берсенә ябышып, сугышып чыгалар. Шунда ук шаулашып, сугышып, бергә әүмәкләшеп Мортаза белән яңадан керәләр.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бану, Хәмит, Гөлҗамал һәм Мортаза.

Мортаза. Качмасын, качмасын, тотыгыз!.. *(Бүлмә буйлап сугышып, тәгәрәшеп, мәш килеп бетәләр. Хәмитнең җилкәсеннән эләктереп.)* Нигә кердең син монда?!
Хәмит. Доклад өчен!..
Мортаза. Тукта әле, тукта, Хәмит, син ләбаса бу.
Хәмит *(елап).* Мортаза иптәш, бу ни эшегез!.. Кешене болай...
Мортаза. Гафу ит, брадәр, гафу ит!.. Булдымы, кая материаллар?
Хәмит *(идәнгә чәчелгән кәгазьләрне күрсәтеп).* Әнә!..
Гөлҗамал. Менә! Бу карак түрә иптәшнең товаришы булды ич!
Бану. Такылдама. Бар, самавырыңны кара!..

Мортаза белән Хәмит кәгазьләрне җыялар.

Гөлҗамал. И-и-и... Нихәтле кәгазь...
Мортаза *(төртеп җибәреп).* Буталма!..

Г ө л җ а м а л. Бер-икесен генә самавыр кабызырга алыйм әле…

М о р т а з а *(катырак кычкырып).* Буталма, дим! Кагыласы булма!..

Г ө л җ а м а л. Исең киткән икән. Дөньяда аның таше кәгазьләр беткән, ди. Кыямәт куптарган була. *(Пыр тузып чыгып китә.)*

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Б а н у һәм Х ә м и т.

Б а н у. Үзеңнең көннәр буе дөмегеп йөрүең җитмәгән. Монда тагы әллә кемнәрне…

М о р т а з а. Җитәр сиңа, гөмбә.

Б а н у. Әнә сәгатькә кара, олтан бит.

М о р т а з а. Олтан дигәннән, өченче мастерскойда олтан беткән бит.

Х ә м и т. Мин аны сезгә әйткән идем.

М о р т а з а. Син әйткән беренче мастерской ул.

Б а н у. Тагын тотындылар…

М о р т а з а. Җитәр, дим!.. Күрәсең бит, эш бар. Бар, чыгып ят. *(Кәгазьләрен актара-актара.)* Безнең доклад хәзерлисебез бар.

Б а н у *(куркып).* Тагы доклад!..

М о р т а з а. Барлык материаллар җыелдымы икән?

Х ә м и т. Булган хәтлесен җыйдым.

Г ө л җ а м а л самавыр кертә.

Б а н у. Мортаза, дим!..

М о р т а з а. Әй, куй әле…

Б а н у *(бик каты кычкырып).* Ятасыңмы, юкмы?!

М о р т а з а *(кычкырып).* Юк, дим ич!.. Гөмбә!..

Б а н у. Алайса, мине көтмә!.. *(Бәргәләнеп чыгып китә.)*

М о р т а з а. Боларны нигә машинада яздырмадың?

Х ә м и т. Өлгереп булмады… Мортаза иптәш, моннан соң, төнге эшләр турында фатирыгызга чакырганда, хатыныгызга әйтеп калдырыгыз. Килгән саен, болай уклаулар белән каршы ала торган булсалар…

М о р т а з а. Әй гөмбә, үзең өйләнәм дисең. Чит хатынкыздан кыйнатып торасың, үз хатының үтерер үзеңне, дурак.

Б а н у *(киенеп, чемоданнар күтәреп чыга).* Мортаза!..

М о р т а з а *(карамыйча).* Әү!..

Б а н у. Мортаза, дим! Мортаза, миңа кара.

М о р т а з а *(борылып).* Йә, тутлы кына, син ни эшлисең, гөмбә?

Б а н у. Китәм.

М о р т а з а. Китәм?! Төн уртасында кая бармакчы буласың, дурак!

Б а н у. Синең шикелле шашкан берәр докладчы урамда очрар әле.

М о р т а з а. Юләрләнмә, чишен, бар, ят.

Б а н у. Менә хәзер, шул минут, бу кешеңне чыгарып җибәрмәсәң, үзең йокларга ятмасаң, билләһи газыйм, дип әйтәм, урамга чыгам да берәр адашкан докладчының муенына асылынам. Билләһи газыйм, сүзем сүз!.. *(Пауза. Кәгазьләрне идәнгә таратып ташлап.)* Ятасыңмы, юкмы?!

М о р т а з а. Юләрләнмә, гөмбә, чит кеше бар ич...

Б а н у. Ә сез, әфәнде, юньле кеше булсагыз, төн уртасында гаилә тормышын агулап йөрмәгез!.. Үз теләгегез белән чыгып китмәсәгез...

Х ә м и т. Мортаза иптәш, булмаса, мин китим.

М о р т а з а. Ярый, алайса, иртәгә иртәрәк кил. Мин үзем генә хәзерләрмен.

Х ә м и т. Хушыгыз!.. *(Китә.)*

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Б а н у.

Б а н у. Гөлҗамал, Гөлҗамал!.. Ишекне бикләп кал! *(Чишенә.)* Бу нинди хәл, иртә доклад, кич доклад, төн доклад. Кеше төсле вакытында ашау юк, эчү юк, йокы юк. Төн урталарында әллә нинди ят ирләр фатирыңа басып керә. Шул булдымы инде яңа тормышыгыз?.. Йә, нәрсә тагын кәгазьләреңә төртелдең?.. Әллә ерткалап ташлаганны көтәсеңме?..

М о р т а з а. Юләрләнмә әле, гөмбә.

Б а н у. Йә, чишенәсеңме?

М о р т а з а *(киерелеп, иснәп).* А-а-аһ... Арылган.

Б а н у *(иснәп).* А-а-аһ... арылмаска, әнә сәгатькә кара!

М о р т а з а *(чәйгә утырып).* Яса!..

Б а н у *(чәй ясый-ясый).* Беренче әтәч кычкырды бит инде. Әй, кара әле, әтәч дигәннән, син теге күгәрченнәр белән сату итүче Низамига әтәч китерергә әйткән идеңмени?

М о р т а з а. Китердеме әллә?..

Б а н у. Китерде. Әмма дә солтанат әтәч, күрсәң исең китәр. Алпавыт токымлы. Төкле аяклы, зур кикрикле, яшькелт койрыклы, бик матур, бик солтанат!..

М о р т а з а. Койрыгы нинди диден?

Б а н у. Яшел, бик матур.

М о р т а з а. Кызыл койрыклысы булмаганмы икәнни...

Б а н у. Яшькелт булса ни... Бик матур, салават күпере төсле, җем-җем итеп тора.

М о р т а з а. Токымы мин әйткән токым булса калдырырбыз. Ләкин койрыгын кисәргә туры килер.

Б а н у. Койрыгын кискәч, нәрсәсе кала соң аның... Матурлыгы да койрыгында гына бит аның.

М о р т а з а. Мин койрыкчылар тарафдары түгел. Бу — бер. Икенчесе, яшел төс артельнең уставына керми. «Кызыл сандал»га яшел койрык батмас.

Б а н у. Миңа димәгәе, нигә әтәчне дә суймыйсың. Мин яраткан койрыкка юри кире килә. Эчеп туйсаң, әйдә, ятыйк. А-а-аһ!..

М о р т а з а. Бар, ят. *(Кәгазьләрен карый.)*

Б а н у. Ә син?

М о р т а з а. Мин ятмыйм.

Б а н у. Ятмыйм?!

М о р т а з а. Иртәгә конференция, доклад хәзерләргә кирәк.

Б а н у. Хәзергә хәтле доклад иде, инде конференцияләрең белән теңкәмә тиячәксең икән, а-а-аһ!.. Бик йокым килә шул. Әйдә, җаным, ятыйк инде.

М о р т а з а. Бар, ят. Мине борчыма. *(Әтәч кычкыра.)* Бу нинди тавыш тагын?!

Б а н у. Шул инде, теге әтәч. Бүгенгә чоланга гына ябып куйган идек.

М о р т а з а. Бану, иртәгә мин йокыдан торуга, бер дистә йомырка хәзерләп куй.

Б а н у. Тәбә итәргәме, әллә?..

М о р т а з а. Чи йомырка, дим ич, гөмбә. Портфелемә салырсың.

Б а н у. Иртәгә куна-төнә китәргә үк уйлыйсыңмы әллә?.. Бу нинди яңа һөнәр чыгардың тагы?

М о р т а з а. Такылдама. Уйларга уңайсызлыйсың.

Б а н у. Вакытында ашамый, чәй эчми, йокламый...

М о р т а з а. Тукта, дим, гөмбә. Чәй белән йокыдан башка кайгың да юк бит синең. Ә без анда дуракланып сезнең өчен ду күчәбез. Яңа тормышка нигез корабыз,

яңа семья, яңа быт турында баш ватабыз. Ә сез монда, күбенә-күбенә чәй эчеп, әтәч кычкырганны саклап, ястык кабартасыз.

Б а н у. Яңа тормышларыгыз белән яңа бытларыгызны башыгызга каплагыз, яме. Синнән яңа тормышка нигез кор дип сораган кеше юк бит әле. Аны әнә машинада язучы кызларыгызга бирегез. Юләр саттырып, яңа тормышка нигез корганчы, син миңа пальтолык кабиркот алып бирсәң, мең өлеш артык булыр иде.

М о р т а з а. Эшләргә уңайсызлыйсың.

Б а н у. Кәгазьләр карау эшмени!

М о р т а з а. Рационализацияләштерелгән реализацияме, әллә реализацияләштерелгән рационализацияме?.. Моның кайсы дөресрәк икән?

Б а н у. Нәрсә тагын трантасланасың?!

М о р т а з а. Чү, дим... Планны таратасың.

Б а н у. Ә син минем планны таратмыйсыңмы?

М о р т а з а. Плансыз да бик чибәр йоклыйсың әле.

Б а н у. Төн буенча әллә кайларда өстерәлеп йөри-йөри дә, никахлы хатыны янына кайткач, доклад, план, ди башлый.

М о р т а з а. Бану!..

Б а н у. Акырма!..

М о р т а з а. Иртәгә иртә беләнгә хәтле доклад әзерләнмәсә, председательлектән, беләсеңме... *(Учына өреп.)* Өреп төшерәчәкләр бит, гөмбә. Төшенәсеңме шуны? Бөтен киләчәк, бөтен хикмәт, бөтен бәрәкәт иртәгәге шул докладка терәлгән. Доклад бит ул ботка пешерү түгел, чүпрәк баш.

Б а н у. Синең докладыңнан башка да дөнья җимерелмәс әле. Докладсыз да насыйп ризык кире китмәс.

М о р т а з а *(гаҗәпләнеп).* Докладсыз да насыйп ризык кире китмәс, ди, ә?! Менә ахмак, менә дивана! Көлтә хәтле чәч үстергән бу башның эчендә тәгаен гөмбәдер, гөмбәнең дә тилеседер. Бар, хатын, яхшылыкта ят. Юкса җилкәңә шундый резолюция салырмын, актык таянычың — йокыңнан да колак кагарсың.

Б а н у. Ә син...

М о р т а з а. Тфү!.. Революциягә хәтле бу кадәр үк аңгыра түгел идең ләбаса.

Б а н у. Ятмаслык булгач, ни дип соң мин сине икенче әтәч кычкырганчы көттем.

М о р т а з а. Ул әтәч тә шул синең шикелле йокыдан башканы белмидер.

Б а н у *(елап).* Ярый, ятмасаң ятмассың, сиңа юри үч итеп иртәгә уникегә хәтле йоклармын. Докладларың белән дөмек. Билләһи менә, уникегә хәтле урынымнан да кузгалмам. *(Чыгып китә.)*

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а ялгыз.

М о р т а з а. Әйтерсең лә башка көнне иртәрәк тора, несознательная, безнең татар хатынының шул булыр инде. Менә хәзер, тынычлыкта, ашыкмыйча гына, докладны хәзерли башларга кирәк. Моның өчен, әлбәттә, тынычлык, бик зур тынычлык кирәк. Уһу! Сәгать иkенче дә булган. Эшкә керешергә бик вакыт икән. *(Басып, тамакларын кырып хәзерләнә.)* Докладны ничек башларга икән? Җәмәгать, дип башласам... Җәмәгать!.. Җәмәгать!.. Тукта, моның русчасы ничек була соң... Русчасы общество була бит моның, ә безнең артель. Бу сүз белән докладны башлау туры килми икән. *(Карана. Тынлык.)* Әллә нәрсә колак төбендә бызылдап тора. Әллә кигәвен-фәлән кергән инде. *(Тынлык.)* Кара, кара, бызылдый да бызылдый бит, юньсез, әллә шөпшә-фәлән ояладымы икән?.. *(Тыңлап, тавыш ягына барып, самавырга бәрелә.)* Әнә нәрсә икән ул... Йә, карагыз инде, кайнаган самавырга нихәтле күмер тутырганнар. Безнең бу миңгерәүләргә экономрежим түгел, политрежим ясасаң да аңлата алмассың. Гөлҗамал, Гөлҗамал, Гөлҗамал, дим, саңгырау ябалак!..

Бану бүлмәдән кычкыра: «Кая акырасың, йокларга бир!»

Бу келәвез анабыз һава шытмаган икән әле. Гөлҗамал, дим!.. Бөтен революцияне йоклап үткәргән җыен гөмбә безгә җыелган.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Г ө л җ а м а л һәм М о р т а з а.

Г ө л җ а м а л *(киерелеп, иснәп).* А-а-аһ!.. Нәрсә?

М о р т а з а. Самавырны алып чык. *(Иснәп.)* А-а-аһ! Тфү, юньсез, өстенә карау белән йокы баса башлады... А-а-аһ!.. Күмерне карап тутырырга кирәк.

Г ө л җ а м а л. Яңартыргамы, а-а-аһ!..

М о р т а з а *(кулы белән чыгарга ишарә кылып изәп).* А-а-аһ! Йокы порошогымыни!..

Г ө л җ а м а л самавырны алып чыга.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а ялгыз.

М о р т а з а. Хуш... Гражданнар дип башлаганда ничек булыр? Бу сүзнең әле хәзергә чаклы һичбер оппозициягә һәм контрреволюциягә катнашканы юк.

Әтәч тавышы.

Әһә, тавышы шактый мәһабәт икән. Ыру өчен калдыру муафыйк булыр. Койрыгы артык яшел булмаса, кисмәскә дә мөмкин. Кикриге кызыл булгач ярый да язар. Хуш... Гражданнар!.. Гражданнар!.. Әнә шул ахырындагы «нары» бөтен кызыкны җибәрә. *(Сәгать суга. Сискәнеп.)* Фу, шәйтан икән. Бер яктан, бөтен көчең белән мещанлыктан качарга тырышасың, икенче яктан, мещанлык баткаклыгына бата барасың. Бүлмәңә гроб хәтле сәгать алып куеп, даң-доң иткән чиркәү тавышын тыңлап тор, имеш. *(Сәгатьне туктата.)* Сокращениегә кертми булмас сине, брадәр.

Әтәч тавышы.

Уһу... Тавышы шактый зур икән, токымы яхшы булса, койрыгын кызылга буярга да мөмкин булыр. Әтәч дигәннән, тавык үрчетү, тавык асрау артельләре төзү турында да докладта берәр сүз әйтеп китәргә кирәк булыр. Кош-кортның туганы файда бит, итен ашыйсың, йоны мендәр-ястыкка, сөякләреннән...

Радио. Аллл, аллл, аллр... шсшссcззз.

Син генә бик тансык идең, ди... *(Радионы туктата.)* Бездә фәннең соңгы иҗатлары белән файдалану юллары бик үк дөрес куелмаган. Мәсәлән, радио бик яхшы, бик һәйбәт нәрсә. Әлбәттә, сүзе аңланса... Инде тишек морҗадан ярык тавышлы җырчылар акыра башлаганда...

Әтәч тавышы.

Тавышы шактый тупас икән, карт булырга кирәк. Койрыгы ямь-яшел булса, кисәргә туры килер. Буяп кына котылып булмас. Буяу дигәннән, кыйммәтле буяуларны нигә кош-корт тәненнән алу юлларын уйлап чыгармыйлар икән? Мәсәлән, әтәч, үрдәк канатларында бик һәйбәт ялтыравыклы төрле-төрле төсләр була.

Әтәч тавышы.

Тавышы тупас, бик тупас. Буксир пароходы төсле акы-

ра. Гаҗәп, карандаш юанлыгы бугаздан моржа юанлыгы тавыш чыга. Тамагына салкын тигән дисәң, кош-кортка насморк булмый бугай. Әлеге дә баягы дигәндәй, иптәшләрсез докладны башлап булмас, ахры. *(Тамак кырып.)* Иптәшләр!.. Бу сүз, уйламыйча, үзе чәчрәп килеп чыга. Идеологиясе дә нык.

Әтәч тавышы.

Акыра да акыра, әллә сәгатем туктаганмы? Бу әтәч безгә кул булмас... Хуш... Мәшһүр Сиррон мәрхүм докладларын бөтенләй икенче төрле хәзерли торган булган. Аның юлы белән башлаганда, ничек булыр икән? Иске мәдәнияттән файдалануны муафыйк күрәләр бит. *(Тамакларын кырып.)* Әй сез, «Кызыл сандал» артеленең каһарман хезмәт батырлары... *(Телефон шалтырый.)* Кайсы юләр төн уртасында йокламыйча дураклана тагын?.. *(Трубканы алып.)* Кем кирәк?.. Ә?.. Соң минем ни эшем бар? Центральныйга шалтырат. Ә мин сиңа әйтәм, мин центральный түгел, дим. Ә?! Син үзең дурак. Үзең идиот! Кешене уятып, борчып йөрисең, прохвост. Менә дивана, сукыр кигәвен төсле, төн уртасында кешене йокысыннан уятып борчуы җитмәгән, сүгенә тагын.

Әтәч тавышы.

Бугазыңа пычак кергере карт юләр. Менә дивана, акыра да акыра... Әллә аягы кысылдымы икән? Иртә үк койрыгын да, кикриген дә кисәргә кирәк. Хуш, ничек башларга соң?.. Бер башлагач, үзе дә китәр иде китүен. Башлый белүдә хикмәт. Аның өчен күп вакытта докладның беренче җөмләсен генә тыңлаучылар күңелләрендә калдыручан була... Иптәшләр, әй сез, «Кызыл сандал» артеленең каһарман хезмәт батырлары! Индустриализациясез рационализация мөмкин булмаган төсле, рационализациясез индустриализация дә мөмкин түгел. Моның өчен массаның инициативасын коллективлаштыру проблемасын тормышка кертү турында субъект белән объект параллель булганда...

Әтәч тавышы.

Аптыратты бит бу радио бугаз. Менә карт анархист! Бөтен планны таратты бит. Доклад нинди һәйбәт башланып киткән иде. Конференция ачылуга барлыгы җиде сәгать вакыт калды. Бераз йоклап алмыйча да булмас. Йокы дигәннән, Һиндстанда кайсыбер хайваннар айга барлыгы дүрт кенә сәгать йоклыйлар икән.

Әтәч тавышы.

Фашисттыр бу!.. Көш, көш, көш!.. Ничек әле, ә?.. Массаның инициативасын коллективлаштыру проблемасын тормышка кертү турында субъект белән объект параллель булганда, эшләп чыгару эшләрен машиналаштыру, электрлаштыру, радиолаштыру белән продукциянең...

Әтәч тавышы.

Тукта, дим, хулиган! Машиналаштыру дигәннән, кайчан да булса бервакыт доклад хәзерли торган машина уйлап чыгарырлармы икән... әллә юкмы икән? Чыгармый калмаслар. Доклад бит һәрбер сознательный кешегә беренче зарур нәрсә ул. Андый машинага бездә спрос бик зур булачак. Ай, безнең заманда булсын иде ул...

Әтәч тавышы.

Тукта, дим, бандит!.. Үз башыңа кычкырасың, брадәр, үз башыңа, менә иртә торып иң элек койрыгыңны, аннан кикригеңне, соңыннан башыңны кисәрмен.

Әтәч тавышы.

*(Бармаклары белән колакларын тыгып.)* Акырырсың, акырырсың да туктарсың әле... Хуш... Иптәшләр!

Әтәч тавышы.

Иптәшләр, әй сез, «Кызыл әтәч» артеленең...

Әтәч тавышы.

Каһарман хезмәт әтәчләре!..

Әтәч тавышы.

Продукцияне тавыклаштыру мөмкин булмаган төсле...

Әтәч тавышы.

Коллективлаштыру проблемасын...

Әтәч тавышы.

*(Үчекләп.)* Тфү!.. Ку-ку-ку... Карт бандит. Төлке, хулиган, Чан Кай-ши!..

Әтәч тавышы.

Син, карт Чемберлен, бугазың белән мактанма, миндә дә ул бар... Кычкырырга калганда әлхәмделлиллаһ...

Әтәч тавышы.

Алаймы?.. Кикрикккy!..

Әтәч тавышы.

*(Өстәлгә менеп.)* Кикрикккү!..

Әтәч тавышы.

*(Канатларын кагып.)* Кикрикку!..

УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза, Бану һәм Гөлҗамал.

Бану. Ай Алла!.. Акылдан шашкан ич бу! Гөлҗамал, Гөлҗамал!..

Гөлҗамал керә. Әтәч тавышы.

Мортаза. Кикрикккү!..
Гөлҗамал. Әтәч, әтәч булган ич бу!..

Әтәч тавышы.
Бертуктаусыз телефон шалтырый башлый.
Гөлҗамал катып, аптырап кала.

Мортаза. Кикрикку!

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук бүлмә. Шул ук җиһазлар.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бану ялгыз. Телефон шалтырый. Әтәч кычкырганы ишетелә.

Бану. Центральный, центральный!.. Центральный, дим! Ләгънәт төшкән икән, телефоны да ватылган...

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бану һәм Гөлҗамал.

Гөлҗамал *(каушап, куркып, кычкырып, төеннәрен алып кереп)*. Пашпортымны бирегез, пашпортымны бирегез!..
Бану. Акырма, юләр чүмәлә!..
Гөлҗамал. Китәм, китәм, пашпортымны бирегез...

Бану. Акырма, котырган!..

Гөлҗамал. Котырып әтәчләр белән сугышканым юк әле, бирегез пашпортымны, бир!.. Газиз җанымнан аерылыр хәлем юк, бирегез, бир!..

Бану. Тукта, дим!..

Гөлҗамал *(кинәт тавышын үзгәртеп).* Йә?

Бану. Абзаң ни эшли анда?

Гөлҗамал. Пычак кайрый.

Бану *(куркып).* Ә?!

Гөлҗамал *(кайрап күрсәтеп).* Җир упсын менә, чаж-чож, чаж-чож китерә...

Бану. Нигә кулыннан пычагын алмадың, юләр.

Гөлҗамал. Юк инде, аны син барып ал, яме!..

Бану. Икебезне дә суяр бит!

Гөлҗамал. Ә?!

Бану. Шуңа ул пычак кайрый бит. Котырган кеше аны-моны абайлыймыни...

Гөлҗамал *(елап-көйләп).* Әй Ходаем, әй Ходаем, котырган хуҗалар кулыннан суелып үләр өчен генә, дөньяга туганмын икән... Әҗәл туфрагым гына мине шәһәргә өстерәп алып килгән икән... Тавык шикелле суелып үләргә тәкъдиремә язылган икән.

Бану. Бар, бар, хәзер кулыннан пычагын тартып ал!.. Ул бернәрсә дә белештерми бит.

Гөлҗамал. Суеласың бик килсә, үзең бар. Мин сезгә суелырга дип кермәдем, хезмәт итәргә кердем.

Бану. Монда кереп икебезне дә...

Гөлҗамал *(ишектән карап, кире кайтып).* Керә, керә, каравыл!.. Суялар, суялар!..

Бану *(Гөлҗамалга ышыкланып).* Гөлҗамал, бәгырем, коткар, коткар!..

Мортаза кулындагы пычагын сөртә-сөртә керә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бану, Гөлҗамал һәм Мортаза.

Гөлҗамал. Каравыл, каравыл, каравыл!..

Бану. Каравыл, каравыл!..

Бүлмә буйлап йөгерәләр. Бану башын диван астына яшерә. Гөлҗамал, тәрәзәдән сикереп төшәргә дип, тәрәзә төбенә атлана.

Мортаза *(пычагын өстәлгә ташлап).* Ни эшләвегез бу, әллә котырдыгызмы, гөмбәләр!.. *(Бануны өстерәп*

*чыгарып.)* Кая качасың, миңгерәү тавык... Әй син, мокыт, төш тәрәзә төбеннән, сквозняк кертәсең.

Бану диван астыннан чыга. Гөлҗамал, тәрәзә төбеннән төшеп, тәрәзәне яба.

Бану. Ә без бит сине...

Мортаза. Кара инде кыяфәтләренә, ха-ха-ха!... Ревизия күргәннәрмени... Ну, гөмбәләр, әтәчегезнең кирәген бирдем...

Гөлҗамал. Ни эшләттең?!

Мортаза *(бугазын күрсәтеп).* Кых!.. Иртәгә бөтен әтәчтән һәйбәт кенә пылау парлагыз, конференциядән соң кунаклар булыр.

Гөлҗамал. Әтәччч, акылында ич!..

Мортаза. Ә...

Гөлҗамал. Ярый, ярый, бик ярый.

Мортаза. Ярый, ярый, дип кенә, беркөнге төсле калмагыз. Обязательно парлагыз... Сәгать дүрттә әзер булсын.

Бану. Кичә алган майны тотарсың. Беркөнге шикелле борычы күп булмасын.

Гөлҗамал. Җимеш салыйммы?

Бану. Тавыкка җимеш килешә килешүен, әтәчкә ничек икән?.. Ярый, әнә теге сары капчыктагы җимешне салырсың.

Мортаза. Барыгыз, барыгыз, миңа уңайсызламагыз. Тфү, таң да аткан. Әй син, гөмбә, пәрдәләрне төшер, чыгып, тәрәзә капкачларын яп.

Гөлҗамал. Хәзер...

Мортаза. Тукта әле... Кара аны, мокыт, минем яныма үзем кушмыйча бер кешене дә кертәсе булма. Ишетсен колагың!

Гөлҗамал тәрәзә пәрдәләрен кора.

Гөлҗамал. Һаман-һаман килә торган кешеләр булса да кертмәскәме?

Мортаза. Берсен дә кертәсе булма... Кертсәң, кара аны!..

Гөлҗамал. Кушмагач, кертергә мин юләрмени... Теге егетне бит син дип ялгыш кына керттем. Ә килүче булса, ни дип әйтим?

Мортаза. Өйдә юк, әллә кайчан чыгып китте, диең.

Бану *(өстәлдәге зур пычакны алып күрсәтеп).* Алып чык!..

Гөлҗамал пычакны алып чыгып китә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Бану.

Бану. Кеше төсле йокы йөзе күрмичә күбрәк шулай йөрсәң, менә күр дә тор, шашарсың әле, Алла боерса, ничә төн бит инде, йокламыйча, шул докладың белән җенләнәсең.

Мортаза. Такылдама, бар, йокыңны бел!.. *(Кәгазьләр рәтли.)*

Бану. Йоклатырсың син!.. Адәм төсле үзе дә йокламый, кешегә дә рәхәтләнеп йокларга ирек бирми.

Мортаза. Уңайсызлыйсың!..

Бану. А-а-а-аһ!.. Рәхәтләнеп төш күреп ятканда, революция куптарды.

Мортаза. Йокла инде, адәм имгәге, йокла, дим...

Бану. Бер йокым ачылгач, дару эчмичә, йоклый алмаганымны беләсең ич... Җикеренгән була тагын...

Мортаза. Даруыңны эч тә дөмек!..

Бану. Эчәрмен дә шул... *(Дару алып, сулар хәзерли башлый. Гөлҗамал тәрәзә капкачларын яба.)*

Мортаза. Яхшылап яп, гөмбә... Менә шулай!.. *(Бануга.)* Йә, нәрсә терәлеп торасың тагы?

Бану. Әллә күзең чыкканмы, күрәсең ич, дару эчәм... Әгәр дә мәгәр, насыйп булып, кызым була калса, докладчы председательгә кияүгә чыгасы булма дип васыятемдә васыять булыр. *(Даруны эчә.)*

Мортаза. Кая, миңа да су бир әле, тамак кибеп китте.

Бану *(кинәт исенә нәрсәдер төшкән төсле, бармагын иренenә китереп)*. Булды гына, шулай итмәгәндә, ятасы юк моның. *(Стаканга дару сала.)*

Мортаза. Нәрсә маташасың анда!.. Бир инде...

Бану. Стаканым ташыды. Баерга булсын инде. Мә, бисмилла әйтеп эч, сихәте булыр.

Мортаза *(теле белән тәмләп)*. Нәрсә бирдең син миңа?

Бану. Нәрсә булсын, су... *(Халыкка.)* Әллә күбрәк ычкындымы икән?

Мортаза. Коры су түгел бу!..

Бану. Әйтте сүз... Су коры буламыни, юеш була инде ул.

Мортаза. Докладларың белән җенләнеп, әллә нәрсә эчермә син тагын.

Бану. Тотынды инде.

М о р т а з а *(стаканны иснәп).* Әнә әллә нинди исе дә бар.

Б а н у. Йоклата торган дару эчкән идем, шуның тәме калса калгандыр. А-а-аһ, әйдә, булмаса, ятыйк инде.

М о р т а з а. Бар ят!..

Б а н у. Ә син?

М о р т а з а. Бану, дим, яхшылап әйткәнне аңламасаң, кара аны, гөмбә, әтәч хәленә төшмә.

Б а н у. Алайса, иртәгә мине дә сәгать өчкә хәтле уятасы булма!.. Ишетсен колагың!.. Билләһи менә, күр дә тор, сәгать өчсез урынымнан да кузгалмам. А-а-а-аһ!.. *(Чыга.)*

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а ялгыз.

М о р т а з а *(торып, киерелеп, иснәп).* А-а-а-аһ, тәмам изелде кеше. *(Утыра.)* Һе, сәгать бишенче булган. А-а-а-аһ!.. Докладка керешергә кирәк. *(Торып, тамак кырып.)* Иптәшләр!.. «Кызыл сандал» артеленең үткән елгы, миңа хәтле булган эшлексез идарәсе... а-а-аһ!.. Үзара әтәч сугыштырып, волокита тудырып, автомобильләрдә йөреп, артель малын туздырып... а-а-а-аһ!.. Мин эшне чын хуҗалык кулына алу белән, иске идарәнең черек мирасы булып миңа күчкән, бөтен дөнья күләмендәге коточкыч хуҗасызлык, разрухага... а-а-аһ... чик куеп, автомобильне саттым. Артык атларны, арбаларны реализовать иттем... Җәй өчен дип хәзерләнгән склад тулы эшсез яткан малларны язга хәтле үк ликвидировать иттем. А-а-а-аһ!.. Бу ләгыйнь әтәч бөтен дәртне сүндерде. *(Кире утыра.)* А-а-а-аһ! Валерианка эчмичә булмас... Гөлҗамал, Гөлҗамал, дим!.. а-а-аһ! Гөлҗамал, дим!..

Г ө л җ а м а л керә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Г ө л җ а м а л .

Г ө л җ а м а л *(иснәп, йокы аралаш).* А-а-а-аһ, әү!..

М о р т а з а. А-а-а-аһ.. Валерианка бир!

Г ө л җ а м а л. Нәрсә?.. А-а-а-аһ!..

М о р т а з а. Әнә шкафтан дару алып бир!..

Г ө л җ а м а л. Кайсын бирим? А-а-аһ!..

М о р т а з а. Шешәсенә сары кәгазь ябыштырылган кызгылт дару, а-а-аһ!.. *(Йоклый башлый.)*

Гөлҗамал *(шешәләрне ут яктысында карап саный).* Шулмы?

Мортаза *(сискәнеп).* Фу, шәйтан арбасы... Кызгылтмы?..

Гөлҗамал. Кызгылт...

Мортаза. Егерме тамчы стаканга тамызып, су тутырып бир, а-а-аһ!.. *(Калгый.)*

Гөлҗамал дару хәзерләп китереп бирә.

Гөлҗамал. А-а-а-аһ!..

Мортаза *(башын күтәреп, алып эчә).* Тфү!.. Йокысызлыктан авызның һичбер тәме калмаган, валерианка тәме әллә нинди булып тоела...

Гөлҗамал *(исни-исни).* Я-я-я-тый-тый-тый-тыйммы инде?

Мортаза *(исни-исни).* Ба-ба-бар-р-р-р-р. Аһ!..

Гөлҗамал кашына-кашына чыга.

### ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза ялгыз.

Мортаза. Докладны баштан бер кат сөйләп чыгарга кирәк. А-а-а-аһ!.. *(Утыра.)* Иптәшләр, индустриализациясез а-а-а-а-аһ! Рационализация, рационализациясез а-а-һ!.. Индустриализация... Масса инициативасын коллективлаштыру... а-а-аһ!.. Проблемасын параллель... «Кызыл сандал» а-а-а-а-аһһһ!.. артель а-а-аһһ! кызыл а-а-аһһ... саф а-а-аһ!.. саф а-а-аһ!.. *(Йокыга китә. Гырлап йоклый.)*

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук бүлмә.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза һәм Гөлҗамал.
Мортаза диванда киенгән килеш йоклап ята.

Гөлҗамал *(щётка, чүпрәкләр күтәреп кереп, бүлмә җыештыра башлый).* Үз иркем белән эшләгәндә, барысына да өлгерәм... Өстә торсалар аптырап бетәсең...

Базарга да барып кайттым. Су да ташып куйдым. Кара чүпрәкләрне дә чайкап элдем. Кухня идәнен дә юып алдым. Әтәчне дә йолыктым, пылау да парларга куйдым... Бүлмә җыештырырга да вакытым калды. *(Мортазаны күреп.)* Әтәч, йоклый ич бу! Мескен, арыган, күрәсең, баш астына мендәр дә салмаган. *(Мендәр кертеп, баш астына куя.)*

Мортаза *(мыгырданып).* Упр-бр-р-р-р...

Гөлҗамал. Мәлҗерәве җиткән икән. Аягыннан салырга да оныткан. *(Аякларын чишендерә. Мортаза тибешеп мыгырдый. Рәтләп яткырып, өстенә яба.)* Бер йоклагач, әйдә, рәхәтләнеп йокласын. *(Борын эченнән көйләп, бүлмә җыештыра башлый. Звонок шалтырый.)* Кайсы пычак кергере тагын!..

Чыгып китә. Бераздан шаулашып, төртешә-төртешә Хәмит белән керәләр.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мортаза, Гөлҗамал һәм Хәмит.

Хәмит. Кермичә һич ярамый!..

Гөлҗамал. Кая керәсең, кая керәсең, дим!.. Өйдә юк дип татарча әйтәләр бит сиңа!..

Хәмит. Кирәк, аңлыйсыңмы, бик кирәк!..

Гөлҗамал. Син, агай-эне, чисти мөгезсез сыер икәнсең. Өйдә юк дигәч, өйдә юк, балтырымнан чыгарып бирмәм бит аны!..

Хәмит. Өйдә булмыйча, кая булсын?

Гөлҗамал. Кая акырасың! Урманда түгелдерсең ич!.. Кешеләрне уятырсың.

Хәмит. Хатыны кая соң?

Гөлҗамал. Анысы нигә тагын?!

Хәмит. Кирәк.

Гөлҗамал. Йоклый.

Хәмит. Йоклый?! Сәгать өч тула бит инде.

Гөлҗамал. Тулсын. Кешенең йоклавында синең ни эшең бар?

Хәмит. Булмаса, уятып, хатыныннан сора. Кая чыгып китте икән...

Гөлҗамал. Сорамый ни, хәзер сорадым, ди. Әйдә, чык, чык, тавышланып торма монда.

Хәмит. Әллә ничә кат телефон шалтыраттым, җавап бирмисез. Күптән чыгып киттеме соң?

Гөлҗамал *(сузып).* Әллә... кайчан... таң белән чыгып китте.

Хәмит. Таң белән?!

Гөлҗамал. Әйе.

Хәмит. Конференция ташлап, таң белән кая китәсе булды икән?

Гөлҗамал. Мин каян белим... Нигә соң, бик кирәк идемени?

Хәмит. Кирәк кенә түгел, уф...

Гөлҗамал. Берәр җирдән акча аласы бар идеме әллә?

Хәмит. Акча аласы гына булса, килеп йөдәтеп тә йөрмәс идем.

Гөлҗамал. Нигә, әллә судка-мазар барасы бар идеме?

Хәмит. Зуррак, зуррак!..

Гөлҗамал. Зур дип инде, Мәскәүгә барасы түгелдер.

Хәмит. Конференция бетеп килә, ул юк.

Гөлҗамал. Әй, ул зур эшмени!.. Ха-ха-ха!..

Хәмит. Соң!..

Гөлҗамал. Бездә үзебездә бар ул... Әллә ничә савыт!

Хәмит. Нәрсә?

Гөлҗамал. Кәнсирва.

Хәмит. Консервы түгел. Конференция, җыелыш.

Гөлҗамал. Соң шулай диең, нигә аны конфиронс, корфиронс дип бутыйсың... Мин тагын, чынлап та, әллә берәр зур эш бармы дип торам...

Хәмит. Зур булмыйча, анда сайлаулар башлана калды бит.

Гөлҗамал. Андый сайлаулар ел саен безнең авыл Советында да була. Берәүне дә көчләп йокысыннан уятып җилтерәтеп илтмиләр анда. Теләгән кеше бара, теләмәгән кеше бармый. Әйдә, әйдә, табан ялтырат. Кешене эшеннән бүлеп такылдап торма монда. Бик кирәк булса, кичкә әйләнеп килерсең тагы, әйдә, үкчәңне күтәр, фиит! *(Сызгыра.)*

Хәмит. Аһ, аңламыйсыз, иптәш, кичкә бит соң була.

Гөлҗамал. Бер дә соң булмас әле. Безнең түрә абзый төн буенча йокламыйча шау килә. Әйдә, әйдә, чык.

Хәмит. Хатынын уятыгыз, хатынын күрмичә китмим мин моннан.

Гөлҗамал. Ә, алаймыни, йомры баш!.. Элек, түрә абзый кирәк, дип ми черетте. Хәзер хатыны кирәк булган

икән... Бар, бар, табан ялтырат, безнең апа сайлауларга йөрми...

Х ә м и т. Сайлау өчен түгел, мин аңардан...

Г ө л җ а м а л. Нәрсә?! Ай, ыштыр бит, оятсыз бәбәк! Кит каршымнан!.. Яшь башың белән ир хатыннарыннан башка хатын-кыз тапмадыңмыни!.. Хәзер күз алдымнан юк бул!.. *(Щётка белән суга.)*

Х ә м и т. Туктагыз, сез нигә...

Г ө л җ а м а л *(аяк тибеп).* Эндәшмә!.. Яхшы ният белән йөрмәвеңне йөзеңнән күреп торам. Кара син аны, нинди йомшак бәлеш тапкан, адашкан ата песи төсле, әле төн уртасында бәреп керә, әле кеше йоклаганда. Башың исән чакта чыгып кит, дим мин сиңа!.. Юкса кабыргаларыңнан кәләвә ясап чыгарырмын мин моннан!.. *(Кизәнә.)*

Х ә м и т. Сез ни эшлисез?!

Г ө л җ а м а л. Әй, күп телеңә салышсаң. *(Бәргәләп чыгара.)*

Х ә м и т. Нигә сугасыз, нигә төртәсез?..

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Г ө л җ а м а л.

Г ө л җ а м а л. Һе, ыштыр бит, күз карашларында ук өмет юк. Бәрәкәтсез, мөгаен, берәр нәрсә чәлдерергә йөри бу, йә *(Бану бүлмәсен күрсәтеп)* моның белән өстерәлә... булыр, булыр, шәһәр халкыннан барысы да булыр. Ирләрен дисәң, иртәгә үләргә хәзерләнгән ютәлле кәҗә тәкәләре төсле, урамнарда, кеше алдында шул кыяфәтләре белән, хатын-кызлар белән оялмыйча култыклашып йөргән булалар. Хатын-кызлары күлмәкләрен тезгә хәтле күтәреп *(үчекләп йөреп күрсәтеп)* чыштыр-поштыр, чыштыр-поштыр камыт сыйракларын күрсәткән булалар, гарьләнмичә... Ә соңыннан атна саен тик доктордан докторга чабалар, тфү!.. *(Звонок.)* Тагы кайсы эшсезе икән... *(Чыгып китә.)*

Шаулашып, Низам белән төртешә-төртешә керәләр.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Н и з а м һәм Г ө л җ а м а л.

Г ө л җ а м а л. Өйдә юк дигәнне аңламыйсың әллә син!..

Н и з а м. Төртмә, нигә төртәсең?

Гөлҗамал. Нигә рөхсәтсез керәсең? Өйдә юк дигәч, юк. Әйдә, әйдә, чык!..

Низам. Өйдә булмаса, Марска очып китмәгәндер бит?

Гөлҗамал. Очып киткән булса, ни әйтерсең?.. Кая керәсең тагы!..

Низам *(этеп җибәреп).* Әй, буталмасана. *(Бану бүлмәсенә кереп китә.)*

Гөлҗамал *(арттан чабуына ябышып өстерәлә).* Кая керәсең, дим, мөгезсез сыер! *(Бераздан шаулашып чыгалар.)* Өйдә юк дигәнне әллә аңламыйсың син?

Низам *(йоклап яткан Мортазаны күреп, аптырап, катып кала).* Бу нәрсә бу?! Тукта, тукта, күземә күренәме әллә?..

Гөлҗамал *(халыкка).* Күрде бит, юньсез... *(Низамга ябышып.)* Уятасы булма!..

Низам *(этеп җибәреп).* Кит!..

Гөлҗамал. Нигә төртәсең син мине? Нигә төртәсең?! *(Якасына ябыша.)*

Низам. Кит лә. *(Каты итеп төртеп җибәрә, Гөлҗамал егыла.)*

Гөлҗамал *(сикереп торып).* Нигә сугасың миңа? Нигә сугасың, дим, ыштыр бит! *(Низамга суга.)*

Низам. Син ни эшлисең?!

Гөлҗамал. Нигә сугасың?! *(Кизәнә, Низам тайпыла, щётка Мортазаның күкрәгенә каты төшә.)*

Мортаза *(сискәнеп, сикереп торып, иләс-миләс булып йокы аралаш).* Пырурррр, пыруррр, пырурррр!..

Низам *(куркып).* Шашкан!..

Гөлҗамал. Көчләп керде, җир упсын, көчләп керде.

Мортаза *(аңына килә алмыйча).* Тукта, тукта, нәрсә булды соң бу?! Ә, Низам брадәр, син икәнсең, бик яхшы. Мин аз гына калгып киткәнмен. Шул арада ат типкән төсле булды... *(Күкрәген тотып.)* Менә хәзер дә авыртып тора.

Низам. Болван!..

Мортаза. Ә?!

Низам. Идиот!..

Мортаза. Нәрсә?!

Низам. Прохвост!..

Мортаза. Тукта әле...

Низам. Холуй!..

Гөлҗамал. Тагы докладларына тотындылар. *(Кул селтәп, чыгып китә.)*

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а һәм Н и з а м.

Н и з а м. Холуй!..

М о р т а з а. Шаштыңмы әллә син, ни булды сиңа?!

Н и з а м. Нигә качтың?

М о р т а з а. Качтың?!

Н и з а м. Нигә конференциядән качтың?..

М о р т а з а. Кем?!

Гөлҗамал тыштан тәрәзә капкачларын ача.

Н и з а м. Син!..

М о р т а з а. Мин?!

Н и з а м. Докладың кая?..

М о р т а з а. Ә-ә!.. Хәзер бетерәм мин аны... *(Сәгатенә карап.)* Туктаган... Әллә барырга да вакыт җиттеме?

Н и з а м. Кая?

М о р т а з а. Кая булсын. Конференциягә.

Н и з а м. Эшчеләр биржасына, диең, идиот!

М о р т а з а. Дулама әле, дулама!.. Докладның яртысы әзер инде.

Н и з а м . Ә конференциянең бөтенесе үтеп китте, болван!

М о р т а з а. Нәрсә?! Юк, чынлап саташкан бу!..

Н и з а м. Әнә урамга кара!..

М о р т а з а *(тәрәзәдән карап, чигенеп).* Аһ!.. Йә Ходай, йә Ходай!.. Беттем, харап булдым!..

Н и з а м. Син хаингә шул кирәк!.. Мине ни хәлдә калдырдың син... Тәрәзәләрен каплап, бикләнеп, сәгать дүрткә хәтле йоклап ята, болван, хөрәсән ишәге!..

М о р т а з а. Әллә, әллә ү-ү-үтте дәме?!

Н и з а м. Үтмичә, сине көтәләр, ди, юләр балык!..

М о р т а з а. А-а-ах!.. Беттем, беттем!..

Н и з а м. Шул кирәк сиңа!..

М о р т а з а. Тукта, тукта... Ә с-с-сайлаулар?..

Н и з а м. Бөтенебезне себереп ташладылар.

М о р т а з а. Себереп?! Әллә ми-ми-ми-мине дә?!

Н и з а м. Башаягың белән җәһәннәмгә хәтле чәнчелдерделәр.

М о р т а з а *(лап итеп утырып).* Ә?!

Н и з а м *(йодрыгын Мортазаның борынына китереп).* Менә мә!.. Салып җибәрермен, ачуым килмәгәе... *(Кизәнә.)* Болван!..

Мортаза аңгыраеп катып кала. Низам йөренә. Пауза.

М о р т а з а. Тукта әле, тукта... Бу ничек булды соң?.. Бернәрсә аңлый алмыйм!..

Н и з а м. Яңа идарәгә эшләреңне тапшырганда аңларсың... Ишәк!..

М о р т а з а. Бетте баш, бетте баш, харап булдым. *(Кулы белән йөзен каплап калтырана.)*

Н и з а м *(бүлмә буйлап йөреп. Паузадан соң).* Әнә теге месткомдагы демагог Шәрәфи малае белән, бузотёр Сафиулла мастерны чыгарырга кирәк дип, ничә әйттем мин сиңа. Тыңламадың... Менә хәзер кирәгеңне бирерләр.

М о р т а з а. Нәрсә?.. Әллә?!

Н и з а м. Яңа идарәгә бертавыштан шулар сайланды.

М о р т а з а. Ә-ә-ә-?!

Н и з а м. Да!..

М о р т а з а. Ә соң башка группалардан?!

Н и з а м. Бер кеше дә үтмәде.

М о р т а з а. Бу ничек була инде?

Н и з а м. Булганда да, майлаган төсле, тавышсыз-тынсыз, ялт итте.

М о р т а з а. Фәттах, Гыйлаҗ группасы?

Н и з а м. Гөрләп яндылар... Әйтәм ич, җиде группаның барысы да чатырдап янды!

М о р т а з а. Кемнәр соң үтте?

Н и з а м. Группасызлар.

М о р т а з а. Бу мөмкин түгел.

Н и з а м. Мөмкин булганлыгын, булмаганлыгын барып... Әй, беттек дигәч беттек инде...

М о р т а з а *(йомшак тавыш белән).* Әй син, «Кызыл сандал»! *(Каты кычкырып.)* Скандал, скандал, скандал!!! *(Куллары белән йөзен каплап, диванга утырып үкси башлый.)*

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

М о р т а з а, Н и з а м һәм Х ә м и т.

Х ә м и т. Уф! Наконец, өйдә икән. Мортаза иптәш, «Кызыл сандал» идарәсенең эшләрен тапшырырга сезне чакыралар.

М о р т а з а. Кемнәр?

Х ә м и т. Яңа идарә.

М о р т а з а. Кем аларны сайлаган?

Х ә м и т. Конференция, масса.

М о р т а з а. Масса юк! Шалишь, брадәр, шалишь!..

Минем докладымнан башка һичбер кешенең сайларга да, сайланырга да хакы юк.

Х ә м и т. Миңа, Мортаза иптәш, сез дә, яңа идарә дә барыбер. Мин кушканны эшлим. Чакырырга кушса, менә чакырам.

М о р т а з а. Юк, брадәр, шалишь, мин ул көн тәпиләргә, эшчеләргә бирешә торган егет түгел. Мин яңадан үзем яңа конференция җыям.

Х ә м и т. Батмас ул, Мортаза иптәш.

М о р т а з а. Менә батканын, батмаганын күрерсез. Бу иске режим түгел. Мин яңадан шундый группа төзермен, чыдап кына торсыннар.

Х ә м и т. Анысы шулаен шулай да, батмас шул. Группаларның базары үтте инде, Мортаза иптәш, батмас шул, батмас.

М о р т а з а. Бату гына түгел, әйләнеп төшәрләр... Мин сайланган кеше. Мине бертавыштан сайлап артель башына куйдылар.

Н и з а м. Бүген бертавыштан бәреп тә төшерделәр.

М о р т а з а. Менә без аларны бәреп төшергәндә, чыдап торсыннар. Хәмит брадәр, хәзер, хәзер, шул минуттан союзга, мастерскойларга, месткомнарга, культкомнарга телефонограммалар тарат... Мин риза түгел... Мин яңа конференциядә доклад ясарга тиеш. Аңлыйсыңмы, доклад ясарга тиеш!..

Н и з а м. Чү, чү, кызма. Тәртәне кызган...

М о р т а з а. Даёшь яңа конференция!!!

Н и з а м. Терәгең кая?

М о р т а з а. Үзем мин терәк!

Н и з а м. Какой син терәк. Дурак дисәң, хәер...

М о р т а з а. Шалишь, брадәр, чебиләрне көз көне саныйлар.

Н и з а м. Синең шикелле дураклар саныйлар, ә акыллылар анда санаган чебешләрне ашыйлар.

Х ә м и т. Мортаза иптәш, сезне анда көтәләр бит.

М о р т а з а. Бармыйм мин анда!..

Х ә м и т. Барырга кирәк булыр, Мортаза иптәш.

М о р т а з а. Бармыйм дигәч бармыйм!

Х ә м и т. Үз аягыгыз белән бармасагыз, башкача да илтеп куярлар.

Н и з а м. Терәксез кибән дә ава. Ә без кызганыч чүмәләләр генә булып калдык. Барысына да син гаепле, син!

М о р т а з а. Яңа конференция җыймыйча, барды юк!

Н и з а м. Куй, булмый торган эш белән баш катырма!
М о р т а з а. Булыр!
Н и з а м. Булмый.
М о р т а з а. Булыр!
Н и з а м. Булмый, булмый!
М о р т а з а. Булыр, булыр, булыр!..

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р, Г ө л җ а м а л һәм Б а н у.

Г ө л җ а м а л *(пылау күтәреп кереп өстәлгә куя).* Булды!..

М о р т а з а. Ә?.. *(Шашына.)*

Б а н у. Бу нинди тавыш тагын! Йә Ходай!

Г ө л җ а м а л. Әтәч шундый симез булып чыкты, чат май!..

Б а н у. Алай! Ә, исәнмесез, Низам әфәнде. Йә, утырышыгыз. Рәхим итегез!..

М о р т а з а. Шушы миңгерәү тавыклар белән менә шушы әтәч башыма җитте!.. *(Пылауны күтәреп идәнгә бәрә.)* Менә сиңа, менә сиңа, менә сиңа!..

Б а н у. Пәрәмәччч!!!

Г ө л җ а м а л. Әтәччч!!!

М о р т а з а. Кая портфелем, кая портфелем, доклад ясап үзем, үзем сайланам...

Б а н у. Киит, киит, кит, котырган, кит, кит, котырган, котырган!

Г ө л җ а м а л. Пашпортымны, пашпортымны бирегез! Пашпортымны бирегез, бирегез!

М о р т а з а. Даёшь конференция, даёшь доклад!!!

Портфелен күтәрә, ул кулыннан төшә.

П ә р д ә.

*1928 ел*

# КАНДЫР БУЕ

*Пьеса*

*Биш пәрдәдә, җиде картинада*

УЙНАУЧЫЛАР:

Акбирдин — егермебишмеңче, «Кызыл йолдыз» колхозының председателе.
Һилал — авыл Советы председателе.
Бригадир — колхозда беренче бригада башлыгы, комсомол.
Гөләндәм — колхозда икенче бригада башлыгы.
Фәридә — колхоз инкубаторында эшли (чебиләр караучы).
Минһаҗ, Үтәш бабай, Балан Сафа — колхоз членнары.
Әмәк, Шәмәк — элек батраклар, хәзер колхоз членнары, яшьләр.
Полевод — полевод һәм ячейка секретаре.
Гали — тегермәнче, соңыннан колхоз хисапчысы.
Тимеркәй, Закирҗан, Гайфулла, Хәйрүш, Бузотёр Нәгыйм, Бузотёр Бәдига, Сепарат Мәрьям — колхоз членнары.
Техник.
Беренче карчык.
Икенче карчык.
Өченче карчык.
Тарасов — монтёр.
Студентлар бригадасы.
Почтальон.
Остроумов — райком вәкиле.

Бюро членнары, колхозчылар, студентлар, кызлар, егетләр, комсомоллар, пионерлар.

Тамаша җәй көне, ике сука арасында, Татарстан колхозларының берсендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Су буе. Таллык. Тегермән. Тегермәнгә төшә торган арык-улак. Гали җырлап тегермән ташын теши, Үтәш бабай тыңлап таяк сырлап утыра.
Аяз көн.

I. Гали, Үтәш бабай.

Гали *(җырлый).*

Кандыр буе, ай, кара урман,
Киек җәнлеккәйләр оясы,
Без җырлыйсы җырлар шунда туган,
Шунда туган Кандыр чишмәсе.

Кандыр иңен йөзеп буйлаганда,
Уртасына басып тын алдым,
Иңнән иңгә сине айкаганда,
Синең өчен, Кандыр, оялдым.

Үтәш бабай. Без башкачарак җырлый идек яшь чакта. Уһу-һу-һу!.. Кандыр суы да болай түгел иде ул чакларда. Челләдә ат йөздереп чыгарга кот оча иде. Ә хәзер нәрсә! Сумыни бу! Борын Кандыр йөзгә оят китерерлек түгел иде.

Гали. Үтәш бабай, Кандыр суы борын заманнарда ике таш күтәргән, ди, шул чынмы?

Үтәш бабай. Исемдә, исемдә... Менә нәкъ шул урында ике ташлы Сәвен тегермәне иде. Күптән, бик күптән аны... яндырдылар. Сәвен үзе дә шунда янып үлде. Ай-Һай, аның шаукымы бик озакка сузылды.

Гали. Менә ул су хәзер булсын иде!.. Кандыр ике ташны күтәргән, диген, ә?

Үтәш бабай. Һи-һи-һи... Кандыр болай идемени!..

Гали. Хәзер көчкә-көчкә бер ташны өстери, дисәңче. Челләдә бөтенләйгә шыкаймаса дип куркам.

Үтәш бабай. Кандыр көчле иде, Кандыр тирән иде. Җир корый, оланнар, җир корый, нигезеннән корый...

II. Әүвәлгеләр һәм Минһаҗ.

Минһаҗ. Контр сөйлисең, Үтәш бабай, әссәламегаләйкем. Контр сөйлисең.

Үтәш бабай. Контр түгел, туры сүз.

Минһаҗ. Белмим тагын... Үзең абайлыйсыңдыр.

Гали. Яңа килгән колхоз председателе, Кандырга су табарга кирәк, ди.

Минһаҗ. Алай, ишетәсеңме, Үтәш бабай. Кандырга

су табарга кирәк, дип әйтә, ди, хи-хи-хи!.. Булдырыр, булдырыр. Иңне-буйны абайлый торганга охшамый. Юк, мин болай гына, яманлавым түгел. Һәйбәт егет күренә. Үзе партиец икән, үзе гомер буе заводта эшләгән, ди. Безнең колхозга председательлеккә коеп куйган инде. Тик борай белән бодайны аеруы чамалы, диләр диюен... Анысын аны агроном аерып бирер. Безнең өчен бик подходяшний кеше. *(Тәмәке урый.)*

Гали. Капкан җиреннән өзеп алам сортка охшый, ут шикелле ялт-йолт килә.

Минһаҗ. Гәрәчи, дисәңче.

Үтәш бабай. Уңган, булган егеткә охшый.

Минһаҗ. Яңа атның көче сабанда күренә, кем, Үтәш бабай.

Гали. Һилал иптәш белән аралары чамалырак, ди, чынмы икән?

Минһаҗ. Балта белән агач арасына бармак тыгарга картлар кушмаганнар. Ише — ише белән, ише җимеше белән дигәндәй, икесе дә партиец, икесе дә председатель. Берсенә без гражданнар, икенчесенә членнар. Труддинеңне исәплә дә тор инде. Башкасы безнең эш түгел.

Үтәш бабай. Кем, Минһаҗетдин энем, кайрысында кипкән агач чатнамый ул. Син кайры каезлап маташма, улым, яме!.. Йә булса, менә шул. Алай труддин исәпләп кенә тору килешмәс.

Минһаҗ. Юк, мин болай гына. Бар әле, кем, Мөхәммәтгали энем, нәрсә тагын анда шыгырдый башлады. Шуны әйтәм, Үтәш бабай, алар бит ай-һай, һай! Бүген кашын сикертсә, иртәгә җилкәңнән эләктерергә дә кыйбат алмыйлар.

Үтәш бабай. Куркытма син мине, энем, мин курыкмыйм. Карачкы итмә син аларны... Яме?.. Йә булса, менә шул. Безнең эшне эшлиләрме? Эшлиләр. Безнең өчен тырышалармы? Тырышалар. Киртә корма син безнең арага.

Минһаҗ. Нинди киртә турында әйтәсең икән?

Сафа керә.

Үтәш бабай. Илдән сөрелгән кулаклар гәбен чүпләү сиңа калдымыни?..

Минһаҗ. Торып-торып бер контр сөйләмәсәң, күңелең булмый үзеңнең, карт. Социализмга барган чакта, син мордар кулаклар шаукымы белән сыйлама мине.

III. Әүвәлгеләр һәм Сафа.

Сафа. Тиз генә буласы түгел, ди, әле ул.
Минһаж. Нәрсә буласы түгел, ди?
Сафа. Социализмны әйтәм.
Минһаж. Контр сөйлисең, кем, Сафа, контр.
Сафа. Әй Минһаҗ агай, социализм булгач, беркем дә бернәрсә дә эшлисе түгел, ди, икән, ә?.. Әмма дә рәхәт буласы икән, дурак.
Минһаж. Сиңа нәрсә!.. Сезгә Үтәш бабай белән хәзер дә социализм.
Үтәш бабай. Ай, канга тоз саласың, Минһаҗетдин. Күпсенмә, энем, күпсенмә, күпсенгән өлешсез калган, ди борынгылар. *(Китә башлый.)*
Минһаж. Уйнап сөйләшкәнне син тагы...
Үтәш бабай. Шул-шул. Күпсенмә, дим, яме?.. Йә булса, менә шул. *(Китә.)*
Минһаж. Чирләде, карт, хи-хи-хи... Йә, ниләр, бетерәсең, Сафа?
Сафа. Кая, урат әле.
Минһаж *(тәмәке бирә-бирә).* Ай-яй, сине тегеләр кыерсыта башладылар. Әллә гаеп, чынлап та, үзеңдә инде.
Сафа. Пүрәткә юк бездә, пүрәткә юк. Колхозмыни бу, тфү!..
Минһаж. Ярамый, колхозга төкерергә ярамый, контр була.
Сафа. Колхозга түгел.
Минһаж. Колхозга түгел?!
Сафа. Юк, менә монда кәгазе ныграк ябышсын өчен. Әбижәйт итәләр бит...
Минһаж. Кемнәр?
Сафа. Бригадлар.
Минһаж. Әбижәйт итәргә ярамый, контр була.
Сафа. Ни хәтле, мин сиңа әйтим, эшләп, барлыгы тугыз труддин исәпләп чыгарганнар. Бу здель дигәннәре безнең ишеләр өчен кул булмас күренә.
Минһаж. Һә, шулай дисеңме... Сабанда ничә көн эшкә чыктың?
Сафа. Сабанда билем авыртты. Авыруга эшкә чыгарга димәгән бит. Ахран трут шулай дип әйтә, ди.
Минһаж. Каты сукада да күренмәгәнсең, имеш?
Сафа. Кайсы әйтә аны?
Минһаж. Чыккан идеңмени?
Сафа. Ничек чыгыйм, ди, хатын авыргач!
Минһаж. Печәнгә чыкканың бармы соң?

С а ф а. Печән җыю бригадаларга бирелгән. Мин бригада түгел.

М и н һ а җ. Уракта сынатма инде, алай булгач. Эчәгеләрең өзелгәнче эшләсәң дә чамалы булыр. Здель, диләр аны.

С а ф а. Ни әйтсәң дә, безнең өчен җан башы җай иде.

М и н һ а җ. Эшләмәгән ашамый, диләр, үз хәлеңне үзең беләсеңдер…

Арбалар тартып килгән к а р ч ы к л а р күренә.

IV. Ә ү в ә л г е л ә р һәм к а р ч ы к л а р.

М и н һ а җ. Әнә колхоз яслесенең кызыл обозы да килә, хи-хи-хи!..

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Ничә әйттем үзенә. Искеләре ару булсын, болай шакшыланма инде, дим…

И к е н ч е к а р ч ы к. Зариф хатыны да шундый ук. Баласын юындырмый. Катырып йөрткәч, еламый нишләсен.

Ө ч е н ч е к а р ч ы к. Ул якка Зифабану уңган. Баласы курчак төсле ялт иткән була.

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Кара әле, Минһаҗетдин, тәгәрмәчем әйләнми. Көпчәгенә әллә үлән, әллә сүс уралган шунда, карап кына җибәрсәнә.

М и н һ а җ. Була ул, Гөлгенә түти, бик рәхәтләнеп, Алла боерса… Каян болай?

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Печәнчеләргә балаларын имездерергә илткән идек.

И к е н ч е к а р ч ы к. Ясле булдык бит, Минһаҗетдин.

М и н һ а җ. Яхшы эш, бик һәйбәт, эшләмәгәнгә бер локма да юк, ди бит алар. Яңа председатель корткаларны мәмке иткән, дигәннәр иде, чын икән.

Ө ч е н ч е к а р ч ы к. Безгә дә үзебезгә күрә бер эш булгач, күңелле булып китте әле…

М и н һ а җ. Сезгә түгел, тавыкларга да эш табарлар алар, хи-хи-хи!..

Б е р е н ч е к а р ч ы к. Тавык дигәннән, калфаклы чуар тавыгыма әллә ни булган, әтәч булып кычкыра башлады.

С а ф а. Тавык әтәч булып кычкыра, диген, хи-хи-хи!..

Ө ч е н ч е к а р ч ы к. Без яшь чакта, бәла-казага каршы тавык әтәч булып кычкырыр, диләр иде.

М и н һ а җ. Контр сөйләргә ярамый. Хәзер барыбер аңа ышанмыйлар.

Ө ч е н ч е к а р ч ы к. Нигә соң тавык әтәч булып кычкыра?

Минһаҗ. Ул болай гына... Заданиесен тутыра алмагач, әтәч булмакчыдыр, наян, хи-хи-хи...

Беренче карчык. Алай әйтмә, Минһаҗетдин, минем тавыгым әтәчләнергә кулак түгел.

Икенче карчык. Алай, безнең тавыклар илдән сөрелгән кулаклардан хат-хәбәр дә алышмыйлар.

Минһаҗ. Син, Фәрхи түти, ерактан чирттермәкче буласың, үзеңчә. Ярый-ярый, тырышыгыз, тырыш, бәлки, комсомол да ясап куярлар үзегезне, хи-хи-хи...

Беренче карчык.Йә, булдымы?

Минһаҗ. Барып чыкты бу, Гөлгенә түти. Яңа председатель китертәсе автомобильдән ким булмады.

Икенче карчык. Тавык бервакытта да бушка гына әтәч булып кычкырмый ул.

Өченче карчык. Йортта эт җир казыса — мәет, чикерткә сызгырса — янгын, тараканнар качса — ачлык.

Китәләр.

Минһаҗ. Син үзеңне әйтәсең, әнә анда тавык та әтәч булып кычкыра башлаган.

Сафа. Пүрәткә булмый торып, миннән эш көтмәсеннәр.

V. Әүвәлгеләр һәм Әмәк, Шәмәк.

Әмәк. Ишеттегезме?

Шәмәк. Яңа хәбәр.

Минһаҗ. Ни бар?

Әмәк. Ни, ни, ни...

Шәмәк. Чү әле, Әмәк...

Әмәк. Болгатма әле, Шәмәк.

Шәмәк. Гайфулла кулак сөргеннән хат язган.

Минһаҗ. Йә, йә?..

Әмәк. Теге Зирек авылының таз Касыймы аркылы кап-йот Хәйрулла Җиһаншасына хат язган.

Шәмәк. Шул хат буенча Чүпрә Хәдичәсенең әвен базына күмелгән нәрсәләрен чыгарып сатып, акчасын үзенә җибәрергә кушкан.

Әмәк. Район Әхмәтша сизеп алып...

Шәмәк. Эзләренә басып...

Әмәк. Шап!

Шәмәк. Чү әле, Әмәк!

Әмәк. Болгатма әле, Шәмәк!

Шәмәк. Шул шап-шоп!

Әмәк. Шатырман.

Ш ә м ә к. Каптырган.
Ә м ә к. Бер кибет тулырлык мал, хәзинә чыккан.
Ш ә м ә к. Ике төлке тун.
Ә м ә к. Илле пот ак он.
Ш ә м ә к. Күлмәк-ыштан, ястык, юрган.
Ә м ә к. Әвен базы шыгрым тулган.
Ш ә м ә к. Кисмәк-кисмәк май, бал!..
Ә м ә к. Ул мал чыккан, ди, мал!
Ш ә м ә к. Әмма ләкин шул малларның барысы җебенә-бөртегенә хәтле череп, сөрсеп эштән чыккан.
Ә м ә к. Әкәмәт инде, әкәмәт!
Ш ә м ә к. Карун малын күсе ашар, әнә шул була инде ул, Әмәк.
Ә м ә к. Шулай икән шул, Шәмәк.
Ш ә м ә к. Әнә бит нишләтә кулак этләре.
Ә м ә к. Кулак кулак инде. Каберендә дә тыныч ятмас ул контр бирән. Шул кулаклар белән хәбәрләшеп торучысын син әйт, дурак...
Ш ә м ә к. Менә бу сүзең хак.
Ә м ә к. Ялганларга мин син түгел лә.
Ш ә м ә к. Таз да түгел ләбаса үзең, нигә бүксәң киерәсең.
С а ф а. Мин бит Гайфулла кулакның кызы да әтәч булып кычкыра башлаганмы әллә дип торам, хи-хи-хи!
Ш ә м ә к. Әтәч дигәннән, Гөлгенә түтинең тавыгы...
М и н һ а җ. Ишеттек, эшсез ни дип кыршылып гайбәт сатып йөрисез, йолкышлар?
Ә м ә к. Ял көне — бу бер.
Ш ә м ә к. Гайбәт түгел — ике.
Ә м ә к. Өченчесе кирәк булса...

VI. Ә ү в ә л г е л ә р һәм А к б и р д и н, Һ и л а л, т е х н и к.

Һ и л а л. Бөгәсең бөгүен, Акбирдин иптәш, кара аны, чатнамасын!
А к б и р д и н. Чатнату гына аз, сындырырга кирәк, менә шулай. *(Кулындагы таякны сындырып ташлый.)*
Ә м ә к. Ишеттегезме?
Ш ә м ә к. Яңа хәбәр.
А к б и р д и н. Буталмагыз, буталмагыз, егетләр!..
Ш ә м ә к. Буталма, Әмәк!
Ә м ә к. Кысылма, Шәмәк.

Сафа белән Минһаждан б а ш к а л а р тегермән эченә кереп китәләр.

М и н һ а ж. Әтә-тә-тә-тә-тә-тә!..

С а ф а. Ай-яй, кайнар күренә.

М и н һ а җ. Кайнар ат тиз аручан була, кем, Сафа. *(Таяк башларын күтәреп.)* Чикләвек икән. Сыры да бар. Һәйбәт таяк, әрәм булган... Бу, энем, болай булгач тавыкларны әтәч итеп кенә түгел, сыерларны да «Баламишкин» көенә җырлатыр бу...

VII. Әүвәлгеләр һәм Акбирдин, Һилал, Гали, техник Әмәк һәм Шәмәк.

А к б и р д и н. Бу тузган әрҗә тәүлеккә ничә пот тарта?

Г а л и. Унбиш, уналты поттан арттырып булмый.

А к б и р д и н. Унбиш пот бер тәүлеккә, егерме дүрт сәгатькә?

М и н һ а җ. Канәгать кирәк, кем, председатель иптәш. Бу бит су тегермәне, паравай түгел. Яз көннәре су күп чакта егерме биш, утыз потка җитә, канәгать кирәк.

А к б и р д и н. Уһу!.. Утыз потка җитә!.. Октябрьнең икенче унында бу эшегез, егетләр, кәҗә бәясенә дә тормый.

М и н һ а җ. Су булмагач, без гаеплемени?

А к б и р д и н. Табарга кирәк!

Һ и л а л. Анысын инде синнән көтәбез, Акбирдин иптәш. Без хәзергә утыз потка да канәгать.

А к б и р д и н. Юк, чынлап та, бу музей экспонатын урын биләп ни диеп монда тотасыз?!

Һ и л а л. Һавадагы торнага караганда, кулдагы чыпчыкны артык күргәнгә.

А к б и р д и н. Бишьеллык план үкереп эшләп торган чакта, һавадагы торналарга кызыгып, чыпчыклар белән маташу кемгә кирәк соң? Начар аучылар икәнсез, егетләр, начар аучылар.

Һ и л а л. Маташып кара, бәлки, син утыз пот урынына өч йөз пот тартырсың.

М и н һ а җ. Алай, хи-хи-хи!..

А к б и р д и н. Ялгыштың, председатель, миңа өч мең пот кирәк.

М и н һ а җ. Җеннәр, пәриләр юк бит хәзер, кемнәр генә аны тартып бирер икән. Өч мең пот, диген, ә? Хи-хи-хи!

А к б и р д и н. Кандыр суы тартыр!

Һ и л а л. Һай, Кандыр Идел булса, мин әйтәм, хи-хи-хи!

М и н һ а җ. Алай!..

А к б и р д и н. Тартырга тиеш!

Һ и л а л
М и н һ а җ } Амин.

М и н һ а җ. Кара аны, икәү бер сүзне әйттек тагын.

А к б и р д и н. Техник иптәш, менә шул урында унбиш пот урынына тәүлеккә өч мең пот тарта алырлык көчле тегермән булырга тиеш.

Һ и л а л. Кызыл кар яуганда, дип тә куй.

М и н һ а җ. Алай, хи-хи-хи!

Һ и л а л. Кеше көлдермә, Акбирдин иптәш. Син монда бер ай торасың, ә без бу су буенда мыек үстердек.

А к б и р д и н. Сакал үстерергә дә рөхсәт сезгә.

М и н һ а җ. Су юк бит.

А к б и р д и н. Табарга кирәк!

М и н һ а җ. Энем, таякны әрәм иткәнсең бит.

А к б и р д и н. Яңасын, тимер башлысын ясарбыз, агай.

М и н һ а җ. Ясарбыз, дисең икән.

А к б и р д и н. Ясарбыз.

М и н һ а җ. Ясаганны сындырдык, дисәңче.

А к б и р д и н. Яңасын ясар өчен кирәк икән, ясаганны да сындырабыз, сындырабыз, шарт итә!

М и н һ а җ. Бу таякны үзең ясадыңмы әллә, мин әйтәм?..

А к б и р д и н *(Һилалга).* Синең фикер белән бу агай фикеренең күчәре уртак күренә. *(Минһаҗга.)* Үзем ясадым, агай.

М и н һ а җ. Мин колхоз члены, мин граждан, агайларны без озаттык!

А к б и р д и н *(техникка).* Безгә Кандыр ярларын ел әйләнәсендә тутырып торырлык су кирәк.

М и н һ а җ. Пичкә белән тутыруы, һай, кыен булыр, председатель иптәш.

Һ и л а л. Һай, усал син, Минһаҗ агай, мичкә белән диген, ә? Ха-ха-ха!

М и н һ а җ. Бездә водопровод юк бит... Завод законын авыл җирендә үткәрү, ай-һай-һай, батмастыр, егет.

А к б и р д и н. Синең тел, агай, шактый озын һәм йөгерек күренә...

М и н һ а җ. Телсезләр Лә суында алар.

А к б и р д и н. Шул-шул, төбендә агуы да юкмы икән, дим.

М и н һ а җ. Өркетмә, егет, өркә торганнардан түгел.

А к б и р д и н *(Галигә).* Бу кем?

Г а л и. Минһаҗ агай.

А к б и р д и н. Нишли ул монда?

Г а л и. Тегермәнче.

А к б и р д и н. Ә син?

Г а л и. Мин аның помошнигы.

А к б и р д и н. Эһем... икәүләп тәүлеккә унбиш пот тарттырасызмы?

М и н һ а ж. Су булмагач, без гаеплемени?

А к б и р д и н. Син, агай, иртәгә правлениегә килеп чык әле. Һилал иптәш, әйдәгез!

Һ и л а л. Кая?

А к б и р д и н. Су эзләргә!

Һ и л а л. Минем башка итегем юк, Акбирдин иптәш! *(Килгән юлыннан кайтып китә.)*

Ә м ә к. Без барабыз!

Ш ә м ә к. Безнең итекләрнең олтаннары бирешерлек түгел!

А к б и р д и н. Ярый бу, ярый бу!.. Болай булса... Әйдәгез!..

Икенче якка китәләр.

М и н һ а ж. Ничек ди, минем башка итегем юк диме, хи-хи-хи... Кандыр суын эчеп үскән егет шул ул, хи-хи-хи. Һә, правлениегә, диең. Барырбыз, барырбыз. Сине чакырмадымы?

Г а л и. Кая?

М и н һ а ж. Правлениегә.

Г а л и. Юк.

М и н һ а ж. Һә...

Еракта хор тавышы ишетелә.

Бу нәрсә тагы?!

Г а л и. Печәннән кайталар. *(Тегермәнгә кереп китә.)*

С а ф а. Анысы алаен алай да, мин әйтәм...

М и н һ а ж. Әйт, әйт, әйтә торган заман.

Һилал чыккан якка китәләр.

Әйдә әле, мин әйткәннәрне тыңласаң, чәчләрең үрә торыр,
Әйдә әле, әйдә!

VIII. П е ч ә н ч е л ә р. Музыка.

Б р и г а д и р, Г ө л ә н д ә м, Ф ә р и д ә, С е п а р а т  М ә р ь я м.

Х о р.

Ташладык иске-москыны,
Башладык өр-яңадан.
Көч ала безнең кырлар
Корыч кул машинадан...

Хор.

Әй-яй, бригадир, батыр ир!

Тавышлар.

Батыр ир!

Хор.

Эш мәйданы сине көтә, күкрәк киер!

Тавышлар.

Күкрәк киер!

Хор.

Эш батыры ударник!

Тавышлар.

Ударник!

Хор.

Тузан очсын, әйдә, сип!
Сип, сип, сип, сип, сип, сип!..

Тавышлар.

Безнең алда зур әмәлләр,
Авылда ясыйк шәһәрләр.

Хор.

Бөтен көч белән!

Тавышлар.

Эшчеләр белән!

Хор.

Кулга-кул!
Атлыйк алга,
Яңа дөньяга!..

Бригадир. Бригада, тукта!

Полевод. Тирләгән көе су керү ярамый, ди доктор Хәрәмша. Кояш баемыйча авылга керү не хорошо. Шуңар күрә булса-булмаса, мин әйтәм, Инкубатор Фәридәне җырлатып, Сепарат Мәрьямне биетеп, Трактор Вәлине сикертеп алмыйбызмы, дим.

Сепарат Мәрьям. Сүзең алтын, үзең бакыр, өндәмә, җем тор!

Гөләндәм. Йә әле, бригадир, удар темп белән, булмаса бер җырлап та бир!

Бригадир. Була ул, әмма ләкин минем дә бер гәп бар.

Гөләндәм. Гәпкә сыйса сөярбез.

Бригадир. Сыймаса?

Гөләндәм. Чөярбез.

Барысы. Ха-ха-ха!

Бригадир. Менә нәрсә, кызлар, егетләр, иптәшләр, комсомоллар, ярыш булса була.

Фәридә. Җырга нинди ярыш тагы?

Б р и г а д и р. Һу, җырның да үзенә күрә ярышы була булдырсаң. Ярышмы, ярыш – салкын әйрән эчү түгел ул.

Г ө л ә н д ә м. Җыр әйрән түгел, эчең күпмәс.

Б р и г а д и р. Мин дә шулай, дим. Күбүен күпмәс, әмма ләкин ярышсыз үтмәс!

С е п а р а т М ә р ь я м. Җырла, бригадир, җырдан бугаз катмый.

Б р и г а д и р. Әйтәм ләсә, ярышсыз батмый!

П о л е в о д. Чәчәк бөресез, шулпа өресез, капка боргычсыз, ярыш договорсыз булмый дигәндәй, әйт теләкләреңне, сызган беләкләреңне!

Б р и г а д и р. Кызлар, егетләр, шуны әйтәм: җырга каршы җыр белән җавап бирер Гөләндәм!

П о л е в о д. Әйдә, Гөләндәм, сөйлән, сүз синнән.

Г ө л ә н д ә м. Кабул иттек, пичәт суктык, бармы тагы яңа пункт?

К ы з л а р. Менә, менә, ха-ха-ха!..

Б р и г а д и р. Искәрмәсе исеңә төшсә, силос базына салырсың, сөт бирер!

Б а р ы с ы. Ха-ха-ха!..

П о л е в о д. Договор укылды, куллар куелды, ярыш башлана!

Г ө л ә н д ә м. Куркытмасана!

П о л е в о д. Бригадир, сынатма, әйдә, башла!

Музыка.

Б р и г а д и р.

Ударниклар ярыш мәйданында
Җиңү байраклары алганда,
Безнең дуслар фабрик-заводларда
Уртак хезмәт өчен янганда,
Кызлар, киленнәр, агай-энеләр,
Ялкау, тиләләр читтә йөриләр.
Матур апайлар, яшь кодачалар,
Нигә соң алар читтә торалар?!
Килегез, керегез безнең штабка,
Көнегез, көчегез узмас бушка!
Ударник бригадир, хәзер тор!
Хәзер тор, сине зур эш көтә.
Әйдә, чык мәйданга, кем батыр,
Кем батыр, кем хәзер көрәшкә!
Алда киң мәйдан!

Х о р.

Киң мәйдан!

Б р и г а д и р.

Эштә без янган.

Х о р.

Без янган.

Б р и г а д и р.

Көрәштә алдан.

Х о р.

Көрәштә алдан,
Беренче сафтан,
Барырбыз һаман!

Б р и г а д и р.

Ударниклар эшкә, ай, чыкканда,
Буй-буй майка уйный кояшта,
Җырлый-җырлый эштә ярышканда,
Җиңелгәннәр кала оятка.
*(Кушымта.)*
Ударниклар эштә күмәк терәк,
Чыныгалар алар көрәштә,
Илгә икмәк, азык-төлек кирәк,
Ударниклар хәзер һәр эшкә!
*(Кушымта.)*

П о л е в о д. Йә Гөләндәм, нәүбәт синнән, җиңелсәң, кара такта, җиңсәң, һәйт, наян, качма, тукта!

Г ө л ә н д ә м. Летун түгел лә мин качарга. Иптәшләр, мин бригадир төсле мактанып санга сыйфатны алдан тагып куймаска булдым.

Б р и г а д и р. Агитация кирәк түгел. Әнә Инкубатор Фәридә, чебиләрнең исәбен көзен алырсыз, ди.

Г ө л ә н д ә м. Шулай димени! Ә мин исәп-хисапны хәзер үк бетерсәм?..

Б а р ы с ы. Әйтә бу, ха-ха-ха!..

П о л е в о д. Тс-с-с... Бетте. Башладык!

Музыка.

Г ө л ә н д ә м.

Батыр егет җиң сызганып эшләгәндә,
Сөйгән яры читтә карап тик торырмы?
Эш мәйданы давыл булып гөрләгәндә,
Намуслы кыз эштән читтә кала алырмы?
Сәрвәр, Җәүһәр, Гөлҗамал,
Гөлсем, дустым Миңкамал,
Хәят, Банат, Шәмсеруй,
Гөлкәй, Миңкәй, Абруй,
Рауза, Рәбүш, Гөлраушан,

Биби, Гөлми, Нургаян,
Фәрхибану, Гөлҗиһан
Ударникка язылган.
Бибинур, ахирәт, син матур,
Гөлйөзем, былбылым, син түзем.
Айсылу, аппагым, син уңган,
Миңсылу мактаулы дан торткан.
Читсенеп-ятсынып тормыйк,
Булыйк мактаулы ударник!
Күмәк эштә уңай бергә-бергә,
Бергә кердек шулай көн күрергә,
Үремнәргә уңай бергә-бергә,
Без дә, сез дә шулай бергә-бергә
Гомергә!

Хор.

Алда киң мәйдан,
Эштә без янган,
Көрәштә алдан,
Беренче сафтан
Барырбыз һаман!
Аумакайлардан,
Ялагайлардан,
Кап-йот наяннан,
Тинтәк ялкаудан
Арыныйк, туган!

Гөләндәм.

Сылу кызлар җиң сызганып эшләгәндә,
Батыр егет читтә карап тик торырмы?
Эш мәйданы давыл булып гөрләгәндә,
Намуслы ир эштән читтә кала алырмы?
Гали, Вәли, Сөләйман,
Әһли, Дәүли, Тимерҗан,
Мифтах, Минһаҗ, Гыйльметдин,
Кави, Каюм, Котбетдин,
Хәйри, Бәдри, Батырҗан,
Локман, Госман, Хәкимҗан,
Закир, Зариф, Фазылҗан
Ударникка язылган!
Хәрәмша, акыллым, син батыр,
Дәүләтша, сөеклем, син матур,
Тимербай сабанда дан алган,
Миңлебай мәйданда танылган.
Читсенеп-ятсынып тормыйк,
Булыйк мактаулы ударник!

Күмәк эштә уңай бергә-бергә,
Бергә кердек шулай көн күрергә,
Үремнәргә уңай бергә-бергә,
Без дә, сез дә шулай бергә-бергә
Гомергә!

Хор.

Алда киң мәйдан,
Эштә без янган.
Көрәштә алдан,
Беренче сафтан
Барабыз һаман!
Аумакайлардан,
Ялагайлардан,
Кап-йот наяннан,
Тинтәк ялкаудан
Арыныйк, туган!

Кызлар. Бригадир җиңелде!

Егетләр. Гөләндәм җиңелде.

Шау-шу.

Полевод. Бетте. Тавышка куям. Хәзерләнегез, кем дә кем...

IX. Әүвәлгеләр һәм Гали.

Гали *(тегермәннән чыгып).* Сүз сорыйм, сүз бирегез!

Полевод. Сүз тегермәнче Гали иптәшкә.

Гали. Егетләр, кызлар, бригадирлар, ударниклар, эш менә нәрсәдә: колхоз правлениесе тегермән келәтен сипләтмәкче була. Шундагы игенне тегермәнгә күчерәсе иде. Вакыт соң түгел, шуны күчерергә разый булганнар кулларын күтәрсеннәр!

Барысы *(кулларын күтәреп).* Күчерәбез, күчерәбез!

Гали. Менә капчыклар да бар. Тишекләрен, кызлар, сез караштырыгыз!.. Менә энәләр, менә җеп...

Бригадир. Беренче бригада, хәзерлән!

Гөләндәм. Икенче бригада!

Бригадир. Гөләндәм, капчык ташыганда ярышып карыйк, мин әйтәм.

Гөләндәм. Алдан күперенмә, әйдә!

Бригадир.
Гөләндәм. } Бригада эшкә!

Тәртип белән чыгып китәләр.
Фәридә белән кызлар капчыклар ямап калалар.

Музыка.

Ф ә р и д ә.

Саф Кандырның, ай, сулары
Сикреп-сикреп акканда,
Ударниклар җиң сызганып
Эшкә җырлап барганда...

Дөнья яңгырасын,
Сулар шауласын.
Ялкау, кит юлдан,
Урын биләмә!
Эшкә чыныккан
Батырлар килә,
Батырлар килә,
Бирегез мәйдан!

К ы з л а р  х о р ы.

Дөнья яңгырасын,
Сулар шауласын.
Ялкау, кит юлдан,
Урын биләмә!
Эшкә чыныккан
Батырлар килә,
Батырлар килә,
Бирегез мәйдан!

Ф ә р и д ә.

Кандыр буе яшел чирәм
Кояшта җем-җем итә.
Ялкаулансаң, егет, сөймәм,
Кызлар булганны сөя.
Дөнья яңгырасын,
Сулар шауласын.
Ялкау, кит юлдан,
Урын биләмә!
Эшкә чыныккан
Батырлар килә,
Батырлар килә,
Бирегез мәйдан!..

Егетләр һәм кайбер кызлар, капчыклар күтәреп, тегермәннең өске катына меноләр.

И р л ә р, к ы з л а р  х о р ы.

Дөнья яңгырасын,
Сулар шауласын,
Ялкау, кит юлдан,
Урын биләмә!

Эшкә чыныккан
Батырлар килә,
Батырлар килә,
Бирегез мәйдан!..

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

«Кызыл йолдыз» колхозында Советлар йорты. Колхоз идарәсе, авыл Советы, партия ячейкасы, янгынга каршы көрәш җәмгыяте һәм башкалар. Язу өстәлләре, урындыклар, эскәмия, телефон, юлбашчыларның рәсемнәре. Б р и г а д и р игенгә, бакчачылыкка карата язылган яңа плакатлар кадаклап җырлый.

I. Б р и г а д и р.

Музыка.

Б р и г а д и р.
Сикереп аккан су, әйтсәңче,
Кайсы илләргә сәфәрең?
Күрше илләргә син салсаңчы
Безнең колхоз хәбәрен.
Сикереп аккан агым судай
Үтә безнең яшь чаклар,
Арыш, тары, солы, бодай,
Уңды ясмык, борчаклар.
Сикереп аккан агым судан
Киек казлар су эчә,
Даёшь торма, кишер, суган,
Фил башыдай кәбестә.
Күктә йолдыз, суда кондыз,
Йолдыздан кондыз матур.
Даёшь кыяр, кавын, карбыз,
Кызыл битле помидор.
Гидер, гидер, гидер,
Гидер, гидер, гидер…

II. Б р и г а д и р һәм Г ө л ә н д ә м.

Г ө л ә н д ә м *(тәрәзәдән).* Ау-у-у!..

Бригадир сискәнеп, плакатларын төшереп җибәреп, үзе сикереп төшә.

Г ө л ә н д ә м. Ха-ха-ха!..

Б р и г а д и р. Фу, шәйтан, котны алдың! *(Плакатларны күтәрә, яңадан өстәлгә менә.)*

Г ө л ә н д ә м. Әмма дә йөрәк икән үзеңдә, ха-ха-ха!..

Б р и г а д и р. Кешнәмә әле! Җыеныгыз әллә кайларда олагып йөрисез, булышырга берегезне бер табар хәл юк.

Г ө л ә н д ә м. Ял көне икәнлеген исеңдә тот! Акбирдин мондамы?

Б р и г а д и р. Әһә-һә-һә!..

Г ө л ә н д ә м. Нәрсә күзләреңне шакмакландырдың?

Б р и г а д и р. Әһә-һә-һә!..

Г ө л ә н д ә м. Акбирдин мондамы, дим?

Б р и г а д и р. Әһә-һә-һә!..

Г ө л ә н д ә м. Мондамы, дим?..

Б р и г а д и р. Ял көне икәнлеген исеңдә тот!

Г ө л ә н д ә м. Йә, шаярмыйча гына, мондамы?

Б р и г а д и р. Әһә-һә-һә!.. Аңлашылды, вопрос ясный.

Г ө л ә н д ә м. Яссымы, түгәрәкме, анысында эшем юк, Акбирдин мондамы, дим?

Б р и г а д и р. Нигә, әллә?..

Г ө л ә н д ә м. Мондамы, дим, шабалак!

Б р и г а д и р. Колхоз уставында тәрәзәдән справка бирү дигән пункт юк, ябалак.

Г ө л ә н д ә м. Кыланышы…

Б р и г а д и р. Гидер-гидер-гидер…

Г ө л ә н д ә м. Әй!

Б р и г а д и р. Әү! Гидер-гидер…

Г ө л ә н д ә м. Кара әле!

Б р и г а д и р. Әү! Гидер-гидер…

Г ө л ә н д ә м. Таңнан килеп ни кырасың монда?

Б р и г а д и р. Балык тотам. Гидер-гидер…

Г ө л ә н д ә м. Чиртәме соң?

Телефон шалтырый, Гөләндәм тәрәзәдән югала.

Б р и г а д и р. Чиртте. Әйе, Кызыл йолдыз… Петров, синме бу?.. Ә?.. Кара әле, бездә бүген ял көне иде бит, парень, шуңа күрә тракторлар, машиналар… Ә?.. Юк, иртәгә соң була. Син инде бүген җибәрә күр… Ә?.. Ярый, молодец!..

Гөләндәм өй эченә керә.

Г ө л ә н д ә м. Син, егет, Советлар йортын аулак өй иттеңме әллә?

Б р и г а д и р. Нигә, уңайсызладыммы әллә?

Г ө л ә н д ә м. Кемгә?

Б р и г а д и р. Акбирдин дисең түгелме соң?

Г ө л ә н д ә м. Акбирдин сезнең шикелле җебеп тормый ул.

Б р и г а д и р. Гыйшык диген, ә?.. Янам диген, ә?.. Пожар диген, ә?..

Г ө л ә н д ә м. Гыйшык шул, ә?.. Янам шул, ә?.. Пожар шул, мә?.. *(Борынына чиртә.)*

Б р и г а д и р. Алай үз утыңа үзең чыдаша алмагач... Кая, әнә теге плакатны бир!

Г ө л ә н д ә м. Йөрәкне песи тырный диген, ә?

Б р и г а д и р. Анысын әле тикшерәсе, беләсе бар... Ә синең песи мыраулый да башлаган күренә.

Г ө л ә н д ә м. Нәрсә дидең?

Б р и г а д и р. Чүкечне бир, дим.

Г ө л ә н д ә м. Акбирдин ут ул. Аның уты янмыйм дисәң дә яндыра...

Б р и г а д и р *(бармагына бәреп).* Тфү, кадалгыры!

Г ө л ә н д ә м. Менә, ха-ха-ха!.. Көнләмисеңме тагы?

Б р и г а д и р. Фу! Йөрәкне өзде.

Г ө л ә н д ә м. Кем?

Б р и г а д и р. Чүкеч... *(Һавада бармагын селки.)*

Г ө л ә н д ә м. Канамыймы?

Б р и г а д и р *(төшеп).* Бар, бар, мен. Мә, кадакла! *(Бер читтә бармагын бәйли.)*

Гөләндәм, өстәлгә менеп, плакатлар кадаклый башлый. Музыка.

Г ө л ә н д ә м.

Көяз кызның көянтәсен
Оста егет сырлаган.
Егетемнең йөрәкләрен
Чуар песи тырнаган.
Читтән килгән батыр тилгән
Урын сайлый кунарга.
Сезнең очтан безнең очка
Кушмый сукмак сугарга.
Ал яулыкның ал бизәген
Бәйрәмгә дип мин чиктем.
Өзелсен, егетем, үзәгең,
Илтифат итмим губчим.

Б р и г а д и р.

Ышык-пышык гыйшык тотып
Сагнып мещан йолдызын,
Обыватель җырын шыңшып
Йөрмә җил куып, кызым!

Гөләндәм. Әбәү! Әле син...

Бригадир. Гидер, гидер, гидер, дим.

Гөләндәм. Әй, бик исем китте, ди. Мә, мә, мә?.. Үзең дә кадакларсың!.. *(Пырылдап чыкканда, Акбирдингә очрый.)*

III. Әүвәлгеләр һәм Акбирдин.

Акбирдин *(күтәренке рух белән керә).* Гөләндәм, тукта! Бригадир, бар, хәзер иптәшләргә әйт, монда килсеннәр. Үзең дә калма. Райкомнан вәкил килде, мәсьәлә тагы ячейкага куела. Бөтен фронт буенча ут ачарга туры киләчәк. Да, трактор Вәлигә узышлый сугыл. Интрда куян базлыгын актартып кайтсын. МТСтан мастер килмәдеме?

Бригадир. Хәзер генә шалтыраттылар, төштән соң килә.

Акбирдин. Ярый, бар.

Бригадир. Ярар. *(Чыгып китә.)*

Акбирдин. Була, Гөләндәм, була!

Гөләндәм. Нәрсә була?

Акбирдин. Су була, Гөләндәм.

Гөләндәм. Әй, әле һаман шул икән...

Акбирдин. Кызылташ, Күлбаш сазлыклары шыңгырап торган чәчү җиренә әйләнәчәк.

Гөләндәм. Әйләнсә соң?

Акбирдин. Әллә син дә ышанмыйсыңмы?

Гөләндәм. Нәрсәсенә ышанасың аны, күрмәгәч?

Акбирдин. Су дүрт метр күтәреләчәк.

Гөләндәм. Күтәрелсә соң?

Акбирдин. Биш йөз киловатт дигән сүз бит ул.

Гөләндәм. Ә анысы нәрсә тагын?

Акбирдин. Их, Гөләндәм, беләсеңме, ул чагында менә бу тупаслык, ярлылык билгесе булып пыскып торган лампа урынында нәрсә булачак?.. Беләсеңме, ул лампалар нинди булачак?

Гөләндәм. Әйтәсең дә бит...

Акбирдин. Менә синең шушы саф күзләрең төсле якты һәм матур булырлар. Өйләрдә, урамнарда гына түгел, сыер абзарларында, күпер башларында электр лампалары йолт-йолт киләчәк. Әле моннан башка да хикмәтләр бар. Берьюлы барын да чыгарырга ярамый.

Гөләндәм. Монысыннан да башым тубал булды.

Акбирдин. Нәрсә, әллә булмас дисеңме?

Гөләндәм. Юк, алай димим... Бәлки, берәр чакта күрерләр, дим.

Акбирдин. Ә мин аларны хәзер үк күрәм. *(Гөләндәмнең башын тотып.)* Менә алар, менә алар!..

Гөләндәм. Әбәү!.. Муенымны авырттырасың!.. Минем башым электр машинасы түгел лә...

Акбирдин. Гөләндәм, әйт, акыллым, син ышанасыңмы?

Гөләндәм. Шаштыңмы?..

Акбирдин. Ха-ха-ха!.. Шулай ук шашканга охшыйммыни?

Гөләндәм. Юк та бит... Кандырга су тутыра башласаң, чамадан чыгып китәсең. Электр шаукымы бар димме үзеңдә...

Акбирдин. Шаукым түгел, план, план ул!.. Безне шулай тудый-судый кешеләр шашканнар дип йөргәннәр иде. Ә хәзер уһу-һу-һу!.. Җитеп узарга дип, мәйдан тоткан биш яшьлек аргамакның тезгене менә ул кайда!.. *(Йодрыклап, бер кулын күтәрә.)* «Кызыл йолдыз» колхозын машиналаштырып, синең күзләреңә төсле якты ут тудыру өчен су кирәк.

Үтәш бабай, Фәридә керәләр.

Су юл сорый, су булыр!..

IV. Әүвәлгеләр һәм Үтәш бабай, Фәридә.

Үтәш бабай. Булмас!.. Персидәтел, тыңла сүземне, су булмас!.. Җир нигезеннән корый. Кандыр суы болай идемени!.. Юк белән халыкның башын катырма... Син күккә менеп Кандырга су төшерә алмассың!

Акбирдин. Күккә менәсе юк, без аны җирдә таптык, карт.

Үтәш бабай. Тапканың юк. Халыкның башын гына катырасың. Иртәгә мине яшәртеп, шушы ак сакалымны каралта алырсыңмы? Юк бит, юк!

Акбирдин. Сакалыңны, бабай, бүген үк каралтырга була. Анысы пустяк аның. Бик теләсәң, үзеңне яшәртергә дә юлын табарбыз. Ләкин безнең әле картларны яшәртү кебек эшләр артыннан йөрергә вакытыбыз юк. Без башта карт табигатьне яшәртергә керештек. Табигатьнең организмына ремонт ясап торган көн хәзер.

Үтәш бабай. Саташма, саташма, егет, Кандыр суы артмас!

Гөләндәм *(көч белән).* Артыр, бабай!.. *(Чыгып китә.)*

Акбирдин. Карт, күккә бер мин генә үрмәләмим күренә, хи-хи-хи!..

Ф ә р и д ә. Җитәр, бабакаем, җитәр. Картлар аңлый ала торган эшләр түгел. Син бит башта инкубатор турысында да булмый-булмый дип торган идең. Үз күзең белән чебиләрне күргәч кенә тындың.

Ү т ә ш б а б а й. Анысы аның башка, бу башка. Анысы аның машина…

Ф ә р и д ә. Ярый-ярый, әйдә теге якка!

Ү т ә ш б а б а й. Мин җыелышка килдем. Мин дөньяның ачысын-төчесен болардан күбрәк күрдем. Кандыр суы артмас!

Ф ә р и д ә. Акбирдин иптәш, минем сиңа сүзем бар иде.

А к б и р д и н. Йомыш димәкчесеңдер?..

Ф ә р и д ә. Йомыш түгел, сүзем бар.

А к б и р д и н. Әйдә, сөйлә.

Ф ә р и д ә. Бабакаем, зинһар, теге якка чыгып тор.

Ү т ә ш б а б а й. Чыгып тор?.. Нинди сер ул тагы, оланнар?

Ф ә р и д ә. Аның сиңа кирәге юк, бар, бар, теге якка чыгып тор!

Ү т ә ш б а б а й. Тискәре китсә китә икән… Сер диген?.. Сер… зур эш. Без яшь чакта болай түгел иде. Уһу-һу-һу-һу!..

Акбирдин телефонда сөйләшкәндә, Үтәш бабай белән Фәридә сүзсез ымлыйлар.

А к б и р д и н. «Үрнәк» совхозын бирегез… Кем бу?.. Мәһди… Ә?.. Ал да гөл. Закир иптәш андамы?.. Ә?.. Кара әле, без аның белән Кызыл йолдыздан сезгә биш көнгә илле кеше ярдәмгә җибәрү турында сөйләшкән идек. Ә?.. Әйе, соңгы декада эчендә. Юкса үзебездә бик зур эш башларга торабыз. Ул чагында кеше арттырып булмас. Шул-шул…

Ү т ә ш б а б а й чыга.

Кара әле, иртәгә старший агрономыгызны безгә җибәрегез әле… Киндер чирләп тора. Ярый, рәхмәт. Бозаулармы?.. Һу, бозаулар шәп… Бар да ак башлы. Бер калыптан чыккан уенчыклар төсле, тупырдап торалар. Ә кодалар, дисеңме, ха-ха-ха. Ярый, ярый, хуш! Йә Фәридә, ни йомыш?

Ф ә р и д ә. Йомыш түгел, дим ич.

А к б и р д и н. Әйе, әйе, дөрес, йомыш түгел, сер бугай, шулаймы?

Ф ә р и д ә. Шулай.

А к б и р д и н. Нәрсә бар? Әллә чебиләргә берәр хәл булдымы?

Ф ә р и д ә. Түгел... Уф!.. Әйтә алмыйм.

А к б и р д и н. Әйдә, сөйлә, сөйлә, курыкма...

Ф ә р и д ә. Курыкмыйм, оялам.

А к б и р д и н. Курыкма дигәнем... Әйе, әйе, оялма, сөйлә, йә?

Ф ә р и д ә. Үзең төшен инде...

А к б и р д и н. Нәрсәсенә төшеним? Мин сине әле бик аз беләм. Кызык кыз син, Фәридә, килгән көннән бирле диярлек шул хәл. Нәрсә әйтмәкчесеңдер — аңлый алмыйм...

Ф ә р и д ә. Гөләндәмгә әйтәсең ич...

А к б и р д и н. У-у, Гөләндәм үз сүзен дә чат иттереп әйтә, кешенең сүзен дә теленнән тартып ала... Гөләндәм ул... *(Сызгыра.)*

Фәридә читтә елый башлый.

V. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Һ и л а л.

Һ и л а л. Таңнан җыелыш ясамасагыз булмадымыни! Әллә нигә бер ял көне, анда да... *(Фәридәне күреп.)* Бу нәрсә?.. Бу кем?..

А к б и р д и н. Кем соң?

Һ и л а л. Фәридә?.. Монда?.. *(Кайтып.)* Нишли ул?

А к б и р д и н. Нишли соң?

Һ и л а л *(кычкырып).* Нигә елый ул?!

А к б и р д и н. Акрынрак, Һилал иптәш, минем колагым телефон трубкасы түгел.

Һ и л а л. Фәридә!.. Ни булды?.. Әллә ул?..

Ф ә р и д ә *(терсәге белән этеп).* Әй, аптыратмасана!..

VI. Ә ү в ә л г е л ә р һәм п о л е в о д, б р и г а д и р, О с т р о у м о в, т е х н и к, тагы бер н и ч ә к е ш е.

П о л е в о д *(сөйләшеп керә).* Башкалар шәп, тик киндергә әллә ни булган, бик йомшак үсә, әллә орлыгында берәр хәл булган инде...

А к б и р д и н. Иртәгә Үрнәк агрономы килә. *(Остроумовка.)* Иптәш Остроумов, актив җыелып җитте диярлек, бюро членнары бар. Монда утырабызмы, тегендә керәбезме?

О с т р о у м о в. Кая да ярый.

П о л е в о д *(Фәридәне күреп).* Тегендә керик, булмаса.

А к б и р д и н. Әйдәгез... *(Папкасын ала.)*

Ячейка бүлмәсенә кереп китәләр.

Һ и л а л. Фәридә, Фәридә, дим!

Б р и г а д и р. Председатель иптәш, әйдә!

Һ и л а л. Хәзер, хәзер, әкиятләрегез белән теңкәгә тидегез... Эшләү түгел, үз турыңда уйларга да ирек бирмиләр, тфү!..

Б р и г а д и р. Чәчрәмәсен!..

Һ и л а л. Чәчрәсә, син сөртмәссең!

Кереп китәләр.
Музыка.

Ф ә р и д ә.

Тибрәнмәсә, йөрәк, тоткын коштай,
Үз күңелеңә, үз күңелеңә, абау, йолдыз ошагач.
Алма бирми тал агач,
Алмагач була алмагач.
Кояш нуры нигә кирәк,
Күрер күзең булмагач?..
Тибрәнмәсә, йөрәк, син ялкындай,
Үзеңә тиң, үзеңә тиң йолдыз сайлый алмагач,
Алма бирми тал агач,
Алмагач була алмагач.
Күз яшьләре кемгә кирәк,
Каршы көрәшә алмагач...

VII. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Ү т ә ш б а б а й.

Ү т ә ш б а б а й. Булмый, булмый... Постановление ясап кына, Кандырның суы артмас. Син тагы елыйсың, бала!..

Ф ә р и д ә. Кем әйтә аны?

Ү т ә ш б а б а й. Әйт, бала, яшермә, кайсы рәнҗетә?

Ф ә р и д ә. Рәнҗеткән кеше юк.

Ү т ә ш б а б а й. Кыерсыталармы әллә?

Ф ә р и д ә. Юк.

Ү т ә ш б а б а й. Юк?.. Елыйлар, җырлыйлар, көләләр, шаулыйлар, Кандырга су даулыйлар... Аңлый алмыйм, аңлый алмыйм... Без яшь чакта болай түгел иде.

Ф ә р и д ә. Әйдә, бабакаем, кайтыйк.

Ү т ә ш б а б а й. Җыелышка килдем мин. Илдә булмаган эшләр уйлап чыгарып, халыкның миен черетәләр. Мин аларга әйтермен, ярамый, ярамый, диярмен. Җирсез-сусыз, өлешсез чыра яндырып та тордык. Бүгенгесенә шөкер итәргә кирәк, диярмен. Пәйгамбәрләр дә судан ут чыгара алмаганнар. Ә бу дивана, яшьлегенә булышып, Кандыр суыннан крәчинсез лампа ясыйм, дип саташа. Су яна торган булса, утны сүндерә алмас иде.

VIII. Ф ә р и д ә, Ү т ә ш б а б а й, М и н һ а ж.

М и н һ а җ *(тәрәзәдән).* Дөрес, Үтәш бабай, дөрес. Әссәламегаләйкем!

Ү т ә ш  б а б а й. Әйе, утны сүндерә алмас иде.

Ф ә р и д ә. Әйдә, кайтыйк, бабакаем.

Ү т ә ш  б а б а й. Бар кайт. Кандыр суын яндырырга постановление ясарга юл куймам. Мин колхоз, мин член, минем сүзем тавыш булыр...

М и н һ а җ. Булырмы икән?!

Ү т ә ш  б а б а й. Булыр!..

М и н һ а җ. Булыр, дисең икән, хи-хи-хи!.. Кая соң болар? Утырыш бара, дигәннәр иде.

Ф ә р и д ә *(ячейка ишеген күрсәтеп).* Әнә анда.

М и н һ а җ. Һаман үзара, диген, ә?.. Киңәштә алар утыра, эшкә килгәндә...

Ф ә р и д ә кулын селтәп, чыгып китә.

Ү т ә ш  б а б а й. Нәрсә лыгырдыйсың син тагы, ачуым килмәгәе!

М и н һ а җ. Шуны әйтәм әле, Үтәш бабай: казан астын ягучыга өйрә юк, дим...

Ү т ә ш  б а б а й. Буразнадан читкә өстерәмә, Минһаҗетдин. Тел төбең кая йөгергәнен үтәләй күрәм мин. Менеп барган таудан ирегә өстерәмә син безне, яме?.. Йә булса, менә шул. Эш турында сөйлә, Кандыр турында сөйлә. Казан асты, имеш... Өйрәсез калганың бармыни?!

М и н һ а җ. Мин үз турымда әйтмим. Илгә ни булса, миңа да шул дигәндәй, ел әйләнәсендә ничә нәчәл алмашынды, һәрбер яңа нәчәл үз белдегенчә яңа закон кора... Закон корыр өчен, колхоз булдыкмыни!..

Ү т ә ш  б а б а й. Буразнадан читкә өстерәмә, дим, ачуым килмәгәе, зиһенемне таратасың!

IX. Ә ү в ә л г е л ә р һәм А к б и р д и н, Һ и л а л, п о л е в о д, б р и г а д и р, О с т р о у м о в, т е х н и к һәм б а ш к а л а р.

П о л е в о д. Туктагыз, тавышланмагыз! Болай булса, мин утырышны ябам.

О с т р о у м о в. Утырышны ябарлык хәл мин күрмим. Әхмәдуллин иптәшне генә ныграк тәртипкә чакырырга кирәк. Мин утырышның дәвам итүен сорыйм.

Һ и л а л. Булмый, булмый! Юк белән баш катырмагыз!

А к б и р д и н. Су юл сорый, су булыр!

Һ и л а л. Әкият ул!

Ү т ә ш  б а б а й. Булмас, балалар, су булмас!

П о л е в о д. Үтәш бабай, сиңа сүз бирелгәне юк, тыңлап кына утыр.

А к б и р д и н *(каты кычкырып)*. Су булыр!

Һ и л а л. Син Кандыр ярларын халыкның маңгай тирләре белән сугармакчы буласың! Андый планнарың белән йөрмә безнең тирәдә.

П о л е в о д. Туктагыз!.. Болай рәтсезгә талаша торган булсагыз, утырышны ябам. Бүлмәдән бүлмәгә күчеп, әтәчләр сугыштырырга җыелмадык ла без монда. Дәвам ит, Акбирдин иптәш!

А к б и р д и н. Уф!.. Шулай итеп, иптәшләр, Кандыр суын дүрт метрга күтәреп була. Бу — биш йөз киловатт дигән сүз. Үзегезчә генә әйткәндә, дүрт ташлы тегермән, сигез валлы яргыч, өч барабанлы суккыч, өргечләр һәм башкалар аның көче белән зырылдап көне-төне эшләп торганда, кем куанмас?! Шул фикерне массага төшендерү эшендә син безгә ярдәм итү урынына, кулак койрыклары, бузотёрлар, лодырьлар сүзләренә ияләсең.

Һ и л а л. Сүз гөбәдиясе белән сыйлама син безне, монда дураклар утырмый... Бер нәрсә булса, масса диләр, алар гына масса өчен тырыша, имеш. Минем кайгым шул масса файдасы өчен түгелмени?

П о л е в о д. Сүз бирелгәне юк сиңа, бирелгәч сөйләрсең.

Һ и л а л. Кандырга күктән диңгез төшерергә җыенмыйм ла сүз сорарга, нигә кирәк безгә...

П о л е в о д. Тукта, дим, ат базары ясама син безнең утырышны. Тыңлыйсың килмәсә чыгып кит!..

Һ и л а л. Секретарь булдым дигәч тә, кума син мине. Остроумов иптәш, алар һәрвакыт шулай.

П о л е в о д. Туктыйсыңмы, юкмы?! Сөйлә, Акбирдин иптәш!

А к б и р д и н. Кандырга без суны күктән көтмибез, җирдән эзлибез...

Һ и л а л. Таптык та диген?

А к б и р д и н. Таптык! Техник иптәш, аңлатыгыз.

Т е х н и к. Иптәшләр, менә күз алдыгызда Акчишмә суы. Бу су ярларының түбәнлеге аркасында әледән-әлегә суын сыйдыра алмыйча ташып, ничә мең еллардан бирле тирә-юнен сазландырып, бизгәк оясы булып ята. Акчишмә суы белән Кандыр арасы күп булса биш-алты километр булыр. Менә шул Акчишмә суы белән Кандыр суын тоташтырганда, Кандыр суы ел әйләнәсендә дүрт метрга күтәреләчәк, тирәнәячәк. Шуны үзәкләштерү өчен, Кандырның ярлары бик уңайлы. Менә шул хәл Кандырда

кечкенә генә алты-җиде йөз ат көчле гидроэлектростанция ачарга мөмкинлек бирә.

Акбирдин. Шуның аркасында Кызылташ, Куянлык, Күлбаш сазлыклары корып, мең гектардан артык урын печәнле болынга, чәчү җиренә әйләнәчәк, һәм биш йөз киловатт көч бирәчәк. Безгә боларның икесе дә һава төсле үк кирәк. Моны аңламау, моңа ышанмау социализм төзелешендә күмәк хуҗалыкның әһәмиятенә бәя куя алмаган буш куык, тол пистон, эшләпә оппортунистлык булачак...

Һилал. Оппортунистлык түгел, теләсә, чорт булсын, төштә күргән кысыр планнарыгыз белән халыкны интектерергә ирек бирмәм! Электростанция, имеш! Нәрсәгә кирәк ул безгә. Томанный күрсәтергәме әллә? Уһу!.. Аны электростанциясез дә бик шәп күрсәтәләр бездә.

Остроумов. Әхмәдуллин иптәш, райком бу эшкә кысыр план дип карамый, бу — бер; икенчедән, райком электростанциянең күмәк хуҗалыкта тоткан урынын томанный күрсәтү өчен генә дип тә карамый. Алда торган зур эшләрнең зур планын корган чакта, аларның зурлыкларын аңлый белергә генә кирәк. Без иртәгәге җиңү чараларын бүген күрә белергә тиешбез. Синең үз карашларыңда кысырлык шактый үткен сизелә. Ул турыда аерым аңлашырга туры киләчәк. Иптәшләр, мәсьәлә ачык, бу турыда ячейканың установкасы дөрес. План, проектларыгызны тулы килеш райкомга җибәрегез. Бу мәсьәләне тормышка ашыру турында райком һәм РИК, әлбәттә, чаралар күрәчәк. Бу эш белән массаны тагын да ныграк таныштырырга кирәк. Актив бу эшкә бөтен көчен куйсын. Бу мәсьәлә турында хәзергә шуның белән чикләнсәк тә ярар, секретарь иптәш!

Полевод. Әйе.

Икәү сөйләшеп калалар.

Иптәшләр, ун минуттан ячейканың утырышы дәвам итәчәк.

Остроумов белән полевод бүлмәгә кереп китәләр. Музыка. Урамда беренче пәрдәдәге икенче номер җыр тавышы ишетелә.

Акбирдин. Без авыл хуҗалыгын социализмга алып барганда, синең шикелле әдрәс йөрәкләргә түгел *(урамга күрсәтеп)*, әнә кемнәргә ышанып алып барабыз!

Һилал. Халык сезгә аңгыра бозау түгел.

Акбирдин. Дөрес. Ул ишәк артыннан бармас...

Һилал. Теркә, бригадир, теркә... Миңа, сайланган

Совет председателенә, кандидат партиягә *(Үтәшне күрсәтеп)* беспартийный алдында, менә бу килмешәк ишәк диде, теркә!..

Акбирдин. Ишәк дигәнен теркә, килмешәк дигәнне язма. Мин аны үз хисабыма алмыйм.

Һилал. Юк, алырсың!

Акбирдин. Ахмаклыкның да бер чиге булырга тиеш, Һилал иптәш!..

Һилал. Теркә, теркә!

Бригадир. Нәрсә тагын?!

Һилал. Ахмак дигәнне дә теркә!

Бригадир. Кемгә?

Һилал. Миңа!.. Ә син, Үтәш бабай, шаһит булырсың, судка бирәм!

Үтәш бабай *(каушап).* Карагыз әле, оланнар, үзебезнең совет сутында түгел, патша сутында да булганым юк. Колакка саграк бит мин. Колакка саграк. Әү! Мине бутый күрмәгез, дим.

Һилал. Ишетмәдем, димәкче буласыңмыни?

Үтәш бабай. Шул чамадарак. Әү!.. *(Чыга башлый.)*

Һилал. Карт дурак!

Үтәш бабай *(кайтып).* Юк, түгел... Ишәк бугай!.. Мине бутый күрмәгез!.. *(Чыга башлый.)*

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук Советлар йорты.

I. Бригадир, Һилал, Тарасов, Гали, Минһаҗ, Сафа.

Бригадир. Син, Һилал иптәш, сул ягың белән тордыңмы әллә бүген, аңламыйм мин сине?

Һилал. Сез, егетләр, Минһаҗ агай әйтмешли, кипкән кисмәккә кыршау киертмәгез әле, яме? Син, энем, бригадир булгач, үз эшеңә үзең хуҗа бул, яме? Телдә генә түгел, эштә дә, дим. Минем аннан башка да эшләрем муеннан. Правлениегез ни эшли соң? Карасын. Колач җәя белгәч, башкарырга да кирәк аны.

Бригадир. Син Совет белән колхоз правлениесе арасына үзән сузып маташма, борный торган эшләр түгел алар хәзер.

Һ и л а л. Һә?.. Йомыш төшкәч үзәнмени? Ай-һай!.. Остарып киттегез, егетләр. Сөйли белгәч, эшли дә белергә кирәк аны. Әнә сүз күлмәк киертми, ди Минһаҗ агай. Үз җаегызны үзегез карагыз! *(Үз бүлмәсенә керә.)*

Б р и г а д и р. Минһаҗ агай сүзен сөйләргә калдыңмыни!

М и н һ а җ. Елан агуы — тешендә, адәмнеке — телендә...

Б р и г а д и р. Шул-шул. Агуың телеңдә шул.

М и н һ а җ. Бригадир энем, минем белән булышма! Җитәрлек очкылык тоттырдың инде.

С а ф а. Пүрәткә юк бездә, пүрәткә юк. Малай-шалай нәчәл булгач, әй...

Б р и г а д и р. Нәрсә булган?

С а ф а. Колхоз җыелышы булсын, күрерсез!

Т а р а с о в. Не понимаю, сездә, по-моему, полный обезличка, сездә берсе эшләгән эшне икенчесе белми. И белергә дә не желает.

Б р и г а д и р. Юк, алай түгел, иптәш Тарасов, колхоз председателе өйдә юкка күрә генә шулай булып чыкты.

Т а р а с о в. Мин причём монда?.. Бөтен көнем бушка үтте.

Б р и г а д и р. Ярый, син хәзер ургычларны төзәтә башла, бушка узган вакытың турында справка бирербез.

Т а р а с о в. Мин справкалар җыйнарга килмәдем. Эшләргә килдем. Булмый икән, мине тотмагыз!

Б р и г а д и р. Хәзер, хәзер, Сафа агай, менә Тарасов иптәш ургычларны төзәтә башлый, син шунда аңа булышырсың.

С а ф а. Шулаймыни!.. Һә, кара син аны... Труддин язганда, Сафа ялкау, Сафа лодырь, эшләми, уңмаган, чорт-горт, чураман, әрле-бирле!.. Йомышка йөртергә Сафа кирәк.

Б р и г а д и р. Барасыңмы, юкмы?

С а ф а. Кычкырма, тавыкларны куркытырсың.

Б р и г а д и р. Барасыңмы, дим?

С а ф а. Итек алып биргәнең юк бит әле, бушка йөрергә...

Б р и г а д и р. Лодырь, тфү!.. Әйдә, Тарасов иптәш.

Чыгып китәләр.

М и н һ а җ. Әтә-тә-тә, Микалай патша үрәтнигемени, нинди җикеренә!.. Тс, тс, тс, тс!.. Атасы булырлык кешегә нинди бәрелә. Юаш дигәч тә, ярыймыни алай... Тс,

тс, тс!.. Бригадир булган булып, нәчәл булып алганнар да, колхозның итен үзләре ашап, сиңа сөяк тә ярый. Синдә шундый ук член түгелмени? Алар түрә булып түрдә утырсын, имеш, ә син йомышка йөр. Хәер-фатихага эшли диярсең. Бар, имеш, теге, имеш, бу, имеш.

Сафа. Әлеге дә баягы, пүрәткә юк бездә.

Минһаҗ. Комсомол, бригадир, ударник, саривнавал булдым дигәч тә, кеше рәнҗетергә димени. Тс, тс, тс!..

Сафа. Менә колхоз җыелышы булсын әле...

Минһаҗ. Юк ла, юк. Синнән буламыни, чүпрә син.

Сафа. Алай димә, Минһаҗ агай, тәртәгә бер тибеп алсаммы!..

Минһаҗ. Буш куык син.

Сафа. Алай димә, Минһаҗ агай. Бер дулап китсәм, ай-яй, мин!

Минһаҗ. Булмый, булмый синнән. Эч пошырма юкка. Хатын дисәң, сакалың бар, әй-й... Булмый ла синнән!..

Сафа *(кызып).* Булмыймы?

Минһаҗ. Булмый!

Сафа. Булмыймы?!

Минһаҗ. Булмый.

Сафа *(түбәтәен идәнгә бәреп).* Булмыймы?!

Минһаҗ. Булмый!

Сафа *(гади, тавыш белән).* Кая, берне урат әле.

Телефон шалтырый.

Минһаҗ. Менә анысы була. *(Тәмәке бирә.)*

Гали *(үз өстәлендә счёт салып торган җиреннән торып).* Әйе. Хәзерләнеп ятабыз... Иртәгә булыр... Ударный дип ударсыз да төтен бара монда... Ә?.. Төтен бара, дим. Иртәгә була, өлгертәм. Ике сөйләү юк бездә хәзер... Ярый...

II. Әүвәлгеләр һәм почтальон.

Почтальон. Почта! *(Галигә тапшыра. Чыгып китә.)*

Минһаҗ бер газета алып укый башлый.

III. Әүвәлгеләр һәм Сепарат Мәрьям.

Мәрьям. Кая болар?

Гали. Ни йомыш? 46. *(Счёт сала.)*

Мәрьям. Председатель кирәк иде.

Гали. Калада. 349.

Мәрьям. Полевод кая?
Гали. Кырда. 981.
Мәрьям. Хөсәен агай да юкмыни?
Гали. 16.
Мәрьям. Өч көннән бирле сөт кими.
Гали. 280.
Мәрьям. Түгел.
Гали. 315.
Мәрьям. Түгел, дим.
Гали. 649.
Мәрьям. Ким.
Гали. Чү әле, чү, ничә дидем?
Мәрьям. Синең исәбеңдәмени, кимегәч.
Гали. Чү әле, чү! Нәрсә кирәк?
Мәрьям. План тулмый.
Гали. Соң?
Мәрьям. Бүген иртәнге сөт барлыгы 480 литр булды.
Минһаҗ. Сепаратыңның төбе тишелмәгәнме икән?
Мәрьям. Әйтте сүз, күзем чыкмаган ла минем.
Минһаҗ. Алай булгач, кая китә соң ул?
Мәрьям. Китәр өчен киләсе бар элек.
Минһаҗ. Ә, сөтнең килере кимедемени?
Мәрьям. Соң, Мәхбүбә түти дә дүрт литр урынына барлыгы ике генә литр китерде.
Минһаҗ. Кырда азык юк бит. Иртә пар дигән булып, хайваннарның ризыкларын авызларыннан тартып алгач...
Мәрьям. Аннан түгел. Каенсарда үлән начармыни!
Минһаҗ. Үлән белән үлән арасында аерма бик зур, сеңлем.
Гали. 770.
Мәрьям. Сезнең сыер гына талымлыдыр инде.
Минһаҗ. Сөт өчен билчән кирәк. Болында билчән үсми.

IV. Әүвәлгеләр һәм Бузотёр Бәдига, Тимеркәй.

Бәдига *(һаман сагыз чәйнәп).* Элек аерым хуҗалык дип теңкәмә тидең, колхоз булгач та көн күрсәтмисең, җирбит!..
Тимеркәй. Мин кыр сакчысымы? Кыр сакчысы. Миңа барыгыз да бертигез.
Бәдига. Миңа каныккансың син, миңа көн күрсәтмисең!
Тимеркәй. Чәпчемә, Бәдига, яме? Чәпчисе урын юк

монда. Колхоз игеннәре өчен мин җавап бирәмме? Мин. Яме?..

Бәдига. Йә.

Тимеркәй. Йә булса, шул. Сыерың өчен син җавап бир, яме?..

Бәдига. Мәхлук хайванның ни гөнаһысы бар?

Тимеркәй. Мәхлук хайванның гөнаһысы юк, ә синең гаеп бар.

Бәдига. Хайваннар каргышы төшеп, бер аягың корыды инде...

Гали *(борылып).* Бәдига җиңги, шаулама, уңайсызлыйсың!

Бәдига. Нигә сыерымны ябып куйган, япмасын!

Тимеркәй. Ябармын!

Бәдига. Ябарга контрмыни ул!..

Тимеркәй. Белмәссең!..

Бәдига. Колхоз сыерын ябарга төсең түгел.

Тимеркәй. Кайчаннан бирле сыерың колхоз соң?

Бәдига. Үзем колхоз.

Тимеркәй. Колхоз игеннәрен таптасаң, сыерыңны түгел, үзеңне дә ябармын.

Бәдига. Аксак Тимеркәйдән аранга ябылыр өчен колхоз булдыкмыни?..

Гали *(кычкырып).* 78.

Бәдига. Ә?

Гали. Эшләргә бирмисез!

Бәдига. Әйт, сыерымны җибәрсен.

Тимеркәй. Әйтмәс.

Бәдига. Әйтер.

Мәрьям. Бәдига түти, бу тикле кычкырмасана, колак тондырып.

Бәдига. Кычкырырмын!

Мәрьям. Әбәү, тавышың.

Бәдига. Тавыш яратмасаң, барып, сепаратыңны әйләндер, кыршылып йөрмә монда!

Мәрьям. Бузотёр дигәч тә...

Бәдига. Кем матур дип синнән сораган кеше юк!

Мәрьям. Кычкырмасана!

Бәдига. Кычкырырмын.

Мәрьям. Кычкыра-кычкыра сөт китерергә дә оныткансың.

Бәдига. Анысын инде Сепарат Мәрьямнән сорамам.

Мәрьям. Сорарсың.

Гали. 90.

Б ә д и г а. Сорарсың?!

Г а л и. Чыгыгыз моннан!

Б ә д и г а *(өстәлгә сугып).* Сыерымны җибәрмиче чыкмыйм! *(Утыра.)*

Г а л и. Нигә миңа кычкырасың? Сыерың бит минем кенәгәләр арасына кысылмаган.

Б ә д и г а. Кысылмаган булса…

Г а л и. Кысылмаган, менә!.. *(Кенәгәне ачып шап итеп яба.)*

Б ә д и г а *(сискәнеп, сикереп торып, читкә китә).* Әч-әч! Нигә миңа, нигә аңа түгел?..

М и н һ а җ. Кара әле, кем, Тимеркәй, хаталык белән бер булган икән, маташма. Ни әйтсәң дә, Бәдига җиңги колхоз члены бит.

Т и м е р к ә й. Колхоз члены дип колхоз игеннәрен эштән чыгарырга дигәнмени! Өндәмә, Минһаҗетдин, өндәмә, яме?.. Синең үзеңнең дә ул турыда тәртәң сынган.

М и н һ а җ. Нишләгән?

Т и м е р к ә й. Эшләгән.

М и н һ а җ. Төш күрәсеңме, юри маташасыңмы, әллә саташасыңмы?

Т и м е р к ә й. Шул-шул, яме… *(Китә башлый.)*

Б ә д и г а. Кая качасың, чыгар сыерымны!

Т и м е р к ә й. Булмый.

Б ә д и г а. Булмаса, әйдә перседәтельгә.

Т и м е р к ә й. Председәтельдә эшем юк, минем сыерым көтүдә, яме?

Б ә д и г а. Йә.

Т и м е р к ә й. Йә булса, шул. *(Китә.)*

Б ә д и г а *(чыга-чыга).* Ай, аксак дөлдел, токымың коргыры!.. Әйдә перседәтельгә!.. *(Тимеркәйне өстери, кулы ычкынып, Сафа өстенә утыра, шаулап чыгып китә.)*

V. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Ф ә р и д ә.

Ф ә р и д ә *(Бәдигага бәрелеп).* Әбәү!.. Пычак кергере, башымны яра язды… Зиннәт кая?

Г а л и. Урманда, эштә.

Ф ә р и д ә. Шакир абый?

Г а л и. Ул да шунда.

Ф ә р и д ә. Төнсез кайтмаслар инде, алай булгач.

М и н һ а җ. Фәридә, машинада ясалган чебиләрең нишли, тавык булдылармы әле? Хи-хи-хи!..

Ф ә р и д ә. Ни дигән сүзең?!

М и н һ а җ. Үсәләрме дигәнем.

Ф ә р и д ә. Тәгәриләр генә.

М и н һ а җ. Тәгәриләр, диген. Кизүдәнме, үләттәнме, әллә ачлыктанмы?!

Ф ә р и д ә. Нәрсә?

М и н һ а җ. Үлүләре, дим.

Ф ә р и д ә. Кем әйтә аны?!

М и н һ а җ. Тәгәриләр, диден ич.

Ф ә р и д ә. Үсәләр дигәнем. Бүген инкубатордан яңадан алты йөз баш кайтты. Шундый терчәләр, чәчрәп торалар. *(Галигә.)* Урын тарайды. Урын кирәк. Шуңа дип килүем.

VI. Ә ү в ә л г е л ә р, п о л е в о д, З а к и р җ а н, Х ә й р ү ш һәм б а ш к а л а р.

П о л е в о д. Син, Закирҗан агай, үзең аңларга тиеш. Бригаданың бөтен инвентаре өчен син җаваплы, син! Сорау гына җитми, барын саклый белергә кирәк. Аннан соң колхоз идарәсе тарафыннан синең бригадаңа ат башына көнгә унике бүрәнә задание бирелгән иде. Ә сез анда сигез өстендә утырасыз. Бу нигә ярый инде!

З а к и р җ а н. Бүген унга тутырдык, туган.

П о л е в о д. Тулы хезмәт көне өчен унике кирәк бит.

З а к и р җ а н. Әҗәткә калмабыз, туган.

П о л е в о д. Әҗәт-мәҗәтең кемгә хаҗәт. Үзегез өчен. Артыңны-алдыңны ныклап абайла, Закирҗан агай. Син җаваплы.

З а к и р җ а н. Беләм, беләм!

П о л е в о д. Белсәң шул, мә!..

З а к и р җ а н кәгазьне алып чыгып китә.

Минһаҗ агай, сиңа ни кирәк?

М и н һ а җ. Әлеге дә баягы дигәндәй, шул инде. Тегермәннән алуыгызның сәбәбен беләсем килә.

П о л е в о д. Белерсең. Колхозның сыерлар абзары идәнен Гыйлаҗ малайлары группасы белән иртәгә эшли башлыйсыз. Бар, хәзер старшиегыз Сирайны монда алып кил.

М и н һ а җ. Мин үзем болай, сыер нәселеннән булмасам да, җир идәнле өйдә үстем. Менә күрәсез, аягым аяк, кулым кул. Колхоз сыерларына идән кирәк булган, ә? Хикмәт идәндәме икән?.. Минем үз сыерым тирес өстендә аунаса да, һәр Алла биргән көнен бер чиләк сөтен биргән көне... Сыерларга идән диген... Кушкач эшләми булмас...

Полевод. Бар, бар, такмазаларыңны тыңлаучыларга сөйләрсең, безгә аның хаҗәте юк. Бар, кушканны эшлә!

VII. Әүвәлгеләр һәм Бузотёр Нәгыйм.

Минһаҗ *(чыга-чыга).* Идән диген, сыерларга идән. Кушкач эшләми булмас... Сыерларга идән...

Нәгыйм *(Галигә).* Әй син, писер калдыгы, кара савыт баш, нигә минем хатынның труддинен теркәмисең, ә?

Гали. Табельдә булмаганны каян алып терким?

Нәгыйм. Нишләп булмасын, ди. Кеше хакын йомып, колхоз баетырга керештегезмени!.. Кая, хәзер күз алдымда теркә, башың исән чакта!..

Полевод. Нәгыйм абый, булмый торган эш өчен чүпрә куертып йөрмә бу тирәдә. Труддин алыр өчен, башта һәйбәтләп, җиң сызганып эшләргә кирәк.

Нәгыйм. Ә җиңгәсе эшләмәгәнмени?..

Полевод. Сталы быть шулай.

Нәгыйм. Ә менә мин әйтәм, эшләгән, дим.

Полевод. Мин әйтәм, эшләмәгән, дим. Эшкә чыккачтын ярты сәгатьтән качып киткәнлеге бригадирның дәфтәрендә ялтырап тора.

Нәгыйм. Авырган булса, ни әйтерсең?

Полевод. Доктордан язуы кая?

Нәгыйм. Дохторга барырлык хәле булмаса?

Полевод. Доктор үзенә барыр. Доктор үзебездә.

Нәгыйм. Дохтор калага киткән булса?

Полевод. Булсага эш калса, булмас, Нәгыйм абый.

Нәгыйм. Туган, кардәш була торып та теркәтмим дисеңмени?

Полевод. Юк.

Нәгыйм. Здель дигәнегез шул кеше хакын йомудамыни?!

Полевод. Эшләмәгәннең аш дауларга хакы юк.

Нәгыйм. Здель, здель дигән булып, каз күкәе күрсәтеп, нәрсә тоттырдыгыз!

Полевод. Эшләмәгәнгә чыпчык күкәе дә юк.

Нәгыйм. Булыр.

Полевод. Булса көтә тор.

Сафа. Пүрәткә юк бездә, пүрәткә юк.

Нәгыйм. Язасыңмы, юкмы?

Полевод. Юк.

Нәгыйм. Юк... Совет перседателе мондамы?

Сафа. Монда.

Н ә г ы й м. Иманнарын этләрдән ялатыйм әле! *(Председатель бүлмәсенә кереп китә.)*

Г а л и. 58. Уф...

Ф ә р и д ә. Полевод иптәш, инкубатордан яңадан алты йөз баш чебеш килде.

П о л е в о д. Беләм, нәрсә кирәк? Азыкмы? Нигә аны миннән сорыйсың, фуражирга бар!

Ф ә р и д ә. Түгел, азык бар.

П о л е в о д. Нәрсә тагы?

Ф ә р и д ә. Урын тар.

П о л е в о д. Бәй! Истән дә чыккан. Нигә көне-сәгате җиткәч кенә йөрисез, башта ни карадың? Балта осталары бригадасы эше ич.

Ф ә р и д ә. Бер атнадан бирле...

П о л е в о д. Ярый, булды. Сафа агай, кил әле монда. *(Фәридәгә.)* Үз эшегезнең хәстәрен үзегез күрегез. *(Сафага.)* Менә сиңа эш. Әмәк белән Шәмәкне хәзер үк тап та, чебешләр курасын бүгеннән зурайта башлагыз!

С а ф а. Алай-й!.. Балта осталары группасы кая соң?

П о л е в о д. Алар эштә. Клуб мәйданына таба киңәйтегез. Казыклар, куралар әзерләнгән, юкә бармы?

Ф ә р и д ә. Бар.

П о л е в о д. Булды гына, бүген үк, хәзер үк эшкә тотыныгыз!

С а ф а. Кирәкми.

П о л е в о д. Нәрсә?

С а ф а. Вакыт юк.

П о л е в о д. Син, Сафа агай, мич башы сөремен башыңнан чыгар.

С а ф а. Башкалар белән труддинемне тигезләсәгез абайлап карармын.

П о л е в о д. Анда да әле абайлыйсы гына икән... Абайлыйсы-нитәсе юк, эшләмәгәнгә бездә чыпчык күкәе дә юк, менә шул!

С а ф а. Илдә чыпчык ачка үлмәс, ди Минһаҗ агай.

П о л е в о д. Үзеңә карыйсың.

С а ф а. Өркетмә! Патша заманы түгел, Совет үзебезнеке.

П о л е в о д. Совет үзебезнеке булгач, нигә эшләмисең? Совет, ди-ди, эшләмичә генә, господа, алпавыт булып тормакчы булдыңмыни! Син Минһаҗ агайлар такмазаларын оныт.

С а ф а. Хатын белән уйлашып карармын.

П о л е в о д. Соң булыр.

С а ф а. Эш бүре түгел, урманга качмас әле.

П о л е в о д. Качса тотуы кыен булыр. Ярый, үз хәлеңне үзең беләсеңдер, көчләгән юк.

Ф ә р и д ә. Газиз агайларга әйтергә кирәк.

П о л е в о д. Алар орлык саклау келәтләрен төзәтәләр.

Ф ә р и д ә. Нурыйларга әйтсәм?

П о л е в о д. Алар амбулаториядә бүлмә бүләләр.

VIII. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Ә м ә к, Ш ә м ә к.

Ә м ә к. Ишеттегезме?

Ш ә м ә к. Яңа хәбәр.

С а ф а. Нәрсә бар?

Ә м ә к. Ни, ни...

Ш ә м ә к. Чү әле, Әмәк.

Ә м ә к. Болгатма әле, Шәмәк.

Ш ә м ә к. Өчиле авылының...

Ә м ә к. Колхоз председателен...

Ш ә м ә к. Ахунҗанны...

Ә м ә к. Сабада...

Ш ә м ә к. Сабада түгел, Түрнәледә, Әмәк.

Ә м ә к. Чәчрәп үлим, Сабада, Шәмәк!

Ш ә м ә к. Җир йотсын, Түрнәледә, Әмәк!

Ә м ә к. Сабага үтешли Түрнәлегә тигән генә булган.

Ш ә м ә к. Әйтте сүз, Сабадан Түрнәлегә килгән булган!

Ә м ә к. Кунакка...

Ш ә м ә к. Җыенга!

П о л е в о д. Әй, болгатмагыз әле, егетләр, сезгә эш бар.

Ә м ә к.<br>Ш ә м ә к. } Хәзер хәзер, хәзер!..

Ә м ә к. Шул Ахунҗанны Сабада...

Ш ә м ә к. Түрнәледә...

П о л е в о д. Йә, ни булган?

Ә м ә к.<br>Ш ә м ә к. } Үтергәннәр.

Б а р ы с ы. Үтергәннәр?!

П о л е в о д. Кемнәр?

Ә м ә к. Кулаклар.

Ш ә м ә к. Чәнечкәннәр.

П о л е в о д. Тукта әле, егетләр, чынны сөйлисезме?

Ә м ә к. Әйтте сүз.

Ш ә м ә к. Алай.

П о л е в о д. Тукта, тукта, мин бит аны кичә генә Күпербашта күрдем, күпертәсез, егетләр.

Ә м ә к. Күпертергә син әллә безне...

Ш ә м ә к. Алай…
Ф ә р и д ә. Йә, йә?
Ә м ә к. Шул, Түрнәледән үтеп барганда…
Ш ә м ә к. Кулакларда җыйналган кунаклар…
Ә м ә к. Хәйләләп алып кергәннәр дә…
Ш ә м ә к. Шәһәрдән җыенга дип кайткан бер спекулянттан…
Ә м ә к. Спекулянт түгел, хулиганнан…
Ш ә м ә к. Спекулянт, хулиган алар икесе бертуган.
Ф ә р и д ә. Йә, йә?
Ә м ә к. Шул, үтергәннәр.
Ш ә м ә к. Ни өчен?
Ә м ә к. Ни өчен дип сорап тора.
Ш ә м ә к. Алай… Янәсе, хатынын көнләгән, имеш. Шулай бит, Әмәк?
Ә м ә к. Ышанма, Шәмәк, кулак калдыклары сүзе генә ул.
П о л е в о д. Дөрес булса кызганыч, һәйбәт егет иде.
Ш ә м ә к. Кулак сайлый белә ул.
Ә м ә к. Алай, Сафа агай белән безнең ишеләр аңа ни эшкә…
С а ф а. Уза тор, уза тор… Эч пошырма йөрәк янганда…
П о л е в о д. Әмәк, Шәмәк, менә сезгә наряд. Хәзер Сафа агай белән бергә чебешләр курасын куралый башлагыз. Урынын Фәридә күрсәтер.
Ә м ә к. Була ул.
Ш ә м ә к. Ялтыратып эшләп ташлыйбыз аны.
Ф ә р и д ә. Әйдәгез.
Ә м ә к *(кире кайтып).* Сафа агай, без киттек бит.
С а ф а. Китсәгез соң…
Ш ә м ә к. Ә син?
С а ф а. Бармыйм.
Ә м ә к. Бармыйм?!
Ш ә м ә к. Безнең Сафа агай кадер-хөрмәт ярата ул. Әйдә, тот!
С а ф а. Кагыласы булмагыз, кагылмагыз! *(Үз урынына яңадан кунаклый.)*
Ш ә м ә к. Фил көче бар үзендә болай!
Ә м ә к. Кара инде, тагы кунаклады бу!
Ш ә м ә к. Тавык кунакласа, чеби чыгара, ичмасам, синнән, Сафа агай, колхозга чеби түгел, чәберчекләнгән күкәй дә юк. Әйдә, тот, Әмәк!..

Култыклап алып чыгалар, Сафа тыпырчына.

Сафа. Бәйләнмәгез, дим, җибәрегез, җибәр!..
Әмәк.
Шәмәк. } Әйдә, әйдә...

Алып чыгып китәләр.

Гали. Бу Ахунҗанны үтерүләре чынмы икән?

Полевод. Үзем дә шул турыда уйлыйм. Булса да булыр. Ул тирәдә, саранча күкәйләре төсле, кулак калдыклары белән нигез шактый каты агуланган. Өчиледәге үткән көз икмәк хәзерләү эшен генә ал, буксирга алмасак, адәм көлкесе булганнар иде бит.

Хәйрүш керә.

Хәйрүш!

Хәйрүш *(туктап).* Әү!

Полевод. Сәмәт атына атланып, менә шул хатны хәзер үк МТСка илтеп тапшыр!

Хәйрүш. Сәмәт аты бер атнадан бирле тоттырмый, болында гүләйт итеп йөри.

Полевод. Әле һаман тота алганыгыз юкмыни?

Хәйрүш. Якын да җибәрми. Үзе пух иткән, бик хитри нәрсә икән, каһәр.

Полевод. Хуҗасына охшаган дисәңче. Кулакның үзеннән соң калган аты да колхозга игелек күрсәтмәскә тырыша. Ярый, «Үрнәк» айгырын иярлә, мә! Гали иптәш, син хәзер, милициягә шалтыратып, Ахунҗан вакыйгасын телефон аркылы тикшер. Чын хәбәрме икән?!

Хәйрүш. Була. *(Хатны алып чыгып китә.)*

IX. Әүвәлгеләр һәм Гөләндәм.

Гөләндәм. Минем бригада заданиесен тутырды. Иртәгәгә эш кирәк.

Полевод. Иртәгә помидор бакчасына чыгасыз. *(Галигә.)* Беренче бригаданы иртәгә «Үрнәк» совхозына өмәгә җибәрергә кирәк. Тимерҗан бригадасын алма бакчасына.

Гали. Ярар.

X. Әүвәлгеләр һәм Акбирдин, техник, бригадир, халык. Шаулашып керәләр.

Акбирдин. Булды, егетләр, булды.

Полевод. Ә?

Акбирдин. Су булды! Бүген кич техниклар килеп җитә. Райком һәм РИК тарафыннан район төзү бүлекләренә бөтен ярдәмне күрсәтергә директива бирелде.

Полевод. Менә анысы яраган.

Акбирдин. Полевод иптәш, иртәгәгә нарядлар бирелеп беткәнме?

Полевод. Беткән диярлек.

Акбирдин. Шул хакта хәзер үк ячейканы җыюга ничек карыйсың?

Полевод. Җыярга кирәк.

Акбирдин. Кичкә бригадирларның производство киңәшмәсен җыярга кирәк булыр. Ә иртәгә колхозның общий собраниесен җыеп, мәсьәләне масса алдына куярга кирәк. Иртәгәдән Акчишмә суын Кандырга ярәшәбез. Бүгеннән бөтен хәзерлекләрне күрергә кирәк.

Полевод. Кирәк-ярак яклары чамалырак бит.

Акбирдин. Үзем белән йөз сиксән көрәк алып кайттым. Йөз көрәк Рамазан йөгендә кайта. Өч тракторны бу эшкә билгеләргә!

Полевод. Алай булса, эш башка.

Акбирдин. Беренче бригада.

Бригадир. Монда!

Акбирдин. Икенче бригада.

Гөләндәм. Монда!

Акбирдин. Иптәшләр, Кызыл йолдызны машиналаштыру, электрлаштыру өчен көрәшне башлыйбыз!

Барысы. Башлыйбыз!

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Акчишмә суы белән Кандыр арасында болак сузалар. Эш кайный. Трактор тавышлары.

I. Масса.

Музыка.

Хор.

Карт тарихның меңләгән
Бите төсле мүкләнгән,
Картайган, каралган,

Ташланган, ташланган
Карт чирәмнең карт күкрәген
Яра-яра юл сузабыз,
Юл сузабыз Кандырга,
Юл сузабыз Кандырга.
Ударниклар тайяр тора,
Мәйдан ачык батырга.
Эш өстендә ярсый йөрәк,
Кәйлә, китмән, тимер көрәк.
Әйдә, әйдә, шулай кирәк,
Әйдә, әйдә, шулай кирәк!
Су юл сорый, суга юл!
Сузабыз сөзәк болак.
Су юл сорый, суга юл!
Сузабыз сөзәк болак.
Ил эше, ил көче сансыз калмас,
Чын батыр мәйданда дансыз калмас.

II. Әүвәлгеләр һәм полевод.

Полевод. Шулай, шулай, карт чирәмнең сыртын каезлагыз, егетләр... Әй сез, өченче бригада, Минһаҗ агай, көн дә, көн дә буксирга тагылу ярамас бит, оятыгызга көч килмәсен, дим!

III. Әүвәлгеләр һәм техник.

Техник. Полевод иптәш, дүртенче бригада йомшак бара.

Полевод. Беләм, әллә күз тиде үзләренә. Кичә беренче бригаданы бәрә язды.

IV. Әүвәлгеләр һәм бригадир.

Бригадир. Беренче удар комсомоллар бригадасының заданиесе ялт! Кайсы бригаданы буксирлыйк?

Техник. Әйдә дүртенчегә.

V. Әүвәлгеләр һәм Гөләндәм.

Гөләндәм. Карагыз әле, ни... өченче бригада безгә кушылды.

Бригадир. Хәйлә, хәйлә, егетләр. Так, булмаса, үзләрен безнең койрыкка!

Гөләндәм. Койрыгың өзелмәсен. Һә, тагар иде бугай.

Полевод. Әйдә, егетләр, әйдә!

Китәләр.

VI. Әүвәлгеләр һәм Минһаҗ.

Минһаҗ *(кулында тимер көрәк).* Техник иптәш, тукта әле!

Техник. Ни бар?

Минһаҗ. Бер мәслихәт бар иде сиңа!

Техник. Йә?

Минһаҗ. Акчишмәдән Кандырга болак казыйбыз, шулай бит?

Техник. Шулай.

Минһаҗ. Менә бу болакның бер башы Акчишмә суына, икенче башы тамак булып Кандырга тоташачак, шулай бит?

Техник. Сезгә нәрсә кирәк соң?

Минһаҗ. Хәзер, хәзер. Акчишмә суы Кандырга караганда җиде метр өстә тора, дисезме?

Техник. Торса соң?

Минһаҗ. Шуны әйтәм, Акчишмә суын буып торган җир калдау дисезме шунда...

Техник. Нәрсә кирәк соң сезгә?

Минһаҗ. Шул калдау ычкынса...

Техник. Нәрсә?

Минһаҗ. Казылмыйча калган җирне әйтәм, бик хөрт бит, ычкынса, бөтен авылны харап итмәсме икән, дим. Кандырның буасы иске, яңа буа ясарга уйланмый да. Бөтен авыл агып китмәсме икән, дим. Сезгә акыл өйрәтүем түгел, сезнең планда бу эшнең ничек торуын белергә теләвем генә. Сез бит инде ул якларын үлчәгәнсез, уйлагансыз.

Техник. Әлбәттә.

Минһаҗ. Планыгыз нәрсә ди инде шул турыда?! Куркыныч юк, диме?

Техник. Көтелмәгәндә бик зур яңгыр, ташкын булса, куркыныч бөтенләй юк түгел.

Минһаҗ. Әһә!.. Куркыныч бар диген?

Техник. Ләкин андый зур ташкыннар бу тирәләрдә булмый бит. Ә инде язгы ташкынга хәтле, Кандырның яңа буасы өлгергән булыр.

VII. Әүвәлгеләр һәм Һилал.

Һилал. Техник иптәш, бишенче бригаданы кайсы участкага куясыз?

Техник. Хәзер. *(Китә.)*

Минһаҗ. Һилал иптәш, бер мәслихәт бар иде сиңа.

Һ и л а л. Ни бар?

М и н һ а җ. Бик зур куркыныч эш туарга тора әле монда.

Һ и л а л. Куркыныч эш?!

М и н һ а җ. Хәтәр!

Һ и л а л. Нәрсә булды тагы?

М и н һ а җ. Миннән, синнән чыккан сүз булмасын. Техник шулай ди...

Һ и л а л. Нәрсә баш катырасың инде! Анда бишенче бригада... *(Китә башлый.)*

М и н һ а җ. Тукта! Исән калсаң, җавабын сиңа бирергә туры киләчәк.

Һ и л а л. Йә?..

Ү т ә ш  б а б а й күренә, тыңлап тора.

М и н һ а җ. Акчишмә суы, Куянлыктагы үргәне, калдауны юса, бөтен авылны су агызып китәчәк, ди техник...

Һ и л а л. Әкият. *(Китә башлый.)*

М и н һ а җ. Тукта. План шулай күрсәтә, ди.

Һ и л а л. Күрсәтсә күрербез тагы, әкият. *(Китә.)*

VIII. М и н һ а җ һәм Ү т ә ш  б а б а й.

Ү т ә ш  б а б а й. Әкият түгел, оланнар. Әкият түгел. Койрыклы йолдыз туган елны, Акчишмә суының котырынып ярларыннан чыкканын хәтерлим. Алла сакласын. Ташкын була калса, бу болак бөтен авылга кабер булачак.

М и н һ а җ. Әллә нәрсә, аңлар хәл юк. Әллә юри эшлиләр инде?! Әйтә башласаң ярамый. Контр сөйлисең, диләр.

Ү т ә ш  б а б а й. Анысы дөрес, Минһаҗетдин, авырга алма, язмаганны сөйләргә яратасың. Җыен тузга язмаган синнән чыга. Ә менә моның турында сүзең дөрес. Ташкын булып, Куянлыктагы калдау ычкынса харап, оланнар!..

IX. Ә ү в ә л г е л ә р һәм С а ф а.

С а ф а. Кая, Минһаҗ агай, берәрне төрик әле!

М и н һ а җ (*тәмәкесен бирә-бирә*). Тәмәке кызганыч түгел. Эш вакытында килешмәс, дим. Кайсы бригадада әле син?

С а ф а. Әй, чәнчелсеннәр лә! Казый-казый билләр калмады.

М и н һ а җ. Син ишеттеңме әле, Акчишмә суы Кандырга караганда җиде метр өстә тора, ди.

С а ф а. Нигә йөз егерме җиде булмый...

М и н һ а җ. Алла сакласын, диген, андый-мондый хәл була калса, беренче булып синең өең агып китәчәк.

С а ф а. Акса агар тагы, колхоз урамда калдырмас.

М и н һ а җ. Үтәш бабай, Һилалга ныграк аңлатасы иде. Шундый чакларда да чарасын күрмәгәч, нинди председатель була инде ул... Әйдә, барыйк әле үзенә.

Ү т ә ш  б а б а й. Алла сакласын. Койрыклы йолдыз туган елны...

Чыгып китәләр.

С а ф а. Акса ни, аксын... Мендәрне күтәрәм дә колхозның тулай торагына барам да керәм. Тугыз кайгымның берсе кимер иде, ичмасам. *(Ятып тарта.)*

X. С а ф а, Ә м ә к, Ш ә м ә к.

Ш ә м ә к *(Сафаны күреп).* Әмәк!

Ә м ә к. Ни бар, Шәмәк?

Ш ә м ә к. Кара.

Ә м ә к. Кая?

Ш ә м ә к. Әнә!

Ә м ә к. Ә-ә-ә!

Ш ә м ә к *(Сафа янына барып).* Авырга алма, Сафа агай.

Ә м ә к. Үпкәләмә, Сафа абый, туры сүз туганына ярамас, дигәннәр борынгылар.

Ш ә м ә к. Дип әйтеп әйткәндә...

Ә м ә к. Җирбит икәнсең!

Ш ә м ә к. Олтан йөз икәнсең!

С а ф а *(яткан җиреннән).* Китегез әле, кит!

Ә м ә к. Имгәк икәнсең!

Ш ә м ә к. Тинтәк икәнсең!

Ә м ә к. Летун.

Ш ә м ә к. Дизинтир!

Ә м ә к. Аппартун!

Ш ә м ә к. Сине без бригадабызга алдыкмы?

Ә м ә к. Алдык.

Ш ә м ә к. Шефка алдыкмы?

Ә м ә к. Алдык.

Ш ә м ә к. Буксирга тактыкмы?

Ә м ә к. Тактык.

Ш ә м ә к. Наданлыкны бетердекме?

Ә м ә к. Бетердек.

Ш ә м ә к. Ә син эштән качтыңмы?

Ә м ә к. Качтың.

Ш ә м ә к. Чү әле, Әмәк!
Ә м ә к. Болгатма, Шәмәк!
Ш ә м ә к. Әйдә.
С а ф а. Кая?
Ш ә м ә к. Эшкә.
С а ф а. Бармыйм.
Ә м ә к. Бармыйм?
Ш ә м ә к. Тот, Әмәк!
Ә м ә к. Була, Шәмәк!

С а ф а н ы күтәреп алып чыгалар.

С а ф а. Җибәрегез, җибәрегез, сакалны яндырасыз!..

XI. А к б и р д и н, Ф ә р и д ә.

А к б и р д и н *(изүләре чишелгән, кулында тимер көрәк).* Әй, мондагы су кая киткән?.. Су, дим, су!..

Ф ә р и д ә *(кулында комган).* Пичкә белән чишмәгә киттеләр. Менә монда бераз бар, җылы димәсәң...

А к б и р д и н *(эчкәч).* Рәхмәт, Фәридә, молодчина! Тамак кибә, эссе.

Ф ә р и д ә. Кызу эшләгәнгәдер. Юри карап сынап тордым, бигрәк кызу эшлисең, Акбирдин иптәш.

А к б и р д и н. Кеше эшләгәнне карап тору ярамый.

Ф ә р и д ә. Мин син эшләгәнне генә карарга яратам. Син һәрбер эшне булдырасың. Сиңа һәрбер эш килешеп тора. Синең кулыңда көрәк тә ыспай булып тора. Тагы эчмисеңме, монда бар әле?

А к б и р д и н *(карап торып).* Әйбәт кыз син, Фәридә, молодчина.

Ф ә р и д ә. Шулай дисең дә бит...

XII. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Һ и л а л.

Һ и л а л. Фәридә, ул синнән башка да су эчә ала. Бар, бар, эшеңдә бул. Казаныңа тоз салырга онытма!

Ф ә р и д ә китә.

Пауза.

А к б и р д и н *(паузадан соң).* Да!
Һ и л а л. Әйе!
А к б и р д и н. Аңламыйм.
Һ и л а л. Аңламыйсың!
А к б и р д и н. Аңлый алмыйм, шәйтан алгыры!
Һ и л а л. Аңлыйсы юк, барысы да үтәли күренә.

А к б и р д и н. Һилал иптәш, авырга алма, һәйбәт егет син үзең болай, ну кәҗә бәясенә дә тормыйсың!

Һ и л а л. Карап карыйк, синең бәяң кая алып барыр икән. Ташкын булып бөтен авылны су агызып китсә, кем җавап бирер? Шул кәҗә бәясенә тормаган Һилалны каптырачаклар бит.

А к б и р д и н. Әһә!.. Ул уйдырма сиңа да ирешкән икән!..

Һ и л а л. Уйдырма түгел, картлар, тәҗрибәле кешеләр фикере ул. Әнә техник белән сөйләшеп кара.

А к б и р д и н. Пыжым диген, хи-хи-хи!..

Һ и л а л. Пыжым шул, урыны бар. Акчишмә Кандырга караганда җиде метр өстә тора.

А к б и р д и н. Менә шуңа күрә дә, һавалар бозылганчы җир эшләрен бетереп, Кандыр буасын яңартырга тотынырга кирәк. Их, тагы йөз генә кеше булса! Җитәр, моннан соң юләр сүзләр бетәргә тиеш! Халык арасына ялган паника салудан сиңа өлеш чыкмас, бел аны! Ячейка директиваларын исеңдә тот. Ә инде кулак өргәләрендә калган кортлар турында яхшылап уйларга кирәк булыр.

Һ и л а л. Әллә, чынлап та, юри авылны...

А к б и р д и н. Җитәр! Кулак этләре агитациясе бу. Ә син шуларның койрыкларына тагылып өстерәлмәкче буласың, эшләпә!

Һ и л а л *(янап)*. Ну, Акбирдин, канга тоз саласың салуын, ярый, вакыты килер, вакыты килер!.. *(Чыгып китә.)*

А к б и р д и н. Янама, курыкмыйм!.. Андый сорттан түгел. Белегез аны, паникага юл куймам.

XIII. А к б и р д и н һәм Г ө л ә н д ә м.

Г ө л ә н д ә м. Нинди паника, кем чыгарган?!

А к б и р д и н. Мыеклары танауларын каплаган егетләр әбиләр сүзен җүпләп йөриләр. Обыватель идеологиясе белән һава тулган монда.

Г ө л ә н д ә м. Нәрсә бар?

А к б и р д и н. Койрыкларыгызны төенләрбез без сезнең!

Г ө л ә н д ә м. Ни бар?!

А к б и р д и н. Бар хәзер, күлмәкләреңне, чүлмәкләреңне күтәр дә Ябалак тавына менеп утыр. Да, да!.. Иртәгә авылны су агызып китә, тфү!..

Г ө л ә н д ә м. Нәрсә саташасың?!

А к б и р д и н. Мин ул кулак сөяген ялаган көчекләрнең койрыкларын кисеп авызларына каптырмасаммы!.. Мин аларны!..

Г ө л ә н д ә м. Нәрсә бар?

А к б и р д и н. Ерунда! Ташкын була калса, янәсе, Акчишмә суы ташып, шул болак буенча Кандырга төшеп, авылны су агызып китү куркынычы бар, имеш.

Г ө л ә н д ә м. Ул турыда мин дә ишеттем.

А к б и р д и н. Син дә шуңар ышанасыңмы?

Г ө л ә н д ә м. Ә син соң үзең?

А к б и р д и н. Әкият.

Г ө л ә н д ә м. Әкият булгач, нигә дулыйсың?

А к б и р д и н. Куркыныч бөтенләй үк юк түгел.

Г ө л ә н д ә м. Нәрсә?!

А к б и р д и н. Ләкин алар уйлаганча түгел. Алар, тавыклар төсле, кетәклекләре агып китүдән куркалар. Монда куркынычның икенче ягы бар, әнә анысы хәтәр.

Г ө л ә н д ә м. Хәтәр?!

А к б и р д и н. Хәтәр. Ләкин хәтәрләр белән көрәшә белергә кирәк. Атна-ун көн эчендә җир эшләрен бетереп, Кандыр буасына керешә алсак, котырган стихияне авызлыклау кәҗә бәясенә дә тормаячак!.. Яңадан йөз генә кеше запас булсын иде... Яңадан йөз генә кеше... Халык арыды. Комсомоллар гына бирешмиләр. Күрәм, әнә син дә арыгансың.

Г ө л ә н д ә м. Арыдым, бик арыдым... Задание ярым тутырдык бит бүген.

А к б и р д и н. Кеше түгел, ут син, Гөләндәм. Үзең арыдым дисең, ә үзең янып торасың! Молодчина, ян, якты ян, безгә ут, яктылык кирәк!..

XIV. Ә ү в ә л г е л ә р һ ә м Ф ә р и д ә.

Ф ә р и д ә. Акбирдин иптәш, эчәсең килмиме?!

Г ө л ә н д ә м. Минем эчәсем килә... *(Аңа таба юнәлә.)*

Ф ә р и д ә *(суын түгеп).* Бәй!.. Түгелде ич. Насыйп түгел, күрәсең...

Г ө л ә н д ә м. Насыйбы әнә пичкә белән килә!.. Күпсендең, ә? *(Чыгып китә.)*

Ф ә р и д ә. Акбирдин иптәш, салкын су китеримме сиңа?

А к б и р д и н. Кирәк түгел... Ут кирәк миңа, ут!.. Мин металлист. Ут янында балавыз кәҗә бәясенә дә тормый, Гөләндәм, мине көт!.. *(Чыгып китә.)*

XV. Ф ә р и д ә һәм Һ и л а л.

Һ и л а л. Фәридә, хәзер әбәт җитә, казан asларыңны карамыйча, ни дип монда кыршыла торгансыңдыр.

Ф ә р и д ә. Миңа ут кирәк, аңлыйсыңмы, ут кирәк! Ут янында балавыз кәҗә бәясенә дә тормый! *(Комганын Һилалның аяк астына куеп чыгып китә.)*

Һ и л а л *(комганны күтәреп).* Утны аны комган тотып эзләмиләр.

XVI. Һ и л а л, М и н һ а җ.

М и н һ а җ. Һилал иптәш, бер мәслихәт бар иде.

Һ и л а л. Тәмам итәк касмагы булдың син, Минһаҗ агай! Ут кирәк миңа, ут! Кулак өргәләрендә калган кортларны көйдерергә ут кирәк!.. *(Комган белән кизәнә, су Минһаҗ башына түгелә, чыгып китә.)*

М и н һ а җ *(сөртенә-сөртенә).* Шашкан дисәң — акылында, акылында дисәң — шашкан! Кулак өргәләрендәге кортлар диген? Кемнәр икән соң ул кортлар! Төшенә алмыйм, төшенә алмыйм... Йә болар юләрләнгән, йә мин дуракланган... *(Чыгып китә.)*

XVII. Б р и г а д и р, Ә м ә к, Ш ә м ә к һәм б а ш к а л а р.

Б р и г а д и р. Егетләр, Әмәк белән Шәмәк бригадасын төштән соң беренче комсомоллар бригадасы буксирга ала.

Ш ә м ә к. Нәрсә ди ул, Әмәк?

Ә м ә к. Саташа ул, Шәмәк.

Б р и г а д и р. Койрыкта өстерәлгәч...

Ш ә м ә к. Кем койрыкта өстерәлә, безме?

Ә м ә к. Беренчедән, бу — чеп-чи ялган!

Ш ә м ә к. Икенчедән, без үзебез буксир!

Ә м ә к. Өченчедән, заданиене ялт иттердек.

Ш ә м ә к. Дүртенчедән...

Ә м ә к. Бишенче...

Ш ә м ә к. Чү әле, Әмәк!

Ә м ә к. Болгатма әле, Шәмәк!

Болар сөйләшкәндә, халык катнаша, көлә. Шулвакыт студентлар җыры ишетелә.

Б р и г а д и р. Чү!.. Болар кемнәр?

Г ө л ә н д ә м. Монда киләләр.

Ш ә м ә к. Кара-кара, Әмәк.

Ә м ә к. Күрәм-күрәм, Шәмәк.

Сәхнә артында музыка.

Студентлар хоры.

Без коллык, наданлык дошманы,
Без хөр студентлар ордасы,
Без чын тормыш нигезен корабыз,
Без алмаш эшкә тайярлар без.
Без бар, без яшь, яна бездә көч!
Билгебез китап, урак һәм чүкеч!

Тавышлар.

Бер, ике, өч; бер, ике, өч!

Студентлар хоры.

Без бүгенге көн җепләреннән,
Без киләчәккә юл сузабыз,
Без үткән көннәрне күмәбез,
Без тарих белән узышабыз!
Без батыр, без яшь, яна бездә көч!
Билгебез китап, урак һәм чүкеч!

Тавышлар.

Бер, ике, өч; бер, ике, өч!

Бригадир студент. Иптәшләр, без интернационал студентлар бригадасы, культура һәм эш фронтларында сезгә булышыр өчен, шәһәрдән килдек.

Барысы. Ура, ура, ура!..

Музыка.

Хор.

Без, без киләчәкнең ал таңында
Төзербез, төзербез
Шәһәрен дә, колхозын да,
Совхозын да, заводын да,
Төзербез, төзербез,
Төзербез уртак дөнья.
Ура, ура, ура!..

Соңгы куплетларда масса сәхнә алдына көчле ташу булып омтыла.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Музыка. Икенче пәрдәдәге Советлар йорты. Караңгы төн. Җил, давыл, күк күкри, яшен яшьни.

I. Карчыклар, Үтәш бабай, Минһаҗ, Закирҗан һәм башка халык.

Карчыклар *(серле яшерен курку тавыш белән).* Бу ни хәл, бу ни хәл!..

Барысы. Тс-с-с!..

Минһаҗ *(кычкырып).* Ут яндырыгыз, ут!

Закирҗан *(шырпы сызып).* Шырпы янмый, чыланган.

Минһаҗ. Мә, мә, яндыр!

Закирҗан асылмалы лампаны кабыза. Телефон шалтырый. Барысы да куркып калалар.

Минһаҗ. Телефонга кагыласы булмагыз, ярамый, ярамый!..

Үтәш бабай *(тынлыктан соң).* Койрыклы йолдыз туган елны нәкъ шундый ташкын булды. Шулай ук күк күкрәде, шулай ук давыл булды...

Беренче карчык. Кая соң болар?

Икенче карчык. Түрәләр кая?

Өченче карчык. Кандырда ни хәл икән?

Беренче карчык. Мондый ташкынны гомеремдә беренче күрәм. Балалар, нәрсә көтәбез соң без монда?

Минһаҗ. Җыен килмешәк, җыен бәрәкәтсез эш башында булгач, нәрсә көтәсең! Авылны су агызып китсә, аларга ни!

Карчыклар. Ләхәүлә, ләхәүлә!..

Бөркәнеп, Сафа керә.

II. Әүвәлгеләр һәм Сафа.

Минһаҗ. Ни бар?..

Сафа. Халык Ябалак тавына күченә, кыямәт анда. Түбән оч күперен агызып киткән, көчкә үттем.

Карчыклар. Ләхәүлә, ләхәүлә!

Үтәш бабай. Сәрмән буасы ычкынмаса, бер хәл әле. Ул ычкынса харап, оланнар!

Телефон.

Минһаҗ. Якын барасы булмагыз!

Бәдига керә.

III. Әүвәлгеләр һәм Бузотёр Бәдига.

Бәдига. Кая алар, кая алар, теге килмешәк үзе кая киткән!.. Ике ай буенча җир казытып, авылга кабер хәзерләгән ул. Кая ул мордар?!

Минһаҗ. Качкан.

Бәдига. Качкан?! Әй Илаһым, алты балам белән шулай ук суда гарык булырмынмы икәнни!.. Нишлим, нишлим, киңәш бирегез, акыл бирегез!

Үтәш бабай. Бәдига килен, болай холыксызланма, ярамый. Безгә дә бәйрәм түгел ич, күрәсең. Сәрмән буасы ычкынмаса, хәтәр алай зур күренми әле.

Бәдига. Хәтәр булырлык булмаса, ул килмешәк үзе дә качмаган булыр иде. Юк, юк, үләбез, үләбез, барыбыз да суда гарык булачакбыз!

Карчыклар. Сөбханалла, сөбханалла!..

Урамда улаган тавыш.

Минһаҗ.Чү, туктагыз!.. Нәрсә үкерә?.. Әллә ычкындымы икән!..

Тынып калалар. Каты күкрәп, тәрәзә пәрдәләрен бәреп, җиргә авыр бер нәрсә гөрселдәп төшә. Ут сүнә.

Барысы. Ай, харап булдык, коткарыгыз!

Минһаҗ. Туктагыз!..

Тынып калалар.

Ут яндырыгыз, ут!

Гайфулла. Шырпы юк.

Минһаҗ. Мә, мә, кая син?

Гайфулла. Кая, бир.

Ут кабызып торганда, урамда ярсыган кеше тавышы ишетелә.

Нәгыйм. Караул, караул, коткарыгыз, коткарыгыз!.. Батабыз!..

Карчыклар. Сөбханалла, сөбханалла!..

Нәгыйм керә.

IV. Әүвәлгеләр һәм Бузотёр Нәгыйм.

Нәгыйм. Коткарыгыз, батабыз!.. Мунчамны су агызып китте.

Барысы. Ә-ә-ә?!

Нәгыйм. Тәкә Хәйрулласының тәрәзәләре суга күмелде.

Карчыклар *(елашып).* Харап булдык, харап булдык!..

Һилал керә.

V. Әүвәлгеләр һәм Һилал.

Һилал. Уф, уф!.. Ни дип монда утырасыз, Акчишмә суы, ярларыннан чыгып, авыл өстенә килә. Түбән очка Ябалак тавына күчәргә куштым. Атлар кирәк. Полевод кая?..

Телефон.

Әһә...

Минһаҗ *(юлына аркылы төшеп).* Тукта!.. Яшен атып үтерәчәк бит үзеңне!

Һилал *(кире чигенеп).* Ух, Акбирдин, картлар сүзен тыңламадың!..

Нәгыйм. Ә син, эттән туган, үзең нәрсә карадың!.. Мунчам агып китте бит, кем түләр аны?..

Бәдига. Алты балам белән батырып үтерәсез бит!..

Һилал. Акбирдинга барыгыз!

Нәгыйм. Эт койрыкка, койрык эткә дигәндәй, бер-берегезгә сылтарга эш калдымыни!..

Урамда тавыш.

Фәридә тавышы. Ярдәм, ярдәм, ярдәм!

VI. Әүвәлгеләр һәм Фәридә.

Фәридә. Абыйларым, җаннарым, ярдәмгә, ярдәмгә әйдәгез, силос башнясына су керә!.. Һилал иптәш!..

Һилал. Акбирдин коткарсын!..

Фәридә. Ә?!

Һилал. Кочаклап Ябалак тавына менгереп куяр, дим.

Бригадир керә.

VII. Әүвәлгеләр һәм бригадир.

Бригадир. Иптәшләр, агайлар, Куянлыкта Акчишмә өргәсе ычкынган. Бөтен көчне шунда ташларга кирәк, әйдәгез!..

Минһаҗ. Комсомоллар, ударниклар барсын!

Б р и г а д и р. Алар анда... Аларга ярдәм кирәк. Марш Куянлыкка!

М и н һ а җ. Җикеренмә, маңка малай!..

Б р и г а д и р. Нәрсә?! Ярый!..

М и н һ а җ. Ярасы юк. Ярылган да, ямалган да, ялт иткән. *(Һөҗүм итеп.)* Акбирдин кая, кая качты?

Н ә г ы й м.<br>Б ә д и г а. } Кая качты?..

Телефон.

М и н һ а җ *(бригадирны этеп җибәреп).* Якын барасы булма!

Б р и г а д и р. Җибәрегез!

М и н һ а җ. Батырып үтерергә теләвегез аз, яшеннән аттырып, яндырып үтерер идеңмени! *(Өстенә бара.)*

Б р и г а д и р. Кит юлымнан!

С а ф а. Ярамый, ярамый, яшен, харап булырсың!

Б р и г а д и р *(телефонга ташланып).* Мине атсын.

М и н һ а җ. Җибәрмә, җибәрмә!

Б р и г а д и р. Якын килмәгез!.. *(Телефонда.)* Әйе, әйе... Нәрсә?.. Ә?.. Сәрмән буасын?..

Б а р ы с ы. Нәрсә, нәрсә?

Б р и г а д и р. Сәрмән буасы... ычкынган!..

Б а р ы с ы. Ә-ә-ә!..

Тынлык.

Б р и г а д и р. Сакланырга кушалар...

Б а р ы с ы. Караул, караул!.. Батабыз, коткарыгыз, коткарыгыз!..

А к б и р д и н, п о л е в о д керәләр.

VIII. Ә ү в ә л г е л ә р һәм А к б и р д и н, п о л е в о д.

А к б и р д и н. Туктагыз!.. Нәрсә бар?..

Б р и г а д и р. Сәрмән буасы ычкынган...

А к б и р д и н. Нәрсә?! Ычкынган!..

Б р и г а д и р. Хәзер генә телефон белән...

А к б и р д и н. Начар!.. Начар!.. Хәзер, чирек сәгать эчендә бөтен авылны җыйнап, бөтен көчне Куянлыктагы өргәне коткарырга куярга!..

Б р и г а д и р. Бөтен җирдә паника, бер кеше табар хәл юк.

А к б и р д и н. Ябалак тавына күчәргә кем кушкан?

Һ и л а л *(алга чыгып).* Мин.

А к б и р д и н. Син?..

М и н һ а җ. Халык сезгә басудагы йомран түгел, суга батырып тончыктырырга!..

Һ и л а л. Алай...

А к б и р д и н. Әһә!..

П о л е в о д. Шундый куркынычлы моментта син, Совет председателе, ячейка директиваларын тормышка ашырмыйча, Минһаҗ агай кочагына кердеңмени?..

Һ и л а л. Җитәр, өркетмә!..

П о л е в о д. Тукта, дим мин сиңа!..

Һ и л а л. Туктамыйм... Моңарчы авызлыклаганыгыз да җитәрлек булды инде!

М и н һ а җ. Алай...

Һ и л а л. Ә син соң, син үзең, ячейка секретаре була торып, шул килмешәкнең койрыгына тагылып, авылны нинди хәлгә китереп куйдыгыз.

А к б и р д и н. Җитәр!.. Сүз вакыты түгел, эш кирәк. Акчишмә өргәсе ычкынган, Сәрмән буасы ычкынган, авыл өстенә ике яклап куркыныч килә!.. Авылны, ничек кенә булмасын, коткарып, саклап калдырырга кирәк!.. Мин комсомоллар янына, Акчишмә өргәсен коткарышырга китәм. *(Полевод белән бригадирга.)* Ә сез, халыкны җыеп, хәзер үк Кандыр буасын өздерегез!..

М и н һ а җ. Әһә!.. Күрдегезме, Кандыр буасын өздерәләр, бөтен авылны батырып үтерергә җыеналар. Безне үтергәнче, үзләре дөмексеннәр, бәр!.. Җаннары җәһәннәмгә!..

Н ә г ы й м. Бугазларын чәйнәгез!..

Ташлананалар. Ү т ә ш ике арага баса.

Ү т ә ш б а б а й. Ярамый, ярамый, оланнар! Аларның безгә хәзер иң кирәк чаклары.

М и н һ а җ. Буталма син, карт үләт!

Ү т ә ш. Ярамый, оланнар!

Н ә г ы й м. Безгә барыбер үлем, бәр!..

Ташлананалар.

Б а р ы с ы. Караул, караул, үләбез, үтерәләр!..

Ыгы-зыгы. Ут сүнә. Тынлык. Бригадир ут кабыза. Куркынычлы тынлык. Минһаҗлар, Нәгыймнәр Акбирдинга һөҗүмгә хәзерләнгән хәлдә катып торалар. Һилал читтә.

А к б и р д и н. Мине кыйнарга өлгерерсез, башта авылны коткарырга кирәк. Кем безнең белән, әйдәгез!..

Акбирдин, полевод, бригадир, Фәридә, Закирҗан, Сафа, ахырдан Үтәш бабай чыгып китәләр, калганнар калалар. Һилал чыгарга да, чыкмаска да белмичә аптырап, буталып кала.

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Күпер төзәтәләр. Ярның ике башында электр өчен ике багана күренә. Әмәк белән Шәмәк күпернең араталарын беркетә. Сафа белән Тимеркәй балта эшендә.

I. Әмәк, Шәмәк, Сафа, Тимеркәй.

Музыка.

Әмәк.
Балан, миләш, җиләк, чия
Бездә күп ул күплеккә.
Шәмәк.
Колхоз уңганнарны сөя,
Ялкауларны чүплеккә.
Әмәк.
Күрәм: кырау тимәгән.
Тыштан гел кызарасың.
Шәмәк.
Кулак тәмең бетмәгән,
Шикәр даулап торасың.
Бергә.
Колхоз яланы иркен, ай-вай, баланым!
Кызарып шунда пеш син, ай-вай, баланым!
Заман кыйбат агаһ бул!
Бездән киңәш сиңа шул:
Советски балан бул,
Шикәрсез дә төче бул.
Ай-вай, баланым, түгәрәгем, кызыл бит,
Бергә-бергә тәгәрәп, күмәк булып гомер ит!
Әмәк.
Кулакларны кикерттең,
Шәмәк.
Ялкауларны төчкерттең.
Бергә.
Әчкел, төчкел төчкелтем,
Әчкел, төчкел төчкелтем.
Шәмәк.
Син, Әмәк, миңа шуны әйт.

Ә м ә к.
Йә?
Ш ә м ә к.
Эштә, көчтә, без күмәкме?
Ә м ә к.
Күмәк.
Ш ә м ә к.
Күмәк илдә хәрәкәтме?
Ә м ә к.
Хәрәкәт, ди, йә?
Ш ә м ә к.
Хәрәкәттә бәрәкәтме?
Ә м ә к.
Бәрәкәт, ди, йә, йә?
Ш ә м ә к.
Син элекке батракмы?
Ә м ә к.
Батрак.
Ш ә м ә к.
Батрак булсаң, балтаңны тот катырак!
Ш ә м ә к.
Кызыл, кызыл, кызыл төс лә,
Кызык төс ул ансы дөрес лә.
Ә м ә к.
Кызлар кызыккан кызыл төс
Советски безнең төс лә.
Ш ә м ә к.
Балан төсе дә кызыл төс.
Ә м ә к.
Миләш төсе дә кызыл.
Ш ә м ә к.
Кызыл борыч үтә кызыл.
Ә м ә к.
Тыштан бар да кып-кызыл.
Кулак койрыгы ишәкләргә,
Ялкау, наян, тинтәкләргә…
Ш ә м ә к.
Оппортунист имгәкләргә,
Тудый-судый хикмәтләргә…
Ә м ә к.
Кызыл балан, дисеңме?
Ш ә м ә к.
Кызыл борыч, дисеңме?

Ә м ә к.

Сыртларына, дисеңме?

Ш ә м ә к.

Артларына, дисеңме?

С а ф а. Разыймын, егетләр. Маладис! Дисвительне балан әчегә әче... Әмма ләкин бәлеше тәмле...

Әмәк, Шәмәк, тимерчыбыклар рәтләп, соңыннан аякларына тырнаклар киеп, баганаларга менеп китәләр.

Т и м е р к ә й. Чү әле!

С а ф а. Колхоз баланы кулакларны дисвительне кикертте. Мине дә ул төчкертте. Мин яшермим. Колхозда атаклы ялкау кем иде?

Т и м е р к ә й. Син.

С а ф а. Дөрес. Кем лодырь иде?

Т и м е р к ә й. Балан Сафа.

С а ф а. Анысы да дөрес.

Т и м е р к ә й. Кем эшләмичә күктән күкәй көтеп торды?

С а ф а. Мин дисвительне күктән күкәй төшкәнен көтеп яттым. Әмма ләкин здель, здельме ул, здель күктән күкәй көтәргә кушмый, җирдә эшләргә куша.

Т и м е р к ә й. Чү әле, чү!..

С а ф а. Тукта, бетмәде. Ә хәзер мин кем? Йә, әйт, хәзер мин кем?

Т и м е р к ә й. Кем соң син?!

С а ф а. Юк, менә син әйт, кем мин?

Т и м е р к ә й. Үзең белмәгәнне мин каян белим.

С а ф а. Ә, алаймы?

Т и м е р к ә й. Шулай.

С а ф а. Сүзең беттемени?

Т и м е р к ә й. Бетте!

С а ф а. Ә, беттеме?

Т и м е р к ә й. Бетте, дим инде, бәрәкәт.

С а ф а. Юк, бетмичәрәк торсын әле.

Т и м е р к ә й. Я, ярый, бетмәде.

С а ф а. Ә, бетмәдеме?

Т и м е р к ә й. Бетмәде.

С а ф а. Юк, бетәр.

Т и м е р к ә й. Йә, ярый, җитәр. Шуннан соң?

С а ф а. Мин, агай-эне, элек Балан Сафа идем.

Т и м е р к ә й. Хәзер кем соң?

С а ф а. Хәзер здель Балан Сафа, ә иртәгә...

Т и м е р к ә й. Чү, чү, сикермә алай киртәгә!

С а ф а. Сикерәм, сикерермен. Безнең, беләсең килсә, агай-эне, Тимеркәй агай, сикерә торган чаклар хәзер.

Т и м е р к ә й. Сикергәч күрербез.

С а ф а. Сикерәм!

Т и м е р к ә й. Сикер.

С а ф а. Сикерәм!

Т и м е р к ә й. Сикер, дим ич инде.

С а ф а. Менә шулай, агай-эне, Тимеркәй агай, иртәгә мин ударник!.. *(Күкрәгенә сугып.)* Ударник, ударник, ударник!..

Т и м е р к ә й. Әй, чү, чү, акрын. Күкрәк дигәч тә, барабан түгел лә ул, алай рәхимсез ударәт итәргә...

С а ф а. Үз күкрәгем, советски, здельни күкрәк! Менә, менә, менә!..

Т и м е р к ә й. Чү әле, чү, кая, борыныңны тотып карыйм әле!

С а ф а. Юк, агай-эне, Тимеркәй агай, борынны тотмыйчарак тор син, яме?! Менә кулны тот син!.. *(Кулын суза.)*

Т и м е р к ә й. Борының кирәк миңа.

С а ф а. Нигә алай кирәк булды соң сиңа минем шадра борын?

Т и м е р к ә й. Шашар алдыннан борын кыза, ди.

С а ф а. Юк, агай-эне, Тимеркәй агай, тора тор. Ударник борыны кызмый ул.

Т и м е р к ә й. Син ударникмы?

С а ф а. Иртәгәдән.

Т и м е р к ә й. Ударник, ә?

С а ф а. Ударник.

Т и м е р к ә й. Син ударник?

С а ф а. Мин ударник!

Т и м е р к ә й. Кит, дим, кит!

С а ф а *(бүреген җиргә бәреп)*. Ударник!

Т и м е р к ә й *(бүреген җиргә бәреп)*. Булмый!

С а ф а. Ударник!

Т и м е р к ә й. Булмый!

С а ф а. Ударник, дим!

Т и м е р к ә й. Булмый, дим!

С а ф а. Ударник!..

Т и м е р к ә й. Чү әле, чү!.. Синең бүрек, үзең әйтмешли, дисвительне ударник икән, шап та шоп килә. Дисвительне тузаны да бар икән. Син, энекәш, ударник бүрек тузанын күзгә җибәреп, минем бригадир бүрекне кимсетмә алай!..

С а ф а. Син, агай-эне, соңгы айның хезмәт табелен карап күр, кайсыбызның труддин күбрәк икән анда! Пештеңме?

Т и м е р к ә й. Сүздә мин арысланның да колакларыннан тотам, ә囗 эштә песи койрыгы да кулдан ычкына, белдеңме!.. Бушка сүз ярышы ясап торганчы, әйдә, пычкы белән сайрашыйк.

С а ф а. Әйдә. Сайратыйм әле мин сине…

Бүрәнә кисәләр.

Ш ә м ә к *(багана башыннан)*. Әмәк!

Ә м ә к. Әү-ү.

Ш ә м ә к. Колхоз сиңа күренәме?

Ә м ә к. Күренә.

Ш ә м ә к. Силос башнясы?

Ә м ә к. Күренә.

Ш ә м ә к. Клуб?

Ә м ә к. Күренми.

Ш ә м ә к. Ашханә?

Ә м ә к. Түбән ич ул.

Ш ә м ә к. Ә тегермән?

Ә м ә к. Нинди тегермән?

Ш ә м ә к. Нинди булсын, яңа.

Ә м ә к. Электр стансасы диләр аңа.

Ш ә м ә к. Күренәме?

Ә м ә к. Әнә, әнә ул.

С а ф а. Тимфы белән, тимфы белән!

Т и м е р к ә й. Айгыр көче икән үзеңдә, бирән!

Ш ә м ә к. Әмәк!

Ә м ә к. Әү, Шәмәк?

Ш ә м ә к. Күрдеңме?

Ә м ә к. Нәрсәне?

Ш ә м ә к. Турбинны.

Ә м ә к. Әйтте сүз!.. Иртәгә куя башлыйлар, ди. Акбирдин иптәш шул эш турында калага китте бит.

Ш ә м ә к. Бушатма, тартып беркет! Техник ни диде?

Ә м ә к. Әү!

Ш ә м ә к! Бушатма, әбиең ычкыры түгел, дим.

Ә м ә к. Ычкындыр дисеңме?

Ш ә м ә к. Әбиеңнең ычкыр бавы түгел, дим… Электр!

Ә м ә к. Эләктердем.

Ш ә м ә к. Тарт, дим, тарт!

С а ф а. Әйдә, әйдә, ләпшемә, агай-эне!

Т и м е р к ә й. Сәләтең үзеңә күрә түгел икән, юньсез.

Сафа. Сәләтне күрсәтәсе көннәр алда әле.
Шәмәк. Әмәк.
Әмәк. Әү-ү?
Шәмәк. Колагыңны куеп тыңла әле, сызгырамы?
Әмәк *(тыңлап).* Сызгыра!
Шәмәк. Электр йөри башлагач сызгырганны күрерсең әле!..

Музыка.

Шәмәк.

Тиз кил, тиз кил, электр,
Яктылык безгә китер!
Яңа дөнья, яңа көн
Колхозлар төзә бүген.

Әмәк.

Шоссе юллар, ай, буенча
Автобус җилдәй чабар.
Агач арба, юкә чана
Колхоз мичендә янар.

Бергә.

Резин көпчәк автобус,
Тизрәк кил син безгә, дус.
Яңа дөнья, яңа көн
Колхозлар төзә бүген.

II. Әүвәлгеләр һәм Минһаҗ.

Минһаҗ. Эш уң булсын, егетләр!..

Дәшмиләр. Пауза.

Сез, йолкышлар, нишләгән буласыз анда?..
Шәмәк. Электрга юл сузабыз!
Минһаҗ. Юл?..
Әмәк. Юл шул. Нигә исең китте аңа?
Минһаҗ. Юк, исем китми. Сез сузган юлдан нинди электр йөрер икән, шуңа акылым җитми.
Шәмәк. Синең акыл кыскалыгына без бинават түгел.
Әмәк. Политграмотасыз акыл дисәңче.
Минһаҗ. Ярый, ярый, мин болай гына.
Шәмәк. Булдымы, Әмәк?
Әмәк. Булды, Шәмәк.

Баганадан төшәләр.

Минһаҗ. Сафа энем, сөбханалла, күз тимәсен!.. Кая, берәрне булмаса урап та алыйк. *(Тәмәке чыгара.)*
Сафа. Үземдә бар.

М и н һ а җ. Һә, үземдә бар диген. Ярый, ярый…

Т и м е р к ә й *(эштән туктап тәмәке урый-урый).* Минһаҗетдин, кая болай?

М и н һ а җ. Районга.

Т и м е р к ә й. Алай…

М и н һ а җ. Шулай. Колхоздан чыгардык дигәч тә, эш бетте дип уйлагансыз үзегезчә.

Т и м е р к ә й. Бетсә дә беткәндер шул.

М и н һ а җ. Юк әле, бетмичәрәк торсын.

Т и м е р к ә й. Анысы инде үз эшең.

М и н һ а җ. Районга барам. Анда чыкмаса, шәһәргә барырмын. Анда да чыкмаса, Мәскәүгә дә юл киселмәгән. Талашырмын, чәйнәшермен, үземнекен итәрмен.

Т и м е р к ә й. Иттерсәләр!

М и н һ а җ. Нәрсә, иттерсәләр?

Т и м е р к ә й. Иттерсәләр итәрсең, дим. Һай, анда утыручыларның башларын, мин әйтәм, синең ишеләргә генә оттырырлыклар түгел, ди, анда.

М и н һ а җ. Мин отарга бармыйм, хакымны дауларга барам.

Т и м е р к ә й. Хак дип инде… Белмим тагы…

М и н һ а җ. Безнең нәсел дүрт буын батрак, өч буын беднәк, ике буын середнәк булып килгән. Шулай булгач, мине, Минһаҗетдин Гыйлаҗетдиневне, колхоздан чистартып чыгару кайсы законда, нинди дикриттә язылган икән. Нисмиешь права!

Ә м ә к. Кулак койрыгы дигән соңгы буыныңны кая куясың?

М и н һ а җ. Анысын синең борын астыңдагы чишмәне сөртергә калдырам.

Ш ә м ә к. Юк, син аны үзеңдә сакла, сәфәргә койрыксыз чыгу килешмәс.

М и н һ а җ. Кулакларга койрык булып нишләгән?

Ш ә м ә к. Нишләр идең тагы?

Ә м ә к. Бәй, син әллә кулак койрыкларын, сыерыңның койрыгы төсле асылынып, былчыранып йөриләр дисеңме? Алар бар да, синең шикелле йомшак җәеп, катыда кабырга кабартучылар, белдеңме?

М и н һ а җ. Шуннан соң?

С а ф а. Өндәмә, Минһаҗ агай, өндәмә. Сөйләгән сүзләреңне, эшләгән этлекләреңне исеңә төшереп кара!.. Харап итә яздың бит кешене, агай-эне.

М и н һ а җ. Нәрсә сөйләгән мин сиңа! Гомерең буена минем тәмәкегә көя булып йөрдең бит.

Сафа. Теге ташкын вакытында Бузотёр Нәгыймнәр дә синең тәмәкене бик күп тарттылар, исеңдәме?.. Колхозга дус кеше шулай буламыни?

Минһаҗ. Курку белән ачу килгәндә, кеше әллә ни эшләр.

Сафа. Мин дә шулай дим, май кап дим, агай-эне, Минһаҗ агай.

Минһаҗ. Алла казасын әллә миннән күрер идегезме?

Шәмәк. Каза тудырмакчы идегез дә — барып чыкмады шул. Ялт итте. Акчишмәне дә, авылны да саклап калдык.

Әмәк. Турбин да килде. Бер айдан колхоз урамнарында гына түгел, менә бу күпер башларында да электр яначак.

Минһаҗ. Күрербез.

Шәмәк. Синең күрүеңнең безгә хаҗәте, — Акбирдин иптәш әйтмешли, кәҗә бәясе. Колхоз күрсә, шул җитәр.

Минһаҗ. Син, егет булсаң, үз сүзеңне сөйлә. Акбирдин сүзләренә тутый булуның истибрама да хаҗәте юк.

Шәмәк. Совет, колхоз эше турында сөйлим мин. Безгә яктылык, яктылык кирәк. Урамнарда, өйләрдә, сыер абзарларында да якты булсын. Шуны эшлибезме, эшлибез. Яктылыктан качкан ярканатларның, кулак койрыкларының, аффартунистларның, чурт-гурләрнең хаҗәтләренә төчкерәм!.. *(Бер бармагы белән танавын тотып сеңгерә.)* Менә!

Әмәк *(декламировать итеп)*.

Ыграк, катырак бәрер өчен
Дошманнарның башына.
Безгә кирәк машина!..

Сафа. Барган җирләреңдә әйт, ялкаулыкка өндәп, бик күп тәмәкемне тарткан Балан Сафа, диген, иртәгәдән ударник була, диген!..

Минһаҗ. Ударник!..

III. Әүвәлгеләр һәм Һилал.

Әмәк. Кая болай, Һилал иптәш?

Һилал *(җилкәсендә котомка)*. Ячейка секретаре белән Акбирдиннан сорарсыз.

Минһаҗ. Һилал иптәш белән минем юл бер хәзер.

Һилал. Саташма, Минһаҗ агай, саташма, дим!

Минһаҗ. Нигә, син райкомга, мин районга — юлыбыз бер.

Һ и л а л. Синең юл белән минем юл бервакытта да бер булмас!

М и н һ а җ. Шулайдыр... Ник дисәң, этнең койрыгын кем киссә...

Һ и л а л. Җитәр! Син ул кулак койрыгы, белдеңме аны, син ул!

М и н һ а җ. Ай, чү, акрын бас, егет, егылганны кем дә кыйный ала аны. Егылганны торгызу әнә ул егет эше инде... Сине торгызгалаган чакларым бар иде. Хәтерең начарланган, күрәм. Чабатадан итеккә күчкәнеңә күпме әле? Азау тешләреңне суырып кара әле, кемнең икмәк тәме килә икән!

Һ и л а л. Кит, дим, кыяфәтеңә карый алмыйм!

М и н һ а җ. Эт этлеген итмәсә, күңеле булмый дигәндәй...

Һ и л а л. Югал!

Т и м е р кә й. Бар инде, бар, Минһаҗетдин.

М и н һ а җ. Һә, батыр, Акбирдин ачуын миннән алмакчы.

Һ и л а л *(наганын чыгарып).* Китәсеңме, юкмы!..

М и н һ а җ. Һә, салам торхан, каһарман... Ата күркә кабарган. Гөлдер, гөлдер!.. *(Чыгып китә.)*

Ш ә м ә к. Әйдә, әйдә, тай.

С а ф а. Кая китәсе булдың, Һилал иптәш?

Һ и л а л. Заводка. Нигә эшләмичә ләчтит сатасыз?

Т и м е р к ә й. Бетердек, кайтырга җыенабыз. Бөтенләйгә үкме?

Һ и л а л. Әйе. Ярый, дуслар, хушыгыз! Яхшымы, начармы, күп еллар бергә эшләдек. Бергә-бергә колхоз оештырдык. Бергә-бергә Кандыр суын эчтек. Халыкка да, колхозга да начарлык теләмәгән идем. Үземчә чын күңелем белән бирелеп эшләгән идем. Ярамадым. Яратмадылар.

Т и м е р к ә й. Эшләгән кеше ялгышмый булмый инде ул. Ярый, хуш, хәерле юл!

Ә м ә к.<br>Ш ә м ә к. } Хуш, иптәш, хат яз!

Китәләр.

Һ и л а л. Хушыгыз, хуш!.. Һә, тәрбияләргә, дисциплинага өйрәтергә, оппортунистлык чиреннән дәваларга заводка җибәрәләр, имеш. Гомеремдә бер генә тапкыр шул оппортунист дигәннәренең йөзен күргән булсам икән?! Фәридәсенә чаклы бит шуның чабуына ябышып йөри,

чүпрәк!.. Ну, Акбирдин, исәп-хисап көне бер килер. Сөйгән кызымның күңелен суындырдың — өндәмәдем. Председательлектән төшертергә сәбәпче булдың — өндәмәдем. Туган илемнән сөрдерәсең, анысына да өндәмим. Инде райкомга әләкләп партия кандидатлыгыннан чыгартсаң, анысын инде бәхилли алмам!..

Акбирдин кереп килә, шат. Һилалны күреп кинәт туктый.

IV. Һилал, Акбирдин.

Акбирдин *(ачык йөз белән).* Ә... Һилал иптәш, китешмени, яхшы, бик яхшы...

Һилал. Тукта!

Акбирдин. Есть! *(Туктый.)*

Һилал. Үзеңне кызгансаң, мине харап итәргә теләмәсәң...

Акбирдин. Син нәрсә?.. Әллә чынлап та?..

Һилал. Урыныңнан кузгалма!

Акбирдин. Балаланма, Һилал иптәш.

Һилал. Әйт, дөресен әйт, район контроль комиссиясендә булдыңмы?

Акбирдин. Булдым.

Һилал. Минем турыда сөйләштеңме?

Акбирдин. Бу ниткән допрос?!

Һилал. Дөресен әйт, сөйләштеңме?

Акбирдин. Конешно, сөйләштем.

Һилал. Кандидатлыктан чыгарттыңмы?

Акбирдин. Кемне?

Һилал. Мине.

Акбирдин. Аңламыйм.

Һилал. Дөресен әйт, миңа хәзер барыбер...

Акбирдин. Организация минем сүз белән йөримени, кызык син!

Һилал. Кызык?!

Акбирдин. Кызык. Тәрбия кирәк сиңа, партия тәрбиясе кирәк. Ничего, анда кеше итәрләр. Хәерле юл!

Һилал. Көлмә!.. Дөресен әйтмәсәң, бу күпердән... *(Кесәсен капшый.)*

Акбирдин. Саташма!.. Кит, юл өстемдә торма!

Һилал. Син минем юл өстемдә торасың, син мине...

Әмәк белән Шәмәк күпер астыннан чыгалар.

V. Әүвәлгеләр һәм Әмәк, Шәмәк.

Шәмәк. Ишеттегезме, яңа хәбәр!

Ә м ә к. Искиткеч кызык хәбәр!
Ш ә м ә к. Чү әле, Әмәк!
Ә м ә к. Болгатма, дим, Шәмәк.

А к б и р д и н, Һ и л а л үз юлларына китәләр.

Ш ә м ә к *(бармагы белән изәп)*. Әмәк!..

П ә р д ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

«Кызыл йолдыз» колхозында мәйдан. Яшьләр баганаларга флаглар, гирляндалар эләләр. Аерым урыннарга — витриналарга плакатлар ябыштыралар. Сәхнәдә хәрәкәт, җанлылык, хәзерлек. А к б и р д и н, п о л е в о д, М и н һ а җ һәм Һ и л а л д а н башка уйнаучыларның б а р ы с ы д а сәхнәдә, киенгән, шат. Читтә клуб парадные күренә.

I. А к б и р д и н, п о л е в о д, М и н һ а җ һәм Һ и л а л д а н башкалар.

К в а р т е т *(җырлый)*.
Бүген бәйрәм, илдә чын ямь,
Илдә чын ямь, илдә чын ямь,
Калма эштән, эштә чын ямь,
Эштә чын ямь, эштә чын ямь.
Батыр, каһарман ударчылар сез,
Эшкә чыныккан колхозчылар сез,
Мактап танылган нык бригадирлар,
Эштә дан алган хатын-кыз, ирләр.

Х о р.
Удар көч белән,
Матур эш белән,
Илдә ямьле дан тота,
Төзелешне ныгыта.
Колхоз, совхозда,
Фабрикта, заводта
Ударник чын эшче,
Ударник колхозчы.
Удар көч белән,
Матур эш белән,
Илдә ямьле дан тота,
Төзелешне ныгыта.
Яңа дәрт белән,
Яңа көч белән,
Шулай иртәгә
Чыгыйк эшкә дә.

К в а р т е т.

Бүген бәйрәм, илдә чын ямь,
Колхозчыга, совхозчыга,
Коммунага күптән көткән
Кояш чыга, кояш чыга.
Соңгы көрәшнең алгы сафында
Көчле сыйныфның көче торганда,
Шәфкать, мәрхәмәт юк, юк дошманга.
Чигенү безгә ят, җиңеп барганда.

Х о р.

Удар көч белән,
Матур эш белән,
Якты яңа дөньяга
Давыл булып барганда,
Колхозда, совхозда,
Фабрикта, заводта
Ударник чын эшче,
Ударник колхозчы.
Удар көч белән,
Матур эш белән,
Илдә ямьле дан тота,
Төзелешне ныгыта.
Яңа дәрт белән,
Яңа көч белән,
Шулай иртәгә
Чыгыйк эшкә дә.

Яшьләр эшләрендә дәвам итәләр. Кайберәүләр йөреп торалар. Күбесе клубка кереп китәләр. Ү т ә ш  б а б а й керә.

С а ф а *(Үтәшкә килеп).* Ничегрәк, Үтәш бабай, ә... Эшебез дә көчле, бәйрәмебез дә күрекле. Кара син боларга, карабодай басуымыни!..

Ү т ә ш  б а б а й. Шуны уйлап утырам әле, кем, Мөхәммәтсафа. Уйлыйм, уйлыйм, очына чыга алмый хәйран булып аптырап калам. Үләсе килми, дим, үләсе килми...

С а ф а. Нигә үләргә, торабыз, шаулатып торабыз!

Ү т ә ш  б а б а й. Шулаймы?

С а ф а. Соң, социализмга барганда үләргә ярыймы соң...

Ү т ә ш  б а б а й. Мин дә шул турыда уйлыйм. Дөньясы бигрәк күңелле булып китте бит, бәрәкәт!..

С а ф а. Әле бу баласы, алда аның анасы...

Ү т ә ш  б а б а й. Мин дә шуны әйтәм. Кырда, ындырда машина. Күкәйдән чебине дә машина чыгара лабаса.

Ә Кандыр, Кандыр нишләде!.. Судан ут чыгардылар. Көннәр, төннәр буе уйлыйм. Ничек соң бу болай, дим. Әллә төшме икән, дим. Төш түгел бит, ә, төш түгел бит...

Сафа, Әле бу баласы гына, дим ләбаса, хикмәтләр алда әле.

Үтәш бабай. Мин дә шуны әйтәм. Кайчагында төннәрдә торып лектр кендеген борып куям... Келт яна, келт сүнә, яңадан келт... Яңадан яна, хи-хи-хи... Кая, якынрак кил әле... Шуны әйтәм, белмәссең, мин әйтәм, Акбирдин бервакытны миңа, теләсәң, картларны да яшәртә алабыз, дигән иде.

Сафа. Үз теле белән әйттеме?

Үтәш бабай. Үз теле белән, бүгенгедәй исемдә. Әйткәнен булдыра торган булып чыкты бит. Белмәссең, мин әйтәм...

Сафа. Зерәгә тел туздырмый инде ул.

Үтәш бабай. Аны сөйлә, моны әйт дигәндәй, үләсе килми бит, хи-хи-хи...

Сафа. Үзең әйтмешли, Алла яшәртә алмаганны булдыра алырлармы икән соң?

Үтәш бабай. Әй, алай димә, теләсәләр булдырып та куярлар. Судан ут чыгарганны... белмәссең... кап-кара сакаллы ир уртасы ясар да куяр, менә вәт, хи-хи-хи!..

Сафа. Белмим...

Үтәш бабай. Ә мин беләм. Дөньяның ачысын-төчесен синнән күбрәк күргән мин...

Сафа. Шулай дисеңме?!

Үтәш бабай. Үтәш бабай әйтте диярсең.

Гөләндәм. Үтәш бабай, кичкә монда килергә онытма, уеннар була, килми калма!

Үтәш бабай. Киләм, киләм. Шуны әйтәм әле, оланнар, белмәссең, мин әйтәм, берәр елдан үзем дә уйнап куйсам... Белмәссең, ә?.. Хи-хи-хи! *(Сафага төртә.)*

Сафа. Эчтән тын! Хи-хи-хи!..

Үтәш бабай. Белмәссең, май кап! Хи-хи-хи...

Гөләндәм. Әллә нәрсә серләшәсез.

Үтәш бабай. Белмәссең, белмәссең, хи-хи-хи...

Сафа. Алай, хи-хи-хи...

Гөләндәм. Кызлар, егетләр, Үтәш бабайның сезгә сүзе бар!

II. Әүвәлгеләр һәм халык.

Барысы *(Үтәшне чолгап алып).* Тыңлыйбыз, тыңлыйбыз!..

Ү т ә ш  б а б а й. Сүз дип инде, хәзергә сер әле. Белмәссең, май кабыгыз, оланнар, хи-хи-хи...

Б а р ы с ы. Үтәш бабай сөйләсен!..

Ү т ә ш  б а б а й. Аны сөйлә, моны әйт, оланнар, картлар эше телдә калтырый, яшьләр эше кулда ялтырый дигәндәй, бәйрәмебез тагы да ямьлерәк, тагы да күреклерәк булсын өчен, һаваларны яңгыратып, су буйларын шыңгыратып алыгыз, булмаса, хи-хи-хи... Әмәк белән Шәмәк кая соң, күренмиләр?

Ә м ә к. Монда без, Үтәш бабай!

Ү т ә ш  б а б а й. Кая әле, теге лектр машинасын җибәргән чакта җырлаган көйне җырламый башладыгыз.

Ш ә м ә к. Кайсын?

Ү т ә ш  б а б а й *(җырлап).*

Без кабызган утлар якты янар...
Хи-хи-хи.

Б а р ы с ы. Ха-ха-ха!..

Ү т ә ш  б а б а й. Йә әле, шуны бер әйтеп алыгыз!..

Ә м ә к. Тамак юк бүген безнең...

Ү т ә ш  б а б а й. Хикмәт тамакта түгел, йөрәктә булсын, йөрәктә бәрәкәт.

Г ө л ә н д ә м. Йә, сырланмагыз инде сораганда...

Ш ә м ә к. Ни дисең, Әмәк?

Ә м ә к. Башлыйк, Шәмәк.

Музыка.

Ә м ә к,  Ш ә м ә к.

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрендә;
Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт илләрендә.

Х о р.

Без кичә алмаган юк кара урман,
Без җиңә алмаган дошман тумаган.
Безнең байраклар котлыйлар алар,
Котлыйлар алар хезмәт бәйрәмен.
Эш өстендә гөрләп үсәбез,
Гасырларны елда үтәбез,
Чыныккан якты корычтай
Зур үсәбез ныгып шулай,
Үсәбез, үсәбез, үсәбез!..

Ә м ә к,  Ш ә м ә к.

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрендә;

Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт илләрендә.

Х о р.

Безнең бакчалар чәчәк аталар,
Чәчәк аталар ил күрке өчен.
Безнең теләкләр уттай яналар,
Уттай яналар зур әмәл өчен.
Безнең байраклар котлыйлар алар,
Котлыйлар алар хезмәт бәйрәмен.
Эш өстендә гөрләп үсәбез,
Гасырларны елда үтәбез.
Чыныккан якты корычтай
Зур үсәбез ныгып шулай,
Үсәбез, үсәбез, үсәбез!
Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрендә,
Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт илләрендә.

Ү т ә ш б а б а й. Разыймын, оланнар!.. Ничек ди, без кабызган утлар, диме?.. Шул, шул, якты яна, якты яна, оланнар?

Г ө л ә н д ә м. Комсомоллар кая, комсомоллар!

Ә м ә к. Трактор Вәли кая?

Ш ә м ә к. Кызлар, ә сез нәрсәгә тындыгыз?

Ә м ә к. Алай, безне генә җигәргәмени! Шулай бит, Үтәш бабай?

Ү т ә ш б а б а й. Әү!

Ә м ә к. Сырланмасыннар, чыксыннар, дим. Әйдә, әйдә, көн дә, көн дә бәйрәм булмый.

Б р и г а д и р.

Безнең байрак җилфердәп уйнасын анда,
Батырларны чакырып биек данга.
Безнең байрак колхозда, совхозда уйный,
Бездән, сездән зур даннар, эшләр сорый.

Х о р.

Данлы чорның матурларын,
Каһарманын, батырларын
Эш мәйданы чакырганда,
Намус өчен, даннар өчен...
Бөек чорның бизәкләре,
Бөек дәртләр теләкләре,
Ударниклар, чын батырлар,
Төшермиек байракларны!

Б р и г а д и р.

Безнең байрак безнең көн ул, безнең заман,
Киләчәккә хәзерли ул якты таң,
Безнең байрак көннән-көн гел ялан-ялан,
Югарырак күтәрик һаман, һаман...

Х о р *(кушымтаны җырлый)*.

Балет башлана.

III. Ә ү в ә л г е л ә р һәм А к б и р д и н, п о л е в о д.

П о л е в о д. Иптәшләр, туктагыз!

Б р и г а д и р. Нәрсә бар?

П о л е в о д. Акбирдин иптәш, үзең әйт.

А к б и р д и н. Иптәшләр, «Кызыл йолдыз» колхозына килеп, сезнең белән бергә эшли башлауга ике ел тула. Шул вакыт эчендә, партия һәм хөкүмәт юлбашчылыгы астында, авыл хуҗалыгын яңа нигездә коруда, машиналаштыруда, электрлаштыруда, ашлык хәзерләү эшләрендә һәм башка кампанияләр буенча хәтсез зур уңышлыкларга ирешелде. Ләкин эшләнәсе эшләрнең зурлары, авырлары алда әле. Без ул кыенлыкларны да партиянең корыч җитәкчелеге белән җиңеп чыгарбыз, әлбәттә. Сөйли башлагач, речь була язды бу... Сезгә хәбәр итәргә теләгәнем менә нәрсә: миңа тиз көннәрдә сездән аерылырга туры килер.

Б а р ы с ы. Нәрсә?.. Аерылырга?!

А к б и р д и н. Әйе. Бәлки иртәгә үк.

Б р и г а д и р. Ничек инде ул алай!.. Шаярта, егетләр, шаярта.

А к б и р д и н. Шаяртмыйм. Заводтан ашыгыч телеграмма алдым. Станогым мине анда көтә.

Б р и г а д и р. Җибәрмибез, монда станок түгелмени!

А к б и р д и н. Дөрес, монда да шундый ук станок. Мине кире заводка кайтару эше заводта каралган, монда да райком һәм башка тиешле урыннарда каралып үтте. Берничә көн эчендә мин заводта үз станогым янында булырга тиеш.

Б р и г а д и р. Тукта әле, тукта, ничек соң бу болай?!

Ә м ә к. Акбирдин иптәш!

Ш ә м ә к. Сиңа йомыш бар.

Читтә ымлашып сөйләшәләр. Ә м ә к, Ш ә м ә к чыгып китәләр.

П о л е в о д. Иптәшләр, барыгыз да хәзер клубка, әйдәгез! Ударникларга бүләкләр өләшәбез!
Б а р ы с ы. Була, була ул!..

Шаулашып чыгалар. Акбирдин белән Фәридә калалар.

Ф ә р и д ә *(борчылып).* Акбирдин иптәш, китүең чынмы?
А к б и р д и н. Чын, Фәридә.
Ф ә р и д ә. Кире Уралга?
А к б и р д и н. Әйе.
Ф ә р и д ә. Күрсәң икән шул Уралны, күңелледер анда?
А к б и р д и н. Эш эчендә кайнаган дуслар булган һәр җирдә күңелле.
Ф ә р и д ә. Мин анда барырга теләсәм, миңа ничек булыр икән?
А к б и р д и н. Ничек?!
Ф ә р и д ә. Күңелле булырмы, дим?
А к б и р д и н. Анысы үзеңнән инде.
Ф ә р и д ә. Син ничек уйлыйсың?
А к б и р д и н. Нәрсә ничек?!
Ф ә р и д ә. Минем турыда.
А к б и р д и н. Синең турыңда?..
Ф ә р и д ә. Әйе.
А к б и р д и н. Ничек дип әйтергә... Ялгыз башыңа күңелсезрәк булуы да бар.
Ф ә р и д ә. Син анда булырсың бит.
А к б и р д и н. Әйе, әйе... Гөләндәм дә анда булыр төсле әле.
Ф ә р и д ә. Гөләндәм дә...
А к б и р д и н. Белмим тагы... Анысы инде аның үз эше.
П о л е в о д *(читтән кычкыра).* Акбирдин иптәш!..
А к б и р д и н. Хәзер!.. *(Китә.)*

Фәридә ялгызы кала.

Музыка.

Ф ә р и д ә.

Үткен саф җилдәй үтеп киттең,
Күрмичә калдым эзеңне.
Нигә соң, егетем, син өздең
Шат күңелемне?..

Данлы Уралның ташы төсле
Кырыс йөрәкле син булма,
«Кызыл йолдыз» кызын онытма!

Үткен саф җилдәй үткән төсле
Үтеп киттең син сузылып,
Яңгырлар көткән кырлар төсле
Калдым өзелеп…

Үпкәм юк сиңа, эшче егет,
Уңыш телим һәр эшеңдә,
Бер теләгем бар: тот исеңдә!..

IV. Акбирдин, бригадир, Гөләндәм.

Фәридә, тавыш ишетелү белән, клубка табан ашыгып китә.

Бригадир. Акбирдин иптәш, бу ничек була инде, аңлый алмыйм?

Акбирдин. Аңлашылмаслык бер эш тә юк. Карагыз аны, сынатасы булмагыз, тикшереп торачакмын.

Гөләндәм. Синең урында кем кала инде?

Акбирдин. Берничә кандидат бар. Кемне сайларсыз тагы?

Бригадир. Анысы алаен алай да, синең капыл гына китүең әллә ничегрәк?

Акбирдин. Килүем дә шулай иде ич.

Бригадир. Килүең яхшы булды, менә китүең шәп түгел. Без анда хәзер ударникларга бүләкләр бирәбез… Соңыннан сөйләшербез әле, Акбирдин иптәш. *(Китә.)*

V. Акбирдин һәм Гөләндәм.

Акбирдин. Ярый, ярый. Һәйбәт егет.

Гөләндәм. Кайчан китәм дисең?

Акбирдин. Иртәгә.

Гөләндәм. Тиз, бик тиз!

Акбирдин. Эшләрне бетереп, бүген төнлә киткәндә дә ярыйсы икән. Ләкин бер эш китүне иртәгә кичектерә.

Гөләндәм. Киткәндә дә эш!..

Акбирдин. Эш дигәнем, үз эшем.

Гөләндәм. Кызык!

Акбирдин. Кызык?!

Гөләндәм. Әйе, кызык. Синең дә үз эшең бармыни?

Акбирдин. Синең мәсьәлә, Гөләндәм.

Гөләндәм. Минем мәсьәлә булгач, ничек инде ул синең эшең була? Минемчә, син үз турыңда берәр эш эшләү түгел, уйлый да белмисеңдер.

Акбирдин. Ялгышасың.

Гөләндәм. Бәлки, шулайдыр. Эшләмәгән генә ялгышмый, диләр бит, Акбирдин иптәш.

Акбирдин. Дөрес. Йә Гөләндәм, уйладыңмы?

Гөләндәм. Уйладым.

Акбирдин. Йә?

Гөләндәм. Очына чыга алганым юк.

Акбирдин. Ялгышудан куркасыңмыни, ха-ха-ха!.. Эштә темп шәп булса да, үзең дә бу турыда бик сүлпән кымшанасың. Кара аны, кара тактага эләкмә.

Гөләндәм. Үземнең дә аптыравым җитте.

Акбирдин. Аптырарлык нәрсәсе бар соң? Кыюрак кына булырга кирәк. Кәҗә бәясе тормаслык кечкенә мәсьәлә бит ул.

Гөләндәм. Менә шул-шул... Синең шундый карашларың аптырата да мине. Син аңа кәҗә бәясе тормаслык кечкенә эш дип карыйсың, ә мин алай карый алмыйм... Булдыра алмыйм!..

Акбирдин. Сүз нихәтле сузылса, шулхәтле очына чыгу кыенлаша. Ударникларча темп белән, йә була, йә булмый, ачык әйтергә дә бетерергә. Болай да бер елдан бирле сузып килдең инде. Ярамый алай. Батыррак булырга кирәк. Йә, иртәгә Уралга бергә китәбезме?

Пауза.

Йә, китәбезме?.. Нигә дәшмисең?..

Гөләндәм. Тукта, уйларга бир.

Акбирдин. Тагын уйлау! Бу синең перманентлы уй булып китте, ә, ударникларча хәзер, раз-два... Бергә китәбезме?

Гөләндәм. Озатып кына калырмын, ахры.

Акбирдин. Һә, уйлый торгач, шулай булып чыктымыни?.. Шәп түгел.

Гөләндәм. Белмим.

Акбирдин. Минем өчен, дим.

Гөләндәм. Башым катты.

Акбирдин. Бик матур тормыш төзер идек, Гөләндәм. Мин заводта, син берәр фабрикка урнашып, яңа дөнья төзү фронтында өздерер идек. Эш кенә кешеләрне бер-берсенә якынлаштыра ала, эш кенә...

Гөләндәм. Менә шуннан куркам да.

Акбирдин. Эштәнме?!

Гөләндәм. Юк ла! Ничек кенә аңлатасы инде сиңа. Эшне мин үзем дә яратам... Ләкин синеңчә түгел.

Акбирдин. Сине яратмыйм, диген дә куй. Нигә сырт сукмаклар белән маташырга.

Гөләндәм. Юк, алай түгел.

Акбирдин. Алай да түгел, болай да түгел, соң ничек инде?

Гөләндәм. Тукта, сөйләп бетергәнне көт!

Акбирдин. Бер елдан бирле көтәм инде.

Гөләндәм. Тыңла!.. Син ут, Акбирдин, аңлыйсыңмы, ут... Ил өчен кирәкле, кадерле ут!..

Акбирдин. У-у-у!..

Гөләндәм. Менә шул утны сүндерүдән куркам.

Акбирдин. Иһи-һи!.. Уйлый торгач, йолдызларга үрмәли башлагансың син, ха-ха-ха!

Гөләндәм. Сөйләп бетергәнне көт!.. Бер уйлаганда, шул утны сүндерүдән курыксам, икенче уйлаганда, үземнең дә шул утта янып бетүемнән шикләнәм.

Акбирдин. Уйлый торгач, син мине бөтенләй бензинга әйләндергәнсең.

Гөләндәм. Мин чынлап сөйлим.

Акбирдин. Мин дә бик чынлап тыңлыйм да бит, төшенә алмыйм. Ут, пожар!..

Гөләндәм. Тукта!

Акбирдин. Уһу!..

Гөләндәм. Аның мәгънәсе болай: син бөтен җаның, тәнең белән эшкә бирелгән кеше, булдымы?

Акбирдин. Йә?

Гөләндәм. Син эшкә җан кертәсең, син аны бизисең. Эшли белгәнгә, син аны яратасың.

Акбирдин. Йә?

Гөләндәм. Синең алдыңда эштән дә зур, эштән дә күрекле, эштән дә артык бернәрсә дә, беркем дә юк...

Акбирдин. Бик әйбәт, синең белән тиңләшергә хакым бар дигән сүз.

Гөләндәм. Шуның аркасында минем читтә калуым да бар бит... Хатын-кыз күңеле бит ул... Калганын үзең аңла инде шунда.

Акбирдин. Син бу фикерне берәр начар китаптан алдыңмы, әллә үз башыңнан чыгарып саташасыңмы?

Гөләндәм. Саташам булырга кирәк.

Акбирдин. Һичшиксез шулай. Син уйлаганча бо-

лай булып чыга: үлчәүнең бер башында эш, икенчесендә гыйшык, уртасында син. Каян бу чүп-чарны җыйнадың?!

Гөләндәм. Үзем дә аптырыйм.

Акбирдин. Аптырыйсыңдыр шул. Синең әле башыңнан аталарың, бабаларың сөреме чыгып бетмәгән. Эшне, башкаларны яратуга караганда, үзеңне яратуың көчлерәк күренә. Һәр дәвердә, һәр заманда, һәр урында беренче сафта зур әмәлләрне тудыруга багышланган эш торырга тиеш. Чөнки шундый эш кенә кешеләрне бер-берсенә якынлаштыра, ул гына аларны оештыра. Синең бу фикерең — кәҗә бәясенә тормаган әкият. Яңа дөньяда әкиятләр белән торырга ярамый. Мөмкин түгел!.. Йә, иртәгә китәбезме?..

Гөләндәм *(бригадирны күреп).* Бригадир!.. Клубта күрешербез әле. Китапларыңны да шунда тапшырырмын.

VI. Әүвәлгеләр һәм бригадир.

Бригадир. Акбирдин иптәш, шулай, иртәгә үк китәргә булдыңмыни?

Акбирдин. Бүген төнлә китәрмен, ахры.

Гөләндәм. Бригадир!

Бригадир. Хәзер!.. Кара әле, минем турыда яңадан бер уйлашасы иде.

Акбирдин. Була.

Гөләндәм. Бригадир!..

Бригадир. Барам!..

Гөләндәм белән клубка кереп китәләр.

Акбирдин. Һә... Кызык... Кызыграк булып чыкты бу!.. *(Сызгыра.)*

Һилал күренә.

VII. Акбирдин, Һилал.

Һилал серле кыяфәттә бер яктан килеп чыга да басып тора.

Акбирдин. Һилал иптәш, бу ничек болай?..

Һилал. Шулай.

Акбирдин. Хәбәрсез-нисез!..

Һилал. Ярканатлар тынлыкны, караңгылыкны яраталар.

Электр фонаре кабына.

А-а-а!.. Бу барып чыккан, ахры.

Акбирдин. Үзгәрмәгәнсең күренә.

Һилал. Үзгәрдем. Бик нык үзгәрдем. Салма авыз булганмын мин монда чакта. Шуңа күрә синең... Ярый, анысы соңыннан. Күпер башы хәтереңдәме, Акбирдин?

Акбирдин, борчылып, сүзсез генә китмәкче була.
Һилал аркылы төшә.

Һилал. Күпер башы хәтереңдәме, дим?

Акбирдин. Балалар уенын истә тотарга вакытым булмады.

Һилал. Ышанам. Ә менә мин, башланган шул уенны төпләргә дип, тавыш-тынсыз гына кайттым.

Акбирдин. Анысы — синең эш... *(Китмәкче була.)*

Һилал *(каршы төшеп).* Тукта!.. Ни чәчсәң, шуны урырсың, дигән халык сүзе бар. Менә шул урак өстенә дип кайттым мин.

Акбирдин *(борчылып)*. Ни кирәк сиңа?..

Һилал. Әзерлән, хәзер белерсең... *(Кинәт чигенеп.)* Әй халык! Колхозчылар, картлар, яшьләр, комсомоллар — барыгыз да җыелыгыз...

Акбирдин. Син ни эшлисең?

Һилал. Хәзер белерсең!.. Бөтен халык, барлык колхозчылар аны белергә тиеш!.. Әй халык...

Халык җыела. Аптырашалар.

VIII. Әүвәлгеләр һәм халык.

Халык. Нәрсә бар, нинди тавыш?.. Һилал!..

Һилал. Әй сез, «Кызыл йолдыз» колхозчылары, ударниклары, тыңлагыз! Уф!.. Мин, сәяси сукырлыгым аркасында, монда чагымда дуслар белән дошманнарны яхшы аера алмаганмын. Мин, сезнең элекке Совет председателегез, хәзерге вакытта шәһәрдә китап фабрикасы эшчесе Һилал Әхмәдуллин, менә шушы газета оттискын кочаклап, шатлыклы бәйрәмегездә катнашып, шатлыгымны уртаклашыр өчен ашыктым. Бу хәбәр басылган газета сезгә иртәгә генә киләчәк, тыңлагыз!.. СССР Үзәк Башкарма Комитеты карары буенча, «Кызыл йолдыз» колхозына Ленин ордены бирелгән...

Халык *(гаҗәпләнеп).* Безгә?!

Акбирдин. Кая, кая?.. *(Газета оттискын карап.)* Иптәшләр, дөрес!.. «Кызыл йолдыз» колхозына, безгә, Ленин ордены, Ленин ордены!.. Ура, ура!..

Х а л ы к. Ура, ура, ура!..

Һилал белән Акбирдин кочаклашалар.
Музыка, утлар уйный, шатлык, яктылык.

Х о р.

Безнең байрак бөек, бөек.
Эш өстендә көн бизибез.
Колхоз, совхоз, завод, фабрик –
Нигезебез, үз илебез!..

П ә р д ә.

*1931 ел*

## ЭЧТӘЛЕК

Сакла, шартламасын!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Казан сөлгесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Зар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Американ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Сүнгән йолдызлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Җилкәнсезләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 309
Зәңгәр шәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 391
Хикмәтле доклад . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 455
Кандыр буе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 505

Литературно-художественное издание

**Тинчурин** Карим Галиевич

ПЬЕСЫ

Казань. Татарское книжное издательство. 2021

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Тинчурин** Кәрим Гали улы

ПЬЕСАЛАР

Төзүче-мөхәррире *Р. Г. Вәһапова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф. Р. Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, А. М. Закирова*

16+ Знак информационной продукции согласно
ФЗ от 29.12.2010 г. № 436 – ФЗ

Форматы 84х108 1/32. Шартлы басма табагы 30,66.

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http: // www.tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**

Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 51. Тел.: (843) 225-76-55.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

**Маркетинг бүлеге:**

Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

**Интернет-кибет:**

**http: // www.tatkniga.ru**